بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

# КЫЙССАСЕЛ-ӘНБИЯ,
## ягъни
# ПӘЙГАМБӘРЛӘР ТАРИХЫ

«РАННУР» НӘШРИЯТЫ

«ЮЛДАШ» ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ
«ДИН ВӘ ЙОЛА» ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

# КЫЙССАСЕЛ-ӘНБИЯ,
## ЯГЪНИ
# ПӘЙГАМБӘРЛӘР ТАРИХЫ

*Әсәрне басмага әзерләүче, Коръән Кәрим аятьләрен кертеп, аларны транскрипцияләүче, гарәп графикасындагы текстларны гамәлдәге язуга күчерүче, тиешле шәрехләр бирүче һәм кереш сүз авторы ТҖМДН Голәмалар шурасы сәркәтибе*
***Җәгъфәр** хәзрәт **Мөбарәк***

КАЗАН
«РАННУР» НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 2
ББК 86.38
К 90

«Юлдаш» газетасының баш мөхәррире
*Ранис Рәхимҗан улы Газизов* редакциясендә

**Джагфар хазрат Мубарак**
**Кыйссасел-анбия, или история пророков**
*(на арабском и татарском языках)*

Ошбу китапка инкыйлабка кадәр чыгарылган җиде авторның «Пәйгамбәрләр тарихы» китапларының иң ышанычлы, ягъни Коръән аятьләре белән дәлилләнгән өлешләре кертелде. Болар: «Кыйссасел-әнбия», авторы Насреддин бине Борһанеддин Рабгузи, мәтәрҗиме (тәрҗемәчесе) — Саләх ибн мулла Шәрәфеддин; «Тарих әнбия», төзүчесе — Габдулла Садыйк әл-Җаекый; «Кыйссасел-әнбия», төзүчесе — Әхмәт Җәүдәт; «Мухтасар тарих мүкаддәс», төзүчесе — Х. Зәбири; «Кыйссасел-әнбия әл-Газами вә Ислам тарихы», төзүчесе — Габдрахман Гомәри; «Адәм галәйһиссәламнән Мөхәммәд галәйһиссәламгә чаклы дәвер», төзүчесе — Й. Хәлили; «Кыйссасел-әнбия», төзүчесе — Мирза Мәхмүд әл-Казани китаплары файдаланылды.

Коръән Кәрим аятьләрендә исемнәре телгә алынган 28 пәйгамбәрнең һәммәсе китапка кертелде. Әлеге хезмәт пәйгамбәрләр тарихы белән кызыксынган һәркем өчен белем чыганагы булыр дип ышанып калабыз.

Җаваплы редакторы *Ранис Газизов*
Техник редакторы *Нурания Газизова*
Версткалаучы *Надежда Люстрицкая*
Җыючы *Сәвия Фәйзрахманова*
Бизәлеш редакторы *Фирая Газизова*
Корректоры *Гүзәлия Шакирҗанова*

Җәгъфәр Мөбарәк
**К 90** **Кыйссасел-әнбия, ягъни пәйгамбәрләр тарихы** — Казан: Раннур, 2003. — 304 б.

Җыярга тапшырылды 11.01.03. Басарга кул куелды 19.09.03. Форматы 60x84 1/16.
Югары сыйфатлы офсет кәгазе, 55 гр. «Прагматика» гарнитурасы. Офсет басмада.
Басма табагы 19. Заказ № 1968. Тиражы 50 000 данә.

«Раннур» нәшрияты. 420066, Казан, а/я 365. Тел.: 43-70-91.
Нәшрият эшчәнлегенә лицензия № 191 (19.06.97).

Отпечатано с готового оригинал-макета в ГУП РМЭ «Марийский полиграфическо-издательский комбинат» 424000, г. Йошкар-Ола, ул. Комсомольская, д. 112.

**ISBN 5-900049-27-2**
**© «Раннур» нәшрияты, 2003**

# КЕРЕШ СҮЗ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Әссәламүгаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ!

Мөхтәрәм мөселман кардәшләр!

Сезләргә бәхет-сәгадәт, җитәкчеләргә мәрхәмәт, Ислам дөньясында яшәп киткән рәсүлләрнең тәрҗемәи хәлләрен яктыртучыларга бәрәкәт телим. Пәйгамбәрләр тарихын тирәнтенрәк белергә теләүчеләр илә араларыбыздагы мөнәсәбәтләр тагын да ныгысын. Хак Тәгалә телләребезгә йомшаклык, күңелләребезгә пакьлек, иманнарыбызга ныклык бирсен. Күңелләребезгә, өйләребез-гаиләләребезгә, барча галәмгә Аллаһы Җәнабел Хак муллык вә сәгадәт насыйп әйләсен. Изге ният вә изге теләкләр илә китабыбызны хөрмәтле укучыларыбызга тәкъдим итәбез. «Пәйгамбәрләр тарихы» китабын төзүдә, әлбәттә, Аллаһы Тәгаләнең Коръән Кәрим китабы вә дәхи сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһиссаләтү вәссәламнең хәдис-шәрифләре төп чыганак булды. Бу ике төп чыганактан башка, инкыйлабка кадәр чыгарылган кыйссалар файдаланылды: «Тарихы әнбия», Казан, 1895, Домбровский нәшриятында басылган, мөәллифе (төзүчесе) Габдулла Садыйк әл-Җаекый; «Кыйссасел-әнбия», Казан, 1914, Харитонов нәшриятында басылган, мөәллифе Әхмәд Җәүдәт; «Кыйссасел-әнбия әл-Газаим вә тәрҗемәтел-әхвәл вә дәверел-Ислам», Казан,1910, Харитонов нәшриятында басыла, мөәллифе Габдрахман Исмәгыйль бән Гомәр әл-Әстерхани; «Кыйссасел-әнбия әл-Газами вә Ислам тарихы», Әстерхан, 1901, мөәллифе Габдрахман Исмәгыйль бән Гомәр әл-Әстерхани; «Адәм галәйһиссәламнән Мөхәммәд галәйһиссәламгә чаклы дәвер», Казан, 1908, Ермолаев нәшриятында басылган, мөәллифе Й. Хәлили; «Кыйссасел-әнбия галәйһимус-сәлам», Казан, 1900, мөәллифе Мирза Габдулла Мәхмүд әл-Казани; «Мухтасар тарих мүкаддәс», Казан, 1910, Кәримиләр нәшриятында басылган, мөәллифе Х. Зәбири; шулай ук төп чыганак булып Рабгузиның 1914 елда Казанда матбагаи Кәримиядә басылган «Кыйссасел-әнбия» китабы (мәтәрҗиме (тәрҗемәчесе) имам Саләх ибн мулла Шәрәфеддин) хезмәт итте. Имам Саләх ибн Шәрәфеддин үзенең искәрмәләрендә:«Бәгъзе урыннары ислях (килештерү) илә әһле Ислам вә Казан лөгатенә әүли (өстен күреп) тәрҗемә кылынды», — дип язып куйган. Кем соң ул Насреддин бине Борһанеддин Рабгузи?

Насреддин бине Борһанеддин Рабгузиның тормышы турында мәгълүматлар сакланмаган. Бары тик тәхәллүсенә (псевдонимына) карап кына, аның Хәраземдәге Рабат Угыз дигән җиргә нинди дә булса нисбәте бардыр, дип уйларга мөмкин. Безнең көннәргә әдипнең 1311 елда язып тәмамланган «Кыйссаи Рабгузи» исемле кита-

бы гына килеп җиткән, ул «Кыйссасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихы») дип тә атала. Автор аны Алтын Урда түрәләреннән берсе булган Тукбуга исемле кешегә багышлаган. Бу китапның XV–XIX йөзләрдә һәм аннан соң күчерелгән дистәләрчә нөсхәләре Казан, Санкт-Петербург, Уфа, Ташкент һ.б. шәһәрләр китапханәләрендә, төрле коллекцияләрдә саклана.

«Кыйссасел-әнбия» китап булып беренче мәртәбә 1859 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыккан. Кыйссада дини вә дөньяви хикәяләр еш кына үзара үрелеп биреләләр. «Кыйссасел-әнбия»дәге вакыйгалар Шәрыкның борынгыдан ук яһүд-гарәп-фарсы халкы арасында сөйләнеп йөргән, аннан соң башка халыкларга күчкән риваять вә хикәятләрдән төзелгән. Ә андагы «Йосыф кыйссасы»н исә Рабгузи үзе үк шул чордагы язма чыганакларга, аерым алганда, «Тәфсир» китабына, Әбү Нишпуриның «Кыйссасел-әнбия»сенә, Шәех Хәсән Басрига, Габдулла бине Габбаска һәм башкаларга таянып язганлыгын искәртә. Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» әсәре белән беррәттән, башка авторлар да кыйсса әсәрләре иҗат итәләр. Әлеге җыентыкларның исемнәрен алдарак әйтеп киткән идек инде. Соңгы вакытта археографик экспедицияләр вакытында татар халкы арасында шундый кыйссаларның байтак кульязмасы табылды.

Кемнәр соң алар пәйгамбәрләр? Пәйгамбәр — Аллаһы Тәгаләнең хөкемнәрен, әмерләрен, хәбәрләрен, тыюларын бәндәләргә тапшыру өчен Үзе белән бәндәләре арасында арадашчы сыйфатында җибәрелгән вә әхлакның барлык гүзәллекләренә ия булган гадәттән тыш заттыр. Бәндәләрнең иң бөек, иң изге, иң акыллы, иң алдан күрүчән вә дәхи иң белемле булганнары — пәйгамбәрләрдер. Аларның барчасы да Аллаһының рәхмәте илә сайланып күндерелгән бөек шәхесләрдер. Иң беренче инсан вә тәүге пәйгамбәр — Адәм галәйһиссәлам. Шуңа күрә дә яратылышыннан башлап тереклек дөньясында асыл зат булган инсанның төп чыгышы да Адәм галәйһиссәламнән килә. Мәгълүмдер ки, безнең асылыбыз Адәм галәйһиссәлам, Хәва радыйаллаһу ганһә — җәннәттән килгән чиста затлар. Бу турыда Коръән Кәримнең «әл-Әгъраф» сүрәсе, 189 нчы аятендә болай диелгән:

هُوَ الَّذِي خَلَقَكُم مِّن نَّفْسٍ وَاحِدَةٍ وَجَعَلَ مِنْهَا زَوْجَهَا لِيَسْكُنَ إِلَيْهَا فَلَمَّا تَغَشَّاهَا حَمَلَتْ
حَمْلًا خَفِيفًا فَمَرَّتْ بِهِ فَلَمَّا أَثْقَلَت دَّعَوَا اللَّهَ رَبَّهُمَا لَئِنْ آتَيْتَنَا صَالِحًا لَّنَكُونَنَّ مِنَ
الشَّاكِرِينَ ١٨٩

«Һүәлләзии халәкакүм миннәфсин үәәхидәтин үә җәгәлә минһәә зәүҗәһәә лийәскүнә иләйһә. Фәләммәә тәгашшәәһәә хәмәләт

хәмлән хафиифәң фәмәррат биһ. Фәләммәә әскаләт дәгәүәл-лааһә раббәһүмәә ләин әәтәйтәнәә саалихәл-ләнәкүүнәннә минәш-шәәкириин (189)».

Мәгънәсе: *«Аллаһы Тәгалә сезне бер Адәм галәйһиссәламнән халык кылды вә Адәмнең сул кабыргасыннан хатыны Хәваны бар итте, ул Хәва илә Адәмнең күңеле карар тапсын өчен. Кайчан Адәм Хәва белән якынлык кылды исә, Хәва җиңел йөкле булды, һәм йөк белән йөрде. Йөге авырайгач, Адәм вә Хәва икәүләп тәрбиячеләре булган Аллаһы Тәгаләгә дога кылдылар: «И, Раббыбыз, әгәр безгә бер яхшы бала бирсәң, әлбәттә, шөкер итүчеләрдән булыр идек (189)».*

Хак Тәгаләнең пәйгамбәрләре түбәндәге сыйфатларга ия:

1. СЫЙДДИКЪ: Пәйгамбәрләр тугрылыклы. 2. ӘМАНӘТ: Алар һәрнәрсәдә иминлеккә баралар һәм үзләренә ышаныч уяталар. 3.ТӘБЛИГЪ: Алар Аллаһы Тәгаләнең әйткәннәрен кешеләргә һич кимчелексез тапшыралар. 4. ФӘТӘХӘТ: Алар бик зирәк. 5. ГЫЙСМӘТ: Алар гөнаһ эшләрдән тәмам сакланалар.

Безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһиссаләтү вәссәламнең тагын биш сыйфаты аны бүтән пәйгамбәрләрдән аерып тора: 1. Бөтен пәйгамбәрләрдән өстендер. 2. Ул барлык кешеләрне вә җеннәрне иманга өндәр өчен җибәрелгән. 3. Пәйгамбәрләр теземенең иң азагыдыр. Аннан соң пәйгамбәр килмәячәк. 4. Ул барча галәмнәргә Пәйгамбәр итеп җибәрелгән. 5. Шәригате кыяматкә кадәр дәвам итәчәк.

Адәм галәйһиссәламнән башлап Пәйгамбәребезгә кадәр бер риваятьтә 124 мең, икенче риваятьтә 224 мең пәйгамбәр килгән диелә. Боларның 28е генә Коръән Кәримдә әйтелгән. Телгә алынган пәйгамбәрләрнең мөбарәк исемнәре: Адәм, Идрис, Нух, Һуд, Салих, Лут, Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб, Йосыф, Әюб, Шөгаиб, Муса, Һарун, Дауд, Сөләйман, Юныс, Ильяс, Әльясәгъ, Зөлкифел, Зәкәрия, Яхъя, Гайсә вә Мөхәммәд галәйһис-саләтү вәссәлам.

Гөзәер, Локман, Зөлкарнәен хәзрәтләренең исемнәре дә Коръән Кәримдә мәзкүрдер. Ләкин аларның пәйгамбәр булулары ачык мәгълүм түгелдер. Вә дәхи Шис, Юшагъ, Хозыр, Бишер, Даниял, Ышмуил, Ашгия, Әрмия исемле пәйгамбәрләр хәдисләрдә бәян кылынган.

Иң соңгы пәйгамбәр — Мөхәммәд галәйһиссәлам, Ул — ахырзаман Пәйгамбәре. Аннан соң җиһанга һич пәйгамбәр килмәячәк. Иң әүвәлге пәйгамбәр Адәм галәйһиссәламнән, иң соңгы пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһиссәламгә чаклы килгән Ислам диненең нигезе кыямәт көненә кадәр һич үзгәрәчәк түгел. Бу турыда Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримнең «әл-Гыймран» сүрәсе, 19 нчы аятендә болай дигән:

إِنَّ الدِّينَ عِندَ اللَّهِ الْإِسْلَامُ ١٩

«Иннәддиинә гиндәллааһил-исләәм (19)».

М ә г ъ н ә с е : *«Аллаһы Тәгалә каршында мәкъбүл булган (хак булган, хупланган) дин — Ислам дине (19)».*

Ислам дине нинди дин ул? Бу сорауга җавапны Коръән Кәримнең «әл-Гыймран» сүрәсе, 137 нче аятендә табабыз, анда болай диелгән:

قد خلت من قبلكم سنن فسيروا فى الارض فانظروا كيف كان عاقبة المكذبين ❀ ١٣٧

«Кад халәт миң кабликүм сүнәнүң фәсийруу фил әрдый фәңзуруу кәйфә кәәнә гәәкыйбәтүл-мүкәззибиин (137)».

М ә г ъ н ә с е : *«Дөреслектә, сездән алдагы кешеләргә дә Хак Тәгалә Ислам динен генә өйрәткән иде. Аллаһы Тәгаләгә итагать иткән кешеләр хак диндә вә туры юлда булдылар. Әмма нәфескә яки шайтанга ияргән кешеләр, төрле фиркаләргә бүленеп, адашу юлында булдылар. Ничек кенә яшәсәләр дә, алар дөньядан үтеп киттеләр. Җир өстендә йөрегез вә күрегез, ялганчыларның хәле ничек булды? (137)».*

Пәйгамбәрләр — Аллаһы Тәгаләнең инсаниятькә Ислам юлын күрсәтү, аларның бәхетле вә сәламәт яшәүләрен тәэмин итү өчен җир йөзенә җибәрелгән илчеләре. Үзенең бәндәләренә дин хөкемнәрен өйрәтмәк өчен Хак Тәгалә вакыт-вакыт пәйгамбәрләр җибәрмештер. Шулай итеп, инсан өчен иң гүзәл җәүһәр булган акылны бәндәләргә тик бер Үзе генә җиткермәвенә ишарә иткән кебек, могҗиза белән коралландырылган пәйгамбәрләрен дә җибәреп, Раббыбыз без инсаннарга шул пәйгамбәрләренә ияреrгә тиеш булуыбызны да аңлата. Ул пәйгамбәрләр һәркайсы Сөбханә вә Тәгалә сайлаган кавемнәндер. Аларның туганда ук пәйгамбәрлек сыйфатлары була. Алар бик күркәм табигатьле, бик гакыллы вә зирәк, татлы сүзле булмышлардыр. Җәнабел Хак Үзенең Җәбраил исемле фәрештәсе аркылы инсаннарга Ислам дине хөкемнәрен җибәреп, шул хөкемнәр аша аларны хак дингә вә изге гамәлләргә өндәргә боермыштыр. Шуннан соң пәйгамбәрләр Аллаһы Тәгаләнең әмере буенча инсаннарны хак дингә вә изге гамәлләргә өндәмешләрдер. Бу турыда Коръән Кәримнең «ән-Ниса» сүрәсе, 163–164 нче аятьләрендә болай диелгән:

انا اوحينا اليك كما اوحينا الى نوح والنبيين من بعده واوحينا الى ابرهيم واسمعيل واسحق
ويعقوب والاسباط وعيسى وايوب ويونس وهرون وسليمن واتينا داود زبورا ❀ ١٦٣
ورسلا قد قصصنهم عليك من قبل ورسلا لم نقصصهم عليك وكلم الله موسى تكليما ❀ ١٦٤

«Иннәә әү хәйнәә иләйкә кәмәә әү хәйнәә иләә Нүүхин үәннәбийинә мимбәгди.Үә әү хәйнәә иләә Ибрааһиимә үә Исмәәгиилә үә Исхәәка үә Йәгъкуубә үәл-әсбәәтый үә Гиисәә үә Әййүбә үә Йүүнүсә үә Һәәруунә үә Сүләймәән. Үә әәтәйнәә Дәәүдә Зәбүүра (163). Үә русүләң каде касаснәәһүм галәйкә миң каблү үә русүләлләм нәкъсусһүм галәйкә.Үә күлләмәл-лааһү Мүүсәә тәклиим (164)».

Мәгънәсе: «...*Сиңа вәхи иңдердек. Нухка һәм аннан соң килгән пәйгамбәрләргә вәхи иңдергән кебек, Без Ибраһимга, Исмәгыйльгә, Исхакка, Ягъкубка, Гайсәгә, Әюбкә, Юныска, Һарун белән Сөләйманга вәхи иңдердек; Даудка Зәбур исемле китап иңдердек (163). Без сиңа синнән алда килгән кайбер пәйгамбәрләр турында сөйләдек, сиңа хәбәр итмәгәннәрне дә пәйгамбәр итеп җибәргән идек, һәм чыннан да, Аллаһы Тәгалә Муса белән турыдан-туры сөйләште (164)*».

Пәйгамбәрләрнең, дин-шәригать хөкемнәрен өйрәтү өчен адәм балаларының үз араларыннан сайланып, Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән вәхи белән кадерләнгән, хөрмәтләнгән илчеләр икәнлеген ошбу аяти кәримәләрдән күрдек. Аларның төп вазыйфалары — инсаннарга өсләренә йөкләтелгән нәрсәләрне белдерү вә шул эшләрне җиренә җиткерү хакында аларны Ислам диненә димләү вә дәхи туры юлга күндерү. Хосусан, инсаннарның бәхет вә сәгадәткә ирешүләре өчен тырышуларыдыр. Пәйгамбәрләр — изге гамәлләр бәрабәренә савап булу белән сөенеч бирәләр вә яман гамәл бәрабәренә газап булачагын белдерәләр. Адәм балалары күтәрә алырлык вә аңларлык кадәр генә гаиб галәмнән дә, ягъни күзгә күренмәгән дөньядан да хәбәрләр ирештерәләр. Яхшылык илә бәндәләрне иманга өндиләр, ягъни авырайтмыйча гаделлеккә күндерәләр-үгетлиләр. Сөбханә Газзә вә Җәллә инсаннарны бик камил итеп яратты, аларга гакыл нигъмәте бирде. Дөньяда гомер сөрү юлларын белдерде, якында вә еракта булганнар илә аңлашу өчен сөйләшергә тел нигъмәтен бирде вә дәхи язуга өйрәтте. Шундый камиллек илә хайваннардан өстен булган инсаннар арасыннан пәйгамбәрләр җибәрелүгә бер дә гаҗәпләнерлек урын юк. Һәрхәлдә, инсаннар арасында галәм гыйлемнәре илә бәйле кәсеп итүгә хаклы затларның пәйгамбәрләр булуын инкарь итү урынсыз бер үзсүзлелек вә бернинди дә дәлилгә таянмаган бер дәгъвадыр.

Әйтеп киткәнебезчә, пәйгамбәрләр, рәсүлләр вә нәбиләрнең саннары да, кайсы тарихларда вә дәхи кайсы кавемнәргә, дөньяның кайсы кыйтгаларында халыкларга җибәрелүләре хакында да мәгълуматлар бик аз. Без инде иң әүвәлге пәйгамбәр Адәм галәйһиссәлам вә ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһис-салату вәссәлам булганы хәлдә һәммәсе хак дип икътикад кылабыз. Пәйгамбәрләрнең рухлары һәрвакыт Җәнабел Хактан ярдәм табып торадыр вә Аллаһы Тәгаләнең зикере вә фикере илә ләззәт-

ләнәдер. Аллаһының чын пәйгамбәрләренең сүзләре вә фигыльләре һәммәсе дә дөрес булып, алар ялган сөйләүдән арынганнар. Тоткан юллары дөрес булуга һәммә хәлләре шаһәдәт бирәдер. Газзә вә Җәлләнең боерыкларын пәйгамбәрләр дөрес хәлләрендә, аз гына да үзгәртмичә, инсаннарга ирештерергә тиешләр. Шулай ук ачу саклау, курку, артык саклану кебек нәрсәләр булу ихтималы һич тә булмас. Һәрхәлдә, чын пәйгамбәрләрнең изге вә Хак Тәгалә тарафыннан сайланган инсаннар булып, үз хезмәтләрендә кимчелек итүләре мөмкин түгел. Гакыл никадәр камил булса да, киләчәктә, ахирәттә булачак мәңгелек тормышта өстенлек кемнәрдә булачагын аңлатып, дөрес юлдан алып баручыларга бәндәләр мохтаҗлар. Пәйгамбәрләр шул юлны күрсәтүче хезмәтен үтәүчеләр, алар үз юлларын ачык белә торган юлбашчылар булып, гавам халкын ияртеп баручылар. Барлык яктан камил вә ышанычлы бер инсанның Аллаһы Тәгаләнең хак пәйгамбәре булуына ачык билгеләр вә ышанычлы дәлилләр булуы вә гакыл камиллеге — башкалардан өстен торуы, вазыйфасын башкаруда Хак Тәгаләдән башкадан ярдәм сорауга ихтыяҗы булмавы, дөнья рәхәтлекләренә бирелмәве вә туры юлдан аерылмавыдыр. Сәламәт гакыл илә Аллаһы Тәгаләнең барлыгын вә берлеген тану, аны аңлау мөмкин булса да, ахирәт көнен тасвирлау өчен сәламәт гакыл гына җитми, бәлки бу турыда хәбәр бирүчегә ихтыяҗ зур. Димәк, адәм балаларын тәрбия кылу өчен Хак Тәгалә тарафыннан вәхи иңдерелүгә дә пәйгамбәрләр, рәсүлләр вә нәбиләр җибәрелүгә дә ихтыяҗ бик зур иде. Ул дәверләрдә инсаннарның хәлләре шул дәрәҗәдә түбән иде ки, үзләре ясап куйган сыннарны тәңре дип, шуңа сәҗдә кылалар иде.

Газиз кардәшләрем! «Пәйгамбәрләр тарихы» китабын төзүдә төп чыганак Аллаһы Тәгаләнең Коръән Кәриме вә дәхи сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһис-саләтү вәссәламнең хәдис-шәриф китаплары булуы сәбәпле, ошбу мөбарәк китабыбыз Ислам дине тарихы белән кызыксынучы мөгаллимнәр һәм хәзрәтләребез өчен вәгазь-нәсыйхәт китабы булырга муафыйк итеп эшләнде. Гарәп имлясы илә язылган Коръән Кәрим аятьләренең вә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам хәдис-шәрифләренең, укырга җиңел булсын өчен, кириллица хәрефләре белән укылышлары (транскрипциясе) да өстәлде. Әмма кириллица хәрефләре илә язып, аяти кәримәләрнең төгәл укылышларын биреп бетереп булмый. Шуның өчен бу язылышларның дөрес укылуын тик берәр мөгаллим ярдәмендә генә үзләштереп була. Кулыгыздагы ошбу «Пәйгамбәрләр тарихы» китабында Аллаһы Тәгаләнең сүзләре вә дәхи Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең хәдисшәрифләре булганга, аны җиргә ташламаска һәм дә хөрмәтсезлек күрсәтмәскә тиеш икәнлекне искәртәбез.

*Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк. 19 гыйнвар, 2003 ел.*

# ДӨНЬЯ ЯРАТЫЛУЫ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Хисапсыз мактау вә макталу кодрәтле Аллаһы Тәгаләгә генә хастыр. Хәбәрдә килә, Аллаһы Тәгалә күкләрне, җирне, фәрештәләрне, җеннәрне вә Адәм галәйһиссәламне бар кылды.

«Әл-Әнбия» сүрәсе, 30 нчы аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтә:

أَوَلَمْ يَرَ الَّذِينَ كَفَرُوٓا أَنَّ السَّمٰوٰتِ
وَالْأَرْضَ كَانَتَا رَتْقًا فَفَتَقْنٰهُمَا ۖ وَجَعَلْنَا مِنَ الْمَآءِ
كُلَّ شَىْءٍ حَىٍّ ۖ أَفَلَا يُؤْمِنُونَ ﴿٣٠﴾

«Әүәләм йәраллләзиинә кәфәруу әннәс-сәмәәүәәти үәл-әрда кәәнәтәә раткаң фәфәтакънәәһүмә. Үә җәгәлнәә минәл-мәәи күллә шәйин хәйи. Әфәләә йүәминүүн (30)».

Мәгънәсе: *«Җир белән күкләр бергә кушылган иделәр, Без аларны аердык вә һәртөрле терек иясен судан чыгардык»*.

«Фуссыйләт» сүрәсе, 11 нче аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтә:

ثُمَّ اسْتَوٰىٓ إِلَى السَّمَآءِ وَهِىَ دُخَانٌ فَقَالَ لَهَا وَلِلْأَرْضِ
ائْتِيَا طَوْعًا أَوْ كَرْهًا قَالَتَآ أَتَيْنَا طَآئِعِينَ ﴿١١﴾

«Сүммәс-тәүәә иләс-сәмәә-и үә һийә духаанүң фәкааләләһәә үә лил-әрдыйэтийәә таугән әү кәрһә. Каалэтәә әтәэнәә тааигиин (11)».

Мәгънәсе: *«Соңра күкне бар кылырга теләде, ул вакытта күк төтен иде, күккә вә җиргә теләп яки теләмичә: «Миңа итагать итегез, ягъни Мин әйткәнчә булыгыз!» — диде. Алар әйттеләр: «Йә, Рабби, теләп, үз ихтыярыбыз белән баш иябез», — диделәр.*

Күк йөзе төтен-газдан гына тора иде. Аллаһы Тәгалә күкне җирдән аерып, һәрберсен үз урынына урнаштырды, күк белән

җир Аллаһы Тәгаләгә буйсынып яшәргә ант бирделәр. Коръән Кәримдә шулай ук күкләрнең җиде катлы булуы хакында «Фуссыйләт» сүрәсе, 12 нче аятендә әйтә:

فَقَضَىٰهُنَّ سَبْعَ سَمَٰوَاتٍ فِي يَوْمَيْنِ وَأَوْحَىٰ فِي كُلِّ
سَمَاءٍ أَمْرَهَا وَزَيَّنَّا السَّمَاءَ الدُّنْيَا بِمَصَٰبِيحَ وَحِفْظًا
ذَٰلِكَ تَقْدِيرُ الْعَزِيزِ الْعَلِيمِ ﴿١٢﴾

«Фәкадааһүннә сәбгә сәмәәүәәти фии йәүмәйни үә әүһәә фии күлли сәмәә-ин әмраһә. Үә зәййәннәс-сәмәә-әддүнйәә бимәсаабиихә үә хифза. Зәәликә тәкъдиирул-гәзиизил-гәлиим (12)».

М ә г ъ н ә с е : *«Күкләрне җиде кат итеп ике көндә төзеп тәмам кылдык, вә һәр күк халкына үзенең әмерен вәхи илә аңлаттык, вә дөнья күген йолдызлар илә зиннәтләдек, вә шайтаннарның фәрештәләрнең сүзләрен тыңлап урлауларыннан, атылучы йолдызлар илә сакладык, бу әйтелгәннәр һәр эштә җиңүче, вә һәрнәрсәне белүче Аллаһы Тәгалә эше (12)».*

«Ән-Нәзигать» сүрәсе, 30 нчы аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَالْأَرْضَ بَعْدَ ذَٰلِكَ دَحَىٰهَا ﴿٣٠﴾

«Үәл-әрда бәгдә зәәликә дәхәәһә (30)».

М ә г ъ н ә с е : *«Моннан соң Аллаһы Тәгалә, торырга яраклы итеп, җирне йомыркасыман итеп түшәде (30)».*

«Фуссыйләт» сүрәсе, 53 нче аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтә:

سَنُرِيهِمْ ءَايَٰتِنَا فِي الْآفَاقِ وَفِي أَنفُسِهِمْ حَتَّىٰ يَتَبَيَّنَ لَهُمْ
أَنَّهُ الْحَقُّ أَوَلَمْ يَكْفِ بِرَبِّكَ أَنَّهُ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ شَهِيدٌ ﴿٥٣﴾

«Сәнүриииһим әәйәәтинәә фил-әәфәәкый үә фии әңфүсиһим хәттәә йәтәбәййәнә ләһүм әннәһүл-хәкко. Әүәләм йәкфи бираббикә әннәһү гәләә күлли шәйин шәһииде (53)».

М ә г ъ н ә с е : *«Безнең кодрәтебезгә вә берлегебезгә дәлаләт иткән ачык вә көчле галәмәтләребезне, бөтен галәм төзелешенең хәлләреннән кешеләргә күрсәтербез, вә кешеләрнең яратылышы Аллаһы Тәгаләнең эше икәнлеген үзләренең төзелешләреннән күрсәтербез, хәтта Аллаһы Тәгаләнең хаклыгы һәм бер генә икәнлеге вә Коръән Аллаһы Тәгаләнең китабы вә Мөхәммәд галәйһиссәлам Хак Тәгаләнең Рәсүле икәнлеге ачыкланганга чаклы. Әллә һәрнәрсәгә шаһит булырга синең Раббың җитмиме? (53)».*

Аллаһы Тәгалә башта, уттан яралтып, Үзенә гыйбадәт кылу өчен, җир йөзенә җен кавемен җибәрде.

# АДӘМ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

«Әлхәмдү лилләәһи раббил гәәләмиин.Үәссаләәтү үәссәләәмү гәлә расүүлиһи үә гәлә алиһи үә әсхәәбиһи әҗмәгиин. Әттайибиинәт-таһириин. Үә гәлә мәң тәбегәһем би-әхсәни илә йәүмиддиин».

«Барлык галәмнәрне юктан бар кылып һәм анда булган барлык мәхлукларын тәрбия кылучы вә кыямәт көненең хуҗасы Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә барлык мактау-олуглауларыбыз булса иде. Һәм безләргә Ислам дине кануннарын вә дәхи безләрне Коръән Кәрим белән гамәл, гыйбадәт кылырга өйрәткән, барча галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһиссәламнең рух шәрифенә, әһле бәйтенә, барча сәхабә кирамнарына һәм аларга кыямәт көненә кадәр изгелектә иярүчеләргә дә чын күңелдән чыккан дога вә сәламнәребез, туктаусыз салават шәрифләребез булса иде».

Галәмдә Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләдән башка һичнәрсә юк иде. Мәгәр бер Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә бар иде. Җәнабел Хак Үзенең кодрәтен вә солтанатын күрсәтте. Барча мәхлукларны алты көндә яралтты. Бу турыда Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә Үзенең мөбарәк китабы Коръән Кәримнең «Каф» сүрәсе, 38 нче аятендә болай ди:

وَلَقَدْ خَلَقْنَا السَّمٰوٰتِ وَالْاَرْضَ وَمَا بَيْنَهُمَا فِى سِتَّةِ اَيَّامٍ وَمَا مَسَّنَا مِنْ لُغُوبٍ ۝٣٨

«Үә ләкаде халәкънәс-сәмәәүәәти үәл әрда үә мәә бәйнәһүмәә фии ситтәти әййәәмин үә мәә мәссәнәә миллүгуубе (38)».

Мәгънәсе: *«Дөреслектә, яраттык Без күкләрне вә җирне, вә дәхи бу күк илә җир арасында булган нәрсәләрне алты көн эчендә, аларны төзегәндә Безгә бернинди дә мәшәкать вә авырлык булмады (38)».*

Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә якшәмбе көн — күкләрне, дүшәмбе көн — ай вә йолдызларны, сишәмбе көн барча җан-

лы мәхлукларны яралтты, чәршәмбе көн дәрья вә балыкларны, дәхи дә агачлар вә кураларны, вә дәхи үләннәрне яралтты, пәнҗешәмбе көн — оҗмах вә тәмугны, рәхмәт фәрештәләрен вә дәхи газап фәрештәләрен, җомга көн Адәм галәйһиссәламне яралтты вә дәхи барча мәхлукларның ризыкларын яралтып өләште, шимбә көн — һичнәрсә дә яралтмады. Бу хакта Җәнабел Хак Коръән Кәримнең «Юныс» сүрәсе, 3 нче аятендә болай ди:

ان ربكم الله الذى خلق السموت والارض فى ستة ايام ثم استوى على العرش
يدبر الامر مامن شفيع الا من بعد اذنه ذلكم الله ربكم فاعبدوه افلا تذكرون ۞ ٣

«Иннә раббәкүмүл-лааһүлләзии халәкас-сәмәәүәәти үәл әрда фии ситтәти әййәәмиң сүммәстәүәә гәләл гарш. Йүдәббирул әмр. Мәә миң шәфиигин илләә мим бәгди изниһ. Зәәликүмүллаһү раббүкүм фәгбүдү. Әфәләә тәзәккәруун (3)».

Мәгънәсе: *«Дөреслектә, сезнең Раббыгыз җир вә күкләрне алты көндә тәмам итте, соңра игътибарын гарше әгъляга (күкнең иң югары катламы) юнәлтте, бөтен галәм белән җитәкчелек иткән хәлдә. Ахирәттә шәфәгать итүче булмас, мәгәр Аның рөхсәте соңында гына булыр. Ошбу эшләрне кылучы Раббыгыз — Аллаһ, Аңа гына гыйбадәт кылыгыз! Әллә сез Коръән Кәрим илә вәгазьләнмәссезме? (3)».*

Аллаһы Тәгалә иң әүвәл җир йөзенә уттан җен кавемен яратты. Алар да Аллаһы Тәгаләгә Аның фәрештәләре кебек көн вә төннәрен гыйбадәт кылып үткәрәләр иде. Бу турыда Коръән Кәримнең «Җен» сүрәсе, 1–2 нче аятьләрендә болай диелә:

بسم الله الرحمن الرحيم ۞ قل اوحى الى انه استمع نفر من الجن فقالوا انا
سمعنا قرانا عجبا ۞ ١ يهدى الى الرشد فامنا به ولن نشرك بربنا احدا ۞ ٢

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Күль үхийә иләййә әнәһүс-тәмәгә нәфәрум-минәл җинни фәкаалүү иннәә

сәмигнәә Куръәәнән гаҗәбә (1). Йәһдии иләр-рушди фәәәмәннәә биһи үәлән-нушрикә бираббинәә әхәде (2)».

Мәгънәсе: *«Әйт: «Миңа вәхи кылынды, Аллаһы Тәгаләдән хәбәр бирелде, дөреслектә, миннән җеннәрдән бер таифә Коръән укуны тыңладылар, ул җеннәр үз кавемнәренә барып сөйләделәр: «Тәхкыйк, без гаҗәп моңлы Коръән укыганны ишеттек! (1). Әлбәттә, ул Коръән туры юлга күндеручедер. Без ул Коръәнгә иман китердек, Раббыбызга һичкемне тиңдәш кылмабыз», — дип (2)».*

Кайчан бу җеннәр, Хак Тәгаләнең боерыгын үтәмичә, җир өстен төрле фасикъ (азгын, бозыклык) илә тутыра башладылар, Аллаһы Тәгалә аларны юк итәр өчен җиргә фәрештәләр җибәрде, алар җеннәрнең күпчелеген юк иттеләр, тик иман китергәннәре вә дәхи тау куышларына, төрле ярыкларга качып ятканнары гына исән калдылар.

Аллаһы Тәгаләнең фәрештәләре җир йөзеннән үзләре белән җиде кат күккә кечкенә генә бер шайтан баласын алып мендeләр. Бу — Иблис иде. Күктә аңар Газазил дигән исем бирделәр, олуг хөрмәтләр күрсәттеләр, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә аңа җәннәткә керергә рөхсәт бирде. Иблис фәрештәләр кебек үк һәрдаим Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләне мактап гел гыйбадәттә булды. Үзенең тырышлыгы һәм Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте илә фәрештәләр белән гыйлем серләрен өйрәнде. Соңыннан фәрештәләргә гыйлем өйрәтүче булды. Теләсә — күккә, теләсә, оҗмахка сәфәр кылыр иде. Бәлкем бу гел шулай дәвам итәр иде, Аллаһы Тәгалә фәрештәләренә: «Мин җир йөзенә хәлифә яратырмын», — диде. Фәрештәләр кайгылы булдылар вә әйттеләр: «Дөньяда фасикъ вә фәсад, вә кан коючы яратырсыңмы? Без Сиңа тәсбих вә хәмед итәбез вә һәрдаим олуглыйбыз». Сөбханә вә Тәгалә аларга: «Сез белмәгәнне Мин беләмен», — диде. Бу турыда Коръән Кәримнең «әл-Бәкара» сүрәсе, 30–34 нче аятьләрендә әйтелә:

وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَٰٓئِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ

فِي الْأَرْضِ خَلِيفَةً قَالُوٓا أَتَجْعَلُ فِيهَا مَن يُفْسِدُ فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَآءَ وَنَحْنُ نُسَبِّحُ

بِحَمْدِكَ وَنُقَدِّسُ لَكَ قَالَ إِنِّىٓ أَعْلَمُ مَا لَا تَعْلَمُونَ ۝٣٠ وَعَلَّمَ ءَادَمَ ٱلْأَسْمَآءَ كُلَّهَا ثُمَّ عَرَضَهُمْ
عَلَى ٱلْمَلَٰٓئِكَةِ فَقَالَ أَنۢبِـُٔونِى بِأَسْمَآءِ هَٰٓؤُلَآءِ إِن كُنتُمْ صَٰدِقِينَ ۝٣١ قَالُوا۟ سُبْحَٰنَكَ لَا عِلْمَ
لَنَآ إِلَّا مَا عَلَّمْتَنَآ إِنَّكَ أَنتَ ٱلْعَلِيمُ ٱلْحَكِيمُ ۝٣٢ قَالَ يَٰٓـَٔادَمُ أَنۢبِئْهُم بِأَسْمَآئِهِمْ فَلَمَّآ أَنۢبَأَهُم
بِأَسْمَآئِهِمْ قَالَ أَلَمْ أَقُل لَّكُمْ إِنِّىٓ أَعْلَمُ غَيْبَ ٱلسَّمَٰوَٰتِ وَٱلْأَرْضِ وَأَعْلَمُ مَا تُبْدُونَ وَمَا
كُنتُمْ تَكْتُمُونَ ۝٣٣ وَإِذْ قُلْنَا لِلْمَلَٰٓئِكَةِ ٱسْجُدُوا۟ لِءَادَمَ فَسَجَدُوٓا۟ إِلَّآ إِبْلِيسَ أَبَىٰ وَٱسْتَكْبَرَ
وَكَانَ مِنَ ٱلْكَٰفِرِينَ ۝٣٤

«Үә из кааләраббүкә лилмәләәикәти инниии җәәгилүн филәрдый хаалифә. Каалүү әтәҗгәлү фииһәә мәй-йүфсиду фииһәә үә йәсфикүд-димә. Үә нәхнү нүсәббиху бихәмдикә үә нүкаддисү ләкә. Каалә инниии әгләму мәә ләә тәгләмүүн (30). Үә гәлләмә әәдәмәл-әсмәә-ә күлләһәә сүммә гәрадаһүм гәләлмәләәикәти фәкаалә әнбиүнии биәсмәә-и һәәүләәи иң күңтүм саадикыййн (31). Каалүү сүбхәәнәкә ләә гилмәләнәә илләә мәә гәлләмтәнә. Иннәкә әңтәл-гәлиимүл хәкиим (32). Каалә йәә әәдәмү әңбиһүм биәсмәәиһүм. Фәләммә әңбәәһүм биәсмәәиһим каалә әләм әкул ләкүм инниии әгләму гайбәссәмәәүәәти үәл әрдый үә әгләму мәә түбдүүнә үә мәә күңтүм тәктүмүүн (33). Үә изкульнәә лил-мәләәикәтисҗүдү лиәәдәмә фәсәҗәдү илләә Иблиис. Әбәә үәстәкбәра үә кәәнә минәлкәәфириин (34)».

Мәгънәсе: *«һәм әйтте синең Раббың фәрештәләргә: «Мин җир өстенә хәлифә итеп Адәмне кылмакчымын. Фәрештәләр әйттеләр: «И, Раббыбыз! Бозыклык кылучы, сугышып кан түгүче затны җир өстенә хәлифә кыласыңмы? Без исә Сине мактап тәсбихләр әйтәбез һәм Сине һәр кимчелектән пакьсең дип игътикад кылабыз». Хак Тәгалә фәрештәләргә: «Дөреслектә, Мин сез белмәгәннәрне беләмен», — диде (30). Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламгә исемнәрнең барчасын өйрәтте дә фәрештәләргә әйтте: «Әгәр дөрес сөйләүчеләрдән*

*булсагыз, Адәм белгән исемнәрнең барчасын әйтеп бирегез» (31). Фәрештәләр әйттеләр: «И, һәр кимчелектән пакь булган Раббыбыз! Бездә һич белем юк, мәгәр Син белдергәнне генә беләбез, Син, әлбәттә, һәрнәрсәне белүче, хикмәт белән эш кылучысың» (32). Җәнабел Хак Адәм галәйһиссәламгә: «Фәрештәләргә Мин өйрәткән исемнәрнең барчасын әйтеп бир», — дип әйтте. Адәм галәйһиссәлам исемнәрнең барчасын әйтеп биргәч, Хак Тәгалә фәрештәләргә: «Мин сезгә әйтмәдемме җирдәге вә күкләрдәге яшерен нәрсәләрне беләмен һәм сезнең дә ачык вә яшерен эшләгән эшләрегезне дә беләмен дип? (33). Хөрмәт йөзеннән Адәм галәйһиссәламгә сәҗдә кылыгыз!» — дип фәрештәләргә әйткән вакытымда, алар сәҗдә кылдылар, мәгәр Иблис кенә сәҗдә кылмады, тәкәбберләнде һәм кяферләрдән булды (34)».*

Аллаһы Тәгалә әйтте: «И, Иблис! Мин сиңа Адәм галәйһиссәламгә сәҗдә кылырга әмер иткәч, сине сәҗдә кылудан нинәрсә тыйды?» Иблис әйтте: «Мин аңардан артыграк, чөнки мине уттан яраттың, Адәмне балчыктан яраттың».

Ничәмә-ничә еллар Аллаһы Тәгалә хозурында тугры хезмәт иткән, көн-төн Аны мактап гыйбадәт кылган, иң тирән гыйлем серләрен өйрәнгән Иблис, тәкәбберләнеп, Аллаһы Тәгалә кушканны үтәмәде. Бу тәкәбберлеккә карата Хак Тәгаләнең хөкеме «әл-Хиҗер» сүрәсенең 34–37 нче аятьләрендә әйтелә:

قَالَ فَاخْرُجْ مِنْهَا فَاِنَّكَ رَجِيمٌ ۝٣٤ وَاِنَّ عَلَيْكَ اللَّعْنَةَ اِلَى يَوْمِ الدِّينِ ۝٣٥

قَالَ رَبِّ فَاَنْظِرْنِي اِلَى يَوْمِ يُبْعَثُونَ ۝٣٦ قَالَ فَاِنَّكَ مِنَ الْمُنْظَرِينَ ۝٣٧

«Каалә фәхруҗ миңһәә фәиннәкә раҗиим (34). Үә иннә гәләйкәл-ләгнәтә иләә йәүмиддин (35). Каалә рабби фәңзирнии иләә йәүми йүбгәсүүн (36). Каалә фәиннәкә минәлмүңзариин (37)».

М ә г ъ н ә с е : *«Аллаһы Тәгалә әйтте: «Алай булса, син җәннәтемнән чык! Фәрештәләрдән булма, хәзер син ләгънәт кылындың вә рәхмәтемнән сөрелдең! (34). Тәхкыйк, сиңа кыямәт көненә кадәр Минем ләгънәтем булачак» (35). Иблис әйтте: «Йә, Рабби, миңа мәхшәр көненә кадәр дөньяда яшәргә*

*рөхсәт бир» (36). Аллаһы Тәгалә әйтте: «И, Иблис, сиңа мәхшәр көненә чаклы яшәргә рөхсәт бирелде (37)».*

Аллаһы Тәгаләне безгә караганда күп мәртәбәләр яхшырак белгән, Аның фәрештәләре белән бергә гыйбадәтләр кылган Иблис Хак Тәгаләнең бер әмерен үтәмәве аркасында кяферләр дәрәҗәсенә төшерелде, мәлгунь исемен алды, кыямәт көненә кадәр ләгънәтле, ахирәттә мәңгелек тәмуглык булды. Бу гыйбрәттән шуны әйтергә була, кемнәр белә торып Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәми, алар Иблис мәлгунь белән бергә мәңгелек тәмугта булачаклар.

Җәнабел Хак Иблис мәлгуньне җәннәттән сөрде, ә Адәм галәйһиссәламне җәннәткә кертте. Газзә вә Җәллә хәзрәти Адәмгә иптәш итеп аның сул як кабыргасыннан хәзрәти Хәваны яратты. Җәбраил фәрештә аларга никах хөтбәсен укыды. Аллаһы Тәгалә: «И, Адәм, үзең вә хатының Хәва белән җәннәтемдә торыгыз һәм теләгән урыннан барча җимешләрне ашагыз, әмма ошбу богъдай агачының җимешен ашамагыз, әгәр ашасагыз, залимнәрдән булырсыз», — дип әйтте.

Иблис мәлгунь атабыз Адәм галәйһиссәлам һәм анабыз Хәвага бик үчле булды. Аларның ябык гаурәтләрен ачмак өчен вәсвәсә кылды вә әйтте: «Аллаһ сезнең фәрештә булуыгызны вә дәхи җәннәттә мәңге калуыгызны теләмәгәне өчен ошбу богъдай агачының җимешен тыйды, дөреслектә, мин сезгә яхшылык кына телим», — дип ант итте. Аларны алдап, богъдай агачы янына алып килде. Иблис мәлгуньнең шулай матур итеп сөйләвенә алданып, алар ошбу тыелган агачның җимешен ашадылар, гаурәтләре ачылды, җәннәт агачының яфрагы белән гаурәтләрен капларга ашыктылар, аларга Раббылары ачуланып: «Мин сезне ошбу агачның җимешләрен ашаудан тыймадыммы? Вә дәхи шайтан сезнең ачык дошманыгыз, аннан сакланыгыз, дип әйтмәдемме?» Адәм галәйһиссәлам вә хәзрәти Хәва әйттеләр: *«И, Раббыбыз! Иблис мәлгуньгә ышанып, үзебезгә золым кылдык, әгәр безне ярлыкамасаң вә дәхи рәхмәтеңнән ташласаң, әлбәттә, без бәхетсезләрдән булачакбыз».* Аллаһы Тәгалә әйтте: *«И, Адәм илә Иблис, бер-берегезгә дошман булганыгыз хәлдә Җиргә иңегез! Сезгә торачак урын вә әҗәлегезгәчә файдаланачак җай — Җирдә. Шунда тереклек итәрсез һәм Җирдә үләрсез, вә дәхи вакыты җиткәч, Җирдән чыгарылырсыз»,* — диде.

Монда сорау туа: нишләп соң әле Аллаһы Тәгалә атабыз Адәм галәйһиссәламне вә анабыз Хәваны кяферләр белән бер дәрәҗәгә куеп тәмуглык итмәде? Җавап: Адәм галәйһиссәлам вә Хәва радыйаллаһу ганһә, үзләренең ялгышканнарын белеп, тәүбә-истигъфар һәм дога кылдылар. Җәнабел Хак аларның тәүбәсен кабул кылды. Ә Иблис мәлгунь кылган гөнаһы өчен тәүбә кылырга уйламады да, шуңа күрә мәңге тәмуглык булды.

Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламне фәрештәләрдән аермалы буларак яратты. Фәрештәләр бөек Раббыбызны гел тәсбих итеп торалар. Фәрештәләрдә, ирлек вә хатынлык сыйфатлары булмаган кебек, гөнаһ эшләү сәләте дә юк.

Ләкин адәм балалары алай түгел. Алар Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылырга, изгелекләр эшләргә яратылган булсалар да, асылларында гөнаһ эшләү мөмкинлеге һәм үзенчәлеге дә бар. Адәм балалары үзләрен юктан бар кылган бөек Раббыларына карата һәрдаим коллык вазыйфаларын җиренә җиткереп үтәп бетермиләр, күп очракта аларга нәфесләре хуҗа була вә аларны начар юлга алып кереп китә. Адәм балаларына яхшылык вә начарлык эшләү үзенчәлеген бирүче, әлбәттә, бөек Аллаһ Үзедер. Димәк, инсан дигән барлыкны бер дә гөнаһ эшләмәслек фәрештәләр дәрәҗәсенә җиткерү мөмкин түгел. Болай уйлау бөек Раббыбызның идарәсенә каршы килү булыр иде. Һәр балигъ булган һәм камил гакыллы кеше гамәлдә дә, фикердә дә мөстәкыйль зат. «Язмыштан узмыш юк» дигән әйтем дөреслеккә туры килми, чөнки һәр кеше тормыштагы юлны үзе сайлый, яхшы юлны сайласа, әлбәттә, киләчәге бәхетле булачак, яман юлны сайласа — үзенә дә, гаиләсенә дә гел бәхетсезлекләр киләчәге дә мәгълүм. Югарыда әйтелгәннәрдән аңлашылганча, адәм балаларының гөнаһ эшләве, хата ясавы табигыйдыр. Биредә иң мөһиме шул: инсанның үзенең хата ясавын, гөнаһ эшләвен таный белүе, вә дәхи шунда ук, тәүбә итеп, Раббысыннан гафу үтенүе. Тәүбә исә дога вә истигъфар белән, вә дәхи яхшы, гүзәл эшләр белән ителер. Адәм балалары тормышының һәр мизгеле Аллаһы Тәгаләнең ярдәме һәм күзәтүе астында булганга күрә, моны истә тотарга кирәк.

Аллаһы Тәгалә ошбу җиһанда яшәгән вакытта тәүбә кылучының зур гөнаһларын да кичерергә мөмкин. Кыямәт көнендә

исә тәүбәләр кабул ителмәс. Монда инде гамәл дәфтәре язмышны хәл итәр. Иблис мәлгунь дөньяда чакта үзенең барлык көчен вә тырышлыгын туры юлдан баручыларны аздыру өчен кулланыр. «Әл-Әгъраф» сүрәсе, 27 нче аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтә:

يَٰبَنِىٓ ءَادَمَ لَا يَفْتِنَنَّكُمُ ٱلشَّيْطَٰنُ كَمَآ أَخْرَجَ أَبَوَيْكُم مِّنَ ٱلْجَنَّةِ يَنزِعُ عَنْهُمَا لِبَاسَهُمَا
لِيُرِيَهُمَا سَوْءَٰتِهِمَآ إِنَّهُۥ يَرَىٰكُمْ هُوَ وَقَبِيلُهُۥ مِنْ حَيْثُ لَا تَرَوْنَهُمْ إِنَّا جَعَلْنَا ٱلشَّيَٰطِينَ
أَوْلِيَآءَ لِلَّذِينَ لَا يُؤْمِنُونَ ٢٧

«Йәәбәнии әәдәмә ләә йәфтинәннәкүмүш-шәйтаанү кәмәә әхраҗә әбәүәйкүм минәл җәннәти йәңзигү гәнһүмәә либәә сәһүмәә лийүрийәһүмәә сәү-әәтиһим. Иннәәһүү йәраакүм һүвә үә кабилүһүү мин хәйсү тәраү нәһүм. Иннәә җәгәлнәш-шәйәәтыййнә әүлийәә-ә лилләзиинә ләә йүәминүүн (27)».

Мәгънәсе: *«И, адәм балалары! Ата-анагызны җәннәттән чыгарган кеби, шайтан сезне фетнәгә салмасын, аларның киемнәрен салдырып, гаурәтләрен үзләренә күрсәтер өчен, аларны алдады. Дөреслектә, шайтан һәм аның гаскәре сезне күрәләр, сез аларны күрмәгән урыннан. Әлбәттә, ышанмаучыларга шайтанны дус кылдык (27)».*

Иблис токымын, ягъни аңа иярүчеләрне, аңа хезмәт итүче гаскәрне халык арасында шайтан, җен, пәри, албасты, йорт иясе, сихерче һ. б. исемнәр белән атыйлар.

Җәннәттән сөрелгәч, Иблис мәлгунь һәр җирдә кешеләрне туры юлдан аздырып йөри башлый. Әлбәттә, кешеләрне аздыру буенча ул зур тәҗрибә туплаган, үзе белгән бозыклыкны үз кавеменә өйрәтә. Шундый тәҗрибәле шайтанга каршы тору өчен адәм балаларына аның йомшак якларын белергә кирәк, ягъни нинди юллар белән ул адәм балаларын үзенә ияртә һәм шуңа каршы нинди киртәләр корырга була?

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә, шайтанга вә аның гаскәренә каршы корал итеп, дин вә шәригать хөкемнәрен бәян кылып, пәйгамбәрләренә 104 китап иңдерде. Пәйгамбәрләр шул китаплардагы хөкемнәр белән кавемнәрне иманга вә изге гамәлләргә өндәделәр. Ошбу китаплардан атабыз Адәм га-

ләйһиссәламгә 10 кәгазь, Шис галәйһиссәламгә 50 кәгазь, Идрис галәйһиссәламгә 30 кәгазь, Ибраһим галәйһиссәламгә 10 кәгазь килүе риваятьләрдә вә хәдисләрдә хәбәр ителә. Вә дәхи Муса галәйһиссәламгә Тәүрат исемле китап, Дауд галәйһиссәламгә Зәбур исемле китап, Гайсә галәйһиссәламгә Инҗил исемле китап, соңгы пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһиссәламгә Коръән исемле китап иңдерелде. Ул Коръән Кәрим китабы әүвәлге китапларның кайсыбер хөкемнәрен мәнсух кыла, ягъни ул заман халкының табигатенә муафыйк рәвештә иңдерелгән. Коръән Кәримдә адәм балаларының дөньялары өчен дә, ахирәтләре өчен дә кирәкле булган хөкемнәр бар. Моннан башка шайтан вә аның гаскәренә каршы торырлык безнең зур коралыбыз — пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең хәдис-шәрифләре бар.

Безнең бу фани тормышыбызда ике юл бар: беренчесе — Аллаһы Тәгалә һәм Аның рәсүле күрсәткән юл, икенчесе — Иблис мәлгунь тарафыннан бизәлгән, әмма бу бозык юл. Бу юл, әлбәттә, туры тәмугка алып бара. Аллаһы Тәгаләнең Коръән Кәримендә күрсәткән туры юлы исә мәңгелек җәннәткә илтә. Җәннәткә кергән бәхетле бәндәләр өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан барлык уңайлыклар әзерләнгән, биредә картлык, авырулар, куркулар, кайгылар берсе дә юк. Монда кергәннәр мәңге рәхәттә яшәрләр. Гакылы камил булган адәм баласы җәннәтне тәмугка бервакытта да алыштырмас.

Без биредә шуны күрәбез: Җәнабел Хак адәм балаларын бервакытта да ташламады, аларга дин-шәригать хөкемнәрен бәян кылып, пәйгамбәрләренә китаплар җибәреп торды, пәйгамбәрләр исә шул китаплардагы хөкемнәр илә гамәлгыйбадәт кылдылар, үз кавемнәрен иманга өндәделәр. Кылган гөнаһлары өчен тәүбә-истигъфар кылырга вә изге гамәлләргә өндәделәр. Бәгъзе адәм балалары: «Нәрсә соң ул тәүбә-истигъфар?» — дип сорарга мөмкиннәр. Адәм балалары — изге вә гөнаһ эшләргә сәләтле булган бер барлык дип, алда әйтелгән иде. Бу Адәм галәйһиссәламнән бирле шулай килә. Бәндәнең Аллаһы Тәгалә каршындагы изге эшләре аны эшләү белән арта. Шулай ук Җәнабел Хак гөнаһ эшләгән бәндәсен гөнаһ дәрьясында бер ялгызын гына калдырмый. Ул, бәндә гөнаһ эшли дип, рәхмәт ишекләрен һич-

бер вакытта да япмас, һәрвакыт ачык тотар. «Әл-Бәкара» сүрәсенең 160 нчы аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Тәүбә итеп, рухларын пакьләп, дөресен сөйләгән кешеләр гөнаһлардан аерылып торалар. Аларның тәүбәләрен кабул, гөнаһларын да гафу итәрмен. Мин ихлас күңелдән кылынган тәүбәләрне шунда ук кабул итәрмен (160)».

Адәм галәйһиссәлам кылган гөнаһлары өчен ихлас күңелдән тәүбә иткәч, Аллаһы Тәгалә «ән-Ниса» сүрәсенең 17 нче аятендә болай ди: «Шунысы да бар, наданлык илә бер гөнаһ эш эшләп, тиз генә тәүбә итеп, гөнаһларыннан ваз кичеп, ихлас күңелдән тәүбә итүчеләрнең тәүбәсен Аллаһы Тәгалә кабул итәр (17)».

Сөбханә вә Тәгалә атабыз Адәм галәйһиссәламне Һиндстанның Цейлон утравына, анабыз Хәваны Гарәп ярымутравының Җиддә тавына төшергәннән соң, алар, бу хәлләренә үкенеп, кайнар күз яшьләрен койдылар һәм ошбу доганы укыдылар: «Раббәнәә заләмнәә әңфүсәнәә үә илләм тәгъфирләнәә үә тәрхәмнәә ләнәкүнәннә минәл-хасириин».

Мәгънәсе: *«И, Раббыбыз! Без үзебезгә золым кылдык, әгәр безне кичермәсәң һәм кызганмасаң, без мәңге кайгыда булырбыз».*

Бик күп еллардан соң Хак Тәгаләнең рәхмәте илә Адәм галәйһиссәлам белән Хәва радыйаллаһу ганһә очраштылар, бик сөенделәр. Аллаһы Тәгаләгә шөкрана кылдылар.

Адәм галәйһиссәлам уяулы-йокылы вакытында Хәва радыйаллаһу ганһәнең яратылуында хикмәт бармы? Риватьләргә караганда, Адәм галәйһиссәлам оҗмахта әүвәл йөзем, инҗир, хөрмә һәм без белмәгән, күрмәгән җимешләрне ашаганнан соң, оҗмах нигъмәтләренә иялләнеп, хуш исле чәчәкләр арасында йөрер иде. Ләкин ялгыз булды, шул сәбәпле аңарда Аллаһы Тәгаләдән бер зат сорарга дигән фикер туды. Шул вакыт күзенә йокы төште, уяулы-йокылы яткканда, сул ягындагы югары кабыргасыннан Хәва радыйаллаһу ганһә яратылды. Әгәр дә уяу вакытында яратылса, Адәм галәйһиссәламнең тәне авыртыр иде. Каты йокы вакытында яратылса, Хәва радыйаллаһу ганһәне белмәс вә сөймәс иде, шуңадыр инде Хәва радыйаллаһу ганһә Адәм галәйһиссәламнең уяулы-йокылы вакытында яратыла.

Адәм галәйһиссәлам Хәваның үзеннән яратылганын белде, йокыдан күзен ачты, Хәва радыйаллаһу ганһәне күрде, күңеленә мәхәббәт төште. Хәва бик матур иде, буе Адәм галәйһиссәлам кебек, күзләре кара төстә, бик саф тавышлы, Адәм галәйһиссәламнең тавышыннан нечкәрәк. Йөз толым итеп үргән чәче бар, аларга оҗмах энҗеләре һәм якутлары үрелгән иде. Хак Сөбханә вә Тәгалә матурлыкны йөз өлештә яратты, туксан өлешен Хәва радыйаллаһу ганһәгә бирде. Ун өлешен янә йөз өлешкә бүлеп, туксан тугызын Йосыф пәйгамбәргә, берсен барча галәм халкына бирде. Әмма гөнаһларга шәфкатьче, галәмнәр Раббысының сөеклесе, Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вәссәламнең матурлыгы вә нуры бу йөз өлеш матурлыктан башкадыр. Бу йөз өлеш матурлык Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам нурына караганда, дәрьядагы бер тамчы кебек иде. Дәхи Адәм галәйһиссәлам һәм хәзрәти Хәва радыйаллаһу ганһә оҗмах, тәмуг, күк, җир, гареш, көрси, ләүхелмәхфуз (тәкъдир тактасы), каләм, фәрештәләр Мөхәммәд галәйһиссәламнең хөрмәтенә юклык дөньясыннан бар кылынды. Бу хәдис-көддесидә бәян ителә, Аллаһы Тәгалә: «Әй, хәбибем Мөхәммәд, син булмасаң, җир вә күкләрне яралтмас идем», — дип әйтә.

Адәм галәйһиссәлам үз алдында гүзәл Хәва радыйаллаһу ганһәне күрде, якын килергә теләп, аңа кулын сузды. Шул вакытта Җәбраил галәйһиссәлам: «Әй, Адәм, кулыңны сузма, Хәва синең өчен яратылса да, никахсыз кул сузу дөрес түгел. Хак Тәгаләдән Хәваны хәләл җефетлеккә сора», — диде. Адәм галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләдән сорады һәм Хак Тәгалә аларга никах хөтбәсен укыды.

Хөтбә укылганнан соң оҗмахта тордылар, төрле ләззәтле җимешләр белән нигъмәтләнделәр. Богъдай агачыннан гына сакландылар.

Ни сәбәпле Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламне Адәм дип, Хәва радыйаллаһу ганһәне Хәва дип атады? Хәбәрләрдән килә, Адәм галәйһиссәламнән фәрештәләр сорадылар: «Ни сәбәпле син Адәм дип аталдың?» «Җир йөзеннән яратылганым өчен», — диеп җавап бирде. Адәм сүзе «әдим» сүзеннән алынган, «әдим» — җир йөзе димәктер. Хәвадан: «Ни өчен Хәва дип аталдың?» — диеп сорагач: «Кабыргадан яратылганым өчен шулай аталдым», — диеп җавап бирде.

Газазилны тәкәбберлеге өчен Аллаһы Тәгалә ләгънәт кыла. Газазил бөек дәрәҗәләргә иреште: бик күп гыйбадәтләр кылды, фәрештәләрне укытты, вәгазьләде. Мәҗлесләренә, вәгазьләренә шулкадәр күп фәрештәләр килер иде, хисабын Аллаһы Тәгаләдән башка беркем белмәде. Шул сәбәпле Газазил: «Гыйлемдә, гыйбадәттә миңа тиңдәш юк, әгәр Хак Тәгалә хәлифлекне миннән башкага тапшырса, гыйбадәт кылмаячакмын», — диеп уйлады. Шул вакыт фәрештәләр ләүхелмәхфуздан: «Аллаһы Тәгаләгә якыннардан булган бәндә, Аның ачуына кереп, ләгънәт кылынды», — дигәнне ишеттеләр. «Без шул фәрештә булмыйк», — диеп Газазилдан дога кылуын үтенделәр. Газазил: «И, Раббым! Фәрештәләрне бу ачудан, бу ләгънәттән сәламәт кыл», — дип дога кылды. Камил тәкәбберлегеннән үзен искә төшерергә күңеленә килмәде. Бу аңа сынау булып, ул аны үти алмыйча, Аллаһы Тәгаләнең ачуына дучар булды. Мең ел җирдә һәм күктә сәҗдә кылган урыныннан башын күтәргәннән соң, «Иблискә ләгънәт булсын» дигән язуны күрде.

Ни өчен Коръән Кәримдә дүрт фәрештәнең исеме генә зикер ителә? Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә: «Барчагыз да Адәмгә сәҗдә кылыгыз!» — дип әмер кылды. Иң беренче булып Җәбраил галәйһиссәлам сәҗдә кылды, аннан соң Микаил галәйһиссәлам, аннан соң Исрафил галәйһиссәлам, аннан соң Газраил галәйһиссәлам, аннан соң барча фәрештәләр сәҗдә кылдылар. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Мин адәм балаларын хөрмәтләдем».

Җәбраил галәйһиссәлам беренче сәҗдә кылганы өчен Хак Тәгалә аны пәйгамбәрләргә вәхи иңдерүче итеп билгеләде. Бәндәләрнең ризык хәзинәсе ачкычын Микаил галәйһиссәламгә бирде. Исрафил галәйһиссәламне кыямәт көнен белдерүче, сур хуҗасы итеп куйды. Газраил галәйһиссәламне фани дөньядагы дусны ахирәттәге дус белән кавыштыручы итеп билгеләде. Калган фәрештәләргә кешеләрне уттан һәм башка афәтләрдән саклау, кылган гамәлләрен язып бару вазыйфасы йөкләнде. Газазил тәкәбберлеге вә баш имәве белән Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән ераклашты, ләгънәт кылынды.

Элек фәрештәләр һәм җеннәр кешеләргә күренеп йөргәннәр, алар белән сөйләшкәннәр. Яхъя ибн Мөгаз әйтте: «Хаҗга сәфәр кылганда, беркая кермичә туры Мәккәи Мөкәррәмә

тарафына көн вә төн бардым. Төннәрнең берсендә каты тавыш ишеттем. Бу нинди тавыш икән дип уйлап, шул тавыш килгән тарафка юнәлдем. Анда бер ир кеше бик каты елый иде. «Ник елыйсың?» — дидем. «Мин еламый, кем еласын. Барча фәрештәләргә остаз булу, оҗмах, җир, күк минем ихтыярымда иде. Җирдә, күктә никадәр гыйбадәт кылдым. Ахырда Аллаһы Тәгалә гыйбадәтемне җилгә очырып, рәхмәтеннән өметсез булып, ләгънәт кылды», — диде. Моның Иблис икәнен белдем. «Син ни өчен сәҗдә кылмадың?» — дип сорадым. Иблис әйтте: «Дөрестән дә мин сәҗдә кылмадым, Аллаһының боерыгын тотмадым. Әмма Адәм дә богъдай агачыннан ашап, Хак Тәгаләнең боерыгын тотмады. Аллаһы Тәгалә миңа кылган газапны аңа да кылырга тиеш иде. Адәмнең гөнаһысын кичерде, минем гөнаһымны кичермәде», — диде. «Адәмне ни өчен кичерде, әмма сине кичермәде?» — дип сорадым. Ул: «Хак Тәгалә Адәмгә мәңгелектәге тәкъдирдә ярдәм итте, миңа кылмады», — дип җавап бирде.

Аллаһы Тәгаләнең Адәм галәйһиссәламне кичереп, Иблисне кичермәвендә нинди хикмәт бар?

Адәм галәйһиссәламнең гөнаһысы онытылып, хаталык беләнбулды. Коръәндә: «Онытты, шуңа аңа гөнаһ булып саналмады» аяте моңа дәлил булып тора. Әмма Иблиснең гөнаһысы көнчелектән, максаты — Аллаһы Тәгаләгә каршы килү иде. «Тәкәбберләнде һәм кяферләрдән булды» аяте дә моңа ишарә булып тора.

Ни өчен хатын-кызларда хәез вакытында кан килә һәм ни өчен хәезнең иң киме өч көн, ә иң күбесе ун көн булды? Риваятьтә килгәнчә, Хәва богъдай агачын сындыргач, агач елады,ботагыннан кан төсле нәрсә акты. Шул сәбәптән хатыннардагы хәез авыруы кыяматкә кадәр мирас булып калды. Бу риваятьтә золымлыкның зарарына ишарә ясала. Хәва анабыз җансыз агачны сындыруы сәбәпле, балаларына кыяматкә кадәр хәез авыруы мирас булып калды. Әй, кардәш! Һәр кыйссадан гыйбрәт ал, золымыннан саклан. Золым үзеңә, балаларыңа афәт китерәчәк. Иблис золым кылып Адәм галәйһиссәламне оҗмахтан чыгаруга сәбәп булганлыгы өчен ләгънәткә, мәңге тәмугта калуга дучар булды. Нинди зур хөрмәттән михнәткә төште. Гафил булма!

Ни өчен хәезнең иң киме өч көн, ә иң күбесе ун көн дигәндә, Хәва радыйаллаһу ганһә богъдайга аягы белән барды, кулы

белән тотып сындырды, авызы белән ашады. Бу өч сәбәптән хәезнең иң киме өч көн булды. Богъдай агачына җиткәнче ун адым атлады, шуңа күрә хәезнең иң күбесе ун көн булды. Янә агачка җиткәнче кырык мәртәбә сулыш алды, кырык көн нифас күргә сәбәп булды. Ягъни озак кан күрүләре сәбәпле, үзләренең хаталарын искә төшереп, тыелган нәрсәләрдән саклансыннар өчен бирелде.

Адәм галәйһиссәлам белән Хәва радыйаллаһу ганһә богъдай агачының җимешен ашагач, ялангач калалар, кайсы агач аларны кызганып, гаурәтләрен капларга яфрагын бирә?

Адәм галәйһиссәлам белән Хәва радыйаллаһу ганһәнең башыннан таҗ, өсләреннән хөлләләре төшкәч, берсенең күзенә ялангач гаурәтләре ачык итеп күренде, гаурәт каплау өчен бер агачтан икенче агачка яфрак эзләп йөгерделәр. Агач саен сорадылар, бер агач та яфрак бирмәде. Мәгәр тин, ягъни инҗир агачы гына дүрт яфрагын бирде. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Адәм белән Хәва гаурәтләрен каплар өчен оҗмахтан яфрак алдылар». Адәм галәйһиссәлам, оятыннан уфтанып, агач саен йөрде. Йөзем агачы Адәмне чәченнән тотты. Адәм галәйһиссәлам: «Җибәр мине, китим», — диде. Йөзем агачы: «Җибәрмимен, мин Аллаһы Тәгаләнең әмере белән сине тоттым. Әгәр җибәрсәм, синең кебек гөнаһлы булырмын», — диде. Йөзем агачы Хак Тәгаләнең боерыгын үтәгәне өчен хуш исле булды.

Адәм галәйһиссәламнең йөзем агачына эләгүе белән Аллаһы Тәгаләдән хитаб кылынды, Коръән Кәримдә әйтелә: «Бездән качасыңмы, йә, Адәм?» Әйтте: «И, Раббым, Синнән оялуымнан качамын, зинһар, коткар мине, коткар». Аллаһы Тәгаләдән хитаб кылынды: «Син кайда, йә, Адәм?» Адәм галәйһиссәлам: «Мин монда тоткын, үзем ялангач, агач ботагында бәладә калдым», — диде. Аллаһы Тәгаләдән хитаб кылынды: «Әй, Адәм! Кайгы вә хәсрәтеңә гөнаһың сәбәптер». Моннан соң Хак Тәгалә инҗир агачына: «Ни өчен Адәмгә яфрак бирдең?» — диде. Инҗир агачы гозер кылып: «И, Раббым! Адәмнең гөнаһысын күрдем, ләкин аңа әүвәл кылган хөрмәтләрең күз алдымнан китмәс иде», — диде. Хак Тәгалә боерды: «Бу шәфкатең өчен сиңа берничә кәрамәт бирәм, барча агачлар әүвәл чәчәк күрсәтеп, аннан соң җимеш бирерләр, син чәчәктән элек җимеш бирерсең», — диде.Башка кәрамәтләрне «Бәхрү дирар» тәфсиреннән укырга мөмкин.

Аллаһы Тәгаләнең боерыгын тотмаганы өчен Адәм галәйһиссәламгә ун бәла бирелә, ә Хәва радыйаллаһу ганһәгә унбиш бәла бирелә. Имам Сәгъләби үзенең «Гараис» исемле китабында әйтә: «Аллаһы Тәгаләнең боерыгын тотмаган өчен Адәм галәйһиссәламгә ун бәла бирелде: беренчесе, Аллаһы Тәгаләнең шелтәсе, Коръән Кәримдә әйтелә: «Аллаһы Тәгалә сезне бу агачтан тыймадымы?» Икенчесе, хөллә һәм таҗдан ялангач калу. Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә әйтә: «Ачылды бу икесенең гаурәтләре».

Галимнәр фикеренчә, ялангач калулары үзләренә генә күренер, әмма фәрештәләр аларны ялангач күрмәсләр иде. Өченчесе, Адәм галәйһиссәламнең йөзе, тәне каралды. Дүртенчесе, оҗмахтан чыгарылды. Бишенчесе, Адәм Хәвадан өч йөз ел буе аерылып торды. Алтынчысы, Адәм белән шайтан арасында дошманлык куәтләнде. Җиденчесе, гөнаһлы булучы исемен күтәрде. Сигезенчесе, шайтан Адәмнең балаларына һәм малларына катышты. Тугызынчысы, дөнья зинданына ябылып, суык, эсселек һәм төрле авырулар белән сыналды. Унынчысы, тормышына төрле мәшәкатьләр бирелде.

Аннан соң Хак Сөбханә вә Тәгалә Хәвадан: «Йә, Хәва! Кайда син?» — диеп сорады. Хәвадан бер кайгылы тавыш килде: «Йә, Раббым, мин ялангач, гаурәтемне капларга бернәрсәм дә юк», — диде. Хак Тәгалә әйтте: «Хата эш кылдың, шул сәбәпле ялангач булдың. Бу бәлагә керергә сәбәп булдың, Адәмне дә кайгылы, ялангач иттең». Хәва радыйаллаһу ганһә әйтте: «Йә, Раббым! Мәхлукларның Синең исемең белән ялган ант биргәнен белмим». Аллаһы Тәгаләдән хитаб кылынды: «Әй, Хәва, җәннәтемнән чык, сине унбиш бәла белән сынаячакбыз. Бу гөнаһың шомлыгыннан кызларың кыямәт көненә кадәр сыналыр. Хәез, нифас каны кызларыңа әманәт булсын. Икенчесе, тугыз ай бала күтәрсеннәр. Өченчесе, бала тапканда үлем ачысын татысыннар. Дүртенчесе, гыйддәт михнәтен чиксеннәр. Бишенчесе, ирләре хөкемендә һәм алар ирегендә булсыннар. Алтынчысы, талак ирләр кулында булсын. Җиденчесе, мираста яртылаш ким булсыннар. Сигезенчесе, шаһәдәт бирүдә; тугызынчысы, акылда; унынчысы, диндә ким булсыннар. Унберенчесе, сәлам биргәндә мәхрүм булсыннар. Уникенчесе, җомга һәм җәмәгать белән укыла торган намазлар-

дан; унөченчесе, пәйгамбәрлектән; ундүртенчесе, патша булудан, хәлифәлектән мәхрүм булсыннар», — диде.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең «Алты төрле җанварны үтермәгез» дигән хәдисе бар. Бу нинди җанварлар? Аллаһы Тәгаләнең әмере белән, Адәм галәйһиссәлам Һиндстанның Цейлон утравына, Хәва радыйаллаһу ганһә Җиддә тавына, Иблис Басрага, елан Әсфәһанга төшерелделәр. Барчасының хәле авыр булды. Адәм галәйһиссәлам төшкән урынында бик күп елады, күзләренең яшеннән үләннәр, әче тәмле дарулар, чишмәләр килеп чыкты. Хәва радыйаллаһу ганһәнең яше тамган җирдә файдалы үләннәр үсте, авыруларга дәва булды.

Адәм галәйһиссәламгә Хак Тәгаләдән хитаб килде: «И, Адәм, тәүбәң кабул булсың дисәң, Мәккәгә бар». Адәм галәйһиссәлам: «И, Раббым, барыр идем, ләкин юлны белмим», — диде. Аллаһы Тәгалә кара карганы юлбашчы итте. Кара карга очып, Адәм галәйһиссәлам аның артыннан барды. Хәбәрдә, ягъни хәдистә килгәнчә, «Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам: «Алты төрле җанварны үтермәгез», — диде. Адәм галәйһиссәламгә юл күрсәткән өчен кара карганы; икенчесе, Сөләйман галәйһиссәламгә нәсихәт кылганы өчен кырмысканы; өченчесе, Нух галәйһиссәлам көймәсен тычкан тишкәч, елан тишекне койрыгын тыгып каплады; Нух галәйһиссәлам заманында, чебен адәм итеннән тәмлерәк ит юк, дип җавап бирергә теләгәч, карлыгач аның телен тешләп, адәм балаларын еланга ризык булудан коткару сәбәпле, карлыгачны; дүртенчесе, Сөләйман галәйһиссәламгә илче булучы һөдһөд кошын; бишенчесе, Нәмруд утына су сибүе өчен су бакасын; алтынчысы, адәмнәргә шифалы бал җыйганы өчен бал кортын үтерергә ярамый.

Адәм галәйһиссәламнең буе элек бик зур булган. Риваятьтә килә, Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламне җиргә төшергәндә, аның буе күккә җитәр, фәрештәләрнең тәсбихләрен тыңлап елар иде. Фәрештәләр, Адәмнең күп елаганын күреп, Хак Тәгаләгә зарландылар. Җәбраил галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең әмере белән кулын Адәм галәйһиссәламнең башына куйды. Адәм галәйһиссәлам алтмыш аршынга кыскарды. Адәм галәйһиссәлам һәм фәрештәләр тынычландылар.

Адәм белән Хәва өч йөз ел бер-берсеннән аерылып, төрле авырлыклар күргәннән соң, Гарәфәт тавында күрештеләр. Адәм галәйһиссәлам һәм Хәва радыйаллаһу ганһәнең төрле-төрле авырлыклардан һәм һава үзгәрүеннән йөзләре һәм тәннәре үзгәргән иде. Алар бер-берсен башта танымадылар. Җәбраил галәйһиссәлам Адәмгә Хәваны, Хәва анага Адәм галәйһиссәламне белдерде. Ничә йөз елга сузылган кайгы-хәсрәт кавышуга, шатлыкка алышынды. Аннан бергәләп Мина тавына килделәр. Фәрештәләр: «Йә, Адәм, нәрсә телисең?» — диделәр. Адәм галәйһиссәлам: «Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен һәм ярлыкавын телим», — диде. Шуның өчен бу тау Мина диеп аталган. Мина — ул нигъмәт мәгънәсендә. Хак Тәгалә Адәм галәйһиссәламне Хәва белән, Хәва радыйаллаһу ганһәне Адәм галәйһиссәлам белән кавыштыру һәм аларның гөнаһларын ярлыкау белән нигъмәтләде. Хак Тәгаләнең рөхсәте белән Минада Адәм галәйһиссәлам Хәва ананы куенына алды, шуның өчен Мина дип аталды.

Җәбраил галәйһиссәлам Адәм галәйһиссәламгә хаҗ гыйбадәтләрен өйрәтте...

Мәккәдәге Бәйтелмәгъмүрне Адәм галәйһиссәламгә Аллаһы Тәгалә бүләк итте. Хак Тәгалә әйтте: «И, Адәм, бу Минем хөрмәтле йортым, гарешем бәрабәремдә, фәрештәләр гарешемне тәваф кылган кебек, син бу йортыңны тәваф кыл, догаңны кабул кылам, гөнаһларыңны кичерәм». Адәм галәйһиссәлам күрде, кызыл якуттан бер йорт, нурдан кандилләр асылынган. Бер ишеге кояш чыгышы тарафында, икенчесе кояш баешы тарафында. Бу йортка «Бәйтелмәгъмүр», ягъни «төзелгән мәһабәт йорт» диләр. Адәм галәйһиссәлам ул Бәйтелмәгъмүрне тәваф кылып, гыйбадәт белән мәшгуль булды.

Туфан вакытына кадәр әл-Хәрам шәриф мәсҗиде урынында торды, туфан вакытында Хак Тәгалә аны күккә күтәрде.

Адәм галәйһиссәлам һәм Хәва радыйаллаһу ганһәнең авыр хәлен Җәбраил галәйһиссәлам Хак Тәгаләгә сөйләде. Хак Сөбханә вә Тәгалә әмер итте, оҗмахтан бер пар куй, ике кәҗә, ике сарык, ике тәвә кошын китерделәр. Алар балаладылар, күбәйделәр. Аларның берсен суйды, йонын Хәва эрләде, Адәм галәйһиссәлам сугып, үзенә җөббә, Хәвага җылы күлмәк ясады. Җир йөзендә куйдан бәрәкәтлерәк мал юктыр. Пәйгам-

бәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам: «Бер куй — бер бәрәкәт, ике куй — ике бәрәкәт, өч куй — хәзинә», — диде. Адәм галәйһиссәлам һәм Хәва радыйаллаһу ганһә кием киеп, эсселек һәм суыклыктан котылдылар. Ләкин ачлык нык тәэсир итте. Җәбраил галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең әмере белән оҗмахтан ике үгез китерде: берсе кара, икенчесе кызыл иде. Шулай ук ике капчык бодай, бер капчык арпа китерде. Адәм галәйһиссәлам, моны күргәч: «Ашыйммы?» — дип сорады. Җәбраил галәйһиссәлам: «Ашыкма, бодай һәм арпа орлыгын җирне үгезләр белән сукалап чәчәрсең», — диде. Үгезләрне җир сөрергә, җигеп сукаларга өйрәтте. Үгезләр оҗмахта мәшәкатьсез торудан сукага ялкауланып, күзләреннән яшьләр акты. Адәм галәйһиссәлам үгезләргә бер-ике мәртәбә сукты, үгезләр телгә килеп: «Безгә ни өчен сугасың?» — диделәр. Адәм: «Сез мине тыңламыйсыз», — диде. Үгезләр: «Сүз тыңламаучыга сугарга кирәкме?» Адәм галәйһиссәлам бу сүзләрдән нәсихәт алып, күп елады. Аннан соң үгезләр ашыгып сөрә башладылар.

Бодай тиз арада үсеп өлгерде. Адәм галәйһиссәлам: «Ашыйммы?» — диде. Җәбраил галәйһиссәлам: «Юк, ур», — диде. Урды. Адәм галәйһиссәлам янә: «Ашыйммы?» — диде. Җәбраил галәйһиссәлам: «Хәзер сук», — диде. Сукты. Адәм галәйһиссәлам: «Ашыйммы инде?» — диде. Җәбраил галәйһиссәлам: «Хәзер он итеп тарттыр», — диде. Он итеп тарттырды. Адәм галәйһиссәлам: «Ашыйммы?» — диде. Җәбраил галәйһиссәлам: «Камыр итеп пешер», — диде. Хәва радыйаллаһу ганһә камыр изде, пешерде һәм: «Хәзер ашыйкмы инде?» — диделәр. Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Хак Тәгаләнең фәрманыдыр, и, Адәм һәм Хәва, көннең ике өлеше үтте, бер өлеше калды. Сабыр итегез, кояш баеганчы ураза тотыгыз. Сез һәм кыяматкә кадәр булган барча балаларыгыз гыйбадәт кылып, ураза тотсалар, гөнаһларын ярлыкап, оҗмахка керү белән Аллаһы Тәгалә вәгъдә кылды», — диде. Адәм галәйһиссәлам ашап, тамагын туйдыргannan соң, корсагында тынычсызлык тойды. Җәбраил галәйһиссәлам: «Бу сусаудандыр», — диде. Адәм галәйһиссәламгә тимер көрәк биреп: «Җирне казып, су чыгар», — диде. Адәм галәйһиссәлам җирне шактый гына казыгач, су чыкты. Җәбраил галәйһиссәлам: «Су тонгач, аны эч», — диде, эчте, җаны тынычланды.

Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләнең Адәм галәйһиссәламне туфрактан яралтуында вә аңа җан керүдә берәр хикмәт бармы? Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә фәрештәләргә җирдә хәлифә бар итүен хәбәр иткәч, һәр җисем Аллаһы Тәгалә ул хәлифәне миннән яралтыр диеп, үзләренең күркәмлеге белән горурландылар. Әмма җир генә: «Мин аяк астында ята торган бер зәгыйфь мәхлук, минем бер куаныр ягым да юк», — диеп тыйнаклык күрсәтте. Шул сәбәптән Аллаһы Тәгалә Адәмне туфрактан яралтты.

Кырык ел үткәннән соң, Аллаһы Тәгалә Адәмнең җанына тәнгә керергә әмер кылды. Җан Адәмнең башы янына килде, керергә ашыкмады. Бөек галәмнән түбән галәмгә төшәргә теләмәде. Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең исеме белән тәнгә кер», — диде. Җан әүвәл Адәм галәйһиссәламнең башына, аннан соң күзенә керде. Адәм галәйһиссәлам үзенең тәне кара туфрактан яратылганын күрде. Җан янә борынына килде, Адәм галәйһиссәлам төчкерде. Аннан соң авызына килеп: «Аллаһы Тәгаләгә мактаулар булсын», — диде. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Раббыңның рәхмәте белән бар кылындың». Аннан соң җан күкрәккә керде, анда хикмәт гыйлеме урнашты. Дөньяда вә галәмдә ни нәрсә булса, барчасының исемен мең төрле телдә әйтә белә иде. Янә җан биленә керде, торырга максат куйды, әмма тора алмады. Аннан соң корсагына килде, Адәм галәйһиссәлам ашарга теләде. Моннан соң җан, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән, тулысынча бәдәнгә керде. Тамырда җан галәмәте булып кан йөрде. Адәм галәйһиссәлам бик гүзәлләнде.

Җан тәнгә теләмичә керде, чыкканда да теләмичә чыгардиләр. Ни өчен бу шулай?Хак Сөбханә вә Тәгалә җанга «Кер!» диеп, өч мәртәбә фәрман кылды. Моннан соң: «Көч белән кер, көч белән чык», дигән әмер бирелде. Изге бәндәләрнең җаны тәннән чыгуына һәм рәхмәткә ирешүенә өмет итеп чыкканда, Аллаһы Тәгалә аларны җәннәт белән сөендерер. Аллаһы Тәгалә аларны җәннәт белән сөендереп әйтте: «Сезне вәгъдә ителгән җәннәт белән сөендерәм. И, иман китерүче нәфес! Аллаһы Тәгаләнең боерыгына, савапка риза булган һәм Аллаһы Тәгалә синең гамәлләреңнән разый булган хәлдә кайт. Оҗмахыма изге бәндәләрем белән бергә кер».

Әмма явыз кешенең җаны авырлык белән чыгар. Моны юеш

йонга тигәнәк сырган очрак белән чагыштырып була. Аллаһы Тәгалә безне мондый хәлдән Үзе сакласа иде.

Адәм галәйһиссәлам елмайса, кояш кебек нурлы булды. Кайсы тарафка гына әйләнсә дә, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламнең нуры тулган ай кебек балкыр иде. Адәм галәйһиссәлам шулкадәр матур, гүзәл булды ки, фәрештәләр аның матурлыгына хәйран калып: «Үә тәбәракә Аллаһү әхсәнүл-халикыйн», ягъни «Иң күркәм халык кылучы Аллаһы Тәгалә мөбарәк, олугтыр», диделәр.

Ни өчен фәрештәләр Адәм галәйһиссәламнең янынннан түгел, ә артыннан йөрделәр? Аллаһы Тәгалә әл-Хәрам мәсҗиденең кадерле җирендә бер тәхет яралтты һәм фәрештәләргә боерды: «Ул тәхетне иңнәрегезгә күтәреп, Адәм галәйһиссәламгә күкләрне күрсәтегез». Барча фәрештәләр, Адәм галәйһиссәламгә хөрмәт күрсәтеп, артыннан йөрделәр. Адәм галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләдән: «Ни өчен алар минем артымнан йөриләр, янымнан йөрмиләр?» — дип сорады. Хак Сөбханә вә Тәгалә: «Аркаңда дустым Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламнең нуры бар. Фәрештәләр аны хөрмәт итеп, артыңнан йөриләр», — диеп хәбәр бирде. Адәм галәйһиссәлам мөнәҗәт әйтте: «И, Раббым, аның нурын каршыма, икенче әгъзама күчер, мине дә шатландырсын». Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә ул нурны Адәм галәйһиссәламнең имән бармагына күчерде. Адәм галәйһиссәлам, имән бармагын күреп, шаһәдәт кәлимәсен әйтте, ягъни: «Шаһәдәт бирәмен ки, Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк», — диде. Шуның өчен имән бармагын шаһәдәт бармагы диләр. Аннан соң, имән бармагын үбеп, күзләрен сыйпады. Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламгә салаватлар әйтте. Моннан соң: «И, Раббым! Ул нурдан аркамда тагын нур калдымы?» — дип сорады. Хак Тәгалә: «Дүрт сәхабәнең нуры калды», — диде. Адәм галәйһиссәлам ул нурларның бармакларына күчүен теләде, кабул булды. Әбү Бәкер Сиддыйк радыйаллаһу ганһенең нуры урта бармакка, хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһенең нуры атсыз бармакка, хәзрәти Госман радыйаллаһу ганһенең нуры баш бармакка һәм хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһенең нуры кечкенә, ягъни чәнти бармакка күчкән. Бармакларына кайчан караса да, нурларның артканын күрә иде. Богъдай агачының җимешен ашагач, бу нурлар янә аркасына күчтеләр.

# КАБИЛ ВӘ ҺАБИЛ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламгә иген игәргә өйрәтү өчен Җәбраил фәрештәне җибәрде. Моннан башка Адәм галәйһиссәлам кыргый киекләрне ауларга өйрәнде. Анабыз Хәва исә ул алып кайткан игеннән он ясап, камыр изеп, икмәк вә киекләрне пешереп, хайван тиреләреннән кием тегеп, үзләре ясаган йортта тора иде.

Көннәрдән бер көнне Хәва анабыз балага узды. Иң әүвәл туган балалары Кабил вә аның белән бер корсакта бик матур кыз Әкълимә иде. Ике ел үткәннән соң, бер корсактан Һабил белән Ләбүдә туды. Ләбүдә матурлыкта Әкълимәгә җитмәс иде. Кайчан болар үсеп балигъ булдылар исә, Хак Сөбханә вә Тәгаләдән Адәм галәйһиссәламгә хитап килде: «Ләбүдәне Кабилгә, Әкълимәне Һабилгә никах кыл», — дип. Адәм галәйһиссәлам шәригать хөкемен вә дәхи Хак Тәгаләнең хитабын Кабил илә Һабилгә ирештерде. Һабил шәригать хөкеменә риза булды, тик Кабил риза булмыйча киреләнде, үзсүзләнде. Ул: «Мин үзем белән бергә туган Әкълимә белән булырга тиеш», — дип карышты. Адәм галәйһиссәламгә Аллаһы Тәгаләдән вәхи килде: «Кабил вә Һабил корбан кылсыннар, кайсының корбаны кабул булса, Әкълимә шуныкы булыр!» — дип. Бу турыда Коръән Кәримнең «әл-Маидә» сүрәсе, 27 нче аятендә болай әйтелә:

وَاتْلُ عَلَيْهِمْ نَبَأَ ابْنَيْ آدَمَ بِالْحَقِّ إِذْ قَرَّبَا قُرْبَانًا فَتُقُبِّلَ مِنْ أَحَدِهِمَا

وَلَمْ يُتَقَبَّلْ مِنَ الْآخَرِ قَالَ لَأَقْتُلَنَّكَ قَالَ إِنَّمَا يَتَقَبَّلُ اللَّهُ مِنَ الْمُتَّقِينَ ٢٧

«Үәтлү галәйһим нәбә-әбнә-э Әдәмә бил хәккый изкаррабәә курбәәнәң фәтүкуббилә мин әхәди һимәә үәләм йүтәкаббил минәл әәхар. Каалә ләә-әкътүләннәк. Каалә иннәмәә йәтәкаббәлүл-лааһү минәл мүттәкыййн (27)».

Мәгънәсе: *«Адәм галәйһиссәламнең угыллары хакындагы хәбәрне хаклык белән укы! Кабил белән бер карында*

*яткан Әкълимә Һабилгә тиешле иде. Әмма Кабил Әкълимәне үзем алам дигәч, Аллаһы Тәгалә икесенә дә корбан кылырга боерды. Ике егет корбаннарын кылдылар. Һабилнең корбанын Хак Тәгалә кабул итте, Кабилнеке кабул булмады. Кабилнең көнчелеге вә ачуы артты, ул әйтте: «И, Һабил, мин сине һичшиксез үтерәчәкмен». Һабил җавабында: «И, Кабил, син ялгышма, Аллаһы Тәгалә гадел кешеләрнең корбанын кабул итәдер», — дип әйтте (27)».*

Кабилнең кәсебе иген игү иде. Һабилнең кәсебе исә хайван вә терлек асрау иде. Кабил корбанлык урынына чүпле бодай китереп салды. Һабил исә симез дөя чалды. Һабилнең Аллаһы Тәгалә исеменә атап чалган корбаны, әлбәттә, кабул булды. Кабилнең корбаны кабул булмады, чөнки ул Хак Сөбханә вә Тәгаләнең хөкеменә буйсынмыйча, киреләнеп, корбанын ачу белән чалган иде. Корбаны кабул булмагач, Кабилнең көнчелектән ачуы тагын да артып, ул Һабилгә: «Мин сине һичшиксез үтерәчәкмен», — диде. Һабил моңа каршы әйтте: «Хакыйкатьтә, Аллаһы Тәгалә тәкъва кешенең корбанын кабул итә, синең корбаның кабул булмады, миннән түгел — үзеңнән. Әгәр дә син мине үтерергә кулыңны сузсаң, мин сине үтерер өчен кулымны сузмыймын, чөнки мин Хак Сөбханә вә Тәгаләдән куркамын. Хакыйкатьтә, мине үтерү нияте илә кулыңны сузсаң, бу кылган гөнаһың бәрабәренә тәмуглык булачаксың», — диде.

Кабил бу сүзләргә игътибар кылмады, ул җан ачуы илә кардәше Һабилне таш белән бәреп үтерде. Бу хакта Коръән Кәримнең «әл-Маидә» сүрәсе, 28–31 нче аяти кәримәләрендә болай диелә:

لَئِنْ بَسَطْتَ إِلَيَّ يَدَكَ لِتَقْتُلَنِي مَا أَنَا بِبَاسِطٍ يَدِيَ

إِلَيْكَ لِأَقْتُلَكَ إِنِّي أَخَافُ

اللَّهَ رَبَّ الْعَالَمِينَ ۞ ٢٨ إِنِّي أُرِيدُ أَنْ تَبُوءَ بِإِثْمِي

وَإِثْمِكَ فَتَكُونَ مِنْ أَصْحَابِ

النار وذلك جزاوا الظلمين ٢٩ فطوعت

له نفسه قتل اخيه فقتله

فاصبح من الخسرين ٣٠ فبعث الله غرابا

يبحث فى الارض ليريه كيف

يوارى سوءة اخيه قال يويلتى اعجزت

ان اكون مثل هذا

الغراب فاوارى سوءة اخى فاصبح من الندمين ٣١

«Ләим бәсәттә иләййә йәдәкә лидәкә литәкътүләнии мәә әнә бибәә ситый-йәдийә иләйкә лиәкътүләк. Иннии әхаафүл-лааһә раббәл-гәәләмиин (28). Иннии үриидү әң түбүү әби-исмии үә исмикә фәтәкүүнә мин әсъхәәбиннәр. Үә зәәликә җәзәә-үззаалимиин (29). Фәтаү-үәгәт ләһүү нәфсүһү катлә әхыйһи фәкатәләһү фә-әсбәхә минәл-хаасриин (30). Фәбәгәсәллааһү гураабәй-йәбхәсү фил-әрдый лийүрийәһ кәйфә йүвәәрии сәү-әтә әхыйй. Каалә йәәүәйләтәә әгәҗәзтү ән әкүүнә мислә һәәзәл-гурааби фәүәәрийә сәү-әтә әхый. Фә-әсъбәхә минән-нәәдимиин (31)».

Мәгънәсе: *«Һабил Кабилгә әйтте: «Син мине үтерергә кулыңны суза торган булсаң да, мин сине үтерергә кулымны сузачак түгелмен. Чөнки мин бөтен галәмнәрне тәрбия кылучы Хак Тәгаләнең газабыннан куркамын (28). Әгәр дә инде явызлыгың илә мине үтерсәң, мин, минем гөнаһымны вә дәхи үз гөнаһыңны бергә йөкләп, Аллаһы Тәгалә каршына кайтуыңны телимен, бу золым эшне эшләсәң, ут әһеленнән бу-*

*лырсың. Ут газабы — залимнәргә тиешле җәза» (29). Явыз нәфесе Кабилне җиңде, ул Һабилне үтерергә өндәде. Кабил нәфесен тыя алмады, Һабилне үтерде вә хәсрәтләнүчеләр җөмләсеннән булды (30). Хак Тәгалә Кабил янына бер карга җибәрде. Ул карга Кабилгә җирне казып күрсәтте, ягъни Кабилгә Һабилнең гәүдәсен ничек күмәргә кирәген өйрәтте. Чөнки Кабил, Һабилне үтергәч, мәетне кая куярга белмичә, берничә көн күтәреп йөрде. Карганың җирне казып күмүен күргәч, Кабил үз-үзенә әйтте: «Һай, миңа ни үкенеч! Мин карга белгәнне дә белмәдем, әгәр белгән булсам, кардәшемнең гәүдәсен, ничә көннәр буе күтәреп йөрмичә, үтерү белән күмгән булыр идем». Бу гөнаһлы эшеннән соң ул үкенүчеләрдән булды (31)».*

Җир йөзендә кан түгү, кеше үтерү хакында Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһис-саләтү вәссәлам әйтте: «Мән сәннә сүннәтән хәсәнәтәң фәләһү әҗруһәә үә әҗру мән гәмилә биһәә иләә йәүмил-кыямәти үә мән сәннә сүннәтән сәйи-әтәң фәләһү үизруһәә үә-үизру мән гамилә биһәә илләә йәүмил-кыйәәмәт».

Мәгънәсе: *«Әгәр бер кемсә күркәм, изге гамәл кылса, ягъни изге гамәл вә гыйбадәткә юл күрсәтсә, аның савабы шул күркәм гыйбадәтне кылучыга булыр, дәхи кыямәт көненәчә шул күркәм гамәл-гыйбадәтне күрсәтүчегә булыр».*

Димәк, савабы күркәм изге гамәл-гыйбадәтне кылучыга вә дәхи күрсәтүчегә уртак булыр.

*«Әгәр инде бер кемсә явыз гамәл кылса, гөнаһы явыз гамәлне әүвәл кылып күрсәтүчегә вә дәхи бу явыз гамәлне белә торып кабатлаучыларга булыр. Бәс, Кабил кеше үтермәк гамәлне күрсәтте, димәк, кыямәт көненәчә золым илә кеше үтергән кемсәләрнең гөнаһы Кабилгә вә дәхи үтерүчегә булыр».*

Газиз кардәшем! Явыз гамәл ул кеше үтерү кенә түгел, һәрбер бозык эш, Хак Тәгаләнең хөкеменә муафыйк булмаса, ул явыз гамәл булыр. Мәсәлән, бай вә фәкыйрьгә Сөбханә вә Тәгаләнең хөкеме биш вакыт намаз укымак, малы булса — зәкятен бирмәк, иген чәчсә — гошерен бирмәк вә дәхи руза тотмак һәм моннан башкалар. Бер кемсә үзен мөэмин-мөселман санап та намаз укымаса, руза тотмаса яки көче җитеп тә

хаҗ гамәлен кылмаса, нисаб иясе булып та зәкятен бирмәсә, яисә иген игеп тә, аның уңышыннан гошер бирмәсә, боларның һәркайсының да гөнаһы аңар булыр. Дәхи ул кемсәдән күреп, баласы, йә кардәше, йә гайре авыру күңелле кемсәләр: «Фәлән кеше дә намаз укымады, гошер бирмәде», — дип үрнәк тотып, намаз укымаса, гошер бирмәсә, башта намаз укымаучы вә башлап гошер бирмәүчегә вә дәхи аны күреп, аңа ияреп намаз укымаучы, гошерен бирмәүчегә гөнаһ булыр.

Риваять кылынадыр, кайчан Кабил Һабилне үтерде исә, Иблис мәлгунь Кабил янына килә вә әйтә: «Беләсеңме Һабилнең корбаны ни өчен кабул булды? Һабил утка табына иде, шуның өчен ут аның корбанын яндырды, синең корбаныңны яндырмады», — ди.

Кабил исә Иблиснең бу сүзләренә ышана, утка табына башлый. Хәмер, зина һ.б. шундый бозык эшләрне кыла. Барча гөнаһларның башы Иблис илә Кабил булдылар. Тәмугта боларга нинди газап булыр дип, Хак Тәгаләдән сорадылар. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Раббәнәә әрнәлләзиинә әдалләнәә минәл җиннә үәл-иңси нәҗгәлүһүмә тәхтә әкъдәәминә лийәкүнәә минәл-әсфилиин».

М ә г ъ н ә с е : *«Йә, безнең Раббыбыз, күрсәт безгә җен илә адәмидән ике кемсәне — ул Иблис белән Кабилдер. Болар көферлек илә нахакка кеше үтерүгә юл күрсәттеләр. Кылырбыз без ул икенең аяк асларына кайнар ут ягып газапның иң олысын».*

Адәм галәйһиссәлам заманыннан башлап пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламгә чаклы булган чорда корбанлыкның кабул булуы галәмәте шул иде ки, әгәр корбан кабул булса — һавадан ут килеп яндыра иде, кабул булмаганда ут килми иде.

Риваятьләргә караганда, утка табыну, төрле сыннарга табыну, төрле бозык уеннар уйнау, хәмер эчү вә гайре бозыклыклар Кабилдән вә дәхи аның балаларыннан калды. Әгәр бер кемсә ошбу бозык эшләрне белә торып кылса яки башкаларны бу эшкә котыртса, кыямәт көнне бу бәндә Кабил вә аның бозык балалары белән бергә кубарылыр.

Янә риваятьләргә караганда, Һабилне үтергәннән соң, Кабил Иблис мәлгунь котыртуы илә барча гөнаһлы эшләрне кыла,

атасы Адәм галәйһиссәламне күрсә, кача. Адәм галәйһиссәлам Хак Сөбханә вә Тәгаләдән: «Җирне минем ихтыярыма кыл», — дип дога кыла. Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул кыла, бәс, Адәм галәйһиссәлам, Кабил янына килеп: «И, Җир, тот минем бозык углым Кабилне», — ди. Җир Кабилне тезенәчә тота. Кабил куркып әйтә: «И, ата, миңа рәхим вә шәфкать кыл». Адәм галәйһиссәлам әйтә: «Син кардәшеңә рәхим вә шәфкать кылмадың, и Җир, тот Кабилне», — ди. Җир Кабилне биленәчә тота. Кабил әйтә: «И, ата, син вә анам үзегезнең хатагызны кичерүен сорап Хак Тәгаләгә ялвардыгыз, Хак Тәгалә сезнең хатагызны кичерде, бу көн син мине кичер», — ди. Адәм галәйһиссәлам әйтә: «Әйе, без, Иблискә ышанып, мәкруһ булган богъдай агачының җимешен ашадык, ә син исә кеше үтерлең, бу хәрамдыр, синең гөнаһың белән безнең гөнаһыбыз бәрабәр түгел. И, Җир, тот Кабилне», — ди. Җир Кабилне күкрәгенәчә тота. Кабил әйтә: «И, ата, рамазан аенда һәр кич 100 өлеш рәхмәт явар, 99 өлеш — мөэминнәргә, бер өлеш башка барча нәрсәләргә булыр дип безгә һәрдаим әйтә идең, Хак Тәгаләдән сора, шул бер өлештән миңа да рәхмәт кылсын». Адәм галәйһиссәлам әйтә: «Рәхимсез вә шәфкатьсезләргә ул рәхмәттән өлеш юк». Кабил, атасы Адәм галәйһиссәламнән өмет өзеп, Хак Сөбханә вә Тәгаләгә ялварып әйтә: «Рахмән вә Рахим, бу ике бөек исемең хөрмәтенә дөньяда мине ошбу газаптан зинһар коткар», — ди. Аллаһы Тәгаләнең рәхим вә шәфкате илә Җир Кабилне өскә чыгара. Шушы вакыйгалардан соң Кабил Йәмән җиренә кача.

Янә риваятьләрдә әйтелә, хәзрәти Адәм галәйһиссәлам белән Хәва радыйаллаһу ганһә Җир өстенә төшерелеп бергә яши башлагач, Хәва радыйаллаһу ганһә беренче балага уза. Аның янына бик күркәм мөэмин карт кыяфәтендә Иблис мәлгунь килә, ул үзен Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән фәрештә дип игълан итә, янә әйтә: «Сезнең углыгыз булачак, ул балага Габделхарис исемен бирерсез, бу — Аллаһының әмере», — дип ышандырып китеп бара. Бала сау-сәламәт туа, аңа Габделхарис, ягъни шайтан колы дигән исем бирәләр. Тугач та ул үлә. Бу турыда Коръән Кәримнең «әл-Әгъраф» сүрәсе, 190 нчы аятендә әйтелә:

فَلَمَّآ ءَاتَىٰهُمَا صَٰلِحًا جَعَلَا لَهُۥ شُرَكَآءَ فِيمَآ

ءَاتَىٰهُمَا فَتَعَٰلَى ٱللَّهُ عَمَّا يُشْرِكُونَ ۝ ١٩٠

«Фәләммәә әәтәәhүмәә саалихәң җәгәләәләhү шуракәә-ә фиимәә әәтәәhүмә. Фәтәгәәләл-лааhү гәммәә йүшрикүүн (190)».

Мәгънәсе: *«Сөбханә вә Тәгалә аларга изге бала биргәч, бирелгән балада Хак Тәгаләгә бернәрсәне ширек кылдылар, ягъни шайтан коткысы илә баланың исемен Габделхарис куш-тылар, шайтан колы дигән сүз. Аллаhы Тәгалә мөшрикләр кылган ширекләрдән пакь (190)».*

Атабыз Адәм галәйhиссәлам бу вакыйгадан соң бик нык борчылды. Җәбраил фәрештә аркылы Хак Сөбханә вә Тәгаләдән Адәм галәйhиссәламгә сөенечле хәбәр килде: «Ал-лаhы Тәгалә сиңа тиз көннәрдә бер бала бирер, ул бала адәм балаларының хуҗасы, соңгы пәйгамбәр Мөхәммәд саллал-лаhу галәйhи вәссәлам нәселеннән булыр, аның исемен Шис дип куярсыз», — диде.

Адәм галәйhиссәламнән пәйгамбәребез саллаллаhу га-ләйhи вәссәлам заманына кадәр корбанның кабул булуы галәмәте шул булды: корбан кабул булса, hавадан ут килеп яндырыр иде. Кабул булмаса, ут килмәс hәм яндырмас иде.

«Рәваникул-мәҗәлис» китабында әйтелә: «Потка табыну, думбра hәм башка музыка коралларында уйнау, хәмер эчү hәм башка бик күп бозыклыклар, барысы да Кабилдән калган. Әгәр берәү ошбу эшләрне кылса, Кабил hәм аның балалары белән бергә кубар».

# ШИС ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Риваятьләргә караганда, Адәм галәйһиссәлам илә Хәва радыйаллаһу ганһә сахрада ял итеп утыралар иде. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте илә алларыннан бер чишмә ага башлады. Ул чишмә оҗмахтан иде. Шул вакыт Аллаһының фәрештәләре белән Җәбраил галәйһиссәлам бер табак җимеш китерде вә әйтте: «И, Адәм галәйһиссәлам, боларның нәрсә икәнен беләсеңме?» — диде. Адәм галәйһиссәлам әйтте: «Әйе, беләмен, болар — җәннәт җимешләредер. Хак Сөбханә вә Тәгаләдән күптән үлемемнән элек ул җимешләрне насыйп кылуын тели идем», — диде. Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Йә, Адәм галәйһиссәлам, бу җимешләрне аша вә дәхи бу чишмәдәге су белән госел коен, Хәва радыйаллаһу ганһәгә дә шуны куш, ошбу чишмә суы белән госел коенсын». Адәм галәйһиссәлам һәм Хәва радыйаллаһу ганһә икесе дә җәннәт җимешләрен ашагач, ошбу чишмә суы белән госел коенып чыккач, якынлык кылдылар. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте илә, пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламнең нуры Адәм галәйһиссәламнән Хәва радыйаллаһу ганһәгә күчте.

Моннан элек килгән фәрештәләр әүвәл Адәм галәйһиссәлам каршысында торалар иде, нур күчкәннән соң Хәва радыйаллаһу ганһә каршысында торыр булдылар. Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламнең нуры Хәва ананың күкрәгендә кояш нуры күк балкый иде. Адәм галәйһиссәлам фәрештәләрнең әүвәл үзенә, аннан соң Хәва анага борылуларының сәбәбен Хак Тәгаләдән сорады. Хак Сөбханә вә Тәгалә: «Фәрештәләр барчасы, ул нурга ияреп, нур иясенә хөрмәт кылалар. Нур синдә булганда сиңа хөрмәт кылдылар, инде нур Хәвага күчкәч, аңа хөрмәт кылалар», — диде.

Риваятьләргә караганда, нур Хәвага күчеп, Шис галәйһиссәлам дөньяга килеп балигъ булганчы Иблис ләгыйнь мәхҗүб булды, ягъни Хәва ананың Шис галәйһиссәламгә корсаклы булуын вә Шис галәйһиссәламнең туганын белмәде вә күрмәде, чөнки ул Аллаһы Тәгаләнең пәрдәсе белән капланган иде.

Нур Шис галәйһиссәламгә күчеп, аның маңгаенда кояш кебек балкый иде. Шис галәйһиссәлам Адәм галәйһиссәламнең башка балаларыннан матурлыкта, гыйлем вә хикмәттә бер башка өстен иде. Кыяфәте вә тормышы атасы Адәм галәйһиссәламгә охшаган иде. Адәм галәйһиссәлам дә Шис галәйһиссәламне башка балаларыннан артык сөя иде.

Аллаһы Тәгаләнең әмере илә исемен Шис дип куйдылар. Шис сәрьян телендә Һибәтулла, ягъни Аллаһы Тәгаләнең бүләге мәгънәсендә була, вә дәхи икенче мәгънәсе — гыйлем өйрәтүче дигәнне аңлата. Бәндәләр арасында иң әүвәл гыйлем өйрәткән, дәрес биргән, шәригать хөкемнәре илә шөгыльләнгән — ул Шис галәйһиссәлам иде.

Шис галәйһиссәлам балигъ булгач, Җәбраил галәйһиссәлам Хак Тәгаләнең әмерен ирештерде: «Иртәгә Шис галәйһиссәламне вә дәхи барча башка балаларыңны бер җиргә җый, бу көнне Шис галәйһиссәламдәге мөбарәк нурга гаһед, мисак, ягъни ант илә килешү беркетелер», — диде. Иртәгесе көнне Адәм галәйһиссәлам сөекле улы Шис галәйһиссәламне барча балалары янына алып барды. Җәбраил галәйһиссәлам дә 70 мең фәрештә белән килеп, Шис галәйһиссәламнән гаһед-вәгъдә алып, килешүне беркеттеләр, ягъни бер якут каләм илә оҗмах ефәкләреннән булган бер ефәккә гаһеднамә яздылар, фәрештәләр вә дәхи Адәм галәйһиссәламнең барча балалары шаһит булдылар. Ошбу язулы ефәк гаһеднамәне төреп, Җәбраил галәйһиссәлам мөһерләде. Хак Сөбханә вә Тәгалә Үзенең кодрәт хәзинәсеннән Шис галәйһиссәламгә ике яшел кием вә бер сандык һәдия итте. Бу яшел киемнәрнең һәрбере кояш нуры кеби яктылык бирә иде, ә һәдия сандык эчендә барча пәйгамбәрләрнең сыйфатлары язылмыш иде. Ошбу гаһеднамәне дә сандык эченә салып, Җәбраил галәйһиссәлам сандыкны Адәм галәйһиссәламгә сакларга боерды. Шул рәвешчә, пәйгамбәр нәселеннән булган балаларга нәселдән нәселгә ошбу рәвешчә гаһеднамә язылып, заман соңында ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламгә килеп ирешәчәк. Шис галәйһиссәлам илә төзелгән гаһеднамәнең мәгънәсе болай иде: «Шис галәйһиссәлам ошбу мөбарәк нурны сакламакта иҗтиһад кылсын. Пакизә, ягъни саф, керсез кыз илә никахлансын, хәрамнан

бик саклансын. Ошбу нур бер атадан анага күчеп, бала туып балигъ булганчы, шайтан хәбес кылыныр».

Риваятьләргә караганда, Адәм галәйһиссәламнең гомере 500 елга ирешкәч, балалары, балаларының балалары күбәйде. Хак Сөбханә вә Тәгалә аны балаларына пәйгамбәр кылды. Көн дә намаз укуны, руза тотуны фарыз кылды. Җөнебедән соң госел коенуны боерды. Хинзир (дуңгыз) итен ашауны, исерткеч эчүне хәрам кылды. Әлифба китабын вә дәхи 10 кәгазьле китап иңдерде. Ул кәгазьләрдә хикмәт, табигатьтә булган файдалы вә кабул итәргә ярамый торган үләннәр, җимешләр, шайтан сихеренә каршы торырлык догалар һ.б. файдалы гыйлемнәр язылган иде.

Кабил Йәмәнгә качканнан соң 70 ел узгач, аның балалары күбәеп, алар утка вә төрле сыннарга табына башладылар. Хак Сөбханә вә Тәгаләдән вәхи килде: «Кабил вә аның балаларын тугры юлга, Ислам диненә өндә», — дип. Хак Тәгалә фәрманы буенча Адәм галәйһиссәлам Кабилне вә аның балаларын хак дин — Ислам диненә өндәде. Күпме генә өндәсә дә, Кабил вә аның балалары Ислам динен кабул кылмадылар.

Адәм галәйһиссәлам үз балаларына шәригать хөкемнәрен өйрәтте. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләне танытты, араларында ихтиляф булуын теләмәде.

Риваятьләргә караганда, Адәм галәйһиссәламнең гомере 1000 елга иреште исә, аңа авыру пәйда булды. Шис галәйһиссәламне вә дәхи барча балаларын җыеп, аларга әйтте: «Хак Тәгалә әмеренә һичшиксез буйсыныгыз, хатыннарыгызга иярмәгез», — диде. Шис галәйһиссәламне янына чакырып, аңа васыять вә нәсыйхәтләрен кылды. Барча васыятьләреннән 5 васыятьне хаслап, болай диде: «И, Шис, бу биш васыять илә гамәл вә гыйбадәт кыл, вә дәхи үзеңнән соң килгән балаларыңа васыять кыл. Әүвәл, ошбу дөньяга күңел багламадым, оҗмахка күңел багладым, күп мәшәкать күрдем. Икенчесе, һәр эшнең ахырын уйламый эшләдем, шуның өчен бу хәлгә төштем. Өченчесе, хатын сүзенә карама, мин хатыным сүзенә карап бәлаләндем. Дүртенчесе, һәр эштә үзеңнән акыллыраклар белән киңәш әйлә, әгәр дә мин фәрештәләргә киңәш иткән булсам, богъдай агачының җимешен ашаудан тыелыр идем вә бу бәлагә төшмәс идем. Бишенчесе, һәр эшне эш-

ләмәкче булсаң, ләкин эчең пошса, ул эшне эшләмә, минем, богъдай агачы янына баргач, күңелем тартмады, эчем пошты, ашадым ирсә — җәннәттән чыгарылдым. Бу васыятемне исеңдә тотып, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламнең нурын яхшы сакла», — диде.

Хәзрәти Адәм галәйһиссәламнең авыруы көчәйде. Үлем фәрештәсе Газраил галәйһиссәлам әдәп белән кереп сәлам бирде, бу вакытта Хәва радыйаллаһу ганһә Адәм галәйһиссәлам артында елап утырыр иде. Җәбраил галәйһиссәлам дәхи әдәп белән кереп сәлам бирде, Адәм галәйһиссәламнең хәлен сорады. Адәм галәйһиссәлам Хәва радыйаллаһу ганһәгә карап әйтте: «Йә, Хәва, бу тирәдән китеп тор, мине Хак Тәгаләнең илчеләре илә калдыр», — диде. Аннан соң йөзен Җәбраил галәйһиссәламгә борып: «Йә, Җәбраил галәйһиссәлам, инде мин әҗәл шәрабын эчсәм кирәк, мине ни көтә?» — диде. Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Йә, Адәм, югары кара». Югары карады, оҗмахны вә дәхи үзе өчен оҗмахта әзерләнгән дәрәҗәләрне күзе илә күрде. Аннан соң Газраил галәйһиссәлам тәсбих вә тәһлил әйтә-әйтә мөмкин кадәр йомшаклык илә Адәм галәйһиссәламнең җанын алды.

Җәбраил галәйһиссәлам Шис галәйһиссәламгә мәет юуны өйрәтте. Җеназа намазында Шис галәйһиссәламне имамлыкка тәгаен кылды. Намаз хәзерге рәвештә кыям хәлендә дүрт тәкбир вә ике сәлам илә тәмам булды. Аннан соң Адәм галәйһиссәламнең җәсәден Әбү Кәбис тавына җирләделәр.

Адәм галәйһиссәлам вафатыннан соң Аллаһы Тәгаләдән Шис галәйһиссәламгә пәйгамбәрлек килде. Адәм галәйһиссәламнең барчасы аңа иярделәр, тик Кабил балалары гына аңа иярмәделәр. Пәйгамбәрлек килгәннән соң, Шис галәйһиссәламгә Җәнабел Хактан 50 кәгазь иңдерелде. Ошбу кәгазьләрдә Хак Тәгаләнең хикмәт гыйлеме, хифзыссыйхәт, гыйлемрух, хисап, хөсне хат, шәригать хөкемнәре язылган иде.

Хәзрәти Шиснең күп балалары булды, нәселе артты. Тугыз йөз унике яшенә җиткәч, Газраил галәйһиссәлам килеп мөмкин кадәрле йомшаклык илә аның җанын алды. Кабере Әбү Кәбис дигән тауда.

# ИДРИС ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Риваятьләргә караганда, Шис галәйһиссәлам вафатыннан соң, адәм балалары төрле бозыклыкка кереп баттылар. Алар төрле сыннарга, сурәтләргә, потларга табына башладылар. Адәм вә Шис галәйһиссәламнәр күрсәткән дөрес юлны оныттылар. Аларда әхлаксызлык өстен булып, гадәт вә мөгамәләләре бик наданнарча иде. Алар бик мактанчык, бик үзсүзле, үч алырга бик хирыс, гөнаһкярлар иде. Ир белән хатын, хуҗа илә кол арасында булган гадәт вә мөгамәләләр һәммәсе дә ифрат вә чиктән тыш әйберләргә корылган, чиктән тыш тупас вә дәхи залимнәрчә ысулда иде. Алар нәсел-нәсеп берлә, кабилә вә ыруг илә мактанышырга яраталар, бу җәһәттән бик көчле кан дошманлыгы саклыйлар, шул сәбәпле күп очракта канлы вакыйгалар китереп чыгаралар иде. Талаш, сугыш, низаг өчен бик күп көч сарыф кылына, яшь гомерләр өзелә вә дәхи байтак нәрсәләр һәлак булуга китерә иде. Багучылар, фалчылар вә сихерчеләр бик каты хөкем сөрәләр иде. Шушы хәлләрендә алар өч йөз ел яшәделәр.

Аларны дөрес юлга күндерү өчен, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә Идрис галәйһиссәламне аларга пәйгамбәр итеп җибәрде. Пәйгамбәрлек нуры Идрис галәйһиссәламгә күчкәч, ул үсеп балигъ булганчы, фәрештәләр аны Иблисләгыйньнән сакладылар.

Идрис галәйһиссәлам үсеп балигъ булгач, Җәбраил галәйһиссәлам аны пәйгамбәрлек килүе белән тәбрикләде вә дәхи Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән 30 кәгазь тапшырды, вә дәхи әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең мөбарәк сәхифәсендә адәм балалары өчен кирәкле нәрсәләрне табарсың вә дәхи шуның илә гамәл кылып, үз кавемеңне туры юлга өндәрсең», — диде. Идрис галәйһиссәлам ошбу сәхифәдән бик күп гыйлем эстәде. Үзе өйрәнгәннәрен кавеменә өйрәтте. Шулай ук аларга кием тегеп күрсәтте. Моннан соң аның кавеме тегелгән кием кия башладылар. Аннан элек бу кавем тәннәренә хайван тиресен ябынып йөри иде.

Ул үз кавеменә Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләнең хөкемнәрен, әмерләрен, хикмәтләрен, тыюларын җиткерде. Хак Тәгаләнең сәхифәдә әйткәннәрен һич кимчелексез тапшырды.

Билгеле булганча, бу заманда бөтен дөньяда торгынлык хөкем сөрә иде. Һәр тараф кояш тотылгандагы шикелле куркыныч караңгылыкта калган иде. Җир йөзе өч йөз елдан бирле берәр пәйгамбәрнең юл күрсәтүеннән мәхрүм иде. Ул чорның кешеләре бидгать вә ялгышлык тозагына эләгеп, бөтен җиһан золмәттә иде. Хаклык вә гаделлек дигәннән берни дә калмаган иде. Фәхеш вә тәкәбберлек, һәртөрле золым вә көчләү гадәт булып киткән иде. Һәркем көче җиткәннән малын, кирәк булса җанын да тартып алыр иде. Күпләр бу халәттән коткарачак пәйгамбәрне көтәләр иде. Аллаһы Тәгаләнең хак пәйгамбәре Идрис галәйһиссәлам килгәч, инсаният күкләрен каплаган золмәт вә афәт болытлары таралып, инсаният сафлана вә нурлана башлады.

«Хак Тәгаләнең сәхифәсендәгечә яшәгез!» — дип, Идрис галәйһиссәлам кавемен өндәде. Ул үзе һәртөрле рия һәм ялганнан азат иде. Инсан инсанга ышанмаган бер дәвердә аның сәхифәдән мисаллар, дәлилләр китереп сөйләгән вәгазьләренә һәркем ышана иде. Аны хөрмәт итәләр, бәхәсле мәсьәләләрдә ошбу сәхифәдән китергән дәлилләренә бердәм риза булалар иде. Соңыннан аның пәйгамбәрлегенә ышанмаган дошманнары да, аңа индерелгән сәхифәләрнең кеше тарафыннан язылырга мөмкин түгеллегенә ышанып, ялган вә рия белән килешмәвен күреп, аңар иярделәр. Җәнабел Хак Тәгалә Үз бәндәләренә юл сайлау хокукы бирде. Бу төшенчәнең әһәмияте бик зур. Чөнки инсан ихтыяр иреген яхшылыкка юнәлтсә, Аллаһы Тәгалә яхшылыкны бар итә, начарлыкка юнәлтсә — яманлыкны бар итә. Бу җәһәттән караганда, инсан җәннәтне дә, җәһәннәмне дә үз теләге белән казана. Әлбәттә, яралтучыбыз бары тик Җәнабел Хактыр. Ул теләмәсә, Ул бар итмәсә, берни дә булмас иде. Идрис галәйһиссәлам үз кавеменә вәгазьләрендә бүтәннәргә золым итү, ялганга ант итү, хәрам булган эчемлекләр эчү, иманлы кешеләрне газаплау, гөнаһыңны оныту, үз-үзеңне галимгә санау, яла ягу, дин дошманнарын хөрмәт итү кебек нәрсәләрнең Ислам шәригатенә хилаф, ягъни кире булуын сөйләде.

Аллаһы Тәгалә Идрис галәйһиссәламне пәйгамбәр итеп җибәргәнче, бу кавемнең бәгъзеләре: «И, Раббыбыз! Безнең нәселебездән килгән өммәт арасыннан бер пәйгамбәр җибәрсәң иде. Ул безгә Синең сәхифәңне укысын, вә хөкемнәреңне өйрәтсен, безне гөнаһлардан аруласын. Һич шөбһәсез, Син газиз вә хәкимсең», — дип дога кылучылар бар иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә аларның кылган догаларын кабул әйләп пәйгамбәр җибәргәннән соң, алар, элек кылган гөнаһлары өчен үкенеп, тәүбә-истигъфар кылдылар.

Сөбханә вә Тәгаләнең Идрис галәйһиссәламгә җибәрелгән сәхифә кәгазендә: гыйбадәт гыйлеме, хинзир (дуңгыз) итенең хәрам булуы, тәнгә зарар китерә торган нәрсәләрнең хәрам булуы, айда ничә көн вә ел башында ничә көн руза тоту, намаз уку, госел, хәездән соң госел, фарыз, вәҗиб гамәлләр язылган иде. Ул аларны үзенең кавеменә өйрәтте.

Идрис галәйһиссәлам һәр көн 12 мең тәсбих әйтер иде. Гыйбадәтенең күплеге сәбәпле, фәрештәләр белән дуслыгы зур иде. Сөбханә вә Тәгалә аның тәкъвалыгын, ягъни Хак Тәгалә юлында ихласлык белән хезмәт итүен күреп, аңар ошбу мөбарәк доганы иңдерде: «Әллаһүммә әслих лии диинийәлләзии һүә гидмәтү әмри үәслих лии дүнйәл-ләтии фииһәә мәгәшии үәслих лии әхыйратәл-ләтии рахәтәл-мәүтә рахәтәллии миң күлли шәрри».

Мәгънәсе: *«И, Раббым! Минем иманымны нык ит, чөнки ул — минем өчен бар афәтләрдән котылу шарты. Минем дөньяви тормышымны яхшырт, чөнки мин аны иманлы хәлемдә яшәргә тиешмен вә дәхи мине ахирәткә хәзерлә, чөнки мин ахирәткә әйләнеп кайтырга тиеш булам вә бу дөньяны савапларга ирешү өчен бер баскыч ит, үлемне бер рәхәт итеп кабул иттер».*

Идрис галәйһиссәлам үзенең кавеменә Аллаһы Тәгаләгә ышану кәлимәләрен өйрәтте: «Ләә иләәһә илләллааһ Идрисү нәби Аллаһ». Бу инде «Гыйбадәт кылырга башка зат юктыр, мәгәр бер Аллаһыдан башка, Идрис галәйһиссәлам Аның җирдәге пәйгамбәре» дигән сүзләр булуын вә дәхи бу кәлимәләрне әйткән бәндәдә шик-шөбһә калмаска тиешлеген аңлата. Ул аларга: «Әй, минем кавемем, башыгызны күтәреп карагыз күк, кояш, ай, йолдызларга вә дәхи Җир бакчасын сугаручы болытларга, карагыз Җирдәге агач вә үләннәрнең

бәндәләргә шәфкать ияләре шикелле җимешләр бүләк итүләренә — болар бар да Аллаһы Тәгалә әмере илә эшләнгәнен күрерсез, боларны күргәч, ихлас күңелдән: «Әмәнтү билләһи», — дип, ягъни бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә ышанамын дип әйтсәгез, иманыгыз артыр. Галәмдә эшләнә торган эшләрнең һәркайсы чиксез илаһи бер кодрәт илә булыр.

Әй, кавемем, Аллаһыга иман китермәгән бәндәләрнең тормышы да безнеке кебек үк хөрмәтле, кадерле вә кыйммәтледер. Хак Тәгалә яралткан һәр бәндәнең ошбу җиһанда яшәргә хокукы бар. Динебез буенча, бер кешене дә хаксызга үтерергә ярамый, чөнки Ислам динендә иң зур гөнаһлардан берсе — кеше үтерү. Аллаһы Тәгалә бөтен кешеләрне хөр, ирекле итеп яралткан. Аналарыннан хөр булып туган бәндәләрне коллыкта яшәтергә сезләрнең хакы юктыр. Бәндәләрнең уй-фикерләре вә ышанулары бертөсле түгелдер, аларның дөрес фикерләрен кабул итәргә, әмма, дөрес түгелләренә җавап итеп, булган ялгышларын ошбу миңа җибәрелгән сәхифәдән дәлилләр китереп, аңлатып бирергә кирәк. Аллаһы Тәгалә яралткан адәм баласы — иң өстен, иң камил, иң дәрәҗәле барлыктыр. Аны: «Иман китермәде», — дип түбән төшерү, яла ягу, гайбәт сөйләү, сүз йөртү, мыскыл итү кебек хәлләр Исламда хәрам саналалар. Адәм балаларының малы да каны кебек хәрамдыр. Хаксызлык вә золым илә кеше малын тартып алу хәрамдыр. Һәр кешенең җанына, малына, намусына, уй-фикерләренә вә ышануларына хөрмәт күрсәтеп, без Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә алдында вазыйфаларыбызны үтәгән булырбыз.

Әй, кавемем! Ялган сөйләмәгез. Аллаһы Тәгалә дә вә башка бәндәләр дә яратмаслар. Алдашу — Ислам динендә хәрамдыр. Хак Тәгаләдән куркыгыз, сөйләгән вакытта турысын сөйләгез. Ислам динендәге бәндә кулы вә теле илә башкаларга зарар итмәс. Үзе өчен теләгән нәрсәне кардәше өчен дә теләр. Хәләл малына хәрам катыштырмас, гаиләсенә вә газиз балаларына хәрам ризык ашатмас. Кардәшенә зарар иткән вә аны алдаган бәндә бездән түгелдер. Кылган гамәлләрегезне, эшләгән эшләрегезне Хак Тәгалә күреп вә белеп тора, фәрештәләре гөнаһ вә савапларыбызны гамәл дәфтәрләренә язып баралар. Кардәшләребезне алдасак та, Хак Тәгаләне алдау мөмкин түгел. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә әйтә: «Йәә әййүһәлләзиинә әәмәнүттәкуллаа һә үә куулүү каулән сәдиидә».

Мәгънәсе: *«Әй, бәндәләр! Аллаһы Тәгаләдән куркыгыз, сөйләгән вакытта турысын сөйләгез!»*

Ислам дине — тырышлык динедер. Динебездә тырышлыкка аерым урын бирелгән. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә аны фарыз кылган вә гыйбадәт кылу белән бер санаган. Тырышмаган кавемнәр фәкыйрь булып калырлар, башка кавемнәрнең ярдәменә мохтаҗ булырлар, көч-куәтләрен югалтып, башка кавемнәрнең кул астына төшәрләр. Мондый очракта ул кавемнәр Аллаһы Тәгалә алдындагы гыйбадәтләрен тәгәл үти алмаслар, надан булып калырлар. Бу кавемнәрнең диннәре зәгыйфьләнер, авыр хәлләргә төшәрләр. Бу турыда Аллаһы Тәгалә әйтә: «Үәбьтәгый фиимәә әәтәәкәл-лааһүд-дәәрал әәхыйратә үәләә тәнсә нәсыйбәкә минәддүнйә».

Мәгънәсе: *«Аллаһы Тәгаләнең биргәне белән ахирәт бәхетен эзлә. Дөньяда да үз өлешеңне онытма».*

И, кавемем! Ислам динендә шәфкатьлегә вә ярдәм итүчегә мәрхәмәт диелә. Бу диндә булган бәндә каты бәгырьле, каты күңелле түгел, киресенчә, мәрхәмәтле вә яхшы күңелле булырга тиеш. Хак Тәгаләнең яратканнары өчен күңелендә шәфкать вә мәрхәмәт йөрткән бәндә — кяферләрдән өстен бәндәдер. Каты күңелләр, башкаларга золым вә газап кылучылар дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле була алмаслар. Ислам дине барыгызның да сәламәтлеген саклаган кебек, мөселманнар да бер-берләренең кайгыларын уртаклашып, мәрхәмәт вә шәфкать күрсәтеп, яшәешне дәвам итәргә тиешләр. Бу турыда Аллаһы Тәгалә әйтә: «Рәхмәтем вә мәрхәмәтем һәрнәрсәне каплады». Ягъни Ислам дине тарафыннан безгә иңдерелгән мәрхәмәт бөтен яшәешне урап алыр. Минем кавемем бәндәләргә генә түгел, бәлки хайваннарга вә Хак Тәгалә ярал†кан барча табигатькә карата да мәрхәмәтле булырга тиеш. Шулай ук динебез ярдәмләшүне фарыз кылган. Юмартлыкның киресе булган саранлык хәрам кылынган. Бу турыда Хак Сөбханә вә Тәгалә әйтә: «Мәң җәә-ә бил хәсәнәти фәләһү гәшру әмсәәлиһә. Үә мәң җәә-ә бисәййиәти фәләә йүҗзәә илләә мисләһәә үә һүм йүзләмүүн».

Мәгънәсе: *«Кем хәерле вә гүзәл бер эш эшләп китерсә, ул кешегә ун кат савап бирелер. Кем начар бер эш эшләсә, арттырып газап кылынмас, җәзасы — эшләгән гөнаһы кадәрледер».*

Хәбәрләрдә бу турыда болай язалар: кайчан пәйгамбәр

булды исә, Идрис галәйһиссәлам барча адәм угланнарын иманга өндәде, бәндәләрнең күбесе кабул кылдылар. Дөньяда Ислам әһелләре күбәйде. Шул заманда иман китергән бәндәләргә ул шәһәрләр салырга вә дәхи каләм илә язу язарга, кием тегеп кияргә өйрәтте. Бу һөнәрләр һәркайсы аңа Аллаһы Тәгалә иңдергән сәхифәдә язылган иделәр. Моннан соң үлем михнәтен, кабер караңгылыгын, кыямәт катылыкларын уйлап шулкадәр гыйбадәт кылды ки, хәтта җир йөзе халкының гыйбадәте кадәр кылган гыйбадәте күккә күтәрелер иде.

Бу кадәр гыйбадәт кылучы вә дәхи адәм балаларына күркәм вәгазьләр сөйләүче Идрис пәйгамбәрне күрергә дип, Газраил фәрештә Аллаһы Тәгаләдән рөхсәт сорады. Хак Сөбханә вә Тәгалә риза булды. Газраил галәйһиссәлам бер күркәм карт кыяфәтендә Идрис галәйһиссәлам янына килде. Алар бергә өч көн тордылар. Газраил галәйһиссәлам ашамас вә эчмәс иде. Алар гел гыйбадәттә булдылар. Идрис галәйһиссәлам аның фәрештә икәнен күңеле илә сизеп, аннан сорады: «Син Аллаһы Тәгаләнең кайсы фәрештәсе булырсың?» «Мин Хак Тәгаләнең адәмнәрнең җаннарын алучы Газраил фәрештәсемен, сине күрергә килдем», — диде. Идрис галәйһиссәлам: «Күрешергә килдеңме, җанымны алырга килдеңме?» — дип сорады. «Синең Аллаһы Тәгаләгә атап искиткеч күп гыйбадәт кылуыңны белеп, күрешергә дип килдем», — диде Газраил галәйһиссәлам. Идрис галәйһиссәлам: «Минем җанымны ал! Үлем ачысын татыйм», — диде. Газраил галәйһиссәлам Хак Тәгаләдән рөхсәт сорады. Билгесезлектән аваз килде: «Колым Идрис ни теләсә, шуны үтә!» Бәс, Газраил галәйһиссәлам Идрис галәйһиссәламнең җанын алды, янә тәненә куйды. Идрис галәйһиссәлам үлеп терелде. Идрис галәйһиссәлам: «Янә бер теләгем бар, мине күккә алып мен, Аллаһы Тәгаләнең җәһәннәмен вә оҗмахын күрим», — диде. Газраил галәйһиссәлам: «Морадың ни-нәрсә?» — диде. Идрис галәйһиссәлам: «Җәһәннәм вә оҗмахны күреп, гыйбадәткә иҗтиһадым тагы да артсын дигән ният илә күрергә телим», — диде.

Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең рөхсәте илә Газраил галәйһиссәлам Идрис пәйгамбәрне җәһәннәмгә китерде, сакчы фәрештәләр тәмуг капкаларын ачтылар. Идрис галәйһиссәлам күрде, ут тәмугы җиде каттыр, һәркайсының исеме бар. Иң астагы тәмугның исеме «Һәвийәһ». Башка каттагы тәмуглар

аның газабыннан вә утының эсселегеннән ыңгырашып елыйлар. Икенче кат тәмугның исеме «Сәгыйр», ягъни газап уты мәгънәсендә. Өченче кат тәмуг «Хотәмәһ», ягъни коточкыч хәсрәт урыны мәгънәсендә. Дүртенче кат тәмугны «Ләза» диләр, ягъни чәчне вә башны яндыручы ут мәгънәсендә. Бишенче кат тәмуг «Сәкарь», ягъни яндыручы ут мәгънәсендә. Алтынчы тәмуг «Җәхим», ягъни фасикълар урыны. Җиденче кат тәмуг «Җәһәннәм», анда кылган гөнаһлары өчен тәүбә итмичә киткән Мөхәммәд галәйһиссәлам өммәтләрен салырлар.

Идрис галәйһиссәлам боларны күргәч бик каты курыкты вә әйтте: «И, Газраил, тәмугны күрдем, инде Хак Тәгаләнең оҗмахына алып бар», — диде. Газраил галәйһиссәлам аны оҗмахка алып барды. Идрис галәйһиссәлам оҗмахка кергәч, җәннәтләрнең сигез кат икәнен күрде. Беренче кат җәннәтнең исеме «Дәрүл-Җәләл», икенче кат җәннәтнеке «Дәрүл-Сәлам», өченче кат җәннәтнеке «Җәннәтүл-Мәэвә», дүртенче кат «Җәннәтүл-Хәмид», бишенче кат «Дәрүл-Вәсилә», алтынчы кат «Җәннәтүл-Фирдәвес», җиденче кат «Җәннәтүн-Нәгыйм», сигезенче кат «Җәннәтүл-Гаден».

Идрис галәйһиссәлам оҗмах нигъмәтләрен авыз итте, хур кызларының матурлыкларын күреп биһуш булды. Җәннәт — ул рәхәт йорты икәнен үз күзләре илә күргәч, гаҗәпкә калып, ничек булса да бире дә мәңге калу чарасын эзли башлады. Газраил галәйһиссәлам: «Йә, Идрис, чык инде җәннәттән, сине үз урыныңа илтим», — диде. «Мин чыкмыйм, мәгәр Хак Тәгаләнең хөкеме ничек була?» — диде. Аллаһы Тәгалә бу икесенә хөкем итәргә бер фәрештә җибәрде. Фәрештә Газраил галәйһиссәлам илә Идрис галәйһиссәламнең низагын күрде. Газраил фәрештә хикәятне баштан ук сөйләп бирде. Фәрештә Идрис галәйһиссәламгә: «Син ни әйтәсең?» — диде. Идрис галәйһиссәлам: «Минем оҗмахтан чыгуым дөрес булмас иде», — диде. Фәрештә әйтте: «Сиңа әле оҗмахка керергә вакыт җитмәгән», — диде. Идрис галәйһиссәлам: «Миңа вакыт җитте, чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте: «Күлли нәфси зәәикатүл-мәүти».

Мәгънәсе: *«Һәркем үлем ачысын татучы».*

«Мин исә үлем ачысын татыдым».

Икенчесе, Аллаһы Тәгалә әйтте: «Үә ин миңкүм илләә үәәириdүһә».

М ә г ъ н ә с е : *«һәркем тәмугны күрер».*

«Мин тәмугны күрдем».

Өченчесе, оҗмах әһеле хакында Аллаһы Тәгалә әйтә: «Хаалидиинә фииһәә ләә йәбгунә гәнһәә хиүәлә».

М ә г ъ н ә с е : *«Мәңге оҗмах әһеле булучы ул оҗмахтан чыгуны теләмәс».*

«Инде мин боларның барысын үтеп оҗмахка кердем, чыгуны теләмим», — диде. Фәрештә ни әйтергә дә белмәде. Хак Тәгаләдән фәрман килде: «Идрис колым дөрес сөйләде, ул җәннәтемдә калсын!»

«Әл-Әнбия» сүрәсенең 85–86 нчы аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَإِسْمَٰعِيلَ وَإِدْرِيسَ وَذَا ٱلْكِفْلِ كُلٌّ مِّنَ ٱلصَّٰبِرِينَ ۝٨٥

وَأَدْخَلْنَٰهُمْ فِى رَحْمَتِنَآ إِنَّهُم مِّنَ ٱلصَّٰلِحِينَ ۝٨٦

«Үә Исмәәгиилә үә Идриисә үә Зәлкифли, күллүм-минәс-саабирииин (85). Үә әдьхалнәәһүм фии рахмәтинә, иннәһүм минәс-саалихиин (86)».

М ә г ъ н ә с е : *«Вә Исмәгыйльне, вә Идрисне, вә Зөлкифелне хәтерләгез, аларның барчасы бәла-казаларга сабыр итүчеләрдән иде (85). Без аларны рәхмәтебезгә керттек, чөнки алар чын изгеләрдән иделәр (86)».*

Хәбәрләрдә сөйләнелә: кыямәт көненәчә дүрт пәйгамбәр теректер, икесе күктә, икесе җирдәдер. Күктә — Идрис галәйһиссәлам илә Гайсә галәйһиссәламдер, җирдә — Хозыр галәйһиссәлам илә Ильяс галәйһиссәламдер. Кыямәт көнне бу дүрт пәйгамбәрнең өчесе үләр, берсе үлмәс — ул Идрис галәйһиссәламдер. Оҗмахта мәңге калыр.

Аллаһы Тәгалә Идрис галәйһиссәламнең ихлас күңелдән бу кадәр гыйбадәт кылуының әҗерен җәннәт белән кайтарды. Гыйбадәт кылганда турыдан-туры бары тик Җәнабел Хакның ризалыгын төп максат итү кирәк. Аллаһы Тәгаләгә ихласлык хакында Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең бер хәдис-шәрифе дә бар: «Һәләкәннәәсү илләл-гәлимүүнә үә һәләкәл-гәлимүүнә илләл-гәмилүүнә үә һәләкәл-гәмилүүнә үә илләл-мүхлисуунә үәл-мүхлисуунә гәләә хатара гәзыйййм».

М ә г ъ н ә с е: *«Инсаннар һәлак булырлар, әмма гыйлемле булганнар котылырлар. Гыйлеме булганнар да һәлак булыр, әмма гамәл кылганнар котылыр. Гамәл кылганнар да һәлак булыр, бары тик ихлас күңелле бәндәләр генә котылыр. Ихлас күңелле мохлисләр дә, ягъни ачык, ихлас күңеллеләр дә киртәләр аша гына котылырлар».*

Югарыда китерелгән ошбу хәдис Идрис галәйһиссәлам кыйссасына турыдан-туры барып тоташа. Җәнабел Хакның ризалыгы ихлас күңелдән кылган гыйбадәтләр белән казаныла, ә бик күп бәндәләрнең буйсынуы белән түгел. Чөнки күп бәндәләрнең буйсынуы — Аллаһы Тәгаләнең шулай теләве аркасында, бәндәләр моны теләмәсәләр дә, Хак Тәгалә аны бирер. Кайсыбер вакыт, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен ихлас күңелдән әйтелгән бер кәлимә сүз сәбәбе нәҗат, ягъни күпме бәндәләрнең котылуына сәбәп була вә мәдари-риза, ягъни Аллаһының ризалыгына сәбәп булыр. Аллаһы Тәгалә теләгән бер кешенең иршады, ягъни хак юлга юнәлүе Җәнабел Хакның мең кешенең иршадына бәрабәр ризасына сәбәп була. Идрис галәйһиссәлам дә, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алыйм дип, гомеренең күп өлешен гыйбадәттә үткәрде. Ихлас күңелдән кавеменә Ислам диненең хаклыгын, Аллаһының берлеген вәгазьләде. Хак Тәгалә аның ихлас күңелдән кылган гыйбадәтен вә дәхи кылган догаларын кабул әйләде вә Үзенең җәннәтенә кертте.

Идрис галәйһиссәламнең ун хасияте бар. Беренчесе, пәйгамбәр булып килде; икенчесе, йолдызлар гыйлеме (астрономия) аңардан калган, бу гыйлемгә нигез салучылардан булды; өченчесе, язуны әүвәл ул чыгарды; дүртенчесе, көмешне ул чыгарды; бишенчесе, сугыш коралы ясауны ул чыгарды; алтынчысы, мөшрикләр (Аллаһы Тәгаләне инкарь итүчеләр) белән сугыш аңардан калды; җиденчесе, мөшрикләрне әсир алу аңардан калды; сигезенчесе, кием тегүне ул чыгарды, аңа кадәр тәннәренә хайван тиресен ябып йөриләр иде; тугызынчысы, «Ләә иләәһә илләллааһү идрис нәбийүллаһ» дигән шаһәдәт кәлимәсен кавеменә өйрәтте; унынчысы, күккә күтәрелде.

Шайтан белән җеннең аермасы нәрсәдә? Хак Сөбханә вә Тәгалә шайтаннарны ир вә хатын итеп яратты, туганнан соң кы-

яматкә кадәр үлмиләр. Җеннәрне дә ир вә хатын итеп яралтты, әмма алар туып күпмедер гомер иткәннән соң, үләләр.

Музыка кораллары ясау шайтаннан калган гамәл. Идрис галәйһиссәламнән соң күп вакыт үтмәде, Ислам дине онытылды, шәригать ташланды. Җир йөзе азгынлык белән тулды. Адәм галәйһиссәлам Шис галәйһиссәламнең балаларына: «Кабилнең балаларына катнашмагыз, аларга кызларыгызны бирмәгез, алардан кыз алмагыз», — дип васыять иткән иде. Шул сәбәпле Шис галәйһиссәламнең балалары сахраларда, ә Кабилнең балалары шәһәрләрдә тордылар. Иблис ләгыйнь беркөнне хезмәтче сурәтенә кереп, Кабил балаларының берсенә ялланды. Ул бер уен коралы ясады, аның тавышы еракларга таралды, бу халыкның аннан да матуррак тавышны ишеткәннәре юк иде. Шуны тыңларга күп халык җыелды. Иблис үзе генә бу уен коралында уйный белә иде. Ирләр вә хатыннарның барчасы җыелып, хәйран булып, авызларын ачып тыңладылар. Моннан соң эчү мәҗлесе оештырып, бик зур бәйрәм иттеләр. Шис галәйһиссәламнең балалары да бу хәбәрне ишетеп килделәр. Ирләр вә хатыннарның барчасы җыелганын күрделәр. Кабилнең балалары бик матур иделәр. Шул сәбәпле, Шис галәйһиссәламнең балалары Кабил балалары белән катнашып киттеләр, васыятьне оныттылар. Эчү вә катнашу булган бер җирдә Иблис үзенең уен коралы белән килеп җитә иде. Бу сихри моң аларны көчсез, ихтыярсыз итә иде.

Потларга табына башлауның сәбәбе шайтан ләгыйньнән башлана. Потка табына башлауның сәбәбе шулдыр: Адәм галәйһиссәламнең вафатыннан соң, Кабил балалары белән катнашкан кяфер балалары Шис галәйһиссәламнең балаларын Адәм галәйһиссәламгә зиярәт кылдырмадылар. Шайтан, олуг остаз кыяфәтенә кереп, аларга әйтте: «Мин сезгә бабагыз Адәм кебек бер сурәт ясап бирермен, бабагызны олыласагыз, саваплы булырсыз», — диде. Шис галәйһиссәламнең балалары моны шатланып кабул иттеләр. Озак та үтмәде, Иблис аларга биш пот ясады, аларны: Вәд, Суагъ, Йәгүс, Йәгук, Нәсер дип атады. Шис балалары, болар безнең бабабызга бик тә ошаганнар, дип, ул потларга табына башладылар. Хак Тәгалә аларга Нух галәйһиссәламне пәйгамбәр итеп җибәрде, потларга табынудан тыйды, алар ишетмәделәр. Соңыннан туфан белән һәлак булдылар.

# НУХ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Нух галәйһиссәлам турында Коръән Кәримнең 43 җирендә искә алына. Аның Аллаһы Тәгаләнең хак пәйгамбәре булуы хакында — 7 җирдә, кяферләр илә бәхәсе хакында — 12 җирдә, көймә төзүе хакында — 5 җирдә, бөтен дөньяны су басуы, ягъни туфан хакында 13 җирдә телгә алына.

Муса галәйһиссәламгә җибәрелгән Тәүрат китабының 6 — 8 нче бүлекләрендә дә Туфан турында бик җентекләп сөйләнә.

Нух галәйһиссәламнең атасы Ләмәк, аның атасы — Мәтүшәлих, аның атасы — Идрис галәйһиссәлам, аның атасы — Ирд, аның атасы — Микаил, аның атасы — Шис галәйһиссәлам, аның атасы Адәм галәйһиссәлам иде.

Адәм галәйһиссәлам илә Хәва радыйаллаһу ганһәнең балалары, балаларының балалары саны артканнан-арта барды. Адәм балалары арасында азгынлык бик күбәеп, тугрылык бөтенләй югалганда, бәндәләр үзләрен юктан бар кылган Хак Тәгаләне оныттылар. Алар үз куллары белән ясаган сыннарны тәңре дип уйлыйлар, вә аларның бәндәләргә ярдәм итүләренә яки зарар китерүләренә ышаналар иде.

Аллаһы Тәгалә хәзрәти Нух галәйһиссәламне Бийүрасиб исемле падишаһка вә аның кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрде. Бу кавем үзләре ясап куйган потларга табынып, алардан үз кирәкләрен сорап гомер кичерәләр иде. Потларның олуглары Вәдү, Сәүәг, Йәгүс, Йәгүк вә Нәср исемле иделәр.

Нух галәйһиссәлам Адәм галәйһиссәламнән соң җиде йөз сиксән җиде ел үткәннән соң, хәзрәти Идрис галәйһиссәламнең күккә ашуына туксан биш ел узгач, бу кавемгә пәйгамбәр итеп җибәрелде.

Риваятьләргә караганда, хәзрәти Нухның исеме Искәндәр иде. Кавеме өчен егълап, Сөбханә вә Тәгаләгә күп мөнәҗәтләр әйткәне өчен Нух дип тәсмия, ягъни исем куштылар. Нух галәйһиссәлам озын буйлы, таза гәүдәле, зур сакаллы, йомшак табигатьле адәм иде. Алты йөз елдан артык иманга өндәп, бары 80 кешене генә иманга кертә алды.

Югарыда әйткәнебезчә, хәзрәти Нух галәйһиссәламнең пәйгамбәр булып килүеннән әүвәл инсаннар арасы гаян гасыйлык, ягъни күзгә күренеп торган буйсынмаучылык белән тулган иде. Хак Тәгалә шул бозык кавемгә пәйгамбәр итеп Нух галәйһиссәламне җибәрде вә боерды: «Әй, Нух, син ошбу кавемгә хак юлны аңлатып, халыкны бер Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылырга өндәрсең! Әгәр дә инде хаклыкны кабул итмәсәләр, аларга газапның олугы киләчәк». Бу хакта Коръән Кәримнең «Нух» сүрәсе, 1–4 нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ۝ اِنَّآ اَرْسَلْنَا نُوحًا اِلٰى قَوْمِهٖٓ اَنْ

اَنْذِرْ قَوْمَكَ مِنْ قَبْلِ اَنْ يَاْتِيَهُمْ

عَذَابٌ اَلِيمٌ ۝١ قَالَ يٰقَوْمِ اِنّ۪ي لَكُمْ نَذِيرٌ مُبِينٌ ۝٢ اَنِ اعْبُدُوا اللّٰهَ

وَاتَّقُوهُ وَاَطِيعُونِ ۝٣ يَغْفِرْ لَكُمْ

مِنْ ذُنُوبِكُمْ وَيُؤَخِّرْكُمْ اِلٰٓى اَجَلٍ مُسَمًّى اِنَّ اَجَلَ اللّٰهِ اِذَا جَٓاءَ

لَا يُؤَخَّرُ لَوْ كُنْتُمْ تَعْلَمُونَ ۝٤

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Иннәә әрсалнәә Нуухән иләә каумиһиән әңзир каумәкә миң кабли әййәэтийәһүм гәзәәбүн әлиим (1). Каалә йәәкауми иннии ләкүм нәзиирум-мүбиин (2). Әнигбүдүл-лааһә үәттәкуһү үә әтыййгүүн (3). Йәгъфир ләкүм миң зүнүүбикүм үә йүәххыйркүм иләә әҗәлим-мүсәммә. Иннә әҗәләллааһи изәә җәә-ә ләә йүәххар. Ләү күңтүм тәгләмүүн (4)».

Мәгънәсе: *«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Тәхкыйк, Без Нухны кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрдек, Аллаһы Тәгаләнең каты газабы килмәс борын кавемеңне кур-*

*кыт, дип (1). Нух әйтте: «И, кавемем, дөреслектә, мин Аллаһы Тәгаләнең газабы илә ачык куркытучы сезгә җибәрелгән пәйгамбәрмен (2). Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылыгыз вә Аннан гына куркыгыз, гөнаһлардан сакланыгыз һәм дә миңа итагать итегез, дип боерамын (3). Әгәр минем боерыкны кабул итеп тәүбә итсәгез, Ислам динен кабул итеп мөселман булсагыз, Аллаһы Тәгалә гөнаһларыгызны ярлыкар һәм сезне билгеләнгән әҗәлегезгә кадәр яшәтер. Тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә билгеләгән әҗәл килсә, ул һичбер вакытка кичектерелмәс. Әгәр шуны уйласагыз, иншә Аллаһ, гөнаһ кылмассыз (4)».*

Хәзрәти Нух шул рәвешле күп еллар буе үз кавемен Ислам диненә һәм «Гыйбадәт кылырга лаек зат бер Аллаһы Тәгалә генәдер, Нух галәйһиссәлам Аның пәйгамбәредер», — дип танырга чакырды. «Әл-Әгъраф» сүрәсенең 59 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

لَقَدْ أَرْسَلْنَا نُوحًا إِلَىٰ قَوْمِهِ فَقَالَ يَٰقَوْمِ اعْبُدُوا اللَّهَ مَا لَكُم
مِّنْ إِلَٰهٍ غَيْرُهُ إِنِّي أَخَافُ عَلَيْكُمْ عَذَابَ يَوْمٍ عَظِيمٍ ٥٩

«Ләкаде әрсәлнәә Нүүхән иләә каумиһии фәкаалә йәәкаумиг будүл-лааһә мәә ләкүм мин иләәһин гайруһү инннии әхаафү галәйкүм газәәбә йәүмин газыййм (59)».

М ә г ъ н ә с е : *«Тәхкыйк, Нухны кавеменә рәсүл итеп җибәрдек, ул әйтте: «И, кавемем, фәкать бер Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылыгыз! Аннан башка Илаһыгыз юк, каһәре зур булган туфан көненең газабы сезгә ирешер дип куркам (59)».*

Ихлас күңелдән сөйләгән вәгазь-нәсыйхәтләрдән соң Нух галәйһиссәламнең өч углы, аларның хатыннары, тагын 72 кеше иман китерделәр. Башкалары аңар ышанмадылар, хәтта үзенең Йәм исемле кече углы иманга килмәде. Нух галәйһиссәлам вәгазь сөйләгәндә алар аннан көләләр, аңа җәфалар китерәләр, ялганчы дип атыйлар. Бу турыда Коръән Кәримнең «Һуд» сүрәсе, 27 нче аятендә әйтелә:

فَقَالَ الْمَلَأُ الَّذِينَ كَفَرُوا مِن قَوْمِهِ مَا نَرَاكَ إِلَّا بَشَرًا مِّثْلَنَا
وَمَا نَرَاكَ اتَّبَعَكَ إِلَّا الَّذِينَ هُمْ أَرَاذِلُنَا بَادِيَ الرَّأْيِ وَمَا
نَرَىٰ لَكُمْ عَلَيْنَا مِن فَضْلٍ بَلْ نَظُنُّكُمْ كَاذِبِينَ ٢٧

«Фәкааләл мәләүл-ләзиинә кәфәруу миң каумиһии мәә нәраакә илләә бәшәрам-мисләнәә үә мәә нәраакәт-тәбәгәкә илләлләзиинә һүм әраазилүнәә бәәдийәрраэи.Үә мәә нәраа ләкүм галәйнәә миң фәдълим-бәл нәзүннәкүм кәәзибиин (27)».

М ә г ъ н ә с е : *«Нух кавеменең олуглары әйтте: «И, Нух, син безнең кебек үк адәмсең, артык бер җирең дә юк, дәхи сиңа ияргән бәндәләр дә арабызда иң түбән бәндәләрдер вә безгә караганда сездә дә бернинди артыклык күрмибез, шуңа күрә сезне ялганчылар дип уйлыйбыз (27)».*

Нух галәйһиссәламгә кадәр бертуган кыз кардәшеңне ир кардәшеңә никахлау дөрес иде. Аллаһы Тәгаләнең әмере илә Нух галәйһиссәлам аны хәрам кылды.

Нух пәйгамбәр үз кавемен иманга өндәп болай диде: «И, кавемем, мин сезне үзем белән бергә бер Аллаһы Тәгаләгә иман китерергә вә гыйбадәт кылырга чакырам. Әгәр инде мин әйткәнчә булсагыз, Җәнабел Хак сезнең элек кылган гөнаһларыгызны да кичерәчәк вә дәхи газап җибәрүдән тыелып торачак. Гомерләрегезнең актык сәгатьләренә кадәр рәхәттә гомер кичерерсез. Уйлап карагыз, Хак Сөбханә вә Тәгалә сез файдалансын өчен терлекләре, суы, үсемлеге вә агачлары булган җирне яратты. Уйлап, фикерләп эшләсеннәр өчен аң бирде, ишетә торган колаклар, сөйли торган авыз, ис сизә торган борын, йөри торган аяклар, эшли торган куллар бүләк итте. Сөбханә вә Тәгалә кояшны, айны, йолдызларны, җирдәге вә күктәге бар нәрсәне сезнең өчен яратты. Сез тәңре дип атаган бу сыннарыгызны үз кулларыгыз белән ясадыгыз. Үзегез дә күреп торасыз, болар бит гади ташлар гына, әмма сез аларга чын Аллаһы Тәгаләгә табынгандай табынасыз, алардан ниндидер ярдәм өмет итәсез, бу ташлар ничек итеп сезгә ярдәм вә шәфкать итә алсын ди?»

Мондый матур вәгазь-нәсыйхәтләрдән соң боларның бәгъзеләре әйттеләр: «Валлаһи, Нух бик акыллы сүзләр сөйли, чыннан да, бу сыннар сөйләшмиләр дә, йөрмиләр дә,ниләр булганын күрмиләр дә. Ничек итеп алар тәңре була алсыннар да, ничек итеп безгә ярдәм итә алсыннар? Юк, таш тәңре була алмый», — дип Нух галәйһиссәламгә иман китерделәр. Ләкин күпчелек халык аңа ышанмады. Алар үзләре ясап куйган потларга карап: «Болар безнең тәңреләребез вә без аларны беркайчан да ташламаячакбыз», — диделәр.

Нух галәйһиссәлам һәр көнне әлеге тәкәббер, үзсүзле кяферләр янына килә, аларны янә үзләре ясап куйган потларга табынуларын ташлап, бер Аллаһыга гыйбадәт кылырга өнди. Кяферләр: «И, Нух, син гакылдан шашкансың, ник вакыт уздырып буш сүзләр сөйлисең? Элегрәк акыллы кеше идең бит син, ни булды сиңа?» — дип аннан көлделәр. Нух галәйһиссәлам, бернигә дә карамыйча, Хак Тәгаләнең әмерен җиренә җиткерергә тырышты. Ул явыз кяферләр янына көн саен килә вә көн саен аларны иман китерергә өндәвен дәвам итә. Бер көнне ул аларга болай диде: «И, кавемем, Сөбханә вә Тәгалә сезгә ачуланыр вә Аның каргышы сезгә төшәр дип куркам. Мин бит сезне ихлас күңелдән кызганам». Кяферләр бу юлы да аннан көлделәр, аны бөтенләй ишетмәмешкә салыштылар. Бу турыда Коръән Кәримнең «Нух» сүрәсе, 5–10 нчы аятьләрендә болай диелгән:

قَالَ رَبِّ إِنِّي دَعَوْتُ قَوْمِي لَيْلًا وَنَهَارًا ﴿٥﴾ فَلَمْ يَزِدْهُمْ دُعَائِي إِلَّا فِرَارًا ﴿٦﴾ وَإِنِّي كُلَّمَا
دَعَوْتُهُمْ لِتَغْفِرَ لَهُمْ جَعَلُوا أَصَابِعَهُمْ فِي آذَانِهِمْ وَاسْتَغْشَوْا ثِيَابَهُمْ وَأَصَرُّوا وَاسْتَكْبَرُوا
اسْتِكْبَارًا ﴿٧﴾ ثُمَّ إِنِّي دَعَوْتُهُمْ جِهَارًا ﴿٨﴾ ثُمَّ إِنِّي أَعْلَنْتُ لَهُمْ وَأَسْرَرْتُ لَهُمْ إِسْرَارًا ﴿٩﴾
فَقُلْتُ اسْتَغْفِرُوا رَبَّكُمْ إِنَّهُ كَانَ غَفَّارًا ﴿١٠﴾

«Каалә рабби иннии дәгәүтү каумии ләйлән үә нәһәәра (5). Фәләм йүзидһүм дүгәә-и илләә фираара (6). Үә иннии күлләмәә дәгәүәтүһүм литәгъфира ләһүм җәгәлүү әса-

абигәһүм фии әәзәә ниһим үәстәгъшәү сийәәбәһүм үә әсарру үәстәкбәрус-тикбәәра (7). Сүммә innии дәгәүтүһүм җиһәәра (8). Сүммә иннии әгъләңтү ләһүм үә әсрартү ләһүм исраара (9). Фәкултүс-тәгъфируу раббәкүм иннәһү кәәнә гаффәәра (10)».

Мәгънәсе: *«Нух әйтте: «И, Раббым, кавемемне Ислам диненә кичләрен дә вә көндезләрен дә чакырдым (5). Минем аларны чакыруым аларның Ислам диненнән, Хак диннән качуын арттырды (6). И, Раббым Аллаһ, һәркайчан мин аларны Синең ярлыкавыңа, гафу итүеңә чакырсам, минем сүзләремне ишетмәс өчен бармакларын колакларына тыгалар, киемнәре илә бөркәнәләр, көферлекләрен дәвам итәләр вә дәхи каты тәкәбберләнү белән тәкәбберләнәләр (7). Моннан соң мин аларны, бик каты кычкырып, иманга чакырдым (8). Соңра чакыруымны ачык игълан иттем, шулай ук яшерен генә аулакта да өндәп карадым (9). Һәм әйттем аларга: «Тәүбә кылып Аллаһы Тәгаләдән истигъфар, гафу сорагыз, шиксез, Ул сезнең гөнаһларыгызны ярлыкар (10)».*

Нух галәйһиссәлам бу елларда бик күп җәфа чикте, соңыннан башкаларның хак юлга керүләреннән өмет өзде вә Хак Тәгаләгә дога кылды: «И, Раббым! Кавемем миңа карышты, минем Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәре булуыма ышанмадылар. Үзләре ясап куйган сыннарга табындылар, яше-карты зина кылдылар. Тәкәбберләнеп, олуг гөнаһларга баттылар. Раббым Аллаһ! Минем инде түземлегем бетте, җир өстендә бу бозык кяферләрдән һичкемне дә калдырма. Әгәр дә калдырсаң, алар янә үзләре ясап куйган сыннарына табына башлаячаклар. И, Раббым! Мине, ата-анамны вә дәхи иман китергәннәрне ярлыка. Боларны Үзеңнең газабыңнан сакла! И, Раббым! Залимнәргә һәлакәт җибәр», — дип дога кылды.

Җәнабел Хак Нух галәйһиссәламнең чын йөрәктән әрнеп кылган догасын кабул әйләде һәм аңа көймә ясарга әмер бирде. Бу турыда Коръән Кәримнең «Һуд» сүрәсе, 36–37 нче аяти кәримәләрендә болай диелә:

وَأُوحِيَ إِلَىٰ نُوحٍ أَنَّهُ لَن يُؤْمِنَ مِن قَوْمِكَ إِلَّا مَن قَدْ آمَنَ فَلَا تَبْتَئِسْ بِمَا كَانُوا

يَفْعَلُونَ ۞ ٣٦ وَاصْنَعِ الْفُلْكَ بِأَعْيُنِنَا وَوَحْيِنَا وَلَا تُخَاطِبْنِي فِي الَّذِينَ ظَلَمُوا إِنَّهُم مُّغْرَقُونَ ۞ ٣٧

«Үә үүхийә иләә Нүүхин әннәһүү ләй-йүәминә миң каумикә илләә мәң каде әәмән. Фәләә тәбтәис бимәә кәәнүү йәфгәлүүн (36). Үәсънәгүл фүлкә биәгйүнинәә үә үәхинәә үә ләә түхаатыйбнии филләзиинә заләмүү иннәһүм мүгъракуун (37)».

Мәгънәсе: *«Дәхи Нухка вәхи килде: «Синең кавемеңнән иман китерәселәре китерделәр, инде калганнары иман китермәсләр, аларның кылган кабахәт эшләре өчен кайгырма! (36). Вә көймә яса, Безнең күз алдыбызда һәм Безнең өйрәтүебез белән, ләкин мөселман булмаган кешеләр өчен Безгә дога кылма, «Аларны газаптан коткар», — дип, чөнки ул залимнәр туфан суына батып һәлак булачаклар (37)».*

Нух пәйгамбәр Хак Тәгаләнең әмере буенча озынлыгы өч йөз, киңлеге илле, ә биеклеге утыз терсәк зурлыгында көймә ясый башлый. Аның эчен-тышын сумала белән сыларга вә һәрбер хайваннан аталы-аналы берәр парны шушы көймәгә кертергә кушыла. Нух галәйһиссәлам вә аңа иман китергәннәр бергә бик тырышып, бер тишеген дә калдырмыйча көймәне ясыйлар. Аллаһы Тәгаләнең әмере илә аларга рәхмәт фәрештәләре дә булыша.

Нух галәйһиссәлам көймәне ясый башлагач, кяферләрнең олуглары аның яныннан үтеп киткәндә: «Кичә генә безне иманга өндәп йөргән пәйгамбәр иде, бүген балта остасы булган», — дип, төрлечә көлеп, мәсхәрә кылып үтәләр иде. Нух галәйһиссәлам: «Бүген сез безне мәсхәрә кылсагыз, иртәгә без сезнең наданлыктан көләрбез», — дип әйтте.

Нух галәйһиссәлам вә аңа иман китергән бәндәләр, бик зур һәм бик нык көймә ясап бетереп, коры җирдә яшәүче хайваннарны Хак Тәгалә әйткәнчә пар-пар итеп шунда урнаштырдылар. Аларга ашар өчен ризык әзерләнде. Һәрхәлдә, Нух галәйһиссәлам көймәсе иксез-чиксез диңгезнең көчле дулкыннары арасында йөзәргә әзер булды.

Күктә туфан галәмәтләре күренде. Көн-төн бер дә туктамыйча чиләкләп яңгыр койды. Бу мәхшәр кырык көн вә кырык төн булды. Нух галәйһиссәлам вә аңа иман китергәннәр көймәгә кереп беткәч, Хак Тәгалә әмере илә көймә ишеге үзе ябылды. Көймәгә кергәндә Нух галәйһиссәлам бер читтә торучы кече углын чакырды: «И, углым, безнең белән көймәгә кер, кяферләрдән булма», — диде. Углы: «Бу судан тау башына менеп котылырмын», — дип әйтте. Нух галәйһиссәлам:

«Бүген Сөбханә вә Тәгаләнең газабыннан беркем дә коткара алмас, сине дә, углым, биек таулар да коткара алмас, мәгәр Хак Тәгалә рәхмәт кылган кешеләр генә көймәгә менеп котылырлар», — диде. Соңра араларына зур дулкын төшеп аларны аерды вә карышкан улы суга батып һәлак булды.

Биек-биек таулар су астында калды. Су алар өстеннән унбиш терсәк биеклегендә күтәрелде. Җир йөзендә яшәүче вә үзләренең борыннары белән сулаучы барлык җан ияләре үлеп бетте. Нух галәйһиссәлам вә аның белән бергә көймәдә булган хайваннар гына исән калдылар.Көймәдә булган 80 кешенең 72 се вафат булдылар. Исән калганнардан Нух галәйһиссәлам үзе, аның хатыны, өч углы: Хам, Сам, Йәфәс вә боларның хатыннары гына булды.

Хәзерге кешеләр барчасы Нух галәйһиссәламнең өч углыннан таралган кемсәләрдер. Сам белән Нухтан таралган нәсел: гарәпләр, фарсылар вә румнардыр. Хамнан таралган нәсел: һиндлар, эфиоплар, зәңкиләр (негрлар). Йәфәстән таралган нәсел: сакалибләр, аурупалылар вә төрекләрдер.

Нух галәйһиссәламнең туфанга кадәр 950 ел яшәве хакында Коръән Кәрим аятьләреннән күрәбез. Туфаннан соң 350 ел үткәч вафат булды.

Нух галәйһиссәлам рәҗәбнең унынчы көнендә көймәгә керде, алты ай су өстендә йөреп, мөхәррәмнең унынчы көнендә көймәдән чыкты. Нух галәйһиссәлам көймәдә йөргәндә ураза тотты. Шул сәбәпле рәҗәбнең һәм мөхәррәмнең унынчы көнендә ураза тоту сөннәт булды.

Хак Тәгалә кешеләрнең гөнаһысын ахирәткә кичектерә, әмма ата-ананың бәддогасын дөньяда ук баласына бирә. Шул сәбәпле тәрбиясез балалар һәртөрле рисвайларга дучар булып, михнәт, мәшәкать күрәләр. Ул бичара балаларның тәрбиясезлеге ата-анасыннан килә. Шулай да, ата-ана, минем тәрбия кыла белмәгәнем сәбәпле булды дип уйламый, ашыгып бәддога кыла һәм догасы кабул була. Соңыннан кире кайтырга файдасы калмый.

Нух галәйһиссәлам көймәдән чыккач, дөнья яшәрде, сахраларда төрле үләннәр үсте. Беркөнне Иблис Нух галәйһиссәламгә килеп: «Әй, Нух, миңа бик зур изгелек кылдың, шуның өчен мин сиңа ни сорасаң да җавап бирермен», — диде. Нух галәйһиссәлам кабул итмәде. Хак Тәгалә вәхи кылды: «Сора,

Мин аның теленә дөреслектән башка нәрсәне китермәм». Нух галәйһиссәлам: «Сиңа минем балаларымның кайсы эше сөекле?» — диде. Иблис: «Комсызлык, саранлык, тар күңеллесеннән сөеклерәге юктыр», — диде. Нух галәйһиссәлам: «Сиңа нинди изгелек кылдым?» — дип сорады. Иблис: «Кавемеңә ашыгып бәддога кылып һәлак иттең, минем эшемне эшләдең. Мин, кайсы иманга килер икән дип, мәшәкатьләнеп йөри идем. Барысы да тәмугта миңа иптәш булды», — диде. Нух галәйһиссәлам, моны ишетеп, күп елады. Үлгәнче бу эшенә кайгыруы бетмәде. Әй, кардәшем! Кулыңда бар икән, саран булма, ашыгып бәддога кылма, комсызлык, тар күңелле булудан саклан. Шайтанны сөендермә.

Хак Тәгалә Адәм галәйһиссәламнең тәүбәсен кабул иткәч, Бәйтелмәгъмүрне иңдерде. «Тәфсир Тәйсир»дә китерелә: «Адәм галәйһиссәламнең гөнаһысын кичергәннән соң, Кәгъбәне фәрештәләр ярдәме белән Адәм галәйһиссәлам үзе төзи. Аның ташлары адәм күтәрерлек түгел иде, фәрештәләр китерделәр». Коръән Кәримдә әйтелә: «Хак Тәгалә бер өй төзеде. Әй, адәмнәр, белегез, сезгә Аллаһы Тәгалә хаҗ кылырга боерды. Бу өйне хаҗ кылыгыз!»

Хак Сөбханә вә Тәгалә барча галәмгә бу өндәүне ишеттерде. Аталар аркасыннан, аналар карыныннан, кайберәүләр бер мәртәбә, кайберәүләре берничә мәртәбә «ләббәйкә», ягъни кабул иттек, дип җавап бирделәр. Әмма кайберләре җавап бирмәде...

Туфан заманы ирешкәч, фәрештәләр ул ташларны тауларга әманәт итеп куйдылар. Кәгъбәтулланың урыны бер кызыл тау булып калды. Туфаннан соң шул кызыл тауга килеп, догалары кабул булыр иде. Ибраһим галәйһиссәлам заманына кадәр шул рәвештә калган иде. Хак Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламгә яңадан Кәгъбәне төзергә боерды. Ибраһим галәйһиссәлам, аның шәрифлеге белән, кыяматкә кадәр шәрифле булган Җәбраил галәйһиссәлам килеп, Шам тарафыннан Мәккәгә юнәлделәр. Мәккәдә улы Исмәгыйль галәйһиссәламгә Аллаһы Тәгаләнең әмерен әйтте. Исмәгыйль галәйһиссәлам җаны-тәне белән шатланып кабул итте. Әмма Хәрам шәриф мәсҗиде туфанга кадәр алыну сәбәпле, урынын белми иде. Хак Тәгалә Җәбраил фәрештә аркылы Кәгъбәнең урынын белдерде. Исмәгыйль галәйһиссәлам балчык изде, Ибраһим

галәйһиссәлам ташларны җайлап салды. Җәбраил галәйһиссәламнең ишарәте буенча, Исмәгыйль галәйһиссәлам фәрештәләр белән биш таудан таш китерделәр. Ул биш тау: Синә тавы, Зидә тавы, Лүбнән тавы, Җүди тавы һәм Хира тавы иде. Бу таулар кайберләре Мәккәдән ерак булса да, фәрештәләр күтәрү һәм ярдәм итү белән тиз һәм җиңел китерелде. Кәгъбә шәрифә бинасы тәмам биекләнгәч, югарысында бер таш җитмәде. Югарыга ташны җиңеллек белән кую өчен Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһиссәлам бер ташны аяк астына куйдылар. Аллаһының рәхмәте белән, Ибраһим галәйһиссәламнең мөбарәк аягының эзе шул ташка төшеп калды, шул сәбәпле Ибраһим галәйһиссәлам басып, Кәгъбә төзегән ташны «Мәкам Ибраһим» диеп мәшһүр кылдылар. Кәгъбәнең дивары тәмам булгач, Ибраһим галәйһиссәлам Исмәгыйль галәйһиссәламгә: «Бер әйбәт таш китер, хаҗиларга галәмәт булсын», — диде. Әбү Кәбис тавы: «Йә, Исмәгыйль, туфан вакытында Җәбраил галәйһиссәлам миңа бер таш куйды, шул ташны алып бар», — диде. Исмәгыйль галәйһиссәлам ул ташны алып килде, ул Кара таш иде. Ибраһим галәйһиссәлам ул ташны бик ошатты, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт йөзеннән сәҗдә кылды.

Кәгъбәнең биш таудан төзелүенә ни сәбәп? Риваятьтә әйтелә: «Хак Тәгалә Кәгъбә тарафына юнәлеп биш вакыт намаз укуны фарыз кылды, биш намазның савабы биш тау кадәр булыр». Галимнәрнең кайберләре әйтүенчә, Кәгъбәнең заһиры (тышкы тарафы) биш таудан төзелде, ә Кәгъбәнең батыны (эчке ягы) Ислам диненең биш әркянедер.

Нух, Гад, Сәмуд, Лут кавемнәрен Аллаһы Тәгалә кара яки кызыл болыт җибәреп һәлак итте. «Әл-Әнбия» сүрәсе, 30 нчы аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтә:

أَوَلَمْ يَرَ الَّذِينَ كَفَرُوٓا أَنَّ السَّمٰوٰتِ وَالْأَرْضَ كَانَتَا رَتْقًا فَفَتَقْنٰهُمَا وَجَعَلْنَا مِنَ الْمَآءِ
كُلَّ شَىْءٍ حَىٍّ أَفَلَا يُؤْمِنُونَ ﴿٣٠﴾

«Әүәләм йәралләзиинә кәфәруу әннәс-сәмәәүәәти үәл-әрда кәәнәтәә раткаң фәфәтакънәәһүмә. Үә җәгәлнәә минәл-мәәи күллә шәйин хәйи. Әфәләә йүэминүүн (30)».

Мәгънәсе: *«Җир белән күкләр бергә кушылган иделәр, Без аларны аердык вә һәртөрле терек иясен судан чыгардык (30)».*

Янә «әр-Рум» сүрәсе, 48 нче аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Аллааһүлләзии йүрсилүр-рийәәхә фәтүсиру сәхәәбәң фәйәбсүтүһү фиссәмәә-и кәйфә йәшәә-ү. Үә йүҗгәлүһү кисәфәң фәтәрал үәдка йәхърәҗү мин хыйләәлиһ. Фә изәә әсаабә биһии мәййәшәә-ү мин гибәәдиһии изәә һүм йәстәбшируун (48)».

Мәгънәсе: *Аллаһы Тәгалә җилләрне җибәрер вә алар белән болытларны күтәрер, вә ул болытларны үзе теләгәнчә бер-берләренә кушып туплар, вә кисәкләргә бүләр, күрерсең, яңгырны болытлар арасыннан чыгарыр, әгәр ул болытларны Үзе теләгән бәндәләренә ирештереп яңгыр яудырса, шул вакытта алар шатланырлар (48)».*

Аллаһы Тәгаләнең: «Һәртөрле терек иясен судан чыгардык», дигәне дәлил түгелмени? Ә су үзе кайдан, нәрсәдән барлыкка килә соң? Бик борынгы галимнәр җир йөзендә суның килеп чыгышы турында ялгыш фикердә торганнар. Алар фикеренчә, караңгы җир куенында, тау куышлыкларында яшеренеп яткан су, җир асты юллары буйлап, даими рәвештә океан-диңгезләргә чыгып, аларны тутырып торган. Бу галимнәр чишмәләрне дә шул яшерен бер җирдән килеп тора дип уйлаганнар.

Суның килеп чыгышы турында бүгенге галимнәрнең фикерләре бераз үзгәрәк, әмма алар да әле бу сорауга тулы җавап биреп бетерә алмыйлар. Бу сорауга җавапны «әр-Рәгъд» сүрәсенең 17 нче аятеннән табарга була: «Әңзәлә минәссәмәә-и мәә-әң фәсәәләт әүдийәтүм-бикадәриһәә фәхтәмәләс-сәйлү зәбәдәр-раабийә (17)».

Мәгънәсе: *«Аллаһы Тәгалә күктән суны иңдерде һәм тармакландырды, һәм ул су көчле агымнар булып билгеле бер үлчәү белән акты (17)».*

Шушының илә Нух галәйһиссәлам кыйссасы тәмам. Җәнабел Хак барча әһле Ислам динендә булучыларга хәер вә бәрәкәт бирсә иде дип теләп калам.

Үәссәламүгаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ!

# ҺУД ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Туфаннан соң өч йөз ел үткәч, Гарәбстан ярымутравының көньягында, Йәмән әтрафында, Әхкаф (комлык) дигән җирдә Гад кавеме яшәгән. Моңа дәлил буларак, Аллаһы Тәгаләнең Коръән Кәрименең 46 нчы сүрәсе «әл-Әхкаф» дип аталган.

Гад халкы гаять озын буйлы, алыптай көчле, бернидән дә курыкмый торган куәтле халык иде. Бу халык башта үзләре яшәгән әтрафны мәгъмүр әйләделәр (төзекләндерделәр, матурладылар). Иген иктеләр, гүзәл вә күркәм биналар, шәһәрләр төзеделәр. Ләкин аларның бу хәлләре озакка бармады, ялкауландылар, араларында төрле бозыклыклар күбәйде, Җәнабел Хакны оныттылар, үзләре ясап куйган потларга табына башладылар.

Хак Сөбханә вә Тәгалә аларны ташламады, аларга файда өчен, Үзенең рәхмәтеннән үзләренең кардәшләре булган хәзрәти Һуд галәйһиссәламне пәйгамбәр итеп җибәрде. Хәзрәти Һуд галәйһиссәлам атабыз Адәм галәйһиссәламгә бик тә охшаган иде. Озын буйлы, гүзәл йөзле, татлы сүзле, бер дә куркусыз ир иде. Һуд галәйһиссәламнең атасы — Гаәс, аның атасы — Ирам, аның атасы — Сам, аның атасы Нух галәйһиссәлам иде. Һуд галәйһиссәлам гарәп нәселеннән булып, үз кавемен иманга өндәде.

Риваятьләргә караганда, Һуд галәйһиссәлам күркәм холыклы, йомшак табигатьле, үзе өчен һичкемнән дә үч алырга теләми, үзенә яман мөгамәлә күрсәткәннәрне дә гафу итеп, яманлыкка каршы яхшылык итәргә тырыша, чит кешеләргә, хәтта дошманнарына да ачык йөз күрсәтеп, татлы сүз белән кайгыларын, борчуларын уртаклаша торган була. Шулай ук ул гаять тә баһадир, һичбер курку дигән нәрсәне белми, һәр эшне Хак Тәгаләгә тәвәккәлләп, Аннан гына ярдәм сорап, камил ихлас вә тырышлык илә эшли, үз кавеменә вә дәхи һәркемгә аңлашылырлык, ачык итеп вәгазьләрен сөйли.

Ләкин Гад кавеме хәзрәти Һуд галәйһиссәламнең үгетнәсыйхәтләрен бер дә тыңламыйлар. Аларның башлары бөек-

лек вә тәкәбберлек илә тулган, көферлекнең көчле дәрәҗәсенә ирешкән иде. Үзара вә күрше кавемнәрне рәнҗетүне гадәт итеп алган бозык табигатьле бу кавемне Һуд галәйһиссәлам бер Аллаһыга буйсынырга чакыра, ягъни үзләре ясап куйган потларга сәҗдә кылуларын туктатырга тырыша. Бу турыда «Һуд» сүрәсенең 50 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَإِلَىٰ عَادٍ أَخَاهُمْ هُودًا قَالَ يَٰقَوْمِ اعْبُدُوا اللَّهَ
مَا لَكُم مِّنْ إِلَٰهٍ غَيْرُهُ إِنْ أَنتُمْ إِلَّا مُفْتَرُونَ ٥٠

«Үә иләә Гаадин әәхаа һүм Һүүдә. Каалә йәәкаумигбүдүллааһә мәәләкүм мин иләәһин гайруһ. Ин әңтүм илләә мүфтәрүүн (50)».

М ә г ъ н ә с е : *«Гад кавеменә кардәшләре Һудны пәйгамбәр итеп җибәрдек. Һуд әйтте: «И, кавемем, Хак Тәгаләгә итагать итегез, Аңа гына гыйбадәт кылыгыз! Сезгә Аңардан башка һич Илаһ юк. Сез хак эшне эшләүче түгел, мәгәр Аллаһы Тәгаләгә ялганны ифтира кылучылардыр (50)».*

Һуд галәйһиссәлам үзенең кавемен илле ел дәвамында иманга өндәде. Ул кавем аның үгет вә нәсыйхәтләрен тыңламады, аннан көлделәр. Бик аз кеше иманга килде. Кавеме элеккечә үк потларга табынды. Һуд галәйһиссәлам аларның табына торган сыннарын ихтирам итмәде вә дәхи алар кебек исерткеч эчмәде, хатын-кызлар белән бозыклык кылмады. Хыянәт, ялган сөйләү вә башка ярамас сыйфатлардан, яман холыклылардан ерак булды. Тугры сүзле, мәрхәмәтле, Хак Тәгалә боерган һәр эштә җитди иде. Ул аларга: «И, кавемем, мин сезне тугры юлга өндим, моның өчен мин сездән хак сорамыйм...» — диде. Бу хакта Коръән Кәримнең «Һуд» сүрәсе, 51 нче аятендә болай диелгән:

يَٰقَوْمِ لَا أَسْأَلُكُمْ عَلَيْهِ أَجْرًا إِنْ أَجْرِيَ إِلَّا عَلَى الَّذِي فَطَرَنِي أَفَلَا تَعْقِلُونَ ٥١

«Йәә кауми ләә әсәлүкүм галәйһи әҗр. Ин әҗриә илләә галәлләзии фәтарани. Әфәләә тәгкыйлүүн (51)».

М ә г ъ н ә с е : *«И, кавемем, сезгә Ислам динен өйрәткәнем өчен хак сорамыйм, минем эшнең әҗере үземне юктан бар*

*итүче Аллаһы Тәгалә кулында. Шуны да аңламыйсызмы? Ягъни Хак Тәгаләгә генә гыйбадәт кылыгыз вә әҗерне дә Аңардан гына сорагыз! (51)».*

Гад кавеме гомер бакый мөстәкыйль яшәде. Фәкать соңгы вакытта ялкауланулары, потларга табынулары, кеше талау, кәрван басу, ганимәт, ягъни башка халыкларның малын талап алу кеби нәрсәләр илә көн күрә башладылар. Башлары гайрәтле булулары илә горурланып, көферлектә көчле дәрәҗәләргә ирешкән, сугыш-талашудан зур ләззәт тапкан шушы кавемне Һуд галәйһиссәлам туры юлга, иманга өндәде. «Һуд» сүрәсенең 52 нче аятендә моның шулай икәнен күрәбез:

وَيَٰقَوْمِ ٱسْتَغْفِرُوا۟ رَبَّكُمْ ثُمَّ تُوبُوٓا۟ إِلَيْهِ يُرْسِلِ ٱلسَّمَآءَ عَلَيْكُم مِّدْرَارًا وَيَزِدْكُمْ قُوَّةً
إِلَىٰ قُوَّتِكُمْ وَلَا تَتَوَلَّوْا۟ مُجْرِمِينَ ۝٥٢

«Үә йәә каумис тәгъфируу Раббәкүм сүммә түүбүү иләйһи йүрсилис-сәмәә-ә галәйкүм мидраараран үә йәзидкүм куввәтән иләә куввәтикүм үә ләә тәтәүәлләү мүҗримиин (52)».

Мәгънәсе: *«И, кавемем! Хак Сөбханә вә Тәгаләнең ярлыкавын сорагыз, соңра тәүбә кылып, Аңа кайтыгыз. Шулай булсагыз, Аллаһы Тәгалә сезгә бер-бер артлы яңгырларын яудырыр вә көч-куәтегезне арттырыр, кяфер булып иманнан качмагыз! (52)».*

Һуд галәйһиссәлам үзенең Җәнабел Хакның пәйгамбәре булуын вә дәхи аңа күктән вәхи килүен, шулай ук Аллаһы Тәгалә тарафыннан үз кавемен Ислам диненә өндәү өчен җибәрелгәнлеген бәян кылды.

Шул кавемнең иң дәрәҗәле вә иң көчле кешеләренең бу вәгазьләргә риза булмыйча куркытулары, аларның сүгенү вә орышуларына карамыйча, Аллаһы Тәгаләгә тапшырып, үзенең вазыйфасын дәвам итте. Моның дәлиле буларак, Коръән Кәримнең «Һуд» сүрәсе, 53 нче аятендә болай диелгән:

قَالُوا۟ يَٰهُودُ مَا جِئْتَنَا بِبَيِّنَةٍ وَمَا نَحْنُ بِتَارِكِىٓ
ءَالِهَتِنَا عَن قَوْلِكَ وَمَا نَحْنُ لَكَ بِمُؤْمِنِينَ ۝٥٣

«Каалүү йәәһүүду мәә җиэтәнәә бибәййиәнәтиу-үә мәә нәхнү битәәрикии әәлиһәтинәә гән каулика үә мәә нәхнү ләкә би-мүэминиин (53)».

М ә г ъ н ә с е : *«Кавеме әйтте: «И, Һуд, син безгә пәйгамбәрлегеңә дәлил вә могҗиза китермәдең, синең сүзеңә карап, без сыннарыбызны ташлаучылар түгелбез (53)».*

Һуд галәйһиссәлам бернигә дә карамыйча вәгазьләрен дәвам итте, чөнки шул эш белән ул боерылган иде. Хак Тәгалә тарафыннан эшнең ничек булачагы тәэмин ителгән, бер кавем генә түгел, бөтен дөнья каршы килсә дә, вазыйфа юлы дөрес икәнлеге үзенә белдерелгән иде. Моның чыннан да шулай булуын «Һуд» сүрәсенең 54 нче аятендә күрәбез:

ان نقول الا اعتريك بعض الهتنا بسوء قال اني اشهد

الله واشهدوا اني بري مما تشركون ۝٥٤

«Иннәкуулү илләг-тәраакә бәгду әәлиһәтинәә бисүү-ин. Кааләә иннии үшһидүл-лааһә үәшһәдүү әннии бәрии-үн миммәә тәшрикүүн (54)».

М ә г ъ н ә с е : *«И, Һуд, без сиңа шуны әйтәбез, син безнең сыннарыбызга начар сүзләр тидергәнсең дә, аларның бәгъзесенең сиңа каргышы ирешеп, син дивана булгансың, шуңа күрә юк-бар сүзләрне сөйлисең». Һуд аларга җавабында әйтте: «Дөреслектә, мин сезгә Хак Тәгаләне шаһит кыламын, сез дә шаһит булыгыз, мин, әлбәттә, сезнең Аллаһы Тәгаләгә тиңдәш кылган нәрсәләрегездән бизүчемен (54)».*

Гад кавеме Һуд галәйһиссәламнең бу тәэсирле сүзләренә дә ышанмадылар вә әйттеләр: «Әгәр син пәйгамбәр булсаң, вәгъдә кылган газабыңны хәзер үк китер», — дип, аннан көлделәр. Бу хакта Коръән Кәримнең «әл-Әхкаф» сүрәсе, 22 нче аятендә әйтелә:

قالوا اجئتنا لتافكنا عن الهتنا فاتنا بما

تعدنا ان كنت من الصدقين ۝٢٢

«Каалүү әҗиэтәнә литәэфикәнәә гән әәлиһәтинәә фәэтинәә бимәә тәгидүнәә иң күңтә минәс-саадыйкыййн (22)».

Мәгънәсе: *«Алар пәйгамбәргә әйттеләр: «Син безне тәңреләребездән тыяр өчен килдеңме? Әгәр дә инде сөйләгән сүзләрең дөрес булса, вәгъдә кылган олуг газабыңны безгә хәзер үк китер (22)».*

Һуд галәйһиссәлам бу кавем үзләре сораганча җәза сорап дога кылды. Догасы кабул булды. Хәзрәти Һуд, Аллаһы Тәгаләнең ярдәме илә, бу тәкәббер кавемгә могҗизалар ясап күрсәтте. Җиде ел буе бу кавемнең хатыннары бер генә бала да тудырмадылар. Челтерәп аккан чишмәләрнең сулары бетте. Күктән яңгыр яумады. Җимеш бакчалары корыды. Күлләр, елгалар юкка чыкты, булган хайваннары үлеп бетте. Бу гыйбрәтләрне күреп, бәгъзеләре иман китерде, әмма күбесе барыбер иман китермәде. Алар бөтен дөньяны су басуга кадәр яшәгән Нух кавеме кешеләренә охшаган тәкәбберләр иде. Алар әйттеләр: «И, Һуд, син безне үзеңнең юк-бар могҗизаларың белән куркытасыңмы? Безгә, шундый көчле, җиңелмәс кешеләргә, кем каршы чыга алыр икән?» — дип, аннан көлделәр.

Һуд галәйһиссәлам бу тәкәббер мәҗүсиләрнең аның могҗизаларына вә сөйләгән сүзләренә бер тамчы да ышанмаганнарына янә бер мәртәбә төшенде, алар Хак Тәгалә үзләрен җиңә алмас дип уйладылар, чөнки әле кайчан гына гүзәл шәһәрләр төзеделәр. Бу шәһәрнең исеме Ирам зат әл-Имат, ягъни күп колонналы Ирам дип атала. Бөтен илдә мондый шәһәр булмый. Алда әйткәнебезчә, әлеге шәһәр кешеләре, ягъни Гад кавеме бик тә зур гәүдәле, көчле вә тәкәббер булдылар, ялкауландылар, потларга табына башладылар. Бу турыда «әл-Әхкаф» сүрәсенең 26 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَلَقَدْ مَكَّنّٰهُمْ فِيمَا إِنْ مَكَّنّٰكُمْ فِيهِ وَجَعَلْنَا لَهُمْ سَمْعًا وَأَبْصَارًا
وَأَفْئِدَةً فَمَا أَغْنَىٰ عَنْهُمْ سَمْعُهُمْ وَلَا أَبْصَارُهُمْ
وَلَا أَفْئِدَتُهُمْ مِنْ شَيْءٍ إِذْ كَانُوا يَجْحَدُونَ بِآيَاتِ اللّٰهِ
وَحَاقَ بِهِمْ مَا كَانُوا بِهِ يَسْتَهْزِئُونَ ۝٢٦

«Үә ләкаде мәккәннәәһүм фиимәә иммәккәннәәкүм фииһ. Үә җәгәлнәә ләһүм сәмгәү-үә әбесаран үә әфидәһ. Фәммәә әгънәә ганһүм сәмгүһүм үә ләә әбесаруһүм үә ләә әфидәтүммиң шәйин из кәәнү йәҗехәдүүнә би-әәйәәтилләәһи үә хәәка биһим мәәкәәнүү биһи йәстәһзиүн (26)».

М ә г ъ н ә с е : *«Без Һуд кавеменә озын гомер, куәтле вә күп мал, вә дәхи торыр урын бирдек, ә инде сез Аллаһы Тәгаләнең сүзенә ышанмаучы кяферләр, аларга бирелгән артыклык сезгә бирелмәде. Ләкин һәммә кешегә бертигез итеп: Безгә ышанмаучыларга да колак, күз, йөрәк бирдек, тик аларның колаклары, күзләре вә йөрәкләре аларга һич тә файда бирмәде, чөнки алар Хак Тәгаләнең аятьләрен инкарь иттеләр, аларга хакны мәсхәрә итүләренең газабы иңде (26)».*

Һуд кавеменең олуглары үзләре ясап куйган потларына мөрәҗәгать итәләр, алардан яңгыр яудыруларын үтенәләр. Һуд галәйһиссәлам аларга: «И, кавемем, сүземне тыңлагыз, һәм Аллаһы Тәгалә сезгә яңгыр бирер, вә сезне бу авыр хәлдән коткарыр», — ди. Кавеме аңа болай җавап бирә: «Без үз тәңреләребездән сорадык, тиздән алар безгә яңгыр җибәрәчәк. Кит яхшы чакта безнең яныбыздан! Син сөйли торган Алла бар икән, ул үзе теләгәнен эшләсен!»

Соңыннан Җәнабел Хак, бу Гад кавеменең шулкадәр гыйбрәтләрне күреп тә иман китермәүләренә бик каты ачуланып, болыт белән искиткеч көчле җил җибәреп, аларны һәлак итте. «Әл-Әхкаф» сүрәсенең 25 нче аятендә Хак Тәгалә әйтә:

تدمر كل شىء بامر ربها فاصبحوا لا يرى

الا مسكنهم كذلك نجزى القوم المجرمين ﴿٢٥﴾

«Түдәммиру күллә шәйин биәмри Раббиһәә фә-әсъбәхүү ләә йүраа илләә мәсәәкинүһүм. Кәзәәликә нәҗзил-каумәл мүҗримиин (25)».

М ә г ъ н ә с е : *«Ул җил Аллаһы Тәгаләнең әмере илә һәрнәрсәне вә дәхи Гад кавеменең һәркайсын һәлак итте, бу коточкыч җилдән соң карасаң, өйләреннән башка һичнәрсә дә калмаган иде. Без Хак Тәгаләгә ышанмаган кавемне әнә шулай җәза кылабыз (25)».*

Бу турыда Аллаһы Тәгаләнең аяти кәримәләренә вә риваятьләргә караганда, көннәрдән бер көнне кешеләр күктә бик зур кара болыт күрәләр. Ул болыт, якынайган саен үскәннәнүсә барып, Гад кавеме яшәгән җирләргә таба якынлаша. Кешеләр шатланышып кычкыралар: «Кара вә куе булуына карамастан, бу, һичшиксез, яңгыр болыты. Тәңреләребез безнең ялваруларыбызны ишеткәннәр вә безгә яңгыр җибәргәннәр. Нинди зур шатлык! Һуд, кая синең Аллаң? Ул берни дә эшләмәде, ә син күреп торган әлеге яңгыр болытын безнең тәңреләр җибәрде».

Аллаһы Тәгалә Һуд галәйһиссәламгә һәм аңа иман китергән мөэминнәргә шәһәрдән чыгарга әмер кылды. Һуд галәйһиссәлам үзенә иман китергән мөэминнәр белән Мәккәи Мөкәррәмә шәһәренә күчеп китте, гомеренең соңгы көненә кадәр гыйбадәттә булды. Кабер шәрифе Мәккә шәһәре янындагы тауда, башка пәйгамбәрләр янәшәсендә. Гомер озынлыгы 165 яшь булды.

Тәкәббер Гад кавеменә килгәндә, алар шатланышып күңел ачканда бик көчле давыл башлана, ул җил барча нәрсәләрне аудара, ком вә ташларны күтәреп алып, мәҗүсиләрнең йөзләренә бәрә, аларны дөм сукыр калдыра. Салкын җилдавылдан кул-аяклары өши. Мәҗүсиләр акырышалар-бакырышалар, үзләре ясап куйган потлардан ярдәм сорыйлар, йөзләрен капларга тырышалар, әмма җил-давыл аларны кызганмый. Гарасат сигез төн, җиде көн дәвам итте, шул вакыт эчендә ул бөтен нәрсәне харап итте, кешеләрне вә хайваннарны бергә буташтырды. Бу кавем кешеләренең танымаслык хәлгә китерелгән үле гәүдәләре генә калды. Җәнабел Хакка ышанмаган кавем әнә шулай һәлак була.

И, Раббым Аллаһ! Мондый бәла-казалардан безләрне Үзең сакла, йөзләребезне кара кылма, иманыбыздан аерма. Җәнабел Хак күңел түрләребезгә иман байлыгы, өйләребезгә, гаиләләребезгә, барча мөэминнәргә муллык вә сәгадәт насыйп әйләсен. Әмин, раббил гааләмиин, бирахмәтикә йәә әрхамәрраахимиин.

# САЛИХ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Әссәламүгаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ!

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә, Гад кавемен кылган гөнаһлары, бозыклыклары, тәкәбберлекләре вә дәхи Хак Тәгаләгә ширек катулары, ягъни үзләре ясап куйган сыннарны тәңребез дип сәҗдә кылулары өчен һәлак иткәннән соң, Сәмүд кавемен җир йөзенә хәлифә кылды вә аларны Хиҗаз илә Шам шәһәрләре арасында булган үзәнлекләр вә таулар янындагы Хәҗәр дигән җиргә урнаштырды. Бу кавем дә Гад кавеме шикелле гаять зур гәүдәле, бернидән дә курыкмаучан батыр йөрәкле халык иде.

Шушындый күркәм, уңдырышлы үзәнлектә урнашкан Сәмүд кавеме искитмәле җимеш бакчалары үстерде.Таулардан зур-зур ташлар кисеп алып, шулардан мәһабәт йортлар вә сарайлар төзеделәр. Фәкыйрьрәкләре тауларны тишеп үзләренә өйләр ясадылар, иген иктеләр, хайван асрап, шуның белән кәсеп иттеләр. Озак вакытлар дәвамында алар бик бәхетле вә рәхәт тормыш кичерделәр.

Ләкин алар тора-бара ялкауландылар, үзләренә шушы рәхәтлек вә мул нигъмәтләр биргән Җәнабел Хакны оныттылар, араларында төрле бозыклыклар күбәйде. Үз куллары илән кисеп алган ташлардан сыннар ясап, аларны тәңребез дип, шуларга сәҗдә кыла башладылар. Алар ахирәт дигән дөнья юк, бу дөньяда кылган бозыклыклар өчен үлгәч бернинди дә җәза юк, шулай ук ошбу җиһанда кылган изгелекләр өчен бүләк тә юк, дип уйлыйлар иде. Гомумән, аларда әхлаксызлык өстен булып, гадәт вә мөгамәләләре бик наданнарча булды. Хак Тәгаләне оныткач, алар бик мактанчык, тәкәббер, үзсүзле булып киттеләр, үч алырга бик хирысландылар. Бозыклык, зина кылу, багучылык вә сихерчелек бу кавемнең хатын-кызлары арасында бик таралган иде. Үзләре ясап куйган потларга багышлап корбан чалу кеби эшләр теләккә ирешүдә беренче арадашчы дип ышаналар иде.

Менә шушы мәҗүси, бозык кавемгә Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә пәйгамбәр итеп үз кавемнәреннән Салих исемле изге бәндәне җибәрде. Ул олы җанлы, аек акыллы, гадел кеше иде. Салих галәйһиссәлам шушы кавем арасында туа, алар күз алдында үсә, аны бу кавем кешеләренең һәркайсы белә, тугры сүзле, гадел булуы өчен бөтенесе хөрмәт итә иделәр. Салих галәйһиссәлам матурлыгы илән Мөхәммәд галәйһиссәламгә охшар иде. Кечкенә чагыннан ук Аллаһы бар вә Ул бер дип ихлас күңеленнән ышана иде. Кавеме рәвешендә потларга, төрле сыннарга табынмады. Үз кавеменең илаһларын, ягъни табына торган сыннарын бервакытта да ихтирам итмәде вә аларга ышанмады. Алар кебек исерткеч эчмәде, зина кылмады, ярамас сыйфатлардан, яман холыклылардан ерак булды.

Сәмүд кавеме кечкенә Салихны матурлыгы, башка балаларга үрнәк булырлык чиста, пакьлеге өчен ярата иделәр. Һәркайсы да үз баласының Салих белән уйнавын тели иде. Әлбәттә, алар Салихның үзләре ясап куйган потларга табынмавын беләләр иде: «Әле кечкенә, бераз үсә төшкәч, безнең потларыбызга табыныр вә сәҗдә кылыр әле», — дип сөйләшәләр иде. Салих үзе дә һәр тотынган эшен ахыргача җиткерүчән, олугларга карата түбәнчелекле, гадел булып үсә. Сәмүд халкы, аны яратып: «Балигъ булгач, безләргә киңәш бирүче вә дәхи картлык көннәребездә безләрне яклаучы гадел хуҗабыз булыр», — дип өметләнә иде.

Салих галәйһиссәлам үсеп балигъ булгач, Аллаһы Тәгаләнең әмере илән Җәбраил фәрештә егет сурәтенә кереп, аның янына килде. Салих галәйһиссәлам, бу таныш булмаган егеткә карап: «И, егет, мин сине белмим, син каян вә кем буласың?» — дип әйтте. Җәбраил галәйһиссәлам җавабында: «Мин Аллаһы Тәгаләнең фәрештәсе Җәбраил галәйһиссәлам булам, сиңа Хак Сөбханә вә Тәгаләнең сәламен китердем. Аллаһы Тәгалә сиңа олуг вазыйфа йөкләде, бүгеннән башлап, син Хак Тәгаләнең берлегенә иман китерергә чакырырсың. Бернидән дә курыкма, кирәк вакытта Аллаһы Тәгаләдән сиңа вәхи вә ярдәм килер», — диде. Салих галәйһиссәлам бу сүзләргә бик шатланды. Ул үз кавеменең олуглары янына барды вә илһам илә ошбу сүзләрне әйтте: «И, минем кавемем, барча галәмнең падишаһы — ул Аллаһы Тәгаләдер, Салих пәйгамбәр — Аның җирдәге илчесе! Үзегез ясап куйган сыннарга гыйбадәт кыл-

магыз, моның белән сез зур гөнаһлы буласыз», — дип, кяферләр кия торган киемне салып, өстенә йоннан эшләнгән кием киде. Башкаларга да шуны эшләргә кушты.

Салих галәйһиссәлам үз кавемен янә бер мәртәбә җыйды вә: «И, кавемем минем, тик Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылыгыз, Ул Үзенең мәрхәмәте илән сезне Гад кабиләсеннән соң җирдә аларның варислары кылды. Сез Аның үзәнлекләрендә йортлар, сарайлар салдыгыз, тауларында йортлар чокып ясадыгыз. Шуларга шөкрана кылып, Аллаһының шәфкате вә мәрхәмәте турында уйлагыз, җирдә төрле бозыклыклар вә әшәкелекләр эшләүдән туктагыз», — дип әйтте.

Көннәрдән бер көнне Салих галәйһиссәлам Хәҗәр җиренә якын булган бер тау итәгендә гыйбадәт кыла иде, кинәт күк йөзе яктырып китте, аның янына үзенең фәрештәләре илә Җәбраил галәйһиссәлам килде вә Аллаһы Тәгаләнең сәламен тапшырды. Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләнең әмере буенча, шушы тау янындагы тигезлектә бер мәйдан ясадылар. Мәйдан читенә күз күрмәгән, колак ишетмәгән гүзәл агачлар утырттылар вә дәхи зур бер кәндил (яктырткыч) асып куйдылар. Бу кәндилнең яктылыгы төрле-төрле төстә булып, бөтен мәйданны яктыртыр, вә уты һичбер вакыт сүнмәс ирде. Ошбу мәйданның нәкъ уртасына бер мәһабәт йорт салдылар.

Иртә белән шул тирәдәге халык, җыелып, әүвәл ул гүзәл агачларны, һич тә сүнми торган кәндилне вә дәхи ошбу мәйдан уртасында салынган мәһабәт йортны күреп, хәйран булып тордылар. Бу могҗизаны күргәч, бәгъзеләре биһуш булдылар, тиз генә барып, Сәмүд кавеменең падишаһына ирештерделәр. Падишаһ, адәм баласы эшли алмаслык бу могҗизаны күреп: «Бу — сихер эше, моны бер төн эчендә һичкем эшли алмас, Салихка аның җен-пәриләре булышкан, ул сихерче булырга тиеш», — диде. Бәгъзеләре бу могҗизаны күреп, Салих галәйһиссәлам чыннан да Хак Тәгаләнең пәйгамбәре булуына инанып, аңа иман китерделәр. Күпчелеге аңа ышанмадылар, бу могҗизаны сихер эше дип кабул иттеләр.

Аллаһы Тәгалә әйтә: «Ул кяферләргә һәм монафикъларга әүвәлге кешеләрдән: Нух, Гад, Сәмүд кавемнәреннән хәбәр килмәдеме? Явызлыклары өчен аларны ничек һәлак иттек! Алар үзләренә үзләре золым кылдылар».

Салих галәйһиссәлам көндезләрен үз кавемен иманга өндәп, кич җиткәч Хәҗәр тавы янындагы йортына кайтып, Хак Сөбханә вә Тәгаләгә пәйгамбәрлек бирүенә шөкраналар кылып, гыйбадәттә булыр иде. Шул рәвешле күп еллар буе үз кавемен бер Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылырга өндәде. Бу турыда Коръән Кәримнең «әл-Әгъраф» сүрәсе, 74 нче аятендә болай диелгән:

وَاذْكُرُوٓا إِذْ جَعَلَكُمْ خُلَفَآءَ مِنۢ بَعْدِ عَادٍ وَبَوَّأَكُمْ فِى الْأَرْضِ
تَتَّخِذُونَ مِن سُهُولِهَا قُصُورًا وَتَنْحِتُونَ الْجِبَالَ بُيُوتًا
فَاذْكُرُوٓا ءَالَآءَ اللَّهِ وَلَا تَعْثَوْا فِى الْأَرْضِ مُفْسِدِينَ ۝٧٤

«Үәзкүруу из җәгаләкүм хуләфәә-ә мим-бәгди гәәдиү-үә бәүвә әкүм фил әрдый тәттәхыйзүнә миң сүһүүлиһә кусууран үә тәнхитүүнәл җибәәлә бүйүүтә. Фәзкүруу әәләә-әллааһи үә ләә тәгсәү фил әрдый мүфсидиин (74)».

М ә г ъ н ә с е : *«Гад кавемен һәлак иткәннән соң Хиҗаз илә Шам арасында булган уңдырышлы җирләргә сезне — Сәмүд кавемен урнаштырдык. Таулардагы ташлардан, йомшак балчыктан йортлар, сарайлар төзисез, тауларны тишеп өйләр ясыйсыз, иген игәсез. Аллаһы Тәгаләнең биргән нигъмәтләрен хәтерегезгә алыгыз вә, аның хөкемнәрен бозып, җир өстендә бозыклык кылып йөрмәгез! (74)».*

Салих галәйһиссәлам кавеменең тәкәббер олуглары: «Салихның пәйгамбәр икәнлегенә ышанасызмы, ул усал бер сихерче вә ялганчы», — дип әйттеләр. Аңа иман китергән мөэминнәр: «Без үз күзләребез белән күргән могҗизага ышанабыз», — дип әйттеләр. Бу хакта Коръән Кәримнең «әл-Әгъраф» сүрәсе, 75 нче аятендә болай әйтелгән:

قَالَ الْمَلَأُ الَّذِينَ اسْتَكْبَرُوا مِن قَوْمِهِۦ لِلَّذِينَ اسْتُضْعِفُوا لِمَنْ ءَامَنَ مِنْهُمْ
أَتَعْلَمُونَ أَنَّ صَٰلِحًا مُّرْسَلٌ مِّن رَّبِّهِۦ قَالُوٓا إِنَّا بِمَآ أُرْسِلَ بِهِۦ مُؤْمِنُونَ ۝٧٥

«Каалəл-мəлəлүлләзиинəс тəкбəруу миң каумиһии лилләзиинəс-түдгифүү лимəн əəмəнə минһүм этəгләмүүнə əннə Саалліхəм-мүрсəлүм-мирраббиһ. Каалүү иннəə бимəə үрсилə биһии мүэминүүн (75)».

Мəгънəсе: *«Салих кавеменең тəкəбберлəнүче олуглары Салихка иман китергəн мөэминнəргə: «Салихның пəйгамбəр икəнлегенə ышанасызмы?» — дип əйттелəр. Мөэминнəр: «Без Салихка бирелгəн могҗизага ышанабыз», — дип əйттелəр (75)».*

Кяферлəр əйттелəр: «Салих, син безгə ата-бабаларыбыз табынган тəңрелəребезгə табынмаска кушасыңмы?» Салих аларга əйтте: «Бу сыннар сезгə вə сезнең бабаларыгызга берни дə бирмəделəр һəм сездəн дə берни дə алмадылар. Алар сезгə файда да китермəгəч, зыян да салмагач, ничек итеп шуларга табынасыз сез? Ата-бабаларыгыз табынган нəрсəлəргə табыныр алдыннан бераз башыгыз белəн уйлап карамыйсызмыни соң сез?» Салих галəйһиссəлам үзенең кавемен иманга өндəвен дəвам итте. Кавем аның үгет-нəсыйхəтлəрен тыңламады, син — явыз сихерче, дип аннан көлделəр. Янə ничə еллар буе вəгазьлəгəннəн соң, тагын берничə кеше иманга килде. Сəмүд кавеменең күпчелеге элеккечə үк потларга табындылар, аның пəйгамбəрлегенə ышанмадылар. Алар əйттелəр: «Салих, без сине элек хөрмəт итə идек, ə хəзер безнең синнəн гайрəтебез чикте, чөнки синең гакылыңа зəгыйфьлек килгəн». Салих галəйһиссəлам: «И, кавемем, минем гакылым һич кенə дə зəгыйфьлəнмəде, мин сезне фəкать туры юлга чыгарырга гына телим. Аллаһыдан куркыгыз вə Аңа гына буйсыныгыз. Мин сездəн моның өчен бернинди дə бүлəк сорамыйм. Моның əҗерен Хак Тəгалə Үзе бирəчəк. Игелекле кешелəр ышандылар вə иман китерделəр, нишлəп сез ышанмыйсыз?» — дип сорады. Аның кавеменең олуглары Салих галəйһиссəлам сүзлəренə ышанган фəкыйрьлəрдəн: «Сез, мескеннəр, Салихның бер Аллаһы тарафыннан җибəрелгəн пəйгамбəр булуына ышанасызмы?» — дип сорадылар. Иман китергəн фəкыйрьлəр əйттелəр: «Əйе, тəхкыйк, без аның бер Аллаһы тарафыннан җибəрелгəн илче булуына вə бу могҗизалар да шул Аллаһы Тəгалə тарафыннан эшлəнүенə ихлас күңелебездəн ышанабыз», — дип җавап бирделəр. Ə теге тəкəббер вə дорфалар: «Тəхкыйк, ə без сез мескеннəр ышанганга

ышанмыйбыз, безнең үз тәңреләребез бар, без аларга гына ышанабыз», — дип әйттеләр.

Әмма Салих моның белән генә тынычланмады. Үз кавеменнән берәр кешене яки төркемне очраттымы, ул аларны туры юлга чыгарырга тырыша, киңәш, үгет-нәсыйхәтләрен бирә. Аларның бәгъзеләре иман китерделәр, ә күпчелеге кяфер булып кала бирде.

Кяферләр мөэминнәргә: «Сез мескеннәр, Салихның теге дөнья турында сөйләгән әкиятләрен хак дип беләсезме? Шулай ук кыямәт көне булачак, вә ул көнне сезне Аллаһыгыз терелтәчәк, бу фани дөньядагы эшләгән эшләребез өчен хисап тотачакбыз, дип уйлыйсызмы? Юк! Ышанмагыз сез шул Салих әкиятләренә! Без бу җирдә бер генә тапкыр яшибез, әгәр дә үләбез икән инде, беркайчан да терелмәячәкбез», — дип, үзләренекен тәкрарладылар.

Салих үзенә иман китергән бәндәләргә әйтте: «Төрле әшәкелек вә бозыклыклар таратучы тәкәбберләргә һәм алар үзләре ясап куйган потларга ышанмагыз. Сезнең үзегезнең күз алдыгызда пәйда булды бу манзара, Ул сезгә дә бүләк итте бу бакчаларны, иген, басу-кырларны, ахирәттә исә миңа иман китергәннәрне җәннәт бакчалары илә шатландырыр».

Кяферләр җыелышып киңәштеләр вә әйттеләр: «И, Салих, синең Аллаһы Тәгаләңә ышанып иман китерсеннәр дисәң, янә бер могҗиза күрсәт. Сиңа кадәр килгән барча пәйгамбәрләр дә, үз вәгазьләренең хаклыгына ышандыру өчен, кешеләргә могҗизалар күрсәткәннәр, син дә безнең күз алдыбызда могҗиза эшләп күрсәт». Салих галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итте вә Аннан үзенең пәйгамбәрлеген раслый алырлык бер могҗиза күрсәтү мөмкинлеге тудыруын үтенде. Ул намаз укып гыйбадәт кылганнан соң, кулларын догага күтәреп болай диде: «И, Раббым Аллаһ! Кавемем мине алдашуда гаепли. Миңа бик аз кешеләр генә иман китерделәр, ә калганнары тәкәббер байлар сүзеннән чыкмый. Бир миңа аларның һәркайсын ышандырырлык бер могҗиза күрсәтү мөмкинлеге».

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә аңа әйтте: «И, Салих! Мин сиңа андый мөмкинлек, әлбәттә, бирермен. Әйт үзеңнең кавемеңә, шәһәр читендәге кыя янында бер бик зур таш бар, барчасы шул таш янына җыелсыннар. Шунда син Миңа багышлап намазыңны укырсың, кулыңны күтәреп дога кылырсың, моннан соң

алар күз күрмәгән, колак ишетмәгән могҗизаның шаһиты булырлар. Ягъни бу зур таш икегә ярылыр, таш эченнән гаять тә зур бер дөя пәйда булыр, ул буаз булыр, таштан чыккач, ул дөя балалар. Дөянең сөте баласына вә кавемендәге барча кешеләргә дә җитәрлек булыр. Әмма шул ук вакытта кавемеңә һичшиксез үтәлергә тиеш булган ике шарт куй: беренчедән, коедан бер көндә алына торган барлык су дөягә булырга тиеш; икенчедән, икенче көнне барлык булган су биредә яшәүче инсаннарга булсын, чөнки барча бәндәләр бер көнне эчә торган суны бу могҗизалы дөя бер көнне эчеп бетерер».

Салих, үз кавеме янына кайтып, булачак могҗиза турында хәбәр бирде. Ул аларны кыя тау янындагы зур таш янына алып килде. Иман китергән мөэминнәр шатландылар вә әйттеләр: «Хак Тәгалә хакыйкатьне раслаячак, Ул Үзенең пәйгамбәрен вә аңа иман китерүчеләрне яклаячак», — диделәр. Тәкәббер кяферләр исә: «Әлбәттә, Салих буш сүз сөйли! Чын ахмаклык белән хур булыр, вә без аны үз арабыздан куып җибәрербез. Уйлап кына карагыз, дөя шулкадәр су эчәргә мөмкинме? Аннан соң таш эченә ничек керә алсын ди ул дөя хәтле дөя. Сөте дә бервакытта да бетми дип, әкият сөйли ул Салих, башына зарар килгән дип әйтмәдекме без сезгә?» — диделәр. Ә бер якка да кушылмаучы кешеләр әйттеләр: «Әйдә, барыйк тауга, күрик, Салих чын пәйгамбәрме, әллә буш сүзле бер алдакчымы — шунда бар да ачыкланыр».

Бу турыда Коръән Кәримнең «әл-Әгъраф» сүрәсе, 73 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَإِلَىٰ ثَمُودَ أَخَاهُمْ صَٰلِحًا قَالَ يَٰقَوْمِ ٱعْبُدُوا۟ ٱللَّهَ مَا لَكُم مِّنْ إِلَٰهٍ غَيْرُهُۥ قَدْ جَآءَتْكُم بَيِّنَةٌ
مِّن رَّبِّكُمْ هَٰذِهِۦ نَاقَةُ ٱللَّهِ لَكُمْ ءَايَةً فَذَرُوهَا تَأْكُلْ فِىٓ أَرْضِ ٱللَّهِ وَلَا تَمَسُّوهَا بِسُوٓءٍ
فَيَأْخُذَكُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ ٧٣

«Үә иләә Сәмүүдә әхааһүм Саалихә. Каалә йәә каумиг бүдүл-лааһә мәә ләкүм-мин иләәһин гайруһ. Каде җәә-эткүм бәййинәтүм-мирраббикүм. Һәәзиһии нәәкатүл-лааһи ләкүм әәйәһ. Фәзәруу һәә тәәкүл фии әрдыйл-ләәһ. Үәләә тәмәссүү һәә бисүү-иң фәйәә хузәкүм гәзәәбүн әлиим (73)».

Мәгънәсе: *«Вә Сәмүд кавеменә кардәшләре Салихны пәйгамбәр итеп җибәрдек, ул әйтте: «И, кавемем, фәкать Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылыгыз! Сезнең Хак Тәгаләдән башка Илаһыгыз юк (Сәмүд кавеме, Салих пәйгамбәрдән могҗиза итеп, ошбу таштан дөя чыгар, диделәр. Салих галәйһиссәлам дога кылды, таш ярылды, дөя чыкты, ләкин алар һаман иман китермәделәр). Тәхкыйк, бу дөя сезгә минем пәйгамбәрлегемне дәлилләп, Аллаһы Тәгаләдән могҗиза итеп җибәрелде, аңа ирек бирегез, теләгән җирендә ашасын-эчсен, явыз ният илә аңа кул тидермәгез, юкса сезләргә Хак Сөбханә вә Тәгаләнең газабы бик тиз ирешер (73)».*

Бу хакта риваятьләрдә болай сөйләнә: «Салих галәйһиссәлам, бу зур таш янына килеп, дүрт рәкәгать намаз укыды, намаздан соң кул күтәреп, Сөбханә вә Тәгаләгә багышлап дога кылды. Кинәт күк күкрәгән тавыш белән бу зур таш ярылды, барчасы күз алдында, нык кычкырып, таш эченнән зур дөя пәйда булды. Ул саф-саф булып тезелгән кешеләр алдыннан узды, моны күреп торган инсаннар аның имчәкләренә исләре китеп карап тордылар. Бераздан дөя бозаулады. Бозавы шунда ук сикереп торып әнисен имәргә тотынды. Ул имеп туйгач, хатын-кызлар үзләре белән алып килгән чүлмәкләренә дөяне савып сөт тутыра башладылар. Күпме генә саусалар да, аның сөте һич тә кимемәде. Аннары дөя кешеләр эчә торган кое янына килде һәм аның суын эчә башлады. Суын бөтенләй эчеп бетерми торып, башын күтәрмәде. Кешеләр бу тамашага карап, аптырап басып тора бирделәр. Шулвакыт халык арасыннан бәгъзеләре кычкыра башладылар: «Салих хаклы! Ул Хак Тәгаләнең пәйгамбәре! Ә бу исә — Аллаһы Тәгаләнең безләргә бүләк итеп биргән дөясе! Без Салихка иман китерергә тиешбез».

Бу могҗизадан соң янә күп кенә инсаннар иман китерделәр. Фәкать тәкәббер кяферләр генә, бер сүз дә әйтә алмыйча, җен ачулары чыгып, өйләренә таралыштылар.

Бу гаҗәеп дөя, беркөнне бөтен суны эчеп бетереп, икенче көнне суны кешеләргә калдырып, Салих кавемендә тыныч кына яши башлады. Әлеге суга алмашка ул олыларга вә балаларга кирәк кадәр сөт бирә иде.

Беренче вакытта Сәмүд кавеме ул дөяне рәнҗетмәде, җиде йөздән артык йортның халкы аның сөтен савып файдаландылар.

Шәһәрдә бик начар холыклы тугыз кеше бар иде. Алар үзләренең явызлыклары, бозык эшләре белән биредәге халыкны җәберләп торалар, Салих галәйһиссәламгә иман китерүчеләргә дә бик үчле иделәр.

Бер төнне алар җыелып хәмер эчеп утырган вакытта явыз ният кордылар: «Салихны вә аның бу дөясен болай гына калдырырга ярамый. Көнаралаш безнең суыбызны эчеп бетерә. Салих исә халыкны иман китерергә өнди. Безгә кичекмәстән Салихны да, аның дөясен дә үтерергә кирәк. Шул вакытта без алардан котылырбыз», — диделәр.

Араларыннан берсе: «Без Салихны үтерсәк, туганнары бездән үч алачак», — дип каршы төште. Икенчесе моңа каршы болай диде: «Без дөяне дә, Салихны да караңгы төндә үтерик. Алар безне, без аларны күрмәячәкбез. Әгәр туганнарыннан берәрсе сораса, без бу караңгы төндә аны да, шулай ук аның дөясен дә күрмәдек, диярбез. Без хаклы булырбыз, чөнки караңгыда беркемне дә күреп булмавы аларга да мәгълүм, һәм алар аны кем үтергәнен белмәячәкләр». Бу явызлар шулай килешеп, бер караңгы төнне Аллаһының дөясе янына килеп, берсе аңа ук атты, башкалары, килеп, ул гөнаһсыз хайванның аякларын кылыч белән чабып өзделәр. Дөя, мескен, коточкыч әрнү тавышы илә ыңгырашып җиргә егылды. Дөяне үтергәннән соң аның баласын да үтерергә ният кылдылар, ләкин дөянең баласы өч мәртәбә бик каты кычкырып, анасы чыккан ташка кереп гаиб булды (юк булды). Дөянең вә аның баласының кычкырган тавышларына Салих галәйһиссәлам, аның кардәшләре вә башкалар уянып, тавыш килгән якка йөгерделәр. Тугыз явызга тизрәк качудан башка чара калмады.

Салих галәйһиссәлам бу могҗизалы дөянең үле гәүдәсен күреп бик кайгырды, ул: «Дөянең баласы кая?» — дип сорады. Кяферләр әйттеләр: «Дөянең баласы, өч мәртәбә кычкырып, әнисе чыккан ташка кереп гаиб булды», — диделәр. Салих галәйһиссәлам әйтте: «Алайса, сезгә өч көннән соң Аллаһы Тәгаләнең газабы киләчәк, бу газаптан тик иман китергән бәндәләр генә исән-имин калачак», — диде. Бу турыда Коръән Кәримнең «әл-Әгъраф» сүрәсе, 77–79 нчы аятьләрендә болай диелә:

فَعَقَرُوا النَّاقَةَ وَعَتَوْا عَنْ اَمْرِ رَبِّهِمْ وَقَالُوا يٰصٰلِحُ ائْتِنَا بِمَا تَعِدُنَآ اِنْ
كُنْتَ مِنَ الْمُرْسَلِينَ ﴿٧٧﴾ فَاَخَذَتْهُمُ الرَّجْفَةُ فَاَصْبَحُوا فِى دَارِهِمْ جٰثِمِينَ ﴿٧٨﴾
فَتَوَلّٰى عَنْهُمْ وَقَالَ يٰقَوْمِ لَقَدْ اَبْلَغْتُكُمْ رِسَالَةَ رَبِّى
وَنَصَحْتُ لَكُمْ وَلٰكِنْ لَا تُحِبُّونَ النّٰصِحِينَ ﴿٧٩﴾

«Фәгәкарун-нәәкатә үә гәтәүгән әмри Раббиһим үә каалү йәә Саалиху этинәә бимәә тәгидүнәә иң күңтә минәл-мүрсәлиин (77). Фә-әхазәтүһүмүр-ражфәтү фә-әсъбәхүү фии дәәриһим җәәсимиин (78). Фәтәүәлләә гәнһүм үә каалә йәә кауми ләкаде әбеләгътүкүм рисәәләтә раббии үә нәсахтү ләкүм үә ләәкиллә түхиббүүнән-нәәсыйхиин (79)».

Мәгънәсе: *«Үзләре сорап алган дөяне үтерделәр вә Раббыларының әмеренә каршы тәкәбберлек кылдылар: «И, Салих, безгә вәгъдә кылган газабыңны китер, әгәр чыннан да пәйгамбәрләрдән булсаң», — диделәр (77). Һәм аларны зилзилә-каты селкетү тотты, йортларыннан чыга да алмыйча һәлак булдылар (78). Аннары Салих галәйһиссәлам үзенә иман китергән бәндәләр белән бу җирләрдән күчеп киткәндә әйтте: «Мин сезгә үземнең пәйгамбәрлегемне ирештердем вә үгет-нәсыйхәт кылдым, ләкин сезнең файдагызга вәгазь кылучыны сөйми торган кавем булдыгыз, Хак Тәгалә сезгә шуның җәзасын бирде», — диде (79)».*

Шушы вакыйгалардан соң Салих галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең әмере илә үзенә иман китергәннәр белән Мәккәи Мөкәррәмәгә китте. Үлгәнче шунда яшәде, Хак Тәгаләгә гел гыйбадәттә булды.

Үәссәламүгаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ!

# ЛУТ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Лут галәйһиссәламнең атасы — Һарун, аның атасы — Тарих, аның атасы — Нәхур. Лут галәйһиссәлам үзе Ибраһим пәйгамбәрнең карендәшенең углы иде.

Хәзрәти Лут Ибраһим галәйһиссәлам белән бергә Бабил шәһәреннән Шам шәһәренә һиҗрәт кылды, шул вакытта Ибраһим галәйһиссәламгә иман китерде. Бу турыда «әл-Ганкәбут» сүрәсенең 26 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فَآمَنَ لَهُ لُوطٌ وَقَالَ إِنِّي مُهَاجِرٌ إِلَىٰ رَبِّي إِنَّهُ هُوَ الْعَزِيزُ الْحَكِيمُ ٢٦

«Фә-әәмәнә ләһү Лүүтун үә каалә инний мүһәәҗирун иләә Рабби. Иннәһү һүәл-гәзиизүл-хәкиим (26)».

Мәгънәсе: *«Лут Ибраһимга иман китерде, Ибраһим әйтте: «Мин, бу мөшрикләрне ташлап, Аллаһы Тәгалә күрсәткән урынга күчәмен, дөреслектә, Хак Сөбханә вә Тәгалә көчледер, Ул мине дошманнардан саклар, вә дәхи Ул хикмәт ияседер, миңа файдалы булган эш белән әмер итәр (26)».*

Хәзрәти Лут яшәгән Сәдүм кавеме илә Ибраһим галәйһиссәлам пәйгамбәрлек кылган Кинган арасы бер көнлек юл ераклыгында иде. Сәдүм кавеме яшәгән җирләргә өч шәһәр керә иде. Аларның падишаһы Шәндум атлы бозык табигатьле бер бәндә булып, халкы үзләре ясап куйган Лат, Гүззә, Мәнат исемле потларга табыналар вә бу сыннарны алар тәңренең кызлары дип атыйлар иде. Бу турыда Коръән Кәримнең «ән-Нәҗем» сүрәсе, 22 нче аятендә Хак Тәгалә әйтә:

تِلْكَ إِذًا قِسْمَةٌ ضِيزَىٰ ٢٢

«Тилкә изәң кыйсмәтүң дыйзә (22)».

Мәгънәсе: *«Әгәр ир балаларны — үзләренә, кыз балаларны тәңрегә булә торган булсалар, бу бүлү тиешсез, үлчәүсез бүлүдер. Ягъни мөшрикләр Лат, Гүззә, Мәнат исемнәрен сыннарга бирделәр дә аларны тәңреләренең кызлары диделәр (22)».*

Торган җирләре бик нигъмәтле булып, бу шәһәрләр янында яшәүче башка кавемнәр һәр елны бу шәһәрләрдән кышлык азык-төлекне Сәдүм кавеменнән алып китәләр иде. Әмма бер елны бу шәһәрләргә салкынлык килде, барча нигъмәтләр салкынлыктан һәлак булдылар. Әүвәлгечә ошбу елны да күрше кавем халкы үзләре җитештергән әйберләрен Сәдүм кавеменең нигъмәтләренә алыштырырга дип килгәннәр иде. Сәдүм халкы: «Бу елны үзебезгә дә нигъмәтләр юк, салкыннан барча нигъмәтләребез һәлак булды, хәзер үк өйләрегезгә кайтып китегез», — дип аларны кудылар. Читтән килгән халык аларны тыңламады, шаулаштылар. Ахыр бу хәлне Шәндум падишаһка барып әйттеләр. Шәндум: «Гүзза исемле тәңрегә барып сорагыз, теләгәнегез кабул булыр», — дип, аларны потка табынырга җибәрде. Гүззага барып зарландылар. Иблис мәлгунь бу кавемнең наданлыгыннан файдаланып, Гүзза исемле потның эченә кереп: «И, минем кавемем! Булган нигъмәтләрегез кире кайтсын дисәгез, читтән килгән ул кавемнәрнең ирләре белән якынлык кылыгыз, шул вакытта читтән килгән кавемнәр үзләре үк качып китәрләр, барча нигъмәтләр үзегезгә калыр», — диде.

Гүзза яныннан чыгып, читтән килгән кавем кешеләрен тотып якынлык кылабыз дип барганда алар каршысына, бер матур ир бала кыяфәтенә кереп, Иблис мәлгунь килде. Баһил исемле кеше Иблисне өенә алып керде һәм аның белән якынлык кылды. Баһил өенә янә җитмеш ир кеше кереп, Иблис белән якынлык кылдылар. Бу кабахәтлек турында Шәндум падишаһка да барып иреште. Ул, Баһил йортына килеп, Иблис белән якынлык кылды. Шуннан соң ул, сараена кайтып, үзенә буйсынган кавемгә карата фәрман чыгарды: «Кайда бер матур ир бала яки читтән килгән ир-егетне күрсәгез, аны тотып, ихтыярлы-ихтыярсыз якынлык кылырга вә бу турыда падишаһка хәбәр итәргә».

Иблис мәлгунь вәсвәсәсе аларга бик хуш килде, һичкем өендәге хатынына карамас булды. Иблис, төрле кыяфәткә кереп, аларның җенси теләкләрен канәгатьләндерә торды.

Көннәрдән беркөн Иблис мәлгунь, үзен бик күркәм табибә хатын кыяфәтенә кертеп, Шәндум яшәгән шәһәргә килде. Бу шәһәр хатыннары җыелышып Иблискә зарлана башладылар: «Безнең ирләребез чит ирләрне хатын итеп тоталар, инде

безгә нишләргә кала?» Иблис әйтте: «Әгәр дә инде алар чыннан да сезгә карамасалар, сез дә аларга игътибар итмәгез, балавыздан ирләрегезнең оят әгъзасы кебек әйбер ясап, шуның белән якынлык кылыгыз», — диде. Аларга бу эшне эшләп тә күрсәтте. Хатыннарга бу бозыклык бик хуш килде, алар да шулай якынлык кыла башладылар.

Риваятьләргә караганда, кайчан бу кавем бозыклыклары вә кабахәтлекләренең чигенә чыктылар исә, Аллаһы Тәгалә Җәбраил галәйһиссәламгә әйтте: «Колым Лутка миннән сәлам әйт, аңа пәйгамбәрлек иңү белән сөендер. Сәдүм кавемен иманга өндәсен, ягъни бу кавем: «Аллаһы Тәгаләдән башка һич тәңре юктыр, Лут галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең колы вә Аның пәйгамбәредер», — дисеннәр. Ирләр вә хатыннар бер-бере белән кавышып бозыклык кылмасыннар, үзләре ясап куйган потларга табынмасыннар, дип өндәсен». «Әл-Әгъраф» сүрәсенең 80–81 нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَلُوطًا إِذْ قَالَ لِقَوْمِهِ أَتَأْتُونَ الْفَاحِشَةَ مَا سَبَقَكُمْ بِهَا مِنْ أَحَدٍ مِنَ الْعٰلَمِينَ ۝٨٠

إِنَّكُمْ لَتَأْتُونَ الرِّجَالَ شَهْوَةً مِنْ دُونِ النِّسَاءِ بَلْ أَنْتُمْ قَوْمٌ مُسْرِفُونَ ۝٨١

«Үә Луутаң из каалә ликаумиһи әтәәтүүнәл-фәәхишәтә мәә сәбәкакүм биһәә мин әхәдим-минәл гааләмиин (80). Иннәкүм ләтәәтүнәр-риҗәәлә шәһүтәм-миң дүүниннисә. Бәл әңтүм каумүм-мүсрифүүн (81)».

Мәгънәсе: *«Вә Лутны үз кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрдек. Ул кавеменә: «Йә, сез бу фәхеш эшне кыласызмы? Мондый фәхеш эшне сездән элек галәмдә һичкем кылмады (80). Тәхкыйк, сез хатыннарыгызны ташлап, ирләргә шәһвәт белән якынлык кыласыз, әлбәттә, сез хактан үткән кавемсез», — дип әйтте (81)».*

Лут галәйһиссәлам ул вакытта Сәдүм сахрасында терлекләр асрап яши иде. Шәһәр халкының кабахәтлекләрен белсә дә, алар белән аралашмый иде. Беркөн Җәбраил галәйһиссәлам ак чалмадан, күркәм бер карт кыяфәтендә Лут галәйһиссәлам янына килеп сәлам бирде. Лут галәйһиссәлам аның сәламен алып, ачык йөз белән әйтте: «И, олуг кыяфәтле, мөхтәрәм карт, син кем буласың вә нинди йомыш белән минем өемә кил-

дең?» — диде. Җәбраил галәйһиссәлам үзенең җавабында болай диде: «Мин Сөбханә вә Тәгаләнең фәрештәсе Җәбраил галәйһиссәлам буламын, Аллаһы Тәгалә сиңа Үзенең сәламен җибәрде, шулай ук Ул сиңа пәйгамбәрлек иңдерде», — диде.

Лут галәйһиссәлам үзенә пәйгамбәрлек иңүенә бик шатланды, әмма бу кабахәт, бозык Сәдүм кавемен ничек иманга өндәрмен икән дип борчылып, кардәше Ибраһим галәйһиссәлам янына барды вә әйтте: «Хак Тәгалә миңа Җәбраил галәйһиссәлам аркылы пәйгамбәрлек иңдерде, иң усал вә иң бозык Сәдүм кавемен иманга өндәргә боерды», — диде. Ибраһим галәйһиссәлам аны тынычландырып болай диде: «И, кардәшем Лут галәйһиссәлам, сиңа пәйгамбәрлек иңүенә мин бик шатмын, әлбәттә, син моңа лаек. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә бу бөек эшне сиңа ышанып тапшырган икән, син инде бернидән дә курыкма, тиз арада бу кавем янына барып, аларны иманга өнди башла, Хак Тәгалә сине Үзенең рәхмәтеннән ташламас», — дип, Лут галәйһиссәламне озатып җибәрде.

Лут галәйһиссәламнең кяфирә хатыны вә ике мөэминә кызы бар иде. Моннан гайре бер дөясе вә бер аты бар иде. Лут галәйһиссәлам, хатынының киреләнүенә карамыйча, Хак Тәгаләгә генә тапшырып, Шәндум падишаһ яши торган шәһәргә күчәргә ниятләп, ике рәкәгать нәфел намазы укыды, озын гына итеп дога кылды. Бар булган әйберләрен дөягә вә аты өстенә төяде. Ике мөэминә кызын вә кяфирә хатынын алып, шәһәргә таба юнәлде. Шәһәр капкасыннан кергәч, биредәге халык күрде: бер ят кеше вә аның бик матур ике кызы һәм хатыны, шәһәргә кереп, буш булган бер урынга чатыр корып урнаштылар. Бу турыда тиз генә Шәндум падишаһка барып әйттеләр. Падишаһ аларга: «Аны монда алып килегез!» — дип, үзенең кешеләрен җибәрде.

Лут галәйһиссәламне бер ягыннан аты, икенче ягыннан дөясе саклап килде. Шәндум падишаһ аннан: «Исемең кем була?» — дип сорады. Лут галәйһиссәлам: «Минем исемем Габдулла», — дип җавап бирде. «Габдулланың мәгънәсе ничек була?» Лут галәйһиссәлам: «Алла колы» дигән мәгънәне аңлата, мин Аллаһы Тәгаләнең хак пәйгамбәремен, бу шәһәргә мине Сөбханә вә Тәгалә биредәге халыкны иманга өндәргә, шулай ук төрле бозыклыклардан арынырга вәгазьләү өчен җибәрде», — диде. Падишаһ бераз уйлап торгач: «Мине ышан-

дырырлык дәлилең бармы?» — диде. Лут галәйһиссәлам: «Әйе, могҗизам бар, менә бу дөям белән атым телгә килеп гуаһлык (шаһитлык) бирерләр», — диде. Дөя дәрхаль (шул ук вакытта) телгә килеп: «Ләә иләәһә илләллааһ үә иннәкә Лутур-расүүлуллаһ», — диде. Ат дәхи телгә килеп, шул ук иман кәлимәләрен әйтте. Падишаһ бу могҗизага хәйран булды, аның әле моның кебек нәрсәне күргәне вә ишеткәне юк иде. Падишаһның бозык табигатьле ярдәмчеләре аның бу могҗизага ышанып иман китерүеннән курыктылар вә әйттеләр: «И, падишаһ, син күрмисеңме, бу бит сихер эше, сине алдап, иман китертеп, синең урынга падишаһ булу аның максуды», — диделәр. Падишаһ әйтте: «Без синең явыз сихерче булуыңны вә теләгән максудыңны белдек, сиңа мал-мөлкәт бирербез, тик син бу сүзләреңне бүтән кабатлама, без биргән мал-мөлкәтне алып, үзең яшәгән тарафка кайтып кит!» — диде. Лут галәйһиссәлам үзенең җавабында болай диде: «Миңа сезнең мал-туарыгыз хаҗәт түгел, сез Аллаһы Тәгаләне бар, Ул бер, дип әйтегез, үзегез ясап куйган потларга табынмагыз вә дәхи ирләргә якынлык кылмагыз, Хак Сөбханә вә Тәгаләнең газабыннан куркыгыз, бу бозык эштән Аллаһы Тәгалә разый түгел, әгәр Хак Тәгаләне бер дип, аның пәйгамбәре Лут галәйһиссәлам хак дип танымасагыз вә бозык эшләрегезне ташламасагыз, Җәнабел Хак тиз арада сезгә Үзенең җәзасын җибәрер. Әгәр дә Хак Тәгаләне берләсәгез, мине Аның пәйгамбәре дисәгез, Аллаһы Тәгалә нигъмәтләрегезне арттырыр, сезләргә оҗмах насыйп итәр», — диде. Алар: «Йә, Лут, бу сүзләреңнән кире кайт, тыел, юкса шәһәрдән куып чыгарабыз», — дип әйттеләр. Ягъни Лут кавеме пәйгамбәрнең сүзләрен ялганга тотты. «Әш-Шугара» сүрәсенең 160–168 нче аятьләрендә болай диелгән:

كَذَّبَتْ قَوْمُ لُوطٍ الْمُرْسَلِينَ ﴿١٦٠﴾
إِذْ قَالَ لَهُمْ أَخُوهُمْ لُوطٌ أَلَا تَتَّقُونَ ﴿١٦١﴾ إِنِّي لَكُمْ رَسُولٌ أَمِينٌ ﴿١٦٢﴾ فَاتَّقُوا اللَّهَ وَأَطِيعُونِ ﴿١٦٣﴾
وَمَا أَسْأَلُكُمْ عَلَيْهِ مِنْ أَجْرٍ إِنْ أَجْرِيَ إِلَّا عَلَىٰ رَبِّ الْعَالَمِينَ ﴿١٦٤﴾ أَتَأْتُونَ الذُّكْرَانَ
مِنَ الْعَالَمِينَ ﴿١٦٥﴾ وَتَذَرُونَ مَا خَلَقَ لَكُمْ رَبُّكُمْ مِنْ أَزْوَاجِكُمْ بَلْ أَنْتُمْ قَوْمٌ عَادُونَ ﴿١٦٦﴾

قَالُوا لَئِن لَّمْ تَنتَهِ يَلُوطُ لَتَكُونَنَّ مِنَ الْمُخْرَجِينَ ﴿١٦٧﴾ قَالَ إِنِّي لِعَمَلِكُم مِّنَ الْقَالِينَ ﴿١٦٨﴾

«Кәззәбәт кауму Лүүтыйл-мүрсәлиин (160). Из каалә ләһүм әхуу һүм Лүүтун әллә тәттәкуун (161). Инии ләкүм расүүлүн әмиин (162). Фәттәкуул-лааһә үә әтыййгүүн (163). Үә мәә әсәлүкүм галәйһи мин әҗри. Ин әҗриә илләә гәлләә Раббил-гәәләмиин (164). Әтәәтүүнәз-зүкраанә минәл гәәләмиин (165). Үә тәзәруунә мәә халәка ләкүм раббәкүм мин әзүәәҗикүм. Бәл әңтүм каумин гәәдүүн (166). Каалүү ләиллән тәңтәһи йәә Лүүту ләтәкүүнәннә минәл мүхърәҗиин (167). Каалә иннии лигәмәликүм минәл каалиин (168)».

Мәгънәсе: *«Лут кавеме пәйгамбәрне ялганга тотты (160). Лут галәйһиссәлам аларга әйтте: «Әллә Аллаһы Тәгаләдән курыкмыйсызмы, Хак Тәгаләгә гыйбадәт кылу урынына һичнәрсәгә ярамаган сыннарга гыйбадәт кыласыз (161). Мин, әлбәттә, сезгә җибәрелгән Аллаһы Тәгаләнең хак пәйгамбәремен ки, миннән зарар күрүдән һәркайсыгыз имин булырсыз (162). Аллаһы Тәгаләдән куркыгыз, Аңа каршы барудан зинһар сакланыгыз, вә дәхи минем әмеремә итагать кылыгыз! (163). Ислам шәригатен өйрәткәнем өчен сездән бернинди дә хак сорамыйм, минем җиһадымның әҗере галәмнәрне тәрбияләүче Аллаһы Тәгаләнең хозурындадыр (164). Дөньяда кешеләр арасыннан сез ир балаларга якынлык кыласыз (165). Раббыгыз сезнең өчен халикъ кылган хатыннарны куярсыз, бәлки сез хәләлдән хәрамга үтүче кавемсез (166). Мөшрикләр әйттеләр: «И, Лут, әгәр ошбу сүзләреңнән туктамасаң, әлбәттә, шәһәребездән куып чыгарылганнардан булырсың» (167). Лут әйтте: «Мин сезнең бу эшегез өчен бик каты ачуланучыларданмын (168)».*

Лут галәйһиссәлам шушы рәвешчә кырык ел үзенең кавемен иманга өндәде, кабахәт эшләрдән тыйды. Иман китерүчеләр саны бик аз булды, күпчелеге иман китермәде, һаман кабахәт эшләрен арттырдылар. Лут галәйһиссәламне, иманга вәгазьләгәне өчен, орып-сугып төрлечә кимсеттеләр, мәсхәрә кылдылар. Лут галәйһиссәлам, бу эшләрдән пакь булып, аларны иманга өндәвен дәвам итте. «Ән-Нәмел» сүрәсенең 54–56 нчы аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَلُوطًا إِذْ قَالَ لِقَوْمِهِ أَتَأْتُونَ الْفَاحِشَةَ وَأَنْتُمْ تُبْصِرُونَ ﴿٥٤﴾ أَئِنَّكُمْ لَتَأْتُونَ الرِّجَالَ
شَهْوَةً مِنْ دُونِ النِّسَاءِ بَلْ أَنْتُمْ قَوْمٌ تَجْهَلُونَ ﴿٥٥﴾ فَمَا كَانَ جَوَابَ قَوْمِهِ إِلَّا أَنْ قَالُوا
أَخْرِجُوا آلَ لُوطٍ مِنْ قَرْيَتِكُمْ إِنَّهُمْ أُنَاسٌ يَتَطَهَّرُونَ ﴿٥٦﴾

«Үә Лүүтан из каалә ликаумиһи әтәәтүүнәл фәәхишәтә үә әңтүм түбесыйруун (54). Әиннәкүм ләтәәтүүнәр-риҗәәлә шәһүәтәм-миң дүүниннисә. Бәл әңтүм камүң тәҗһәлүүн (55). Фәмәә кәәнә җәүәәбә каумиһии илләә әң каалүү әхъриҗүү әәлә Лүүтыйм-миң карйәтикүм. Иннәһүм үнәәсүй-йәтәтаһһәрун (56)».

Мәгънәсе: *«Лутны хәтерләгез, ул кавеменә әйтте: «Әллә, сез бик яман фәхеш эшне кыласызмы, җитмәсә, яшермичә бер-берегезгә күрсәтеп эшлисез (54). Әллә, сез хатыннарыгызны калдырып ирләргә якынлык кыласыз, бәлки сез бу эшләрегезнең ахыры ничек булачагын уйламый торган җаһил кавемсез» (55). Лут кавеменең җавабы булмады, мәгәр Лутның җәмәгатен шәһәрдән чыгарыгыз, дөреслектә, алар ирләрнең артына якынлык кылудан пакь адәмнәрдер, дигән сүзләр булды (56)».*

Лут галәйһиссәлам моннан элек килгән Нух, Һуд, Салих, Ибраһим пәйгамбәрләр кавемнәренең үз тәкәбберлекләре аркасында нинди газапларга дучар булулары хакында мисаллар китереп вәгазен сөйләде. Ләкин Сәдүм кавеме аңа: «Син үзеңнең Раббыңнан безгә газап алып килеп күрсәт», — дип, аннан көлделәр. Лут галәйһиссәлам: «И, Раббым, үз-үзенә золым кылучы кавемнең бозык гамәленнән мине вә гаиләмне коткар», — дип дога кылды. Хак Сөбханә вә Тәгалә догасын кабул кылды. Бу турыда Коръән Кәримнең «әл-Ганкәбут» сүрәсе, 29–30 нчы аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

أَئِنَّكُمْ لَتَأْتُونَ الرِّجَالَ وَتَقْطَعُونَ السَّبِيلَ ۝ وَتَأْتُونَ فِي نَادِيكُمُ الْمُنْكَرَ ۝
فَمَا كَانَ جَوَابَ قَوْمِهِ إِلَّا أَنْ قَالُوا ائْتِنَا بِعَذَابِ اللَّهِ إِنْ كُنْتَ مِنَ الصَّادِقِينَ ﴿٢٩﴾
قَالَ رَبِّ انْصُرْنِي عَلَى الْقَوْمِ الْمُفْسِدِينَ ﴿٣٠﴾

«Әиннәкум ләтәэтүүнәр-риҗәәлә үәтәкътагүүнәс-сәбиил. Үә тәэтүүнә фии нәәдиикумүл мүңкәр. Фәммә кәәнә җәүәәбә каумиһи илләә әң каалүэтинәә бигәзәәбил-ләәһи иң күңтә минәс-саадикыйн (29). Каалә раббин сурнии гәләл каумил-мүфсидиин (30)».

М ә г ъ н ә с е : *«Йә, сез ирләргә якынлык кыласызмы, дәхи юлчыларны талыйсызмы, вә җыелган җәмәгать эчендә фәхешлек кыласызмы, янә юлдан үтүчеләргә таш атасызмы? Лутның нәсыйхәтләренә каршы җаваплары башкача булмады, мәгәр дөрес сөйли торган булсаң, бу эшләребез өчен безгә Аллаһы Тәгаләнең газабын китер, диделәр (29). Лут әйтте: «И, Раббым, миңа ярдәм бир фәхеш эшне эшләүче кавем өстенә (30)».*

Көннәрдән бер көнне Җәбраил галәйһиссәлам, Микаил галәйһиссәлам, дәхи дә ун фәрештә яшь егетләр сурәтендә Хак Тәгаләнең әмерен үтәп, ягъни Лут галәйһиссәламнең кавемен юк итәр өчен җиргә төшерелделәр.

Төннең ике өлеше үткән бер вакытта алар Лут галәйһиссәламнең ишеген шакыдылар. Лут галәйһиссәлам чыгып ишекне ачты, фәрештәләр сәлам биреп эчкә уздылар. Лут галәйһиссәлам алар өчен борчылып әйтте: «И, егетләр, зинһар өчен урамга чыкмагыз, безнең өч шәһәр кяферләре ир егетләр илә бозык эш кылалар», — диде. Фәрештәләр аслан бер җавап та бирмәделәр. Алда әйткәнебезчә, Лут галәйһиссәламнең хатыны кяфирә иде, ул боларның сөйләшкәннәрен ишетеп, тиз генә падишаһка барып хәбәр бирде: «Лутның өенә бик матур унике яшь егет килделәр, форсатны кулдан ычкындырмагыз, эш кылгач, мине дә бүләксез калдырмассыз дип ышанам», — диде. Падишаһ тиз генә, биш йөз кешелек гаскәрен алып, Лут галәйһиссәлам өенә таба китте. Керергә теләделәр, Лут галәйһиссәлам, каршы чыгып, бераз низаг кылды: «Падишаһ, мине коткар, рисвай итмә, кирәк булса, әнә кызларымны никахлап алыгыз, тик минем кунакларыма тимәгез», — дип гозерләнде. Падишаһ: «Синең кызларыңда безнең эшебез юк, син үзең дә беләсең безнең максудыбызны, безгә ир-егетләрең кирәк», — дип, шул матур егетләргә кулын сузды. Җәбраил галәйһиссәлам идәннән алып йөзләренә бер уч туфрак сипте, күзләре урыннары белән беленмәс булды, ягъни алар тәмам сукырайдылар. «Лут сихерчеләр китергән, безне сихерләделәр, иртәгә сине вә кунакларыңны нинди җәзалар

көткәнен әле син белмисең генә», — дип, кычкырып өеннән чыктылар. Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «И, Лут, син безнең өчен бер дә кайгырма, без Аллаһы Тәгаләнең фәрештәләре, бу өч шәһәрнең бозык халкын һәлак итәргә боерылдык. Сине, ике кызыңны вә дәхи сиңа иман китергән кешеләрне сәхәр вакытында коткарырбыз, мәгәр кяфирә хатының болар белән бергә һәлак булачак», — диде.

Лут галәйһиссәламне, ике кызын вә иман китергәннәрне исән-имин коткарганнан соң, бу өч шәһәрнең астын өскә әйләндереп һәлак иттеләр вә җәһәннәмдә кыздырылган ташларны өсләренә яудырдылар.

Дөреслектә, фикерләп караучылар өчен аларның һәлак булуында, әлбәттә, гыйбрәтләр бар. Бу урында тирән-тирән чокырлар хасил булды, ул тирән чокырларда сасы сулар җыелып, аларда күз күрмәгән хәшәрәтләр пәйда булдылар. Юлдан узучылар бу тирәне әйләнеп уздылар.

Газиз кардәшләрем! Коръән Кәримдә һәм Насреддин бине Борһанеддин Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия»сендә һәм башка авторларның «Пәйгамбәрләр тарихы»нда шулай бәян кылынган. Күргәнебезчә, Лут пәйгамбәр, аның ике кызы һәм иман китергәннәрдән кала, өч шәһәр халкы бер мизгел эчендә юкка чыга.

Коръән Кәрим буенча археологик эзләнүләр Сәдүм шәһәренең Иордан-Израил чиге янындагы Тозлы күл (Лут күле яки Үле диңгез) янына урнашканлыгын ачыклады. Бу халыкның һәлак булуы сәбәбе дә Коръәндәгечә булуы расланды. Аятьтә әйтелгән «астын өскә әйләндердек» гыйбарәсе шәһәрнең көчле җир тетрәү нәтиҗәсендә юкка чыгуын раслый. Лут кавемен һәлак иткән бу вакыйга безнең эрага кадәр 1800 елларда булган. Аллаһы Тәгаләнең каһәренә юлыккан кавемнәр гыйбрәт түгелмени безләргә?

Аллаһы Тәгаләнең кануннары төгәл үтәлә, анда искәрмәләр юк. Кем дә кем аның кушканнарын үтәмәсә, һәрчак аның җәзасына лаек була. Коръән Кәрим һәм археологлар раслаганча, бу шәһәр үзенең һәлакәтенә кадәр азгынлык һәм фәхешлек үзәге булган. Җенси әгъзалар һәм җенси мөнәсәбәтләрне ачыктан-ачык күрсәтү гадәти күренеш булган. Менә шушы халык Аллаһының әмере илә бер мизгел эчендә юкка чыккан. Бу халәт Коръәндәге «Без аларны бер тавыш белән һәлак иттек» дигән аятькә туры килә. Хак Тәгаләнең газабына каршы торырлык көч тә, сизгерлек тә бирелмәгән шул адәм баласына!

# ИБРАҺИМ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Ибраһим галәйһиссәлам туфаннан соң 2640 ел үткәч, хәзерге Гыйрак җирләренең Бабил (Вавилония) шәһәрендә, йолдызларга вә потларга табынучы кавем арасында дөньяга килә. Бу турыда Коръән Кәримнең «әс-Саффәт» сүрәсе, 83 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَإِنَّ مِن شِيعَتِهِۦ لَإِبْرَٰهِيمَ ٨٣

«Үә иннә миң шиигәтиһи лә Ибраһиим (83)».

Мәгънәсе: *«Диннең асылында Нух галәйһиссәламгә иярүчеләрнең берсе Ибраһим галәйһиссәламдер, гәрчә аралары ике мең алты йөз кырык ел булса да (83)».*

Риваятьләргә караганда, бу кавем мәдәният, мәгърифәт өлкәсендә шактый алга киткән була. Алар зур-зур шәһәрләр төзи белүләре белән тирә-юньдә дан казанганнар.

Ибраһим галәйһиссәлам туганда Бабил шәһәрендә Нәмруд патша хакимлек итә. Нәмруд кайчан падишаһ булды исә, камил гаделлек илә берничә заман гомер кичерә. Ахыр Иблис ләгыйнь вәсвәсә кылып, тәңрелек дәгъвасын кылдыра. Моннан соң Нәмруд барча халыкка үзенә табынырга боера. Ул үзен мәңгелек падишаһ вә җирдәге тәңре дип дәгъвәт кыла башлый.

Ибраһим галәйһиссәламнең әтисе Нәмруд патшаның бик дәрәҗәле вәзирләреннән берсе булып, потларны үз кулы белән ясап сата. Моннан башка ул Бабил шәһәре потханәсенең рәисе булып та тора.

Менә шушы потларга һәм йолдызларга табынучы бозык кавем арасында Ибраһим галәйһиссәлам туа. Ул Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте илә бик кызыксынучан, әдәпле бала булып үсә. Җир вә күкләрдә булган могҗизаларның хуҗасы кем булуын белергә теләп, ул сахрага чыга. Күктә балкып торган Зөһрә йолдызга карап: «Будыр минем тәңрем», — ди. Иртән йолдыз югалгач, ул: «Югала торган әйбер тәңре була алмый», — дип фараз кыла. Ай туганын күргәч вә дәхи кояш чыкканын

һәм аларның күк йөзеннән юк булуларын күргәч, алардан да ваз кичә. Коръән Кәримнең «әл-Әнгам» сүрәсе, 76–79 нчы аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فَلَمَّا جَنَّ عَلَيْهِ الَّيْلُ رَاٰ كَوْكَبًا قَالَ هٰذَا رَبِّيْ فَلَمَّآ اَفَلَ قَالَ لَآ اُحِبُّ الْاٰفِلِيْنَ ۝٧٦
فَلَمَّا رَاَ الْقَمَرَ بَازِغًا قَالَ هٰذَا رَبِّيْ فَلَمَّآ اَفَلَ قَالَ لَئِنْ لَّمْ يَهْدِنِيْ رَبِّيْ لَاَكُوْنَنَّ
مِنَ الْقَوْمِ الضَّآلِّيْنَ ۝٧٧ فَلَمَّا رَاَ الشَّمْسَ بَازِغَةً قَالَ هٰذَا رَبِّيْ هٰذَآ اَكْبَرُ فَلَمَّآ
اَفَلَتْ قَالَ يٰقَوْمِ اِنِّيْ بَرِيْٓءٌ مِّمَّا تُشْرِكُوْنَ ۝٧٨ اِنِّيْ وَجَّهْتُ وَجْهِيَ لِلَّذِيْ فَطَرَ
السَّمٰوٰتِ وَالْاَرْضَ حَنِيْفًا وَّمَآ اَنَا مِنَ الْمُشْرِكِيْنَ ۝٧٩

«Фәләммәә җәннә галәйһил-ләйлү раәәкәү кәбә. Каалә һәәзәә Рабби. Фәләммәә әфәлә каалә ләә үхиббүл-әәфилиин (76). Фәләммәә раәл-камәра бәәзиган каалә һәәзәә Рабби. Фәләммәә әфәлә каалә ләилләм йәһдинии Раббии лә әкүүнәннә минәл каумид-дааллиин (77). Фәләммәә раәш-шәмсә бәәзигатәң каалә һәәзәә Рабби һәәзәә әкбәр. Фәләммәә әфәләт каалә йәәкауми иннии бәрии-үн миммәә түшрикүүн (78). Иннии үәҗҗәһтү үәҗһийә лилләзии фәтарас-сәмәәүәәти үәл-әрда хәниифәү-үә мәә әнә минәл мүшрикиин (79)».

Мәгънәсе: *«Кич караңгы булгач, Ибраһим йолдызларны күрде, йолдызларга гыйбадәт кылырга ярамаганлыкны аңлатыр өчен, хәйлә корып, йолдызга ишарә кылып: «Бу йолдыз — минем Раббым», — диде. Иртән йолдыз югалгач, мөшрикләр янына килеп, аларга: «Үзгәреп-югалып киткән нәрсәләрне һич сөймим, Илаһы дияргә риза түгелмен», — дип әйтте (76). Ибраһим айның туганын күргәч: «Будыр минем Раббым», — диде, ай баегач, мөшрикләргә карап: «Ай да үзгәрде-югалды, әгәр Раббым мине туры юлга күндермәгән булса, әлбәттә, мин дә сезнең кеби адашкан кавемнәрдән булыр идем», — дип әйтте (77). Кояш тугач, аңа карап, көлеп: «Бу кояш минем Раббымдыр — барысыннан да ул зуррак, Илаһы булырга яраклы», — дип әйтте. Кояш баегач, мөшрикләргә карап: «И, кавемем, күрдегезме, кояш та үзгәрде-югалды, мин, әлбәттә, сез Ал-*

*лаһы Тәгаләгә тиңдәш иткән нәрсәләрнең һәммәсеннән дә бизүчемен», — диде (78). Ибраһим әйтте: «Батыйльдән хакка авышкан хәлдә җир вә күкләрне төзүче Аллаһы Тәгаләгә йөземне юнәлдердем вә мин Хак Тәгаләгә һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылучы түгелмен (79)».*

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә, Ибраһим галәйһиссәламне Үзенең пәйгамбәре итеп сайлаганнан соң, аңар 10 кәгазь китап иңдерде һәм шул китапта язылган әмерләр белән үз кавемен иманга өндәргә боерды. Бу турыда Коръән Кәримнең «әш-Шугара» сүрәсе, 69–86 нчы аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَاتْلُ عَلَيْهِمْ نَبَأَ إِبْرَٰهِيمَ ۝٦٩ إِذْ قَالَ لِأَبِيهِ وَقَوْمِهِۦ مَا تَعْبُدُونَ ۝٧٠ قَالُوا۟ نَعْبُدُ أَصْنَامًا
فَنَظَلُّ لَهَا عَٰكِفِينَ ۝٧١ قَالَ هَلْ يَسْمَعُونَكُمْ إِذْ تَدْعُونَ ۝٧٢ أَوْ يَنفَعُونَكُمْ أَوْ يَضُرُّونَ ۝٧٣
قَالُوا۟ بَلْ وَجَدْنَآ ءَابَآءَنَا كَذَٰلِكَ يَفْعَلُونَ ۝٧٤ قَالَ أَفَرَءَيْتُم مَّا كُنتُمْ تَعْبُدُونَ ۝٧٥ أَنتُمْ
وَءَابَآؤُكُمُ ٱلْأَقْدَمُونَ ۝٧٦ فَإِنَّهُمْ عَدُوٌّ لِّىٓ إِلَّا رَبَّ ٱلْعَٰلَمِينَ ۝٧٧ ٱلَّذِى خَلَقَنِى فَهُوَ يَهْدِينِ ۝٧٨
وَٱلَّذِى هُوَ يُطْعِمُنِى وَيَسْقِينِ ۝٧٩ وَإِذَا مَرِضْتُ فَهُوَ يَشْفِينِ ۝٨٠ وَٱلَّذِى يُمِيتُنِى ثُمَّ
يُحْيِينِ ۝٨١ وَٱلَّذِىٓ أَطْمَعُ أَن يَغْفِرَ لِى خَطِيٓـَٔتِى يَوْمَ ٱلدِّينِ ۝٨٢ رَبِّ هَبْ لِى حُكْمًا وَأَلْحِقْنِى
بِٱلصَّٰلِحِينَ ۝٨٣ وَٱجْعَل لِّى لِسَانَ صِدْقٍ فِى ٱلْءَاخِرِينَ ۝٨٤ وَٱجْعَلْنِى مِن وَرَثَةِ جَنَّةِ
ٱلنَّعِيمِ ۝٨٥ وَٱغْفِرْ لِأَبِىٓ إِنَّهُۥ كَانَ مِنَ ٱلضَّآلِّينَ ۝٨٦

«Үәтлү галәйһим нәбә-ә Ибрааһиим (69). Из каалә ли әбииһи үә каумиһии мәә тәгъбүдүүн (70). Каалүү нәгбүдү әсънәә мәң фәнәзаллү ләһәә гәәкифиин (71). Каалә һәл йәсмәгүүнәкүм изтәдгүүн (72). Әү йәңфәгүүнәкүм әү йәдурруун (73). Каалүү бәл үә җәднәә әәбә-әнәә кәзәәликә йәфгәлүүн (74). Каалә әфәра әйтүм мәә күңтүм тәгъбүдүүн (75). Әңтүм үә әәбәәүкүмүл-әкъдәмүүн (76). Фә иннәһүм гәдүвүн лии илләә Раббәл-гәәләмиин (77). Әлләзии халәкании фәһүвә йәһдиин (78). Үәлләзии һүвә йүтъгимүнии үә йәскыййн (79). Үә изәә мәридътү фәһүвә йәшфиин (80). Үәлләзии йүмиитүнии сүммә

йүхиин (81). Үәлләзии әтъмәгү әййәгъфиралии хатыйй-әтии йәүмәддиин (82). Рабби һәблии хүкмән үә әл-хикъниии бис-саалихиин (83). Үәҗгәл-лии лисәәнә сыйдкыйн фил әәхыйри-ин (84). Үәҗгәлнии миң үәрсәти җәннәтин-нәгиим (85). Үәгъфир лиәби. Иннәһүү кәәнә минәд-дааллиин (86)».

Мәгънәсе: *«Вә кешеләргә гыйбрәт өчен Ибраһимның хәбәрен укы! (69). Аның кавеме сөйләшкәнен игътибарга алыгыз, ул атасыннан вә кавеменнән: «Нәрсәгә гыйбадәт кыласыз?» — дип сорады (70). Әйттеләр: «Потларга гыйбадәт кылабыз, һәрвакыт аларга гыйбадәттә булабыз» (71). Ибраһим әйтте: «Дога кылып, хаҗәтләрегезне сораганда потларыгыз сезнең сүзләрегезне ишетәләрме? (72). Яки сезгә файда итәргә көчләре җитәме? (73). Әйттеләр: «Юк, потларыбыз ишетми дә, файда вә зарар итәргә дә көчләре җитми, ләкин без аталарыбызны шулай таптык, алар да безнең кеби гыйбадәт кылалар иде, без аларга ияреп шулай кылабыз» (74). Ибраһим әйтте: «Йә, күрдегезме сез нәрсәгә гыйбадәт кылганыгызны (75), үзегез вә әүвәлге бабаларыгыз? (76). Ул потлар — минем дошманнарымдыр, аларга һич гыйбадәт кылмам, мәгәр барча галәмнәрнең Раббысы — Аллаһы Тәгалә минем Раббым. Ул минем дустым. Мин Аңа гына гыйбадәт кыламын (77). Ул Аллаһы Тәгалә мине бар кылды, вә Ул мине туры юлга күндерде (78). Вә Ул мине ашата вә эчертә (79). Әгәр авырсам, Ул миңа сәламәтлек бирә (80). Вә Ул мине үтерә, соңра тергезә (81). Вә кыямәт көнне гөнаһларымны Ул ярлыкар дип өмет итәм (82). И, Раббым, миңа белем хикмәте бир вә изгеләргә тоташтыр (83). Йә, Рабби, миннән соң килгән өммәтләр мине яхшылык белән зикер итсеннәр (84). Вә мине Нәгыйм җәннәтенең варисларыннан кыл (85). Вә атамны ярлыка, чөнки ул хак юлдан адашканнардан булды (86)».*

Ибраһим галәйһиссәлам кавеменең тәкәббер олуглары әйттеләр: «Ибраһимның пәйгамбәр икәнлегенә ышанасызмы, ул усал ялганчы». Ләкин ул Хак Тәгалә аңа боерганча үзенең кавемен иманга өндәвен дәвам итте. Алар Ибраһим галәйһиссәламнең үгет-нәсыйхәтләрен тыңламадылар, аннан көлделәр. Ибраһим галәйһиссәлам: «Аллаһы Тәгалә исеме белән ант итеп әйтәмен, үзегез ясап куйган потларыгызны сез юк чакта җимерермен», — дип ант итте.

Бу хакта Коръән Кәримнең «әл-Әнбия» сүрәсе, 57–67 нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَتَاللَّهِ لَأَكِيدَنَّ أَصْنَامَكُم بَعْدَ أَن تُوَلُّوا مُدْبِرِينَ ﴿٥٧﴾ فَجَعَلَهُمْ جُذَاذًا إِلَّا كَبِيرًا لَّهُمْ لَعَلَّهُمْ
إِلَيْهِ يَرْجِعُونَ ﴿٥٨﴾ قَالُوا مَن فَعَلَ هَٰذَا بِآلِهَتِنَا إِنَّهُ لَمِنَ الظَّالِمِينَ ﴿٥٩﴾ قَالُوا سَمِعْنَا فَتًى
يَذْكُرُهُمْ يُقَالُ لَهُ إِبْرَاهِيمُ ﴿٦٠﴾ قَالُوا فَأْتُوا بِهِ عَلَىٰ أَعْيُنِ النَّاسِ لَعَلَّهُمْ يَشْهَدُونَ ﴿٦١﴾
قَالُوا ءَأَنتَ فَعَلْتَ هَٰذَا بِآلِهَتِنَا يَا إِبْرَاهِيمُ ﴿٦٢﴾ قَالَ بَلْ فَعَلَهُ كَبِيرُهُمْ هَٰذَا فَاسْأَلُوهُمْ إِن
كَانُوا يَنطِقُونَ ﴿٦٣﴾ فَرَجَعُوا إِلَىٰ أَنفُسِهِمْ فَقَالُوا إِنَّكُمْ أَنتُمُ الظَّالِمُونَ ﴿٦٤﴾ ثُمَّ نُكِسُوا عَلَىٰ
رُءُوسِهِمْ لَقَدْ عَلِمْتَ مَا هَٰؤُلَاءِ يَنطِقُونَ ﴿٦٥﴾ قَالَ أَفَتَعْبُدُونَ مِن دُونِ اللَّهِ مَا لَا يَنفَعُكُمْ
شَيْئًا وَلَا يَضُرُّكُمْ ﴿٦٦﴾ أُفٍّ لَّكُمْ وَلِمَا تَعْبُدُونَ مِن دُونِ اللَّهِ أَفَلَا تَعْقِلُونَ ﴿٦٧﴾

«Үә тәллааһи лә-әкииданнә әсънәәмәкүм бәгдә әң түвәллүү мүдбиир (57). Фәҗәгәләһүм җүзәәзән илләә кәбиирал-ләһүм ләгәлләһүм иләйһи йәрҗигүүн (58). Каалүү мәң фәгәлә һәәзәә биәәлиһәтинәә иннәһү ләминәз-заалимиин (59). Каалүү сәмигнәә фәтәй-йәзкүруһүм йүкаалү ләһүү Ибрааһиим (60). Каалүү фәәтүү биһии гәләә әгйүнин-нәәси ләгәлләүһүм йәшһәдүүн (61). Каалүү-ә әңтә фәгәлтә һәәзәә биәәлиһәтинә йәә Ибрааһиим (62). Каалә бәл фәгәләһү кәбииру һүм һәәзәә фәсәлүү һүм иң кәәнүү йәңтыйкуун (63). Фәраҗәгүү иләә әңфүсиһим фәкаалүү иннәкүм әңтүмүз-заалимүүн (64). Сүммә нүкисүү гәләә ру-үсиһим ләкаде галимтә мәә һәәүләә-и йәңтыйкуун (65). Каалә әфтәгбүдүүнә миң дүүнил-лааһи мәә ләә йәңфәгүкүм шәйән үәләә йәдур-рукүм (66). Үфил-ләкүм үә лимәә тәгбүдүүнә миң дүүниллааһ. Әфәләә тәгкыйлүүн (67)».

Мәгънәсе: *«Аллаһы Тәгаләнең исеме илә ант итеп әйтәмен ки, потларыгызны җимерермен, сез алар яныннан киткән вакытыгызда» (57). Мөшрикләр китеп беткәч, Ибраһим балта белән потларны ваклады, мәгәр бер зур потны калдырды, мөшрикләр килгәч, кем ватканын шул поттан сорасыннар өчен (58). Мөшрикләр әйттеләр: «Безнең тәңреләребезгә бу әдәпсезлекне кем кылды? Дөреслектә, ул кеше — залимнәр-*

*дәндер» (59). Әйттеләр: «Бер егетне ишеттек, ул безнең тәңреләребезне гаепләп сөйли иде, ул егетнең исеме Ибраһим» (60). Нәмруд вә башкалары әйттеләр: «Ул Ибраһимны тотып китерегез кешеләр алдына — шаять, күргән кешеләр шаһәдәт бирерләр» (61). Әйттеләр: «И, Ибраһим, безнең тәңреләребезгә бу эшне син кылдыңмы?» (62). Ибраһим әйтте: «Бәлки бу эшне ошбу зур потыгыз эшләгәндер, үзен калдырып, кечкенә потларга табынганыгыз өчен хурланыптыр, инде ватылган потлардан сорагыз, әгәр алар сөйләшә торган булсалар» (63). Нәмруд вә аның кавеме гакыл вә фикерләренә кайтып уйлап тордылар һәм бер-берсенә әйттеләр: «Ошбу сөйләшми торган нәрсәләргә табынабыз, сез залим булдыгыз» (64). Соңра, дәлилләре булмагач, оялып, Ибраһим алдында башларын иделәр һәм әйттеләр: «Дөреслектә, беләсең, безнең потларыбыз сөйләшмиләр, алардан ничек сорыйк?» (65). Ибраһим әйтте: «Әллә сез Аллаһы Тәгаләдән башка файда итәргә дә, зарар итәргә дә көче җитмәгән нәрсәләргә табынасызмы? (66). Сезнең Аллаһы Тәгаләдән башка табынган нәрсәләрегез бозыклыктыр! Шуны да аңламыйсызмы? (67)».*

Нәмруд падишаһ, Ибраһим галәйһиссәламнең бу сүзләренә бик ачуы килеп, аны утта яндырырга кушты. Бу вәхшилекне кылыр өчен ул бик зур итеп учак ягарга боерды, учак кызып җиткәч, махсус ясалган атынчык белән аны нәкъ урта җиренә ташлатты. Бу турыда Коръән Кәримнең «әл-Әнбия» сүрәсе, 68–69 нчы аятьләрендә Хак Тәгалә әйтә:

قَالُوا حَرِّقُوهُ وَانصُرُوا آلِهَتَكُمْ إِن كُنتُمْ فَاعِلِينَ ۝٦٨

قُلْنَا يَا نَارُ كُونِي بَرْدًا وَسَلَامًا عَلَى إِبْرَاهِيمَ ۝٦٩

«Каалү хәррикуһү үәңсуруу әәлиһәтәкүм иң күнтүм фәәгилиин (68). Кульнәә йәә нәәру күүнии бәрдән үәсләәмән гәләә Ибрааһиим (69)».

Мәгънәсе: *«Ачулары кабарып, Нәмруд үз кавеменә әйтте: «Ул Ибраһимны утка салып яндырыгыз, әгәр үзегезнең потларыгыздан сорый торган булсагыз, Ибраһимны яндырырга алардан ярдәм сорагыз!» (68). Ибраһимны тау кадәр утка ыргыттылар, ләкин әйттек: «И, ут, Ибраһимга салкын бул, һәм салкынлык белән дә зарар тидермә (69)».*

Ибраһим галәйһиссәламнең Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән ничә көннәр буе ягылган уттан исән-имин чыкканың күреп торган Нәмруд кавеменең бәгъзеләре иман китерделәр. Бу турыда Коръән Кәримнең «әл-Әнгам» сүрәсе, 83 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَتِلْكَ حُجَّتُنَآ ءَاتَيْنَٰهَآ إِبْرَٰهِيمَ عَلَىٰ قَوْمِهِۦ نَرْفَعُ
دَرَجَٰتٍ مَّن نَّشَآءُ إِنَّ رَبَّكَ حَكِيمٌ عَلِيمٌ ٨٣

«Үә тилкә хүҗҗәтүнәә әәтәйнәәһәә Ибрааһиимә гәләә каумиһ. Нәрфәгү дәраҗәәтим-мин-нәшә. Иннә раббәкә хәкиимүн гәлиим (83)».

Мәгънәсе: *«Күңеле саф, иманы көчле һәм дине дөрес булган мөселманның гына Аллаһы Тәгаләнең газабыннан исән-имин булачагына китергән дәлилебез — көчле дәлил, без аны Ибраһимга бирдек, саф иманы, дөрес дине һәм хак эше белән өскә чыкканлыгын мөшрик кавеме күрсен өчен. (Ибраһим пәйгамбәр һичкемнән курыкмыйча Нәмруд кавемен Исламга өндәгән өчен Нәмруд падишаһ, ачуы килеп, тау хәтле ут яндырып, Ибраһимны шул утка ташлатты. Ибраһим исә күлмәге дә көймичә уттан исән-имин чыкты. Бу могҗиза Ибраһимга дәрәҗә өстенә дәрәҗә булды. Нәмрудка һәм аның явыз кавеменә газап өстенә газап булды.) Әнә шулай үзебез теләгән кешеләрнең дәрәҗәсен дөньяда да, ахирәттә дә бөек кылабыз (83)».*

Риваятьләргә караганда, Ибраһим галәйһиссәлам киң холыклы, йомшак табигатьле була. Үзенә кылынган явызлыклар өчен һичкемнән дә үч алырга теләми, үзен утка салган кавемен дә гафу итеп, аларны иманга өнди: «Газиз кавемем! Сезнең күз алдыгызда шушындый гыйбрәтләр, могҗизалар күрсәткән Аллаһы Тәгаләдән курыкмыйсызмы, Аны ташлап, һичнәрсәгә ярамаган потларга гыйбадәт кыласыз. Әлбәттә, мин Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләнең хак пәйгамбәремен, миннән һичберегез зарар күрмәс. Иман китереп, Аллаһы Тәгаләгә тиңдәшлекне вә башка золым эшләрне катыштырмаган хак мөселманнар Аның газабыннан имин булачаклар һәм алар туры юлга күнүчеләр», — дип вәгазьләвен дәвам итте. «Әл-Ганкәбут» сүрәсенең 16–17 нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَإِبْرَٰهِيمَ إِذْ قَالَ لِقَوْمِهِ ٱعْبُدُوا۟ ٱللَّهَ وَٱتَّقُوهُ ذَٰلِكُمْ خَيْرٌ لَّكُمْ
إِن كُنتُمْ تَعْلَمُونَ ﴿١٦﴾ إِنَّمَا تَعْبُدُونَ مِن دُونِ ٱللَّهِ أَوْثَٰنًا
وَتَخْلُقُونَ إِفْكًا إِنَّ ٱلَّذِينَ تَعْبُدُونَ مِن دُونِ ٱللَّهِ لَا يَمْلِكُونَ لَكُمْ
رِزْقًا فَٱبْتَغُوا۟ عِندَ ٱللَّهِ ٱلرِّزْقَ وَٱعْبُدُوهُ وَٱشْكُرُوا۟ لَهُۥٓ إِلَيْهِ تُرْجَعُونَ ﴿١٧﴾

«Үә Ибрааһиимә из каалә ликаумиг-бүдүл-лааһә үәттәкууһ. Зәәликүм хайрул-ләкүм иң күңтүм тәгләмүүн (16). Иннәмәә тәгъбүдүүнә миң дүүнил-лләһи әүсәәнәң үә тәхълүкуунә ифкә. Иннәлләзиинә тәгбүдүүнә миң дүүнил-лләһи ләә йәмликүүнә ләкүм ризкаң фәбтәгуу гиндәл-лааһир-ризка үәгбүдүүһү үәшкүруу ләһ. Иләйһи түрҗәгүүн (17)».

Мәгънәсе: *«Вә Ибраһим үз кавеменә: «Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылыгыз вә аннан гына куркыгыз, бу әйткәннәрне кылсагыз, үзегез өчен хәерледер, әгәр белсәгез», — диде (16). Аллаһы Тәгаләдән башка потларга гыйбадәт кыласыз вә потларыгызны тәңре дип ялган сөйлисез, Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кыла торган потларыгыз сезгә ризык бирергә кадир түгелләр бит, һәм ризыкны тик Хак Тәгаләдән сорагыз вә Аңа гына гыйбадәт кылыгыз һәм Аңа шөкер итегез, чөнки хөкем ителергә Аңа кайтасыз», — диде (17)».*

Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне төрле эшләр белән сынады, йөкләтелгән эшләрне үтәгәч, кешеләргә имам итеп куйды. Бу турыда Аллаһы Тәгалә «әл-Бәкара» сүрәсенең 124 нче аятендә әйтә:

وَإِذِ ٱبْتَلَىٰٓ إِبْرَٰهِـۧمَ رَبُّهُۥ بِكَلِمَٰتٍ فَأَتَمَّهُنَّ قَالَ إِنِّى جَاعِلُكَ
لِلنَّاسِ إِمَامًا قَالَ وَمِن ذُرِّيَّتِى قَالَ لَا يَنَالُ عَهْدِى ٱلظَّٰلِمِينَ ﴿١٢٤﴾

«Үә изибтәләә Ибрааһиимә Раббүһүү бикәлимәәтиң фәәтәммәһүннә. Каалә иннии җәәгилүкә линнәәси имәәмә. Каалә үә миң зүррийййәт. Каалә ләә йәнәәлү гаһдиз-заалимиин (124)».

М ә г ъ н ә с е : *«Янә Ибраһимның эшләрен хәтерләгез. Раббысы Ибраһимны боерган эшләр белән сынады. Ибраһим галәйһиссәлам йөкләтелгән эшләрне үтәгәч, Хак Тәгалә аңа әйтте: «И, Ибраһим, Мин сине кешеләргә имам итеп билгеләдем». Ибраһим әйтте: «И, Раббым, минем нәселемне дә имамнардан кыл». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Имам кылыр өчен булган вәгъдәм залимнәргә ирешмәс». Чөнки Ибраһим нәселеннән имам булырга яраклы изге кешеләр дә вә залимнәр дә булды (124)».*

Ибраһим галәйһиссәлам үз кавемен күпме генә иманга өндәсә дә, кяферләр үзләре ясаган потлардан аерылмадылар. Аллаһы Тәгаләнең әмере илә Ибраһим галәйһиссәлам һәм аның кардәше Лут галәйһиссәлам, Шам шәһәренә күчереп, ошбу залим кавемнән коткарылдылар. «Әл-Әнбия» сүрәсенең 71 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَنَجَّيْنَٰهُ وَلُوطًا إِلَى ٱلْأَرْضِ ٱلَّتِى بَٰرَكْنَا فِيهَا لِلْعَٰلَمِينَ ٧١

«Үә нәҗҗәйнәәһү үә Лүүтан иләл-әрдыйл-ләтии бәәракнәә фииһәә лил-гәәләмиин (71)».

М ә г ъ н ә с е : *«Ибраһим белән Лутны, Үзебез бөтен галәм өчен бәрәкәтле кылган Шам җиренә күчереп, залим кавемнән коткардык (71)».*

Хәбәрләрдән вә риваятьләрдән күренгәнчә, Бәйтелмөкаддәс мәсҗиден беренче булып Ибраһим галәйһиссәлам төзегән. Заманнар үтү белән ул җимерелә. Аннан соң бу бинаны Дауд галәйһиссәлам төзи башлый. Ул төзеп бетерә алмый, улы Сөләйман галәйһиссәламгә бинаны төзеп бетерергә васыять итеп калдыра. Мәсхур җеннәр, ягъни кулаяклары богауланган җеннәр, Сөләйман галәйһиссәлам вафатыннан соң, аны төзеп тәмам кылалар. Бу турыда «Сәба» сүрәсе, 14 нче аяти кәримәдә болай диелгән:

فَلَمَّا قَضَيْنَا عَلَيْهِ ٱلْمَوْتَ مَا دَلَّهُمْ عَلَىٰ مَوْتِهِۦٓ إِلَّا

دَآبَّةُ ٱلْأَرْضِ تَأْكُلُ مِنسَأَتَهُۥ فَلَمَّا خَرَّ تَبَيَّنَتِ ٱلْجِنُّ أَن

لَوْ كَانُوا يَعْلَمُونَ الْغَيْبَ مَا لَبِثُوا فِي الْعَذَابِ الْمُهِينِ ﴿١٤﴾

«Фәләммәә кадайнәә гәләйһил мәүтә мәә дәлләһүм гәләә мәүтиһии илләә дәәббәтүл әрдый тәәкүлү миңсә әтәһ. Фәләммәә харра тәбәй-йәнәтил җиннү әлләү кәәнү йәгләмүүнәл гайбә мәә ләбисүү фил гәзәәбил мүһиин (14)».

Мәгънәсе: *«Сөләйманның Без билгеләгән гомере беткәч, мөнбәрдә басып торган хәлдә җанын алдык, аның үлгәнен Хак Тәгалә җеннәргә дә, кешеләргә дә белдермәде. Мәгәр үлгән хәлдә таянып торган таягын кортлар ашап өзгәч, ул җиргә егылды, шул вакытта аның үлгәнен кешеләр дә, җеннәр дә белделәр, әгәр җеннәр яшерен нәрсәне белә торган булсалар, әлбәттә, авыр эштә бер ел буена кыйналып эшләп ятмаслар иде (14)».*

Аллаһы Тәгалә бу бина төзелеп бетсен өчен шулай эшләде. Чөнки Сөләйман галәйһиссәлам үлгәч, таягына таянып бер ел торды, мәсхур җеннәр, безгә карап тора дип, һаман эшләделәр, егылгач кына котылдык, дип качып беттеләр.

Бәйтел мөкаддәснең тәмамлануын белгәч, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә агач кортына: «Барып Сөләйман галәйһиссәламнең таягын кимер», — диде. Агач корты таякны кисеп бетерү белән Сөләйман галәйһиссәлам егылды. Җеннәр Сөләйман галәйһиссәламнең үлгәнен белгәч, тиз арада аңа хезмәт итүдән котылып, төрлесе-төрле якка качып беттеләр. Коръән Кәримдә әйтелә: «Без Сөләйман галәйһиссәламгә хөкем кылган заманда, аның үлеменә һичнәрсә ишарә итмәде, мәгәр агач кортының таякны кимерүе ишарәләде».

Сөләйман галәйһиссәлам унөч яшендә патша булды. Адәм балаларына зарар китермәсеннәр өчен, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән, җеннәргә һәм диюләргә вәгъдә кылдырды.

Унсигез яшендә Бәйтелмөкаддәсне төзеп тәмам кылырга Аллаһыдан әмер кылынды. Илле өч яшендә вафат булды. («Тәфсир Кадый»дан китерелде). Тарих галимнәре Сөләйман галәйһиссәламнең кая күмелгәне хакында ихтиляф кылдылар: кайберләре вафат булган сараенда, кайберләре Кызыл диңгез буенда, диделәр. Аллаһы Тәгалә белүчедер.

# ИСМӘГЫЙЛЬ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Ибраһим галәйһиссәлам вә Сара радыйаллаһу ганһә Бабил шәһәреннән чыгып киттеләр. Шәһәрдән чыгып бераз киткәч, Хак Сөбханә вә Тәгаләдән вәхи килде: «Хәлилем Ибраһим Сара белән никахлансын». Бу вакытта Ибраһим галәйһиссәламгә 38 яшь иде.

Газзә вә Җәлләнең әмере илә Ибраһим галәйһиссәлам һәм кардәше Лут галәйһиссәлам, Шам шәһәренә күчерелеп, потларга вә йолдызларга табынучы залим кавемнән коткарылдылар.

Ибраһим пәйгамбәргә Хак Сөбханә вә Тәгалә күп маллар бирде, иген бирде, су бирде. Тора-бара ул торган җир шәһәргә әйләнде. Ләкин аның Сара радыйаллаһу ганһәдән картайганчы баласы булмады. Моңа Сара радыйаллаһу ганһә үзе дә бик борчыла иде. Шул сәбәпле, карт көннәрендә булса да, Ибраһим галәйһиссәлам Хак Тәгаләдән бала сорап дога кылды. Аллаһы Тәгалә аның сораган догасын кабул итте һәм бер ир бала бүләк итте.

Риваятьләргә караганда, Ибраһим галәйһиссәламнең Һаҗәр исемле җариясе (хезмәтче хатын-кыз) бар иде. Үзенең баласы булмаганнан гаҗиз булган Сара радыйаллаһу ганһә ире Ибраһимга Һаҗәрне тәкъдим итте, ягъни аларны бергә йокларга күндерде. Сара радыйаллаһу ганһәнең күңелендә уе бар иде: Ибраһим пәйгамбәрнең бу җариядән углы туар, шуның белән ул ирен сөендерер.

«Әс-Саффәт» сүрәсенең 99–101 нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَقَالَ إِنِّي ذَاهِبٌ إِلَىٰ رَبِّي سَيَهْدِينِ ۝٩٩ رَبِّ هَبْ لِي مِنَ ٱلصَّٰلِحِينَ ۝١٠٠ فَبَشَّرْنَٰهُ بِغُلَٰمٍ حَلِيمٍ ۝١٠١

«Үә каалә иннии зәәһибүн иләә Раббии сәйәһдиин (99). Рабби һәблии минәс-саалихин (100). Фәбәшшәрнәәһү бигуләәмин хәлиим (101)».

М ә г ъ н ә с е : *«Вә ул әйтте: «Раббым әмер иткән җиргә күчеп китәмен, әлбәттә, Раббым мине барасы җиремә җит-*

*керер». Ибраһим вә аның хатыны картайганнар, балалары юк иде. Шул сәбәпле, карт көннәрендә булса да Ибраһим Аллаһы Тәгаләдән бала сорады (99): «И, Раббым, миңа бер изге ир бала биргел, ул миңа карт көнемдә ярдәмче булса иде». (100). Без Ибраһимга бер ир бала белән шатлык хәбәрен бирдек, ул бала кечкенә чагында ук галим иде, зуррак булгач та йомшак күңелле бала булды (101)».*

Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләдән бала сорап дога кылганнан соң, күп тә үтми, пәйгамбәрлек нуры аңа угыл тудырачак хатынга, ягъни Һаҗәр анага күчте. Сара радыйаллаһу ганһәдә көнчелек уты кабынды. Сара радыйаллаһу ганһә ачу белән: «Һаҗәрнең өч әгъзасын кисәрмен вә Ибраһим алдында гаепле кылырмын», — дип ант эчте, ягъни Һаҗәрнең борынын, ике колагын кисәргә ант итте. Һаҗәр ана моны белгәч, зар-зар елады. Хак Тәгаләгә гыйбадәт кылып, бу бәладән коткаруын сорап дога кылды. Догасы кабул булды. Җәбраил галәйһиссәлам килеп, Ибраһим галәйһиссәламгә әйтте: «Сара Һаҗәргә золымлык кылмасын, бу — Аллаһы Тәгаләнең әмере, золымнардан Хак Тәгалә разый булмас», — диде. Ибраһим галәйһиссәлам Сара радыйаллаһу ганһәгә Җәбраил галәйһиссәламнең әйткән сүзләрен ирештерде. Сара радыйаллаһу ганһә әйтте: «Әйе, мин Һаҗәрнең өч әгъзасын кисәрмен дип касд кылган идем (ант иткән идем), нишләмәк кирәк инде?» — диде. Җәбраил фәрештә Ибраһим галәйһиссәламгә әйтте: «Сара Һаҗәрнең ике колагын тишсен, шуның белән анты кире кайтарылыр», — диде. Сара радыйаллаһу ганһә боларны бик теләп эшләде, күңеленнән: «Инде Һаҗәрне Ибраһим алдында ямьсез кылдым, аны һәм туачак баланы инде яратмас», — дип шатланды. Аллаһы Тәгаләнең әмере илә Җәбраил галәйһиссәлам оҗмахтан Һаҗәр анага ике алка китереп колагына кидерде. Бу алкалар белән Һаҗәр ананың матурлыгы тагын да артты. Бу гамәл, ягъни колакны тишеп алка тагу Исламда сөннәт гамәл булып калды.

Һаҗәр ананың хәмел мөддәте (бала тудырыр вакыты) якынлашкан саен Сара радыйаллаһу ганһәнең аслан (чынлыкта) сабырлыгы калмады. Ул: «Һаҗәрне күз алдымда тотма, моннан ерак булган җиргә илтеп ташла», — дип, Ибраһимны борчып ирексезләде. Ибраһим галәйһиссәлам инде ни эшләргә дә белмичә гаҗиз булып торганда, Хак Сөбханә вә Тәгаләдән Җәбра-

ил галәйһиссәлам аркылы: «Бу эшне Сара теләгәнчә башкар», — дигән фәрман килде. Сара радыйаллаһу ганһә әйтте: «Һаҗәрне сусыз, илсез җиргә илтеп куй, дөяңнән төшмә, Һаҗәрне һәм туачак балаңны кызганып, аның белән төн кунма! Шуларны үтим дип ант ит!» — диде. Ибраһим галәйһиссәлам шушы өч шартны үтисен белдереп ант итте. Ибраһим галәйһиссәлам алга, Һаҗәр ана артка утырып, Шам җиреннән юлга чыктылар. Бернинди терексез, сусыз чүл-таулар аша узып, бик озак баргач, тирә-якта таулык-ташлык, бернинди дә үлән үсми торган җиргә җиттеләр. Ибраһим галәйһиссәлам Һаҗәр ананы шунда төшереп, янында бер тәлгәш йөзем җимеше, бер савыт су калдырып, Сара радыйаллаһу ганһәгә вәгъдә кылганча, Шам Шәриф тарафына борылып кайтып китте.

Һаҗәр ана Ибраһим галәйһиссәлам киткәч ары йөгерде, бире йөгерде, чарасызлыктан гаҗиз булып, баласын шунда тапты. Берәр җирдә су тапмаммы дип, Сафа тавына, аннан Мәрва тавына менеп карады.

Янә Сафа тавына барды, аннан янә Мәрва тавына барды. Ахыр үзенең вә дәхи йөрәк парәсе баласының исән калуына өметен өзеп, җиденче мәртәбә Мәрва тавына барганда бер тавыш ишетте, әмма һичкемне дә күрмәде, бу тавыш иясе Җәбраил галәйһиссәлам иде. Ул: «Хак Тәгалә синең углыңны заегъ кылмас (бәхетсез итмәс), бу урында Аллаһы Тәгаләнең әмере илә синең углың Исмәгыйль атасы Ибраһим галәйһиссәлам белән Кәгъбәтулланы салсалар кирәк», — диде. Һаҗәр ана баласының аяк үкчәсе турысына караса, су чыга башлаганын күрде. Баласын кочагына алып, Хак Сөбханә вә Тәгаләгә шөкрана кылды. Бу суны эчкәч, йөрәгенә хәл керде, тамагы да тукланды. Моннан соң ана вә бала сусызлыктан котылдылар. Янә Җәбраил галәйһиссәламнең авазы ишетелде: «Бу чишмәнең исеме Зәмзәм булыр, Аллаһы Тәгалә аны сезгә һәм барча дөнья мөселманнарына һәдия, ягъни бүләк итеп бирде. Зәмзәм суын нинди ният белән эчсәң, шул ниятең кабул булыр, син аны су савытына да тутырма, таш белән дә бума, Хак Тәгалә бу чишмәне кыяматкә кадәр туктатмас вә дәхи мөбарәк урынны гыйбадәтханә кылыр, синең углың Исмәгыйльнең пәйгамбәр булачагы хакында Газзә вә Җәллә сезгә сөенеч җибәрде», — диде.

Йәмән гарәпләре сәүдә кәрваны белән Шам Шәриф тарафына, бу җирләрдән узып, күп еллар буе йөриләр иде. Бу тирә-юньдә һичбер вакыт суның әсәре дә югын алар яхшы беләләр иде. Бик сусадылар, кайда гына суга ирешербез инде, дип барганда бер төркем кошлар күрделәр. Ошбу сәүдә юлында күп йөргән тәҗрибәле картлар әйтте: «Су булмаган җирдә бу кошлар булмыйлар, монда бер яңа су чыга башлагандыр». Килеп баксалар, күрделәр: көчле агымлы чишмә янында бер бик гүзәл хатын кечкенә баласы белән утыра. Кәрван хуҗасы Һаҗәр анадан сорады: «И, гүзәл хатын, сез адәм нәселеннәнме яки җен кавеменнәнме? Ничә еллардан бирле мин үземнең кәрваным илә бу тирәдән узып сәүдә итәм, бередә бервакытта да суның әсәре дә булганы юк иде, бу ни хикмәт?» — дип сорады. Һаҗәр ана үзенең хәл-әхвәлен сөйләде вә әйтте: «Аллаһы Тәгалә бу мул сулы гаҗәеп чишмәне йөрәк пәрәсе газиз балама һәм миңа багышлады, бу чишмәнең исеме Зәмзәм булыр, аның суы сусаган барча тереклеккә җитәрлек», — диде. Аннан соң барча кәрван халкы ошбу могҗизалы судан үзләре һәм дөяләре эчеп хушландылар. Сәүдәгәрләр баланың исемен сорадылар. Һаҗәр ана җавабында: «Бу мин сезгә сөйләгән Ибраһим пәйгамбәрнең углы Исмәгыйль була», — диде. Һаҗәр анадан рөхсәт сорап, бу гарәпләр Йәмән җирләреннән бөтенләйгә бирегә күчеп килделәр. Алар Һаҗәр ананы вә дәхи аның углы Исмәгыйльне бик хөрмәт иттеләр. Исмәгыйль галәйһиссәлам гарәпчә сөйләшер иде вә һәрдаим гарәп балалары илә уйнап үсте. Шул рәвешчә 7 ел вакыт узып та китте.

Ибраһим галәйһиссәлам төш күрде, төшендә үзенең иң якын булган газиз баласы Исмәгыйльне корбан итеп чалырга тиешлеген аңлады. Өченче мәртәбә ошбу халәтне төшендә күргәч, «Йә, Аллаһ, бу төшемдә Газзә вә Җәллә ошбу сабый баламны, күз нурымны, бәгырь җимешемне суярга боера икән лә», — дип, Хак Тәгаләгә биргән вәгъдәсен исенә төшерде. Олыгайган көннәрендә Аллаһы Тәгалә аңа ир бала насыйп итте. Аның: «И, Раббым, хәерле бала насыйп итсәң иде, ул Хак Тәгаләгә изгелек кылучы бала булса, аны Сиңа багышлар идем», — дигән сүзләре исенә төште. Төшләрендә, караңгы төн урталарында, үз баласын үзе суйганын күреп, тетрәнеп

уянды. Әстәгъфируллаһ, кем үзенең ялгыз бер сабыен суйсын? Йә, Рабби, нинди ата, йә нинди ана үз баласын суйсын? Хайван да үз баласын тоягы белән дә басмый. Ерткыч җанварлар да балаларына самими-эчкерсез мөнәсәбәттәдер. Йә инде, нинди ата суяр үз баласын? Бу баласын нишләтер икән дип, Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне сынады. Югыйсә, Аллаһы Зөл-Җәләлгә кечкенә генә җан иясен дә юкка чыгару кирәк түгел!

Ибраһим галәйһиссәлам Мәккә җирләренә килгәч, углы Исмәгыйльне һәм Һаҗәрне кочаклап, бик җылы күреште. Углы Исмәгыйльгә киенергә кушты, Һаҗәр ана аны киендереште, өстенә хушбуйлар сипте. Янәсе, Ибраһим галәйһиссәламнең бередә яшәүче якын дустына кунакка баралар, саф һава сулыйлар — хозур кичерәләр. Ибраһим галәйһиссәлам бердәнбер углын Мина тавына корбан итеп чалырга алып бара. Исмәгыйль галәйһиссәлам күзенә Иблис ләгыйнь күренә, ул Ибраһим галәйһиссәламнең кулындагы бауга һәм үткен пычакка ишарә кылып: «Йә, Исмәгыйль, күрмисеңме атаңның кулында бау вә үткен пычак, ул сине суярга алып бара!» — диде. Исмәгыйль галәйһиссәлам өч таш ала да котыртучы шайтанга ата. Баруларын дәвам итәләр. Иблис ләгыйнь янә шуны кабатлый. Исмәгыйль галәйһиссәлам тагын өч таш ата, шул рәвешчә өч тапкыр кабатлана. Мина тавына барып җиткәч, Ибраһим галәйһиссәлам катрә-катрә күз яшьләрен агызып әйтә: «И, бәгырь җимешем, мин Хак Тәгаләдән сине корбан чалырга боерылдым», — дип, үзенең төшендә ни күргәнен углына бәян итә. Исмәгыйль галәйһиссәлам әтисенә әйтә: «Йә, атам, чалган вакытта син мине җәлләмә, минем күзләремә карама, күзләремә карасаң, чалырга кулың бармас, Аллаһы Тәгаләгә биргән вәгъдәң үтәлмәс», — ди. Бу турыда «әс-Саффәт» сүрәсенең 102–111 нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فلما بلغ معه السعى قال يبنى انى ارى فى المنام انى اذبحك فانظر ماذا ترى
قال يابت افعل ما تؤمر ستجدنى ان شاء الله من الصبرين ۝١٠٢ فلما اسلما وتله
للجبين ۝١٠٣ ونادينه ان يابرهيم ۝١٠٤ قد صدقت الرءيا انا كذلك نجزى المحسنين ۝١٠٥

إن هذا لهو البلؤا المبين ۝١٠٦ وفدينه بذبح عظيم ۝١٠٧ وتركنا عليه في الآخرين ۝١٠٨ سلم
على إبرهيم ۝١٠٩ كذلك نجزي المحسنين ۝١١٠ إنه من عبادنا المؤمنين ۝١١١

«Фәләммәә бәләга мәгәһүс-сәгйә каалә йәә бүнәййә иннии әраафил мәнәәми әннии әзбәхүкә фәңзур мәә зәә тәра. Каалә йәә әбәтифгәл мәә түэмәру сәтәҗидүнии иң шәәәллааһү минәс-саабириин (102). Фәләммә әсләмәә үә тәлләһү лил-җәбиин (103). Үә нәә дәйнәәһү әййәә Ибрааһиим (104). Каде саддәкътәрруйә. Иннәә кәзәәликә нәҗзил-мүхсиниин (105). Иннәә һәәзәә ләүһәл-бәләәүл мүбиин (106). Үә фәдәйнәәһү бизибхин гәзыыйм (107). Үә тәракнәә гәләйһи фил әәхыйриин (108). Сәләәмүн гәләә Ибраһиим (109). Кәзәәликә нәҗзил-мүхсиниин (110). Иннәһү мин гибәәдинил-мүэминиин (111)».

Мәгънәсе: *«Ул бала җиде яшенә җитеп атасы илә йөри башлагач, Ибраһим әйтте: «И, углым, мин төшемдә Аллаһы Тәгалә тарафыннан сине корбан итеп чалырга боерылдым, уйлап күр, бу эшкә ничек карыйсың?» Углы Исмәгыйль: «И, атам, ни белән боерылган булсаң, шуны эшлә, мин Аллаһы Тәгаләнең хөкеменә ризамын, бу эштә мин, Хак Тәгалә теләсә, сабыр итүчеләрдән булырмын», — диде. (102). Безнең әмерне икесе дә риза булып кабул иттеләр вә Исмәгыйльне яны белән яткызды (103). Кулына пычак алуга, Без кычкырдык: «И, Ибраһим (104), төшеңдә күргән Безнең әмерне тәсдыйк кылдың, үтәгән хөкемендә булдың». Әнә шулай Үзебезгә итагать иткән яхшы мөэминнәрне изгелекләр белән нигъмәтлибез (105). Аллаһы Тәгаләнең изге балаңны корбан итеп чал дигән әмере, әлбәттә, зур вә авыр сынаудыр (106). Без аңа Исмәгыйль урынына корбан итеп бугазлар өчен җәннәттән зур тәкә бирдек (107). Яхшылык белән искә алу өчен дөньяга соңыннан килгәннәргә Ибраһимның яхшы әсәрләрен калдырдык (108). Ул Ибраһимга барча галәм сәлам әйтер (109). Яхшы эшләрне кылучыга Без шулай изгелек итәбез (110). Ибраһим Безнең хак мөэмин колларыбыздандыр (111)».*

Шушы авыр сынауны үткәннән соң Хак Сөбханә вә Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне Хәлиуллаһ дип атады, ягъни ул Аллаһы Тәгаләнең дусты, сөеклесе булды.

Ибраһим галәйһиссәламгә вә аның сөекле углы Исмәгыйль галәйһиссәламгә Кәгъбәтулланы салу хакында Аллаһы Тәгаләнең әмере булды. Риваятьләргә караганда, җәннәттән атабыз Адәм галәйһиссәламне Һиндстан җиренә, Хәва анабызны Җиддә тавына иңдергәннән соң, алар аерылышу ачысыннан кайнар күз яшьләрен түктеләр. Ошбу күз яшьләренең ихлас күңелдән булганы өчен, Хак Тәгалә аларга миһербанлык кылды вә аларны Мәккә җирендә очраштырды. Шуның хөрмәтенә Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламгә вә аның булачак балаларына, гыйбадәт кылу өчен, фәрештәләре ярдәмендә Бәйтелмәгъмүрне иңдергән иде. Әлбәттә, аның ташларын адәм күтәрерлек түгел иде. Адәм галәйһиссәламгә Аллаһы Тәгаләдән хитаб килде: «Балаларыңнан һәркем бу бинаны тәваф кылса, гөнаһлары ярлыканыр, әҗер-савапларыартыр». Адәм галәйһиссәламнең балалары ошбу Бәйтелмәгъмүрдә гыйбадәт кылдылар. Кайчан туфан заманы булды исә, Хак Тәгаләнең әмере илә рәхмәт фәрештәләре Бәйтелмәгъмүргә куелган ул зур-зур ташларны тауларга илтеп куйдылар. Туфаннан соң бу урында кызыл таучык хасил булды. Соңгы вакытка кадәр адәмнәрнең шул кызыл таучык янына килеп Аллаһы Тәгаләдән сораган догалары кабул була иде. Ибраһим галәйһиссәлам заманынача бу кызыл таучык шул хәлдә кала бирде. Хак Сөбханә вә Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламгә вә аның углы Исмәгыйль галәйһиссәламгә нәкъ менә шушы кызыл таучык булган урынга Кәгъбәтулла бинасын салырга боерды. Аллаһы Тәгаләнең әмерен алар җан-тәннәре белән шатланып кабул иттеләр вә шул көнне үк эшкә дә тотындылар. Исмәгыйль галәйһиссәлам таш, балчык ташыды. Ибраһим галәйһиссәлам исә бу ташларны шомартып, җайлап салып торды. Бәйтелмәгъмүрдән калган зур-зур ташларны Хак Тәгаләнең фәрештәләре ташып тордылар. Бина югары күтәрелгәч, Ибраһим галәйһиссәлам аяк астына таш куеп, үрелеп, өске ташны куйды. Шул вакытта, Ходай рәхмәте, аның аяк астына куйган ташта батып кергән аяк эзләре калды. Ул урын Мәкам Ибраһим дип атала.

Соңгы ташны куйганнан соң, Җәбраил галәйһиссәламнең өйрәтүе буенча, ихрам баглап, биредәге гарәп каваеме белән бергә, хәзерге хаҗ вакытына охшашлы хаҗ кылдылар. «Әл-Хаҗ» сүрәсенең 26–30 нчы аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

واذ بوانا لابرهيم مكان البيت ان لا تشرك بي شيا وطهر بيتي للطائفين والقائمين والركع
السجود ۝ ٢٦ واذن في الناس بالحج ياتوك رجالا وعلى كل ضامر ياتين من كل فج
عميق ۝ ٢٧ ليشهدوا منفع لهم ويذكروا اسم الله في ايام معلومت على ما رزقهم من بهيمة
الانعام فكلوا منها واطعموا البائس الفقير ۝ ٢٨ ثم ليقضوا تفثهم وليوفوا نذورهم
وليطوفوا بالبيت العتيق ۝ ٢٩ ذلك ومن يعظم حرمت الله فهو خير له عند ربه واحلت
لكم الانعام الا ما يتلى عليكم فاجتنبوا الرجس من الاوثان واجتنبوا قول الزور ۝ ٣٠

«Үә из бәүвәэнәә ли Ибрааһиимә мәкәәнәл-бәйти әлләә түшрик бии шәйән үә таһһир бәйтиә литтааифиинә үәл-кааимиинә үәр-руккәгис-сүҗүүд (26). Үә әззиң финнәәси билхәҗҗи йәэтүүкә риҗәәләү-үә гәләә күлли даамирин йәэтиинә миң күлли фәҗҗин гәмиикъ (27). Лийәшһәдүү мәнәәфигә ләһүм үә йәзкүрусмәллааһи фии әййәәмим-мәглүмәәтин гәләә мәә разәкаһүм мим-бәһииммәтил-әнгәәм. Фәкүлүү минһәә үә әтъгимүл-бәәисәл-фәкыыйр (28). Сүммәл-йәкъдуу тәфсәһүм үәл-йүүфүү нүзүүраһүм үәл-йәттаүвәфүү бил-бәйтил-гәтиикъ (29). Зәәликә үә мәй-йүгәззыйм хүрумәәтил-ләәһи фәһүвә хайрул-ләһү гиндә раббиһ. Үә үхилләт ләкүмүл-әнгәәмү илләә мәә йүтләә гәләйкүм фәҗтәнибүр-риҗсә минәл-әүсәәни үәҗтәнибүү кауләз-зүүр (30)».

Мәгънәсе: *«Дәхи хәтерләгез, Ибраһимга Кәгъбәнең урынын бәян иттек, вә аңа әйттек: «Миңа һичнәрсәне тиңдәш итмә, вә Минем өемне яңадан килеп тәваф итүчеләргә, вә анда торучыларга, вә намаз укучыларга пакьлә, анда Ислам диненә хилаф бер гамәл дә булмасын (26). Кешеләрне хаҗга чакырып кычкыр, җәяү йөреп сиңа килерләр, вә арык дөяләргә атланып килерләр, ул дөяләр ерак юлларның һәрбереннән килерләр (27). Хаҗиларның дөньяларына вә диннәренә файда китерсеннәр өчен һәм тәшрикъ кебек билгеле бәйрәм көннәрендә Аллаһы исемен күп зикер итсеннәр өчен, дөя, сыер вә куйлар белән ризыкландыруына шөкер итеп, хаҗда чалган корбан итләрен ашагыз һәм бик фәкыйрьләргә аша-*

*тыгыз (28). Соңра чәч, мыек, тырнак кебекләрне кисеп артыгын бетерсеннәр, нәзерләрен үтәсеннәр вә Минем иске өем Кәгъбәне тәваф итсеннәр (29). Зикер ителгәннәр хаҗ гамәлләредер, берәү Аллаһы Тәгаләнең хөкемнәрен вә Кәгъбәне зурласа, аның зурлавы Хак Тәгалә хозурында аның өчен хәерледер. Сезгә дөя, сыер вә куй, кәҗә хәләл булды, мәгәр Коръәндә хәрамлыгы зикер ителгән нәрсәләр хәләл түгел, тәреләрдән сакланыгыз, нәҗестән сакланган кебек, һәм ялган, бөһтан һәм пычрак сүзләрдән сакланыгыз! (30)».*

Ибраһим галәйһиссәлам исеме Коръән Кәрим аятьләрендә 69 урында искә алына.

Исмәгыйль галәйһиссәлам исеме 12 аяти кәримәдә искә алына.

Мөхтәрәм мөселман кардәшләр! Ибраһим галәйһиссәлам вә дәхи Исмәгыйль галәйһиссәлам кыйссасы Коръән Кәримдә, риваятьләрдә инде ничәмә-ничә гасырлардан бирле мөселман өммәте күңелендә, аңында, теле вә язуында, әдәби һәм мәдәни мирасында яшәп килә. Бу аяти кәримәләрдә Аллаһы Тәгаләнең Үз бәндәләрен төрле авырлыклар биреп сынавы, корбан чалу, Кәгъбәтулланы аякка бастыру вакыйгалары тарихи дәлилләр белән тасвирланганнар, шуңа күрә дә инде вакыйгалар мөселман халкының рухи дөньясында һаман да эзлекле рәвештә тәэсир ясый торган, ягъни аңар ямь һәм төс бирә торган иң асыл җәүһәрләрнең берсе булып тора бирә.

Халкыбызның рухи тормышына, аның көндәлек дөньясына бу кыйссаның никадәр тирән үтеп керүен җомга көннәрендә хәзрәтләребезнең вәгазьләрендә Ибраһим вә Исмәгыйль галәйһиссәламнәргә багышланган аяти кәримәләргә мөрәҗәгать итүләреннән, Исмәгыйль галәйһиссәлам кыйссасын сөйләгәндә күзләрендәге яшь бөртекләреннән күрергә була, чөнки ошбу авыр сынаудан соң Зөл-Җәләлнең әмере илә сабый балалар урынына корбанга куй, кәҗә, сыер яки дөяне чала башладылар.

# ИСХАК ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Мәккәи Мөкәррәмәдә Һаҗәр анадан Ибраһим галәйһиссәламнең углы Исмәгыйль галәйһиссәлам туып унөч ел вакыт үткәч, Җәбраил галәйһиссәлам аркылы Сара радыйаллаһу ганһәгә ир бала табачагы хакында сөенечле хәбәр бирелде. «Әс-Саффәт» сүрәсенең 112 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَبَشَّرْنَٰهُ بِإِسْحَٰقَ نَبِيًّا مِّنَ ٱلصَّٰلِحِينَ ۝١١٢

«Үә бәшшәрнәәһү би-Исхәәка нәбиййәм-минәс-саалихиин (112)».

М ә г ъ н ә с е : *«Дәхи, Без Ибраһимга Исхак исемле углының дөньяга киләчәге һәм аның изге кеше, пәйгамбәр булачагы турында сөенечле хәбәр бирдек (112)».*

Аллаһы Тәгалә Җәбраил галәйһиссәламне ун фәрештә белән Ибраһим галәйһиссәлам янына җибәрде. Әлеге фәрештәләр яшь егет сурәтендә Ибраһим галәйһиссәламгә килеп сәлам бирделәр. Бу вакытта Ибраһим галәйһиссәлам ураза тота иде. Ифтарга, ягъни авыз ачарга кунаклар килде, дип сөенде. Дүрт аягы да ак, үзе кызыл төстә, маңгаенда ак каш-касы да булган бик матур бозаулары ишегалдында уйнап йөри иде. Ибраһим галәйһиссәлам, кунакларның да күңелен күрим дип, ошбу үзләренә дә сөекле булган бозауны чалды. Тик бу сөйләшми торган егетләрдән ни өчендер курка иде. «Әл-Хиҗер» сүрәсенең 51–56 нчы аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَنَبِّئْهُمْ عَن ضَيْفِ إِبْرَٰهِيمَ ۝٥١ إِذْ دَخَلُوا عَلَيْهِ فَقَالُوا سَلَٰمًا قَالَ إِنَّا مِنكُمْ وَجِلُونَ ۝٥٢ قَالُوا
لَا تَوْجَلْ إِنَّا نُبَشِّرُكَ بِغُلَٰمٍ عَلِيمٍ ۝٥٣ قَالَ أَبَشَّرْتُمُونِى عَلَىٰٓ أَن مَّسَّنِىَ ٱلْكِبَرُ فَبِمَ تُبَشِّرُونَ ۝٥٤
قَالُوا بَشَّرْنَٰكَ بِٱلْحَقِّ فَلَا تَكُن مِّنَ ٱلْقَٰنِطِينَ ۝٥٥ قَالَ وَمَن يَقْنَطُ مِن رَّحْمَةِ رَبِّهِۦٓ إِلَّا ٱلضَّآلُّونَ ۝٥٦

«Үә нәббиәһүм гән дайфи Ибрааһиим (51). Из дәхалүү гәләйһи фәкаалүү сәләәмә. Каалә иннәә миңкүм үә җилүүн (52). Каалүү ләә тәүҗәл иннәә нәбәш-ширүкә бигуләәмин гәлиим (53). Каалә әбәшшәртүмүүнии гәләә әммәс-сәниәл-кибәру фәбимә түбәшшируун (54). Каалүү бәшшәрнәәкә бил-хәккый фәләә тәкүм-минәл-каанитыййн (55). Каалә үә мәй-йәкънәту мир-рахмәти Раббиһии илләд-дааллүүн (56)».

Мәгънәсе: *«Аларга Ибраһим өенә килгән кунаклар турында хәбәр бир!» (51). Ибраһим өенә кергәч, кунаклар сәлам бирделәр, алар фәрештәләр иде. Ибраһим аларга: «Мин сездән куркамын», — диде (52). Фәрештәләр әйттеләр: «Син бездән курыкма, без сиңа Аллаһы Тәгаләдән шатлыклы хәбәр китердек, синең гыйлемле углың туачак» (53). Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Гаҗәп, сез миңа карт көнемдә балаң туачак, дип куандырырга килдегезме?» (54). Фәрештәләр әйттеләр: «Без сиңа дөрес хәбәр китердек, аң бул, өметеңне өзмә!» (55). Ибраһим әйтте: «Әлбәттә, мөэмин бәндә Раббысының рәхмәтеннән өмет өзмәс, мәгәр юлдан язган вә адашканнар гына өмет өзә», — диде (56)».*

Ибраһим галәйһиссәлам кунаклар алдына яңа пешкән бозау итен китереп куйды.

Аларның бу бозау итен ашамауларын күргәч: «Ник ашамыйсыз?» — дип сорады. Алар җавап бирмәделәр. Ибраһим галәйһиссәлам янә бик каты курыкты, күңеленнән: «Болар фәрештәләр, Аллаһы Тәгаләнең газабын җиткерергә килгәннәрдер», — дигән уй аның тынычлыгын алды, аның янында басып торган хатыны да куркуга төште. «Һуд» сүрәсенең 71–73 нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وامراته قائمة فضحكت فبشرنها باسحق ومن وراء اسحق يعقوب ۝٧١ قالت يويلتى ءالد
وانا عجوز وهذا بعلي شيخا ان هذا لشيء عجيب ۝٧٢ قالوا اتعجبين من امر الله
رحمت الله وبركته عليكم اهل البيت انه حميد مجيد ۝٧٣

«Үәмра әтүһү кааимәтүң фәдахикәт. Фәбәшшәрнәәһәә би-Исхәәка үә миү-үә рааи Исхәәка Йәгкууб (71). Кааләт йәәүәйләтәә-ә әлиду үә әнә гәҗүүзүн үә һәәзәә бәглии шәйха. Иннә һәәзәә ләшәәүн гәҗиибе (72). Каалүү әтәгҗәбиинә мин

әмрилләәһ. Үә рахмәтуллааһи үә бәракәәтүһү гәләйкүм әһләлбәйти иннәһү хәмиидүм-мүҗииде (73)».

Мәгънәсе: *«Ибраһим галәйһиссәламнең хатыны шунда ук басып тора иде, Без аңа Исхак исемле бала тудырачагы вә Исхактан Ягъкуб исемле бала булачагы турында сөенечле хәбәр бирдек (71). Хатын әйтте: «Бу — кеше ышанмаслык эш. Мин бит карчык инде, ирем дә карт кеше, каян килеп безнең балабыз булсын? Бу гайре табигый хәл» (72). Фәрештәләр әйттеләр: «Аллаһы Тәгаләнең кодрәтенә гаҗәпләнәсезме? И, пәйгамбәрлек заһир булган өй кешеләре! Сезгә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте вә бәрәкәте булачак.Шөбһәсез ки, Ул мактауга лаек зат, Аның игелеге киңдер (73)».*

Риваятьләргә караганда, Ибраһим галәйһиссәлам вә Сара радыйаллаһу ганһә бозау ите вә башка нигъмәтләр илә авыз ачып туклангач, Хак Сөбханә вә Тәгалә биргән нигъмәтләргә дога кылдылар. Шуннан соң Җәбраил галәйһиссәлам канаты белән өстәлдәге бозау итен сыйпады, бозау дәрхаль терелде вә әнисе янына йөгереп барып, аның сөтен имә башлады. Бу могҗизаны күреп, Ибраһим галәйһиссәлам вә Сара радыйаллаһу ганһә бу егетләрнең чыннан да Аллаһы Тәгаләнең фәрештәләре булуларына янә бер мәртәбә инандылар.

Бу сөенечле вакыйгадан соң тугыз ай узгач, Сара радыйаллаһу ганһә бик матур, сау-сәламәт ир бала тапты. Аңа Исхак дип исем куштылар. Ибраһим галәйһиссәлам вә Сара ана бик сөенештеләр. Ибраһим галәйһиссәлам, Мәккәи Мөкәррәмәгә барып, Һаҗәр ана вә углы Исмәгыйль галәйһиссәлам белән бу шатлыкны уртаклашты. Хак Тәгаләгә багышлап, Мина тавында корбан чалып, Мәккәдә яшәүче халыкны ошбу корбан ите белән сыйлады. Моннан соң Һаҗәр ана, углы Исмәгыйль галәйһиссәлам вә оныклары белән саубуллашып, Шам Шәриф шәһәренә кайтып китте.

Исхак галәйһиссәлам балигъ булгач, аңа Аллаһы Тәгаләдән пәйгамбәрлек килде. Ибраһим галәйһиссәламнең фатихасы белән Исхак галәйһиссәлам Батул исемле гадел кешенең Рабика исемле кызын никахлап алды. Рабикадан игез ике ир бала дөньяга килде. Бу балаларның берсенә Гайсу, икенчесенә Ягъкуб исеме куштылар.

Риваять кылынадыр ки, Хак Сөбханә вә Тәгаләнең Ибраһим галәйһиссәламгә иңдергән Китабында мондый юллар

язылган була: «Оҗмах сараенда тәвә кошына охшашлы зур-зур кошлар агачтан-агачка очып, бик матур авазлар чыгарып сайрарлар. Оҗмах әһелләре, ул кошларның сайрауларыннан хозурланып, Хак Тәгаләгә хәмед әйтерләр. Әгәр дә инде күңелдә бу кошларны ашау нияте туса, шул мизгелдә үк алар пешерелеп, алтын-көмеш савытларда алга китереп куелыр. Ашап туеп дога кылгач, дәрхаль терелеп, сайрый-сайрый китеп барырлар», — дигән сүзләрне укыгач, Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә болай диде: «И, Раббым, үлекне ничек тергезәсең, моның мисалын җир өстендә дә күрсәт», — диде. Хак Тәгалә әйтте: «Син шикләнәсеңме?» — диде. «Әл-Бәкара» сүрәсенең 260 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَإِذْ قَالَ إِبْرَٰهِمُ رَبِّ أَرِنِي كَيْفَ تُحْيِ الْمَوْتَىٰ قَالَ أَوَلَمْ تُؤْمِنْ قَالَ بَلَىٰ وَلَٰكِنْ لِيَطْمَئِنَّ
قَلْبِي قَالَ فَخُذْ أَرْبَعَةً مِنَ الطَّيْرِ فَصُرْهُنَّ إِلَيْكَ ثُمَّ اجْعَلْ عَلَىٰ كُلِّ جَبَلٍ مِنْهُنَّ جُزْءًا
ثُمَّ ادْعُهُنَّ يَأْتِينَكَ سَعْيًا وَاعْلَمْ أَنَّ اللَّهَ عَزِيزٌ حَكِيمٌ ۝٢٦٠

«Үә из каалә Ибрааһиимү Рабби әринии кәйфә түхил-мәүтә. Каалә әүәләм түэмин. Каалә бәләә үә ләәкил-лийәтъмәиннә калби. Каалә фәхуз әрбәгәтәм-минәт-тайри фәсур һүннә иләйкә сүммәҗгәл гәләә күлли җәбәлим-минһүннә җүзәң сүммәд-гүннә йәэтиинәкә сәгйә. Үәгләм әннәллаа һә гәзиизүн хәкиим (260)».

Мәгънәсе: *«Ибраһим әйтте: «И, Раббым, үлекне ничек тергезәсең, моның мисалын җир өстендә күрсәтсәңче», — диде. Аллаһы Тәгалә әйтте: «И, Ибраһим! Әллә Миңа ышанмыйсыңмы?» — диде. Ибраһим әйтте: «Үлекне тергезүеңә инанамын, ләкин күңелем ышанып җитми», — диде. Җәнабел Хак, нинди генә кодрәт иясе булмасын, Ибраһим галәйһиссәламнең эчкерсез әйтелгән бу сүзләрен кабул кылды вә әйтте: «И, Ибраһим, тот син үзең теләгән дүрт кошны, аларны суеп, итләрен бер-берсенә катнаштыр, соңыннан каршыңда торган тауларга шул кошлардан берәр кисәк бүлеп илтеп куй. Моның соңында: «Аллаһы Тәгаләнең азаны (чакыруы) илә килегез!» — дип әйт, әлбәттә, алар йөгереп килерләр синең яныңа», — диде. Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгалә әйткәнчә эш кылды һәм кошлар, терелеп, Ибраһим галәйһиссәлам*

*янына йөгереп килделәр. Шуны бел, Аллаһы Тәгалә — бөтен эштә җиңүче һәм хикмәт белән эш кылучы (260)».*

Ибраһим галәйһиссәлам адәм балаларына якын булган дүрт кошны тотып бугазлады, болар: карга, әтәч, күгәрчен вә тавык иделәр. Ул ошбу дүрт кошның итләрен кушып, бутап, дүрт кисәккә бүлде. Йоннарын йолкып, дүрт кисәк итне дүрт тауга илтеп куйды. Башларын үзе белән алды, уртадагы бер тигез җиргә барып басты вә: «Әй, кошлар, Аллаһы Тәгаләнең азаны илә минем яныма килегез!» — дип әйтте. Хак Тәгаләнең әмере илә дәрхаль бу кошлар, терелеп, Ибраһим галәйһиссәлам янына килделәр. Ибраһим галәйһиссәлам аларның башларын үз урыннарына куйды. Башлары урыннарына урнашкач, алар телгә килеп: «Ләә иләәһә илләллааһ Ибраһим Хәлиуллаһ!» — дип зикер әйттеләр. Шушы могҗизадан соң Ибраһим галәйһиссәлам Җәнабел Хакның кодрәтенә тагы да ныграк ышанып, тәүбә итеп дога кылды, күңелендә шик вә шөбһәсе калмады.

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламгә вә аның балаларына бик күп изгелекләр эшләде. Ибраһим галәйһиссәлам ике йөз ел гомер кичерде. Гомере ахырына якынлашты исә, аның янына Аллаһы Тәгаләнең әмере илә Газраил галәйһиссәлам килде вә әйтте: «Әгәр рөхсәт итсәң, җаныңны алырга килдем», — диде. Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Миңа Хак Тәгаләнең әмере булмады әле», — диде. Газраил галәйһиссәлам: «И, Ибраһим, сакалыңның агаруы кайчан башланды? — дип сорады. Ибраһим әйтте: «Ике ел булды инде». Газраил галәйһиссәлам әйтте: «И, Ибраһим, сакалның аклыгы ул үлемнең якынлыгы хәбәре, кем инде Аллаһы Тәгаләнең җәннәт бакчасына керүне сузарга теләр икән?» — диде. Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «И, Газраил! Тиз кил, җанымны ал», — диде. Газраил галәйһиссәлам аның җанын мөбарәк тәненнән җиңеллек белән алды. Углы Исхак галәйһиссәлам ошбу мөбарәк гәүдәне юып, кәфенләп, җеназасын укып, Сара радыйаллаһу ганһә янына җирләде.

Ибраһим галәйһиссәлам вафатыннан соң Шам Шәриф, Кинган, Хуран җирләрендә Исхак галәйһиссәлам пәйгамбәрлек кылды. Исхак галәйһиссәламнең Гайсу исемле углы Исмәгыйль галәйһиссәламнең кызын никахлап алды һәм Рум (Византия) иленә барып урнашты. Аларның бик күп балалары булды. Ул бу илдә падишаһ булды. Әтисе Исхак галәйһиссә-

лам кебек, Гайсуның да халыкларга бик тәэсирле итеп вәгазь сөйләү куәте бар иде. Ул биредәге халыкларны бер Аллаһыга гыйбадәт кылырга өндәде. Соңгы елларда румиларда тәэсирле итеп вәгазь сөйләүнең күркәм бер фән булып, гаять дәрәҗәдә алга китүе мәгълүм. Гайсу радыйаллаһу ганһе башлап җибәргән хитабәтчелек бүгенге көндә мөстәкыйль фән рәвешендә укытыла.

Исхак галәйһиссәламнең икенче углы Ягъкубка Аллаһы Тәгаләдән пәйгамбәрлек иңдерелде. Ягъкуб галәйһиссәлам вәгазьләгән кавемне бәни Исраил дип атадылар. Коръән Кәримнең бу кавемгә багышланган өлеше «бәни Исраил» сүрәсе дип атала.

Ибраһим галәйһиссәламнең вафатыннан соң кырык бер ел үткәч, Исмәгыйль галәйһиссәлам гомеренең ахырына якынлашуын белеп, туганы Исхак галәйһиссәламне Мәккә шәһәренә чакырды. Бу вакытта Исмәгыйль галәйһиссәламгә 130 яшь иде. Исмәгыйль галәйһиссәламнең вафатыннан соң аның мәетен юып, кәфенләп, җеназасын укып, әнисе Һаҗәр янына дәфен кылганнан соң, Исхак галәйһиссәлам Шам Шәрифкә, үз өенә кайтып китте. Анда кайткач үлем турында үз кавеменә вәгазь-нәсыйхәт сөйләде: «Барча ләззәтләрне кисә торган үлемне күп зикер итегез! Үлемне онытмау вә һәрдаим искә төшерү сәбәпле, дөньялары иркен вә бай кешеләрнең горурлыгы бетәр вә инсафка кайтырлар. Үлемнең кисәктән вә көтмәгәндә, хәтта йоклап ятканда да килүе мөмкин, бәлки бу хәл күбрәктер дә әле. Шуның өчен аны һәркайчан зикер итү, хыялда вә хәтердә тоту, онытмауга вә кулдан килгән кадәр хәзерләнүгә сәбәп булыр. Үлемгә хәзерләнү Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәп, бозык эшләрдән тыелу, адәмнәрне рәнҗетмәү, үткәндәге кимчелекләр өчен үкенү, иманлы кешеләргә мөмкин булган кадәр файда китерүдән гыйбарәттер. Хәләл мал белән кәсеп итеп, гаиләңне тәрбиялә. Бу эшләр дә үлемгә хәзерләнүгә кирә», — дип, катрә-катрә күз яшьләре илә ошбу вәгазьне сөйләде.

Исхак галәйһиссәлам Исмәгыйль галәйһиссәламнән соң унөченче елда, 130 яшендә ошбу җиһаннан мәңгелек ахирәт дөньясына күчте. Ягъкуб галәйһиссәлам әтисенең мәетен юып, кәфенләп, җеназасын укып, Ибраһим галәйһиссәлам кабере белән янәшә дәфен кылды.

# ЯГЪКУБ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Ягъкуб пәйгамбәрнең атасы Исхак галәйһиссәлам, аның атасы Ибраһим галәйһиссәлам иде. Риваятьләргә караганда, Исхак пәйгамбәрнең Гайсу белән Ягъкуб исемле углы игезәкләр иде. Ягъкубның мәгънәсе сәрьян телендә бер-бер артлы туучы игезәкләр дигәнне аңлата.

Ягъкуб галәйһиссәламнең ләкабе, ягъни кушаматы «Исраил» иде. «Исраил» сәрьянча «Габдулла», ягъни Аллаһы Тәгаләнең колы дигәнне аңлата.

Хәзрәти Исхак галәйһиссәлам вафатыннан соң Кинган өлкәсендә аның углы хәзрәти Ягъкуб пәйгамбәр булды. Коръән Кәримнең «Мәрьям» сүрәсе, 49 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فلما اعتزلهم وما يعبدون من دون الله وهبنا
له إسحق ويعقوب وكلا جعلنا نبيا ﴿٤٩﴾

«Фәләммәг-тәзәләһүм үә мәә йәгбүдүүнә миң дүниллләәһи үә һәбнәә ләһүү Исхәәка үә Йәгкууб. Үә күллә җәгәлнәә нәбиййә (49)».

М ә г ъ н ә с е : *«Ибраһим галәйһиссәлам мөшрикләрдән вә Аллаһы Тәгаләдән башка ай, йолдыз, кояш вә потларга табынган кавемнән аерылып киткәч, Без аңа Исхакны вә аның углы Ягъкубны бирдек, вә барын да пәйгамбәр кылдык (49)».*

Хәзрәти Ягъкубның Ләбән (Ливан) якларында анасы белән бертуган кардәше яши иде. Аның бик матур, бик акыллы ике кызы бар иде. Олысы Лийә исемле, кечесе Рәхилә. Хәзрәти Ягъкуб әнисенең карендәшенә кунакка барган җирендә бу кызларның кечесе Рәхиләне бик ошатты вә бу турыда кызның әтисенә белгертте. Кызның әтисе үзенең җавабында болай диде: «Әгәр дә алты ел миндә хезмәт итсәң, Рәхиләне сиңа бирермен», — дип вәгъдә бирде. Хәзрәти Ягъкуб аның белән килеште, алты ел бирелә хезмәт итте. Ләкин шулай да кызның атасы: «Олы кызым барында, кече кызымны бирә ал-

мыйм», — дип, олы кызы Лийәне никахлап аңа бирде. Хәзрәти Ягъкуб, янә алты ел хезмәт итеп, Рәхиләне дә никахлап алды. Гаиләсен алып, үзе яшәгән Кинган шәһәренә кайтып китте.

Лийә белән булган никахтан алты бала, Лийәнең җариясе Зөлфәдән ике бала, Рәхиләдән ике бала, Рәхиләнең җариясе Бәлһәдән ике бала туды. Барысы унике баласы дөньяга килде. Кинган җирләрендә яшәүче халык хәзрәти Ягъкубны вә аның балаларын бик хөрмәт иттеләр. Коръәндә әйтелгәнчә, аларның бәгъзесенә пәйгамбәрлек килде. Хәзрәти Гайсә галәйһиссәламгә кадәр пәйгамбәрлек алар кулында гына булды. Шул сәбәпле, хәзрәти Ягъкубтан башлап хәзрәти Гайсәгә кадәр булган заман бәни Исраил заманы дип аталды. Ягъни, Исраил балаларының заманы дигән сүз, Ягъкуб балалары дигәнне аңлата. Шул арадагы пәйгамбәрләрне дә бәни Исраил пәйгамбәрләре диярләр. Бәс, Ягъкуб галәйһиссәлам бәни Исраилнең атасы булды. Алдагы җөмләләрдә әйткән идек инде, Коръән Кәримнең унҗиденче сүрәсенең иseme дә «Бәни Исраил» дип атала. Ибраһим галәйһиссәлам һәм Исхак галәйһиссәлам вә дәхи аның углы Ягъкуб галәйһиссәлам дә үз кавемнәрен Ислам диненә өндәделәр. «Әл-Бәкара» сүрәсенең 132–133 нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

ووصى بها ابرهم بنيه ويعقوب يبنى ان الله اصطفى لكم الدين فلاتموتن الا
وانتم مسلمون ❀ ١٣٢ ام كنتم شهداء اذ حضر يعقوب الموت اذ قال لبنيه ماتعبدون من بعدى
قالوا نعبد الهك واله اباىك ابرهم واسمعيل واسحق الها واحدا ونحن له مسلمون ❀ ١٣٣

«Үә үәссаа биһәә Ибрааһиимү бәнииһи үә Йәгкууб. Йәә бәниййә иннәллааһәс-тафәә ләкүмүд-диинә фәләә тәмүүтүннә илләә үә әңтүм мүслимүүн (132). Әм күңтүм шүһәдәә-ә из хәдара Йәгкуубәл-мәүтү из каалә либәәнииһи мәә тәгбүдүнә мим-бәгди. Каалүү нәгбүдү иләәһәкә үә иләәһә әәбәәикә Ибрааһиимә үә Исмәәгиилә үә Исхәәка иләәһәү-үәәһидә. Үә нәхнү ләһү мүслимүүн (133)».

Мәгънәсе: *«Ибраһим галәйһиссәлам угылларына васыять әйтте һәм әмер бирде: «И, угылларым, Аллаһы Тәгалә сезгә Ислам динен насыйп итте, шуңа күрә, бары тик мөсел-*

*ман булып яшәгез һәм мөселман булып үлегез! Динегез була торып, кяфер булмагыз!» Ягъкуб галәйһиссәлам дә угылларына шул ук сүзләрне әйтте. Яһүдләр исә: «Ягъкуб безгә, яһүдлекне ташламагыз, дип әйтте», — диделәр (132). И, яһүдләр! Ягъкуб галәйһиссәлам җан биргәндә сез аның янында идегезме? Ягъкуб галәйһиссәлам үләр алдыннан улларыннан: «Мин үлгәннән соң нәрсәгә гыйбадәт кылырсыз?» — дип сорады. Угыллары әйтте: «Син үлгәч, синең ата-бабаларың Ибраһим, Исмәгыйль, Исхакларның Илаһысына гыйбадәт кылырбыз. Ул Аллаһының тиңдәше юк, Ул — бер генә Илаһыдыр. Без Аңа гына буйсынучы мөселманнарбыз (133)».*

Риваятьләрдә сөйләнә: Ягъкуб галәйһиссәлам намаз гыйбадәтен үтәгәндә Иблис мәлгунь килеп ул яндырып куйган утны сүндерә. Мондый хәл берничә мәртәбә кабатлана. Бер кичне Ягъкуб галәйһиссәлам саклап торып, Иблисне тотып әсир итте. Иблисне дә әсир итә алгач, Ягъкуб галәйһиссәламнең күңелендә тәкәбберлек хисе уянды, ул: «Миннән дә көчлерәк адәм бармы икән?» — дип, як-ягына карады. Моны белеп, Хак Сөбханә вә Тәгалә бер фәрештәне адәм сурәтенә кертеп, угры кыяфәтле кылып, сахрада куйлар, дөяләр саклаучы Ягъкуб галәйһиссәлам янына җибәрде. Ягъкуб галәйһиссәлам бу вакытта йоклаган иде. Уянып китсә, ул үзе саклый торган хайваннар арасында бер шикле кешене күрде. Аны угры дип белеп: «Минем дөяләрем вә куйларым янына ник килдең?» — дип, аны тотып алды. Алар үзара таң атканчы низаглаштылар, ахырда фәрештә Ягъкуб галәйһиссәламне күтәреп җиргә салды. Шушы вакыйгадан соң Ягъкуб галәйһиссәламнең бот төбе авырту булып калды. Бу авырудан гаҗизләнеп, Хак Тәгаләгә ялварып, ул болай диде: «И, Раббым! Бу авыруны миннән алсаң, үземә сөекле булган тәгамнән баш тартыр идем», — дип, үзе яраткан дөя сөтеннән баш тартты. «Әл-Гыйммран» сүрәсенең 93 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

كُلُّ الطَّعَامِ كَانَ حِلًّا لِبَنِىٓ اِسْرَآئِلَ اِلَّا مَا حَرَّمَ اِسْرَآئِلُ عَلٰى نَفْسِهٖ مِنْ قَبْلِ اَنْ تُنَزَّلَ التَّوْرٰيةُ
قُلْ فَاْتُوا بِالتَّوْرٰيةِ فَاتْلُوهَآ اِنْ كُنْتُمْ صٰدِقِينَ ﴿٩٣﴾

«Күллүт-тагәәми кәәнә хилләллибәнии Исрааиилә илләә мәә хәррамә Исрааиилү гәләә нәфсиһии миң кабли әң түнәззәләт-Таураат. Куль фәәтүү бит-Тәүраати фәтлүүһәә иң күңтүм саадикыйн (93)».

Мәгънәсе: *«Ягъкуб балаларына барча ризык хәләл булып, мәгәр Тәүрат иңмәс борын үзләре хәрам кылган нәрсәләр хәрам түгел иде. Ягъкуб пәйгамбәр: «Ошбу сырхаулыктан сәламәтләнсәм, дөя итен вә сөтен үземә хәрам кылыр идем», — дип нәзер әйткән иде, сәламәтләнгәч, дөя итен ашамас һәм сөтен эчмәс булды. Аңа карап, балалары да үзләренә бу ризыкларны хәрам кылдылар. Яһүдләр, бу хөкем Тәүратта бар дип, Мөхәммәд галәйһиссәлам белән бәхәсләштеләр. Син аларга Тәүратны алып килегез, ул хөкемне карыйк диген! Яһүдләр хәйран булдылар, чөнки ул хөкем Тәүратта юк (93)».*

Ягъкуб галәйһиссәлам үз кавеменә иман китерергә, шайтанга баш ормаска, чынлыкта шайтанның чын дошман булуы хакында сөйләде: «Шайтанның безгә дошман икәнен белдергәне кебек, Аллаһы Тәгалә аннан котылу юлларын да белгертә. Маңгай күзләребез белән күргән дошманнарыбыз дөньядагы гомеребезне бетерергә ничек тырышса, шайтан да дөньядагы вә ахирәттәге тормышыбызны пыран-заран китерергә омтыла. Чыннан да, шайтанның адәм баласына кагылышы бар, шулай ук Аллаһы Тәгалә фәрештәләренең дә кешегә кагылышы бар. Шайтанның кагылуы начарлыкка илтә, хакны ялганга чыгара. Фәрештәнең кагылышы исә хәерле эшкә өнди вә хакны раслый. Моны тойган, сизгән һәр кеше белсен ки, бусы Аллаһы Тәгаләдән. Кичекмәстән Хак Тәгаләне хөрмәтләсен, башкага дучар булган кеше исә шайтаннан качып Аллаһы Тәгаләгә сыенсын.

Кардәшләрем! Минем бу сүзләремнән күренәдер ки, кемнәр шайтанга дус, кемнәр аңа дошман. Шулай булгач, һәркем үзен шулай тикшереп торса, шайтанга дусмы, дошманмы икәнен үзеннән-үзе аңлаячак. Аллаһы Тәгалә беребезне дә тугры юлдан аермасын. Ул безне кабилә-кабилә, милләт-милләт итеп бер ир белән бер хатыннан яратты. Берберебезгә гадел, яхшы мөнәсәбәттә, иманлы булыйк. Ошбу хак диндә булуына Ягъкуб галәйһиссәлам вә аның сөекле углы

Йосыф галәйһиссәлам дә шөкрана кылдылар. «Йосыф» сүрәсенең 38 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَاتَّبَعْتُ مِلَّةَ آبَاءِيٓ إِبْرَٰهِيمَ وَإِسْحَٰقَ وَيَعْقُوبَ ۚ مَا كَانَ لَنَآ أَن نُّشْرِكَ بِاللَّهِ مِن شَىْءٍ ۚ

ذَٰلِكَ مِن فَضْلِ اللَّهِ عَلَيْنَا وَعَلَى النَّاسِ وَلَٰكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَشْكُرُونَ ٣٨

«Үәттәбәгтү милләтә әәбәәии Ибрааһиимә үә Исхәәка үә Йәгкууб. Мәә кәәнә ләнәә ән-нүшрикә билләәһи миң шәй-ин. Зәәликә миң фәдълиләәһи гәләйнәә үә гәләннәәси үә ләәкиннә әксәраннәәси ләә йәшкүруун (38)».

Мәгънәсе: *«Йосыф әйтте: «Мин кердем ата-бабаларым Ибраһим, Исхак, вә Ягъкублар диненә, Аллаһы Тәгаләгә берәр мәхлукны тиңдәш итү безнең өчен һич тә дөрес вә лаек эш түгел. Ошбу хак диндә булуыбыз безгә вә башка кешеләргә Хак Тәгаләнең юмартлыгы вә рәхмәте, ләкин күп кешеләр моны зур нигъмәт дип белмиләр вә Аллаһы Тәгаләгә шөкер итмиләр (38)».*

Ягъкуб галәйһиссәламгә 140 яшь тулгач, хәзрәти Адәмнән соң 3804 ел, Нух галәйһиссәлам вакытындагы туфаннан соң 1408 ел үткәч, ул вафат булды. Кинган өлкәсендәге Хәлил әр-Рахмән дигән җирдә әтисе Исхак галәйһиссәлам кабере янында җирләнде.

# ЙОСЫФ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Борынгы Кинган сахрасында яшәүче Ягъкуб пәйгамбәрнең ике хатыны вә унике углы бар иде. Аларның өлкәннәре инде буй җиткән, өйләнгән. Әмма алар һаман бергә яшиләр, уртак хуҗалык алып баралар иде. Ун өлкән углы далада шушы кавемнең көтүен көтәләр. Ягъкуб галәйһиссәламнең сөекле хатыны Рәхилә иртә үлеп киткәч, яшьли ятим калган Йосыф илә Биниәмин этиләре янында тора. Ягъкуб галәйһиссәлам иң кече углы Йосыфны барчасыннан артык сөя иде. Йосыф бик гүзәл, сөйкемле, зирәк, нечкә күңелле бала иде.

Коръән Кәримнең 12 сүрәсе тулысы белән дип әйтерлек Ягъкуб углы Йосыфка багышланган. Моннан башка «әл-Әнгам» сүрәсенең 84 нче вә «Әл-Гафир» сүрәсенең 34 нче аятьләрендә дә аның исеме телгә алына.

Йосыф беркөнне хикмәтле төш күрә, уянгач, моңа гаҗәпләнеп, этисеннән әлеге төшен тәгъбир кылуын, ягъни юравын сорый. Бу хакта Коръән Кәримнең «Йосыф» сүрәсе, 4 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

إذ قال يوسف لابيه يا ابت انى رايت احد عشر
كوكبا والشمس والقمر رايتهم لى سجدين ﴿٤﴾

«Из каалә Йүүсүфү ли әбииһи йәә әбәти инниии раәйтү әхәдә гәшәра кәүкәбән үәш-шәмсә үәл камәра раәйтүһүм лии сәәҗидиин (4)».

М ә г ъ н ә с е : *«Йосыф атасына әйтте: «И, атам, мин төшемдә күрдем: унбер йолдыз һәм ай белән кояш көлеп миңа сәҗдә кылдылар (4)».*

Атасы әйтте: «И, углым, син төшеңне агаларыңа сөйләмә! Әгәр аларга сөйләсәң, хөсетләнеп, сине һәлак итәр өчен хәйлә корырлар, чөнки шайтан адәмнәргә ачык дошман, агаларыңны хәйләгә котыртыр. Хак Тәгалә сиңа яхшы төш күрсәткән,

сине Үзенең пәйгамбәре итеп сайлыйдыр вә сиңа тәгъбирне, ягъни төш юрауны өйрәтәдер, сиңа вә минем башка балаларыма нигъмәтне мул итеп бирер, моннан элек яшәгән бабаларың Исхак белән Ибраһимга биргән кеби. Әлбәттә, Җәнабел Хак кемгә нәрсә, күпме бирергә икәнлеген тик Үзе генә белүче вә кирәгенчә эш кылучы».

Ата белән угылның бу сөйләшүен олы угылларының берсе тыңлап тора вә башка туганнарына ирештерә. Күңелләрендә көнчелек уты кабынган агалары, шайтан вәсвәсәсе белән, Йосыфтан үч алу ниятенә керешәләр. Өстәвенә, алар Йосыфның төшендә хәйлә-мәкер галәмәте дә күрәләр. Алар җыелышып сөйләштеләр, бәгъзеләре әйтте: «Йосыфны берәр хәйлә илән сахрага алып чыгып үтерик яки билгесез, моннан бик ерак җиргә илтеп ташлыйк», — диделәр. Араларыннан берсе әйтте:«Йосыфны үтереп гөнаһка батарбыз, аны кое төбенә салыйк, бәгъзе мосафирлар аны табып алырлар да моннан ерак җирләргә алып китәрләр, ә без, тәүбә итеп, Хак Тәгалә каршында яхшы бәндәләрдән булырбыз, атабыз безгә дә кадер-хөрмәт кылыр». Бу киңәшкә бар да риза булып, Йосыфны сорарга аталары янына килеп: «Әй, атабыз, иртәгә син Йосыфны безнең белән сахрага җибәрсәң иде, ул безнең белән уйнар, рәхәтләнеп сахра һавасын сулар, хозурланып кайтыр иде, борчылма, без аны үзебездән бер адым да читкә җибәрмәбез», — дип, кайнар вәгъдәләр бирделәр. Ниһаять, ата күңеле түзмәде, сөекле углын сәйранга җибәрергә риза булды. Иртән ул үз кулы белән Йосыфның чәчен тарап үрде, ашаттыэчертте, яхшы киемнәр кидереп, сөекле баласын агалары кулына тапшырды. Агалары Йосыфны бик кадерләп, иңнәренә күтәреп алып киттеләр. Ягъкуб галәйһиссәлам юл өстендә елап озатып калды. Сахрага чыгу белән Йосыфны төрлечә җәберли башладылар, хәлдән тайганчы җәберләгәч, аны кое янына сөйрәп китерделәр, күлмәген салдырып, коега ташладылар. Кое төбендәге ташларга бәрелеп имгәнмәсен өчен, Җәбраил фәрештә, канатын җәеп, аны акрын гына таш өстенә төшереп куя вә кое төбен елан, чаяннардан арындыра. Шул вакыт Аллаһы Тәгалә Җәбраил галәйһиссәлам аркылы Йосыф галәйһиссәламгә вәхи җибәрә. «Йосыф» сүрәсенең 15 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فلما ذهبوا به واجمعوا ان يجعلوه في غيبت الجب

واوحينا اليه لتنبئنهم بامرهم هذا وهم لا يشعرون ۝ ١٥

«Фәләммәә зәһәбүү биһии үә әҗмәгүү әй-йәҗгәлүһү фии гайәәбәтил-җүббе. Үә әухәйнәә иләйһи ләтүнәббиәннәһүм биәмриһим һәәзәә үә һүм ләә йәшгүрүүн (15)».

Мәгънәсе: *«Аны алып китеп, кое төбенә салырга карар кылганнан соң, Без Йосыфка вәхи кылдык: «Бу җәфалардан, әлбәттә, беркөнне котылырсың вә синә кылган явызлыкларын үзләренә сөйләрсең», — дип, ләкин агалары Йосыфка вәхи кылганыбызны сизмәделәр вә белмәделәр (15)».*

Йосыфның агалары кич җитү белән, чырайларына елаган кыяфәт ясап, аталары янына кайттылар. Әтиләренә әйттеләр: «Әй, атабыз, без үзара узыша идек, шул вакытта Йосыфны әйберләребез янында калдырдык. Кире әйләнеп килсәк, Йосыфны бүре ашаган. Безнең сүзебезгә ышанмасагыз, менә аның канлы күлмәге», — дип, ялган канга буялган күлмәкне китереп каршына куйдылар. Канлы күлмәкне күргәч, мескен ата һуштан язып егылды.

Йосыф галәйһиссәлам, өч көн коеда торганнан соң, юлда туктаган кәрванчыларның су алырга дип төшергән чиләгенә ябышып чыкты. Әмма ерак түгел генә көтү көткән туганнары килеп: «Ул безнең качкан колыбыз», — дип, аны кәрван хуҗасы Мәлик Дәгыйргә арзан гына бәягә сатып җибәрделәр. Ошбу кәрван белән Йосыф Мисырга барып җитте. Мисырда аны патшаның хәзинәчесе Газизгә бик зур бәһагә сатып җибәрделәр. Сарайга кайткач, Газиз үзенең хатыны Зөләйхага әйтте:«Йә, Зөләйха, бу егетне үзебезгә сатып алдым, син аңар яхшы урын әзерлә, ул безнең углыбыз булыр», — диде.

Мәгъриб иле хөкемдары Тәймусның бердәнбер сөекле кызы чибәр Зөләйха, әле үсмер кыз чагында ук, Йосыфны төшендә күреп, аңар гашыйк иде, зур бәһагә Газиз сатып алып кайткан гүзәл егетнең аның төшенә кергән, үзенә гашыйк иткән кол егет икәнен танып, Зөләйха һушын җуйды.

Зөләйха бик сөенде, Хак Тәгаләгә шөкрана кылды, бу кол егетне үз тәрбиясенә алды, аның әүвәлге мәхәббәт хисләре

яңадан уянды, ягъни гыйшык уты тагын да көчлерәк дөрләп яна башлады. Бу көчле хистән Зөләйха саташу дәрәҗәсенә җитте. Йосыф исә Зөләйхага бары ихтирам гына саклый, шуңа күрә аның нәфесе теләгәнне үтәүдән баш тарта. Зөләйха әйтә: «Әгәр мин әмер кылганны эшләмәсәң, ягъни якынлык кылмасаң, мин сине зинданга салдырырмын, хурлыкка төшкән бәндәләрдән булырсың». «Йосыф» сүрәсенең 33–34 нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

قَالَ رَبِّ السِّجْنُ أَحَبُّ إِلَىَّ مِمَّا يَدْعُونَنِى إِلَيْهِ وَإِلَّا تَصْرِفْ عَنِّى كَيْدَهُنَّ أَصْبُ إِلَيْهِنَّ
وَأَكُن مِّنَ الْجَٰهِلِينَ ﴿٣٣﴾ فَاسْتَجَابَ لَهُ رَبُّهُ فَصَرَفَ عَنْهُ كَيْدَهُنَّ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ ﴿٣٤﴾

«Каалә Раббис-сиҗнү әхәббү иләййә миммәә йәдегүүнәнии иләйһи үә илләә тәсъриф гәннии кәйдә һүннә әсъбү иләйһиннә үәкүм-минәл җәәһиилин (33). Фәстәҗәәбә ләһү раббүһүү фәсарафә гәнһү кәйдә һүннә, иннәһү һүәс-сәмиигүлгәлиим (34)».

Мәгънәсе: *«И, Раббым! Мине чакырган зинага караганда зиндан яхшырак, әгәр бу хатыннарның хәйләләреннән мине коткармасаң, мин аларга ияручe җаһилләрдән булырмын» (33). Йосыфның догасын Раббысы кабул әйләде вә Йосыфны ул хатыннарның хәйләләреннән имин кылды, дөреслектә, Ул —сүзләрне ишетүче вә хәлләрне белүче (34)».*

Зинданга аның белән бергә ике егет тә керде. Берсе — хәмер ясаучы, икенчесе — икмәкче иде. Алар төш күрделәр. Аларның берсе әйтте: «Мин төшемдә хәмер сыкканымны күрдем». Икенчесе әйтте: «Мин төшемдә икмәк күтәреп йөргәнемне күрдем, ул күтәргән икмәгемне кошлар ашый, имеш. И, Йосыф, ул төшнең тәгъбире ничек, безгә сөйләп бирче? Без сине яхшы кеше дип беләбез».

Йосыф әйтте:«Төшегезне юраганчы мин сезгә иман кәлимәләрен өйрәтергә тиешмен:«Әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһ», ягъни «чын күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, тәхкыйк, бер Аллаһы Тәгаләдән башка һич тәңре юктыр». Алар иман кәлимәләрен кабатладылар, ягъни иман китерделәр. Шуннан соң Йосыф әйтте: «И, зиндандагы ике иптәшем, инде төшегезгә тәгъбир кылам: берегез моннан чыгып әүвәлге урынын-

да хәмер ясаучы булыр, ә икенчегезне асып куярлар вә аның башын кошлар ашарлар, эш мин тәгъбир кылганча булыр, чөнки төш юрауны миңа Раббым Хак Тәгалә өйрәтте», — диде.

Йосыф әйткәнчә, икмәкчене — асалар, хәмерче исә үз урынында эшли башлый. Хәмерчегә Йосыф әйтә: «Зинданнан чыккач, патшага минем нахакка утыруымны сөйлә, мине чыгарсын». Ләкин шайтан мәлгунь егеткә оныттыра, янә Йосыф галәйһиссәлам ничә еллар буе зинданда кала.

Мисыр падишаһы төннәрнең берендә серле төш күрде: имеш ул елга ярында утыра, ә аннан җиде симез сыер вә алар артыннан җиде арык сыер чыга. Аннары җиде симез сыерны җиде арык сыер ашый. Падишаһ бик куркып уяна. Бераз тынычлангач, ул янә йокыга китә вә төшендә җиде яшел башак, җиде корыган башак күрә. Корыган башаклар яшел башакларны ашап бетерә. Бик каты куркып, падишаһ икенче тапкыр уяна.

Иртә белән падишаһ барча сарай әһелләрен җыя вә төшендә күргәннәрен сөйли. Әмма берәү дә аның бу хикмәтле төшен юрый алмый. Шулчак шәрабчы төшләрне бик дөрес юраучы Йосыф турында исенә төшерә. Падишаһ аны зинданга Йосыф галәйһиссәлам янына җибәрә. Төшне сөйләгәч, Йосыф әйтә: «Җиде ел тоташтан иген чәчегез, җиде елда уңыш яхшы булыр, алган уңышны сукмыйча башагы вә саламы белән кибәндә саклагыз, үзегезгә ашарга җитәрлек кенә сугарсыз. Моннан соң җиде ел ачлык килер, җиде елда җыйган игеннәрегез җиде ачлык елларында ашалып бетәр, мәгәр орлык өчен саклаган игеннәрегез калыр. Ачлык еллардан соң бер ел килер, ул елда яңгырлар явар, игеннәр вә җимешләр үсәр һәр җәһәттән иркенлек булыр».

Падишаһ, бу сүзләрне ишеткәч, гаҗәпкә калды вә Аллаһының рәхмәте белән әйтте: «Китерегез миңа ул Йосыфны, мин аны игенчелек эшләренә хуҗа итеп куям», — диде.

Йосыф галәйһиссәлам Хак Тәгаләнең аңа өйрәткән төш юрау белеме ярдәме белән зинданнан котылды. «Йосыф» сүрәсенең 101 нче аятендә Хак Тәгалә әйтә:

رَبِّ قَدْ اٰتَيْتَنِى مِنَ الْمُلْكِ وَعَلَّمْتَنِى مِنْ تَاْوِيلِ الْاَحَادِيثِۚ فَاطِرَ السَّمٰوٰتِ وَالْاَرْضِ

اَنْتَ وَلِيّٖ فِى الدُّنْيَا وَالْاٰخِرَةِۚ تَوَفَّنِى مُسْلِمًا وَاَلْحِقْنِى بِالصَّالِحِينَ ۝١٠١

«Рабби каде әәтәйтәнии минәл-мулки үә гәлләмтәнии миң тәәүиилил-әхәәдиис. Фәәтыйрас-сәмәәүәәти үәл әрдый әңтә үәлиййи фид-дүнйәә үәл әәхыйрати, тәүәффәнии мүслимәү-үә әлхикъниии биссаалихиин (101)».

Мәгънәсе: *«И, Раббым! Син миңа Үзеңнең мөлкәтеңнән Мисыр байлыгын бирдең вә дәхи төшләр юрау могҗизасын өйрәттең. И, Раббым, Син күкләрне вә җирне яратучы, дөнья вә ахирәттә Син миңа ярдәмчесең, йә, Рабби, мөселман хәлемдә җанымны ал, вә мине изге бәндәләр илә бергә кыл! (101)».*

Муллыкта яшәү еллары узып, ачлык еллары башлангач, Йосыфның агалары Кинган шәһәреннән Мисырга ашлык алырга килделәр, ашлык сорар өчен Йосыф галәйһиссәлам янына керделәр. Йосыф галәйһиссәлам аларны таныды, агалары исә аны танымадылар. Йосыф алардан сорашты: «Сез ничә кардәш, кем балалары, атагыз ни хәлдә?» Алар җавап бирде: «Без Ибраһим галәйһиссәлам нәселеннән Ягъкуб пәйгамбәр балаларыбыз, барчабыз унике идек, Йосыф исемле кече кардәшебезне бүре ашады, Биниәмин исемле кече кардәшебез атабыз янында калды, без монда унау килдек».

Йосыф галәйһиссәлам аларның һәрберсенә берәр дөя йөге ашлык биргәч, әйтте: «Атагыз янында калган кече кардәшегезне алып килерсез, әгәр дә ул кардәшегезне алып килмәсәгез, миндә сезнең өчен ашлык булмас».

Кайткач аталарына әйттеләр:«И, атабыз, ашлык хуҗасы кече кардәшегез Биниәминне алып килмәсәгез, сезгә ашлык бирмим диде. Биниәминне безнең белән җибәр, аны сакларбыз, ашлык та алып кайтырбыз».

Аталары әйтте: «Безнең сөйләшкәнне Аллаһы Тәгалә ишетүче вә белүчедер, Аның исеме белән ант итеп вәгъдә бирми торып, Биниәминне сезнең белән җибәрмим». Угыллары ант иттеләр.

Туганнар исән-имин Мисырга барып җиттеләр. Бар да җыелып, Йосыф галәйһиссәлам янына керделәр. Йосыф галәйһиссәлам агаларын сыйларга алты савыт аш китертте.

Һәр савыттан икешәр-икешәр ашыйсыз диде, һәм агалары һәр савыттан икешәрләп ашый башладылар, Биниәмин исә бер савытка берүзе калды. Йосыф галәйһиссәлам: «Без си-

нең белән кардәш булырбыз, әйдә бергә ашыйк», — дип, аны пәрдә артына алып керде һәм икесе бер савыттан ашадылар. Биниәмингә үзен таныттты: «Мин синең кардәшең Йосыфмын, Аллаһы Тәгалә мине ташламады», — диде, янә әйтте: «И, кардәшем Биниәмин, сине алып калыр өчен бер хәйлә уйладым, бер бәһале савытны синең йөгеңә яшереп куярбыз да аннары «савыт югалды» дип игълан итәрбез, тентегәндә савыт синең йөгеңнән чыгар, сине карак исеме белән кол итеп алып калырбыз». Бу хәйләгә Биниәмин дә риза булды. Шулай эшләделәр дә. Биниәмин, карак исемен күтәреп, Йосыф галәйһиссәлам кулында калды.

Аталары янына кайткач, әйттеләр: «И, атабыз, углың Биниәмин бер зур бәһале савыт урлады, без фәкать белгәнебез вә күргәнебез белән шаһәдәт бирәбез, ягъни аның йөгеннән бер алтын савыт чыкты, шуның өчен аны кол итеп алып калдылар». Аталары бу сүзләргә ышанмады: «Юк, сез дөрес сөйләмисез, нәфесегез бер яман эшне яхшы итеп күрсәткәндер, ә сез ул эшне Биниәмингә япкансыз. Моннан элек Йосыф хакында ышандым, ә сез нәрсә эшләдегез? Инде миңа Рабым Аллаһ сабырлык бирер, ике углымны да кире кайтарыр дип өмет итеп калам. Һичшиксез, Аллаһы Тәгалә аларның кайда икәнен белә вә гадел хөкем итә. Мисырга барып, Йосыф вә Биниәмин турында белегез, өметегезне өзмәгез», — диде. «Йосыф» сүрәсенең 87 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

يَٰبَنِيَّ ٱذْهَبُوا۟ فَتَحَسَّسُوا۟ مِن يُوسُفَ وَأَخِيهِ وَلَا تَا۟يْـَٔسُوا۟ مِن رَّوْحِ ٱللَّهِ ۖ إِنَّهُۥ لَا يَا۟يْـَٔسُ مِن رَّوْحِ ٱللَّهِ إِلَّا ٱلْقَوْمُ ٱلْكَٰفِرُونَ ﴿٨٧﴾

«Йәәбәний-йәзһәбүү фәтәхәссәсүү мий-йүүсүфә үә әхыййһи үәләә тәйәсүү мирраухил-ләәһ. Иннәһүү ләә йәәәсү мир-раухил-ләәһи илләәл каумүл кәәфируун (87)».

Мәгънәсе: *«И, угылларым, Мисыр шәһәренә барып, Йосыф вә кардәше турында сораштырып карагыз, алар хакында берәр хәбәр булмасмы, Аллаһы рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез! Дөреслектә, мөэминнәр Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өметләрен өзмиләр, мәгәр кяферләр генә өметсез булалар (87)».*

Ягъкуб угыллары Мисырга барып, Йосыфка кереп әйттеләр: «И, игенчелек эшләренә хуҗа! Безгә вә өй җәмәгатьләребезгә бик каты ачлык иреште, менә сезгә төрле акчалар китердек, акчабызга карата безгә ашлык үлчәп бир һәм, мөмкин булса, садака итеп тә бир, шулай ук Биниәминне дә биреп җибәр, атабызның аның өчен бик хәсрәтләнеп елый-елый ике күзе сукыр булды».

Агаларының бу сүзләреннән Йосыф галәйһиссәламнең күңеле нечкәрде вә ул үзен танытырга теләп әйтте: «Хәтерегездәме, Йосыфка вә аның кардәше Биниәмингә җаһиллек белән ниләр кылдыгыз?» Кардәшләре гаҗәпләнеп вә куркып сорадылар: «Син әллә безнең кардәшебез Йосыфмы? Йосыф галәйһиссәлам аларның күзләренә туры карап әйтте: «Әйе, мин сезнең кардәшегез Йосыфмын, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә тәкъвалыгым өчен олуг нигъмәт вә дәрәҗәләр бирде». Агалары, куркып вә калтырап, аның аягына егылдылар вә әйттеләр: «И, кардәшебез Йосыф, һичшиксез, Хак Тәгалә сине безгә ихтыярлы вә баш кылды, син күргән төш, ягъни унбер йолдыз вә ай белән кояш көлеп миңа сәҗдә кылдылар, дигәнең Ходай рәхмәте белән хак булып чыкты. Безнең хаталануыбыз өчен безгә нинди җәза кыласың?» — диделәр.

Йосыф галәйһиссәлам әйтте: «Бүген минем шатлыклы көнем, сезне гаепләп, җәза кылырга һич ниятем юк. Кылган гөнаһларыгызны Аллаһы Тәгалә Үзе ярлыкасын, Ул бик шәфкатьле вә мәрхәмәтле! — диде. — Кардәшләрем! Хәзер инде сез хакыйкатьне белдегез, Кинганга кайтып, атабыз Ягъкуб пәйгамбәрнең йөзенә ошбу күлмәгемне ябыгыз, иншә Аллаһ, атабызның күзләре ачылыр, күрә башлар. Атамны вә барча җәмәгатьләрегезне җыеп, Мисырга минем хозурыма килегез!»

Угылларының кәрваны Мисырдан чыгып киткәч, Кинганда аталары Ягъкуб әйтте: «Картлыгы белән саташып сөйли дип уйламагыз, мин сезгә бер хәбәр әйтәм, Йосыф углымның исен сизәм, ул исән икән, тиздән сез дә минем сүзләремә ышанырсыз». «Йосыф» сүрәсенең 96 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فَلَمَّآ أَنْ جَآءَ الْبَشِيرُ أَلْقَىٰهُ عَلَىٰ وَجْهِهِۦ فَارْتَدَّ

بَصِيرًا ۖ قَالَ أَلَمْ أَقُل لَّكُمْ إِنِّىٓ أَعْلَمُ مِنَ اللَّهِ مَا لَا تَعْلَمُونَ ۝٩٦

«Фәләммәә әң җәә-әл бәшииру әл кааһү гәләә үәҗһиһии фәртәддә бәсыййр. Каалә әләм әкул ләкүм инний әгләмү миналлааһи мәә ләә тәгләмүүн (96)».

Мәгънәсе: *«Кәрван Кинган шәһәренә кайтып җиткәч, шатлыклы Йосыф хәбәрен китерүче бер углы, күлмәкне кулына тотып, атасы янына кереп, күлмәкне атасының йөзенә куйды вә дәрхаль атасының күзләре ачылды, ягъни күрә башлады. Шул вакыт Ягъкуб галәйһиссәлам әйтте:«Мин сезгә әйтмәдемме Аллаһы Тәгаләнең белдерүе илән сез белмәгән нәрсәләрне беләмен дип? (96)».*

Угыллары әйттеләр: «И, атабыз! Тәхкыйк, без хаталык кылдык, вә гөнаһлы булдык, инде безне, зинһар, гафу ит! Һәм безнең өчен Хак Тәгаләдән ярлыкау эстә!» Аталары әйтте: «Әлбәттә, мин сезнең өчен Аллаһы Тәгаләдән ярлыкау сорармын вә дәхи истигъфар кылырмын. Тәхкыйк, Ул Аллаһы Тәгалә ярлыкаучы вә рәхмәт кылучы».

Шуннан соң барчасы җыелып, җитмеш ике җан Мисыр шәһәренә күчеп киттеләр. Барып җитеп, Мисыр шәһәренә кергәндә аларны Йосыф каршы алды, ата-анасын вә кардәшләрен кочаклады һәм әйтте: «Һәр бәла-казадан имин хәлдә, Мисыр шәһәренә керегез!» Йосыф галәйһиссәлам үзенең ата-анасын хөрмәтләп тәхеткә утыртты, аннары Йосыфны хөрмәтләп, шөкер йөзеннән барчасы да сәҗдәгә керештеләр, вә Йосыф әйтте: «И, атам, күп еллар элек күргән төшемнең тәэвиле ошбудыр, тәхкыйк, Раббым миңа ихсан кылды, мине зинданнан чыгару белән вә сезне сахрадан Мисырга китерү белән кардәшләрем арасына шайтан вәсвәсә белән дошманлыкны салганы соңында, тәхкыйк, Раббым теләгән нәрсәсен шәфкать белән кылучы, әлбәттә, Ул белүче вә тиешенчә эш кылучы».

Хак Сөбханә вә Тәгаләдән кодрәтле вә гүзәл Йосыфка Зөләйхага өйләнү хакында әмер килә, вә Зөләйха илаһи көч илә яңадан элекке яшьлегенә, матурлыгына вә дәхи гыйффәтенә кире кайтарыла. Аларның никахыннан Ифраһим вә Мөсалим атлы ике угыл туа.

Ягъкуб пәйгамбәр, углы Йосыф галәйһиссәлам вә башка балалары белән Мисырда бик бәхетле 17 ел гомер кичереп, вафат була. Васыяте буенча аны Кинганга, атасы Исхак галәйһиссәлам янына дәфен кылалар.

Әтисе Ягъкуб пәйгамбәр вафат булгач, Йосыф галәйһиссәлам Мисырда янә 54 ел игенчелек белән идарә итә. Ул идарә иткәндә Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән илдә гел муллык вә иркенчелек була. Инде тиздән әҗәле якынлашуын белеп, Йосыф пәйгамбәр ошбу доганы укый: «Йә, Раббым! Мөселман хәлемдә җанымны ал вә мине изге бәндәләр илән урнаштыр!»

Йосыф галәйһиссәлам 125 яшендә вафат була. Аның гәүдәсе салынган мәрмәрдән ясалган табутны Нил елгасының Нәһр әл-Гуйун (чишмәләр елгасы) дигән җиренә төшерәләр. Муса пәйгамбәр заманында бу табут, Кинганга кайтарылып, әтисе Ягъкуб галәйһиссәлам янына җирләнә.

Газиз мөселман кардәшләрем! Коръән Кәримнең «Йосыф галәйһиссәлам кыйссасы» инде ничә гасырлардан бирле мөселман халкы күңелендә, аңында, теле вә язуында, әдәби мирасында яшәп килә. Җәнабел Хакның ошбу сүрәсе һаман да Ислам дененең рухи дөньясында эзлекле рәвештә тәэсир ясый торган, ягъни аңар ямь вә төс бирә торган иң асыл җәүһәрләренең берсе булып кала бирә. Халкыбызның рухи тормышына, аның көндәлек дөньясына бу кыйссаның никадәр тирән үтеп керүен җомга көннәрендә хәзрәтләребезнең үзләренең вәгазьләрендә «Йосыф» сүрәсенә мөрәҗәгать итүләреннән, сөйләгәндә нинди рухи ләззәт алуларыннан күрергә мөмкин.

Коръән Кәримнең ошбу кабатланмас сүрәсе гасырлар буена мөселман халкының әхлагын, зәвыгын тәрбияләүгә вә дәхи сафлык-пакьлек, гаделлек-тугрылык, кешелеклелек сыйфатларын үстерүгә зур йогынты ясаган. Сүрә барча мөселман халкына якын, гади, ягымлы, шул ук вакытта бик табигый да, укыганда аһәңле һәм дә Раббыбыз Газзә вә Җәлләнең без бәндәләренә биргән кабатланмас могҗизасы булып кала. Укыганда сүрәнең тирән мәгънәле, гыйбрәтле сүзләре, тәгъбирләре өр-яңадан ачыла, үзгәчә яктыртыла. Шул чордагы пәйгамбәрләрнең катлаулы язмышлары, кайгы-хәсрәтләре, шатлыклары, борчулары әле бүген дә безне тетрәндерә, уйландыра.

Әйтәсе килгән сүзем шул, Коръән Кәримнең кыйммәтле җәүһәрләреннән берсе булган бу сүрә мөселман дөньясы яшьләренең зәвыгын, гыйффәтен тәрбияләүгә зур өлеш керткән олуг сүрә булып тора.

# ӘЮБ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Әюб галәйһиссәламнең атасы — Мәгъсүб, аның атасы — Раүәх, аның атасы — Рум, аның атасы — Гайсу, аның атасы — Исхак пәйгамбәр иде.

Әюб пәйгамбәр Рум җирендә туып-үсте. Әнисе Лут галәйһиссәламнең кызы иде.

Хатыны Йосыф галәйһиссәлам нәселеннән Рәхимә исемле иде.

Әюб галәйһиссәламнең атасы белән бертуган Баһил атлы кяфер кардәше бар иде.

Хуран вилаятендә унике шәһәргә падишаһлык кылыр вә потка табыныр иде. Баһилнең Сәлес атлы бер поты бар иде, әгъзасы, ягъни гәүдәсе — алтыннан, куллары — көмештән, аяклары лөгал ташыннан ясалган иде.

Баһилнең йөз меңнән артык гаскәре бар иде, әмма углы вә кызы юк иде. Баһил үзенең поты Сәлескә кырык ел буе: «И, тәңрем! Миңа угыл бир», — дип зарилык кылды, поттан ни булсын, әлбәттә, кабул кылынмады.

Көннәрдән бер көнне Әюб янына Җәбраил галәйһиссәлам килеп: «Мин Аллаһы Тәгаләнең фәрештәсе Җәбраил булам. Хак Сөбханә вә Тәгалә сиңа Үзенең сәламен җибәрде вә әйтте:«И, Әюб, сине Хуран вилаятендә яшәүче кавемгә пәйгамбәрем итеп сайладым, Баһилне вә аның кавемен Ислам диненә өндәргә боерам!» — диде.

Әюб галәйһиссәлам үзенә пәйгамбәрлек иңүенә бик сөенеп, атасы белән бертуган Баһил янына барды. Баһил Әюб галәйһиссәламне таныды, күреште вә үзе янына утыртты вә әйтте: «И, Әюб, ни йомыш илән минем яныма килдең, әллә берәр нәрсә кирәкме?» Әюб галәйһиссәлам әйтте:«И, Баһил, мине Хак Тәгалә Үзенең пәйгамбәре итеп сайлады вә синең яныңа җибәрде, вәгазь вә нәсыйхәт кылып иманга өндәр өчен. Син ошбу кәлимәләрне әйтеп иман китерерсең, әгәр иман китерсәң, Хак Тәгалә синең падишаһлыгыңны вә дәүләтеңне арттырыр, иман кәлимәләрен минем арттан кабатла: «Ләә иләәһә иллаллааһү үә әннә Әййүбә расүүлуллааһ» дип әйт», — диде.

Баһил Әюбтән бу сүзләрне ишеткәч, кычкырып көлде вә үзенең хезмәтчеләренә әйтте: «Туганым Әюбкә бер меӊ куй сарыклары бирегез!» — диде. Әюб карышмакчы иде, ләкин шулвакыт Җәбраил галәйһиссәлам килеп әйтте: «Карышма, Баһил ни-нәрсә бирсә, шуны ал!» Бу көнне Әюб галәйһиссәлам меӊ куй сарыгын алып кайтып китте.

Икенче көнне дә Әюб галәйһиссәлам Баһил янына килеп иман кәлимәләрен әйттерергә тырышып вәгазьләде. Бу көнне Баһил аӊа бер меӊ сыер биреп җибәрде.

Өченче көнне Баһил аӊа меӊ ат бүләк итте.

Дүртенче көнне меӊ дөя бүләк итте.

Бишенче көнне янә меӊ дөя бүләк итте.

Алтынчы көнне Әюб галәйһиссәлам килгәндә, Баһил бик күӊелсез иде. Ул әйтте: «И, Әюб, кырык елдан бирле Сәлес тәӊремнән бер угыл сорыймын, ләкин файдасы булмады, әгәр дә синеӊ Хак Тәгаләӊ миӊа бер бала бирсә, син тәкрар иткән кәлимәләрне әйтеп иман китерермен», — диде. Әмма угыл дигән сүзне онытты. Әюб пәйгамбәр Аллаһы Тәгаләдән Баһилгә бер бала бирүен сорап дога кылды. Догасы кабул булды, бу кичтә Баһил падишаһныӊ сөекле хатыны йөкле булды. Баһил йокыга китте вә төш күрде: төшендә күктән бер тишек энҗе төшүен күрде, ул энҗедән арыслан чыкты, аныӊ авызыннан ут чыгып, кояш баешына таба таралды.

Баһил, йокысыннан торып, төш юраучыларын җыйды вә аларга күргән төшен бәян кылды. Әйттеләр: «И, падишаһ, синеӊ сөекле хатыныӊ кыз бала табар, әгәр дә энҗене тишексез күргән булсаӊ, углыӊ булган булыр иде. Кызыӊ, үсеп буй җиткәч, бер мәшһүр падишаһка кияүгә чыгар, ул никахтан кызыӊ бер пәһлеван ир бала табар, ул ир бала арыслан авызыннан чыгып таралган ут җиткән җирләргә кадәр падишаһлык кылыр», — диделәр.

Төш юраучылар бәян иткәнчә, тугыз ай вә ун көн үткәч, Баһилнеӊ хатыны бер бик гүзәл кыз тапты. Балага Куркыйсүн дип исем куштылар. Куркыйсүн, егерме яшенә җиткәч, әтисенә әйтте: «И, атам! Син кемгә табынырсыӊ?» — дип. Әтисе әйтте: «Сәлес исемле тәӊрегә табынырмын», — диде. «И, атам, миӊа да бер пот ясатсаӊ, мин шуӊа табыныр идем». Баһил үзенеӊ алтын вә көмешчеләрен чакыртып, аларга бик тиз арада кызы өчен алтын-көмештән вә энҗеләрдән бер пот ясарга

әмер бирде. Осталар бу эшне бик тиз башкардылар. Баһил бу потны кызы сараеның тәхетенә утыртты вә әйтте: «Менә сиңа тәңре, бар кирәгеңне аннан сора һәм аңа табын», — диде. Куркыйсүн әтисе әйткәнчә шул потка табына башлады.

Көннәрдән бер көнне Куркыйсүн ашарга утыргач, аның янына каяндыр искиткеч матур бер күгәрчен очып керде. Куркыйсүн бу күгәрченне тотарга теләп куа башлады, күгәрчен очып потның башына кунды вә әйтте: «И, Куркыйсүн, мин Аллаһы Тәгаләнең фәрештәсемен, мине синең янга Ул җибәрде вә әйтте: «Син табына торган пот тәңре була алмый, чын Тәңре ул сине дә, мине дә вә галәмдәге барча нәрсәләрне дә юктан бар кылган Аллаһы Тәгалә, Аның җирдәге илчесе, ягъни пәйгамбәре — Әюб галәйһиссәлам. Син туганчы ук, Әюб галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең әмере илә атаңны иманга өндәп килгән иде, ләкин атаң: «40 ел буе көткән балам туса, Аллаһы Тәгаләгә иман китерермен», — дип вәгъдә биргән иде. Әюб галәйһиссәлам Хак Тәгаләдән Баһилгә бер бала бирсәң иде дип дога кылды, догасы кабул булды, инде сиңа да егерме яшь тулды, ләкин ул вәгъдәсен үтәргә уйламый да. Син инде бу потка табынуыңны ташлап: «Ләә иләәһә иллаллааһү үә әннә Әййүбә расүүлуллааһ», — диген, ягъни Аллаһы Тәгаләдән башка Тәңре юк вә Әюб галәйһиссәлам Аның бәндәләргә дин өйрәтмәк өчен җибәрелгән илчеседер, диген». Куркыйсүн акыллы кыз иде, бу сүзләрдә чыннан да хаклык барын шунда ук аңлады вә, иман кәлимәләрен кабатлап, хак мөслимә булды. Әтисе ясаткан бер файдасыз потны кискәләп, фәкыйрь-фөкарәгә өләшергә кушты.

Бу вакыйганы тиз арада Баһилгә җиткерделәр. Моны ишетеп, Баһил кызы Куркыйсүн сараена килде вә әйтте: «Куркыйсүн, мин сиңа дип ясаткан тәңрең кая?» Куркыйсүн әйтте: «Ул пот тәңре түгел, аны ваттырып фәкыйрь-фөкарәгә хәер итеп өләшергә куштым. Чын Тәңре исә сине дә, мине дә вә барча галәмне дә юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләдер, ә Аның илчесе — Әюб пәйгамбәр», — диде. Баһил, бу сүзләрне ишеткәч, бик борчылып, үз сараена кайтып китте.

Баһил барча вәзирләренә вә якыннарына сарайга җыелырга әмер бирде.

Җыелып беткәч, ул аларга кызы Куркыйсүннең үзе табына торган потны тураклап фәкыйрьләргә өләшүе һәм аның бер

Аллаһыга гыйбадәт кылуы турында сөйләде. Күп бәхәсләрдән соң, Куркыйсүн бер көн безнең потка табынсын, икенче көнне Аллаһыга гыйбадәт кылсын, әгәр дә шуны үтәмәсә, башкаларга гыйбрәт өчен, уң кулын кисеп, башка мәмләкәткә илтеп ташларга дигән фикергә килделәр.

Куркыйсүнне чакырып, чыгарылган карарны аңа укыдылар. Карарны тыңлап бетергәч, Куркыйсүн тыныч кына әйтте: «Үтерсәгез дә, мин бер Аллаһыдан башка бернәрсәгә дә гыйбадәт кылмаячакмын, сезне дә шуңа өндим, бу минем катгый карарым», — диде. Ачуыннан ни эшләгәнен дә белмичә, Баһил җәлладка Куркыйсүннең уң кулын кисәргә һәм күрше мәмләкәтнең диңгез буена илтеп ташларга әмер бирде. Әмер шул вакытта ук җиренә җиткерелде.

Куркыйсүн киселгән кулын кочаклап, канлы күз яшьләре белән Хак Сөбханә вә Тәгаләгә ярдәм сорап дога кылды. Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул кылды һәм күгәрчен кыяфәтендә бер фәрештә җибәрде. Фәрештә аңа Хак Тәгаләнең сәламен ирештерде вә канаты белән киселгән кулын сыйпады, кул берни дә булмагандай үз урынына урнашты. Куркыйсүн шатланып: «Ләә иләәһә илләллааһү үә әннә Әййүбә расүүлуллааһ», — диде.

Куркыйсүн басып торган диңгез буйлары Мөсәвил атлы падишаһның җирләре иде. Мөсәвил бу көнне үзенең якыннары белән ауга чыккан иде. Бер куян артыннан куып, Куркыйсүн янына килеп чыктылар, курыккан куян күз ачып йомганчы Куркыйсүннең алдына сикереп менде. Иң алдан ат өстендә килүче Мөсәвил падишаһ куянны кочаклап торучы Куркыйсүннең матурлыгына хәйран калды вә әйтте: «И, гүзәлләрнең гүзәле, син хур кызымы, әллә пәри кызымы?» Куркыйсүн әйтте: «Мин синең кебек үк адәм баласымын». Мөсәвил әйтте: «И, гүзәлләрнең гүзәле, каян килдең, исемең кем? Әгәр риза булсаң, сине анам вә кыз туганнарым янына алып кайтыр идем», — диде. Куркыйсүн әйтте: «Безнең очрашуга сәбәпче булган бу йомшак куянны иреккә җибәрегез, сез яхшы кешегә охшагансыз, мин сезнең белән кайтырга риза», — диде.

Сараена кайткач, Мөсәвил кызны әнисенә тапшырды вә әйтте: «И, анам, минем бүген шатлыклы көнем, бу гүзәл кызны диңгез буеннан таптым, аны сиңа тапшырам, аңа кадерхөрмәт күрсәт», — диде. Берничә көн сабыр итеп йөргәннән

соң, Мөсәвил падишаһ Куркыйсүн янына керде вә аңа карап әйтте: «И, гүзәлләрнең гүзәле, сине күргәннән бирле мин үземнең синнән башка яши алмавымны аңладым, миңа хатынлыкка кил», — диде. Куркыйсүн әйтте: «Әйе, син куркусыз, батыр йөрәкле вә мәрхәмәтле ир-егет, ләкин минем синнән зур аермам бар, син потларга табынасың, ә мин бер Аллаһыга гына гыйбадәт кыламын һәм мин моннан мәңге кайтачак түгелмен», — дип, үзенең башыннан үткәннәрен сөйләде. Бу кыйссаны ишеткәч, Мөсәвил аны тынычландырды вә әйтте: «Әгәр синең динеңә кереп иман китерсәм, миңа кияүгә чыгасыңмы?» — диде. Куркыйсүн риза булды. Шул көнне үк Мөсәвил патша барлык халык алдында: «Ләә иләәһә иллаллааһ үә әннә Әййүбә рәсүүлуллааһ», — дип иман китерде, вә бу иман кәлимәләрен барча шәһәр халкы кабатлап, мөселман булдылар.

Икенче көнне никах укылды, зур туй мәҗлесе булды. Бу кичне Куркыйсүн әтисе Баһил төшендә күргән арысланга йөкле булды. Кайчан җиде ай корсаклы булды исә, Мөсәвил мәмләкәтенә дошманнар басып керде. Ул гаскәр белән аларга каршы сугышка чыгып китте. Тугыз ай булды исә, Куркыйсүн бер ир бала тудырды. Аңа Куркыйса дип исем бирделәр. Барча дошманнарын җиңеп, Мөсәвил падишаһ та улын күрергә кайтты. Ул, улының сау-сәламәт булуына вә матурлыгына бик шатланып, Аллаһы Тәгаләгә шөкраналар кылды.

Күп еллар узды, Куркыйса үсеп пәһлеван егет булды. Мөсәвил дәүләте белән идарә итүне углына тапшырды, үзе гел гыйбадәттә булды.

Көннәрдән бер көнне Куркыйса анасына әйтте: «И, анам, син кай җирләрдән вә бабам кем минем, сөйләп бирсәңче?» — диде. Әнисе үзенең кайсы илдән булуын, Ислам динен кабул иткәннән соң нинди авырлыклар күрүен һәм Аллаһы Тәгаләнең аны ташламавын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Улы Куркыйсаның потларга табынучы, вәгъдәсез бабасы Баһилгә бик ачуы чыкты һәм аның иленә гаскәр белән барырга булды. Җитмеш меңлек гаскәр туплады, үзе белән әнисен дә алды. Баһил падишаһ җирләренә кергәч, сугыш кырына чакырып, аңа хәбәр җибәрде. Баһил йөз мең гаскәр белән сугыш кырына килде вә сугыш мәйданын күзәтү өчен вәзирләре белән бер биек урынга урнашты.

Мәйданга Куркыйса һәм Баһил гаскәренең зур гәүдәле пәһлеваны чыкты.

Пәһлеван, кулына зур гөрзиен алып, Куркыйсага һөҗүм итте вә әйтте: «Әй, үзенең баһадирлыгында мәгърур бәндә, синең гакылың башыңда калмаган, шул гакылыңны мин башыңа китерәм», — дип, гөрзие белән берне орды. Куркыйса калкан астында тауларны тетрәтерлек өч сугуга түзде, моның оста сугышчы бер баһадир икәнен күрде. Өч сугудан соңра нәүбәт Куркыйсага килде. Кулына гөрзиен алып, бу тәкәббер баһадирга бер нәгъра орып, бик каты тавыш белән: «Менә бу егетнең сугуларына түз дә бу дөньяның кайгыларын тәмам оныт», — диде дә гөрзие белән орды, җир йөзе тәмам ут белән тулды. Бу сугудан баһадирның аты һәм үзе чыдый алмый җиргә егылдылар, Куркыйса торып баскан баһадирның биленнән алды вә югары күтәреп әйләндерде, әйләндерде дә җиргә орды, җир селкенгәндәй булды, Баһилнең иң куәтле баһадиры җан тәслим кылды.

Баһил гаскәренә һөҗүм итәргә әмер бирде. Моны сизеп, Куркыйса атына атланды да, гаскәр арасына кереп, арыслан кебек сугыша башлады. Ул көнне ахшамга кадәр сугыштылар. Куркыйса шулкадәр гайрәт белән сугышты, сугышта үлгәннәргә карап хәйран калырлык булды. Баһилнең күп сугышларда булган сугышчылары, бу көнгә кадәр мондый сугышчыны күргәнебез юк иде, диделәр.

Куркыйса икенче көнне сабах вакытында уянып, чишмә янына барып таһарәтләнгәч, иртә намазын укыды, Хак Тәгаләдән бу көрәштә җиңү китерүен сорап дога кылды вә гаскәрен янә сугышка күтәрде. Тагын көне буе сугыштылар һәм бу юлы Баһил гаскәре җиңелде, Куркыйса Баһилнең үзен тотып анасы каршысына китерде вә әйтте: «И, ана, менә дошманыңны сиңа тотып китердем, инде ихтыяр синдә, теләсәң нишләт», — диде. Куркыйсүн әйтте: «Әй, карт, син мине таныйсыңмы?» Баһил әйтте: «Минем кызыма охшыйсың, әмма кызымның бер кулы юк иде». Куркыйсүн әйтте: «Кызыңның ни сәбәпле кулы юк иде?» Баһил әйтте: «Гөнаһ кылды, минем динемне ташлап, башка дингә керде, шул сәбәпле кулын кисеп, шәһәрдән куаладым». Куркыйсүн әйтте: «Син Әюб пәйгамбәр белән вәгъдә кылган икәнсең, «әгәр синең Тәңрең миңа бала бирсә, иман китерермен» дип. Аннан соң төш күргәнсең: күктән бер тишек

энҗе төшәр, энҗедән арыслан чыгар, ул арыслан авызыннан ут чыгып, кояш баешы тарафына җәелер, дип. Бу көн ул төшеңнең тәгъбире килде. Мин синең кызың Куркыйсүн. Сине тотып минем каршыма китергән егет — ул минем углым Куркыйса», — диде. Баһил, күзләреннән яшьләр агызып, кызының аягына төшеп, гозер кылды: «И, кызым, кулың ничек төзәлде?» — диде. Кызы әйтте: «Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә кулымны төзәтте. Ислам дине — хак дин, ий ата, иман китер, ахирәт вә дөнья максудына ирешерсең», — диде. Бу сүзләрне ишеткәч, Баһил күзләреннән шатлык яшьләре агызып: «Ләә иләәһә иллаллааһ үә әннәә Әййүүбә расүүлуллааһ», — дип иман китерде. Кызы Куркыйсүн әтисен иман китерүе белән тәбриклэп кочаклады. Әтисен зур хөрмәт белән үз шәһәренә кадәр озаттылар. Үзләре йөрәкләрендә шатлык вә иман нуры илә яши торган шәһәрләре Мәгъриб Зәмингә кайтып киттеләр.

Әюб галәйһиссәламгә, Хуран халкын иманга өндәргә дип, вәхи иңә башлады. Бу хакта Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримнең «ән-Ниса» сүрәсе, 163 нче аятендә әйтә:

إنا أوحينا إليك كما أوحينا إلى نوح والنبيين من بعده وأوحينا
إلى إبرهيم وإسمعيل وإسحق ويعقوب والأسباط وعيسى وأيوب
ويونس وهرون وسليمن واتينا داود زبورا ﴿١٦٣﴾

«Иннәә әүхәйнәә иләйкә кәмәә әүхәйнәә иләә Нүүхин үәннәбиийинә мим-бәгдиһии үә әүхәйнәә иләә Ибрааһиимә үә Исмәәгиилә үә Исхәәка үә Йәгкуубә үәл әсбәәтый үә Гийсәә үә Әййүүбә үә Йүүнүсә үә Һәәруунә үә Сүләймәәнә үә әәтәйнәә Дәәүдә Зәбүүр (163)».

Мәгънәсе: *«...Вәхи кылдык Нух пәйгамбәргә, аннан соң килгән Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб, Гайсә, Әюб, Юныс, Һарун, Сөләйман пәйгамбәрләргә вәхи кылган кеби вә дәхи Даудка Зәбур исемле китап иңдердек (163)».*

Әюб галәйһиссәлам һәр көн килеп Баһилгә шәригать хөкемнәрен өйрәтә башлады.

Аллаһы Тәгалә, аннан алда килгән пәйгамбәрләрне һидаятькә, ягъни туры юлга күндергән кебек, Әюб галәйһиссәламне дә һидаятькә күндерде. Бу хакта Аллаһы Тәгалә «әл-Әнгам» сүрәсенең 84 нче аятендә әйтә:

وَوَهَبْنَا لَهُۥٓ إِسْحَٰقَ وَيَعْقُوبَ كُلًّا هَدَيْنَا وَنُوحًا هَدَيْنَا مِن قَبْلُ وَمِن ذُرِّيَّتِهِۦ دَاوُۥدَ

وَسُلَيْمَٰنَ وَأَيُّوبَ وَيُوسُفَ وَمُوسَىٰ وَهَٰرُونَ وَكَذَٰلِكَ نَجْزِى ٱلْمُحْسِنِينَ ۝

«Үә үәһәбнәә ләһүү Исхәәка үә Йәгкуубә, кулләән һәдәйнәә, үә Нүүхән һәдәйнәә миң кабелү үә миң зүрриййәтиһии Дәәүдә үә Сүләйməәнә үә Әййүүбә үә Йүсүүфә үә Мүүсәә үә Һәәрунә, үә кәзәәликә нәҗзил мүхсиниин (84)».

Мәгънәсе: *«Ибраһимга Исхакны вә аның углы Ягъкубны бирдек, һәрберсен һидаятькә салдык вә Ибраһимнан элек Нухны һидаятькә салдык. Ибраһим нәселеннән Даудны, Сөләйманны, Әюбне, Йосыфны, Мусаны, Һарунны һидаятькә салдык вә чын иманлы, изге гамәлле инсаннарны әнә шулай һидаятькә салачакбыз (84)».*

Әюб галәйһиссәлам, Хак Тәгаләгә шөкраналар кылып, гел гыйбадәттә булды. Булган малыннан фәкыйрьләргә садака өләште, мал-мөлкәте гел артып торды.

Иблис мәлгунь Әюб галәйһиссәламнең гел гыйбадәттә вә күркәм холыклы булуыннан көнчелек кылды вә Аллаһы Тәгаләгә әйтте: «Ул Әюбкә байлык, нигъмәт, җан тынычлыгы бирдең, шул сәбәпле генә ул Сиңа гыйбадәт кыла. Әгәр бу кадәр маллары вә нигъмәтләре булмаса, Сиңа гыйбадәт кылмас иде», — диде. Бәс, Аллаһы Тәгалә әйтте: «И, мәлгунь! Син ялган сөйлисең, Мин Үз колым Әюбне яхшы беләм: ни бәла-каза күрсә дә, ул Миңа гыйбадәт кылудан туктамас, һаман сабыр итеп, шөкрана кылыр. Әй, мәлгунь! Әюбнең җаныннан башка, һәммәсенә сине ирекле кылдым, сынап кара: Әюбнең Минем гыйбадәтемә иҗтиһадын белерсең, дөнья малы өчен кайгырмыйча, сабыр итә белүен күрерсең», — диде.

Иблис мәлгунь үзенең гаскәренә әйтте: «Аллаһы Тәгалә миңа Әюбне сынап карарга ирек куйды. Әюбне гыйбадәтеннән туктатырга ярдәм итегез», — диде.

Бәс, шайтаннар, шул вакытта ук таралышып, Әюб галәй-

һиссәламнең барча малларын, иген-кырларын, аш ашап утыручы алты кызын вә сигез углын йортын җимереп һәлак иттеләр.

Иблис мәлгунь шул вакыт Әюб галәйһиссәламгә килде. Әюб галәйһиссәлам бу вакытта тыныч бер урында намаз укый иде. Мәлгунь шатлыгын эченә сыйдыра алмыйча әйтте: «И, Әюб! Синең Аллаһың, күктән ут җибәреп, барча малларыңны, иген-кырларыңны яндырды һәм аш өендә ашап утыручы балаларыңны һәлак кылды. Сиңа шулкадәр зарар китергән Аллаһыңа гыйбадәт кыласыңмы?! Ахмак икәнсең!» — диде. Әюб пәйгамбәр һич ашыкмый намазын тәмам кылды. Намаздан бушангач, әйтте:«Бел, и мәлгунь! Әлхәмдүлилләһи, Хак Тәгалә бу мал-мөлкәтне, игеннәрне вә балаларның һәммәсен дә Үзе бирде вә Үзе алган. Бу мал-мөлкәтләр вә бала-чага һәммәсе дә ирләргә һәм хатыннарга бер фетнәдер, инде калган гомеремдә Аллаһы Тәгаләнең гыйбадәтен тагын да бирелеп, тынычлык белән кылырмын», — диде.

Иблис мәлгунь бик мәхрүм булып, кылган вәсвәсәсе тәэсир итмәгәч, бик яман ачуы килеп, шайтаннары янына кайтып китте. Әюб галәйһиссәлам тыныч кына янә намазга керeште. Иблис мәлгунь шайтаннары белән киңәшеп, яңадан Әюб галәйһиссәлам янына әйләнеп килеп, сәҗдәдә вакытында аның борынына вә авызына кабахәт сулышын өрде. Бу сулыштан аны башыннан аягына чаклы бетчәләр басты, ул бетчәләр эрен вә сары суга әйләнеп кортладылар. Моны күреп, Әюб галәйһиссәламнең барча дуслары, кордашлары аның яныннан качтылар. Әюб галәйһиссәламнең өч хатыны бар иде, ике хатыны, аның хәлен күреп, талак сорадылар. Әюб галәйһиссәлам талак кылды, ягъни аерып җибәрде. Рәхимә Әюб галәйһиссәламгә көн-төн хезмәт итте. Әюбнең күрше хатыннары Рәхимәгә әйттеләр: «Без Әюбнең чире балаларыбызга йогар дип куркабыз, яхшылык белән алып китмәсәң, көчләп чыгарып ташларбыз», — диделәр.

Рәхимә елый-елый, Әюб галәйһиссәламне аркасына салып барып, шәһәр читендәге бер ташландык йортка урнаштырды. Шәһәр халкы, моны белеп, әйттеләр: «Әй, хатын, иреңне моннан теләсә кая алып кит, алып китмәсәң, этләр җибәреп ашатырбыз», — диделәр.

Рәхимә Әюб галәйһиссәламне тагын күтәреп, сахрага алып чыгып, бер юл читына куйды. Балта, бау алып, бер шалаш

ясады. Печән алып килеп, астына салды. Аннан соң Рәхимә, шәһәргә барып, хезмәт итеп, бер сынык икмәк алып кайтырга чыкты. Әюб галәйһиссәламнең борчылганын күргәч, әйтте: «И, Әюб! Курыкма, җаным тәндә бар вакытта, сине ташламам», — диде.

Шәһәр халкы аның Әюб галәйһиссәлам хатыны икәнен белделәр вә әйттеләр: «Әй, хатын! Без синнән җирәнәбез, безнең шәһәргә килмә», — дип, шәһәргә керүдән тыйдылар, һичнәрсә ашарга бирмәделәр, хезмәткә дә ялламадылар.

Беркөнне Рәхимә яшеренеп кенә икмәк пешерүче таныш хатын янына керде вә әйтте:«И, дустым! Мин сиңа хезмәт итәрмен, минем ирем Әюб ач ята, бер сынык икмәк бирсәнә?» — диде. Икмәкче хатын як-ягына каранып әйтте: «Ирем күрмәсен, миннән ерак бул, алай да бер толым чәчеңне кисеп бирсәң, сиңа тулы бер икмәк бирермен», — диде.

Рәхимәнең чәче унике толымга үрелеп, алар бик күркәм булып җиргә кадәр сузылып төшкәннәр иде. Матурлыкта Рәхимә бабасы Йосыф галәйһиссәламгә охшар иде. Әюб галәйһиссәламнең тамагын туйдырыр өчен чәченең бер толымын кисеп бирде вә тулы бер икмәк алды.

Рәхимә кулында тулы бер икмәк күргәч, Әюб галәйһиссәлам: «Рәхимә үзен сатып, тулы бер икмәк алып кайткандыр, әгәр сәламәтләнсәм, йөз мәртәбә сугармын», — дип, эченнән генә ант итте.

Рәхимә кыйссаны сөйләп, ягъни чәчен икмәк өчен биргәнен белдереп, Әюб галәйһиссәламне ышандырды. Икмәкне, кисеп, Әюб галәйһиссәламгә ашатты.

Әюб галәйһиссәламнең тәнен кортлар шулкадәр ашадылар ки, аслан тәнендә итләре калмады, тәненә кояш төшсә, бер ягыннан икенче ягы үтәли күренә иде.

Хатыны Рәхимә беркөнне әйтте: «И, Әюб! Син Аллаһының сөекле пәйгамбәресең, әгәр дога кылсаң, догаң кабул булыр, сәламәтләнерсең», — диде. Әюб галәйһиссәлам әйтте: «Без синең белән сиксән ел рәхәт гомер кичердек, ә бу авыруыма унсигез ел булды, Аллаһы Тәгаләдән сәламәтлек сорап дога кылырга ояламын», — диде.

Әюб галәйһиссәламнең кортлары бер-берсен ашап бетерделәр. Мәгәр ике корт калды, бөтен тәнендә йөрделәр, ит таба алмагач — берсе теленә ябышты, икенчесе йөрәген тешләде.

Әюб галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә дога кылды: «Йә, Раббым! Күңелем шөкер берлә Сине сөймәклектә даим булган мөддәттә, телем Сине зикер кыйлу берлә даим булган мөддәттә, һәр бәлагә сабыр кылырмын. Әгәр инде бу ике корт йөрәгем белән телемне ашасалар, Сине ничек зикер кылырмын?» — диде.

Аллаһы Тәгалә бу ике кортның берсен суга төшерде — сөлек булды, инсаннарга файда өчен. Икенчесе сахрага төшеп бал корты булды, аның балы адәмнәргә шифадыр. Әюб галәйһиссәламнең догасын Хак Тәгалә кабул итте. Ул «әл-Әнбия» сүрәсенең 83 нче аятендә әйтә:

وَأَيُّوبَ إِذْ نَادَىٰ رَبَّهُ أَنِّي مَسَّنِيَ الضُّرُّ وَأَنتَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ ﴿٨٣﴾

«Үә әййүүбә изнәәдәә раббәһү иннии мәссәнийәд-дурру үә әңтә әрхәмүр-раахимиин (83)».

Мәгънәсе: *«Вә Әюбне хәтерләгез, Ул Раббысына дога кылды: «И, Раббым! Мине сырхау вә катылык тотты, Син рәхмәт итүчеләрнең иң рәхимлесе, мине дә рәхмәтеңнән ташлама! (83)».*

Шулай ук «Сад» сүрәсенең 41 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَاذْكُرْ عَبْدَنَا أَيُّوبَ إِذْ نَادَىٰ رَبَّهُ أَنِّي مَسَّنِيَ الشَّيْطَانُ بِنُصْبٍ وَعَذَابٍ ﴿٤١﴾

«Үәзкүр гәбдәнәә әййүүбә, изнәәдәә раббәһүү иннии мәссәнийәш- шәйтаанү бинүсбиү-үә гәзәәбе (41)».

Мәгънәсе: *«Янә колыбыз Әюб пәйгамбәрне сөйлә, Әюб Раббысына дога кылды: «И, Раббым! Мине шайтан авырлык вә каты мәшәкать илә тотты, барча малымны вә балаларымны һәлак итте». Әюб күп еллар буе сырхау булды, тәнендә һичнәрсәсе калмады, ул һаман сабыр итте, зикердән туктамады (41)».*

Аллаһы Тәгаләнең әмере белән Җәбраил фәрештә, оҗмахтан руммән җимеше алып килеп, Әюб галәйһиссәламне ашатты һәм әйтте: «И, Әюб! Тор, аягың белән җиргә тип, җирдән ике чишмә чыгар, берсе җылы, икенчесе салкын сулы, җылы чишмәдән госел коен, салкын чишмәдән эч, эчеңдәге вә тышыңдагы барча авыруларың китәр», — диде. Аллаһы Тәгалә «Сад» сүрәсенең 42 нче аятендә әйтә:

ارْكُضْ بِرِجْلِكَ هٰذَا مُغْتَسَلٌ بَارِدٌ وَشَرَابٌ ۝٤٢

«Үркүдъ бәриҗликә, һәәзәә мүгътәсәлүм бәәридү-үә шәрабе (42)».

Мәгънәсе: *«И, Әюб, аягың илә җиргә тип», — дип әйтелде, типкәннән соң салкын вә җылы чишмә чыкты. Җылы чишмәдә юынды, госелләнде, салкын чишмәнең суын эчеп, шунда ук сәламәтләнде, әүвәлге куәтен тапты (42)».*

Кайчан сихәт вә сәламәтлек тапты исә, Аллаһы Тәгаләгә шөкраналар кылып, шунда бер калкурак җиргә утырды. Шәһәрдән икмәк сыныгы тотып Рәхимә кайтты, шалашны карады, Әюб галәйһиссәламне тапмады, канлы күз яшьләре илән елый башлады: «Кайсы бүре Әюб пәйгамбәрне ашады икән, ах, мин дә монда булсам, мине дә ашаган булыр иде. Кыямәт көнне Әюб пәйгамбәр белән бергә кубарылган булыр идем», — дип зарилык кылды. Әюб галәйһиссәлам аны күреп дәште: «Ник еглыйсың?» — диде. Рәхимә: «Менә бу шалашта бер авыруым бар иде, кайда китте икән, бүре ашадымы икән, дип, шул кайгыдан елыйм», — диде. Әюб галәйһиссәлам: «Авыруың нинди кеше иде?» Рәхимә әйтте: «Сәламәт вакытында сиңа охшаган иде». Әюб галәйһиссәлам әйтте: «Әй, Рәхимә! Авыру ирең Әюб — мин, Хак Тәгаләнең рәхмәте ирешеп сихәтләндем», — дип, кыйссаны сөйләде, икесе дә шат булдылар. Аллаһы Тәгаләгә шөкраналар укып, сәҗдә кылдылар.

Әюб галәйһиссәламгә Аллаһы Тәгаләдән вәхи килде: «И, Әюб, «сәламәтләнсәм, Рәхимәгә йөз мәртәбә сугармын», дип ант иткән идең, бер уч салам алып, бер мәртәбә сук, антыңда торган булырсың вә гөнаһтан котылырсың». Бу хакта Аллаһы Тәгалә «Сад» сүрәсенең 44 нче аятендә әйтә:

وَخُذْ بِيَدِكَ ضِغْثًا فَاضْرِبْ بِهِ وَلَا تَحْنَثْ

إِنَّا وَجَدْنَاهُ صَابِرًا نِعْمَ الْعَبْدُ إِنَّهُ أَوَّابٌ ۝٤٤

«Үә хуз бийәдикә дыйгъсәң фәдърибе биһии үә ләә тәхнәс, иннәә үә җәднәәһү саабиир. Нигмәл гәбдү, иннәһүү әүвәә-бе (44)».

Мәгънәсе: *«И, Әюб, бер уч салам алып, хатыныңа сук, Аллаһ исеме илә әйткән антыңны үтәмичә, гөнаһлы булып калма. «Сырхау вакытында үзен караучы Рәхимә хакында, хаталык белән, бозык эшне эшләүче дип зан кылып, «Валлаһи, терелсәм, йөз мәртәбә сугармын», дип ант иткән иде. Соңра Рәхимәнең бозык эше юклыгы мәгълүм булгач, шул бер уч салам белән сугып, йөз мәртәбә суккан хөкемендә булды». Без Әюбне бәла-казага вә сырхауга сабыр итүче таптык. Ул Әюб ни хуш бәндәдер, вә ул Аллаһы Тәгаләгә нык ышанып кайтучыдыр (44)».*

Аллаһы Тәгалә, сабырлыгы өчен, Әюб галәйһиссәламнең барча сырхауларын алды вә барча балаларын вә малларын икеләтә кайтарды. Аллаһы Тәгалә «әл-Әнбия» сүрәсенең 84 нче аятендә әйтә:

فَاسْتَجَبْنَا لَهُ فَكَشَفْنَا مَا بِهِ مِنْ ضُرٍّ وَآتَيْنَاهُ أَهْلَهُ
وَمِثْلَهُمْ مَعَهُمْ رَحْمَةً مِنْ عِنْدِنَا وَذِكْرَى لِلْعَابِدِينَ ٨٤

«Фәстәҗәбнәә ләһүү фәкәшәфнәә мәә биһии миң дурриүүә әәтәйнәәһү әһләһү үә мисләһүм мәгһүм рахмәтәм-мин гиңдинәә, үә зикраа лил гәәбидиин (84)».

Мәгънәсе: *«Без аның догасын кабул иттек вә аңарда булган сырхау вә бәлане җибәрдек һәм аңар өй әһелләрен кайтарып бирдек, вә балаларын, малларын ике өлеш арттырып бирдек, Үз хозурыбыздан рәхмәт йөзеннән, вә Аллаһ колларына гыйбрәт булсын өчен (84)».*

Аллаһы Тәгалә әүвәлге балаларын тергезеп, тагын шул кадәр үк балалар бирде. Сигез углы, алты кызы бар иде, янә сигез угыл, алты кыз бирде. Бу турыда Аллаһы Тәгалә «Сад» сүрәсенең 43 нче аятендә әйтә:

وَوَهَبْنَا لَهُ أَهْلَهُ وَمِثْلَهُمْ مَعَهُمْ رَحْمَةً مِنَّا وَذِكْرَى لِأُولِي الْأَلْبَابِ ٤٣

«Үә үәһәбнәә ләһүү әһләһү үә мисләһүм-мәгһүм рахмәтәм-миннәә үә зикраа ли үүлил әлбәәбе (43)».

Мәгънәсе: *«Вә Без Әюбкә балаларын ике өлеш арттырып бирдек, Бездән аңа рәхмәт булсын өчен вә гакыллы инсаннарга вәгазь булсын өчен (43)».*

Аллаһы Тәгалә Үзенең Коръән Кәримендә сабырлыкны сөюе хакында: «Иннәллааһи мәгәс-саабириин», — ди.

Мәгънәсе: *«Хакыйкатьтә, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә сабыр кылучылар берлә бергә».*

Сабыр иткән бәндәләрнең нинди нигъмәтләргә ирешүләре хакында Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең хәдис-шәрифләрендә дә күрергә була: «Изәә әсаабә әхәдәкүм мүсыйбәтүң фәлйәкули иннәә лилләәһи үә иннәә иләйһи раажи-гүүн. Әллаһүммә гиндәкә әхтәсибү мүсыйбәтии фә әҗирнии фииһәә үә әбүдилнии миңһәә хайр».

Мәгънәсе: *«Башына кайгы килүче бәндә күңеле ихлас булган хәлдә «Иннәә лилләәһи үә иннәә иләйһи раажигүүн» дисен, ягъни без үзебез вә әһлебез һәм барча малыбыз Аллаһы Тәгаләнеке, безнең хакыбызда Үзе теләсә ни эшләр вә ахирәттә Аның хозурына кайтачакбыз. И, Аллам, бу кайгым бәрабәренә булачак савапны киләчәк көн өчен саклап торамын, моның бәрабәренә миңа савап вә мәрхәмәт кыл, шушы кайгы-борчу урынына хәерле бәдәл, ягъни алыштыру насыйп ит!»*

Җәнабел Хак Коръән Кәримнең күп урынында «сабыр»ны мәдех кылды, ягъни мактады вә хәер эшләрне сабырга изафә кылды. Адәм баласы өчен кайгылар, бик авыр вә уңайсыз нәрсәләр килсәләр дә, һәр авырлыкның асылында бер җиңеллек вә бертөрле файда булганлыктан, кайгылар да файдасыз түгел. Кайгы күрү сәбәбеннән адәм балаларының холыклары төзәлә, күңелләре яхшылана, гакыллары арта.

Кайгылар, хәсрәтләр ничаклы зур булса да булсыннар, куркынычлар никадәр тоташ килеп торса торсыннар, шуларга каршы бәндәнең вазыйфасы өметсез булу түгел, бәлки «минем өчен инде шушы эшләр хәерле булгандыр, бу Аллаһы Тәгаләнең мине сынавыдыр» дип кабул итәргә кирәк,чөнки моның артында Хак Тәгаләнең мәрхәмәте вә савабы ята.

Сабырлык турында Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең янә бер хәдис-шәрифе: «Мәсгуд, ягъни бәхетле, игелекле шул кешедер ки, төрле фетнәләрдән читтә калучы вә дәхи шул кешедер ки, гөнаһсыз бәлаләнсә, сабыр итүче».

Рәсүл Әкрам галәйһиссәлам үзенең догаларында һәрвакыт төрле фетнәләрдән сакланырга боера. Инде сакланып та фетнә белән мөбтәля булынса, аның чарасы сабыр итү булып, сабыр итүче инсан мәсгудтер. Кирәксә-кирәкмәсә ахы-

рын уйламыйча кешеләр өстеннән шикаятьләр кылучылар, гаиләләр вә гөнаһсыз бала-чагалар арасына куркулар салып, яшьләр агызуга, хаклы яки хаксыз икәнлеген яхшы белми торып, үзенең дин карендәшләрен мәхкәмәләргә тарттырырга, адәмнәр арасында дошманлык артып, дуслык җепләре өзелергә сәбәпче булучылар — ошбу хәдис-шәрифтән фәһемләп, үзләренең мәсгуд адәмнәрдән булмауларын аңларлар.

Әлбәттә, адәм баласының дөньяда булган мөддәтендә кайгылар, хәсрәтләр күрми генә гомер сөрүе мөмкин түгел. Мәгыйшәт вә хәят — төрле авырлыклар, кайгы-борчулар, мәшәкать дулкыннары белән көрәшеп йөрүдән гыйбарәттер. Иманлы кеше шушы мәшәкатьләрдән авырсынмаска вә киләчәктәге рәхәтләрне өмет итеп яшәргә, күңелен төшермәскә тиеш. Һәр авырлык соңында җиңеллек булуын Коръән Кәрим вәгъдә кыладыр. Мөселман булган кеше, әлбәттә, шул вәгъдәне хәтерләп, күңеленә тәслия, ягъни юату табар, вә Коръән укып, үз-үзенә нәсыйхәт дәресләре бирер.

Адәм баласы кайгы вә хәсрәтнең иң элек килеп бәрелгән вакытында түзсә вә үз-үзен дөрес итеп тота алса, гакылының күндерүе вә юатуы сәбәбеннән акрынлап өйрәнә вә күңеле дә тәслия кыла башлар. Шуның өчен «сабыр» дип хәсрәтнең иң әүвәл килеп сугылган сәгатендә түзүгә әйтелә, сабыр хакында Коръәндә булган вәгъдәләр вә әйтелгән саваплар да шул вакытка туры киләдер. Мәгәр күңелнең сызлануы, тавышсыз гына күзләрдән яшь агызу сабырга хилафлык кылмас. Чөнки бу нәрсәләр хакында бәндәләр ихтыярсызлардыр. Мисал өчен, Ибраһим исемле углы вафат булгач, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам сабыр гына күзеннән яшьләр агызды вә тәһарәт алып ике рәкәгать намаз укыды.

Бәла вә хәсрәт килгәндә, Рәсүлулла сөннәтенә ияреп, без дә, тәһарәт алып, намаз укырга тиеш булабыз.

Әюб галәйһиссәлам кыйссасында без аның нигъмәт бирелгәндә шөкер кылуын, авырлык килгәндә Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорап тизрәк дога кылырга ашыкмавын күрдек. Димәк, сабырлык ул коры тел белән әйтү генә түгел, ә бәлки гамәлдә дөньядагы кайгыларга түзү вә сабыр итүдән гыйбарәттер.

# ШӨГАИБ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Шөгаиб пәйгамбәрнең атасы — Мәсгук, аның атасы — Синак, аның атасы — Сабит, аның атасы — Мәдйән. Мәдйән исә Ибраһим галәйһиссәлам нәселеннән иде.

Шөгаибнең әбисе Лут галәйһиссәламнең кызы иде.

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә Шөгаибны Мәдйән шәһәрендә төрле сыннарга вә потларга табынучы, алганда һәм сатканда бик тә алдакчы булган Әйкә кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрде. Мәдйән шәһәренең нигез ташын Ибраһим галәйһиссәлам нәселеннән булган Мәдйән салган иде. Мәдйән шәһәре Фәлестин мәмләкәтенең көньягында, Мисырга якын булган җирдә урнашкан. Әйкә кавеме яшәгән һәм файдалана торган зур биләмәләрдә бакчалар вә болыннар җәелеп яткан. Үзләре бай яшәсәләр дә, Аллаһы Тәгаләне вә кыямәт көнен инкарь итеп, төрле потларга вә сыннарга табыналар иде. Менә шушы бозык табигатьле кавемгә Хак Тәгалә Шөгаиб галәйһиссәламне пәйгамбәр итеп, аларны иманга өндәргә җибәрде. Бу хакта Коръән Кәримнең «әл-Әгъраф» сүрәсе, 85 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَاِلٰى مَدْيَنَ اَخَاهُمْ شُعَيْبًا

«Үә ләә мәдйәнә әхааһүм Шүгәйбә (85)».

Мәгънәсе: *«Вә Мәдйән шәһәренә кардәшләре Шөгаибне пәйгамбәр итеп җибәрдек (85)».*

Бу кавем кешеләренең барчасы алганда вә сатканда бик тә алдакчы иделәр. Алар әгәр дә бер-бер нәрсә саталар икән, герләрнең вә үлчәүләрнең авырлыгын киметәләр, ягъни тиешлесеннән кимрәк бирәләр. Әгәр дә инде берәр нәрсә сатып алалар икән, ул чакта гернең авырлыгын арттыралар.

Шөгаиб галәйһиссәлам беренче эше итеп үз кавемен иманга өнди башлады. Бу турыда да Аллаһы Тәгалә «әл-Әгъраф» сүрәсенең 85 нче аятендә әйтә:

يٰقَوْمِ اعْبُدُوا اللّٰهَ مَا لَكُمْ مِنْ اِلٰهٍ غَيْرُهُ

«Йәә каумиг бүдүллааһ мәә ләкүм-мин иләәһин гайруһ (85)».

Мәгънәсе: *«Ул кавеменә әйтте: «И, кавемем, фәкать Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылыгыз! Ул Аллаһы Тәгаләдән башка сезнең Илаһыгыз юк! (85)».*

Ләкин кавеме аны тыңламый, алар үзләре ясаган сыннарга табыналар, бу тирәдән узучы кәрваннарга вә сәяхәтчеләргә һөҗүм итәләр, талыйлар, кыйныйлар, аларны гарипләндерәләр. Әйбер алганда вә сатканда, үлчәгәндә күрше кабиләкешеләрен вә сәүдәгәрләрне алдаудан ләззәт табалар, шуның белән бер-берсенә мактанышалар, кыскасы, аларның күңелләрен тәкәбберлек уты каплаган иде.

Шөгаиб галәйһиссәлам аларны гаделлек илә сату-алу эшләрен алып барырга чакыра. Аллаһы Тәгалә «Һуд» сүрәсенең 85 нче аятендә әйтә:

وَيٰقَوْمِ اَوْفُوا الْمِكْيَالَ وَالْمِيزَانَ بِالْقِسْطِ وَلَا تَبْخَسُوا النَّاسَ اَشْيَاۤءَهُمْ وَلَا تَعْثَوْا فِي الْاَرْضِ مُفْسِدِينَ ﴿٨٥﴾

«Үә йәә кауми әүфүл-микйәәлә үәл-мизәәнә бил-кыйстый үә ләә тәбхасун-нәәсә әшйәә-ә һүм үә ләә тәгсәү фил-әрдый мүфсидиин (85)».

Мәгънәсе: *«И, кавемем, үлчәүләрегезне гаделлек белән үлчәгез! Вә үлчәүләрдә сатып алучы кешеләрнең әйберләрен киметмәгез вә җир өстендә бозыклык кылып йөрмәгез! (85)».*

Югарыда зикер ителгәнчә, Әйкә кавеменең күбесе мөшрик булып сыннарга табыналар. Алар ул сыннардан файда вә зарар килүен игътикад итәләр иде. Шуның өчен сыннарның алдына барып сәҗдә кылалар, ялваралар, хаҗәтләрен сорыйлар, бәла-казаларны алардан бетерүләрен өмет итәләр иде. Алар хозурында корбан чалалар, алар исемнәренә садакалар җыялар. Бу хакта Коръән аятендә әйтелә: «Алар Аллаһыдан башка файда да, зарар да ирештерә алмый торган сыннарга табыналар вә әйтәләр: «Бу сыннар — безнең шәфәгатьчеләребез». Син аларга әйт: «Сез Аллаһыга җирдә вә күкләрдәге Үзе белмәгән нәрсәләрдән хәбәр бирәсезме? Ягъни Аның тиңдәше булып та, Үзе белми, сез беләсезме? Мөшрикләр

тиңдәш кылган нәрсәләрдән Аллаһы пакь вә бик бөек дәрәҗәдә». Шөгаиб галәйһиссәлам үз кавемен кешеләрне алдап байлык туплаудан тыйды. «Һуд» сүрәсенең 84 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

اِنِّىٓ اَرٰيكُمْ بِخَيْرٍ وَاِنِّىٓ اَخَافُ عَلَيْكُمْ عَذَابَ يَوْمٍ مُحِيطٍ ﴿٨٤﴾

«Иннии әраакүм бихайрин үә иннии әхаафү гәләйкүм гәзәәбә йәүмим-мүхиит (84)».

М ә г ъ н ә с е : *«Тәхкыйк, мин сезне бик күп байлыкта күрәмен һәм сезнең өчен куркамын, кыямәт көнне чолгап алачак тәмуг газабыннан (84)».*

Шөгаиб галәйһиссәлам, Мәдйән шәһәре халкын җыеп, аларны вәгазьләде: «И, кавемем, Аллаһыдан башка Илаһы юк. Сатканда-алганда тиешенчә бирегез. Алдап, кешеләрнең хәләл малын алмагыз, җирдә гөнаһ кылып яшәмәгез. Мин сезне үзем булдыра алганча туры юлга кертмәкче булам. Сезнең белән ачуланышырга вә сүз көрәштерергә теләмимим, тик мин сезнең эшләрегезне төзәтмәкчемен, чөнки Аллаһы Тәгалә сезнең сатканда һәм алганда кешеләрне алдавыгызны теләми. Вә дәхи ул сезнең кешеләрне талавыгызны һәм үтерүегезне теләми». Шөгаибнең искиткеч матур итеп сөйләгән һәр вәгазеннән соң берничә кяфер иман китерә иде. Ләкин күпчелеге иман китерергә теләмәделәр. «Һуд» сүрәсенең 87 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

قَالُوا يٰشُعَيْبُ اَصَلٰوتُكَ تَاْمُرُكَ اَنْ نَتْرُكَ مَا يَعْبُدُ اٰبَاؤُنَا اَوْ اَنْ نَفْعَلَ فِىٓ اَمْوَالِنَا
مَا نَشٰٓؤُا اِنَّكَ لَاَنْتَ الْحَلِيمُ الرَّشِيدُ ﴿٨٧﴾

«Каалүү йәә Шүгайбү әсаләәтүкә тәәмүрукә әннәтрукә мәә йәгбүдү әәбәә-үнәә әү әннәфгәлә фии әмүәәлинәә мәә нәшәәү. Иннәкә лә әңтәл-хәлиимүр-рашииде (87)».

М ә г ъ н ә с е : *«Кяферләр әйттеләр: «И, Шөгаиб! Аталарыбыз табынган сыннарыбыздан йөз чөерергә вә үзебезнең байлыгыбыздан ваз кичәргә синең намазың кушамы?» Көлеп әйттеләр: «Әлбәттә, сине шәфкатьле вә туры юлда йөрүче бер кеше дип беләбез (87)».*

Шөгаиб галәйһиссәлам эштән буш вакытларында гел намазда булып, калган вакытында үз кавемен иманга, ягъни бер Аллаһыга гына гыйбадәт кылырга вә сәүдә кылганда гадел булырга чакырды: «Мин сезнең өчен Аллаһы тарафыннан җибәрелгән рәсүлмен, Аннан куркыгыз вә Аңа гына гыйбадәт кылыгыз! Мин үземнең вәгазьләрем өчен сездән берни дә сорамыйм, чөнки минем эшемнең әҗере Хак Тәгалә кулында. Сәүдә иткәндә хәләл өлешне бирегез вә хәләл өлешне алыгыз, үлчәүләрегезне, герләрегезне үз файдагызга уйнатмагыз вә җирдә гөнаһ эшләр кылмагыз!»

«Һуд» сүрәсенең 88 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

قَالَ يٰقَوْمِ اَرَاَيْتُمْ اِنْ كُنْتُ عَلٰى بَيِّنَةٍ مِنْ رَبِّى وَرَزَقَنِى مِنْهُ رِزْقًا حَسَنًا وَمَا اُرِيدُ اَنْ اُخَالِفَكُمْ اِلٰى مَا
اَنْهٰيكُمْ عَنْهُ اِنْ اُرِيدُ اِلَّا الْاِصْلَاحَ مَا اسْتَطَعْتُ وَمَا تَوْفِيقِى اِلَّا بِاللّٰهِ عَلَيْهِ تَوَكَّلْتُ وَاِلَيْهِ اُنِيبُ ﴿٨٨﴾

«Каалә йәә кауми әраәйтүм иң күңтү гәләә бәййинәтиммирраббии үә разәкании минһү ризкан хәсәнә. Үә мәә үриидүән үфәәлифәкүм иләә мәә әнһәәкүм гәнһ. Ин үриидү илләл-исләәхә мәстәтагтү, үә мәә тәүфиикыйй илләә билләәһи гәләйһи тәүәккәлтү үә иләйһи үниибе (88)».

Мәгънәсе: *«Шөгаиб әйтте: «И, кавемем, уйлап карагыз, әгәр мин Раббымнан көчле дәлилләр белән килгән булсам вә миңа затлы ризыклар да бирелгән булса, ни әйтерсез? Аллаһы Тәгалә рөхсәт итмәгәннәрне эшләгәнегезне мин хуплый алмыйм. Моны мин фәкать Хак Тәгаләнең ярдәме белән генә башкара алам. Бары тик Аңа гына тәвәккәл иттем, бары тик Аңа кайтачакмын (88)».*

Үзенә ияргән мөселманнар белән бергә Шөгаиб галәйһиссәлам базарларда була. Алар ярлы, намуслы кешеләр, алганда вә сатканда беркемне алдамыйлар, беркемне таламыйлар, шулай ук сәяхәтчеләрнең акчаларын тартып алмыйлар. Шөгаиб галәйһиссәлам, кешеләр җыелган җиргә килеп, аларны бер Аллаһыга гыйбадәт кылырга өнди, әгәр алар җирдә явызлык эшләүләрен туктатмасалар, Хак Тәгаләнең җәзасы булачагы белән куркыта. Мондый татлы вәгазьләрдән соң янә берничә кеше иман китерә. Кяферләр, иман китергән бәндәләр бергәләшеп намаз укый алмасыннар өчен, аларның юлларын ябалар, кемнең дә булса аның янына баруын белсәләр,

ул кешене кыйныйлар вә талыйлар иде. Әйкә кавеме тәмам залим булды. Бу турыда Коръән Кәримнең «әл-Хиҗер» сүрәсе, 78 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَإِن كَانَ أَصْحَٰبُ ٱلْأَيْكَةِ لَظَٰلِمِينَ ۝٧٨

«Үә иң кәәнә әсхәәбүл әйкәти ләзаалимиин (78)».

М ә г ъ н ә с е : *«Дәхи Шөгаиб җибәрелгән Әйкә кавеме залим булдылар (78)».*

Шөгаиб алар янына килеп: «И, кавемем, җирдә явызлык вә әшәкелек кылмагыз, бу сезнең үзегез өчен дә яхшы булыр. Аллаһы Тәгаләгә иман китергәннәрнең юлларына аркылы төшеп, аларга янамагыз вә аларны хак юлдан яздырырга тырышмагыз. Аллаһының җәзасыннан куркыгыз. Ул элегрәк Нух кавемен, Һуд кавемен, Салих кавемен кылган бозыклыклары өчен җәзалады, әле күптән түгел бозыклыклары илә даннары таралган Лут кавемен һәлак итте, шулардан гыйбрәт алып иманга килегез», — дип вәгазьләде.

Коръән Кәримнең «Һуд» сүрәсе, 89 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَيَٰقَوْمِ لَا يَجْرِمَنَّكُمْ شِقَاقِىٓ أَن يُصِيبَكُم مِّثْلُ مَآ أَصَابَ قَوْمَ نُوحٍ أَوْ قَوْمَ هُودٍ أَوْ قَوْمَ صَٰلِحٍ ۚ
وَمَا قَوْمُ لُوطٍ مِّنكُم بِبَعِيدٍ ۝٨٩

«Үә йәкауми ләә йәҗри мәннәкүм шифәә фии әййүсыййбәкүм-мислү мәә әсаабә каумә Нүүхин әү каумә Һүүдин әү каумә Саалих. Үә мәә каумү Лүүтыйм-миңкүм бибәгииде (89)».

М ә г ъ н ә с е : *«И, кавемем! Сак булыгыз, миңа карышуыгыз Нух кавеменә яки Һуд кавеменә, яки Салих кавеменең башына килгән җәзалар сезнең дә башыгызга төшмәсен иде. Гөнаһлары өчен җәзаланган Лут кавеме сездән ерак түгел (89)».*

Әйкә кяферләре аннан көлеп әйттеләр: «И, Шөгаиб, бар, әйт үзеңнең Аллаһыңа, Ул безгә син әйткән үлемне җибәрсен. Буш сүзләрең белән безнең башларны катырма, барыбер тыңламыйбыз синең ул буш сүзләреңне. Арабызда сине бик зәгыйфь дип беләбез, әгәр синең яныңда иман китергән безнең кардәшләребез булмаса, без сине ташлар белән бәреп үтергән булыр идек». Шуннан соң кяферләр иман китергән-

нәргә карата тагын да начаррак мөнәсәбәттә булдылар. Алар элеккечә үк сәяхәтчеләрне талыйлар, алганда вә сатканда алдыйлар, Аллаһыдан вә гөнаһтан һич курыкмыйлар, Шөгаибнең сөйләгәннәрен тыңларга да теләмиләр. Ниһаять, аларның беркайчан да тыңламаячакларына ышанып, Шөгаиб галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә багышлап дога кылды: «И, Рабым Аллаһ! Мин хәлемнән килгәннең барын да эшләдем, ләкин аларның явызлыклары иман китерүчеләргә карата тагы да артты, иман китерүчеләр вә кяферләр үз өлешләрен алсыннар, ярдәмеңнән ташлама», — диде. Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул кылды һәм Шөгаиб галәйһиссәлам янына Җәбраил фәрештәне иңдерде. Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Аллаһы Тәгалә сиңа сәлам күндерде вә синең догаңны кабул кылды. Бу явыз кяферләр үз өлешләрен, ягъни тәкәбберлекләре өчен җәзаларын алачаклар, ә син үзеңә ияргән мөселманнар белән Мәдйән шәһәреннән чыгып тор, бездән хәбәр булгач, шәһәргә кире кайтырсыз», — диде.

«Һуд» сүрәсенең 94 нче аятендә бу хакта Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَلَمَّا جَآءَ أَمْرُنَا نَجَّيْنَا شُعَيْبًا وَالَّذِينَ ءَامَنُوا مَعَهُ بِرَحْمَةٍ مِّنَّا وَأَخَذَتِ الَّذِينَ ظَلَمُوا
الصَّيْحَةُ فَأَصْبَحُوا فِي دِيَارِهِمْ جَٰثِمِينَ ﴿٩٤﴾

«Үә ләммәә җәә-ә әмрунәә нәҗҗәйнәә шүгәйбәү-үәлләзинә әәмәнүү мәгәһү бирахмәтим-миннә. Үә әхазәтил-ләзинә заләмүс-сайхәтү фә-әсъбәхүү фии дийәәриһим җәәсимиин (94)».

Мәгънәсе: *«Газап килергә әмеребез булгач, Шөгаибне вә аңа иярген мөэминнәрне Үзебезнең рәхмәтебез илә газаптан коткардык. Әмма залим кяферләргә Җәбраилнең тавышы ирешә, алар өйләре эчендә ябышып каттылар (94)»*.

Моны дәвам итеп, Аллаһы Тәгалә «Һуд» сүрәсенең 95 нче аятендә әйтә: «Гүя алар йортларында һич тормаган шикелле булдылар. Сәмуд кавеме Аллаһының рәхмәтеннән ерак булган кеби, Мәдйән халкы да Аның рәхмәтеннән ерак булды». Бу афәттән котылганнан соң, Шөгаиб галәйһиссәлам бик озак яшәде. Күп вакытын намазда вә гыйбадәттә үткәрде, һәр намаздан соң шөкрана кылды. Аллаһы Тәгалә аңа озын гомер вә күп байлык бирде. Ул 254 ел гомер кичереп вафат булды.

# МҮСА ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Муса пәйгамбәрнең вә аның бертуганы Һарун галәйһиссәламнең аталары — Гыймран, аның атасы — Йәсһир, аның атасы — Райан, аның атасы — Ләүйә, аның атасы — Ягъкуб галәйһиссәлам, аның атасы — Исхак галәйһиссәлам, аның атасы Ибраһим галәйһиссәлам иде.

Муса галәйһиссәлам атабыз Адәм галәйһиссәлам вафатыннан 3836 ел үткәч, туфаннан соң 440 елдан соң дөньяга килә. Хәзрәти Муса бәни Исраилдән, ягъни хәзрәти Ягъкуб нәселеннән Гыймран исемле кешенең углы иде. Бәни Исраилнең унике кабиләсе булып, һәркайсы хәзрәти Ягъкубның бер углының нәселедер. Бәни Исраил халкы Йосыф пәйгамбәр Мисырда падишаһ булгач күчкән иделәр. Мисыр халкы исә кобтыйлар иде. Алар үзләре ясап куйган потларга, кояш, ай, йолдызларга һәм фиргавенгә табыналар иде. Кобтыйлар бәни Исраил халкына бик дошман иделәр. Барлык авыр, пычрак эшләрне бәни Исраил халкына эшләтәләр иде. Бәни Исраил халкы бабалары гомер кичергән Кинган җирләренә китәргә телиләр иде. Ә кобтыйлар исә бәни Исраил халкының Мисырдан китүләрен теләмиләр иде. Бу заманда Мисыр мәмләкәтенең падишаһы фиргавен Вәлид Мәсгаб углы иде. Йосыф галәйһиссәлам вафатыннан соң падишаһ булып Мәсгаб калган иде. Ул үзен һәр җирдә фиргавен дип атарга кушты. Аның вафатыннан соң урынына углы Вәлид калды. Вәлид фиргавен Аллаһы Тәгаләнең барлыгын, берлеген инкарь кылып, гаять күп бозыклык кылучы булды. Хәтта горурлык вә тәкәбберлеге илә үзен җирдәге тәңре дип атарга җөрьәт кылды (Әстәгъфируллаһ).

Бервакыт фиргавен төш күрде. Бәйтелмөкаддәс ягыннан ут чыгып, фиргавен кавеменең өйләрен яндырды, бәни Исраил яшәгән йортларга һичбер зарар килмәде. Иртә торгач, фиргавен барча төш юраучыларны вә дәхи мөнәҗҗимнәрен, ягъни йолдызларга карап киләчәктән хәбәр бирүчеләрен җыеп, төшенең тәгъбирен сорады. Багучылар озак киңәшкәннән соң әйттеләр: «Бу елны бәни Исраил кавемендә бер ир бала дөньяга киләчәк һәм синең мәшһүр дәүләтеңне, вә синең үзеңне

һәлак итәчәк». Фиргавен бу сүзләрдән гаять курыкты, бәс, әмер бирде: «Бу елда бәни Исраил таифәсеннән туган барча ир балалар үтерелергә тиеш», — дип, бәни Исраилнең корсаклы хатыннарына каравылчылар куелды. Ир балалар туса, үтерелде, кыз балалар калдырылды. Гыймран хатыны Ләүханың корсагын карадылар, әмма аның корсаклы икәнен белмәделәр, алай да ике кобтый хатынын каравылга куйдылар. Бу көннәрдә Гыймран вафат булды, аны җирләп кайткан көнне каравылчы хатыннар килмәделәр, шул көнне Ләүха Муса галәйһиссәламне тудырды. Газиз баласының гомерен саклап калу өчен, аны сандыкка салып, Нил дәрьясына төшерде. Үзенең өлкән кызына, ягъни Мусаның апасына әйтә: «Кызым, сандыкны агым кая алып барыр, шуны карап тор», — диде. Кыз бөтенесен әнисе кушканча эшләде.

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте илә, сандык фиргавен сарае янына килеп туктады. Фиргавеннең хатыны Асиябикә үзенең җария кызлары белән Нил дәрьясы буена ял итәргә, күңел ачарга чыккан чак иде, ул хезмәтчеләренә сандыкны тартып чыгарырга кушты. Сандыкны ачып, андагы бик матур баланы күргәч, Асиябикә бик шатланды, чөнки аларның үзләренең балалары юк иде. Баланы күтәреп, ире Вәлид янына сарайга ашыкты: «И, Вәлид, безнең балабыз юк иде, Тәңребез безгә бу баланы бүләк итте, әйдә, бу баланы үзебезгә алыйк та, ул безнең тормышыбызның бер бизәге булыр», — диде. Ире фиргавен башта моңа каршы булса да, баланың сәламәт, матур булуын вә хатынының бу балага җаны-тәне белән биреләгәнен күреп, риза булды.

Асиябикә балага сөт анасы табарга кушты. Ләкин бала тәкъдим ителгәннәрнең һичкайсының имчәген капмый. Бала үлмәгәе дип куркуга калалар. Шулчак Муса галәйһиссәламнең апасы: «Минем әниемнең сөте бик тәмле иде, риза булсагыз, мин аны бирегә чакырам, бала бәлки аның сөтен кабул итәр», — диде. Фиргавен аңа: «Тик тиз бул, күрәсең бит, бала чак сулыш ала», — дип аны ашыктырды. Кыз тиз генә әнисе янына кайтты да аны сарайга алып килде. Газиз углын күргәч, ананың йөрәге сикерә башлады, әмма беркем берни сизмәсен өчен, тыныч булырга тырышты. Балага имчәген биргәч, ул аны шунда ук имә башлады. Сарайдагы барча кеше җиңел сулап куйды. Әни кешенең исә шатлыгы барсыныкын-

нан да артыграк иде, чөнки ул сарайда бала ашатучы булып эшләп калды. Бала көн-төн диярлек аның белән, ана өчен моннан да зур шатлыкның булуы да мөмкин түгел. Бу турыда «әл-Касас» сүрәсенең 13 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فرددنه إلى أمه كى تقر عينها ولا تحزن ولتعلم أن وعد الله حق ولكن أكثرهم لا يعلمون ١٣

«Фәрадәднәәһү иләә үммиһии кәй тәкарра гәйнүһәә үә ләә тәхзәнә үәлитәгләмә әннә үәгдәлләәһи хәккун үә ләәкиннә әксәраһүм ләә йәгләмүүн (13)».

М ә г ъ н ә с е : *«Мусаны анасына кайтардык, баласын күреп, күзе вә җаны шатлансын, көенмәсен һәм дә Хак Тәгаләнең вәгъдәсе хак икәнне белсен өчен, ләкин күпчелек кешеләр Аллаһының эше һәм вәгъдәсе хак икәнне белмиләр (13)».*

Муса галәйһиссәлам куе кара чәчле, озын буйлы, көчле, зирәк зиһенле бер егет булып үсеп җитте. Фиргавен сараендагы галимнәрдән ул күп гыйлем алды. Бәни Исраил халкы һәм кобтыйлар аны фиргавен углы дип таныйлар. Ә ул үзе эченнән генә булса да бәни Исраил кавеменнән икәнлеген сизенә. Үз халкының шундый мөшкел хәлдә булуына бик борчыла. Фиргавенгә карата аның эчендә ачу кайный.

Көннәрнең берендә Муса галәйһиссәлам сарайдан чыгып, Мисыр шәһәре урамы буйлап бара иде. Юлда ул бәхәсләшүче ике ирне күрде. Аларның берсе бәни Исраил кавеменнән, икенчесе кобтый кешесе иде. Бәни Исраил кешесе аннан ярдәм сорады. Муса галәйһиссәлам кобтый кешесенә йодрыгы белән шундый иттереп сукты ки, тегесе шунда ук җан тәслим кылды. Муса галәйһиссәлам бу эшенә бик үкенеп, Аллаһы Тәгаләнең ярлыкавын сорады. «Әл-Касас» сүрәсенең 16 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

قال رب إنى ظلمت نفسى فاغفر لى فغفر له إنه هو الغفور الرحيم ١٦

«Каалә Рабби иннии заләмәтү нәфсии фәгъфирлии фәгафәра ләһ. Иннәһүү һүәл гафүүрур-рахиим (16)».

М ә г ъ н ә с е : *«Муса галәйһиссәлам үкенеп әйтте: «Йә, Раббым! Кеше үтерү сәбәпле, үземә золым иттем, зинһар мине ярлыка!» Хак Тәгалә аны ярлыкады, тәхкыйк, Ул Аллаһы — ярлыкаучы вә рәхмәт кылучыдыр (16)».*

Соңра Муса галәйһиссәлам Мисыр шәһәрендә курыккан хәлдә хөкем көтеп калды. Шулчак кичә кобтый белән сугышканда Мусадан ярдәм сораган кеше, бүген дә бер кобтый кешесе белән сугышып, янә Мусадан ярдәм сорады. Муса ярдәм сораучыга әйтте: «Дөреслектә, син бер азгын кеше икәнсең, кичә бер кешене миннән үтерттең, бүген тагын үтертмәкче буласыңмы?» — диде. Кинәт Муса галәйһиссәлам янына бер ир кеше килеп әйтте: «И, Муса, кобтыйлар сине үтерергә киңәш иттеләр. Син бу шәһәрдә торма, тизрәк кач, мин сиңа яхшы киңәш бирүчеләрдәнмен», — дип, аңа Мәдйән шәһәренең юлын күрсәтеп җибәрде. Ул, авылдан-авылга керә-керә, Мәдйән шәһәренә килеп җитте. Мәдйәннең кое суына җиткәндә, ул кое янында хайваннарны эчерүче кешеләрне күрде. Алардан читтәрәк үзләренең сарыкларын су янына җибәрмичә саклаучы ике кызны күрде. Муса галәйһиссәлам кызлардан сорады: «Нишләп сез үз сарыкларыгызга су эчермисез?» Алар әйттеләр: «Сез күргән көтүчеләр хайваннарын эчереп китмичә, без эчермибез. Безнең атабыз бик карт кеше, шул сәбәпле хайваннарны эчерергә үзе чыга алмый, коеның чиләге бик зур булганлыктан, коедан су ала алмыйбыз, фәкать башка көтүчеләрдән калган суны эчерәбез». Шуннан соң Муса галәйһиссәлам бу кызларның сарыкларын кое янына алып барып, коедан су алып, аларны эчерде. Алар аңа рәхмәтләр әйтеп, сарыкларны өйләренә кудылар. Муса галәйһиссәлам исә, агач күләгәсенә утырып, Аллаһы Тәгаләдән тамагын туйдыруын вә фиргавеннән коткаруын сорады.

Кызлар кайтып аталарына Муса галәйһиссәлам турында сөйләделәр. Аталары бер кызын Муса галәйһиссәламне чакырырга җибәрде. Ул шулай утырганда кызларның берсе, бик оялып кына, Муса галәйһиссәлам янына килеп әйтте: «Безнең сарыкларыбызны эчерткәнең өчен әтиебез шуның хакын бирергә уйлый, үзе янына чакыра». Муса галәйһиссәлам кызларның атасы Шөгаиб пәйгамбәр белән таныша. Башыннан кичкән вакыйгаларны сөйләп бирә. Шөгаиб галәйһиссәлам аны тынычландыра вә әйтә: «И, Муса, курыкма, залим фиргавеннән котылдың инде, бирердә аның фәрманы йөрми». Ике кызның берсе әйтә: «И, атам, бу кешене, хакын түләп, көтүчелеккә ал, ул хак түләп алган кешеләрнең хәерлесе, куәтлесе вә әманәтлеседер». Шөгаиб галәйһиссәлам әйтте: «И, Муса,

мин ошбу ике кызымның берсен сиңа хатынлыкка бирергә телим, куйларымны сигез ел көтүең бәрабәренә. Әгәр ун елга тутырсаң, анысы синең изгелегеңнән булыр. Аллаһы теләсә, син минем игелекле кеше икәнемне күрерсең». Муса галәйһиссәлам әйтте: «Ошбу шарт синең белән минем арабыздадыр, Аллаһы Тәгалә шаһиттер, мин ризамын».

Өстенә алган мөддәтне үтәгәч, Муса галәйһиссәлам Шөгаибнең кызына никахланып, хатыны белән Мисырга барырга чыкты. Тур тавы янында ут күрде һәм хатынына әйтте: «Шул җирдә торыгыз, мин ут күрдем, шаять, ут янында кешеләрдән юлны сорашып, ут та алып килермен, аның янында җылынырбыз». Ут янына килгәч, ул йөзем агачын күрде, аннан аваз килде: «И, Муса! Мин — барча галәмнәрнең тәрбиячесе Хак Тәгаләмен! Мин сине һәм синең бертуганың Һарунны Үземнең пәйгамбәрем итеп сайладым. Фиргавенне җиңәр өчен, сиңа берничә могҗиза бүләк итәм. Таягыңны ташла!» Муса галәйһиссәлам таягын ташлады, таяк зур кара еланга әверелеп, төрле хәрәкәтләр ясый башлаганын күргәч, куркып артка чигенде. Янә аваз килде: «И, Муса, курыкма, таягыңны кулыңа ал, ул сине күп бәлаләрдән коткарыр».

Тагын бер могҗиза, кулыңны култык астына тык, ул аннан зарарсыз хәлдә якты нур чәчеп чыгар, әгәр дә кулыңның нур чәчеп торуын теләмисең икән инде, яңадан култык астына тык, әүвәлге халәтенә кайтыр. Таяк һәм нур чәчә торган кулың тәкәббер фиргавенне җиңәргә ярдәм итәрләр».

Муса галәйһиссәлам хатыны янына барып, булган хәлне сөйләп бирде. «Безгә хәзер үк Мисырга барырга кирәк, анда туганым Һарунны эзләп табып, аның белән фиргавенне иманга өндәргә тиешбез, Аллаһы Тәгаләнең әмере шулай», — дип, Мисыр тарафына юнәләләр.

Муса галәйһиссәлам Мисырда туганы Һарун галәйһиссәламне эзләп тапкач, үзе белән булган вакыйганы сөйләп бирде. «Аллаһы Тәгалә сине дә Үзенең пәйгамбәре итеп сайлады һәм, фиргавенгә кереп, аны Ислам диненә өндәргә безгә боерды. Ул миңа могҗизалы таяк һәм нурлы кул бирде, без синең белән курыкмыйча Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәргә тиешбез», — дип, Муса галәйһиссәлам туганы Һарун галәйһиссәламне фиргавен сараена алып барды. Фиргавен янына кергәч, Муса галәйһиссәлам әйтте: «Мин һәм минем берту-

ганым Һарун — Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләнең сайлап куйган пәйгамбәрләре. Ул сиңа бер Аллаһыга гыйбадәт кылырга вә дәхи барча бәни Исраил кавемен ирекккә җибәрергә әмер кылды. Пәйгамбәрлегемә дәлил итеп, Хак Тәгалә менә бу могҗизалы таякны һәм син күреп торган нур чәчеп торучы кулны бүләк итте». Фиргавен җавабында: «Без уллыкка алып тәрбияләгән, шуннан соң кеше үтереп качкан Муса түгелме син?» — диде. «Әйе, мин шул Муса, әмма мин шул вакытта ук Аллаһы Тәгалә каршында тәүбә-истигъфар кылдым, Ул мине кичерде, миңа гыйлем бирде һәм Үзенең рәсүле итеп таныды һәм сине иманга өндәргә җибәрде», — дип, Муса галәйһиссәлам таягын фиргавен каршысына ташлады. Таяк зур бер еланга әверелде, фиргавен куркып калды һәм әйтте: «Ярый яхшы, фәлән көнне мин үземнең барча сихерчеләремне җыярмын, менә шул вакытта кем көчлерәк икәне ачыкланыр», — дип, аларга ышанмыйча сараеннан чыгарып җибәрде.

Билгеләнгән көнне сарай алдындагы зур мәйданга кобтый түрәләре һәм, Муса галәйһиссәлам белән Һарун галәйһиссәламнең җиңүен теләп, бәни Исраил кавеме җыелды. Мисыр иленең бөтен почмакларыннан җыелган сихерчеләр фиргавенгә: «Әгәр җиңсәк, бүләкләрсеңме безне?» — дип сорадылар. Фиргавен: «Әйе, бүләгем зурдан булыр», — дип җавап кайтарды.

Сихерчеләр Мусадан: «Әүвәл булып кем башлый: синме, безме?» — дип сорадылар. Муса әйтте: «Сез башлагыз». Алар үзләренең бауларын вә таякларын мәйдан уртасына ташлый башладылар. Бу баулар вә таяклар еланга әверелеп, зур мәйдан еланнар белән тулды, Муса күңеленнән шикләнә дә башлады, әмма шул вакыт Аллаһы Тәгаләдән вәхи килде: «И, Муса, бернидән дә курыкмыйча, таягыңны җиргә ташла». Муса галәйһиссәлам таягын җиргә ташлады, ул бик зур еланга әверелде. Авызын зур итеп ачып, уң вә сул тарафка борыла-борыла, тиз-тиз еланнарны йота башлады. Халык исе китеп бу тамашаны карый. Күп тә үтми, Муса галәйһиссәламнең еланы барча еланнарны кабып йотты. Шуннан соң Муса галәйһиссәлам аны кулына алды, ул яңадан таякка әверелде. Хаклык өскә чыкты, аларның сихергә таянып, күз буып эшләгән эшләре юкка чыкты, ягъни фиргавеннең сихерчеләре җиңелеп хур булдылар. Алар, Муса галәйһиссәламнең могҗизасын күреп, иман китерделәр вә дәхи Аллаһы Тәгаләгә сәҗдә

кылдылар. Моны күргәч, фиргавен әйтте: «Мин рөхсәт бирмичә, Мусага иман китерергә ничек җөрьәт иттегез, моның өчен мин сезнең уң кул вә сул аякларыгызны кистерәм, соңра астырам, җирдә тәңре мин генә, хәзер үк Муса вә Һарунның Раббысыннан ваз кичегез». Сихерчеләр әйттеләр: «Без синең җәзаңнан курыкмыйбыз, чөнки син безне бу дөньяда җәзаласаң, Аллаһы Тәгалә безне мәңгелек дөньяда Үзенең җәннәтенә урнаштырачак. Теләсәң нишлә, әмма без элекке динебезгә кайтмаячакбыз». Фиргавен аларны үзе әйткәнчә җәзалап үтерде. Аларның берсе дә иманнарыннан кире кайтмадылар.

Шушы көннәрдә Нил дәрьясының суы күтәрелеп, шәһәрләр вә авыллар бер-бер артлы су астында кала башладылар. Фиргавен, моның Муса вә Һарун галәйһиссәлам эше икәнен белеп, әйтте: «Су басуны туктатуны сорап, Раббыңа дога кыл, мин Аңа иман китерермен, синең белән бәни Исраил кавемен җибәрермен». Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләдән бәла-казаны туктатуны сорап, дога кылды. Хак Тәгалә аның догасын кабул итте, су кире үз ярларына кайтты. Әмма фиргавен иман китермәде, бәни Исраил кавемен газаплавын да дәвам итте. Аллаһы Тәгалә фиргавен кавеменә саранча явы җибәреп бәлаләндерде, бөтен җирне бака басты, фиргавен кавеменең барча киемнәре бет белән тулды, сөтләре вә барча сулары канга әверелде. Фиргавен Муса галәйһиссәламгә әйтте: «Әгәр илне бу бәлаләрдән коткарсаң, мин иман китерермен, шулай ук бәни Исраил кавемен синең белән җибәрермен», — дип вәгъдә кылды. Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә дога кылды, догасы кабул булды, бу афәтләр юкка чыкты, тик фиргавен үзенең вәгъдәсендә тормады.

Бәни Исраил кавеменең акыллылары әйттеләр: «Без барыбыз да Мисырдан китәргә тиешбез, чөнки фиргавен безне яңадан да җәзалый башлаячак, тик бу хакта кобтый кавеменнән булганнарның берсе дә белмәскә тиеш. Гает бәйрәменә чыгабыз дип, хатыннарыбыз да барлык булган алтын-көмешләрен кобтыйлардан алсыннар». Төнлә ай калыкканны көттеләр, барлык кирәк-яракларын, алтын-көмешләрен алып, юлга чыктылар. Китүләрен беркем дә белмәсен өчен, тизрәк барырга тырыштылар. Алар көнчыгышка таба, ягъни Кызыл диңгезгә таба киттеләр. Берничә көн кайнар кояш астында шулай барганнан соң, алар Кызыл диңгез ярларына килеп җиттеләр.

Мисырда калган фиргавен берничә көн күп гаскәр җыеп, бәни Исраил кавемен куа китте. Кызыл диңгез ярларында ул аларны куып җитте. Бәни Исраил халкы, бик куркып, Муса галәйһиссәламгә әйттеләр: «Безнең газапларыбыз, бәлаләребезнең сәбәпчесе — син. Фиргавен безне хәзер кырып бетерәчәк, алда дәрья, артта фиргавен гаскәре, авыр хезмәт үлемнән яхшырак», — дип, Мусаны гаепләделәр. Муса галәйһиссәлам аларга әйтте: «Курыкмагыз, сезне фиргавен газабыннан коткарган Аллаһы Тәгалә үлемнән дә һичшиксез коткарыр. Миңа таягым белән суга сугарга вәхи килде», — дип, ул таягы белән суга сукты. Су икегә аерылды, коры юл пәйда булды, ике якта, таулар кебек, дәрья суы тора.

Аллаһы Тәгаләнең ярдәме илә үз алларында ачылган юлны күргәч, бәни Исраил кавеме шунда ашыктылар. Курку аларны тизрәк йөгерергә мәҗбүр итте. Алар шулай икенче ярга чыгып җиткәнче йөгерделәр. Фиргавен гаскәре бәни Исраил кереп киткән коры юл белән диңгезгә керделәр, диңгез кушылып, һәммәсе дә һәлак булдылар. «Юныс» сүрәсенең 90–92 нче аятьләрендә әйтелә:

وَجَاوَزْنَا بِبَنِىٓ إِسْرَٰٓءِلَ ٱلْبَحْرَ فَأَتْبَعَهُمْ فِرْعَوْنُ وَجُنُودُهُۥ بَغْيًا وَعَدْوًا حَتَّىٰٓ إِذَآ أَدْرَكَهُ
ٱلْغَرَقُ قَالَ ءَامَنتُ أَنَّهُۥ لَآ إِلَٰهَ إِلَّا ٱلَّذِىٓ ءَامَنَتْ بِهِۦ بَنُوٓا۟ إِسْرَٰٓءِلَ وَأَنَا۠ مِنَ ٱلْمُسْلِمِينَ ﴿٩٠﴾ ءَآلْـَٔـٰنَ
وَقَدْ عَصَيْتَ قَبْلُ وَكُنتَ مِنَ ٱلْمُفْسِدِينَ ﴿٩١﴾ فَٱلْيَوْمَ نُنَجِّيكَ بِبَدَنِكَ لِتَكُونَ لِمَنْ خَلْفَكَ
ءَايَةً وَإِنَّ كَثِيرًا مِّنَ ٱلنَّاسِ عَنْ ءَايَٰتِنَا لَغَٰفِلُونَ ﴿٩٢﴾

«Үә җәәүәзнәә бибәнии Исраaиилəл-бәхра фә-әтбәгәһүм фиргәүну үә җунүүдүһү бәгъйән үә гәдүән, хәттәә изәә әдракәһүл-гарку каалә әәмәнтү әннәһү ләә иләәһә илләлләзии әәмәнәт биһии бәнүү Исраaиилә үә әнә минәл-мүслимиин (90). Әәл-әәнә үә кадгәсъйәтә каблү үә күңтә минәлмүфсидиин (91). Фәл-йәүмә нүнәҗҗиикә бибәдәникә литәкүүнә лимән халфәкә әәйәтә. Үә иннә кәсиирам-минәннәәси гән әәйәәтинәә ләгаафилүүн (92)».

М ә г ъ н ә с е : *«Бәни Исраилне дәрья аркылы үткәрдек, тәкәбберлек вә дошманлык белән алар артыннан фиргавен вә аның гаскәре куып чыктылар. Бәни Исраил өчен ачылган*

*су аралыгына кереп бата башлагач, фиргавен әйтте: «Иман китердем, гыйбадәт кылырга яраклы Илаһы юк, мәгәр бәни Исраил иман китергән Аллаһы Тәгалә генәдер, вә мин мөселманнарданмын» (90). Аллаһы Тәгалә әйтте: «Хәзер иман китерәсеңме? Башта Аллаһыга гасый вә бозыклык кылучылардан идең» (91). Сездән соң киләчәк кешеләргә гыйбрәт булсын өчен, тәнегезне су өстенә чыгарабыз. Ләкин кешеләрнең күпчелеге Безнең гыйбрәтләнерлек аятьләребездән гафилләр, һич вәгазьләнмиләр (92)».*

Фиргавеннең соңгы минутта иман китерүе ярдәм итмәде, ул вә аның гаскәре тончыгып үлде. Башкаларга гыйбрәт булсын өчен, фиргавеннең вә аның гаскәренең үле гәүдәләре өскә чыгарылды. Бәни Исраил кавемен фиргавеннән коткарганнан соң, Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламгә Синай чүлендәге Тур тавына килергә кушып вәхи иңдерде. Аның кавеменә Хак Тәгалә бытбылдык ите белән бал иңдерде. Муса галәйһиссәламгә кыяга сугарга кушты, җир астыннан берсеннән берсе тәмле унике чишмә бәреп чыкты, бәни Исраил кавеменең унике кабиләсенең һәркайсының үз чишмәсе вә тәмле ризыклары булдырылды. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә Мусага Тәүратны алу өчен Тур тавына менәргә боерды.

Тау башында Муса галәйһиссәлам кырык көн булды. Тәүратта аның үзе өчен вә дәхи бәни Исраил кавеменә файдалы васыятьләр, ярагaн вә ярамаган гамәлләр, тыныч вакытта вә сугыш булганда үзара мөнәсәбәт, дөньялыкта яшәр өчен белергә тиешле тагын бик күп нәрсәләр өйрәтелде. Боларны кабул итеп алгач, Муса галәйһиссәлам: «И, Раббым! Үзеңне миңа күрсәтче?» — дип ялынды. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Син бел! Бу җиһанда яшәүче беркем дә мине күрмәячәк. Мин караган тауга кара». Муса аяклары астындагы тауга карады. Тау селкенде, калтырады, Хак Тәгаләнең карашы астында вак кисәкләргә таркалды, ә бәгъзе җирләрдә эреп, сыек хәлгә килде. Гаҗәпкә калган вә искиткеч курыккан Муса галәйһиссәлам, аңын югалтып, җиргә ауды. Аңына килгәч, Аллаһы Тәгалә аңа әйтте: «Син инде минем нинди куәткә ия икәнлегемне күрдең, хәзер үзеңнең кавемеңә Тәүратта язылганнарны ирештер!»

Муса галәйһиссәлам Тәүратны алып төшкәч, үз кавеменең алтын бозауга табынуларын күрде, бик нык ачуы килеп, туганы Һарунның чәченнән вә сакалыннан сөйрәп әйтте: «И, Һарун,

кавемең бозауга табынганда, син ник аларны тыймадың?» Һарун әйтте: «И, туганым, алар минем сүземне тыңламадылар, әгәр мин алар белән сугышсам яки аларны ташлап китсәм, ник минем сүземне тотмадың дип ачулануыңнан курыктым».

Бераз тынычлангач, Муса галәйһиссәлам аларга үзе алып төшкән Тәүратны өйрәтте. Аннары алар юлга чыктылар һәм Фәлестин җирләренә килеп җиттеләр. Биредә Муса галәйһиссәлам аларны сугышырга өйрәтте. Ул аларга әйтте: «Аллаһы Тәгаләдән вәхи иңде, без бу потларга табынучы мәҗүси кавем белән сугышып, җиңәргә тиешбез, вә бу җирләрдә урнашып, рәхәт тормыш корырга безгә Хак Тәгалә Үзе ярдәм итәчәк, Ул үзенең вәгъдәсенә хилафлык кылмый».

Бәни Исраил халкы әйтте: «И, Муса, әгәр син көчле икәнсең һәм Аллаһың көчле икән, нигә сиңа ул мәҗүсиләргә каршы Аның белән бергә сугышмаска? Әйт үзеңнең Аллаһыңа, Ул аларның барысын да һәлак итсен, шуннан соң без ул җиргә керербез». Бу сүзләрне ишеткәч, Муса галәйһиссәлам бик нык борчылып, Аллаһы Тәгаләгә әйтте: «И, Раббым! Син күреп торасың, үземнең туганымнан башка беркемне дә тыңлата алмыйм, шунлыктан Син безнең белән динсезләр арасын аер», — дип дога кылды. Догасы кабул булды. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Инде аларга бу шәһәргә керүне кырык елга чаклы хәрам кылдым. Кырык ел үтмичә, анда керә алмаслар, хәйран булып, сахрада адашып йөрерләр. И, Муса, фасикъ кавемең өчен кайгырма, Безнең сүзләребезне инкарь итсәләр, җәзаларын да үзләре алырлар».

Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламгә ул белми торган күп нәрсәләрне өйрәтте, тәкъва акыл иясе Хозыр галәйһиссәлам белән очраштырды. Муса галәйһиссәлам аңа әйтте: «Үзең өйрәнгән хак юлны вә гыйлемлекне өйрәнү өчен мин сиңа иярә аламмы?» Хозыр галәйһиссәлам әйтте: «Яхшы, минем белән барасың килә икән, мин сүз башламый торып, миннән бернинди дә җавап ишетмәссең, мин сиңа үзем аны бәян иткәнче, шуңа түземлегең җитсә, мин сине үзем белән алам». Муса галәйһиссәлам аннан берни дә сорамаска риза булды.

Алар бер көймәгә утырдылар. Ярга чыккач, Хозыр галәйһиссәлам көймә төбен балта белән тиште. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Көймәнең төбен тишеп, син һич тә ярамаган эш кылдың!» Хозыр галәйһиссәлам бер сүз дә эндәшмәде.

Көймәдән төшеп, юл белән киттеләр. Юлда уйнап йөрүче бер матур сабыйны күреп, Хозыр галәйһиссәлам аны үтерде. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Гөнаһтан пакь баланы үтердең, дөреслектә, син бу юлы тагы да яманрак эш кылдың». Хозыр галәйһиссәлам янә бер сүз дә эндәшмәде.

Болар икәү юлларын дәвам иттеләр. Бик озак баргач, бер шәһәргә килеп җиттеләр. Шәһәр кешеләреннән ашарга сорадылар, әмма шәһәрдә боларга беркем дә ризык бирмәде. Шәһәр буйлап шулай барганда, аварга торган бер койма янында Хозыр галәйһиссәлам туктап аны төзәтә, тирә-юненә балчык өя башлады. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Ач көе шушы беркемгә кирәкмәгән койманы төзәтәсең. Әгәр теләсәң, бу хезмәтең өчен хак алган булыр идең, шул бәягә ашарга алган булыр идек», — диде. Хозыр галәйһиссәлам әйтте: «Безгә синең белән аерылышыр вакыт җитте. Мин эшләгәндә сабыр гына, дәшмичә карап торырга чыдамлыгың җитмәгән нәрсәләрнең серен хәзер сиңа бәян кылам. Мин тишкән көймә ошбу судан балык тотып, шуның белән кәсеп иткән фәкыйрь кешенеке иде. Иртәгә бу җиргә аларның көймәләрен вә анда булган балыкларын тартып алучы залим патша киләчәк иде. Ул яхшы көймәләрне тартып алачак, ә бу мескеннең көймәсе үзендә калачак. Ул, аның төбенә ямау салгач, янә балык тотачак.

Мин үтергән балага килгәндә, Хак Тәгалә миңа хәбәр бирде, ул баланың ата-анасы мөэминнәр, ә бу бала динсез вә азгын, үсеп җиткәч, ул ата-анасына һәм туганнарына бик күп җәфалар китерәчәк иде. Тиз вакытта аның ата-анасы мәрхәмәтле вә шәфкатьле бер бала табачаклар, ул бала тугач, алар кайгыларын тиз көннәрдә онытачаклар.

Ач көе мин турайткан коймага килгәндә, ул койма астында ике ятим балага дип яшерелгән хәзинәләр бар иде. Аларның аталары иманлы, изге кеше иде, шунлыктан Аллаһы Тәгалә аларның, үсеп җитеп, үз хәзинәләрен үзләре алып кирәк җиргә файдалануларын теләде. Әгәр дә мин коймага аварга ирек куйсам, хәзинә күренер иде һәм хәзинәгә бернинди дә катнашы булмаган кешеләр аны исраф итеп бетерерләр иде. Ә хәзер хәзинә исән-имин койма астында калды. Малайлар үсеп җиткәч, алар аны алып файдаланачак. Аллаһы Тәгалә әнә шулай теләде, ә мин бары тик Ул кушканны гына эшләдем. Син сабыр гына үткәреп җибәрә алмаган нәрсәләрнең аңлатмасы

менә шулар», — диде. Муса аңа олуг рәхмәтләрен әйтергә дип башын күтәрде, як-ягына карады, әмма акыл иясе юкка чыккан иде. Кая китте ул, ничек итеп кинәт юкка чыкты? Бу бер Аллаһы Тәгаләгә генә мәгълүм иде, Аннан башка беркем дә белми һәм белмәячәк тә.

Шушының белән Муса галәйһиссәлам кыйссасы тәмам, Җәнабел Хак барыбызга да хәер вә бәрәкәт насыйп итсә иде.

«Нәзһәтүл-мәҗәлис» китабында Муса галәйһиссәлам вакытында яшәгән Карун турында риваять кылына: Карун мәлгунь Муса галәйһиссәламнең атасы белән бертуганының улы иде. Аллаһы Тәгалә аны сынау өчен бик күп мал бирә. Ул малларын саклаган амбарларның ачкычын берничә кеше күтәреп йөргән. Ләкин ул Аллаһы Тәгаләгә шөкрана кылмый, ягъни зәкят, гошер малын бирми һәм соңыннан аны барлык байлыклары белән җир йота. «Әл-Касас» сүрәсе, 76–81 нче аятьләрдә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Тәхкыйк, Карун Муса галәйһиссәлам кавеменнән булып, аңа иман китергән кешеләрдән иде, Ягъкуб балаларына золым итте һәм байлыгы белән олугланды, Без аңа күп байлык бирдек, аның хәзинә сарайларының ачкычларын күтәрмәк куәт ияләре булган җәмәгатькә дә авыр булыр иде. Кавеме Карунга әйтте: «Малың күплеге белән мактанып шатланма, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә мал белән мактанучыларны сөймидер (76).

Бәлки Хак Тәгалә биргән малны Аның юлына биреп, ахирәтне кәсеп итәрсең, дөньядан үз өлешеңне генә алып, ахирәтең өчен гамәл кылырга онытма. Аллаһы Тәгалә сиңа ихсан кылып мал биргән кебек, син дә мохтаҗ кешеләргә малыңнан өлеш чыгар, җир өстендә явызлык белән фәсад кылып йөрмә, тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә фәсад кылучыларны сөймидер (77)».

Карун әйтте: «Миңа бу мал белемемнең күплеге өчен бирелде». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әгәр дә ул галим икән, белергә тиеш, моннан элек Аллаһы Тәгалә күпме җәмәгатьне Аңа карышканнары өчен һәлак итте, ул һәлак булган кешеләр куәттә Каруннан артыграк, вә җыйган маллары да күбрәк иде, фәсадчы залимнәр кыямәт көнендә гөнаһларыннан соралмаслар, турыдан-туры җәһәннәмгә керерләр (78)».

Карун беркөнне йөгән, иярләре алтын белән зиннәтләнгән атка атланып кавеме янына чыкты, дөнья тереклеген теләүчеләр әйттеләр: «Карунга бирелгән кебек байлык безгә дә бирелгән булса, нинди яхшы булыр иде, никтер ул Карунга гына насыйп булды», — диделәр (79).

Белем бирелмеш кешеләр дөньяны сөючеләргә әйттеләр: «Үкенеч булсын сезгә, иман китереп изге гамәлләр кылган кешеләргә Аллаһы Тәгалә вәгъдә иткән җәннәт нигъмәтләре Карунга бирелгән малдан хәерлерәктер, ул җәннәткә ирешмәс, мәгәр сабыр итеп Аллаһы Тәгалә юлында яшәгән хак мөэминнәр ирешерләр», дип (80).

Без ул Карунны һәм йортын җиргә йоттырдык, чөнки Карун, байлыгына таянып, Муса галәйһиссәламне күп җәберләде. Шул вакытта Аллаһы Тәгаләдән башка Карунга ярдәм бирүче булмады һәм җир астына китүдән үз-үзен дә саклый алмады (81)».

Мәгълүм булган Карун кыйссасында, Аллаһы Тәгаләнең әмерен тотмаучыларга, ягъни Хак Сөбханә вә Тәгалә биргән мал-мөлкәтнең зәкятен, гошерен бирмәүчеләргә күп гыйбрәт, күп куркынычлар бар. Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга тәүфыйк, һидаять, шәригать әмерләрен тотарга, галимнәребезгә, остазларыбызга хөрмәт күрсәтергә насыйп итсен. Әмин.

Муса галәйһиссәлам заманында тау куышлыгында калып, 300 ел йоклаган егетләр һәм бер эт турында Коръән Кәримдә бу вакыйгага карата «әл-Кәһеф», ягъни «Тау куышлыгы» сүрәсе бирелгән.

«Әл-Кәһеф» сүрәсе, 21 нче аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَكَذَٰلِكَ أَعْثَرْنَا عَلَيْهِمْ لِيَعْلَمُوٓا۟ أَنَّ وَعْدَ ٱللَّهِ حَقٌّ وَأَنَّ ٱلسَّاعَةَ لَا رَيْبَ فِيهَا

«Үә кәзәәликә әгсәрнәә гәләйһим лийәгләмүү әннә үәгдәллааһи хәккун үә әннәс-сәәгәтә ләә райбә фииһә (21)».

Мәгънәсе: *«Каты йокыларыннан уятканыбыз кеби шул вакыттагы патшага һәм кавеменә ул егетләрнең хәлен күрсәттек, ачык бәян кылдык, аларның хәле белән танышкан кешеләр, Аллаһы Тәгаләнең кыямәт көне белән кылган вәгъдәсе хак икәнен вә кыямәтнең булачагына һич шик юк икәнен белсеннәр өчен (21)».*

Риваятьләрдә бу вакыйга турында болай языла: Рум мәмләкәтендә Дәкәйәнүс исемле бик явыз падишаһ бар иде. Гаскәре белән икенче патшага сугыш ачып, ул патшаны үтерде, алты углын әсир итте. Бу алты егет Дәкәйәнүскә хезмәт иттеләр, алар аны бар нәрсәгә көче җитүче Илаһ дип уйладылар.

Беркөнне Дәкәйәнүс патша тәхетендә утырганда, идәндәге

бер тишектән сарай эченә ике тычкан керде. Патша, моны күреп, курыкты, төсе үзгәрде һәм бу егетләргә тычканнарны тотарга әмер бирде. Егетләр тотканчы дип, бу ике тычкан тишеккә кереп качтылар.

Бу алты егеткә Хак Сөбханә вә Тәгаләдән һидаять ирешге вә күңелләренә мондый уй килде: «Бу залим вә өстәвенә тычканнан да куркучы патша һич тә Илаһ булырга тиеш түгел, без үзебез адашып, ничә ел аңа хезмәт иткәнбез». Болар үз бүлмәләренә кергәч, уртак бер фикергә килеп: «Без җирне вә күкне бар кылучы Аллаһы Тәгаләгә генә иман китердек», — диделәр. Патшаның җәзасыннан куркып, сахрага качтылар. Шулай сахрада барганда, бер көтүчегә очрадылар. Бу көтүче аларның хәл-әхвәлләрен сорашты. Болар булган хәлләрне сөйләп бирделәр. Көтүче байтак уйлап-фикерләп торгач: «Сез хаклы. Тычканнан да курыккан зат Илаһлыкка лаек булмас, мин дә Аллаһы Тәгаләнең барлыгына вә берлегенә иман китерәм: «Ләә иләәһә иллаллаah», — дип, мөселман булды. Бу көтүче дә егетләргә иярде, юлга чыктылар. Көтүченең эте бар иде, ул да хуҗасына иярде. Бу алты егет көтүчегә: «Әй, көтүче дустыбыз, без тау куышлыгына кереп, Аллаһы Тәгаләгә гамәл-гыйбадәт кылып яшәргә ниятлибез, эт тавышланыр, аны куып җибәр», — диделәр. Көтүче этне куалап, аңа таш атты, таш этнең аягына тиеп, аягын сындырды. Аллаһы Тәгаләнең рөхсәте белән эт телгә килеп: «Әй, егетләр, сез Аллаһы Тәгаләнең дуслары. Мин Хак Тәгаләнең дусларын сөямен, сез тау куышлыгында гамәл-гыйбадәт кылырсыз, ял итеп йокларсыз, мин сезне саклармын», — диде.

Бу егетләр этнең кеше теле белән сөйләгәненннән янә дә Аллаһы Тәгаләнең берлегенә һәм барлыгына шөһбәләре бетеп, җаннары тынычланып, тау куышлыгына керделәр. Боларга Аллаһы Тәгаләнең әмере иңде: «Имансыз кавемегездән аерылгач, Аллаһы Тәгаләдән башка затка гыйбадәт кылмас булсагыз, тау куышлыгына керегез. Аллаһы Тәгалә үз рәхмәтеннән сезгә дөнья вә ахирәт киңлегеннән киңлек бирер һәм эшләрегездә җиңеллек белән ризыкны сезгә әзер кылыр».

«Тәфсир Кадый» риваятенчә, әсхәбү кәһәф, ягъни тау куышлыгына керүчеләрнең исемнәре: Йәмлихә, Мәкешлинә, Мәшлинә, Мәрнуш Дәбернуш, Шәзүнүш, җиденчесе аларга ияргән көтүче һәм аның Кыйтмир исемле эте иде.

Әсхәбү кәһәф кешеләре тау куышлыгына кереп, Аллаһы Тәгаләне мактап гамәл-гыйбадәт кылганнан соң ял итәргә дип яткач, Хак Сөбханә вә Тәгалә аларга өч йөз елга сузылган каты йокы

бирә, алар, каты йокы сәбәпле, бернинди тавышны ишетмәделәр. Моннан соң аларны йокыдан уята, күпме вакыт ятулары хакында белү өчен һәм ризык алып кайтырга дип, берсен, көмеш тәңкә биреп, шәһәр базарына җибәрделәр һәм киткәндә: «Хәләл ризыкның яхшырагын карап ал һәм сак бул, сине һичкем белмәсен, белсәләр, әлбәттә, ташлар белән бәреп үтерерләр яки көчләп үз диннәренә кертерләр. Аларның бозык диннәренә керсәң, мәңге чыга алмассың, имансыз көе вафат булырсың», — дип кат-кат әйттеләр. Бу җибәрелгән егет, көмеш тәңкәне алып, шәһәр базарына барып керде. Мул итеп хәлвә үлчәтте, хәлвәчегә көмеш тәңкәне бирде, шулчак сатучы бу егеткә һәм якындагы адәмнәргә кычкырды: «Бу егет борынгы заманнан калган көмеш тәңкәләр тапкан, миңа шуларның берсен биреп хәлвә сатып алмакчы булды, хәзинәне кайдан тапканын белү өчен аны патшага алып барырга кирәк», — диде. Тиз арада аны иftира кылып, патшага илттеләр. Егет тә патшаның Дәкъйәнүс булмавын күреп, бераз тынычланды. Патша: «И, егет, бу тәңкәне кайдан алдың, дөресен сөйлә, дөресен сөйләсәң, миннән бүләк алырсың», — диде. Егет патшага булган хәлләрне сөйләп бирде. Патшаның вәзире: «Минем бабамның бабасы сөйләгән вакыйгада, Дәкъйәнүснең потларга табынуына риза булмыйча, алты егетнең качуы турында атабыздан ишеткән идек, бу шул егетләр булырга тиеш, без шәһәрдәге мөэминнәрне җыеп, бу егет әйткән тау куышлыгына барыйк», — диде.

Патша һәм шәһәрдәге мөэминнәр тау куышлыгына килделәр, тау куышлыгындагы егетләр: «Дәкъйәнүс патша безне зинданга ябарга дип гаскәр белән килә, бу тау куышлыгында соңгы намазыбызны укыйк», — дип ике рәкәгать намаз укыдылар. Патша һәм аның тирәсендәге якыннары бөтенләй башка кешеләр булуын күреп, бик гаҗәпләнделәр. Патша һәм аның тирәсендәгеләргә карап әйттеләр: «Аллаһы Тәгаләнең кыямәт белән кылган вәгъдәсе хак икәнен вә кыямәтнең булачагында шик вә шөбһә юк икәнен яңадан бер кат үз күзләребез белән күрдек вә инандык», — дип, бу җиде егет һәм Кыйтмир исемле эт үз урыннарына кереп җан тәслим кылдылар.

Патша, бу могҗизаны күреп, иман китерде һәм бу егетләрне шул мәгарәдә күмеп, өсләренә мәсҗид төзетте. Әсхәбү кәһәф кыйссасының күбрәге «Тәфсир Кадый»дан алынды.

Үәссәламүгаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ!

# ДАУД ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Хәзрәти Дауднын атасы Иша исемле була. Аллаһы Тәгалә бәни Исраил кавеменә бик күп пәйгамбәрләр җибәрә. Муса галәйһиссәлам уллыкка алып үстергән егетнең исеме Юшагъ галәйһиссәлам иде. Муса галәйһиссәлам унике кабилә башлыкларын Әрихә шәһәренә илче итеп җибәргәндә дә Юшагъ галәйһиссәламне алар белән җибәрә. Бу турыда Аллаһы Тәгалә Коръән Кәрименең «әл-Маидә» сүрәсе, 12 нче аяти кәримәсендә әйтелә. Шулай ук Муса галәйһиссәлам Юшагъ галәйһиссәламне Хозыр галәйһиссәлам белән очрашырга барганда үзе белән ала, бу хакта «әл-Кәһеф» сүрәсенең 60-65 нче аяти кәримәләрендә әйтелә. Башта Һарун галәйһиссәлам вафат була, озак та тормый Муса галәйһиссәлам вафат була.

Аллаһы Тәгаләнең кушкан әмерләрен үтәмәгәннәре, Муса пәйгамбәр белән бергә изге җиргә, ягъни Фәлестин җиренә кермәгәннәре өчен җәзаланып, бәни Исраил кавеме кырык ел буе чүлдә адашып йөри. Аллаһы Тәгаләнең гыйбрәт өчен чүлдә күрсәткән газаплары аларны тәүбәгә китерә. Бәни Исраил кавеме Аллаһы Тәгаләнең Ышмуил исемле пәйгамбәренә буйсыналар һәм, Фәлестин җирендә яшәүче, потларга табынучы таифәләрне җиңеп, алар ясап куйган потларны җимерәләр, бу җирләргә үзләре хуҗа булалар.

Ләкин озак та үтми, алар Муса галәйһиссәламнең могҗизалы таягы, чалмасы, Һарун галәйһиссәламнең чапаны һәм башка шундый әйберләре салынган табутка табына башлыйлар, безне коллыктан шул әйберләр коткарды дип, Аллаһы Тәгаләнең ачуын китерәләр.

Мәҗүсиләр, берләшеп, бәни Исраил кавемен җиңәләр, аларны тар-мар итеп, өйләреннән куалар, ирләре үтерелә, ә балалары әсир ителә. Алар табына торган табут та дошманнары кулына эләгә. Хак Тәгаләне онытканнары өчен әнә шундый җәза бирелә аларга. Алар яңадан йорт-җирсез мескеннәр хәленә төшәләр.

Үзләренең бу хәлләргә төшүләренең сәбәпләрен тикшерер өчен, бәни Исраил кавеменең аксакаллары киңәшкә җыела-

лар. Хәлләре түзеп тормаслык булганга күрә, алар Юшагъ галәйһиссәламгә мөрәҗәгать итәләр: «Без синең Аллаһы Тәгаләгә багышлап дога кылуыңны телибез, син Хак Тәгаләдән безнең белән идарә итә торган патша җибәрүен сора, без аның тирәсенә тупланып, Аллаһы Тәгалә хакы өчен сугышырга әзербез», — диләр.

Юшагъ галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә багышлап дога кылды, догасы кабул булды. Бу турыда Коръән Кәримнең «әл-Бәкара» сүрәсе, 246–251 нче аяти кәримәләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

أَلَمْ تَرَ إِلَى الْمَلَإِ مِنْ بَنِي إِسْرَائِيلَ مِنْ بَعْدِ مُوسَى إِذْ قَالُوا لِنَبِيٍّ لَهُمُ ابْعَثْ لَنَا مَلِكًا نُقَاتِلْ

فِي سَبِيلِ اللَّهِ قَالَ هَلْ عَسَيْتُمْ إِنْ كُتِبَ عَلَيْكُمُ الْقِتَالُ أَلَّا تُقَاتِلُوا قَالُوا وَمَا لَنَا أَلَّا نُقَاتِلَ

فِي سَبِيلِ اللَّهِ وَقَدْ أُخْرِجْنَا مِنْ دِيَارِنَا وَأَبْنَائِنَا فَلَمَّا كُتِبَ عَلَيْهِمُ الْقِتَالُ

تَوَلَّوْا إِلَّا قَلِيلًا مِنْهُمْ وَاللَّهُ عَلِيمٌ بِالظَّالِمِينَ ﴿٢٤٦﴾ وَقَالَ لَهُمْ نَبِيُّهُمْ إِنَّ اللَّهَ قَدْ بَعَثَ

لَكُمْ طَالُوتَ مَلِكًا قَالُوا أَنَّى يَكُونُ لَهُ الْمُلْكُ عَلَيْنَا وَنَحْنُ أَحَقُّ بِالْمُلْكِ مِنْهُ وَلَمْ يُؤْتَ سَعَةً مِنَ

الْمَالِ قَالَ إِنَّ اللَّهَ اصْطَفَاهُ عَلَيْكُمْ وَزَادَهُ بَسْطَةً فِي الْعِلْمِ وَالْجِسْمِ وَاللَّهُ يُؤْتِي

مُلْكَهُ مَنْ يَشَاءُ وَاللَّهُ وَاسِعٌ عَلِيمٌ ﴿٢٤٧﴾ وَقَالَ لَهُمْ نَبِيُّهُمْ

إِنَّ آيَةَ مُلْكِهِ أَنْ يَأْتِيَكُمُ التَّابُوتُ فِيهِ سَكِينَةٌ مِنْ رَبِّكُمْ وَبَقِيَّةٌ مِمَّا تَرَكَ آلُ مُوسَى وَآلُ هَارُونَ تَحْمِلُهُ

الْمَلَائِكَةُ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَةً لَكُمْ إِنْ كُنْتُمْ مُؤْمِنِينَ ﴿٢٤٨﴾ فَلَمَّا فَصَلَ طَالُوتُ

بِالْجُنُودِ قَالَ إِنَّ اللَّهَ مُبْتَلِيكُمْ بِنَهَرٍ فَمَنْ شَرِبَ مِنْهُ فَلَيْسَ مِنِّي وَمَنْ لَمْ يَطْعَمْهُ

فَإِنَّهُ مِنِّي إِلَّا مَنِ اغْتَرَفَ غُرْفَةً بِيَدِهِ فَشَرِبُوا مِنْهُ إِلَّا قَلِيلًا مِنْهُمْ فَلَمَّا جَاوَزَهُ هُوَ وَالَّذِينَ آمَنُوا

مَعَهُ قَالُوا لَا طَاقَةَ لَنَا الْيَوْمَ بِجَالُوتَ وَجُنُودِهِ قَالَ الَّذِينَ يَظُنُّونَ أَنَّهُمْ مُلَاقُو اللَّهِ كَمْ مِنْ فِئَةٍ

قَلِيلَةٍ غَلَبَتْ فِئَةً كَثِيرَةً بِإِذْنِ اللَّهِ وَاللَّهُ مَعَ الصَّابِرِينَ ﴿٢٤٩﴾ وَلَمَّا بَرَزُوا لِجَالُوتَ وَجُنُودِهِ

قَالُوا رَبَّنَا أَفْرِغْ عَلَيْنَا صَبْرًا وَثَبِّتْ أَقْدَامَنَا وَانْصُرْنَا عَلَى الْقَوْمِ الْكَافِرِينَ ﴿٢٥٠﴾ فَهَزَمُوهُمْ

بِإِذْنِ اللَّهِ وَقَتَلَ دَاوُدُ جَالُوتَ وَآتَاهُ اللَّهُ الْمُلْكَ وَالْحِكْمَةَ وَعَلَّمَهُ مِمَّا يَشَاءُ ۗ وَلَوْلَا دَفْعُ اللَّهِ
النَّاسَ بَعْضَهُمْ بِبَعْضٍ لَفَسَدَتِ الْأَرْضُ وَلَٰكِنَّ اللَّهَ ذُو فَضْلٍ عَلَى الْعَالَمِينَ ٢٥١

«Әләм тәра иләл-мәләи мим-бәнии Исрааиилә мим-бәгди Мүүсә. Из каалүү линәбийил-ләһүмү бәгәс ләнәә мәликәннүкаатил фии сәбиилил-лләәһ. Каалә һәл гәсәйтүм иң күтибә гәләйкүмүл-кыйтәәлү әлләә түкаатилү. Каалүү үә мәә ләнәә әлләә нүкаатилә фии сәбиилилләәһи үә каде үхърижнәә миң дийәәринә үә әбнәәинә. Фәләммәә күтибә гәләйһимүл-кыйтәәлү тәүәлләү илләә калиилəм-минһүм. Үәллааһү гәлиимүм-биззаалимиин (246). Үә каалә ләһүм нәбий-йүһүм иннәллааһә каде бәгсә ләһүм Таалүүтә мәликә. Каалүү иннәә йәкүүнү ләһүл-мүлкү гәләйнәә үә нәхнү әхәкку бил-мүлки минһү үә ләм йүәтә сәгәтәм-минәл-мәәл. Каалә иннәллааһәстафәәһү гәләйкүм үә зәәдәһү бәстатән фил-гилми үәл-җисми, үәллааһү йүәтии мүлкәһү мәй-йәшәә-ү үәллааһү үәәсигүн гәлиим (247). Үә каалә ләһүм нәбийййүһүм иннә әәйәтә мүлкиһии әй-йә-тийәкүмүт-тәәбүүтү фииһи сәкиинәтүммир-раббикүм үә бәкый-йәтүм-миммәә тәракә әәлү Мүүсәә үә әәлү Һәәруунә тәхмилүһүл-мәләәикәһ. Иннә фии зәәликә лә-әәйәтәл-ләкүм иңкүңтүм мүәминиин (248). Фәләммәә фәсалә таалүүтү билҗүнүүди каалә иннәллааһә мүбтәлиикүм бинәһәр. Фәмәң шәрибә минһү фәләйсә минни. Үә мәл-ләүм йәтгәмһү фәиннәһү минниии илләә мәниг тәрафә гурфәтәм-бийәдиһии фәшәрибү минһү илләә калиилəм-минһүм. Фәләммәә җәәүәзһү һүвә үәлләзиинә әәмәнү мәгәһү каалүү ләә таакатә ләнәл-йәүмә биҗәәлүүтә үә җүнүүдиһ. Каaләл-ләзиинә йәзуннүнә иннәһүм мүләәкуллааһи кәм миң фиәтиң калииләтин галәбәт фиәтәң кәсииратәм-би-изнилләәһи, үәллааһү мәгәс-саабириин (249). Үә ләммәә бәразү ләә-Җәәлүтә үә җүнүүдиһии каалүү раббәнәә әфриг гәләйнәә сабран үә сәббит әкъдәә мәнәә үән-сурнәә гәләл-каумил-кәфириин (250). Фәһәзәмүү һүм би-изнил-ләәһи үә катәлә Дәәүдү Җәәлүүтә үә әәтәәһүллааһүл-мүлкә үәл-хикмәтә үә гәлләмәһү миммәә йәшәә-ү. Үә ләү ләә дәфгүл-ләәһин-нәәсә бәгдаһүм бибәгдыйл-ләфәсәдәтил-әрду үәләәкин-нәллааһә зуүфәдълин гәләл-гәләмиин (251)».

М ә г ъ н ә с е : *«Муса пәйгамбәрдән соң Ягъкуб балаларыннан бер җәмәгатьнең хәлен белдеңме? Алар үзләренең пәйгамбәре Юшагъ галәйһиссәламгә әйттеләр: «Безгә патша билгелә, без, аңа буйсынып, Аллаһы Тәгалә юлында кяферләр белән сугышыр идек», — дип. Юшагъ галәйһиссәлам әйтте: «Әгәр сезгә сугыш фарыз ителсә, ихтимал, сугышмассыз, карышырсыз», — дип. Алар әйттеләр: «Безгә ни булган, Аллаһы Тәгалә юлында сугышмаска? Без бит шул кяферләр тарафыннан йортларыбыздан куып чыгарылдык, газиз балаларыбыздан аерылдык, әлбәттә, алар белән сугышабыз». Кайчан аларга кяферләр белән сугышу фарыз ителде, алар сугыштан баш тарттылар, мәгәр бик азлары гына баш тартмады, гайрәт белән сугыштылар. Хак Тәгалә сугыштан баш тарткан куркак залимнәрне белә (246). Һәм аларның пәйгамбәрләре аларга әйтте: «Аллаһы Тәгалә сезгә Талутны патша кылды». Алар пәйгамбәргә әйттеләр: «Кайда инде ул Талутка безнең өстән патша булу, моңа без хаклырак, чөнки Талутка мал байлыгы бирелмәгән». (Ләкин Талут, фәкыйрь булса да, гакыллы, галим вә гаять тә көчле иде.) Пәйгамбәрләре әйтте: «Аллаһы Тәгалә сезгә Талутны патшалыкка ихтыяр кылды, дәхи аны белемдә вә көчтә сездән артык кылды. Патша булу өчен бай булу шарт түгел, бәлки гакыллы вә галим булу шарт». Хак Тәгалә Үзенең байлыгын теләгән бәндәсенә бирер, Ул — киңлек вә белем иясе» (247). Пәйгамбәрләре Талутның Хак Тәгалә тарафыннан билгеләнгән патша икәнлеген әйтте: «Аллаһы Тәгаләдән бер сандык килер, аның эчендә күңелләрегезгә хуш булырлык нәрсәләр булыр — Муса галәйһиссәлам белән Һарун галәйһиссәлам калдырган Мусаның таягы, чалмасы, чапаны һәм башка нәрсәләре булыр,ул сандыкны сезгә фәрештә алып килер. Аллаһы Тәгаләдән сезгә бу сандыкның килүендә Талутның патша икәнлегенә шиксез дәлилләр бар, әгәр дә инде бу дәлилләрнең Хак Тәгаләдән булуына ышансагыз». Моннан соң алар Талутның патша икәнлегенә ышандылар. Талут 70 мең мөселман гаскәрен хәзерләп, кяферләр белән сугышырга юлга чыкты. Көн бик эссе иде, шул сәбәпле гаскәр Талуттан су эчәргә рөхсәт сорады (248). Талут гаскәр белән шәһәрдән чыгып сәфәргә киткәндә гаскәргә әйтте: «Аллаһы Тәгалә сезне бер челтерәп аккан елга белән сыный, кем дә кем ошбу елгадан су эчә, ул кеше миннән аерылып*

*китәр, фәкать су эчми сабырлык кылган кеше генә минем белән сугышка керер яки учын тутырып бер мәртәбә эчкән кеше миңа юлдаш булыр». Әмма гаскәриләрнең күбесе елгадан туйганчы эчтеләр, мәгәр бик азлары гына эчмәде. (Су эчкән кешеләрнең иреннәренә Аллаһы Тәгалә бер галәмәт чыгарды, шуның белән алар эчмәгән кешеләрдән аерылдылар.) Талут һәм аның белән бергә су эчмичә калган мөселманнар шул елганы үтеп киткәч, алар арасыннан берсе әйтте: «Кяферләргә каршы сугышырга безнең көчебез җитмәс, Җалутка һәм аның гаскәренә каршы тора алмабыз, чөнки аларның саны безгә караганда бик күп артык». Ахирәт көненә вә Аллаһы Тәгаләгә ышанучы мөселманнар әйттеләр: «Аллаһы Тәгаләнең ярдәме илә күп вакытта аз санлы булган мөселманнар күп санлы кяферләрне җиңделәр түгелме? Шулай булгач, без дә күп санда булган кяферләрдән курыкмыйча, Газзә вә Җәлләнең ярдәменә таянып сугышыйк». Аллаһы Тәгалә сугышларда батырлык вә сабырлык күрсәткән чыдамлы мөэминнәр белән бергә (249). Мөэминнәр, Җалутка һәм аның гаскәренә якынлашкач, әйттеләр: «И, Раббыбыз! Безгә ныклык, сабырлык вә батырлык бир һәм аякларыбызны җиргә нык беркет вә дәхи кяфер гаскәрен җиңәргә ярдәм бир» (250). Аллаһы Тәгаләнең ярдәме илә аз санда булган мөселманнар гаскәре күп санда булган кяфер гаскәрен җиңделәр һәм Дауд кяферләрнең башлыгы булган Җалутны үтерде. Хак Тәгалә Даудка байлык вә пәйгамбәрлек бирде һәм аңа Үзе теләгән нәрсәләрне өйрәтте. Әгәр Аллаһы Тәгалә мөселманнарны якламаса, әлбәттә, җирдәге кешеләр һәммәсе дә һәлак булып бетәрләр иде. Ләкин Җәнабел Хак — барча галәмнәр мәхлукларына рәхмәтле (251)».*

Ул заманнарда сугыш ике яктан да иң батыр ике каһарманның кара-каршы сугышы белән башлана, аннары инде барча гаскәр сугышка катнаша. Алып гәүдәле Җалут алга чыгып: «Миңа каршы бергә-бер кем чыга? Әгәр мин җиңсәм, җиңү — безнең якта булачак, әгәр синең пәһлеваның мине җиңсә, җиңү — синең якта булыр!» — диде. Әмма Җалутка каршы чыгарга беркемнең дә йөрәге җитмәде. Дауд галәйһиссәлам бәни Исраил улларының куркып калуларын күреп: «Мин сугышам синең белән!» — ди. Дауд галәйһиссәлам бауга бәйләнгән

таш белән бик оста эш итә, ул селтәнеп ыргыткан таш Җалутның ике күз арасына барып тия, Җалут җиргә ава, Дауд галәйһиссәлам аның янына йөгереп барып, кылычы белән башын чабып өзә. Сугышларда гел җиңү китергән каһарман Җалутның үлеме гаскәрне тетрәндерә, алар тәртипсез рәвештә кача башлыйлар. Аллаһы Тәгаләнең ярдәме илә аз санлы булган мөэминнәр күп санлы булган кяфер гаскәрен җиңәләр. Моннан соң Аллаһы Тәгалә Дауд галәйһиссәламгә байлык һәм пәйгамбәрлек бирә һәм аңа Үзе теләгән нәрсәләрне өйрәтә.

Аллаһы Тәгаләнең ярдәмен вә үзләренең көчләрен сизгән бәни Исраил кавеме кяферләр белән тагын бик күп сугышлар алып бара. Шундый сугышларның берсендә бәни Исраил кавеменең патшасы Талут үтерелә.

Хак Сөбханә вә Тәгаләнең әмере илә Дауд галәйһиссәламне бәни Исраил кавеменә падишаһ итеп сайлап куялар. Моннан башка да Аллаһы Тәгалә Дауд галәйһиссәламгә башка пәйгамбәрләргә бирмәгән өстенлекләрне бирә: ул — бәни Исраил кавеменең беренче патша-пәйгамбәре булды. Коръән Кәримдә аның исеме 16 тапкыр искә алына. Аллаһы Тәгалә, аны хөрмәтләп, Зәбур дигән китабын иңдерә һәм аңа бу китапны укыр өчен бик көчле вә матур тавыш бүләк итә. Янә аңар гадел казыйлык алып бару сәләтен һәм тимердән сугыш киемнәре вә башка кирәк-яраклар эшләү сәләтен бирә. Ул бу эшкә башкаларны да өйрәтә, чөнки сугышканда алардан файдалана белүләрен тели. Болардан башка Хак Тәгалә аңа Сөләйман исемле, үзе кебек бик зирәк, гакыллы бер угыл бүләк итә. Бу мәгълүматларны без Коръән Кәрим аяти кәримәләрендә ачык күрәбез.

Дауд галәйһиссәламнең җәмгысы 99 хатыны була. Көннәрнең берендә ул сарай тәрәзәсеннән бик тә гүзәл бер хатынны күрә вә аңар шул вакытта ук җаны-тәне илә гашыйк була. Ул аңа өйләнергә, хатыннарының санын төгәл 100 гә җиткерергә ниятли. Әмма теге хатын ирдә булып чыга. Инде нишләргә дип, Дауд галәйһиссәлам гыйбадәт кыла башлый. Шул вакыт ул ике ягында ике ир кешенең утырганын күреп куркып кала, чөнки барлык ишекләрдә ышанычлы сакчылар куелган иде. Бу хакта Коръән Кәримнең «Сад» сүрәсе, 22–25 нче аяти кәримәләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

إِذْ دَخَلُوا عَلَىٰ دَاوُودَ فَفَزِعَ مِنْهُمْ قَالُوا لَا تَخَفْ خَصْمَانِ بَغَىٰ بَعْضُنَا عَلَىٰ بَعْضٍ فَاحْكُمْ
بَيْنَنَا بِالْحَقِّ وَلَا تُشْطِطْ وَاهْدِنَا إِلَىٰ سَوَاءِ الصِّرَاطِ ﴿٢٢﴾ إِنَّ هَٰذَا أَخِي لَهُ تِسْعٌ وَتِسْعُونَ نَعْجَةً
وَلِيَ نَعْجَةٌ وَاحِدَةٌ فَقَالَ أَكْفِلْنِيهَا وَعَزَّنِي فِي الْخِطَابِ ﴿٢٣﴾ قَالَ لَقَدْ ظَلَمَكَ بِسُؤَالِ نَعْجَتِكَ
إِلَىٰ نِعَاجِهِ وَإِنَّ كَثِيرًا مِنَ الْخُلَطَاءِ لَيَبْغِي بَعْضُهُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ إِلَّا الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا
الصَّالِحَاتِ وَقَلِيلٌ مَا هُمْ وَظَنَّ دَاوُودُ أَنَّمَا فَتَنَّاهُ فَاسْتَغْفَرَ رَبَّهُ وَخَرَّ رَاكِعًا وَأَنَابَ ﴿٢٤﴾
فَغَفَرْنَا لَهُ ذَٰلِكَ وَإِنَّ لَهُ عِنْدَنَا لَزُلْفَىٰ وَحُسْنَ مَآبٍ ﴿٢٥﴾

«Из дәхалү гәләә Дәәүдә фәфәзигә минһүм. Каалүү ләә тәхаф хасмәәни бәгаа бәгдунәә гәләә бәгдыйң фәхкүм бәйнәнәә бил-хәккый үә ләә түштыйт үәһдинәә иләә сәүәәис-сыйраат (22). Иннәә һәәзәә әхыйй ләһү тисгүн үә тисгүүнә нәг-җәтән үә лиә нәгҗәтүн үәәхидәтүң фәкаалә әкфилниииһәә үә гәззәниииһәә үә гәззәнии фил-хыйтаабе (23). Каалә ләкаде за-ләмәкә бисүүәәли нәгҗәтикә иләә нигәәҗиһ. Үә иннә кәсии-рам-минәл-хуләтаа-и ләйәбгыйй бәгдуһүм гәләә бәгдин илләәл-ләзиинә әәмәнүү үә гәмилүс-саалихәәт. Үә калиилүм-мәә һүм, үә заннә Дәәүүд әннәмәә фәтәннәәһү фәстәгъфәра раббәһү үә харрараа кигәү-үә әнәәбе (24). Фәгъфәрнәә ләһүү зәәликә, үә иннә ләһүү гиндәнәә ләзүлфәә үә хүснә мәәбе (25)».

Мәгънәсе: *«Алар кеше сурәтендә Дауд галәйһиссәлам янына кергәч, ул — бу кешеләр кайдан керделәр икән дип, куркып калды. Чөнки барча ишекләрдә дә көчле сакчылар тора иде. Бу кеше сурәтендәге фәрештәләр әйттеләр: «Син бездән бер дә курыкма, без ике дәгъвачыларбыз, беребез икенчебезгә золым итмештер, арабызны хаклык илә хөкем ит, безгә золым итмә вә бу эшебездә безне туры юлга сал!» (22). Аларның берсе әйтте: «Менә бу иптәшем диндә минем кардәшемдер, аның туксан тугыз сарыгы бар, минем исә бер генә сарыгым бар, шул бер сарыгыңны миңа бир, дип, ул минем белән низаг кылды вә сүзендә мине җиңде, минем ни әйтергә дә хәлем калмады» (23). Дауд галәйһиссәлам әйтте: «Туксан тугыз сарыгы була торып, синең бердәнбер сарыгыңны сорап, сиңа золым иткән. Уртаклык илә эш кылучылар, әлбәттә, бер-*

*берсенә золым итәрләр, мәгәр иман китереп, изге гамәлләр кылган мөэминнәр золым итмәсләр, ләкин андый кешеләр аздыр». Фәрештәләр, бу гадел сүзләрне ишеткәч, аның күз алдыннан кинәт юк булып, күккә аштылар. Дауд галәйһиссәлам бу ике фәрештәнең аны сынар өчен килгәннәрен белде, Раббысыннан гафу сорады вә күз яшьләре илә сәҗдәгә китте (24). Ярлыканырга теләгән хатасын гафу иттек, кыямәт көнендә Безгә якын булуга вә аңа күркәм урын бардыр (25)».*

Алда әйткәнебезчә, Аллаһы Тәгалә Дауд галәйһиссәламгә Зәбур китабын иңдерде һәм аңа Сөләйман исемле малай бүләк итте. Коръән Кәримнең «Сад» сүрәсе, 29–30 нчы аяти кәримәләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

كِتَٰبٌ أَنزَلْنَٰهُ إِلَيْكَ مُبَٰرَكٌ لِّيَدَّبَّرُوٓا۟ ءَايَٰتِهِۦ وَلِيَتَذَكَّرَ أُو۟لُوا۟ ٱلْأَلْبَٰبِ ۝٢٩

وَوَهَبْنَا لِدَاوُۥدَ سُلَيْمَٰنَ ۚ نِعْمَ ٱلْعَبْدُ ۖ إِنَّهُۥٓ أَوَّابٌ ۝٣٠

«Китәәбүн әңзәлнәәһү иләйкә мүбәәракүл-лийәддәббәрру әәйәәтиһи үә лийәтәзәккәра үүлүл-әлбәәбе (29). Үә үәһәбнәә лидәәүдә Сүләймәән. Нигмәл-гәбдү, иннәһү әүвәбе (30)».

Мәгънәсе: *«Без сиңа иңдергән китап (Зәбур китабы) күп файдалы вә бәрәкәтледер, аның һәр аятен уйлап-фикерләп аңласыннар. Без аны гакыл ияләре үзләре укып вәгазьләсеннәр өчен иңдердек (29). Вә Без Дауд галәйһиссәламгә Сөләйманны һибә кылдык, нинди хуш баладыр ул Сөләйман, ул һәрдаим тәүбә-истигъфар вә зикер илә Аллаһы Тәгаләгә кайтучыдыр (30)».*

Дауд галәйһиссәлам углы Сөләйманны укытырга бик күп көч түкте. Кешеләрнең бәхәсләрен чишкән вакытта, аны мәхкәмә залына үзе белән алып керә торган иде. Бу хакта Коръән Кәримнең «әл-Бәкара» сүрәсе, 78–79 нчы аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Вә Дауд галәйһиссәлам илә аның углы Сөләйманны хәтерләгез. Бер кешенең игенен башка кешенең куйлары, кич белән кереп, ашап вә таптап юкка чыгарган иделәр, шул хакта алар икесе, ягъни аталы-уллы хөкем иттеләр, вә Без аларның хөкем карарына шаһит булдык (78). Иген хакында дөрес хөкемне Сөләйманга җиткердек. (Дауд тапталган иген бәрабәренә иген хуҗасына куйларны бирергә хөкем иткән иде. Бу вакытта Сөләйманга 13 яшь иде. Ул атасы Дауд галәйһиссәлам чыгарган хөкемгә риза булмыйча:

«И, атам, минем фикеремчә, бу хөкемнән яхшырак хөкем бар. Куйлар вакытлыча иген хуҗасына бирелсен, иген хуҗасы куйларның сөтеннән вә йоннарыннан файдаланып торсын. Ә куйлар хуҗасы исә җирне эшкәртеп, иген чәчеп, үстереп бирсен, аннары куйларын кайтарып алыр», — диде.) Аларның һәр икесенә дә файдалы белем вә шәригать хөкемнәрен бирдек, Дауд галәйһиссәлам белән бергә таулар вә кошлар да Аллаһыга зикер әйтәләр иде (79)».

Җәнабел Хак Дауд галәйһиссәламгә тимерчелек һөнәрен өйрәтте. Бәни Исраил кавемендә ул беренчеләрдән булып тимер күлмәк ясады вә моны башкаларга да өйрәтте. «Әл-Әнбия» сүрәсенең 80 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَعَلَّمْنَٰهُ صَنْعَةَ لَبُوسٍ لَّكُمْ لِتُحْصِنَكُم مِّنۢ بَأْسِكُمْ ۖ فَهَلْ أَنتُمْ شَٰكِرُونَ ٨٠

«Үә гәлләмнәәһү сангәтә ләбүүсил-ләкүм литүхсыйнәкүм мим-бәәсикүм, фәһәл әңтүм шәәкируун (80)».

Мәгънәсе: *«Вә Даудка сезнең өчен тимердән сугыш киемнәрен тегәргә өйрәттек, ул киемнәрне сезне кылыч зарарыннан сакламак өчен эшләдек. Ә сез шуның өчен шөкер итәсезме? (80)».*

Дауд галәйһиссәлам углы Сөләйман галәйһиссәламне үзе янына чакырып әйтте: «И, углым! Инде сиңа минем урыныма патша булырга вакыт җитте. Мин картайдым, ә син көчле һәм акыллы ир-егет булдың».

Дауд галәйһиссәламнең гомере ахырына якынлашты исә, Газраил галәйһиссәлам Дауд галәйһиссәламгә килде. Ул Газраил галәйһиссәламне күреп таныды, үлем фәрештәсенә сәлам бирде вә әйтте: «И, Газраил, ни эш белән вә кем янына килдең?» — диде. Газраил галәйһиссәлам әйтте: «Синең җаныңны оҗмахка алып китәр өчен килдем», — диде. Дауд галәйһиссәлам: «Аллаһының хөкеменә ризамын», — дип, урынына килеп ятты. Газраил галәйһиссәлам шул сәгатьтә үк аның җанын җиңеллек илә алды.

Сөләйман галәйһиссәлам атасының гәүдәсен юып, җеназа намазында да имам булып торды. Дәфен кылганда, гәүдәсен хуш исле җофар илә исләндерделәр. Ничә елларга кадәр җофар исе Дауд галәйһиссәламнең кабереннән килеп торыр иде.

Дауд галәйһиссәлам, бу фани дөньяда йөз ел гомер сөреп, бакый дөньяга күчте.

# СӨЛӘЙМАН ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Бәндәләргә дин хөкемнәрен өйрәтмәк өчен, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә бәни Исраил кавеменә бик күп пәйгамбәрләр җибәрде. Муса галәйһиссәлам вафатыннан соң пәйгамбәр булып калган аның туганы Һарун галәйһиссәлам турында Коръән Кәримдә 20 җирдә әйтелә.

Дауд углы Сөләйман галәйһиссәлам турында Коръән Кәримдә 17 җирдә әйтелә.

Атасы Дауд галәйһиссәлам вафатыннан соң аның урынына падишаһ булып утырганда, Сөләйман галәйһиссәламгә бары 13 яшь иде. Исән вакытында атасы аны бик күп мәхкәмәләргә үзе белән алып йөрде. Сөләйман галәйһиссәлам кешеләрнең бәхәсләрен тыныч кына тыңлап тора да үзенең төпле фикерен әйтә, аның сүзеннән ике як та канәгать булып кала иделәр. Моны күреп, Давыт галәйһиссәлам Сөләйманның зирәклегенә бик сөенә иде. Үзе вафат булганда да: «И, углым, Газраил галәйһиссәлам минем җанымны алырга килде, инде сиңа патша булырга вакыт җитте, патшалыкта вә мәхкәмәләрдә һәрвакыт шулай гадел бул, халык сине яратыр, ә иң мөһиме — Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылудан туктама, Ул сине ташламас», — дип, тыныч кына җан тәслим кылды.

Сөләйман галәйһиссәламнең атасы Дауд галәйһиссәлам Ислам шәригатен күп илләргә тарату нияте илә бик күп сугышларда катнашты. Әл-Кодес шәрифне (Иерусалим) кяферләрдән алып, аны пайтәхете итте. Болардан тыш Бәлад, Голман, Халеб, Нәсбин вә Әрмәнстанны алып, үз дәүләтен көчәйтте. Үзе алган җирләрдә Муса галәйһиссәламгә иңдерелгән Тәүрат вә үзенә иңдерелгән Зәбур китаплары илә вәгазь-нәсыйхәт кылды. Ягъни бу җирләрдә шәригать хөкемнәрен шушы изге китапларга таянып гамәлгә ашырды вә гаделлек илә хөкем кылды. Атасы урынына патша булып калгач, Сөләйман галәйһиссәлам Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә бик күп шөкраналар кылды. Күп вакытын гыйбадәттә булып, бик гадел вә миһербанлы хөкем итте. Сөләйман галәйһиссәламнең һәрдаим тәүбә-истигъфарда вә гыйбадәттә булуы

хакында Коръән Кәримнең «Сад» сүрәсе 30 нчы аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Үә үәһәбанәә лидәәүдә Сүләймәәнә нигмәл гәбдү иннәһүү әүвәәбе (30)».

Мәгънәсе: *«Вә Без Даудка Сөләйманны һибә кылдык, нинди хуш бәндәдер ул Сөләйман, ул һәрвакыт тәүбә вә тәсбих илә Хак Тәгаләгә кайтучыдыр (30)».*

Сөләйман галәйһиссәламнең пәйгамбәрлектә вә патшалыкта гадел варис булып калуы хакында «ән-Нәмел» сүрәсенең 16 нчы аяти кәримәсендә болай диелә:

وَوَرِثَ سُلَيْمَٰنُ دَاوُۥدَ

«Үә үәрисә Сүләймәәнү Дәәүүдә (16)».

Мәгънәсе: *«Сөләйман атасы Даудка пәйгамбәрлектә вә патшалыкта варис булды (16)».*

Сөләйман галәйһиссәламнең һәр эштә вә гамәлдә гадел булуын күреп вә белеп торучы Аллаһы Тәгалә аңа әйтә: «И, Сөләйман! Синең гаделлек илә Ислам диненә хезмәт итүеңне күреп вә белеп торучы Раббыңнан ни телисең — шуны сора, Мин барын да сиңа бирермен, чөнки Минем кодрәтемнән килмәгән эш юк». Сөләйман галәйһиссәлам җавабында: «И, Раббым! Кичер мине, Син миңа шундый бүләк бир, андый бүләк миннән башка беркемдә дә булмасын. Тәхкыйк, Син юмарт вә игелеклесең», — дип әйтә.

«Сад» сүрәсе, 35 нче аятьтә әйтелә: «Үә һәбелии мүлкәлләә йәмбәгыйй лә әхәди мимбәгди (35)».

Мәгънәсе: *«Йә, Раббым! Миңа падишаһлык һибә кыл, миннән соң һичкемдә андый патшалык булмасын (35)».*

«Сад» сүрәсе, 39 нчы аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Һәәзәә гәтаа-ү нәә фәмнүн әү әмсик (39)».

Мәгънәсе: *«Бу падишаһлык вә бу нигъмәтләр Безнең сиңа биргән бүләгебез, ошбу Без биргән бүләктән теләгән кемсәгә бир, теләмәгән кемсәгә бирмә, моның өчен хисап тотмассың (39)».*

Җәнабел Хак, бәндәләрне иманга өндәсен өчен, Сөләйман галәйһиссәламгә бик күп өстенлекләр вә могҗизалар бирде, шулардан берсе кошлар телен өйрәтә. Ул кошларның сөйләшүләрен аңлый һәм теләкләрен белә башлый. «Ән-Нәмел»

сүрәсенең 16 нчы аяти кәримәсеннән моның шулай булуын күрәбез:

وَقَالَ يَٰٓأَيُّهَا ٱلنَّاسُ عُلِّمْنَا مَنطِقَ ٱلطَّيْرِ وَأُوتِينَا مِن كُلِّ شَىْءٍ ۖ إِنَّ هَٰذَا لَهُوَ ٱلْفَضْلُ ٱلْمُبِينُ ﴿١٦﴾

«Үә каалә йәә әййүһәннәсү гүллимнәә мәнтыйкат-тайри үә үүтиинәә миң күлли шәйин иннә һәәзәә ләһүүәл-фәдлүл-мүбиин (16)».

М ә г ъ н ә с е : *«Вә әйтте: «И, кешеләр! Мин кошлар белән сөйләшергә өйрәтелдем, пәйгамбәрлеккә вә патшалыкка бирелә торган бар нәрсәләр дә миңа бирелде, миңа бирелгән бу нәрсәләр, әлбәттә, башкаларга бирелгәннән артыктыр (16)».*

Аллаһы Тәгалә Сөләйман галәйһиссәламгә төрле хайваннарның, балыкларның, бөҗәкләрнең вә кырмыскаларның телләрен өйрәтте. Бу хакта Коръән Кәримнең «ән-Нәмел» сүрәсе, 17–19 нчы аяти кәримәләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَحُشِرَ لِسُلَيْمَٰنَ جُنُودُهُۥ مِنَ ٱلْجِنِّ وَٱلْإِنسِ وَٱلطَّيْرِ فَهُمْ يُوزَعُونَ ﴿١٧﴾ حَتَّىٰٓ إِذَآ أَتَوْا۟ عَلَىٰ وَادِ ٱلنَّمْلِ قَالَتْ
نَمْلَةٌ يَٰٓأَيُّهَا ٱلنَّمْلُ ٱدْخُلُوا۟ مَسَٰكِنَكُمْ لَا يَحْطِمَنَّكُمْ سُلَيْمَٰنُ وَجُنُودُهُۥ وَهُمْ لَا يَشْعُرُونَ ﴿١٨﴾ فَتَبَسَّمَ ضَاحِكًا
مِّن قَوْلِهَا وَقَالَ رَبِّ أَوْزِعْنِىٓ أَنْ أَشْكُرَ نِعْمَتَكَ ٱلَّتِىٓ أَنْعَمْتَ عَلَىَّ وَعَلَىٰ وَٰلِدَىَّ وَأَنْ أَعْمَلَ صَٰلِحًا تَرْضَىٰهُ
وَأَدْخِلْنِى بِرَحْمَتِكَ فِى عِبَادِكَ ٱلصَّٰلِحِينَ ﴿١٩﴾

«Үә хүшира лисүләймәәнә җүнүүдүһү минәл җинни үәл иңси үә үәт-тайри фәһүм йүүзәгүүн (17). Хәттәә изәә әтәү гәләә үәәдин-нәмли кааләт нәмләтүй-йәә-әййүһән-нәмлүд хулүү мәсәәкинәкүм. Ләә йәхтыймәннәкүм Сүләймәәнү үә җүнүүдүһү үә һүм ләә йәшгүрүүн (18). Фәтәбәссәмә даахикәм-миң каулиһәә үә каалә Рабби әүзигнииән әшкүра нигмәтәкәл-ләтии әнгәмтә гәләййә үә гәләә үәәлидәййә үәән әгмәлә саалихәң тәрдааһү, үә әдехыйлнии бирахмәтикә фии гибәәдикәс-саалиһиин (19)».

М ә г ъ н ә с е : *«Сөләйман үз гаскәренә җыелырга әмер бирде; кешеләр, җеннәр вә кошлар җыелдылар, барысы да җыелып беткәнче көтеп тордылар (17). Кайчан алар бер кырмыска өеменә килеп җиттеләр, кырмыскаларның патшасы Сөләйман гаскәрен күреп әйтте: «И, кырмыскалар! Керегез урын-*

*нарыгызга, Сөләйман вә аның гаскәре сезне сизмичә таптап китмәсеннәр»,* — диде (18). *Сөләйман кырмысканың сүзеннән елмаеп көлде вә әйтте: «И, Раббым! Үземә вә ата-анама биргән нигъмәтләреңә шөкер итмәккә миңа илһам бир, дәхи Син риза була торган изге гамәлләр кылырга ярдәм бир, вә рәхмәтең илә мине изге бәндәләрең арасына керт! (19)».*

Сөләйман галәйһиссәлам Хак Сөбханә вә Тәгаләгә зур рәхмәтләр илә шөкрана кылып, гел намазда булды, хәмед вә салаватлар, ягъни мактау догалары укыды. Аллаһы Тәгалә җилгә вә җеннәргә Сөләйман галәйһиссәламгә буйсынырга әмер кылды. «Әл-Әнбия» сүрәсенең 81–82 нче аяти кәримәләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

ولسليمن الريح عاصفة تجرى بامره الى الارض التى بركنا فيها وكنا بكل شىء علمين ٨١

ومن الشيطين من يغوصون له ويعملون عملا دون ذلك وكنا لهم حفظين ٨٢

«Үә ли Сүләймәәнәр-риихә гәәсыйфәтәң тәҗрии би әмриһии иләл әрдыйл-lәтии бәәракнәә фииһә. Үә күннәә бикүллии шәйин гәәлимиин (81). Үә минәш-шәйәәтыйййни мәййәгуусуунә ләһүү үә йәгмәлүүнә гәмәләң дүүнә зәәлик. Үә күннәә ләһүм хәәфизыййн (82)».

Мәгънәсе: *«Вә Сөләйманга каты исүче җилне ихтыяр кылдык, ул җил, Сөләйманны күтәреп, аның әмере илә Без бәрәкәтле кылган җиргә алып барыр. Без һәрнәрсәне белүче булдык (81). Дәхи Сөләйманга шайтаннарны итагать иттердек; диңгезгә чумып, җәүһәр ташларын чыгара торганнарын вә диңгезгә чумудан башка эшләрне дә алар беләләр иде. Вә Без аларны Сөләйманга итагать итсеннәр өчен карап, тикшереп тордык (82)».*

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә Сөләйман галәйһиссәламгә искиткеч матур атлар бүләк итте. Ул күп вакытын аларны иркәләп, кыргыч белән йоннарын чистартып үткәрә вә аларны уйната иде. Ә бервакыт, атлар илә мәшгуль булып, икенде намазы вакытын да онытып җибәрде. «Сад» сүрәсенең 31–32 нче аяти кәримәләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

اذ عرض عليه بالعشى الصفنت الجياد ٣١

فَقَالَ إِنِّيٓ أَحْبَبْتُ حُبَّ ٱلْخَيْرِ عَن ذِكْرِ رَبِّى حَتَّىٰ تَوَارَتْ بِٱلْحِجَابِ ۝٣٢

«Из гурида гәләйһи бил гәшиййис-саафинәәтүл җийәәде (31). Фә каалә иннии әхбәбтү хүббәл хайри гәң зикри Раббии хәттәә тәүәәрат бил хиҗәәбе (32)».

Мәгънәсе: *«Икенде намазына хәтле Сөләйманга Хак Тәгаләдән бүләк итеп атлар бирелде, ул атлар бик җиңел вә бик тиз йөрүче, тышкы кыяфәтләре бик тә матур атлардыр. Сөләйман, атларның матурлыгына сокланып, аларны уйнату илә мәшгуль булды, хәтта икенде намазын онытып, аны кичектерде (31). Сөләйман үкенеп әйтте: «Мин, атларга карата булган мәхәббәтемә авышып, Раббымның зикере булган намазны кичектердем, хәтта кояш баеганын да сизмәдем (32)».*

Сөләйман галәйһиссәлам бик үкенде, икенде намазын ахшамнан соң каза кылып укыды. Ястү намазыннан соң тәүбә-истигъфар кылып, бу төнне сәҗдә кылып үткәрде.

Бервакыт Сөләйман галәйһиссәлам үзенең гаскәре, үзенә буйсынган җанварлар вә кош-кортлар белән ауга чыкты. Саф һавалы табигатьтә озак йөргәч, сусадылар, әмма бер җирдә дә су юк иде. Суның кайдалыгын хәбәр итүче һөдһөд кошының кайдалыгын сорады, әмма аны беркем дә белми иде. Һөдһөд кошының рөхсәт сорамыйча үз урынын ташлап китүе Сөләйман галәйһиссәламнең ачуын чыгарды: «Әгәр дә ул ни өчен үз урынын ташлап киткәнен дәлилле алмаса, мин аны җәзалап үтерәм», — диде. Икенче көнне һөдһөд кошы әйләнеп кайтты һәм әйтте: «И, падишам, мине Аллаһы Тәгалә син белми торган җиргә җибәргән иде, синә яңа хәбәр белән кайттым», — диде. «Ән-Нәмел» сүрәсенең 20–24 нче аяти кәримәләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَتَفَقَّدَ ٱلطَّيْرَ فَقَالَ مَا لِىَ لَآ أَرَى ٱلْهُدْهُدَ أَمْ كَانَ مِنَ ٱلْغَآئِبِينَ ۝٢٠ لَأُعَذِّبَنَّهُۥ عَذَابًا شَدِيدًا أَوْ لَأَا۟ذْبَحَنَّهُۥٓ أَوْ لَيَأْتِيَنِّى بِسُلْطَٰنٍ مُّبِينٍ ۝٢١ فَمَكَثَ غَيْرَ بَعِيدٍ فَقَالَ أَحَطتُ بِمَا لَمْ تُحِطْ بِهِۦ وَجِئْتُكَ مِن سَبَإٍۭ بِنَبَإٍ يَقِينٍ ۝٢٢ إِنِّى وَجَدتُّ ٱمْرَأَةً تَمْلِكُهُمْ وَأُوتِيَتْ مِن كُلِّ شَىْءٍ وَلَهَا عَرْشٌ عَظِيمٌ ۝٢٣ وَجَدتُّهَا وَقَوْمَهَا يَسْجُدُونَ لِلشَّمْسِ مِن دُونِ ٱللَّهِ وَزَيَّنَ لَهُمُ ٱلشَّيْطَٰنُ أَعْمَٰلَهُمْ فَصَدَّهُمْ عَنِ ٱلسَّبِيلِ فَهُمْ لَا يَهْتَدُونَ ۝٢٤

«Үә тәфәккадәт-тайра фәкаалә мәәлии ләә әрал һүд-һүдә әм кәәнә минәл гааибиин (20). Лә үгәззи бәннәһүү гәзәәбәң

шәдиидән әү лә әзбәхәннәһүү әүләйәә тийәннии бисүлтаанимм-мүбиин (21). Фәмәкәсә гайра бәгиидиң фәкаалә әхәттү бимәәләм түһитъ биһии үәҗиэтүкә миң сәбәбим-бинәбәий-йәкыййн (22). Иннии үә җәдтүм-раәтәң-тәмликүһүм үә үтийәт миң күлли шәйин үә ләһәә гәршүн гәзыййм (23). Үә җәдтүһәә үә каумәһәә йәсҗүдүүнә лиш-шәмси миң дүүнил-лләәһ. Үә зәййәнә ләһүмүш-шәйттаанү әгмәәләһүм фәсаддаһүм гәнис-сәбиили фәһүм ләә йәһтәдүүн (24)».

Мәгънәсе: *«Сөләйман шул арада һөдһөд кошын югалтты һәм әйтте: «Миңа ни булды, һөдһөд кошын күрмимен, ул кая югалды? (20). Әгәр ул качкан булса, мин аны, әлбәттә, бик каты газап кылырмын, китүенә ачык дәлил китерсә, ул вакытта котылыр» (21). Аз гына вакыт үткәч, һөдһөд кошы, бер гаепле кеше кеби башын иеп, түбәнчелек илә Сөләйман янына килде вә әйтте: «И, падишаһым! Мин, ерак җиргә барып, син белмәгәнне белдем, Сәба шәһәреннән сиңа хак булган яңа хәбәр белән кайттым (22). Мин Бәлкыйс исемле бер хатын патшаны таптым, ул хатынга патшаларга бирелә торган һәрнәрсә дә бирелгән, дәхи аның искиткеч матур итеп зиннәтләнгән бер зур тәхете бар (23). Ул хатынны вә аның кавемен, бер Аллаһыны танымыйча, кояшка табынучылар икәнлекләрен белдем, шайтан аларга кояшка табынуларын яхшы гамәл итеп күрсәткән вә хак диннән тыйган, инде алар хак дингә кермәсләр (24)».*

Сөләйман галәйһиссәлам әйтте: «Карарбыз: син дөрес сөйлисеңме, әллә алдакчыларның берсеме. Менә сиңа хат, аны Йәмән мәмләкәте, Сәба шәһәре мәликәсе Бәлкыйска тапшыр вә тиз вакытта әйләнеп кайт», — дип, һөдһөдкә хат тапшырды. Хатны укыгач, Бәлкыйс үзенең вәзирләре белән киңәшкәч, бүләкләр белән үзенең илчеләрен җибәрергә булды, алар кайткач, зур гаскәр белән үзе барырга ниятләде. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә «ән-Нәмел» сүрәсенең 27–37 нче аяти кәримәләрендә әйтә:

قَالَ سَنَنظُرُ أَصَدَقْتَ أَمْ كُنتَ مِنَ الْكَٰذِبِينَ ۝٢٧ اذْهَب بِّكِتَٰبِى هَٰذَا فَأَلْقِهْ إِلَيْهِمْ ثُمَّ تَوَلَّ عَنْهُمْ
فَانظُرْ مَاذَا يَرْجِعُونَ ۝٢٨ قَالَتْ يَٰٓأَيُّهَا الْمَلَؤُا۟ إِنِّىٓ أُلْقِىَ إِلَىَّ كِتَٰبٌ كَرِيمٌ ۝٢٩ إِنَّهُۥ مِن سُلَيْمَٰنَ
وَإِنَّهُۥ بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ ۝٣٠ أَلَّا تَعْلُوا۟ عَلَىَّ وَأْتُونِى مُسْلِمِينَ ۝٣١ قَالَتْ يَٰٓأَيُّهَا الْمَلَؤُا۟

أَفْتُونِي فِي أَمْرِي مَا كُنتُ قَاطِعَةً أَمْرًا حَتَّىٰ تَشْهَدُونِ ﴿٣٢﴾ قَالُوا نَحْنُ أُولُو قُوَّةٍ وَأُولُو بَأْسٍ شَدِيدٍ
وَالْأَمْرُ إِلَيْكِ فَانظُرِي مَاذَا تَأْمُرِينَ ﴿٣٣﴾ قَالَتْ إِنَّ الْمُلُوكَ إِذَا دَخَلُوا قَرْيَةً أَفْسَدُوهَا وَجَعَلُوا أَعِزَّةَ
أَهْلِهَا أَذِلَّةً وَكَذَٰلِكَ يَفْعَلُونَ ﴿٣٤﴾ وَإِنِّي مُرْسِلَةٌ إِلَيْهِم بِهَدِيَّةٍ فَنَاظِرَةٌ بِمَ يَرْجِعُ الْمُرْسَلُونَ ﴿٣٥﴾ فَلَمَّا جَاءَ
سُلَيْمَانَ قَالَ أَتُمِدُّونَنِ بِمَالٍ فَمَا آتَانِيَ اللَّهُ خَيْرٌ مِّمَّا آتَاكُم بَلْ أَنتُم بِهَدِيَّتِكُمْ تَفْرَحُونَ ﴿٣٦﴾
ارْجِعْ إِلَيْهِمْ فَلَنَأْتِيَنَّهُم بِجُنُودٍ لَّا قِبَلَ لَهُم بِهَا وَلَنُخْرِجَنَّهُم مِّنْهَا أَذِلَّةً وَهُمْ صَاغِرُونَ ﴿٣٧﴾

«Каалә сәнәнзуру әсдакътә әм күнтә минәл кәәзибиин (27). Изһәбе бикитәәбии һәәзәә фә әлкыйһ иләйһим сүммә тәүәллә гәнһүм фәнзур мәә зәә йәрҗигүүн (28). Кааләт йәә әййүһәл мәлә үинни үлкыйә иләййә китәәбуң кәриим (29). Иннәһүү миң Сүләймәәнә үә иннәһүү бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим (30). Әлләә тәглүү гәләй-йә үә этүүнии мүслимиин (31). Каләт йәә әййүһәл мәләү әфтүүнии фии әмри. Мәә күнтү каатыйгәтән әмран хәттәә тәшһәдүүн (32). Каалүү нәхнү үүлүү кувәтин үә үүлүү бәәсиң шәдиидин, үәл әмру иләйки, фәнзурии мәә зәә тәәмүриин (33). Кааләт иннәл мүлүүкә изәә дәхалүү карйәтән әфсәдүү һәә үәә җәгәлүү әгиз-зәтә әһлиһәә әзилләтәү-үә кәзәәликә йәфгәлүүн (34). Үә иннии мүрсиләтүн иләйһим биһдийәтиң фәнәәзыйратүм-бимә йәрҗигүл мүрсәлүүн (35). Фәләммәә җәә-ә Сүләймәәнә каалә әтүмиддүүнәни бимәәлиң фәмәә әәтәәнәл-лааһү хайрум-миммәә әәтәәкүм. Бәл әңтүм биһәдий-йәтикүм тәфрахүүн (36). Ирҗиг иләйһим фәләнәә тийән-нәһүм биҗүнүүдил-ләә кыйбәлә ләһүм биһәә үә ләнүхъри җәннәһүм-минһәә әзилләтәү-үә һүм саагыйруун (37)».

Мәгънәсе: *«Сөләйман әйтте: «И, һөдһөд, тиз карарбыз син китергән хәбәрне, дөресме яки ялганчылардан булдыңмы? (27). Менә бу хатымны алып барып алларына куй, соңыннан читкәрәк китеп карап тор, нинди җавап бирерләр». Һөдһөд хатны илтеп алларына куйды (28). Бәлкыйс хатны алгач, әйтте: «И, җәмәгать! Миңа бер яхшы хат тапшырылды (29). Ул хат Сөләйманнандыр вә ул хатта: «Рәхмәтле вә рәхимле булган Аллаһының исеме белән әйтәмен (30). Миңа тәкәбберлек кылмагыз, итагать иткәнегез хәлдә миңа килегез», — дип язылган», — диде (31). Бәлкыйс янә үзенең янын-*

*дагыларына әйтте: «И, җәмәгать! Ошбу эш хосусында нинди киңәшегез вә хәйләгез бар, миңа әйтегез, мин бер эш хакында карар чыгармыйм, мәгәр сезнең белән бергә булганда гына карар чыгарамын» (32). Бәлкыйсның ярдәмчеләре әйттеләр: «Без — куәт ияләребез вә сугышларда күп батырлык ияләребез, шулай булса да, эш синең тапшырыла, уйлап эш кыл, сугышыргамы яки килешергәме, ничек әйтсәң — без синең сүзеңнән чыкмабыз» (33). Бәлкыйс әйтте: «Әгәр патшалар бер шәһәргә һөҗүм илә керсәләр, ул шәһәрне җимерәләр вә хөрмәтле олуг кешеләрен иң түбән вә хур итеп калдыралар, патшалар әнә шулай кылырлар (34). Мин Сөләйманга бүләкләр белән илчеләр җибәрәмен, соңра карармын, илчеләр нәрсә белән кайтырлар, минем бүләгемне кабул итеп алырлармы, юкмы?» (Бәлкыйсның җибәргән бүләкләре: биш йөз кол, биш йөз җария, биш йөз алтын кирпече вә башка кыйммәтле нәрсәләр иде) (35). Илчеләр бүләкләре белән Сөләйман хозурына килгәч, Сөләйман әйтте: «Миңа мал белән ярдәм итәсезме, Аллаһының миңа биргән пәйгамбәрлек вә патшалыгы сез алып килгән малдан хәерлерәктер, бәлки сез ошбу бүләкләрегез белән үзегез мактанырсыз» (36). Бүләкләр алып килгән илчеләргә Сөләйман әйтте: «Бүләкләрегезне алып кайтып, Бәлкыйска тапшырыгыз, без, әлбәттә, ул имансызларга гаскәр белән барабыз, безнең гаскәребезгә каршы торырга аларның көче булмас, без аларны Сәба шәһәреннән хур итеп чыгарырбыз». Илче, иленә кайтып, Сөләйман әйткән сүзләрне Бәлкыйска ирештерде. Бәлкыйс, Сөләйманның пәйгамбәр икәнлегенә инанып, аның янына барырга юлга чыкты. Сөләйман Бәлкыйсның күп гаскәр белән килгәненерактан күрде (37)».*

Бәлкыйс Сөләйман галәйһиссәлам белән очрашуга кадәр тәхетен сарай эчендәге җиде кат бүлмәнең иң түренә урнаштырып куйды. Җиде кат йозакка бикләп, аны сакларга 77 сакчы куйды, сакчыларга әлеге бәһасез тәхетне күз карасыдай сакларга кушты. Сөләйман галәйһиссәлам үзенең дөньядагы иң бөек патша икәнлегенә ышандыру өчен Бәлкыйсның тәхетен биргә китертеп вә аны бераз үзгәртеп, патшабикәгә утырырга тәкъдим итәргә уйлады. Бу хакта Коръән Кәримнең «ән-Нәмел» сүрәсе, 38–44 нче аяти кәримәләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

قال يأيها الملؤا أيكم يأتيني بعرشها قبل أن يأتوني مسلمين ۝٣٨ قال عفريت من الجن أنا آتيك به قبل أن
تقوم من مقامك وإني عليه لقوي أمين ۝٣٩ قال الذي عنده علم من الكتب أنا آتيك به قبل أن يرتد
إليك طرفك فلما رآه مستقرا عنده قال هذا من فضل ربي ليبلوني ءأشكر أم أكفر ومن شكر فإنما
يشكر لنفسه ومن كفر فإن ربي غني كريم ۝٤٠ قال نكروا لها عرشها ننظر أتهتدي أم تكون من
الذين لا يهتدون ۝٤١ فلما جاءت قيل أهكذا عرشك قالت كأنه هو وأوتينا العلم من قبلها وكنا
مسلمين ۝٤٢ وصدها ما كانت تعبد من دون الله إنها كانت من قوم كفرين ۝٤٣ قيل لها ادخلي الصرح
فلما رأته حسبته لجة وكشفت عن ساقيها قال إنه صرح ممرد من قوارير ۝ قالت رب إني ظلمت نفسي
وأسلمت مع سليمن لله رب العلمين ۝٤٤

«Каалә йәә әййүhәл мәлә-ү әййүкүм йәэтиинии бигәршиhәә каблә әййәтүүнии мүслимиин (38). Каалә гифриитүн минәл җинни әнә әәтиикә биhии кабелә әң тәкуумә мим-мәкаамик. Үә иннии гәләйhи ләкаүиййүн әмиин (39). Каалә-ләзии гиңдәhүү гилмүмминәл китәәби әнә әәтиикә биhии каблә әййәртәддә иләйкә тарфүк. Фәләммәә рәәhү мүстәкыйрран гиндәүү каалә hәәзәә миң фәдли раббии лийәбелу-үәнии ә-әшкүру әм әкфүр. Үә мәң шәкәра фәин-нәмәә йәшкүру линәфсиh. Үә мәң кәфәра фәиннә раббии гәнииййүң кәриим (40). Каалә нәккируу ләhәә гәршәhәә нәнзур әтәhдәдии әм тәкүүнү минәлләзиинә ләә йәhтәдүүн (41). Фәләммәә җәә-әт кыййлә әhәәкәзәә гәршүк. Кааләт кәәннәhүү hүә, үә үүтиинәл-гилмә миң каблиhәә үә күннәә мүслимиин (42). Үә саддәhәә мәә кәәнәт-тәгбеду миң дүүнил-ләәhи иннәhәә кәәнәт миң каумиң кәәфириин (43). Кыййләләhәд хулис-сархә, фәләммәә рәәтhү хәсибәтhү лүҗҗәтәү-үә кәшәфәт гәң сәәкайhәә, каалә иннәhүү сархүн мүммәр-радүм-миң каүәәриир. Кааләт рабби иннии заләмтү нәфсии үә әсләмтү мәгә Сүләймәәнә лилләәhи раббил гәәләмиин (44)».

Мәгънәсе: *«Сөләйман әйтте: «И, җәмәгать! Бәлкыйсның тәхетен миңа кайсыгыз китерә, алар минем яныма килеп, иман китереп, мөселман булганнарына чаклы?» (Кяфер хәлләрендә аларның әйберләрен алырга ярый, әмма иман китереп мөселман булгач, бер әйберен дә алырга дөрес булмас)*

*(38). Җен таифәсеннән булган Гыйфрит әйтте: «Син утырган урыныңнан торганчы, мин ул тәхетне тѳзек хәлендә алып килергә, әлбәттә, кадирмын», — диде (39). Аллаһы китабын яхшы белгән вәзире әйтте: «Син, бер тарафка башыңны борып, яңадан алдыңа караганчы, Хак Тәгаләнең рәхмәте илә, ул тәхетне алып килермен». Сѳләйман, башын күтәреп, күккә карады, яңадан алдына караса, алдында искиткеч матур тәхетне күрде. Сѳләйман тәхетне алдында күргәч, әйтте: «Бу тәхетнең шулай тиз килүе Раббымның бер могҗизасыдыр, шѳкер итәрме яки кѳферлек кылырмы, дип мине сынар ѳчендер. Берәү шѳкер итсә, үзе ѳчен шѳкер итәдер, вә берәү нигъмәткә кѳферлек итсә дә аның үзенә кайтадыр, тәхкыйк, аның шѳкер итүенә Раббыбыз һич тә мохтаҗ түгел, Ул байдыр» (40). Сѳләйман әйтте: «Тәхетнең тышкы күренешен үзгәртегез, карарбыз: Бәлкыйс үзенең тәхетен танырмы яки танымаучылардан булырмы?» (41). Бәлкыйс Сѳләйман янына килгәч, аңа әйтелде: «Синең тәхетең шундый идеме? Бәлкыйс әйтте: «Әйе, бу тәхет минем тәхетемә охшаган, минем тәхетем булса кирәк, ошбу хәлдән элек Аллаһының кодрәтенә, синең пәйгамбәрлегеңә, безгә дәлил бирелеп, иман китереп, без мѳселман булган идек» (42). Сѳләйман Бәлкыйсны Аллаһыдан башка кояшка гыйбадәт кылудан тыйды, чѳнки Бәлкыйс элек кяферләр кавеменнән иде (43). (Бәлкыйсның аягы ишәк аягы кеби йонлы икән дигән хәбәр таратканнар иде шайтаннар, шуны белмәк ѳчен, Сѳләйман, пыяладан бер бина ясатып, идәнен дә пыяладан ясатып, идән астына су тутыртты һәм суга балыклар җибәрде.) Бәлкыйска шул пыяла сарайга керергә әйтелде. Бәлкыйс сарайга кергәндә, суга керәм дип уйлады һәм аяк балтырларын ачты (Сѳләйман, күренмичә, бер читтән карап торды, Бәлкыйсның аягында бернинди йон юклыгын күрде). Сѳләйман әйтте: «Син уйлаганча тирән су түгел, бәлки су ѳстенә урнаштырылган пыяла идән ул». Бәлкыйс әйтте: «И, Раббым! Ничә еллар кояшка табынып, үземә вә кавемемә золым иткәнмен, инде барча галәмне тәрбия кылучы Аллаһы Тәгаләгә вә Аның пәйгамбәре Сѳләйман галәйһиссәламгә иман китереп, мѳселман булдым (44)».*

Сѳләйман галәйһиссәлам Бәлкыйсның матурлыгын, акыллылыгын бик яратты вә аны никахлап үзенә хатын итте. Бер-

никадәр вакыттан соң аны үзенең асыл йорты Сәбага җибәрде. Бәлкыйс Йәмән мәмләкәтендә падишаһлык кылды, аңа буйсынган кавемнәр иман китерделәр. Сөләйман һәр айда, Сәба шәһәренә барып, Бәлкыйс янында өч көн торып кайта иде. Аллаһы Тәгалә Сөләйман галәйһиссәламне сынау өчен 40 көн буена аның патшалыгы белән идарә итәргә бер шайтанга ирек бирде. «Сад» сүрәсенең 34 нче аяти кәримәсендә Хак Тәгалә әйтә:

وَلَقَدْ فَتَنَّا سُلَيْمٰنَ وَأَلْقَيْنَا عَلٰى كُرْسِيِّهِ جَسَدًا ثُمَّ أَنَابَ ﴿٣٤﴾

«Үә ләкаде фәтән-нәә Сүләймәәнә үә әлкайнәә гәләә күрсийи-һии җәсәдәң сүммә әнәәбе (34)».

Мәгънәсе: *«Тәхкыйк, Без Сөләйманны патшалыгын алмак белән бәлаләндердек, чөнки аның патшалыгы йөзегендә иде, бер кич йөзеген хатыны янында калдырып киткәч, Сөләйман сурәтенә кергән бер җен йөзекне алып китте, шуның белән бергә Сөләйманның кулыннан патшалыгы да китте. Вә без аның тәхетенә әлеге йөзекне алган җенне утырттык, соңра Сөләйман тәүбә-истигъфар кылды, Аллаһыга кайтты, ягъни йөзекне кулга төшереп, яңадан патша булды (34)».*

# ЮНЫС ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Юныс пәйгамбәрнең нәсәбе, ягъни нәселыругы, ата-бабалары бәни Исраил кавеменнән булып, аның атасы — Мәтә, аның атасы — Биниәмин, аның атасы — Ягъкуб галәйһиссәлам була.

Юныс галәйһиссәламне Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә бик күп олуг нигъмәтләр белән нигъмәтләндерә — Коръән Кәримнең 10 нчы сүрәсен аның исем-шәрифе белән атый. Моннан башка аңа пәйгамбәрлек ихсан кыла, ягъни яхшылык вә изге гамәлләр кылырга мөмкинлекләр ача. Кирәк вакытта аңа Хак Тәгаләдән вәхи килеп тора. Коръән Кәримдә дүрт аяти кәримәдә аның исеме әйтелә. «Ән-Ниса» сүрәсенең 163 нче аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

إِنَّا أَوْحَيْنَا إِلَيْكَ كَمَا أَوْحَيْنَا إِلَىٰ نُوحٍ وَالنَّبِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ وَأَوْحَيْنَا إِلَىٰ إِبْرَاهِيمَ وَإِسْمَاعِيلَ وَإِسْحَاقَ
وَيَعْقُوبَ وَالْأَسْبَاطِ وَعِيسَىٰ وَأَيُّوبَ وَيُونُسَ وَهَارُونَ وَسُلَيْمَانَ وَآتَيْنَا دَاوُودَ زَبُورًا ١٦٣

«Иннәә әү хәйнәә иләйкә кәмәә әү хәйнәә иләә Нүүхиүүәннбиййинә мим бәгъдиһ. Үә әүхәйнәә иләә Ибрааһиимә үә Исмәәгиилә үә Исхәәка үә Йәгкуубә үәл әсбәәтый үә Гиисәә үә Әййүүбә үә Йүнүүсә үә Һәәруунә үә Сүләймәәнә үә әәтәйнәә Дәәүүдә Зәбүүр (163)».

Мәгънәсе: *«Без, Нухка һәм аннан соңгы пәйгамбәрләргә вәхи биргән кебек, сиңа да вәхи кылдык, һәм Без, Ибраһимга, Исмәгыйльгә, Исхакка, Ягъкубка, Гайсәгә, Әюбкә, Юныска, Һарунга, Сөләйманга вәхи кылган кеби, Даудка Зәбур исемле китап иңдердек (163)».*

Аллаһы Тәгалә Юныс галәйһиссәламгә олуг нигъмәтләр вә дәрәҗәләр бирә. Бу хакта «әл-Әнгам» сүрәсенең 86 нчы аяти кәримәсендә дә әйтелә:

وَإِسْمَاعِيلَ وَالْيَسَعَ وَيُونُسَ وَلُوطًا وَكُلًّا فَضَّلْنَا عَلَى الْعَالَمِينَ ٨٦

«Үә Исмәәгиилә үәл Йәсәгә үә Йүүнүсә үә Лута. Үә күлләң фәддалнәә гәләл гәәләмиин (86)».

М ә г ъ н ә с е : *«Һәм Исмәгыйльне, Әльясәгъне, Юнысны һәм Лутны һидаятькә салдык, барысының да галәмдәге дәрәҗәләрен югары күтәрдек (86)».*

Аллаһы Тәгалә Юныс галәйһиссәламне күп вә тирән сулы Дәҗлә елгасы буена урнашкан Нинүә шәһәрендә яшәүче, потларга табынучы кавемгә пәйгамбәр итеп җибәрде.

Хәзрәти Юныс галәйһиссәлам бу кавемне гаять зур сабырлык белән хак дингә өндәде. Күпме генә вәгазьләсә дә бу кавемнең халкы аның вәгазь-нәсыйхәтләренә колак салмады, мәгәр ике бәндә генә иман китерде. Юныс галәйһиссәламнең мондый сабырлыгын Аллаһы Тәгалә белә һәм аңа пәйгамбәрлек вазыйфасын йөкли. Юныс галәйһиссәламгә пәйгамбәрлек иңүе хакында Коръән Кәримнең «әс-Саффәт» сүрәсе, 139 нчы аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَإِنَّ يُونُسَ لَمِنَ الْمُرْسَلِينَ ۝١٣٩

«Үә иннә Йүнүсә ләминәл-мүрсәлиин (139)».

М ә г ъ н ә с е : *«Һәм, хакыйкатьтә, Юныс Без җибәргән пәйгамбәрләрдән булды (139)».*

Хәзрәти Юныс күпме генә вәгазьләсә дә, аны тәсдыйк әйләмәделәр, ягъни аңа ышанмадылар. Ул аларны потларга табынудан тыя вә әйтә: «Әгәр дә тәүбә-истигъфар кылмасагыз, Хак Тәгалә сезләргә фәлән көнне газап бирәчәк», — дип, бу кавемне ташлап, шәһәрдән чыгып китә.

Коръән Кәримнең «әс-Саффәт» сүрәсе, 140 нчы аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

إِذْ أَبَقَ إِلَى الْفُلْكِ الْمَشْحُونِ ۝١٤٠

«Из әбәка иләл фүлкил-мәшхүүн (140)».

М ә г ъ н ә с е : *«Юныс галәйһиссәлам иман китермәгән кавемен ташлап, кешеләр белән тулган көймәгә керде (140)».*

Аның нияте Дәҗлә елгасының аргы ягына чыгып, шунда тыныч кына яшәү була. Хак Сөбханә вә Тәгаләнең әмереннән башка кавемен ташлап качуы өчен, Аллаһы Тәгалә көймәгә урыныннан кузгалмаска әмер бирә. Көймәнең урыныннан кузгалмавына көймәдәгеләр бик гаҗәпләнәләр. Араларыннан

берсе әйтә: «Җәмәгать, арабызда Хак Тәгаләгә буйсынмаучы бер адәм бардыр, шул бәндәдән котылмыйча торып, көймәбез алга таба хәрәкәт итмәс, шобага салсак, без бу бәндәнең кемлеген белербез», — ди. Шобага салалар, шобага хәзрәти Юныска чыга. Өч мәртәбә салалар, өчесендә дә шобага Юныс галәйһиссәламгә чыга. Бу хакта «әс-Саффәт» сүрәсенең 141 нче аяти кәримәсендә әйтелә:

فَسَاهَمَ فَكَانَ مِنَ الْمُدْحَضِينَ ١٤١

«Фәсәәһәмә фәкәәнә минәл-мүдхәдыййн (141)».

М ә г ъ н ә с е : *«Көймәдәгеләр белән шобага салуда катнашты һәм отылучылардан булды (141)».*

Юныс галәйһиссәлам, Аллаһы Тәгаләнең әмере булмыйча Нинүә шәһәрен вә кавемен ташлап чыгып китүе өчен Хак Тәгаләнең җәзасы шулай булырга тиешлеген аңлап, үзен Дәҗлә елгасына ата. Көймәдәгеләрнең күз алдында, Хак Тәгалә әмере илә, дәрхаль, хәзрәти Юнысны бер олуг балык йота. «Әс-Саффәт» сүрәсенең 142 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فَالْتَقَمَهُ الْحُوتُ وَهُوَ مُلِيمٌ ١٤٢

«Фәл тәкамәһүл-хүүтү үә һүә мүлиим (142)».

М ә г ъ н ә с е : *«Һәм аны хут балыгы йотты, Аллаһы Тәгаләнең рөхсәтеннән башка кавемен ташлап качканы өчен ул моңа лаек иде (142)».*

Хәзрәти Юныс галәйһиссәлам балык карынында кырык көн торды. Ул, үзенең Хак Тәгалә каршында зур гөнаһ кылганына инанып, тәүбә-истигъфар кылды. Катрә-катрә күз яшьләрен агызып, балык эчендә сәҗдә кылды. «Әс-Саффәт» сүрәсенең 143 нче аятендә Хак Тәгалә әйтә:

فَلَوْلَا أَنَّهُ كَانَ مِنَ الْمُسَبِّحِينَ ١٤٣

«Фәләү ләә әннәһү кәәнә минәл мүсәббихиин (143)».

М ә г ъ н ә с е : *«Әгәр Юныс: «Һич юктыр Илаһы, мәгәр Син генә минем Раббым, мин Сине һәр кимчелекләрдән пакьсең*

*дип беләм, мин, әлбәттә, Синең рөхсәтеннән башка качып, үземә-үзем золым итүчеләрдән булдым», — дип әйтмәгән булса, ул чакта кубарылачак көнгә кадәр балык карынында калган булыр иде (143)».*

Аллаһы Тәгалә бу хакта «әс-Саффәт» сүрәсенең 144 нче аяти кәримәсендә әйтә:

لَلَبِثَ فِى بَطْنِهِ اِلٰى يَوْمِ يُبْعَثُونَ ١٤٤

«Ләләбисә фии бәтънииһии иләә йәүми йүбгәсүүн (144)».

М ә г ъ н ә с е : *«Әлбәттә, ул балык карынында кешеләр терелеп каберләреннән кубарылган көнгә чаклы калыр иде (144)».*

Шулай ук бу хакта «әл-Әнбия» сүрәсенең 87–88 нче аяти кәримәләрендә әйтелә:

وَذَا النُّونِ اِذْ ذَهَبَ مُغَاضِبًا فَظَنَّ اَنْ لَنْ نَقْدِرَ عَلَيْهِ فَنَادٰى فِى الظُّلُمٰتِ

اَنْ لَا اِلٰهَ اِلَّا اَنْتَ سُبْحٰنَكَ اِنِّى كُنْتُ مِنَ الظّٰلِمِينَ ٨٧

فَاسْتَجَبْنَا لَهُ وَنَجَّيْنٰهُ مِنَ الْغَمِّ وَكَذٰلِكَ نُنْجِى الْمُؤْمِنِينَ ٨٨

«Үә зәннүни из зәһәбә мүгаадыйбәң фәзаннә әллән-нәкъдира гәләйһи фәнәәдәә физ-зулүмәәти әлләә иләәһә илләә әңтә сүбехәәнәкә иннии күңтү минәз-заалимииин (87). Фәстәҗәбнәә ләһүү үә нәҗ-җәйнәәһү минәл гамми, үә кәзәәликә нүнҗил мүэминииин (88)».

М ә г ъ н ә с е : *«Юнысны хәтерләгез, ул ачуланып кавеменнән аерылып китте, ул кавемен ташлап киткән өчен Безнең аңа хөкем булмас дип уйлады. Ул караңгыда, балык эчендә дога кылып, әйтте: «Йә, Раббым, Синнән башка гыйбадәт кылырга һич Илаһы юк, мәгәр Син генә, Сине һәр кимчелектән пакь дип беләмен, Синең рөхсәтеннән башка кавемемне ташлап китүем белән үземә золым итүчеләрдән булдым» (87). Без аның кылган тәүбәсен кабул иттек, вә аны ошбу*

*кайгысыннан коткардык, әнә шулай мөэминнәрне коткарабыз (88)».*

Җәнабел Хак Тәгалә Юныс галәйһиссәламнең тәүбәсен ишетте вә догасын кабул кылды һәм балыкка хәзрәти Юнысны елга читенә чыгарырга әмер бирде. Моның шулай булуын без «әс-Саффәт» сүрәсенең 145 нче аяти кәримәсеннән күрәбез:

فنبذنه بالعراء وهو سقيم ١٤٥

«Фәнәбәзнәәһү бил гәраа-и үә һүә сәкыыйм (145)».

Мәгънәсе: *«Без аны берникадәр вакыт балык карынында торканнан соң, сырхау хәлендә яр читенә чыгарып куйдык (145)».*

Аллаһы Тәгалә, аның сәламәтлеген саклау өчен, киң яфраклары белән күләгә ясаучы бер зур агач үстерә. «Әс-Саффәт» сүрәсенең 146 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وانبتنا عليه شجرة من يقطين ١٤٦

«Үә әңбәтнәә гәләйһи шәҗәратәм-мииййәкътыыйн (146)».

Мәгънәсе: *«Вә Без аның янына киң яфраклы агач үстердек, ул агач аңа кояштан күләгә булды, чөнки аның тәне җәрәхәтләнгән иде. Ул шул урында берничә көн торып, Аллаһының рәхмәте илән бик тиз сәламәтләнде (146)».*

Хәзрәти Юныс галәйһиссәлам, үз кавеменә иман китермәгән өчен аларга газап киләсен әйтеп, шәһәрдән чыгып киткәч, бу кавем халкы җыелышып Нинүә падишаһына бардылар һәм әйттеләр: «Без Юнысның пәйгамбәрлегенә ышанмыйча ялгыштык, чыннан да безләргә бу тәкәбберлегебез өчен Аллаһыдан җәза килүе бар, мондый хәлләр башка кавемнәргә килгәне мәгълүм, шуның өчен аны эзләргә арабыздан кешеләр җибәрик», — диделәр. Падишаһ аларның бу сүзләрендә хаклык барлыгын аңлады һәм Юныс галәйһиссәламне эзләргә үзенең кешеләрен җибәрде. Аны яр буендагы зур агач төбеннән таптылар һәм зур хөрмәт вә гаять тәгъзим, түбәнчелек белән йөз меңлек халкы булган Нинүә шәһәренә алып кайт-

тылар. Бу кавем Аллаһы Тәгалә бар вә бер дип иман китереп, Ислам шәригате кушканча яши башлап, Раббыбызның җәзасыннан котылып калдылар.

Без моның шулай булуын «әс-Саффәт» сүрәсенең 147–148 нче аяти кәримәләреннән күрәбез:

وارسلنه الى مائة الف او يزيدون ﴿١٤٧﴾ فامنوا فمتعنهم الى حين ﴿١٤٨﴾

«Үә әрсәлнәәһү иләә миәти әлфин әү йәзиидүүн (147). Фә әәмәнүү фәмәттәгнәәһүм иләәхиин (148)».

М ә г ъ н ә с е : *«Вә Без аны йөз меңнән артык кешесе булган шәһәргә пәйгамбәр итеп җибәрдек (147). Һәм бу юлы һәммәсе иман китерделәр, вә Без дә аларны билгеләнгән әҗәлләренә чаклы малларыннан файдаландырып, тыныч яшәттек (148)».*

Газзә вә Җәллә аңа, вәхи иңдереп, пәйгамбәрлеген дәвам итәргә мөмкинлек бирде. Бу хакта «Нун» сүрәсенең 48–50 нче аяти кәримәләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فاصبر لحكم ربك ولا تكن كصاحب الحوت اذ نادى وهو مكظوم ﴿٤٩﴾ لولا ان
تدركه نعمة من ربه لنبذ بالعراء وهو مذموم ﴿٤٩﴾ فاجتبيه ربه فجعله من الصلحين ﴿٥٠﴾

«Фәсъбир лихүкүми Раббикә үәләә тәкүң кәсаахибил хүүт. Из нәәдәә үә һүә мәкзуум (48). Ләү ләә әң тәдәәракәһү нигмәтүм-мир-раббиһии ләнүбизә бил гәраа-и үә һүә мәзмүүм (49). Фәҗтәбәәһү Раббүһү фәҗәгәләһү минәс-саалихиин (50)».

М ә г ъ н ә с е : *«Раббыңның хөкеменә вә кяферләрнең каршылык күрсәтүләренә сабыр бул, балык карынындагы Юныс кеби булма. Ул Юныс балык карынында тәүбә-истигъфар кылды, эченә кайгы вә үкенү тулган хәлдә (48). Әгәр ул Юныска балык эчендә Раббысының рәхмәте ирешмәгән булса, әлбәттә, балык эченнән чыгарылып, агачсыз вә үләнсез булган кызу сахрага чыгарып ташлап хур ителер иде (49). Ул Юнысны Раббысы ихтыяр кылды, яңадан вәхи иңдерде, вә дәхи аны изгеләрдән кылып, озын вә бәхетле гомер кичерергә насыйп әйләде (50)».*

Газиз кардәшләрем! Без ошбу аяти кәримәләрдән дога кылыначак җирнең кайда булуы артык бер әһәмиятле булмавын күрәбез. Кайда гына дога кылсак та, Җәнабел Хак безнең догаларыбызны ишетә. Чөнки дога — эшләгән гөнаһларыбыз өчен Аллаһы Тәгаләдән гафу үтенмәк. Юныс галәйһиссәлам балык карынында гөнаһлары өчен тәүбә-истигъфар кылды, тәүбәсе кабул булды. Ә тәүбә адәм балаларының күңелләрен гөнаһтан сафландыра һәм аларга котылу алып килә. Тәүбә иткән кешеләр Аллаһы Тәгаләдән ерак булудан кире кайтырлар вә, җаннарын нур эченә салып, үзләрендә тынычлык табарлар. Тәүбә Раббыбыз каршында бәндәләрнең абруен күтәрер һәм аларга ныклы терәк бирер. Димәк, тәүбә итү адәм балаларын һәлакәттән саклап кала. Тәүбә иткән кешене Аллаһы Тәгалә башкаларга караганда якынрак итә, ягъни үзенең дуслары дәрәҗәсенә күтәрә. Шунлыктан, һәркем тәүбәдән качмаска, тәкәбберләнмәскә, Хак Тәгаләдән ярлыкау үтенергә тиеш вә бу сөннәт дәрәҗәсендә йөри. Тәүбә — Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән мөмкинлек вә Аның кабул итә торган илаһи бөеклеге ул.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең бик күп хәдис-шәрифләреннән күренгәнчә, тәмугта газапланып кычкырган кемсәләрнең күбесе дөньялыктан тәүбәсез киткәннәр, Хак Тәгаләнең юлын ташлап, бозыклыкка вә хәрамга юл куйганнар. Бу бәндәләрне гөнаһ ияләре дип атарлар.

# ИЛЬЯС ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Бәни Исраил кавеме Баһил исемле потка табына башлагач, Сөбханә вә Тәгалә аларга пәйгамбәр итеп хәзрәти Ильясны җибәрде. Хәзрәти Ильясның атасы Йәсин, аның атасы Фәтхәс, аның атасы Гизәр, аның атасы Һарун иде. Бу кавемнең барчасы диярлек төрле потларга табыналар иде. Иң олуг потлары Баһил исемле булып, ул потханәнең иң түрендә алтын тәхеткә утыртылган иде.

Ошбу бозык кавемгә Ильяс галәйһиссәламнең пәйгамбәр итеп җибәрелүе хакында Коръән Кәримнең «әс-Саффәт» сүрәсе, 123 нче аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَإِنَّ إِلْيَاسَ لَمِنَ الْمُرْسَلِينَ ﴿١٢٣﴾

«Үә иннә Ильясә лимәнәл-мүрсәлиин (123)».

Мәгънәсе: *«Һәм, хакыйкатьтә, Ильяс та Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән рәсүлләр арасыннан иде (123)».*

Ильяс галәйһиссәлам бу азгын кавемгә бик күп вәгазь вә нәсыйхәт кылды. Һәм, аларның падишаһларына кереп, ошбу кәлимәи шаһәдәтне әйтергә боерды: «Ләә иләәһә илләллааһү үә иннә Илйәәсә расүүлуллааһ».

Мәгънәсе: *«Күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Аллаһы Тәгаләдән башка һич Тәңре юктыр, Ильяс галәйһиссәлам — Аллаһы Тәгаләнең рәсүледер».*

Бу кавемнең падишаһы: «Безнең тәңребез Баһил, башка тәңрене танымыйбыз, тик аңа гына табынабыз», — дип аны сарайдан куып чыгарды. Ильяс галәйһиссәлам, базарга барып: «Әй, бәни Исраил кавеме, сез бу мәгъбүдләрдән, ягъни кешеләр ясап куйган потлардан ерак булыгыз! Бөтен дөньяны вә барча мәхлукатны юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылыгыз!» — ди. Коръән Кәримнең «әс-Саффәт» сүрәсе, 124–126 нчы аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

إِذْ قَالَ لِقَوْمِهِ أَلَا تَتَّقُونَ ﴿١٢٤﴾ أَتَدْعُونَ بَعْلًا وَتَذَرُونَ أَحْسَنَ الْخَالِقِينَ ﴿١٢٥﴾

اللّٰه ربكم ورب اٰبائكم الاولين ۝١٢٦

«Из каалә ликаумиһи әләә тәттәкуун (124). Әтәд гүүнә бәгләү үә тәзәруунә әхсәнәл хааликыййн (125). Аллааһә раббәкүм үә раббә әәбәәикүмүл-әүвәлиин (126)».

М ә г ъ н ә с е : *«Ильяс пәйгамбәр кавеменә әйтте: «Сез Аллаһы Тәгаләдән, гөнаһ кылудан вә җәза алудан курыкмыйсызмы?» (124). Сез Баһилгә табынып, сезне барлыкка китергән Раббыгызны ташлыйсызмы? (125). Юктан бар итүче, иң игелекле, сезнең дә Раббыгыз булган, вә дәхи сездән әүвәл килгән ата-бабаларыгызның да Раббысыдыр (126)».*

Ильяс галәйһиссәлам аларга Аллаһы Тәгаләнең ярдәме илә бик күп могҗизалар күрсәтте, ләкин алар моңа да ышанмадылар, бу — сихер эше дип карадылар. Ул аларны Хак Тәгаләдән җәза килер, дип тә куркытты. Аны мыскыл иттеләр, аның сөйләгәннәрен әкияткә санап, аннан көлделәр, иман китермәделәр. Бу хакта Коръән Кәримнең «әс-Саффәт» сүрәсе 127–129 нчы аяти кәримәләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فكذبوه فانهم لمحضرون ۝١٢٧ الا عباد الله المخلصين ۝١٢٨ وتركنا عليه في الاخرين ۝١٢٩

«Фәкәззәбүүһү фәиннәһүм ләмүхдаруун (127). Илләә гибәәдәллааһил мүхләсыййн (128). Үә тәракнәә галәйһи фил әәхыйриин (129)».

М ә г ъ н ә с е : *«Ләкин алар аны ялганчыга чыгардылар һәм алар, хакыйкатьтә, җыелып китереләчәкләр (127). Мәгәр Аллаһның ихласлы коллары утка кертелмәсләр (128). Без Ильяска соңыннан килгәннәрнең телләрендә яхшы сүз калдырдык (129)».*

Аллаһы Тәгалә аңа, сабыр булуны теләп, Үзенең сәламен күндерде. Төрле гөнаһтан сакланып, изге гамәлләр кылырга әмер кылды. Җәнабел Хак Үзенең Коръән Кәрименең «әс-Саффәт» сүрәсе, 130–132 нче аятьләрендә әйтә:

سلٰم على ال ياسين ۝١٣٠ انا كذلك نجزي المحسنين ۝١٣١ انه من عبادنا المؤمنين ۝١٣٢

«Сәләәмүн галәә Илйәәсиин (130). Иннәә кәзәәликә нәҗзил мүхсиниин (131). Иннәәһү мин гибәәдинәл мүәминиин (132)».

М ә г ъ н ә с е : *«Ул сүз Ильяска Аллаһының сәламе булып барсын (130). Гөнаһтан сакланып изге гамәлләр кылучылар-*

*га әнә шулай изгелек итәбез (131). Дөреслектә, Ильяс Безнең хак мөэмин колларыбыздан иде (132)».*

Бу кавем Ильяс галәйһиссәламне бик иза вә җәфа кылдылар, ахырда үзләренең шәһәрләреннән чыгып китәргә мәҗбүр иттеләр. Бу хакта Коръән Кәримдә болай диелгән: «Рабби нәҗҗинии минәл каумиз-заалимиин».

Мәгънәсе: *«Йә, Раббым, мине бу залим кавемнән коткар».*

Көннәрдән бер көнне Ильяс галәйһиссәлам, Аллаһының ризалыгы илән бу кавемне ташлап, Хәлил тавына барып урнашты һәм биредә гыйбадәт илән мәшгуль булды. Хак Тәгалә Үзе җибәргән пәйгамбәргә буйсынмаулары өчен ошбу кавем яшәгән мәмләкәтнең бәрәкәтен алды. Өч ел буе күктән бер тамчы да яңгыр яумады, илгә корылык килде. Өч ел буе бәни Исраил халкы ачлыктан интекте, хәтта үләксәләр ашый башладылар. Үзләренең падишаһларына барып, хәзрәти Ильяс өндәгән дингә керик, шунсыз бу бәладән котылу юк, дип киңәштеләр. Падишаһлары риза булды, хәзрәти Ильясны эзләп табып шәһәргә алып кайтырга дип, ул шәһәрнең мәшһүр кешеләрен җибәрде. Падишаһның илчеләре, Ильяс галәйһиссәламне Хәлил тавыннан эзләп табып, хәл-әхвәлләрен, моңзарларын сөйләп бирделәр, шәһәргә падишаһлары янына баруын ялварып сорадылар. Ильяс пәйгамбәр аларны кызганды, шәһәргә падишаһ янына барырга риза булды. Падишаһ янына баргач, бу афәттән котылу өчен, Аллаһы Тәгаләгә иман китерү шарты белән, Газзә вә Җәлләгә багышлап дога кылдылар. Догасы кабул булды, дәрхаль җылы яңгыр ява башлады, барлык җирләр яшелләнде, бу елны мул итеп ашлыклар үсте, барча амбарлар ашлык белән тулды. Ильяс галәйһиссәлам падишаһтан вә ошбу кавемнән биргән вәгъдәләрен үтәүләрен таләп итте. Ләкин алар, биргән вәгъдәләрен «онытып», әүвәлгечә потларга табына башладылар. Кавеменең бу кыланышларына Ильяс галәйһиссәламнең бик хәтере калды вә: «И, Раббым! Кыямәт көненә кадәр дин Исламга, фәкыйрь-фөкарәгә вә ятим-мохтаҗларга күренмичә ярдәм итүемне вә дәхи ашау-эчүдән имин булуымны, ягъни фәрештәләр дәрәҗәсенә җиткерүеңне сорыйм», — дип дога кылды, догасы кабул булды. Кыямәткәчә Хозыр галәйһиссәлам һәм Ильяс галәйһиссәлам диңгездә вә коры җирдә ярдәмгә мохтаҗларга ярдәмче вә шәфәгатьче булдылар. Хак Сөбханә вә Тәгалә аларны Үзенең ярдәменнән ташламасын. Әмин.

# ӘЛЬЯСӘГЪ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Риваять кылынадыр ки, Шам вилаятендә Дадийан исемле бер падишаһ бар иде, үзе потка табыныр, потының исеме Әфлүн булып, гәүһәр ташлар белән бизәлмеш иде.

Фәлестин вилаятендә Ильяс галәйһиссәламнең шәкерте, Әльясәгъ исемле мөэмин — Аллаһы Тәгаләнең бер бәндәсе бар иде. Әльясәгъ даимән хәләл кәсеп берлә гыйбадәттә көн кичермеш иде. Көннәрдән бер көнне бу изге бәндә янына Хак Тәгаләнең фәрештәсе Җәбраил галәйһиссәлам килде вә әйтте: «Әльясәгъ, мин сиңа Аллаһы Тәгаләнең сәламен җиткерәм вә дәхи сөенечле хәбәр китердем, Сөбханә вә Тәгалә синең кылган гыйбадәтләреңне кабул әйләде һәм сине Үзенең пәйгамбәре итте. Ул сиңа, Шам шәһәренә барып, аның падишаһы Дадийанны иманга өндәргә боерды».

Әльясәгъ, Аллаһы Тәгаләнең фәрештәсе Җәбраил галәйһиссәлам әйткәнчә, икенче көнне үк Шам вилаятенә таба юнәлде. Берничә көннән ул инде Шам шәһәренең тәкәббер падишаһы Дадийан янында иде. Дадийан аның кем икәнлеген һәм ник килгәнлеген сорады. Әльясәгъ аның күзләренә туры карап әйтте: «Мин Фәлестин вилаятеннән, Ильяс пәйгамбәрнең шәкерте, Әльясәгъ исемле кешемен, Аллаһы Тәгалә мине Үзенең пәйгамбәре итеп сайлады һәм сине иманга өндәргә җибәрде», — диде. Дадийан әйтте: «Кем ул Аллаһ?» Әльясәгъ әйтте: «Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә — Улдыр сине вә мине юктан бар кылучы, Ибраһим галәйһиссәламнең догасы берлә Нәмрудны һәлак кылучы, Муса пәйгамбәрнең догасы берлә фиргавенне һәлак кылучы, галәмдә тиңдәшсез куәтле зат», — диде. Дадийан әйтте: «Мин Ибраһимны вә Мусаны белмимен, Әльясәгъне тотыгыз, җәза мәйданына алып чыгып, баганага кул-аякларын бәйләгез һәм шәһәр халкын җыегыз!» — диде.

Җәза мәйданына шәһәр халкы җыелып беткәч, Дадийан әйтте: «Менә бу Фәлестин иленнән килгән кеше үзен Аллаһының пәйгамбәре ди, без һәм безнең ата-бабаларыбыз табын-

ган тәңреләребезне ташлап, бары тик бер Аллаһыга гыйбадәт кылырга өнди. Аңар үлем җәзасыннан котылу өчен бер генә юл бар, ул да булса — тәңребез Әфлүнгә сәҗдә кылып, аннан гафу үтенүдер», — диде. Кул-аяклары богауланган Әльясәгъ галәйһиссәлам әйтте: «Сезнең падишаһыгыз дөрес әйтте, мин Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләнең хак пәйгамбәремен, мине падишаһыгыз Дадийанны һәм сезнең барчагызны иманга өндәргә сезне һәм мине, ай, кояш вә йолдызларны юктан бар кылучы Аллаһы Тәгалә җибәрде, шуны да бел, Дадийан, мин Хак Тәгаләдән башка беркемгә дә сәҗдә кылмаячакмын», — диде.

Мондый сүзләрне ишеткәч, Дадийан аны җәзаларга боерды. Аны алдан да, арттан да калын таяклар белән кыйный башладылар. Әльясәгъ галәйһиссәламнең куәте килеп, көчле тавыш илән: «Ләә иләәһә илләллааһу уәхдәһү ләә шәрикә ләһ», ягъни «Бер Аллаһы Тәгаләдән башка һич тәңре юктыр», — диде. Падишаһның ачуы чыгып, пычак белән аның тиресен тунарга кушты, бу җәзага түзә алмыйча, Әльясәгъ Әфлүнгә сәҗдә кылыр дип уйлады. Әльясәгъ галәйһиссәлам соңгы сулышына кадәр иман кәлимәләрен кабатлады. Шулай итеп, аны җәзалап үтерделәр. Падишаһның күңеле булып әйтте: «Моның гәүдәсен шәһәр читенә чыгарып ташлагыз, инде рәхәтләнеп хәмер эчәбез», — дип, сараена кайтып китте.

Шул вакыт һавадан бик куркыныч тавыш ишетелде, көчле җил чыгып, бик күп йортларны җимерде, сарай диварлары ярылды. Шәһәрнең күп кенә халкы, Әльясәгъ чыннан да Аллаһының илчесе булгандыр дип, Әльясәгъ өйрәткән иман кәлимәләрен әйтеп, мөселман булдылар.

Аллаһы Тәгаләнең фәрманы белән Әльясәгъ пәйгамбәр, терелеп, падишаһ сараена килеп керде. Хәмер эчеп утыручы Дадийан кулындагы хәмер савытын төшереп җибәрде. Моны күреп, сарай эчендәге күп кенә кешеләр иман китерделәр. Әльясәгъ галәйһиссәлам әйтте: «Әй, мәлгунь: «Ләә иләәһә илләллааһ үә иннәә Әльясәгъ рәсүлуллааһ», ягъни «Бер Аллаһы Тәгаләдән башка һич тәңре юк һәм дөреслектә Әльясәгъ галәйһиссәлам — Аллаһы Тәгаләнең илчеседер», — дип әйт», — диде. Падишаһ хәйран булып бераз торгач, әйтте: «Бу олуг бер сихерче булып чыкты, моның кул-аякларын богаулап, сарай астындагы зинданга илтеп ташлагыз, иртәгә мин

аны башкача җәзалап үтерермен», — диде. Әльясәгънең кул-аякларын богаулап, сарай астындагы зинданга ташладылар.

Сөбханә вә Тәгалә Әльясәгъ янына Җәбраил галәйһиссәламне җибәрде вә әйтте: «Бар, колым Әльясәгъкә әйт, бу явыз кяфернең газаплауларына сабыр итсен, оҗмах эчендә Әльясәгъ өчен иң хөрмәтле урын әзерләдем вә дәхи олуг дәрәҗә бирдем». Җәбраил галәйһиссәлам барып, Газзә вә Җәлләнең сәламен тапшырып, аны сөендерде вә әйтте: «Бу кяфер сине төрле газап белән үтерсә дә, син сабырлык кыл», — дип, Аллаһы Тәгаләнең вәхиен ирештерде. Әльясәгъ галәйһиссәлам: «Әлхәмдүлилләһи Раббил галәмин», ягъни «Һәр мактаулылык барча галәмне тәрбия кылучы Раббыма хастыр», — дип, Хак Тәгаләнең әмеренә буйсынып, шөкрана кылды.

Берничә көннән соң Дадийан падишаһ барча сихерчеләрен җыйды, олугларына хөрмәт киемнәре бирде вә әйтте: «Сезне монда чакыруымның максуды шулдыр, Фәлестин вилаятеннән минем илемә бер сихерче килде, мине вә минем вилаятемдәге барча халкымны бер Аллаһыга гыйбадәт кылырга өндәде, мин аны җәзалап үтерттем, янә терелде», — диде. Сихерчеләр әйттеләр: «Бу эш бик җиңел эшләнә, без дә үлгәнне терелтәбез, китерегез бер сыерны, без аны барлык халык алдында бугазлап, янә терелтербез», — диделәр.

Дәрхаль бер сыерны китерделәр, аны бугазлап икегә ярдылар. Сихер көче илән ул сыер терелде, ике кисәге ике сыер булды. Падишаһ, бу хәлне күреп, бик сөенде. Сихерчеләр әйттеләр: «Әгәр дә без Әльясәгъне җиңсәк, безгә ни-нәрсә бирерсең?» Падишаһ әйтте: «Ярты падишаһлыгымны бирермен», — диде. Сихерчеләр һәм падишаһ озак кына киңәшкәч, Әльясәгъне зинданнан алып чыгып, шәһәр читендәге зиратка алып барырга булдылар, аның зиратның бер читендә булган бик борынгы унҗиде кабердә булган мәетләрне терелтеп күрсәтергә тиешлеген әйттеләр, әгәр дә инде Әльясәгъ моны эшли алса, без барыбыз да иман китерербез, диделәр. Бу сүзләрне ишеткәч, Әльясәгъ галәйһиссәлам әйтте: «Мин сихерче түгелмен, Аллаһы Тәгаләнең зәгыйфь бер колымын, һәр ни кылса, моны бар нәрсәгә дә кодрәтле Аллаһы Тәгалә кыладыр, минем кулымнан бернәрсә дә килмәс», — диде. Сихерчеләрнең башлыгы, кайсы Аллаһыны әйтәсең, диде. Әльясәгъ галәйһиссәлам әйтте: «Сине, мине вә барчабызны юк-

тан бар кылган, ай, кояш, йолдыз вә барча галәмне бар кылган Аллаһыны әйтәмен», — диде. Сихерчеләр бу сүзләрдән уйга калдылар. Падишаһ, кычкырып, аларны айнытып җибәрде: «Әй, сез, бөек сихерчеләрем, ник аның әкиятләрен тыңлыйсыз, әгәр дә ул без әйткәнне үти алмаса, без аны зур казанда терекөмеш белән бергә кайнатырбыз, шуннан соң аны Аллаһысы терелтеп күрсәтсен», — дип, богауланган Әльясәгъне каберләр янына сөйрәп китерде.

Әльясәгъ галәйһиссәлам сабыр гына аңа әйтте: «Ярый, яхшы, тик миңа башта тәһарәт алырга һәм, Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә багышлап, ике рәкәгать намаз укырга рөхсәт итегез, чөнки Хак Тәгалә пакь кешенең генә догасын кабул итә», — диде. Агымсу янына барып тәһарәтләнеп, ике рәкәгать намаз укыгач: «Йә, Раббым, хаҗәтем Үзеңә мәгълүм, ярдәмеңнән ташлама», — дип, Хак Сөбханә вә Тәгаләгә багышлап дога кылды. Әльясәгъ галәйһиссәламнең ихлас күңелдән кылынган догасы кабул булды, дәрхаль ошбу унҗиде кабер ярылып, биш олуг ир, ике ир бала, ун хатын терелеп каберләреннән чыктылар. Бу могҗизага барча сихерчеләр вә барча шәһәр халкы хәйран калды. Ләкин Дадийан үзенең тәкәбберлегеннән кире кайтырга теләмәде, ул бу мәетләрнең берсе янына килеп сорады: «Ничә елдан бирле монда ятасың?» — диде. Ул кеше әйтте: «Мең елдан бирле монда ятамын», — диде. Падишаһ сорады: «Ни-нәрсәгә табына идегез?» Ул кеше әйтте: «Потларга табына идек, Хак Тәгалә безгә олуг газаплар кылды, бик үкендек, алай да файдасы булмады, газабыбыз кимемәде, сез дә потка табынмагыз, үкенерсез». Аннан соң Әльясәгъ галәйһиссәламгә күрсәтеп әйтте: «Бу кеше Сөбханә вә Тәгаләнең сезгә җибәрелгән илчеседер», — диде, мәетләрнең барчасы беравыздан: «Ләә иләәһә илләлааһә үә әннә Әльясәгъ рәсүлуллааһ», диеп иман китереп, шул заман әүвәлге хәлләренчә үлеп, каберләре эченә керделәр һәм газаптан котылдылар.

Бу могҗизаны үз күзләре белән күреп вә үз колаклары илән ишетеп торган сихерчеләр һәм шәһәр халкының күпчелеге Әльясәгъ галәйһиссәламгә иман китерделәр. Шушы гыйбрәтләрне күреп вә ишетеп торган тәкәббер Дадийан иман китермәде, үзенең Әфлүн дигән потына табынырга дип, бик ачулы кыяфәт белән сараена кайтып китте.

Әльясәгъ галәйһиссәлам иман китергән бәндәләрне шәһәрдән читкәрәк алып чыкты һәм намаз укып дога кылды: «И, Раббым! Син күрүче, Син белүчесең, бу залим, тәкәббер Дадийаннан өмет өздем, Син күрсәткән могҗизалар вә гыйбрәтләр дә аны иманга кертмәде, ул һәм аңа ияручеләр кяфер булып калдылар. Инде Үзеңнең кодрәтең илә бу кяферләргә җәзаңны бир». Догасы кабул булды.

Шул вакыт Аллаһы Тәгаләнең кодрәте илә күк күкрәде, әллә каян кара болыт килеп чыкты, ошбу кара болыттан утлы шар чыгып, шәһәрдәге барча кяферләрне яндырып бетерде.

Газиз кардәшләрем, Әльясәгъ галәйһиссәламнең Аллаһы Тәгаләнең сөекле пәйгамбәрләре арасында булуы хакында Коръән Кәримнең ике аяти кәримәсендә әйтелгән. Коръән Кәримнең «әл-Әнгам» сүрәсе, 86 нчы аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَإِسْمَٰعِيلَ وَٱلْيَسَعَ وَيُونُسَ وَلُوطًا ۚ وَكُلًّا فَضَّلْنَا عَلَى ٱلْعَٰلَمِينَ ﴿٨٦﴾

«Үә Исмәәгиилә үәл-Йәсәгә үә Йүүнүсә үә Лүүта. Үә күлләң фәддалнәә галәл гәәләмиин (86)».

М ә г ъ н ә с е : *«Һәм Исмәгыйльне, Әльясәгъне, Юнысны һәм Лутны барысын да туры юлга күндердек. Һәрберсен дөньядагы барлык кешеләрдән югары дәрәҗәләргә күтәрдек (86)».*

Коръән Кәримнең «Сад» сүрәсе, 48 нче аяти кәримәсендә Сөбханә вә Тәгалә әйтә:

وَٱذْكُرْ إِسْمَٰعِيلَ وَٱلْيَسَعَ وَذَا ٱلْكِفْلِ ۖ وَكُلٌّ مِّنَ ٱلْأَخْيَارِ ﴿٤٨﴾

«Үәзкүр Исмәәгиилә үәл Йәсәгә үә зәл-Кифли, үә күллүм-минәл әхъйәәр (48)».

М ә г ъ н ә с е : *«Янә Исмәгыйль, Әльясәгъ вә Зөлкифелләрне искә төшер, аларның һәркайсы изгеләрдән иде (48)».*

# ЛОКМАН ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Локманның атасы Багур, аның атасы Азур иде. Бу Азур Әюб галәйһиссәламнең анасы берлә бертуган кыз кардәшенең углы иде. Мең ел гомер сөрде, Дауд пәйгамбәр заманында сау-сәламәт иде. Дауд галәйһиссәлам берлә әңгәмә корып утырды, аннан гыйлемлек алды. Дауд галәйһиссәлам үзенең гаскәре өчен тимердән кием ясады. Кием ясалып тәмам булгач, беренче булып бу киемне Локман галәйһиссәлам киеп карады һәм әйтте: «И, Дауд галәйһиссәлам, нинди күркәм һәм нык итеп ясагансың син бу сугыш киемен, ләкин шунысы кызганыч, сугыш киемен мондый яхшы итеп ясый белүче осталарыбыз юк дәрәҗәсендә, шуңа күрә син бу һөнәреңне башкаларга да өйрәтергә тиешсең», — диде.

Риваять кылынадыр ки, Локман галәйһиссәлам бер төш күрә. Төшендә аңар әйтәләр: «Йә, Локман хәким, сиңа җир йөзендә пәйгамбәр һәм хәлифә булып хөкем кылмак кирәкми», — диләр. Локман галәйһиссәлам әйтә: «Миңа төрле бәлаләрдән адәмнәрне саклау өчен иминлек вә сәламәтлек кирәк вә дәхи мин беләмен, пәйгамбәрләргә пәйгамбәрлек белән бергә бәла-казалар вә төрле авырлыклар да килә, шәригать буенча хөкем кылучы пәйгамбәр көтелмәгән кыенлыклар эчендә кала. Әгәр хөкем иткәндә дөрес хөкем итсә яхшы, әгәр дә инде нәфесенә ияреп, Аллаһы Тәгаләнең шәригатенә золымлык кылса, урыны мәңгелек җәһәннәмдә булачак. Миңа ошбу фани дөньяда төрле хурлыклар күреп, ахирәттә кадерле булмак күпкә артыграктыр», — ди. Локман галәйһиссәлам йокысыннан уянды исә, Хак Тәгалә аны гыйлем вә хикмәт иясе кылды. Бәгъзе бәндәләр әйтәләр: «Локман галәйһиссәлам пәйгамбәр вә хикмәт иясе», — диләр. Бәгъзеләре әйтәләр: «Локман галәйһиссәлам пәйгамбәр түгел, ул хикмәт иясе олуг хакимдер», — диләр. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә Коръән Кәримнең 31 нче сүрәсенә «Локман» исеме биргән вә дәхи ошбу сүрәнең 12 нче аяти кәримәсендә болай ди:

وَلَقَدْ آتَيْنَا لُقْمَانَ الْحِكْمَةَ أَنِ اشْكُرْ لِلَّهِ وَمَنْ يَشْكُرْ

فَاِنَّمَا يَشْكُرُ لِنَفْسِهٖ وَمَنْ كَفَرَ فَاِنَّ اللّٰهَ غَنِيٌّ حَمِيدٌ ۝١٢

«Үә ләкаде әәтәйнәә Лукмәәнәл-хикмәтә әнишкүрлил-ләәһ. Үә мәй-йәшкүр фә-иннәмәә йәшкүру линәфсиһ. Үә мәң кәфәра фәиннәл-лааһә гәниййүн хәмииде (12)».

Мәгънәсе: *«Дөреслектә, Без Локманга хикмәт, гыйлемлекне бирдек вә әйттек: «Аллаһы Тәгаләнең биргән нигъмәтләренә һәрдаим шөкрана кыл! Берәү шөкер итсә, шөкер итүенең файдасы үзенәдер. Берәү шөкер итүне инкарь итсә, Аллаһы Тәгалә аның шөкер итүенә мохтаҗ түгелдер, хакыйкатьтә, Ул — бернәрсәгә мохтаҗ булмаучы, мактауга лаектыр (12)».*

Риваятьләргә караганда, Локман галәйһиссәламнең өч углы бар иде. Аларның исемнәре Әнгам, Әшкәм, Мәсан иде. Ул аларны үзенең тирән мәгънәле сүзләре илә вәгазьли иде. Коръән Кәримнең «Локман» сүрәсе, 13 нче аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَاِذْ قَالَ لُقْمٰنُ لِابْنِهٖ وَهُوَ يَعِظُهٗ يٰبُنَيَّ لَا تُشْرِكْ بِاللّٰهِ اِنَّ الشِّرْكَ لَظُلْمٌ عَظِيمٌ ۝١٣

«Үә из каалә Лукмәәнүл ибенииһии үә һүә йәгзуһү йәәбүнәййә ләә түшрик билләәһ. Иннәш-ширкә ләзульмүн газыйййм (13)».

Мәгънәсе: *«Локман галәйһиссәлам кылды үзенең кече углына вәгазь: «И, минем углым, Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә һичбер вакытта да ширек катма, Аны бер генә дип бел, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш итмә, Аның тиңдәше юк, хакыйкатьтә, Аллаһы Тәгаләгә ширек кату гөнаһларның иң зурысыдыр», — диде (13)».*

Риваять кылмышлар, Локман галәйһиссәламнең бер углы кяфер була. Локман хәким аны үзенең тирән фикерле вәгазьнәсыйхәтләре белән мөселман кылды, ягъни бу углы иман китереп, башкаларны да моңа өнди башлады. Локман хәкимнең үз угылларына күркәм вәгазь-нәсыйхәтләр сөйләве хакында Аллаһы Тәгалә «Локман» сүрәсенең 16 нчы аятендә әйтә:

يٰبُنَيَّ اِنَّهَا اِنْ تَكُ مِثْقَالَ حَبَّةٍ مِنْ خَرْدَلٍ فَتَكُنْ فِي صَخْرَةٍ اَوْ فِي
السَّمٰوٰتِ اَوْ فِي الْاَرْضِ يَاْتِ بِهَا اللّٰهُ اِنَّ اللّٰهَ لَطِيفٌ خَبِيرٌ ۝١٦

«Йәә бүнәййә иннәәһәә иң тәку мискаалә хәббәтим-мин хардәлиң фәтәкүң фии сахратин әү фис-сәмәәүәәти әү филәрдый йәәти биһәл-лааһ. Иннәл-лааһә ләтыйййфүн хабиир (16)».

Мәгънәсе: *«И, минем кече углым, изгелек яки явызлык, кечкенә хөрмә орлыгы кадәр генә булса да, таш астыннан да шытып чыгып зураер. Аллаһы Тәгалә яхшылыкка — җәннәт, явызлыкка җәһәннәм әзерләп куйды. Ул ачык вә яшерен кылынган гамәлләрнең һәммәсен белүчедер (16)».*

Риваять кылына, Дауд пәйгамбәр Локман галәйһиссәламгә бер куй сарыгын суеп, иң ләззәтле әгъзасыннан ике кисәк ит пешереп алып килергә куша. Локман хаким куй сарыгын «Бисмилләәһи, Аллаһу әкбәр!» дип суеп, аның теле белән йөрәген пешереп алып килә. Берничә көннән соң Дауд галәйһиссәлам янә Локман хәкимне сараена чакырып әйтә: «И, Локман хәким, инде куйның иң ләззәтсез ике әгъзасын пешереп алып кил», — ди. Локман галәйһиссәлам янә тел белән йөрәген пешереп алып килә. Дауд галәйһиссәлам аптырап сорый: «И, Локман хәким, син миңа иң ләззәтле җирен алып кил дисәм дә, иң ләззәтсез әгъзасын алып кил дисәм дә, тел илә йөрәген пешереп алып килдең, моның сере нидер?» — ди. Локман галәйһиссәлам җавабында әйтә: «И, Аллаһының рәсүле, әгъзаның яхшы җире дә вә иң яман җире дә ошбу ике әгъзага яшеренгәндер. Бар да яхшы булганда тел дә, йөрәк тә бик яхшылар, алардан да ләззәтле нәрсә юк. Яман булганда, болардан да яманрак нәрсә юктыр. Ягъни хайванның да, адәмнең дә теле берлә йөрәге яхшы булса, тирә-юньдәгеләргә дә күп шатлык вә ләззәт китерер. Әгәр теле илә йөрәге яман булса, үзенә дә һәм башкаларга да бер афәт булыр», — ди. Локман хәким вәгазь-нәсыйхәтләрендә үзенең углын намазларын үз вакытында үтәргә, кешеләргә һәрдаим изгелек эшләргә, ваемсыз булмаска өнди. «Локман» сүрәсенең 17–19 нчы аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

يٰبُنَيَّ أَقِمِ الصَّلٰوةَ وَأْمُرْ بِالْمَعْرُوفِ وَانْهَ عَنِ الْمُنْكَرِ وَاصْبِرْ عَلٰى مَا أَصَابَكَ إِنَّ ذٰلِكَ مِنْ عَزْمِ الْأُمُورِ ۝١٧

وَلَا تُصَعِّرْ خَدَّكَ لِلنَّاسِ وَلَا تَمْشِ فِي الْأَرْضِ مَرَحًا إِنَّ اللّٰهَ لَا يُحِبُّ كُلَّ مُخْتَالٍ فَخُورٍ ۝١٨

وَاقْصِدْ فِي مَشْيِكَ وَاغْضُضْ مِنْ صَوْتِكَ إِنَّ أَنْكَرَ الْأَصْوَاتِ لَصَوْتُ الْحَمِيرِ ۝١٩

«Йәә бүнәййә әкыймис-саләәтә үәәмур бил-мәгърууфи үәнһә ганил мүңкәри үәсбир гәләә мәә әсаабәк. Иннә зәәликә мин газмил-үмүүр (17). Үә ләә түсаггир хаддәкә линнәси үә ләә әәтәмши фил-әрдый мәрахә. Иннәллааһә ләә йәхиббү күллә мүхтәәлиң фәхуур (18). Үәкъсыйде фии мәшикә үәгъдудъ миң саутикә иннә әңкәрал әсүәәти ләсаутүл-хәмиир (19)».

Мәгънәсе: *«Минем кече углым, намазыңны камил вә үз вакытында үтә. Әмере билмәгъруф вә нәһи ганилмөнкәр, ягъни шәригать кушкан эшне эшләп, тыйганыннан тыел! Аллаһы Тәгалә кылган гамәлләреңне изгелек илә кайтарыр. Хакыйкатьтә, Хак Тәгалә боерган эшләргә сабырлык кыйлмак важибтыр (17). Кешеләр белән сөйләшкәндә тәкәббер рәвештә йөзеңне читкә борма. Дәхи дә җир йөзендә бик шатланып, ваемсыз рәвештә йөрмә, хакыйкатьтә, Раббыбыз ваемсыз, мактанып йөрүчеләрне сөймәс (18). Һәр җирдә үзеңне уртача тот. Шулай ук бик ашыгып вә дәхи акрын да йөрмә, тавышыңны артык күтәреп сөйләшмә, болай акырып сөйләшүең сине кычкыручы ишәккә охшатыр (19)».*

Локман хәкимне күреп белгән Ваһаб бән Мәнбә радыйаллаһу ганһе риваять кыладыр: «Локман галәйһиссәлам озын буйлы, каратут йөзле, ап-ак тешле бер изге кеше иде. Элек ул бер балта остасының колы иде. Үзе дә балта остасы иде. Эштән буш вакытында гел гыйбадәттә иде. Аллаһы Тәгаләдән вәхи килеп, ул хикмәт иясе булды исә, хуҗасы аны коллыктан азат итте. Бик күп вакытын адәм балаларына вәгазь-нәсыйхәт сөйләп үткәрә иде. Көннәрдән бер көн бер кеше Локман хәкимнән сорады: «И, Локман, син бер балта остасының колы идең, ничек син бу дәрәҗәләргә ирештең?» — диде. Локман галәйһиссәлам әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең берлегенә иман китердем, ялган сөйләмәдем, әманәткә хыянәт итмәдем, һәр мохтаҗ кешегә хәлемнән килгәнчә ярдәм итәргә тырыштым, шул сәбәпле Сөбханә вә Тәгалә мине шул дәрәҗәләргә ирештерде», — диде. Локман галәйһиссәлам Аллаһы Тәгалә боерган барча нәрсәләрне үтәде, тыйган нәрсәләрдән тыелып, хәрамнан ерак булып, шөбһәле эшләрдән сакланды.

**Хикмәт.** Беркөнне бер кеше килеп, Локман хәкимнән бурычка дип мең алтын алды. Кулына алтын кергәч, аның күңеленә Иблис мәлгунь вәсвәсә сала, «син бу алтыннарны хуҗасына кайтарып бирмәсәң, дәрхаль баеп китәрсең», ди. Һәм

ул чыннан да алтыннарны кайтарып бирмәскә ниятли. Бара торгач кысталып, алтынын капчыгы белән җиргә куеп, олуг хаҗәтен үтәргә дип куаклар арасына кереп утырды. Шул вакыт һавадан бер кош очып төшеп, алтынны капчыгы белән күтәреп очып китеп, аны Локман хәким алдына китереп куйды. Локман галәйһиссәлам, әлбәттә, үзе биргән алтыннарны һәм капчыкны таныды. Озак та үтмәде, тирләп-пешеп, бурычка алган кеше дә йөгереп килеп җитте һәм әйтте: «Йә, Локман, алтыннары белән бергә минем капчыгымны явыз кош сиңа китердеме?» — диде. Локман галәйһиссәлам әйтте: «Әйе, ул кош алтыннарны миңа китереп тапшырды, ләкин моннан соң мин сиңа бурычка бер алтын да бирмимен, чөнки син, бурычка алганыңны онытып, аларны үзеңнеке итәргә ниятләдең, моны мин Хак Тәгаләнең миңа биргән гыйлем хикмәте белән белдем һәм бу кошны синең артыңнан җибәрдем», — диде. Бу кеше Локман галәйһиссәламнең чыннан да олуг гыйлем иясе икәненә инанды һәм күңеленнән тәүбә-истигъфар кылды: «И, Раббым, әгәр дә Локман хәкимнең күңеленә рәхим-мәрхәмәт кереп, ул бу алтыннарны янә миңа бирсә, мин аларны гаиләмә һәм сәүдә эшенә тотар идем, вәгъдә иткән вакытка һичшиксез кайтарып бирер идем», — дип ният тә кылды. Локман галәйһиссәлам аның изге ниятен белде һәм аңа алтыннарын биреп җибәрде. Ул кеше, бу алтыннардан күп файда күреп, сөйләшкән вакытка китереп тапшырды.

**Хикмәт.** Бервакыт Локман галәйһиссәлам башка вилаятькә сәфәр кылырга әзерләнде. Углын чакырып, аңа васыять әйтте: «И, углым, сереңне хатыныңа әйтмә, яңа байдан бурычка алма, куштан илә дус булма», — диде. Локман хәкимнең углы да акыллы вә төпле бала иде. Атасының васыятен тәҗрибә кылмакчы булып, беркөнне үзенең сахрадагы куйларыннан бер куйны бугазлап, пешереп капчыгына салды һәм аның авызын бик нык итеп бәйләде, капчыкны хатыны күрерлек итеп өенә алып кайтып куйды. Күршедәге яңа байга кереп, бурычка аз гына алтын алды. Шәһәр башлыгының якын бер куштанына дуслык күрсәтеп, яңа байдан алган алтынны, садакадан булсын дип, аңа бирде. Локман хәкимнең углы өеннән чыгып китү белән аның хатыны, бу капчыкта нәрсә бар икән дип, аны чишмәкче булып күпме генә тырышса да чишә алмады. Кызыксынудан түземлеге беткән хатын ире кайтып керү белән ан-

нан сорады: «И, сөеклем, ул капчыкта син нәрсә алып кайттың?» Локман хәкимнең углы, як-ягына каранган булып, серле тавыш белән әйтте: «И, минем кадерлем, бүген сахрага чыккан идем, анда бер кеше белән сүзгә килеп бик нык ачуланыштык, ахырда аны үтереп котылдым, зинһар кешегә әйтә күрмә, моны сиңа гына әйтәм», — дип, «эш белән» өйдән чыгып китте. Өйгә әйләнеп кайткач, хатыны, төрле кирәкмәгән нәрсәләргә бәйләнеп, зур тавыш куптарды. Иренең бу хәлгә ачуы килеп, сугарга дип кулын күтәргән иде, хатыны дәрхаль өйдән урамга чыгып: «Каравыл, минем ирем сахрада бер кешене үтереп капчыкка тыгып алып кайткан иде, хәзер инде мине дә үтермәкче була, коткарыгыз мине бу вәхшидән», — дип кычкырды. Халык җыелды, бу хәбәр шәһәр башлыгына иреште. «Локман галәйһиссәламнең углын кайсыгыз монда гадел хөкемгә алып килә?», — дип сорагач, аның хәер-садакасын алган куштан, сикереп торып: «Мин аны үзем алып киләм», — дип, аның өенә барды һәм: «Тиз җыен, сине кеше үтергәнең өчен шәһәр башлыгы хөкемгә чакырды», — дип аңа кычкырды. Локман углы аңа: «Әй, дустым, бүген генә иң зур садаканы сиңа бирдем, зинһар, мине җибәр, мин тиз генә качып котылыйм», — диде. Куштан аның ай-ваена карамыйча кулына богау салды һәм урам буйлап сүгә-сүгә сөйри башлады. Бу хәлне күршедәге яңа бай да күрде һәм йөгереп чыгып: «Миннән бүген алган бурычыңны хәзер үк түлә, югыйсә мәхкәмәдә бер алтын урынына ун алтын алды диячәкмен», — дип, аның бугазына ябышты. Локман галәйһиссәлам углы аңа бурычын түләде. Кайчан мәхкәмәгә шәһәр башлыгына аны алып килделәр, шәһәр башлыгы каты тавыш илә аңа әйтте: «Кеше үтергәнең өчен мин сине дә үтерергә тиешмен, син бүген үк үләчәксең», — диде. Локман углы әйтте: «Сез шәригать кушканча хөкем итәсез, үлгән кешенең тәнендә никадәр җәрәхәтләре булса, мине дә шулкадәр җәрәхәтләп үтерегез», — диде. Мәхкәмә залына капчыкны күтәреп алып керделәр, тырыша торгач, аның авызын чишеп җибәрсәләр, анда пешерелгән куй сарыгын күреп, бар да хәйран булып калдылар. «Бу ни хәл?» — дип сорадылар. Локман хәким углы атасының васыятен ничек тәҗрибә кылганын сөйләп бирде. Барчасы бу кыйссадан гыйбрәт алды.

**Хикәят.** Бер залим падишаһ Локман галәйһиссәламне, ачуланып, шәһәр читендәге бер коега салдыра. Коеның өстен каплап, аның өстенә иген иктерә. Күп вакыт үтмичә бу залим падишаһ вафат булып, аның урынына икенче кешене падишаһ итеп куялар. Ул сәрхуш вакытында сөяктән җилек суырып утырганда, җилек белән бергә бер сөяк кереп, тамагына китеп кадала. Һичбер табиб бу сөякне ала алмый. Соңыннан, шәһәрнең 160 яшьлек иң карт кешесен чакыралар һәм хәлне сөйләп бирәләр. Карт әйтте: «Әгәр биредә Локман хәким булган булса, сөякне ул бик тиз чыгарган булыр иде», — диде. Падишаһ әйтте: «Кем ул Локман хәким дигәнегез, ник мин аны белмим?» Карт әйтте: «Синнән элек булган падишаһ аны тереләй коега салды, коены каплап, аны күмдереп, аның өстенә иген иктерде. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте илә ул бәлкем үлмәгәндер дә, тик бу хәлгә инде җиде ел вакыт үтте. Мин үземнең озын гомеремдә андый галим табибны күргәнем вә ишеткәнем булмады», — диде. Падишаһ тиз вакыт эчендә коены табып, аның өстен ачтырды. Локман галәйһиссәламне Аллаһы Тәгаләнең әмере илә фәрештәләр ризыкландырып торганнар, ул исән иде, тик һава начарлыктан вә хәрәкәт булмаганлыктан бик зәгыйфьләнгән иде. Коедан чыгаргач, ул үзенә кирәкле үләннәр белән берничә көн дәваланды. Бераз савыккач, падишаһ янына килде вә әйтте: «И, падишаһ, синең авыруыңның дәвасы бер генәдер, ул да булса — син үз углыңның йөрәген пешереп ашарга тиешсең, шул вакытта сәламәтләнерсең», — диде. Бу падишаһның бердәнбер газиз углы бар иде, күңеле аны үтерергә бармады. Вәзирләре әйттеләр: «И, падишаһыбыз, агач сәламәт булса, ботаклары булыр вә дәхи агачның тамырыннан да янә агачлар үсәр. Әгәр инде агач корыса, аның барча ботаклары вә тамыры да корыр», — диделәр. Падишаһны һәр көн шундый үтемле вәгазьләр белән вәгазьләгәч, ул риза булды. Локман хәкимнең боерыгы белән падишаһның угылын алып керделәр. Падишаһ, елый-елый чарасыз калып, углына карап торыр иде. Локман хәким әйтте: «И, падишаһ, син күзең илә карап торсаң, гакылдан язарсың», — дип, ике арага чаршау кордырды. Тышкы якка чыгып, тиз арада бер куй сарыгын китертте. Куйның аякларын бәйләп, чаршау артында һәр тавышны ишетеп торган падишаһка ишетелер-

лек итеп: «Бисмилләәhи, Аллаhу әкбәр!» — дип чалдылар. Куйның шаулап каны ага башлагач, падишаh бик каты хәсрәттән «ваh!» дип кычкырып җибәрде һәм шул мизгелдә аның тамагына утырган сөяге атылып килеп чыкты. «Йә, Хода, максатыбызга ирештек!» — дип, Локман хәким падишаhның углын чаршау артына, әтисе янына чыгарды. Падишаh, углының исәнимин булуын күреп, аны кочагына алып, бик озак шатлык яшьләрен койды. Локман хәкимнең гакылына вә сәләтенә барча шәһәр халкы хәйран булды вә аңа күп рәхмәтләр яудырдылар. Падишаh исә Локман хәкимне үзенең баш вәзире итеп куйды, үзе исән чагында аңа бик күп кадер-хөрмәт күрсәтте.

Локман хәкимнең моннан башка да бик күп хикмәтләре бар.

Үәссәламүгаләйкүм үә рахмәтуллаhи үә бәракәтүh!

# ГӨЗӘЕР ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Гөзәер галәйһиссәламнең атасы Шәрхис исемле кеше иде. Шам вилаятендә Хоснүри исемле бер авылда тереклек кылмыш иде. Бу заманда бәни Исраил кавеме бик күп бозыклыкларга, җаһилиять дөньясына кереп батты. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә бәни Исраил кавемен тугры юлга өндәр өчен бик күп пәйгамбәрләр җибәрде. Ләкин алар тугры юл күрсәтүче әнбияләрне вә изге бәндәләрнең сүзләрен тыңламадылар, каршы тордылар, аларны иза вә җәфа чиктереп үтерделәр. Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләнең әмерен бозып, шәригатьтә булмаган гамәлләр кылулары өчен Җәнабел Хак Бабил вилаятендә падишаһлык итүче, явызлыгы белән барча әтрафка мәшһүр булган Бәхтел Насыйр исемле гаять тә залимгә, бу тәкәббер бәни Исраил кавеме яшәгән җирләрне басып алып, үзләрен кол итәргә ирек куйды.

Бабил дәүләтенең падишаһы булган Бәхтел Насыйр бик күп гаскәр илә Әл-Кодес шәрифкә һөҗүм итте. Бәни Исраил кавеме, бер дә әзерлексез булу сәбәпле, аларга каршы тора алмады, җиңелде. Бәхтел Насыйр бәни Исраил дәүләтен җиңгәннән соң Кодес шәрифне алгач, анда булган Бәйтелмөкаддәсне, ягъни Әл-Әкъса мәсҗиден җимерде. Тәүрат шәрифнең барча нөсхәләрен яндырды. Бәни Исраилнең олугларын вә падишаһларын әсир итеп, Бабил вилаятенә кудырды. Аларны вә барча гавам халкын, кол итеп, гаять тә авыр хезмәткә куйды. Балаларны вә дин белгече, шәехләрне үтертте. Әсир төшүчеләр белән бергә хәзрәти Гөзәер вә хәзрәти Даниял галәйһиссәламнәр, кол ителеп, Бабил шәһәренә китерелгәннәр иде. Алар да әсирләр белән бергә кол рәвешендә иң авыр эшләрдә эшлиләр иде.

Җәнабел Хакның әмере илә Бәхтел Насыйр әсирләр арасында хәзрәти Гөзәер вә хәзрәти Даниял исемле ике пәйгамбәр барлыгын белде вә аларны үзенең сараена чакырып хөрмәт күрсәтте. Соңыннан аларга үз илләренә кайтырга ирек бирде. Хәзрәти Даниял үз авылына, ә хәзрәти Гөзәер галәйһиссәлам, ишәгенә атланып, Бәйтелмөкаддәскә китте. Ул күр-

де, йортлар җимерелгән, урам тулы мәетләр аунап ята. Моны күреп, ул әйтте:«Аллаһы Тәгалә боларны ничек терелтер икән?» Хак Тәгаләнең әмере илә, шул вакытта ул йокыга китте, шул ятудан йөз ел буе йоклады. Бу хәлләрнең ничек булуы хакында Коръән Кәримнең «әл-Бәкара» сүрәсе, 259 нчы аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

اَوْ كَالَّذِى مَرَّ عَلٰى قَرْيَةٍ وَهِىَ خَاوِيَةٌ عَلٰى عُرُوشِهَا قَالَ اَنّٰى يُحْيِ هٰذِهِ اللّٰهُ بَعْدَ

مَوْتِهَا فَاَمَاتَهُ اللّٰهُ مِائَةَ عَامٍ ثُمَّ بَعَثَهُ قَالَ كَمْ لَبِثْتَ قَالَ لَبِثْتُ يَوْمًا اَوْ بَعْضَ يَوْمٍ

قَالَ بَلْ لَبِثْتَ مِائَةَ عَامٍ فَانْظُرْ اِلٰى طَعَامِكَ وَشَرَابِكَ لَمْ يَتَسَنَّهْ وَانْظُرْ اِلٰى حِمَارِكَ

وَلِنَجْعَلَكَ اٰيَةً لِلنَّاسِ وَانْظُرْ اِلَى الْعِظَامِ كَيْفَ نُنْشِزُهَا ثُمَّ

نَكْسُوهَا لَحْمًا فَلَمَّا تَبَيَّنَ لَهُ قَالَ اَعْلَمُ اَنَّ اللّٰهَ عَلٰى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ ۝٢٥٩

«Әү кәлләзии мәрра гәләә карйәтиү-үә һийә хааүийәтүн гәләә гүруушиһәә каалә әннәә йухии һәәзиһил-лааһү бәгдә мәүтиһә. Фә-әмәә тәһүллааһү миәтә гәәмиң сүммә бәгәсәһ. Каалә күм ләбистә, каалә ләбистү йәүмән әү бәгда йәүм. Каалә бәл ләбистә миәтә гәәмиң фәңзур иләә тагәәмикә үә шәраабикә ләм йәтәсәннәһ. Үәңзур иләә химәәрикә үә линәҗгәликә әәйәтәл-линнәәси үәңзур иләл-гизаами кәйфә нүншизүһәә сүммә нәксүүһәә ләхмә. Фәләммәә тәбәййәнә ләһүү каалә әгләмү әннәллааһә гәләә күлли шәйин кадиир (259)».

М ә г ъ н ә с е : *«Янә кешеләре үлгән, йортлары җимерелгән шәһәр яныннан үтеп баручы Гөзәер галәйһиссәламнең хәле белән танышыгыз! Шәһәрнең асты-өскә килгәнен күреп, Гөзәер галәйһиссәлам әйтте: «Кешеләр шәһәр белән бергә һәлак булганнар, боларны Аллаһы Тәгалә ничек тергезсен?» — диде. Гөзәер галәйһиссәлам шәһәрдән үтеп үзенең авылына кайткач, Аллаһы Тәгалә аны йоклатты, йөз ел үткәч уятты һәм әйтте: «И, Гөзәер галәйһиссәлам, син күпме йокладың?» — диде. Гозәер галәйһиссәлам әйтте: «Бер көн яки бер көннән азрак йокладым». Аллаһы Тәгалә әйтте: «И, Гөзәер, бер көн түгел, ә йөз ел йокладың, кара ашый торган ризыгыңа һәм эчә торган эчемлегеңә, аларның берсе дә бо-*

*зылмаган, ә хәзер үзең атланып йөргән ишәгеңә кара». Хак Тәгаләнең рәхмәте илә Гөзәернең йоклар алдыннан ашаган ризыгы һәм йөзем суы йөз ел буе торып та бозылмаган, әмма ишәгенең кояшта агарган сөякләре генә калган иде. Бу могҗизаны күреп, Гөзәер галәйһиссәлам бик гаҗәпләнде. Раббыбыз Газзә вә Җәллә Гөзәер галәйһиссәламгә әйтте: «И, Гөзәер! Сөякләрне җыеп, аларга әүвәлдәгечә ит кундырып, аның өстенә тире белән каплавыбызны вә дәхи аңа җан өреп тергезгәнебезне карап тор», — диде. «И, Гөзәер! Бу эшне сиңа гыйбрәт, ягъни үлгәннән соң терелү булачагына бер дәлил булсын өчен кылдык». Гөзәер галәйһиссәлам ишәгенең терелгәнен күргәч, әйтте: «Мин чыннан да Аллаһы Тәгаләнең һәрнәрсәгә көче җитүенә ышанамын (259)».*

Бәни Исраил халкы җитмеш ел Бабилдә әсир хәлендә яшәде. Бу вакыйгалар һиҗрәттән 1120 ел элек булды. Сөбханә вә Тәгаләнең әмере илә Иран шаһы Хусрау, Бәхтел Насыйр хөкүмәтен галиб кылып, ягъни җиңеп, Бабил шәһәрен алды. Бәни Исраил халкын азат кылып, әүвәлге үзләре яшәгән шәһәрләренә кайтырга рөхсәт бирде. Бәни Исраил халкы моңа бик шатланды. 70 елдан артык җимерек хәлендә яткан Бәйтелмөкаддәсне янә торгыздылар.

Алда әйткәнебезчә, йөз ел вакыт үтеп киткәч, Хак Тәгалә Гөзәер галәйһиссәламне уятты. Ишәген Бәйтелмөкаддәс янындагы бер агачка бәйләп куеп йокыга киткән Гөзәер галәйһиссәлам чыннан да ишәгенең сөякләренә Аллаһы Тәгалә әйткәнчә ит кунып, аның өстенең тире белән каплануын вә дәхи аңа җан керүен күргәч, әйтте: «Ләә иләәһә илләллааһ», ягъни «Гыйбадәт кылырга лаек башка зат юктыр, мәгәр бер Аллаһы Тәгалә генәдер». Гөзәер галәйһиссәлам Бәйтелмөкаддәснең төзек булуын күреп шатланды вә ошбу кәлимәне янә кабатлады. Аллаһы Тәгалә аңа пәйгамбәрлек ихсан кылды вә Тәүратны тулысы белән исенә төшерде. Шушы көннән башлап, бәни Исраил кавемен иманга, ягъни Муса галәйһиссәлам юлына өндәргә боерылды.

Гөзәер галәйһиссәлам туган авылына кайтты, ишегалдында хайваннарга ризык бирүче, ак сакаллы 120 яшьлек улын күрде (әтисе 100 еллык йокыга киткәндә улына 20 яшь, Гөзәер галәйһиссәламгә исә 40 яшь иде, ул йокыдан уянганда әүвәлгечә кара сакаллы 40 яшендәге кеше булып уянды).

Ишегалдында йөрүче ак сакаллы карт янына килеп, ул: «Әссәламүгаләйкүм, йәә, углым», — диде. Углы аңа карап әйтте: «Син мине мыскыл итәсеңме? Мин ничек синең углың була алыйм», — диде. Гөзәер галәйһиссәлам: «Мин синең атаң Гөзәер», — диде. Углы, әлбәттә, бу сүзгә ышанмады. Шул вакыт аларның сөйләшкәннәрен күршеләре ишетеп тордылар. Бу хәбәрне барча кавемгә җиткерделәр. Ләкин берәү дә бу сүзгә ышанмады. Аны патша сараена чакырдылар вә әйттеләр: «Муса галәйһиссәламгә иңдерелгән Тәүрат китабы явыз Бабил патшасы Бәхтел Насыйр тарафыннан тулысы белән юк ителде. Гөзәер галәйһиссәлам Тәүрат китабын тулысы белән күңелдән белә иде, әгәр син чыннан да Гөзәер пәйгамбәр булсаң, Тәүратны төп нөсхәдәгечә әйтеп тор, ә безнең кятипләр аның хәрефен хәрефкә язып алырлар. Менә шул чакта без синең Гөзәер галәйһиссәлам булуыңа ышанырбыз һәм Аллаһы Тәгаләгә иман китерербез», — диделәр. Гөзәер галәйһиссәлам Тәүратны башыннан ахырына кадәр бер хәрефен дә үзгәртмичә укып биргәч, аның Гөзәер пәйгамбәр булуына вә йөз ел буе йоклап янә алар катына кайтуына ышандылар, күбесе иман китерде. Бу могҗизаны күреп, бәгъзе яһүдиләр аны «Аллаһының улы» дип әйтеп кяфер булдылар. Бу хакта «әт-Тәүбә» сүрәсенең 30 нчы аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَقَالَتِ الْيَهُودُ عُزَيْرٌ ابْنُ اللَّهِ ۝٣٠

«Үә кааләтил йәһүүдү гүзәйрун ибнүл-лааһ (30)».

Мәгънәсе: *«Яһүдләр: «Гөзәер — Аллаһының углы», — дип әйттеләр (30)».*

# ӘРМИЯ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Әрмия галәйһиссәлам Гөзәер, Даниял галәйһиссәламнәр белән бер заманда яшәде.

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә аңа пәйгамбәрлек белән бергә алдан күрүчәнлек сәләтен дә бирде.

Әрмия галәйһиссәлам яшәгән заманда бәни Исраил кавеме Аллаһы Тәгаләдән Муса галәйһиссәламгә җибәрелгән Тәүрат китабында язылган кануннарны бозып, тугры юлдан язганнар иде. Җәнабел Хак ошбу турыда Коръән Кәримнең «бәни Исраил» сүрәсе, 4–5 нче аятьләрендә әйтә:

وَقَضَيْنَآ إِلَىٰ بَنِىٓ إِسْرَٰٓءِيلَ فِى ٱلْكِتَٰبِ لَتُفْسِدُنَّ فِى ٱلْأَرْضِ مَرَّتَيْنِ وَلَتَعْلُنَّ عُلُوًّا كَبِيرًا ﴿٤﴾ فَإِذَا جَآءَ وَعْدُ أُولَىٰهُمَا بَعَثْنَا عَلَيْكُمْ عِبَادًا لَّنَآ أُو۟لِى بَأْسٍ شَدِيدٍ فَجَاسُوا۟ خِلَٰلَ ٱلدِّيَارِ ۚ وَكَانَ وَعْدًا مَّفْعُولًا ﴿٥﴾

«Үә кадайнәә иләә бәнии исрааииләә фил-китәәби lәтәфсидүннә фил-әрдый мәррратәйни үә ләтәглүннә гүлүвәң кәбиир (4). Фәизәә җәә-ә үәгдү үүләәһүмәә бәгәснәә галәйкүм гибәәдәл-ләнәә үүлии бәэсиң шәдиидиң фәҗәәсүү хыйләәләд-дийәәр. Үә кәәнә үәгдәм-мәфгүүлә (5)».

Мәгънәсе: *«Без Исраил угылларына Тәүратта хәбәр бирдек: «Сез җир йөзендә ике мәртәбә бозыклыклар кылырсыз вә тәкәбберләнеп халкыгызга каты золымнар кылырсыз», — дип хөкем кылдык (4). Ике бозыклыкның әүвәлгесе җиткәч, Без сезгә Үзебезнең олы куәтле колларыбызны җибәрдек, алар сезнең йорт араларыгызда йөреп, сезгә бөтен явызлыкны кылырлар. Бу эшләр булачак вәгъдәбездер ки, әлбәттә, ул хәл башыгызга килер (5)».*

Хак Тәгалә аларга пәйгамбәр итеп Әрмия галәйһиссәламне җибәрде. Ул үзенең кавеменә әйтте: «И, кавемем, Аллаһы Тәгаләне бар һәм бер дип белегез! Ул Муса пәйгамбәргә Тәүрат китабын иңдерде, сезгә биргән нигъмәтләрне вә фазыйләтне башка бер кавемгә дә бирмәде. Бәни Исраил кавеме күп гөнаһларга кереп батты, бу гөнаһ кылуларыгызны туктатып, Тәүрат илә гамәл вә гыйбадәт кылмасагыз, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә

сезгә тиз көннәрдә Бәхтел Насыйр исемле залимне җибәрер, бу залим улларыгызны вә кызларыгызны үтерер, үзегезне әсир итәр, Муса галәйһиссәламгә җибәрелгән изге Тәүратны утка ягар, Тәүратны күңелдән белүче Гөзәер галәйһиссәлам аны янә торгызыр, тик сез аны Аллаһы Тәгаләнең улы дип янә гөнаһка керерсез. И, кавемем, куркыгыз бу дәһшәтле көннән! Ул көндә бер кешегә икенче кеше өчен җәза кылынмас һәм сезгә шәфәгать итүче булмас», — диде.

Бәни Исраил кавеменең олуглары: «Әрмия ул безнең шикелле үк кеше, тик саташып әллә ниләр сөйли, аны халыктан аерырга кирәк», — дип, аны зинданга илтеп ташладылар.

Әрмия галәйһиссәламне зинданга ташлаганнан соң күп тә үтми, Хак Тәгаләнең әмере илә, Бәхтел Насыйр исемле залим бәни Исраил кавеме яшәгән җирләрне басып алды, олугларны вә балаларны үтертте, гыйбадәт кыла торган изге Тәүрат китабын утка якты, гавам халкын әсир итеп үзе яши торган җирләргә куып алып китте. Әсирлектә яшәүчеләрдән берсе Бәхтел Насыйрга әйтте: «И, падишаһ, без яшәгән Бәйтелмөкаддәс шәһәренең зинданында бер кеше бар, ул син безнең җирләребезне яулап алганчы күп вакыт элек «...әгәр дә Аллаһыны бер дип, Муса галәйһиссәламгә җибәрелгән изге Тәүрат илә гамәл-гыйбадәт кылмасагыз, Хак Тәгалә сезнең өскә Бәхтел Насыйр исемле залимне җибәрәчәк, ул сезнең ир вә кыз балаларыгызны үтерәчәк, изге китап Тәүратны утка ягачак, олугларыгызны үтертеп, гавам халкын кол итеп иң авыр эшләрдә файдаланачак» дигән иде, безнең олугларыбыз аннан көлделәр һәм шул көнне үк аны зинданга ташладылар, шуннан бирле ул зинданда гомер кичерә», — диде.

Бәхтел Насыйр: «Ул кешене китерегез, мин аны күрим», — диде. Тиз арада Әрмия галәйһиссәламне Бәхтел Насыйр каршысына китереп бастырдылар, ул әйтте: «Минем сезнең шәһәрләрегезне алачагымны һәм башка эшләрем турында кем белдерде?» Әрмия галәйһиссәлам әйтте: «Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәбәр бирде», — диде. Бәхтел Насыйр әйтте: «Мин сине саклармын, бу илгә олуг кылырмын, син үзеңнең күрәзәчелегең белән миңа тугры хезмәт итәрсең», — диде. Әрмия галәйһиссәлам әйтте: «Мин синең саклавыңа вә олуг кылуыңа мохтаҗ түгелмен, мине төрле афәтләрдән Рабым Аллаһ саклый, мин ирекле, кайчан кирәк, шул вакытта

Аңа гыйбадәт кылам, һәр кирәгемне тик Аннан гына сорыйм, әгәр бәни Исраил кавеме минем сүзләремне тыңлап Тәүрат-та кушканча гамәл-гыйбадәт кылган булсалар, әлбәттә, Аллаһы Тәгалә аларга синең кебек залимне җибәрмәс иде», — диде. Бәхтел Насыйрга Әрмия галәйһиссәламнең Аллаһы Тәгаләгә нык ышануы һәм аның белән болай кыю сөйләшүе ошады, ул аңа теләсә кая яшәргә ирек бирде.

Әрмия галәйһиссәлам үзе яшәгән Әл-Кодес шәһәренә кайт-ты һәм, Әл-Әкъса мәсҗидендә Хак Тәгаләгә багышлап гамәл-гыйбадәт кылып, үз йортында яши башлады. Әл-Кодестә кал-ган бәгъзе яһүдиләр аның янына килеп киңәш сорадылар: «И, Әрмия, без синең пәйгамбәр булуыңны беләбез, шуңа күрә сиңа киңәшергә дип килдек, Бәхтел Насыйр янә Әл-Кодескә килеп, безне дә кол итеп алып китәр дип куркабыз, без бары-быз да киңәштек, Мисырга барып, аның падишаһына баш ияргә һәм Бәхтел Насыйрның явызлыкларын аңа җиткерергә ният-ләдек, син ни әйтерсең?» — диделәр. Әрмия галәйһиссәлам әйтте: «И, кавемем, минем киңәшем шул, куркаклыгыгызны өстен чыгарып, ошбу туган җирләребездән Мисыр мәмлә-кәтенә барып, аның падишаһына баш имәгез. Биредә миңа ияреп иман китерегез, Аллаһы Тәгаләгә багышлап гамәл-гый-бадәт кылыгыз. Хак Сөбханә вә Тәгалә сезне Үзенең рәх-мәтеннән ташламас».

Бәни Исраил халкы аны тыңламады, ошбу туган җирләрен ташлап, Мисыр мәмләкәтенә качтылар. Анда барып җиткәч, Мисыр падишаһына сыгындылар, Бәхтел Насыйрның вәхши-лекләрен сөйләп бирделәр. Мисыр падишаһы аларга үз җи-рендә калырга рөхсәт бирде. Бу турыда Хак Тәгалә Бәхтел Насыйрга белгертте. Бәхтел Насыйр Мисыр падишаһына хат язып җибәрде, хатында ул: «И, олуг Мисыр падишаһы! Ми-нем берничә колым качып синең җирләреңә барып урнаш-каннар, әгәр дә инде минем белән киләчәктә дә дус яшәргә уйласаң, тиз арада минем колларымны җибәр!» — дип язды. Кайчан хат Мисыр падишаһына ирешә исә, аның җен ачула-ры чыкты һәм тиз арада ул җавап хаты язып җибәрде: «И, залим Бәхтел Насыйр, бәни Исраил халкы синең колларың түгел, алар ирекле халык, бел, мин аларны һичбер вакытта ирексезләп кире сиңа җибәрмәячәкмен», — диде. Мондый җавап хатын алгач, Бәхтел Насыйрның Мисыр падишаһына

бик ачуы килде. Тиз арада бик күп гаскәр җыеп, Мисыр мәмләкәтенә һөҗүм итте һәм аны җиңде, падишаһын сугышта үтерде, Мисырның күп кешесен вә дәхи бәни Исраил кешеләрен, кол итеп, Бабил шәһәренә алып кайтып китте.

Үз җирләрендә калган бәни Исраил халкының күпчелеге Әрмия галәйһиссәламгә иярделәр, иман китереп, буш вакытларын гамәл-гыйбадәттә үткәрделәр. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең вәгъдәсе җиткәч, бәни Исраил кавеме Бәхтел Насыйрны җиңде һәм алар үз җирләрендә яңа йортлар, мәсҗидләр салдылар. Бу турыда Аллаһы Тәгалә «бәни Исраил» сүрәсенең 6–7 нче аяти кәримәләрендә әйтә:

ثُمَّ رَدَدْنَا لَكُمُ الْكَرَّةَ عَلَيْهِمْ وَأَمْدَدْنَاكُمْ بِأَمْوَالٍ وَبَنِينَ وَجَعَلْنَاكُمْ أَكْثَرَ نَفِيرًا ﴿٦﴾

إِنْ أَحْسَنْتُمْ أَحْسَنْتُمْ لِأَنْفُسِكُمْ وَإِنْ أَسَأْتُمْ فَلَهَا فَإِذَا جَاءَ وَعْدُ الْآخِرَةِ لِيَسُوءُوا وُجُوهَكُمْ

وَلِيَدْخُلُوا الْمَسْجِدَ كَمَا دَخَلُوهُ أَوَّلَ مَرَّةٍ وَلِيُتَبِّرُوا مَا عَلَوْا تَتْبِيرًا ﴿٧﴾

«Сүммә радәднәә ләкүмүл кәрратә галәйһим үә әмдәднәәкүм биәмүәәлиү-үә бәниинә үә җәгәлнәәкүм әксәра нәфиира (6). Ин әхсәңтүм әхсәңтүм лиәңфүсикүм. Үә ин әсәәтүм фәләһә. Фә изәә җәә-ә үәгдүл-әәхыйрати лийәсүү вүҗүүһәкүм үәлийәде хулүл-мәсҗидә кәмәә дәхалүүһү әүвәлә мәрратиү-үәлийүтәббируу мәә галәү тәтбиир (7)».

М ә г ъ н ә с е: *«Соңра куәт вә гайрәтегезне янә үзегезгә кайтардык, сезне җиңгәннән соң кимсеткән кешеләргә хәзер үзегез өстен булдыгыз. Малларыгызны, балаларыгызны күбәйтеп, сезгә ярдәм бирдек вә сезне күп гаскәрле дәүләт кылдык (6). Әгәр сез яхшылыклар кылсагыз, үзегез өчен яхшылык кылган буласыз, әгәр явызлыклар кылсагыз, шулай ук үзегез өчен явызлык кылган буласыз. Әгәр сезгә икенче фәсад, ягъни бозыклык вакыты җитеп, иман китермичә явызлыклар кылсагыз, янә өстегезгә бер залимне гыйбрәт өчен җибәрербез, йөзләрегезне кара кылмак вә барысын да һәлак итмәк өчен (7)».*

Бу вакыйгалардан соң да әле Әрмия галәйһиссәлам озак вакытлар яшәде, Җәнабел Хак аңа озын гомер вә иман байлыгы бирде, ул күп вакытын намазда вә сәҗдәдә үткәрде. Соңгы елларда аңа ияреп иман китерүчеләр саны күбәйде, вә дәхи Раббыбыз бу кавемгә күп нигъмәтләр бирде.

# ЗӘКӘРИЯ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Зәкәрия галәйһиссәлам Сөләйман нәселеннән иде, Кодес шәрифтә дөньяга килеп, Әл-Әкъса мәсҗидендә Тәүратны күчереп язучы, корбан чалучы рәис булып тора иде. Аллаһы Тәгалә аңа пәйгамбәрлек бирде. Хатыны Йәсәг белән озын гомер кичерделәр, ләкин балалары булмады. Йәсәгнең кыз карендәше Хүннә Исраилнең олугларыннан Гыймран исемле мәшһүр вә бик гадел кешенең хатыны иде. Аллаһы Тәгалә, бу изге кешене хөрмәтләп, Коръән Кәримнең өченче сүрәсенең исемен «әл-Гыймран» дип атаган. Хүннә дә картаймыш көненә кадәр бала тапмады.

Риваятьләрдә бу турыда сөйләнә: Гыймран вә аның хатыны Хүннә картлыкка ирештеләр, ләкин аларның балалары булмады. Хүннә беркөнне агач күләгәсендә утырганда бер кошның үз балаларын ашатканын вә моңа бик шатланганын күреп: «И, Раббым Аллаһ, миңа да бала бирсәңче, ул баланы мәсҗид Әл-Әкъсага дин хезмәтенә куяр идем», — дип нәзер әйтте. Аллаһы Тәгалә аның зарилыгын кабул әйләде, Хүннә кинәт корсагында балага узу галәмәте сизде. Ул заманда баланы Әл-Әкъса мәсҗиденә илтеп тапшыру бик саваплы гамәлләрдән санала иде. Әл-Әкъсада хезмәт итүче галимнәр бу баланы тәрбия кылалар иде. Эшкә ярый башлагач, гыйбадәтханәдә хезмәт итә вә биредәге галимнәрдән Тәүратны өйрәнер иде. Ә балигъ булганнан соң, теләсә үз ихтыярына салырлар иде. Теләсә, Әл-Әкъсада хезмәт итәргә калыр, теләсә кәсеп итеп мал табар. Бу турыда Коръән Кәримнең «әл-Гыймран» сүрәсе, 35 нче аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

إِذْ قَالَتِ امْرَأَتُ عِمْرَٰنَ رَبِّ إِنِّى نَذَرْتُ لَكَ مَا فِى بَطْنِى مُحَرَّرًا فَتَقَبَّلْ مِنِّىٓ ۖ إِنَّكَ أَنْتَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ ۝٣٥

«Из кааләтим-раәтү Гыймраанә Раббии инниии нәзәртү ләкә мәә фии бәтъниии мүхәррараң фәтәкаббәл минни, иннәкә әңтәс-сәмиигүл галиим (35)».

М ә г ъ н ә с е : *«Гыймран хатыны Хүннәнең Раббысына ялварганын хәтерләгез, ул әйтте: «И, Раббым, карынымдагы*

*баланы үз хезмәтемнән азат итеп, Синең юлыңа тапшырырга нәзер әйттем. И, Раббым, сораганымны кабул итеп, теләгемә ирештер! Син минем сүземне ишетүче вә теләгемне белүчесең (35)».*

Вакыты җиткәч, Хүннә кыз бала тапты, исемен Мәрьям дип куйдылар. «әл-Гыймран» сүрәсенең 36 нчы аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فَلَمَّا وَضَعَتْهَا قَالَتْ رَبِّ إِنِّي وَضَعْتُهَا أُنْثَىٰ وَاللَّهُ أَعْلَمُ بِمَا وَضَعَتْ وَلَيْسَ الذَّكَرُ كَالْأُنْثَىٰ ۖ وَإِنِّي
سَمَّيْتُهَا مَرْيَمَ وَإِنِّي أُعِيذُهَا بِكَ وَذُرِّيَّتَهَا مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ ٣٦

«Фәләммәә үә дагәтhәә кааләт Рабби иннии үә дагтүhәә үңсә. Үәллааhү әгләмү бимәә үә дагәт. Үә ләйсәз-зәкәру кәлүңсә. Үә иннии сәммәйтүhәә Мәрйәмә үә иннии үгиизүhәә бикә зүррийййәтәhәә минәш-шәйтаанир-ражиим (36)».

Мәгънәсе: *«Хүннә Мәрьямне тудыргач: «И, Раббым, кыз бала тудырдым, ир бала булса, дин хезмәтенә яхшы булыр иде», — диде. Аллаһы Тәгалә белүчерәктер, нинди бала тудырганыңны. Хүннә әйтте: «Ир бала, әлбәттә, кыз бала түгел, аның исемен Мәрьям куштым, бу баланы вә аннан туачак балаларны рәхмәтеңнән сөрелгән шайтан шәрреннән Синең саклавыңа тапшырдым». Мәрьямнең анасы Хүннә Зәкәрия галәйһиссәламнең хатыны белән бертуган иделәр (36)».*

Хүннә Мәрьямне нәзере буенча Әл-Әкъса мәсҗиденә илтеп тапшырды. Ул вакытта Әл-Әкъсада, «Тәфсир Кадый» риваятенчә, егерме җиде галим бар иде, барчасы Тәүраттан гыйлем алып, аны күчереп язалар иде. Мәрьямне күреп, һәркайсы: «Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен мин тәрбия кылырмын», — дип бәхәсләштеләр. Бу хакта «әл-Гыймран» сүрәсенең 37 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فَتَقَبَّلَهَا رَبُّهَا بِقَبُولٍ حَسَنٍ وَأَنْبَتَهَا نَبَاتًا حَسَنًا وَكَفَّلَهَا زَكَرِيَّا ۖ كُلَّمَا دَخَلَ عَلَيْهَا زَكَرِيَّا الْمِحْرَابَ وَجَدَ
عِنْدَهَا رِزْقًا ۖ قَالَ يَا مَرْيَمُ أَنَّىٰ لَكِ هَٰذَا ۖ قَالَتْ هُوَ مِنْ عِنْدِ اللَّهِ ۖ إِنَّ اللَّهَ يَرْزُقُ مَنْ يَشَاءُ بِغَيْرِ حِسَابٍ ٣٧

«Фәтәкаббәләhәә Раббүhәә бикабүүлин хәсәнин үә әңбәтәhәә нәбәәтән хәсәнәү-үә кәффәләhәә Зәкәрийййә. Күлләмәә дәхалә галәйhәә Зәкәрийййәл михраабә үә җәдә

гиндәһәә ризка. Каалә йәә Мәрйәму әннәә ләки һәәзә. Кааләт һүә мин гиндилләәһ. Иннәллааһә йәрзүку мәййәшәә-ү бигайри хисәәбе (37)».

М ә г ъ н ә с е : *«Мәрьямне Раббысы мәсҗид Әкъсага күркәм кабул итте, яхшы тәрбия илә тәрбияләмәк өчен Зәкәрия пәйгамбәргә тапшырды.* (Хүннә Мәрьямне тудыргач, мәсҗид Әкъсага алып барып, анда намаз укучыларга: «Бу бала Аллаһы юлына нәзер ителгән, кабул итеп алыгыз», — диде. Мәсҗид әһелләре баланы кабул итеп алдылар, аны тәрбияләп үстерү хакында һәрберсе: «Мин алам», — дип, үзара бәхәсләштеләр. Бу бәхәсне бетерү өчен, Хак Тәгаләдән юл күрсәтелде: «Барчагыз да каләмнәрегезне суга салыгыз, кемнең каләме суга батмаса, Мәрьямне шул кеше алыр». Әйтелгәнчә эш кылдылар, Зәкәриянең каләме суга батмады, Мәрьям аңа тапшырылды.) *Зәкәрия мәсҗид эчендә бер бүлмә әзерләп, Мәрьямне шунда тәрбия кылды. Мәрьям зикер, гыйбадәт илә мәшгуль булды. Зәкәрия Мәрьям янына кайчан гына керсә дә, алдында төрле җимешләр вә башка ризыкларны күрер иде. Бер кергәндә: «И, Мәрьям, бу ризыклар сиңа кайдан килә?» — дип сорады. Мәрьям әйтте: «Бу ризыклар Аллаһы хозурыннан килә, Җәнабел Хак, әлбәттә, Үзе теләгән бәндәсен хисапсыз ризыкландыра (37)».*

Хәзрәти Зәкәрия картлык көнендә Аллаһы Тәгаләдән бер бала сорап, яшерен тавыш илә дога кылды. Догасында ул: «И, Раббым, минем сөягем зәгыйфьләнде, башыма ак чәчләр кунды, моңа кадәр мин Сиңа атап кылган догамнан кире кайтарылучы булмадым, һәрвакыт догамны кабул әйләдең. Үлгәнемнән соң вәли булып калачак кемсәләрнең золым итүләреннән куркамын, ә минем хатыным бала тудырмый торган кысыр булды, үзеңнең фазылыңнан миңа бер изге угыл бирсәң иде», — диде. Хак Тәгалә аның догасын кабул итте вә аңа Яхъя исемле бер газиз углан ихсан әйләде. Аллаһы Тәгалә «әл-Гыймран» сүрәсенең 39 нчы аяти кәримәсендә әйтә:

فَنَادَتْهُ الْمَلَٰٓئِكَةُ وَهُوَ قَآئِمٌ يُصَلِّي فِي الْمِحْرَابِ أَنَّ اللَّهَ يُبَشِّرُكَ بِيَحْيَىٰ

مُصَدِّقًا بِكَلِمَةٍ مِّنَ اللَّهِ وَسَيِّدًا وَحَصُورًا وَنَبِيًّا مِّنَ الصَّٰلِحِينَ ﴿٣٩﴾

«Фәнәәдәтһүл мәләәикәту үә һүвә кааимүй-йүсаллии фил михрааби әннәллааһә йүбәшширукә бийәһйәә мусаддикамбикәлимәтим-миналлааһи үә сәййидәү-үә хәсуурау-үә нәбиййәм-минәс-саалихиин (39)».

М ә г ъ н ә с е : *«Зәкәрия михрабта намаз укып торганда, Җәбраил фәрештә килеп, Аллаһының сәламен ирештерде вә әйтте: «И, Зәкәрия, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә сине Яхъя исемле изге угыл илә шатландыра. Ул Яхъя Хак Тәгаләнең сүзенә ышанучы булган хәлдә, ягъни Гайсә пәйгамбәргә иң беренче иман китерүчеләрдән булып, аның ярдәмчесе булыр. Янә ул Яхъя бәни Исраил кавеме арасында хөрмәтле вә олуг булыр, һәм дә хатыннар белән сохбәт итүдән сакланучы изге пәйгамбәрләрдән булыр (39)».*

Зәкәрия галәйһиссәлам фәрештәнең бу хәбәренә ышанмады. Бу хакта «әл-Гыймран» сүрәсенең 40 нчы аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

قَالَ رَبِّ أَنَّىٰ يَكُونُ لِي غُلَٰمٌ وَقَدْ بَلَغَنِيَ ٱلْكِبَرُ وَٱمْرَأَتِي عَاقِرٌ قَالَ كَذَٰلِكَ ٱللَّهُ يَفْعَلُ مَا يَشَآءُ ﴿٤٠﴾

«Каалә Рабби әннәә йәкүүнү лии гүләәмун үә каде бәләганиийәл-кибәру үәмраәтии гәәкыййру. Каалә кәзәәликәл-лааһү йәфгалү мәә йәшәә-ү (40)».

М ә г ъ н ә с е : *«Зәкәрия әйтте: «И, Раббым, миңа кайдан угыл булсын, дөреслектә, миңа картлык иреште, хатыным да бала тудырмаучыдыр». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Аллаһы Тәгалә теләгәнен әнә шулай кылыр (40)».*

Корьән Кәримнең «әл-Гыймран» сүрәсенең 41 нче аяти кәримәсендә бу хакта болай диелгән:

قَالَ رَبِّ ٱجْعَل لِّيٓ ءَايَةً قَالَ ءَايَتُكَ أَلَّا تُكَلِّمَ

ٱلنَّاسَ ثَلَٰثَةَ أَيَّامٍ إِلَّا رَمْزًا وَٱذْكُر رَّبَّكَ كَثِيرًا وَسَبِّحْ بِٱلْعَشِيِّ وَٱلْإِبْكَٰرِ ﴿٤١﴾

«Каалә Раббиҗгәл лии әәйәтә. Каалә әәйәтүкә әлләә түкәллимәннәәсә сәләәсәтә әййәмин илләә рамзә. Үәзкүр Раббәкә кәсиирау-үә сәббих бил-гәшиййи үәл ибкәәр (41)».

М ә г ъ н ә с е : *«Зәкәрия әйтте: «И, Раббым, хатынымның йөкле булуына миңа бер галәмәт бир». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Синең кешеләр белән сөйләшә алмавың сиңа галәмәт бу-*

*лыр, кешеләр белән өч көн сөйләшә алмассың, мәгәр ишарә илә генә сөйләшерсең». Хатыны йөкле булгач, Зәкәриянең теле бәйләнде, зикер-тәсбихтан башка сүзләрне сөйли алмады. Хак Тәгалә әйтте: «И, Зәкәрия, Раббыңны күп зикер ит, көндезләрен вә кичләрен намаз укы!(41)».*

Вакыты җиткәч, Җәбраил фәрештә хәбәр биргәнчә, Зәкәрия галәйһиссәламнең хатыны хәзрәти Йәсәгтән Яхъя исемле ир баласы туды. «Әл-Әнбия» сүрәсенең 90 нчы аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

فَاسْتَجَبْنَا لَهُ وَوَهَبْنَا لَهُ يَحْيَىٰ وَأَصْلَحْنَا لَهُ زَوْجَهُ ۚ إِنَّهُمْ كَانُوا يُسَارِعُونَ فِي

الْخَيْرَاتِ وَيَدْعُونَنَا رَغَبًا وَرَهَبًا ۖ وَكَانُوا لَنَا خَاشِعِينَ ﴿٩٠﴾

«Фәстәҗәбнәә ләһүү вә вәһәбенәә ләһүү Йәхйәә вә әсъләхнәә ләһүү зәүҗәһ. Иннәһүм кәәнүү йүсаарри гүүнә фил хайраати вә йәдгүүнәә рагабәү-вә раһәбә. Үә кәәнүү ләнәә хаашигиин (90)».

М ә г ъ н ә с е : *«Аның догасын кабул иттек вә аңа Яхъя исемле изге угыл бирдек, аның бала тудырмый торган хатынын тудыра торган кылдык. Моннан соң да алар күркәм эшләргә ашыгучылардан булдылар, Безнең хозурыбызда булган савапка кызыгып вә ахирәттә булачак хәлләрдән куркып, Безгә даим гыйбадәт кылалар иде (90)».*

Хәзрәти Зәкәриягә бөһтан-яла яктылар вә аны үтерергә карар кылдылар. Зәкәрия галәйһиссәлам бу шәһәрдән чыгып качарга ниятләде. Ул куып килүчеләрдән бер агач куышына кереп качты. Бәни Исраил кавеме, агач янына килеп җитеп, агачны хәзрәти Зәкәрия галәйһиссәлам белән бергә кистеләр. Хәзрәти Зәкәрия галәйһиссәлам, агач эчендә киселеп, шәһит китте.

# ЯХЪЯ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Хәзрәти Яхъя — Зәкәрия галәйһиссәламнең углыдыр. Хәзрәти Яхъя галәйһиссәлам атасы Зәкәрия галәйһиссәламнең картлык көнендә Аллаһы Тәгаләдән соравы буенча дөньяга килмештер.

Хәзрәти Яхъя кечкенә бала вакытында ук Тәүратны кулыннан төшермәде, аны күңелдән белә иде. Ул һәрдаим бәни Исраил кавеменә үгет-нәсыйхәт кылды. Атасы Зәкәрия галәйһиссәлам үрнәгендә бу кавемне хәзрәти Муса галәйһиссәлам шәригатенә өндәмәк өчен Җәнабел Хак тарафыннан пәйгамбәр кылынды. Аллаһы Тәгалә «әл-Әнгам» сүрәсенең 85 нче аятендә әйтә:

وَزَكَرِيَّا وَيَحْيَىٰ وَعِيسَىٰ وَإِلْيَاسَ كُلٌّ مِّنَ الصَّالِحِينَ ﴿٨٥﴾

«Үә Зәкәриййәә үә Йәхйәә үә Гиисәә үә Илйәәсә күллүмминәс-саалихиин (85)».

Мәгънәсе: *«Янә Зәкәрияне, Яхъяны, Гайсәне, Ильясны һидаятькә салдык, алар һәммәсе дә изгеләрдән (85)».*

Хәзрәти Яхъя, Гайсә галәйһиссәламгә пәйгамбәрлек иңдерелгәнче, бәни Исраил кавемен Тәүрат илә гамәл-гыйбадәт кылырга өндәде.

Хәзрәти Гайсәгә Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләдән пәйгамбәрлек белән бергә Инҗил китабы иңдерелгәч, Яхъя галәйһиссәлам Инҗил китабын бик ныклап өйрәнде һәм аның белән гамәл-гыйбадәт кыла башлады. Бигрәк тә ул, Гайсә галәйһиссәлам барча халык алдында шундый зур могҗизалар күрсәткәч, аның пәйгамбәрлегенә инанып, беренчеләрдән булып аңа иман китерде. Һәм аның шәригате буенча гамәлгыйбадәт кыла башлады. Бу яңа шәригать хөкемнәрен үзенең вәгазь-нәсыйхәтендә башкаларга да җиткерергә тырышты, аларны туры юлга өндәде, «Аллаһы Тәгаләнең вәгъдәсе җиткәч, Инҗил китабы Муса галәйһиссәламнең Тәүрат китабын алмаштырды, барыгыз да Хак Тәгаләнең пәйгамбәренә җибәрелгән ошбу мөбарәк Инҗил китабы кануннарына буй-

сынып гамәл кылыгыз, ахирәттә сез отучылардан булырсыз, кем аның белән гамәл кылмый, алар оттыручылардан булачаклар», — дип сөйләде.

Аллаһы Тәгалә «Мәрьям» сүрәсенең 12–15 нче аяти кәримәләрендә әйтә:

يَٰيَحْيَىٰ خُذِ ٱلْكِتَٰبَ بِقُوَّةٍ ۖ وَءَاتَيْنَٰهُ ٱلْحُكْمَ صَبِيًّا ﴿١٢﴾ وَحَنَانًا مِّن لَّدُنَّا وَزَكَوٰةً ۖ وَكَانَ تَقِيًّا ﴿١٣﴾
وَبَرًّۢا بِوَٰلِدَيْهِ وَلَمْ يَكُن جَبَّارًا عَصِيًّا ﴿١٤﴾ وَسَلَٰمٌ عَلَيْهِ يَوْمَ وُلِدَ وَيَوْمَ يَمُوتُ وَيَوْمَ يُبْعَثُ حَيًّا ﴿١٥﴾

«Йәә Йәхйәә хузил-китәәбә бикуввәт. Үә әәтәйнәәһүл хүкмә сабыййә (12). Үә хәнәәнәм-миң ләдүннәә үә зәкәәтә, үә кәәнә тәкыййә (13). Үә бәррам-биүәәлидәйһи үәләм йәкүң җәббәәран гәсыййә (14). Үә сәләәмүн гәләйһи йәүмә үлидә үә йәүмә йәмүтү үә йәүмә йүбегәсү хәййә (15)».

Мәгънәсе: *«И, Яхъя! Ал Тәүратны ныклап, ихлас күңел белән! Вә Без Яхъяга сабый чагында ук хикмәт вә зур гыйлем бирдек (12). Вә Без Яхъяга рәхимлек вә шәфкатьлелекне, мөшриклек кереннән саклаучы пакьлекне бирдек. Вә ул Аллаһы Тәгаләдән куркучы тәкъва булды (13). Вә ата-анасына изгелек кылучы иттек вә ул Аллаһы Тәгаләгә гөнаһкяр вә тәкәббер булмады (14). Вә Яхъяга туган көнендә вә үлгән көнендә һәм дә кабердән кубарылган көнендә Аллаһы Тәгаләдән сәламнәр булды (15)».*

Яхъя галәйһиссәлам дөньяга килгәндә бәни Исраил кавеме белән Һарус исемле кеше падишаһлык иткән заман иде. Аның пайтәхете Әнтакия шәһәрендә иде. Аның кул астында гыйбрани, юнан, әфрәнҗ халыклары яши иде.

Гайсә галәйһиссәламгә Инҗил китабы иңүе хакында хәбәр таралгач, Һарус падишаһ: «Тәүрат вә Инҗил китаплары барыгыз өчен дә мәкруһ, шуның өчен ата-бабаларыбыз табынган потларга гына табыныгыз, кем минем әмеремә каршы чыга, ул җәзага тартылачак», — дип әмер чыгарды. Яхъя галәйһиссәламне үз сараена чакырттты, аңа үзенең иң кыйммәтле потларын күрсәтте.

Яхъя галәйһиссәлам Һарус падишаһ белән бәхәскә керде, ул: «Сине, мине, айны, кояшны, барча йолдызларны яраткан зат — бер Аллаһтыр, Тәүрат вә Инҗил — Аның безгә туры юлны күрсәтүче изге китаплары», — дип, падишаһка иман ките-

рергә кушты. Падишаһ, Яхъя галәйһиссәламнең бу сүзләрен ишетеп, үзенә буйсынган халыклар иман китерерләр дип курыкты, Яхъя галәйһиссәламне, башын ләгәнгә куеп, бугазларга боерды. Яхъя галәйһиссәлам шәһит китте. Урыны җәннәттә булсын. Әмин.

# ЗӨЛКАРНӘЕН ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим.

Риваять кылынадыр ки, пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламгә пәйгамбәрлек килде исә, ул адәмнәрне иманга өндәргә кереште. Мәккә мөшрикләренә никадәр могҗизалар күрсәтсә дә, алар һаман каршылык күрсәттеләр, иман китермәделәр. Мөшрикләрнең иң явызы булган Әбү Җаһил тарафыннан Мәдинә шәһәренә хат җибәрелде, хат озын булып, анда: «... Мәккәдә Мөхәммәд исемле бер адәм үзен пәйгамбәр дип атый, бу бәндәне ни кылмак кирәк, җавап хатында шуны әйтеп языгыз», — дип язылган сүзләр дә бар иде. Мәдинә халкының күбесе ул заманда яһүдиләр иде. Әбү Җаһилнең хатын алгач, алар киңәшеп, җавап хаты яздылар: «Сез тасвирлап язган Мөхәммәд турында безнең Тәүрат китабында язылган, аннан ике мәсьәлә турында сорагыз, әгәр икесенә дә дөрес җавап бирсә, әлбәттә, ул хак пәйгамбәр булыр. Беренчесе, рух, ягъни җан ни-нәрсә дип сорагыз. Әгәр җанның кыяфәтен тасвирлап җавап бирсә, ул пәйгамбәр түгел. Тәүратта «җанның кыяфәтен, хакыйкатьтә, Аллаһыдан башка һичкем дә белмәс» диелгән. Икенче мәсьәлә, Зөлкарнәен падишаһ турында сорагыз». Әбү Җаһил, җавап хатын алгач, бик сөенде. Мөшрикләр белән җыелышып, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнән бу ике мәсьәләне сорадылар. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам: «Мин сезгә өч көннән җавап бирермен», — диде, әмма «иншә Аллаһ» димәде. Өч көн үтте, бер вәхи дә иңмәде. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам бик кайгырды, аның янына һәр көнне мөшрикләр килеп, «син хак пәйгамбәр булсаң, безнең сорауларыбызга җавап бирер идең» дип, аны борчыдылар. Вә аның турында һәртөрле батыйль сүзләр сөйләделәр: «Аллаһың сиңа ачуланды, сине ташлады», — дип, аннан көлделәр. Ун көн үткәч, Җәбраил фәрештә Аллаһы Тәгаләнең сәламен вә Аның вәхиен китерде. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам: «И, Җәбраил кардәшем, нигә вәхи болай соңарып килде, моңа ни сәбәп?» — диде. Җәбраил галәйһиссәлам җавабында: «Син мөшрикләргә

өч көннән мин сезгә җавап бирермен дигәч, иншә Аллаһ, димәгәнең өчен, — диде. — Әгәр дә синнән рух ни-нәрсә дип сорасалар, әйт, рух Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең әмере вә Аның бер могҗизасыдыр, рухның ни икәнен Аллаһы Тәгаләдән башка һичкем белмәс вә аңа туры җавап бирә алмас дип җавап бирерсең, — диде. — Зөлкарнәен турында сорасалар, Сөбханә вә Тәгалә аның турында синә «әл-Кәһеф» сүрәсенең 83–99 нчы аяти кәримәләрендә иңдерде, син шуларны аларга дәлил итеп китерерсең», — диде. Бу вакыйгаларны әйтеп язган Мәккәдән килгән хатны укыгач, Мәдинәдәге яһүдиләр Мөхәммәд галәйһиссәламнең чыннан да ахырзаман пәйгамбәре икәнлегенә инандылар, бәгъзеләре шул вакытта ук иман китерделәр вә мөэмин-мөселман булдылар.

Җәгъфәр бән Мөхәммәд Рәхмәтулла галәйһидән риваять кылынадыр: Зөлкарнәен юнан дигән кавемнең падишаһы иде. Чын исеме Искәндәр булып, башында ике мөгезе булганлыктан, аның ләкабе, ягъни кушаматы Зөлкарнәен (мөгезле) булды. Зөлкарнәен падишаһны бәгъзе галимнәр пәйгамбәр диләр, ә бәгъзеләре Аллаһы Тәгаләнең дусты, якыны булган диләр. Зөлкарнәен падишаһның бер фәрештә белән дуслыгы бар иде. Көннәрдән бер көнне Зөлкарнәен фәрештәдән: «Фәрештәләр ни рәвешле гыйбадәт кылалар?» — дип сорады. Фәрештә әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең әмере илә бәгъзе фәрештәләр даим кыяматкәчә кыямда торалар, бәгъзесе рөкүгъта торалар, бәгъзесе сәҗдәдә булалар, шул рәвештә гыйбадәт кылалар», — диде. Зөлкарнәен галәйһиссәлам әйтте: «Мин дә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә гамәл-гыйбадәт кылу өчен озак гомер кичерүне телимен», — диде. Фәрештә әйтте: «Әгәр син озын гомер теләсәң, бел, җир йөзендә бер чишмә бар, аңар Гайнелхәят, ягъни тереклек чишмәсе диярләр, шул чишмәнең суын эчкән кеше әҗәлне үзе теләми торып үлмәс, ләкин ул чишмә тау куышында, тирән караңгылыкта, аны табуы бик кыен, зур батырлык таләп итә», — диде.

Зөлкарнәен падишаһ үз мәмләкәтенең барча галимнәрен җыйды вә алардан сорады: «Сез Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Зәбур вә Тәүрат китапларын укыганыгыз бармы, җир йөзенең кайсы әтрафында Гайнелхәят исемле чишмә бар?» — диде. Галимнәрдән берсе: «Әйе, Гайнелхәят чишмәсе бар, ул чишмә таулар илендәге тау куышында, тик син анда Хозыр

галәйһиссәлам һәм зур гына гаскәр белән барырга тиешсең», — дип әйтте.

Кайчан бу тау куышына җиттеләр исә, Хозыр галәйһиссәлам Зөлкарнәенгә әйтте: «Әгәр без бу караңгы тау куышында адашсак нишләрбез?» Зөлкарнәен аңа бер асылташ бирде вә әйтте: «Әгәр дә без бу караңгы тау куышында адашсак, син бу асылташны җиргә куярсың, ул тирә-юньне яктыртыр», — диде. Бәс, Зөлкарнәен падишаһ һәм Хозыр галәйһиссәлам караңгы тау куышына керделәр вә икесе ике тарафка юнәлделәр. Бераз баргач, Хозыр галәйһиссәлам бер чокырга төшеп китте, Зөлкарнәен биргән асылташны җиргә куйды, тирә-юнь яктырып китте, чокыр төбендә бер чишмә ага иде, ул чишмәнең суын эчте, суы сөттән ак, балдан татлы иде. Бу агымсуда госел коенып, ике рәкәгать намаз укыды. Чокырдан зур авырлык белән чыкты һәм Зөлкарнәенне эзләп китте, аны эзләп күпме генә кычкырса да, җавап ишетмәде. Зөлкарнәен бу вакытта тау куышының башка бүлмәләрендә йөри иде. Хозыр галәйһиссәлам, аны эзләп табып, үзе госел коенган чишмәгә алып килергә теләде. Күпме генә эзләсәләр дә, теге чокырны һәм андагы чишмәне һич таба алмадылар. Зөлкарнәен галәйһиссәламгә Гайнелхәят чишмәсенең суын эчәргә һәм анда госел коенырга насыйп булмады.

Ләкин Аллаһы Тәгалә Зөлкарнәен галәйһиссәламне Үзенең рәхмәтеннән ташламады, аңа куәт бирде вә дәхи һәрнәрсәнең сәбәбен белгертте. Бу урында ул бер кяфер кавемне очратты, Аллаһы Тәгалә Зөлкарнәен галәйһиссәламгә ирек кылды: «...Бу кавемне үтереп бетерәсең яки аларны әсир кыласың — син үз иркеңдә», — диде. Зөлкарнәен галәйһиссәлам әйтте: «Аллаһы Тәгаләне танымау, ягъни ширек кату белән залимлек кылсалар, әлбәттә, үтерү белән җәза кылырмын. Хак Сөбханә вә Тәгалә кыямәт көнендә имансызларны тәмуг газабы белән җәзалар. Әмма, бу кавем Аллаһы Тәгаләнең барлыгын вә берлеген танып, Аңа гамәл-гыйбадәт кылсалар, без аларга рәхимле вә шәфкатьле булырбыз», — диде.

Зөлкарнәен галәйһиссәлам бу кавемне иманга өндәде, ягъни Аллаһы Тәгаләне бар һәм бер дип «Ләә иләәһә илләллааһ» кәлимәсен ихлас күңелдән әйтергә өйрәтте. Элек кяфер булган ошбу кавемнең күпчелеге иман китерде.

Аллаһы Тәгаләнең әмере илә Зөлкарнәен галәйһиссәлам шәрык тарафына килеп чыкты. Биредә ул куе урманнар арасында яшәүче кыргый кавемгә очрады вә аларны иманга өндәргә боерылды. Ул кавем күлмәк-ыштан кими торган зәнкиләр кавеме иде. Аларның тора торган йортлары да юк иде. Төннәрен бу кавем кешеләре агач башында үзләре ясаган ояларда йоклыйлар да көннәрен кыргый хайваннарны аулап, шуларның итләрен вә елгадан тотып кайткан балык итен ашап көн күрәләр иде.

Зөлкарнәен галәйһиссәлам әүвәл бу кавемгә аларның Нух галәйһиссәламнең углы Хам нәселеннән булуларын, аннан соң Аллаһы Тәгаләнең һәр бәндәсе гаурәтләрен каплап йөрергә тиешлеген вә дәхи Сөбханә вә Тәгаләне бар һәм бер дип, Аның биргән нигъмәтләренә шөкрана кылып, «Ләә иләәһә илләллааһ» кәлимәсен һәрдаим ихлас күңелдән әйтергә тиешлеген, әгәр дә иман китермәсәләр, аларны кыямәт көнендә тәмуг газабы көтәчәген аңлатты. Бу кыргый кавемнең дә күп өлеше иман китерде.

Җәнабел Хак Тәгаләнең әмере илә Зөлкарнәен үзенең сыналган, батыр йөрәкле гаскәре илә Каф тавына барып чыкты. Мондагы кавем кешеләре сүзләрен аңлап булмас дәрәҗәдә сәер сөйләшәләр иде. Тәрҗемәче Зөлкарнәен галәйһиссәламгә әйтте: «Бу кавем, ошбу Каф тавының теге ягында Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗ дигән коточкыч вәхши кавем яши, дип әйтә. Алар әйтеп бетергесез күп бозыклыклар кылалар, әгәр безнең кавемгә ярдәм итәргә теләсәң вә бу эш көчеңнән килсә, шул явыз Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗ кавеме белән безнең арабызга койма кор. Бу Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗ кавеме Каф тавының теге ягыннан чыгып, безнең кавем халкын үтерәләр, игеннәребезне харап итәләр, хәтта алар бер-берсен ашыйлар. Әгәр син безне бу афәттән коткарсаң, без син әйткән Аллаһының берлегенә иман китереп, мөселман булырбыз, диләр».

Зөлкарнәен галәйһиссәлам әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең ярдәме илә вә дәхи сезнең ярдәмегез илә ике арага, иншә Аллаһ, олуг бер койма корырбыз, моны башкаргач, сез барыгыз да Хак Тәгаләнең барлыгына вә берлегенә иман китерерсез!» — диде. Бу кавем Зөлкарнәен галәйһиссәлам кушкан җиргә бик күп тимер ташыды. Зөлкарнәен галәйһиссәлам үзенең гаскәре белән, ике кат итеп, ул тимерләрне бер таудан икенче тауга кадәр тез-

де. Урмандагы агачларны кисеп, турап бу ике кат тимер арасына тутырдылар. Моның соңында бу агачларга ут төрттеләр. Тимер кызып кып-кызыл ут кебек булгач, аның өстенә бу кавем ташыган бакырны койдылар. Бакыр эреп тимер белән катнашкач, бу койма ике тауның башы белән тигезләнде.

Яәҗүҗ вә Мәәҗүҗ кавеме һәрдаим үзләре чыгып йөри торган җиргә килделәр. Күрделәр, юл бикләнгән, тырнаклары вә тешләре белән ябышып, бу биек коймага менәргә теләделәр, ләкин койма шома вә нык итеп ясалган булганлыктан, тешләрен, тырнакларын сындырдылар, әмма койманы үтә алмадылар. Зөлкарнәен галәйһиссәлам әйтте: «Бу койманы бу кадәр нык вә биек итеп ясавыбызга, әлбәттә, Аллаһы Тәгалә һәм Аның рәхмәт фәрештәләре ярдәм итте, Хак Тәгаләнең вәгъдәсе илә ахырзаман җитсә, Аллаһы Тәгалә бу койманы җир белән тигез кылыр, ул вакытта Яәҗүҗ вә Мәәҗүҗ кавеме ошбу койманы үтеп чыгачак», — диде.

Зөлкарнәен галәйһиссәлам Яәҗүҗ вә Мәәҗүҗдән коткарган кавем, алдан вәгъдә кылганча, ихлас күңелдән иман китереп мөселман булдылар.

Гомәр ибн Әлгас радыйаллаһу ганһе әйтә: «Яәҗүҗ вә Мәәҗүҗ кавеме — җәһәннәм халкының иң әүвәлгеседер. Ахырзаман алдыннан җир йөзенең җиде өлешеннән алты өлешендә Яәҗүҗ вә Мәәҗүҗ кавеме булыр, ә бер өлешендә барча мәхлуклар торырлар. Бу Яәҗүҗ вә Мәәҗүҗ кавеме һәрнәрсәне ашарлар: филне, дуңгызны, елан-бакаларны, хәтта үзләренең үлекләрен дә ашарлар, ләкин үзләре бик озын гомерле булырлар, бик күп балалары булыр, тәннәре сары төстә булыр».

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә Зөлкарнәен галәйһиссәламгә Һиндстанга барырга әмер кылды. Һиндстанның падишаһы, Зөлкарнәен галәйһиссәламнең яхшы коралланган гаскәрен күреп, озын буйлы хәкимен илче итеп җибәрде вә аңа әйтте: «Барып бел, ул нинди гаскәр, безгә сугыш беләнме яки башка ният белән килгәнме?» — диде. Илче мәһабәт гәүдәле Зөлкарнәенне вә аның сугышларда чыныккан кырыс йөзле гаскәрен күздән кичерде, башын түбән иеп сәлам бирде. Зөлкарнәен галәйһиссәлам сәлам кайтарды һәм әйтте: «Сез нинди кавем, мәҗүсиләрме, әллә бер Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кыласызмы?» — диде. Бу хәким әйтте: «Без борынгы

бабаларыбыз ясап куйган потларыбызга табынабыз, кирәк булганда алардан ярдәм сорыйбыз», — диде. Зөлкарнәен галәйһиссәлам аларның патшалары белән очрашты һәм әйтте: «Сезнең бабаларыгыз ясап куйган бу потларыгыз сезгә авыр вакытларда берничек тә ярдәм итә алмыйлар, сез боларны ташлап, барча галәмне, сине, мине, ай, кояш вә йолдызларны юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылырга тиешсез, моның өчен Аңа чын күңелдән ышанып, «Ләә иләәһә илләллааһ» кәлимәсен әйтергә һәм кешеләргә һәр җирдә изгелекләр эшләргә вә фарыз булган гыйбадәтләрне башкарырга кирәк», — диде. Һиндстан падишаһы вә аның якыннары Зөлкарнәеннән көлделәр, аның әйткән сүзләренә ышанмадылар, сарайдан куып чыгардылар.

Зөлкарнәен галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы илә бу тәкәббер кавемне кылычтан үткәрде, сугышта бик күпләре һәлак булды, ләкин иман китерүчеләр бик аз булды.

Зөлкарнәен галәйһиссәлам иманга өндәп тагын бик күп кавемнәр белән сугышты, Аллаһы Тәгаләнең ярдәме илә бөтен сугышларда да өстен чыкты. Искәндәрия (Александрия) шәһәрендә вафат булды.

Үзебез язганнарга дәлил итеп, Коръән Кәримнең «әл-Кәһеф» сүрәсе, 83– 99 нчы аяти кәримәләрен китерәбез:

وَيَسْـَٔلُونَكَ عَن ذِى ٱلْقَرْنَيْنِ ۖ قُلْ سَأَتْلُوا عَلَيْكُم مِّنْهُ ذِكْرًا ﴿٨٣﴾ إِنَّا مَكَّنَّا لَهُۥ فِى ٱلْأَرْضِ وَءَاتَيْنَٰهُ مِن
كُلِّ شَىْءٍ سَبَبًا ﴿٨٤﴾ فَأَتْبَعَ سَبَبًا ﴿٨٥﴾ حَتَّىٰٓ إِذَا بَلَغَ مَغْرِبَ ٱلشَّمْسِ وَجَدَهَا تَغْرُبُ فِى عَيْنٍ
حَمِئَةٍ وَوَجَدَ عِندَهَا قَوْمًا ۗ قُلْنَا يَٰذَا ٱلْقَرْنَيْنِ إِمَّآ أَن تُعَذِّبَ وَإِمَّآ أَن تَتَّخِذَ فِيهِمْ حُسْنًا ﴿٨٦﴾
قَالَ أَمَّا مَن ظَلَمَ فَسَوْفَ نُعَذِّبُهُۥ ثُمَّ يُرَدُّ إِلَىٰ رَبِّهِۦ فَيُعَذِّبُهُۥ عَذَابًا نُّكْرًا ﴿٨٧﴾ وَأَمَّا مَنْ ءَامَنَ
وَعَمِلَ صَٰلِحًا فَلَهُۥ جَزَآءً ٱلْحُسْنَىٰ ۖ وَسَنَقُولُ لَهُۥ مِنْ أَمْرِنَا يُسْرًا ﴿٨٨﴾ ثُمَّ أَتْبَعَ سَبَبًا ﴿٨٩﴾ حَتَّىٰٓ إِذَا بَلَغَ
مَطْلِعَ ٱلشَّمْسِ وَجَدَهَا تَطْلُعُ عَلَىٰ قَوْمٍ لَّمْ نَجْعَل لَّهُم مِّن دُونِهَا سِتْرًا ﴿٩٠﴾ كَذَٰلِكَ وَقَدْ أَحَطْنَا
بِمَا لَدَيْهِ خُبْرًا ﴿٩١﴾ ثُمَّ أَتْبَعَ سَبَبًا ﴿٩٢﴾ حَتَّىٰٓ إِذَا بَلَغَ بَيْنَ ٱلسَّدَّيْنِ وَجَدَ مِن دُونِهِمَا قَوْمًا لَّا يَكَادُونَ

يَفْقَهُونَ قَوْلًا ﴿٩٣﴾ قَالُوا يَٰذَا الْقَرْنَيْنِ إِنَّ يَأْجُوجَ وَمَأْجُوجَ مُفْسِدُونَ فِي
الْأَرْضِ فَهَلْ نَجْعَلُ لَكَ خَرْجًا عَلَىٰ أَنْ تَجْعَلَ بَيْنَنَا وَبَيْنَهُمْ سَدًّا ﴿٩٤﴾ قَالَ مَا مَكَّنِّي
فِيهِ رَبِّي خَيْرٌ فَأَعِينُونِي بِقُوَّةٍ أَجْعَلْ بَيْنَكُمْ وَبَيْنَهُمْ رَدْمًا ﴿٩٥﴾
آتُونِي زُبَرَ الْحَدِيدِ حَتَّىٰ إِذَا سَاوَىٰ بَيْنَ الصَّدَفَيْنِ
قَالَ انْفُخُوا حَتَّىٰ إِذَا جَعَلَهُ نَارًا قَالَ آتُونِي أُفْرِغْ عَلَيْهِ قِطْرًا ﴿٩٦﴾ فَمَا اسْطَاعُوا أَنْ يَظْهَرُوهُ
وَمَا اسْتَطَاعُوا لَهُ نَقْبًا ﴿٩٧﴾ قَالَ هَٰذَا رَحْمَةٌ مِنْ رَبِّي فَإِذَا جَاءَ وَعْدُ رَبِّي جَعَلَهُ دَكَّاءَ وَكَانَ
وَعْدُ رَبِّي حَقًّا ﴿٩٨﴾ وَتَرَكْنَا بَعْضَهُمْ يَوْمَئِذٍ يَمُوجُ فِي بَعْضٍ وَنُفِخَ فِي الصُّورِ فَجَمَعْنَاهُمْ جَمْعًا ﴿٩٩﴾

«Үә йәс-әлүүнәкә гәң Зилкарнәйн. Куль сә-әтлүү галәйкүм минһү зикра (83). Иннәә мәккәннәә ләһүү фил әрдый үә әәтәйнәәһү миң күлли шәйиң сәбәбә (84). Фә-әтбәгә сәбәбә (85). Хәттәә изәә бәләга мәгърибәш-шәмси үә җәдәһәә тәгърубү фии гайнин хәмиәтиү-үә үәҗәдә гиңдәһәә каумә. Кульнәә йәәзәл-курнәйни иммәә әң түгәззибә үә иммәә әң тәттәхыйзә фииһим хүснә (86). Каалә әммәә мәң заләмә фәсәүфә нүгәззибүһү сүммә йүраддү иләә Раббиһии фәйүгәззибүһүү газәәбән-нүкра (87). Үә әммәә мән әәмәнә үә гамилә саалиһә фәләһү җәзәә-әл хүснә. Үә сәнәкуулү ләһү мин әмиринәә йүсра (88). Сүммә әтбәгә сәбәбә (89). Хәттәә изәә бәләга мәтълигиш-шәмси үә җәдәһәә тәтълүгү гәләә каумиллләм нәҗгәл ләһүм миң дүүниһәә ситра (90). Кәзәәликә, үә каде әхәтънәә бимәә ләдәйһи хубра (91). Сүммә әтбәгә сәбәбә (92). Хәттәә изәә бәләга бәйнәс-сәддәйни үә җәдә миң дүүниһимәә каумәллләә йәкәә дүнә йәфкаһүүнә каулә (93). Каалүү йәәзәл-карнәйни иннә йәәҗүүҗә үә мәәҗүүҗә мүфсидүүнә фил-әрдый фәһәл нәҗгәлү ләкә харҗән гәләә әң тәҗгәлә бәйнәнәә үә бәйнәһүм сәддә (94). Каалә мәә мәккәннии фииһи Раббии хайруң фә әгиинүүнии бикувәтин әҗгәл бәйнәкүм үә бәйнәһүм радмә (95). Әәтүүнии зүбәрал-хәдииде. Хәттәә изәә сәәүәә бәйнәс-садәфәйни кааләнфүху. Хәттәә изәә җәгаләһү нәәраң каалә әәтүүнии үфриг гәләйһи

кыйтра (96). Фәмәстаагүү әй-йәзъһәруүһү үәмәс-тәтаагүү ләһүү нәкъбә (97). Каалә һәәзәә рахмәтүм-миррабби. Фә изәә җәә-ә үәгдү Раббии җәгәләһүү дәккә. Үә кәәнә үәгдү Рабби хәкка (98). Үә тәракнәә бәгдаһүм йәүмәизий-йәмүүҗү фии бәгдый. Үә нүфиха фис-суури фәҗәмәгнәәһүм җәмгә (99)».

М ә г ъ н ә с е : *«И, Мөхәммәд галәйһиссәлам, синнән Зөлкарнәен турында сорарлар. Әйт: «Мин сезгә аның турында сөйләрмен» (83). Дөреслектә, Без аны җир йөзендә хаким вә кодрәт иясе иттек, аңа җир өстендә тизлек белән йөри торган сәбәпне бирдек (84). Һәм ул җир өстендә йөрү сәбәбе юлыннан китте (85). Сәбәп белән ул кояш бата торган җиргә килеп җитте, кояшның балчыклы чишмәгә батканын күрде. Бирердә ул бер кавемне тапты. Шунда Без әйттек: «И, Зөлкарнәен, теләсәң, ул кавемне имансыз булганнары өчен газап кыл, вә теләсәң, аларга яхшылык итеп шәригать хөкемнәрен өйрәт» (86). Зөлкарнәен әйтте: «Әмма иман китермичә үзенә золым кылган кешене, әлбәттә, үтермәк илә газап кылырбыз, соңра Раббысы хөкеменә кайтарылыр. Шунда Раббысы аны каты газап белән газап кылыр» (87). Әмма берәү иман китереп изге гамәлләр кылса, әлбәттә, аңа Бездән гүзәл бүләкләр булыр. Без андыйларга үтәве җиңел булган әмерләр бирербез (88). Соңра Зөлкарнәен мәшрикъка ирештерә торган сәбәпкә иярде (89). Ниһаять, ул кояш чыга торган җиргә ирешге, вә ул җирдә яши торган кавемне тапты, Без аларга күләгә ясарлык нәрсә бирмәдек (90). Зөлкарнәенне мәшрикъка ирештерү вә мәгърибкә ирештерү Безгә бик җиңелдер. Менә шулай итеп, Без аны һәм аның янындагыларны гыйлем белән чорнап алдык (91). Соңыннан ул янә алып барып җиткерә торган сәбәпкә ияреп юлга чыкты (92). Ниһаять, ул ике тау арасында яши торган кавемгә очрады, ул кавем белән бик авырлык илә генә аңлаштылар (93). Алар әйттеләр: «И, Зөлкарнәен, шушы ике тау арасыннан Яәҗүҗ вә Мәәҗүҗ кавеме чыгып төрле бозыклыклар кылалар, алар белән безнең арага, ягъни шушы ике тау арасына бөек бер дивар корсаң, без син әйткәнчә бер Аллаһыга иман китерер идек», — диделәр (94). Зөлкарнәен әйтте: «Раббым миңа гыйлем бирде, сез миңа эшче куллар белән ярдәм итегез, Аллаһы Тәгаләнең ярдәме вә Аның ризалыгы илә мин сезнең белән Яәҗүҗ вә Мәәҗүҗ арасына тау кебек нык койма ясап бирермен (95).*

*Инде миңа тимерләр китерегез!» Ике тау арасында тимерләрне утыннар белән аралаштырып, тау биеклеге кадәр өйделәр. «Хәзер инде яндырып утыннарның көлен очырыгыз», — диде. Утыннар бик каты янып, тимерләр эреп ут кебек булгач, әйтте: «Алып килегез эрегән бакыр, аны тимер өстенә коярбыз», — диде (96). Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗ кавеменең бу дивардан чыгарга хәлләреннән килмәде, тимер вә бакырдан ясалган диварны тишә дә алмадылар (97). Зөлкарнәен галәйһиссәлам әйтте: «Бу диварны сезгә ясап бирмәклегем — Раббымның рәхмәтедер. Раббым вәгъдә кылган кыямәт килсә, Ул без ясаган бу диварны җир белән тигезләр. Раббымның вәгъдәсе хактыр» (98). Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗ чыккан көнне аларны, бер-берсе илә аралаштырып, кайнаган су кебек кылырбыз. Кубарылмак өчен Сур мөгезенә өрелсә, барча кешеләрне хисап өчен мәхшәргә җыярбыз (99)».*

# ЗӨЛКИФЕЛ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Риваять кылынадыр ки, Кинган шәһәрендә Маһияр исемле бер падишаһ бар иде, үзе мөселман иде. Мал-мөлкәте чиксез күп иде. Мал-мөлкәте шулкадәр күп булса да, баласы юк иде. Кич вә көндез бу Әнтакия падишаһы Сөбханә вә Тәгаләгә бала сорап ялварды вә үтенечләр кылды. Бала хакы өчен дәрвишләргә садакалар, фәкыйрьләргә ризыклар биреп, коелар, күперләр, кәрвансарайлар вә мәсҗидләр төзетте.

Аллаһы Тәгалә аның юмартлыгын вә изге гамәлләрен күрде, шулкадәр ялварып сораудан соң, аңа бер гүзәл угыл бүләк итте, аңа Зөлкифел исеме бирделәр. Бала гаять җитешле вә камил иде, бәхет әсәре аның өстендә ачык чагыла иде.

Падишаһ моңа күп шөкрана кылды, юмартлык кулын тагы да киңрәк ачты, мохтаҗларга вә фәкыйрьләргә Аллаһы Тәгалә биргән мал-нигъмәтне бирде ки — чиге-чамасы юк иде.

Көннәрдән бер көнне сөекле углын йолдызларга карап тәкъдирне белүче мөнәҗҗимгә китерделәр, мөнәҗҗим аның күзләреннән үпте, сөенүеннән торып, Җәнабел Хакка шөкрана кылды вә әйтте: «И, олуг падишаһ! Ошбу балага Хак Тәгаләдән пәйгамбәрлек килер, бу турыда Тәүратта язылган. Аның юлында күп каршылыклар вә кыенлыклар булыр, әмма ахыры хәерле булыр, Аллаһы Тәгаләнең ярдәме илә ул бу киртәләрне берәм-берәм юк итәр, Газзә вә Җәллә аңа могҗизалы кылыч бүләк итәр, ул бу кылыч белән бик күп мәҗүсиләрне вә кяферләрне кырыр, аларның күбесе иманга килер, каһарманлыгы белән ул кяферләрнең тынычлыгын алыр», — диде.

Менә Зөлкифелгә унбиш яшь тулды, чагыштыргысыз гыйлеме белән сабакташларыннан күпкә аерылды. Яхшыны ямannan аерды, тагын ук ату, сөңге тоту, җәядән ату, ау кошы илә җәнлекләр аулау, аркан ату вә атылган арканны тоту остасы, кылыч вә чукмардан да бик оста файдалана белә иде. Ошбу заманның чагыштыргысыз куәтлесе булды.

Зөлкифел көннәрдән бер көнне сахрага ауга чыккач, арып йокларга ятты. Янына мәһабәт гәүдәле бер ир-егетнең

килгәнен сиздe. Бу ир-егет аңа сәлам бирде вә әйтте: «И, Зөлкифел! Мин Хак Тәгаләнең фәрештәсе Җәбраил галәйһиссәлам буламын, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә сиңа сәламен җибәрде вә дәхи сине Үзенең пәйгамбәре итеп сайлады. Әнтакия шәһәре тирәсендә бик күп мәҗүсиләр вә кяферләр яши, син аларны иман китерергә чакырырга тиешсең, Аллаһы Тәгалә аларны җиңү өчен ошбу могҗизалы булат кылычны сиңа бүләк итте. Аның сере шунда, бу кылыч кирәк вакытта озынаер, син аның белән күп шөһрәт казанырсың, кяферләрнең йөрәгенә курку салырсың. Моннан еракта Мосул шәһәре патшасының искиткеч гүзәл кызы бар, син ул кызны үзеңә никахлап алырсың, тик ул мөселман иленә барып җиткәнче син бик күп кяфер кабиләләре белән очрашырсың вә аларны иманга өндәрсең, каршы килгәннәрен ошбу кылычтан үткәрерсең», — дип, аңа могҗизалы кылычны тапшырып, Җәбраил галәйһиссәлам үзе юк булды.

Зөлкифел галәйһиссәлам әтисенә ничек Җәбраил галәйһиссәламне күргәнен вә аның әйткәннәрен, бәйнә-бәйнә сөйләде. Әтисе әйтте: «Моннан 12 ел элек мөнәҗҗим боларны тасвирлаган иде, димәк, Аллаһы Тәгаләнең вәгъдәсе җитеп, син пәйгамбәр булдың һәм моңа дәлил булып ошбу могҗизалы кылычың да бар. Безнең Кинган шәһәренә мәҗүсиләр вә кяферләр һөҗүм иттеләр. Без шәһәребезне саклап кала алдык. Әй, күз нурым, йөрәк парәм, углым минем, инде гомеремнең ахыры җитеп килә, картлык галәмәтләре тәмам беленә башлады, инде Хак Тәгаләгә күп шөкер, миңа синең кебек угыл бирде. Сиңа актык сүзләрем шул, син һичбер вакытта да баһадирлыгыңны куеп, падишаһлыкка кызыкма, дуслар белән дус бул, дошманнар белән дошман бул. Аллаһы Тәгалә әйткәннәрне үтә, карышма, Аның әмерләренә һичбер вакытта каршылык итмә. Баһадирлык падишаһлыктан артыктыр, чөнки падишаһлар шул пәһлеваннар аркасында гына падишаһ булып яшиләр. Янә бер нәсыйхәтем шул, әгәр дә Хак Тәгалә кушып Мосул шәһәренә барып җитә алсаң, аның падишаһы Бәһрузга миннән күп сәлам әйт, аңа бик кадер-хөрмәт ит, һичбер аның хәтерен калдырачак хәлдә булма, югыйсә ул сиңа үзенең өзелеп сөйгән бердәнбер кызын бирмәс», — дип, углының башыннан сөйде.

Маһияр падишаһ тик ятмады, улына кяферләрнекеннән артык итеп сугыш әсбабы, юлдаш итеп Хозыр галәйһиссәламне, пәһлеваннарны, яхшы атлар вә дөяләр хәзерләп, Мосул шәһәренә таба озатып җибәрде.

Шәһәрдән чыгып, Мосул шәһәренә таба хәрәкәт иткәндә Дәҗлә (Тигр) елгасы буенда урнашкан Басра шәһәренә килеп җиттеләр. Бу шәһәрнең падишаһы Җәйсүр потка табынучылардан иде. Зөлкифел пәйгамбәр Хозыр галәйһиссәлам илә киңәшеп, пәһлеваннарын шәһәр читендә калдырып, бу шәһәрнең падишаһын иманга өндәргә ниятләп, аның катына барды вә әйтте: «И, олуг шәһәрнең падишаһы Җәйсүр, мин Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәре Зөлкифел буламын, сине һәм сиңа буйсынган барча мәҗүсиләрне вә кяферләрне бер Аллаһыга буйсынырга өндимен, әгәр сез минем сүзләремне тыңлап ихлас күңелдән «Ләә иләәһә илләллаah» кәлимәсен әйтсәгез, мөселман булырсыз, ошбу җиһанда вә ахирәттә бәхетле булырсыз», — диде. Җәйсүр падишаһның Зөлкифел галәйһиссәламгә бик каты ачуы чыкты вә әйтте: «Безнең ата-бабаларыбыз табынган олуг потларыбыз бар, ничек инде мин аларны ташлап син әйткән Аллаһыга гыйбадәт кылыйм ди, бу гакылга сыймаслык нәрсәне телең башка кабатламасын өчен, мин синең башыңны кистерәм», — диде. Җәлладлар аны тотып алмакчы булдылар, Зөлкифел галәйһиссәлам, кылычын тартып алып, уңлы-суллы Җәйсүр кешеләрен кыра башлады. Бу хәлне күреп, Җәйсүр сарайдагы утларны сүндерергә кушты, ягъни ул Зөлкифелне караңгыда тотып алып үтермәкче булды. Аллаһы Тәгаләнең бүләге булган үткен булат кылыч, караңгыда ай кебек яктылык вә нур чәчеп, кирәк вакытта озынаеп яки кыскарып, мәҗүсиләрне кырды да кырды. Ул шулай сугыша-сугыша иптәшләре янына шәһәр читенә чыкты.

Җәйсүр падишаһ сараена галимнәрен җыйды, алар белән киңәште. Аларның күпчелеге Зөлкифел вә аның пәһлеваннарын шәһәр читеннән куып җибәрергә кирәк диделәр. Шул нияттән күп гаскәр белән Зөлкифел туктаган чатырга юнәлделәр. Зөлкифел исә, үзенең пәһлеваннары белән иртә торып, агачлар арасына керде вә бу Җәйсүр гаскәре ни кылыр икән дип, тамаша кыла иде. Җәйсүр падишаһ гаскәре Зөлкифелне чатырда ял вакытында үтерергә кирәк дип, кинәт һөҗүм итте, ләкин чатырда беркемне тапмады. Гаскәрне күргәч, качкан-

нар икән дип тынычланып, коралларын читкә куеп, бәйрәм итә башладылар. Шул мәлне агачлар арасыннан Зөлкифел вә аның пәһлеваннары, дошманнарга һөҗүм итеп, аларның бик күп кешеләрен юк иттеләр. Ул көнне сугыш ахшамга кадәр барды. Зөлкифел галәйһиссәлам шулкадәр гайрәт белән сугышты ки, сугышта үлгәннәргә карап хәйран калырлык булды. Күп сугышларда булган кешеләр дә бу көнгә кадәр мондый сугыш булганы юк иде диләр.

Җәйсүр падишаһ бу кайгылы вә күңелсез хәлне күрүгә: «Бу эшкә тәмам аптырадым, бу бер гаҗәп эш, шулкадәр гаскәр аз гына булган баһадирлар кулыннан юк булсын әле», — дип, хәйран калды. Сугыш мәйданында Җәйсүр сугышчыларының үлгән гәүдәләре шулкадәр күп иде ки, һич хисабы юктыр. Күп баһадирлары үлеп ята иделәр. Аларны күмеп бетерерлек тә түгел иде.

Җәйсүр падишаһ калган гаскәре илә бергә кайтып, вәзир вә баш кешеләрне дәшеп, киңәшләшә башладылар. Падишаһ сүзне башлап: «Бу ни гаҗәп эш, бу нинди безгә күктән җибәрелгән бәла, моңа бер чара юкмыни?» — диде. Шунда булган вәзирләр вә башка халык әйтте: «Зөлкифелнең бүгенге сугышында да, һәм алдагы көнне сарайда шулкадәр гаскәргә бер башы каршы торып, үлми калуында да ниндидер могҗиза бар, без ул әйткән Аллаһыга иман китерергә тиешбез, югыйсә тагын шундый бер сугыштан соң безнең бер сугышчыбыз да калмаячак», — диделәр. Сүзне гаскәр башлыгына бирделәр, ул: «Бу безнең белән сугышкан егет дөньяда тиңе булмаган бер баһадирдыр. Моның пәһлеваннары белән сугышу безгә бик авыр вә бик кыендыр. Без никадәр сугышсак та, аны кулга төшерә алмабыз. Минемчә мәслихәт шул, менә мин, моңа кадәр күп сугышларда җиңгән колыгыз, рөхсәт итсәгез, мин аны төрле ялынычлар вә үтенүләр илә сезнең катыгызга китерәм», — диде.

Җәйсүр падишаһ бу сүзләрне бик яратып, шул ук сәгать гаскәр башлыгы белән коралланган илле кешегә Зөлкифелне киң түбәнчелек илә сарайга чакырырга әмер бирде. Зөлкифел, урыныннан торып, аларны каршы алды. Башка пәһлеваннар да килеп җиттеләр. Гаскәр башлыгы Зөлкифел пәйгамбәрне вә Хозыр галәйһиссәламне зур түбәнчелек белән сарайга чакырды.

Падишаһ, сүз башлап, аларның бу пәһлеваннар белән кая барганлыкларын сорашты. Болар: «Без Мосул шәһәре падишаһының кызын сорарга бара идек, Аллаһы Тәгаләнең әмере шундый, юлда очраган кавемнәрне иманга өндәргә, карышканнарны, иман китермәгәннәрне кылычтан үткәрергә тиешбез, сез безнең юлыбызда очраган беренче кавем, әгәр дә карышмыйча иман китергән булсагыз, бу афәтләр булмас иде вә бу гаскәриләр исән-имин булырлар иде», — диделәр. Падишаһка боларның сүзләре хуш килде һәм ул, барча сарай әһелләре алдында иман китереп, мөселман булды. Падишаһның иман китерүен күреп, барча сарай халкы, гаскәриләр вә гавам халкы иман китереп мөселман булдылар.

Зөлкифел үзенең пәһлеваннары белән Васыйтә шәһәренә җитте. Биредә утка табынучылар яши иде. Зөлкифел бу шәһәрнең падишаһы Мәгъфиргә хат язып җибәрде. Хатның эчтәлеге болай иде: «Җир вә күкләрнең тәрбиячесе Аллаһы Тәгаләнең исеме илә ант итеп әйтәмен, мин Хак Тәгаләнең пәйгамбәре Зөлкифел булырмын, курку белмәс йөз илле пәһлеваным бар. Җир йөзен мөшрикләрдән вә мәҗүсиләрдән пакьләп, бөтен җиһанга Ислам динен таратып, барча галәмне нурландырабыз. Сезгә шуны белдерәбез, Җәнабел Хак утны адәмнәргә файда өчен яратты, ә сез аны тәңребез дип, шуңа табынасыз, моны эшләп Хак Тәгалә алдында зур гөнаһлы буласыз. Шуның өчен бу ялгыш юлны ташлап, тугры вә хак юлга керергә өндибез. Моның өчен сез «Ләә иләәһә илләллаааһ» кәлимәсен ихлас күңелдән әйтеп, Тәүрат китабында язылган фарыз, важиб гамәлләрне үтәргә тиеш буласыз. Әгәр дә шушы вәгаземне тыңлап, тугры юлны кабул итсәгез, элеккечә падишаһлыгыгызда калырсыз. Әгәр кабул итмәсәгез, бөтен Васыйтә шәһәрен харап итеп ташламыйча, бирерән һич китмәячәкбез. Тәмам. Үәссәламүгаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ».

Бу хатны алып сарай халкына укыгач, Мәгъфир падишаһ үзенең вәзирләрен вә түрәләрен җыеп, табына торган утларына киттеләр. Һәммәсе килеп беткәч, олуглап утка сәҗдә кылганнан соң, Мәгъфир әйтте: «И, минем мәгъбүдем, нур вә нар-ут! Кинган падишаһының углы Зөлкифел үзенең пәһлеваннары белән безне иманга өндәргә килде, аның белән сугышыйкмы, әллә Аллаһыны бер дип иман китерикме?» — дигәч, адәмнәрнең вә диннең дошманы, җәннәттән сөрелгән

Иблис ләгыйнь, утның артыннан ачулы тавыш илә: «И, минем тугры бәндәләремнән Мәгъфир! Зөлкифел пәйгамбәр ул йөз илле кешесе белән ни эшли алачак, ник аның белән килешәсең, әлбәттә, сугыш, менә сиңа мин рөхсәт бирдем, сине җиңүче кылдым, аны җиңәрсең», — диде. Мәгъфир, вәзирләр вә барча түрәләр ут тарафыннан бу сүзләрне ишеткәч, янә бер мәртәбә сәҗдә кылдылар вә шатланып иртәнгә кадәр йөз илле меңлек гаскәр җыйдылар.

Иртә белән капкалар ачылды вә аннан йөз илле меңлек яхшы коралланган гаскәр чыкты, алда кызыл атта Мәгъфир падишаһ килә иде. Каршысында Зөлкифелнең йөз илле пәһлеванын күргәч, ул каты тавыш илә кычкырып көлде вә әйтте: «Әй, сез, мескеннәр, безнең ата-бабаларыбыз гомер-гомергә утка табынганнар, сез, моны тыеп, бер Аллаһыга гыйбадәт кылуыбызны телисез, яхшы вакытта хәзер үк безнең җирләрдән качып котыла аласыз, югыйсә барыгызны да тотып утка корбан итеп бирәчәкбез. Белегез, без бервакытта да иман китермәячәкбез», — диде.

Алга Зөлкифел пәйгамбәр чыкты, әйтте: «Мин Аллаһы Тәгаләнең хак пәйгамбәре Зөлкифел буламын, сезне иманга өндәргә килдем. Әгәр сез утка табынуыгызны ташлап, ихлас күңелдән «Ләә иләәһә илләллааһ» дип иман китерсәгез, минем пәһлеваннарым сезгә зарар китермәсләр, әгәр дә инде Аллаһының берлеген танымыйча, утка табынуыгызны дәвам итсәгез, сезгә зур афәт киләчәк, икенең берсен сайлагыз», — диде.

Мәгъфир падишаһ һәм аның гаскәре: «Сугышабыз, боларны кырып бетерәбез», — дип кычкырдылар. Алга Мәгъфир падишаһның ифрат көчле вә зур гәүдәле мәшһүр пәһлеваны чыкты. Ислам гаскәре дә саф-саф булып тезелеп сугыш мәйданында тордылар. Иң әүвәл ак атка атланып, Зөлкифел галәйһиссәлам чыкты. Ифрат зур гәүдәле Мәгъфир пәһлеваны Зөлкифел галәйһиссәламгә гөрзие илә һөҗүм итте. Зөлкифел галәйһиссәлам дә кулына гөрзиен алып һөҗүм итештеләр.

Һичберсенә зыян ирешмәде. Соңра Мәгъфирнең пәһлеваны, кылычын кынысыннан чыгарып, Зөлкифел галәйһиссәламнең баш түбәсенә кизәнде. Моны күргәч, Зөлкифел галәйһиссәлам кылычын тартып чыгарып, бу шыксыз зур пәһлеванның башына бар көченә булат кылычы белән орды, пәһлеван, башыннан аягына кадәр урталай ярылып, атыннан мәтәлеп

төште. Бу хәлне күргәч, Мәгъфир гаскәрләренә ишарә кылды. Аның гаскәре Зөлкифелне чолгап алып һөҗүм иттеләр. Зөлкифел, могҗизалы кылычын кулына алып, шул хисапсыз гаскәргә каршы сугыша башлады. Бу тарафтагы Ислам гаскәре дә, бу хәлне күргәч, гайрәткә килеп, бүлем-бүлем булып төрле яктан һөҗүм иттеләр. Мәйдан уртасында Зөлкифел галәйһиссәлам үзенең атына атланган көе кылыч вә гөрзие белән адәм гәүдәсеннән таулар ясый иде. Әлхасыйль, сугыш шундый куәтле булды ки, ата угылны, ана кызны, туган кардәшен танымаслык кыямәт көне кебек булды. Сугыш ахшамгача булды, адәм каны дәрья булып акты. Читтән карап торган кеше дөньяда мондый дәһшәткә мисал таба алмыйча, шөбһәсез хәзрәте Адәм заманыннан бу вакытка кадәр мондый дәһшәтле сугыш булмаган дияр иде.

Мәгъфир гаскәре сансыз кырылганнан соң, зәгыйфьләнеп, тәртипсез рәвештә качарга тотынды. Аларның иң алдында, кызыл аты өстендә Мәгъфир падишаһ үзе сахрага качты.

Зөлкифел галәйһиссәлам үзенең ак аты өстендә пәһлеваннары белән, солтанатлы рәвештә шәһәргә керде. Шәһәрдә калган барча гавам халкы иман китерделәр. Утка табына торган потханәләрен җимерделәр, үзләренә яңа патша сайлап куйдылар.

Зөлкифел галәйһиссәлам вә аның баһадирлары, тагын берничә кяфер шәһәр халкын иманга керткәннән соң, Мосул шәһәренә килеп җиттеләр. Зөлкифел галәйһиссәлам түбәнчелек илә Мосул падишаһы Бәһрузга әтисе Кинган падишаһы Маһиярнең сәламен тапшырды. Бәһруз падишаһ Зөлкифел галәйһиссәламне вә аның пәһлеваннарын кунак итте, юлда булган вакыйгаларны белеште һәм аларның сау-сәламәт килеп җитүләренә зур шатлык белдерде.

Бәһруз падишаһ бик тә динле, тәкъва кеше иде. Аның бер гүзәл кызы бар, Бәһия исемле иде. Чибәрлектә, камиллектә тиңе юк иде. Бар халык арасында аның яхшылыгы вә сафлыгы шөһрәт казанган иде. Күп вакыты намаз вә гыйбадәттә үтә иде.

Бәһияне сорап, атасына күп кенә кияү булырга теләүчеләр килә, әмма ул кыз һичбер кияүгә ризалык бирмәс, үз тормышына вә Хак Тәгаләгә шөкрана кылып яшәр иде. Зөлкифел галәйһиссәлам түбәнчелек белән аның кулын сорады. Зөлкифел галәйһиссәламнең иманлылыгы, әдәплелеге вә түбәнчелеге Бәһруз патшага һәм Бәһия туташка бик хуш килгән иде,

алар икесе дә никах укытырга риза булдылар. Алар бер-берсенә бик туры килделәр. Никах укылып туйлар узгач, Зөлкифел галәйhиссәлам хатыны Бәhияне туган шәhәре Кинганга алып кайтып китте. Кяферләргә каршы күп кенә көрәшләрдә катнашты, hәрвакыт җиңеп чыкты. Зөлкифел галәйhиссәлам турында Коръән Кәримнең «әл-Әнбия» сүрәсе, 85 нче аяти кәримәсендә Аллаhы Тәгалә әйтә:

وَإِسْمَٰعِيلَ وَإِدْرِيسَ وَذَا ٱلْكِفْلِ كُلٌّ مِّنَ ٱلصَّٰبِرِينَ ﴿٨٥﴾

«Үә Исмәәгиилә үә Идриисә үә Зәлкифл. Үә күлли минәссаабириин (85)».

М ә г ъ н ә с е : *«Вә Исмәгыйльне, вә Идрисне, вә Зөлкифелне хәтерләгез, боларның барчасы бәла-казаларга сабыр итүчеләрдән булдылар (85)».*

Шулай ук «Сад» сүрәсенең 48 нче аятендә Аллаhы Тәгалә әйтә:

وَٱذْكُرْ إِسْمَٰعِيلَ وَٱلْيَسَعَ وَذَا ٱلْكِفْلِ وَكُلٌّ مِّنَ ٱلْأَخْيَارِ ﴿٤٨﴾

«Үәзкүр Исмәәгиилә үәл-Йәсәгә үә Зәлкифли, үә күллүмминәл-әхъйәәр (48)».

М ә г ъ н ә с е : *«Янә Исмәгыйль, Әльясәгъ, вә Зөлкифелне зикер ит, аларның hәркайсы изгеләрдән иде (48)».*

Инде белегез: hәркем җиhанда ни эзләсә, Хак Тәгалә шуны бирер. Һәр кешегә иманында кодрәте җиткәнчә куәтле булу кирәк. Тырышлыктан башка эш башкарылып чыга алмас. Үзеңнән соң бер яхшы исем калдыру өчен тырышырга кирәк. Күргәнебезчә, иманы нык булганы өчен, Җәнабел Хак hәр көрәштә Зөлкифелне өстен кылды.

# ГАЙСӘ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим.

Хикәят сөйләүчеләр вә риваять тапшыручылар шулай хәбәр кылдылар: Гыймран кызы Мәрьям радыйаллаһу ганһә мәсҗид Әкъсада Зәкәрия галәйһиссәлам тәрбиясендә үсте. Зәкәрия галәйһиссәлам мәсҗид эчендә бер бүлмә әзерләп, Мәрьямне шунда тәрбия кылды. Мәрьям радыйаллаһу ганһә һәрдаим зикер вә гыйбадәт илә мәшгуль булды. Зәкәрия галәйһиссәлам кайчан гына Мәрьям радыйаллаһу ганһә янына керсә дә, аның алдында төрле-төрле җимешләр вә башка нигъмәтләр күрә иде. Бер кергәндә ул сорады: «И, Мәрьям, барча ишекләр бикле, бирегә миннән башка беркем дә керми, бу нигъмәтләр сиңа кайдан килә?» Мәрьям радыйаллаһу ганһә әйтте: «Бу ризыклар, бу нигъмәтләр Аллаһы Тәгалә хозурыннан килә, Хак Тәгалә, әлбәттә, Үзе теләгән бәндәсен хисапсыз ризыкландыра», — диде.

Мәрьям радыйаллаһу ганһә Газзә вә Җәлләнең биргән нигъмәтләренә һәм кылган изгелекләренә көнен дә, төннәрен дә гыйбадәт кыла. Ул бәни Исраил кавеме арасында үзенең игелеге вә тугрылыгы белән танылa. Мәрьям радыйаллаһу ганһә әдәпле бер бала булып, һичвакытта ялгыш эш кылмас, нечкә калебле, зирәк зиһенле, аны күргән кешенең дикъкатен җәлеп итәр, һәр кеше, минем балам да шундый булса, никадәр сәгадәтле булыр идем, дип уйлар иде.

Гыйбадәт кылганда аның янына рәхмәт фәрештәләре килеп, моңарчы күрелмәгән җәннәт нигъмәтләрен калдыралар иде.

Бервакыт рәхмәт фәрештәләре Мәрьям радыйаллаһу ганһә янына килделәр вә әйттеләр: «И, Мәрьям, Җәнабел Хак сине барча хатын-кызлар арасыннан сайлап алды вә гөнаһлардан пакьләде вә дәхи сине галәмдәге барча хатын-кызлардан өстен кылды», — диделәр.

Көннәрдән бер көнне Мәрьям радыйаллаһу ганһә, шәһәрдән чыгып, күремнән соң агымсуда госел коену нияте илә үзенә пәрдә тотты. Шәһәргә кайту юлына чыккач, аның каршысында бер яшь егет сурәтендә Җәбраил фәрештә күренде. Бу турыда Коръән Кәримнең «Мәрьям» сүрәсе, 17–21 нче аять-

ләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Без Мәрьям янына Җәбраил фәрештәбезне җибәрдек, ул Мәрьямгә яшь егет сурәтендә күренде. Мәрьям әйтте: «Мин синең шәрреңнән Аллаһы Тәгаләгә сыгынамын, әгәр син тәкъва мөэмин булсаң, миңа якын килмә». Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Хакыйкатьтә, мин синең Раббыңның илчесемен, синең күлмәгеңнең җиңенә өрмәк илә боерылдым. Син саф кыз бала көенчә бер ир бала табачаксың, мин шуны хәбәр итәргә килдем», — диде. Мәрьям әйтте: «Минем ничек балам булсын? Мине һичбер ир тотканы юк вә дәхи мин зина кылучы да булмадым». Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «И, Мәрьям, эш, әлбәттә, син әйткәнчә, ләкин Раббың әйтәдер: «Атасыз бала тудыру Миңа бик җиңел. Без аны атасыз тудырдык, кодрәтебезгә галәмәт булсын вә аңа ияргәннәргә рәхмәт булсын өчен, мәңгелеккә хөкем ителгән әмер булды, әлбәттә, гамәлгә ашар», — диде.

Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең «Бул!» дигән әмере илә ул бала дөньяга килер, адәмнәргә гыйбрәт өчен, ягъни Хак Тәгаләнең камил кодрәтен белсеннәр, дәхи дә бәндәләрне туры юлга күндермәк өчен җибәрелә бу бала», — диде. Бәс, Мәрьям радыйаллаһу ганһә ул балага йөкле булды.

Мәрьям радыйаллаһу ганһә, йөкле булуын аңлап, кавеменнән аерылып, ерак җиргә китте. Рәхмәт фәрештәләре аңа ризык, нигъмәтләр китерделәр вә дәхи төрле ерткыч хайваннардан сакладылар. Хәмел мөддәте җиде ай булды. Бары ике хәез күрмеш Мәрьям радыйаллаһу ганһәгә бу вакытта унөч яшь иде.

Мәрьям радыйаллаһу ганһә, баласын табу нияте илә, хөрмә агачы янына килде, ягъни аның белән пәрдәләнде. Ул карт хөрмә агачының башы күптән корыган иде. Кыш көне булганлыктан, аның яфраклары коелган вә хөрмәсе дә юк иде. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте илә шул мәлне хөрмә агачы чәчәк атты, шунда ук җимешләре өлгереп, Мәрьям радыйаллаһу ганһәне ризыкландырды. Шушындый могҗизаны булдырырга көче җиткән Сөбханә вә Тәгаләнең Мәрьям радыйаллаһу ганһәне ирдән башка гына корсакландырып, бала таптырырга гына көче җитәдер, балчыктан Адәм галәйһиссәламне бар кылуын исегезгә төшерегез! Бу турыда Коръән Кәримнең «Мәрьям» сүрәсе, 25–26 нчы аяти кәримәләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وهزي إليك بجذع النخلة تسقط عليك رطبا جنيا ٢٥ فكلي واشربي وقري عينا فإما ترين من
البشر أحدا فقولي إني نذرت للرحمن صوما فلن أكلم اليوم إنسيا ٢٦

«Үә һүззии иләйки биҗизгин-нәхъләти түсәәкыйтъ гәләйки рутабәң җәннийййә (25). Фәкүлии үәшрабии үә каррии гәйнә. Фә иммәә тәраиннә минәл-бәшәри әхәдәң фәкуулии иннии нәзәртү лиррахмәәни саумәң фәлән үкәллимәл-йәүмә иңсийййә (26)».

Мәгънәсе: *«И, Мәрьям, хөрмә агачының кәүсәсеннән тотып, үзеңә таба селкет, хөрмә сиңа яңа өлгергән җимешен төшерер (25). Ул хөрмәне аша вә чишмә суын эч, углың Гайсә белән күзең нурланып, кайгың бетсен! Әгәр бер кешенең балаң хакында сораганын ишетсәң, әйт: «Мин Аллаһы ризалыгы өчен һичкем белән сөйләшмәскә нәзер әйттем, шуның өчен бу көнне һичкем белән сөйләшмим (26)».*

Хәзрәти Мәрьям радыйаллаһу ганһә, улын күтәреп, Бәйтелмөкаддәс янына килде. Кешеләр аны ташлар атып куарга ниятләделәр. Хәзрәти Гайсә галәйһиссәлам, бишектә булуына карамастан, Аллаһы Тәгаләнең әмере илә телгә килеп, аларны бу ниятләреннән кире кайтарды. Аллаһы Тәгалә «Мәрьям» сүрәсенең 27–33 нче аятьләрендә әйтә:

فأتت به قومها تحمله قالوا يمريم لقد جئت شيئا فريا ٢٧ يأخت هرون ما كان
أبوك امرأ سوء وما كانت أمك بغيا ٢٨ فأشارت إليه قالوا كيف نكلم من كان في المهد صبيا ٢٩
قال إني عبد الله ءاتيني الكتب وجعلني نبيا ٣٠ وجعلني مباركا أين ما كنت وأوصيني
بالصلوة والزكوة ما دمت حيا ٣١ وبرا بولدتي ولم يجعلني جبارا
شقيا ٣٢ والسلم علي يوم ولدت ويوم أموت ويوم أبعث حيا ٣٣

«Фә-әтәт биһии каумәһәә тәхмилүһ. Каалу йәә Мәрьйәәмү ләкаде җизти шәйәң фәрийййә (27). Йәә ухътә һәәруунә мәә кәәнә әбүүкимраәсәүин үә мәә кәәнәт үммүки бәгыйййә (28). Фә-әшәәрат иләйһи, каалүү кәйфә нүкәллимү мәң кәәнә филмәһди сабийййә (29). Каалә иннии гәбдүллааһ. Әәтәәнилкитәбә үә җәгәләнии нәбийййә (30). Үә җәгәләнии мүбәәракән

әйнә мәә күңт. Үә әүсаании биссаләәти үәззәкәәти мәә дүмтү хәййә (31). Үә бәррaң биүәәлидәтии үә ләм йәҗгәлнии җәббәраң шәкыййә (32). Үәссәләәмү гәләййә йәүмә үлидтү үә йәүмә әмүтү үә үбгәсү хәййә (33)».

Мәгънәсе: *«Гайсәне тудыргач, Мәрьям радыйаллаһу ганһә кавеме янына килде. Кавеме әйтте: «И, Мәрьям, ярамаган зур гөнаһлы эш кылдың (27). И, Һарунның кыз кардәше, атаң Гыймран яман юлда булмады, анаң да азгын түгел иде (28). Мәрьям углы Гайсә белән сөйләшергә ишарә кылды. Алар әйттеләр: «Син безне мәсхәрә итәсең, бишектәге сабый бала белән без ничек сөйләшик ди?» (29). Гайсә аларның таш тоткан кулларын вә әйткән сүзләрен ишеткәч, әйтте: «Мин Хак Сөбханә вә Тәгаләнең колымын, Ул миңа Инҗил исемле китап бирде вә мине Үзенең пәйгамбәре итте (30). Кайда гына булсам да, кешеләр өчен мине файдалы кылды, вә миңа намаз укырга, зәкят бирергә әмер итте (31). Янә анама изгелек итүче кылды, мине тәкәбберләнүче вә үзенә гөнаһ эшләүче кылмады (32). Туган көнемдә, үлгән көнемдә вә кабердән кубарылган көнемдә Җәнабел Хактан миңа сәлам булыр (33)».*

Мәрьям радыйаллаһу ганһә, яһүдиләрнең улы Гайсә галәйһиссәламгә вә үзенә зарар китерүләреннән куркып, бер ир карендәше белән Мисыр мәмләкәтенә китте. Биредә алар 12 ел торып, янә Нәсыйра карьясенә кайттылар. Гайсә галәйһиссәламгә 30 яшь тулганчы ошбу карьядә яшәделәр.

30 яшендә Аллаһы Тәгаләнең әмере илә Гайсә галәйһиссәламгә Инҗил исемле китап иңдерелде. Бу китап иңдерелгәч, хәзрәти Муса галәйһиссәлам шәригате вә хөкеме тәмам булды. Соңра хәзрәти Гайсә галәйһиссәлам, Кодес шәрифкә килеп, өч ел буе Инҗил хөкемнәрен дәгъвәт итте. Ләкин бу залим кавем аның сөйләгән вәгазь-нәсыйхәтләрен вә дәхи күрсәткән могҗизаларын сихер, күз буу дип кабул иттеләр. Ул алар күз алдында үлекләрне тергезде, балчыктан бер кош сурәте ясап, аны очырды. Анадан туганда ук сукыр булганнарны күзле итте. Ала тәнле булган бәндәләрне алалыктан коткарды, җеннәрне куып чыгарды, фалиҗ зәхмәтеннән (паралич) терелтте, телсезләрне савыктырды, су өстеннән йөреп күрсәтте. Залим булган яһүди кавеме бу кадәр могҗизаларны күрсәләр дә, калебләренең каралыгыннан хәзрәти Гайсә галәйһиссәламне пәйгамбәр дип кабул итмәделәр. Һәм аңа

иңдерелгән Инҗилне дә кабул итмәделәр. Гыйбрәт өчен аның дөньяга атасыз килүен дә бер зур гаеп эш дип бәяләделәр. Гайсә галәйһиссәлам бу кавемнән көннән-көн күбрәк җәфалар күрде. Хәтта аны үтерергә җайлы вакытны көттеләр. Яһүдиләрдән хәзрәти Гайсә галәйһиссәламгә 12 кеше иман китереп, мөселман булдылар. Боларның күпчелеге балыкчылар иде. Гайсә галәйһиссәлам алар белән яшерен утырышлар җыя иде. Бер кичне үзенә иярган шәкертләренә Инҗил китабын өйрәткәндә Гайсә галәйһиссәлам әйтте: «Бу төн үтеп таң атканда, арагыздан берегез әтәч кычкырганчы мине яһүдиләргә бик аз гына акчага сатачак», — дип белдерде.

Гайсә галәйһиссәламнең әйткәне дөрес булды. Аңа иярган шәкертләреннән берсе, яһүдиләр янына барып, биш-алты дирһәмгә Гайсә галәйһиссәламне сатты, ягъни алар җыелып Инҗилне өйрәнә торган йортны гаскәриләргә күрсәтте. Яһүдиләр, йортны чолгап алып, бу хаинга йортка кереп, Гайсә галәйһиссәлам андамы-юкмы икәнен белеп чыгарга куштылар. Ул йортка керә һәм Гайсә галәйһиссәлам шунда шәкертләре белән дип әйтергә чыга, шул вакыт Аллаһы Тәгалә бу хаинны Гайсә галәйһиссәлам кыяфәтенә кертте, ә Гайсә галәйһиссәламне күккә ашырды. Күзләре тонган яһүдиләр исә Гайсә галәйһиссәлам кыяфәтенә кертелгән хаинны тотып алып дар агачына кадаклап үтерделәр.

Шушы вакыйгадан соң Гайсә галәйһиссәламнең шәкертләре җиһанның төрле тарафларына таралдылар һәм барган җирләрендә Инҗил китабындагы аятьләрне сөйләп, вәгазьнәсыйхәт кылдылар.

Борынгы Ислам тарихы битләренә күз салсак, хәзрәти Гайсә галәйһиссәлам Адәм галәйһиссәламнән соң 5594 елга соңрак, Нух галәйһиссәламнән соң 3198 елга, хәзрәти Ибраһим галәйһиссәламнән соң 2120 елга, хәзрәти Дауд галәйһиссәламнән соң 1104 елга соңрак, хәзрәти Яхъя галәйһиссәламнән соң 1 ел үткәч туа.

Аллаһы Тәгалә «әл-Маидә» сүрәсенең 110 нчы аяти кәримәсендә әйтә: «Аллаһы Тәгалә кыямәт көнне әйтер: «И, Мәрьям углы Гайсә, без сиңа һәм анаңа биргән нигъмәтне бүген сөйлә! Җәбраил галәйһиссәлам белән сиңа куәт биргәнебезне, кешеләр белән бишектә һәм пәйгамбәр булгач хикмәтле сүзләр сөйләвеңне, Мин сине укырга вә язарга өйрәткәнемне, Ис-

лам хөкемнәрен, Тәүратны вә Инҗилне өйрәткәнемне, янә Минем әмерем илә кош сурәтен ясап аңа сулышың белән өрүең, аннары бу кош Минем әмерем илә очып китүен, янә Минем әмерем илә сукырларны күзле итүеңне вә дәхи ала тәнлеләрне һәм башка авыруларны сәламәтләндерүеңне, дәхи бәни Исраилнең явыз мәкереннән сине коткарганымны, син аларга Инҗил китабының хөкемнәрен өйрәткәч вә ачык могҗизалар күрсәткәч, аларның ышанмаулары, ягъни бу — сихердән башка берни түгел, дип инкарь итүләрен сөйләп бир, янә хәтерләренә төшер (110)».

Гайсә галәйһиссәлам вафатыннан соң бәгъзе наданнар аны Аллаһы Тәгаләнең улы диделәр. Мондый сүзне әйтүчеләр кяфер булдылар. Чөнки Коръән Кәримнең «әл-Маидә» сүрәсе, 17 нче аяти кәримәсендә Хак Тәгалә әйтә: «Мәрьям углы Гайсәне Аллаһының углы диючеләр кяфер булдылар. И, Мөхәммәд галәйһиссәлам, әйт: әгәр Аллаһ җирдәге бөтен нәрсәне, вә Гайсәне һәм анасын һәлак итәргә теләсә, Аллаһының бу теләгенә кем каршы тора алыр икән? Ягъни Аллаһы Тәгалә җир йөзендәге бөтен нәрсәне һәлак итә калса, шул вакытта Гайсә галәйһиссәламнең үзен коткарырга да көче җитмәс иде, шулай булгач, ничек инде ул Аллаһ яки аның углы була алсын? Җирдә, күкләрдә вә алар арасында булган бөтен нәрсә Аллаһы Тәгаләнең байлыгы, Аллаһ Үзе теләгән нәрсәне бар кылыр, Аның һәрнәрсәгә көче җитә (17)».

Ислам шәригате буенча Гайсә галәйһиссәлам башка пәйгамбәрләр шикелле анадан туды һәм кыямәт көнне кабердән кубарылачак. Моңа Коръән Кәримдә дәлилләр бар. «әл-Гыймран» сүрәсенең 49–50 нче аяти кәримәләрендә болай диелгән: «Гайсә, пәйгамбәр булгач, Ягъкуб балаларына әйтте: «Мин сезгә Раббымнан пәйгамбәрлегемә ачык дәлилләр вә төрле галәмәтләр белән килдем... Аллаһы Тәгаләнең әмере илә үлеләрне тергезермен, янә нәрсә ашаганыгызны белермен, өйләрегездә яшереп саклаган нәрсәләрдән хәбәр бирермен (49). Бу нәрсәләрдә, әлбәттә, минем пәйгамбәрлегемне тәсдыйклаучы галәмәтләр бар, әгәр хаклыкка ышанучылардан булсагыз. Миннән әүвәл иңдерелгән Тәүратны кабул иткәнем хәлдә, ... Раббымнан төрле могҗизалар белән сезгә пәйгамбәр булып килдем. Шулай булгач, Җәнабел Хактан куркыгыз, миңа итагать кылыгыз вә карышудан сакланыгыз! (50)».

Гайсә галәйhиссәламнең ничек вафат булуы хакында Коръән Кәримнең «әл-Гыймран» сүрәсе, 54–55 нче аяти кәримәләрендә Аллаhы Тәгалә әйтә: «Кяферләр Гайсә галәйhиссәламгә каршы явыз хәйлә кордылар. Аллаhы Тәгалә аларга каршы көчлерәк хәйләне корды. Чөнки Газзә вә Җәллә хәйлә коручыларның иң хәерлесе вә иң көчлеседер. Кяферләр Гайсәне ничек гаепләргә, үзләрен дөресләргә дәлил тапмагач, ачуларыннан Гайсәне үтерергә әмер бирделәр. Мөселманнар арасында кяферләргә сатылган бер монафикъ бар иде, кяферләр Гайсәне үтерергә карар чыгаргач, шул монафикъ Гайсә кергән өйгә кяферләрне җыеп алып килде. Ләкин бу вакытта Аллаhы Тәгалә Гайсәне күккә алган иде инде. Монафикъ Гайсә галәйhиссәламне тотабыз дип өйгә кергәч, Сөбханә вә Тәгалә аның сурәтен Гайсә сурәтенә кертте. Кяферләр аны Гайсә дип белеп, тотып алып, асып куйдылар. Менә аларга Аллаhы Тәгаләнең бер хәйләсе шул булды. Җәнабел Хак әйтте: «И, Гайсә, Мин, әлбәттә, сине үтерүче вә үз хозурыма күтәрүчемен, hәм сине кяферләрнең явыз хәйләсеннән саклап, пычрак йогынтыларыннан пакьләүчемен. Сиңа ияргән мөэминнәрне кыямәт көненә чаклы кяферләрдән өстен кылучымын (54–55)».

Мөхәммәд пәйгамбәргә чаклы 600 ел элек Гайсә галәйhиссәламгә иңдерелгән Инҗилдә Мөхәммәд галәйhиссәламнең, ягъни соңгы пәйгамбәрнең киләчәге турында әйтелгән. Бу турыда Коръән Кәримнең «Саф» сүрәсе, 6 нчы аяти кәримәсендә Аллаhы Тәгалә әйтә: «Мәрьям углы Гайсә пәйгамбәр әйтте: «И, Ягъкуб балалары, тәхкыйк, мин Аллаhы Тәгаләдән сезгә җибәрелгән пәйгамбәрмен, миннән элек иңдерелгән Тәүратны ихлас күңелемнән кабул иткәнем hәм миннән соң килә торган пәйгамбәр белән сөенеч бирәм, аның исеме Әхмәд (Мөхәммәд) булыр», — диде (6)».

Инде бу кыйссаның файдасы шул: Хак Сөбханә вә Тәгаләгә буйсынган, аны үзәктә тоткан, Хак Тәгалә хөкеменә бәйле булган, Җәнабел Хак саклаган кешегә үлем вә газап юктыр.

Янә бер файдасы шул: кем дә кем Аллаhы Тәгалә белән булса — Хак Тәгалә hәрдаим аның беләндер, әгәр дә мәгәр хәйлә вә явызлык аңа зыян китерә икән — ахырда барыбер гыйzzәттән мәхрүм булмас. Һәркем изге уйда булса, hәрвакытта Хак Тәгаләне хәтерендә сакласа — ул кешенең hәр эшен Аллаhы Тәгалә уң итәр.

# МӨХӘММӘД ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Әссәламугаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ!

Корьән Кәримнең 105 нче «Фил» сүрәсе пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вәссәлам туасы елда булган вакыйгаларны яктырта. «Фил ияләре кыйссасы»нда бу турыда язылा: Йәмән патшасы Нәҗәшинең бер азгын Әбраһә исемле вәзире бар иде. Әбраһә Сунга шәһәрендә бер чиркәү салды, ул чиркәүне Кәлис дип атады. Эчен зиннәтләп, зур шәмнәр яндырып, бер пот кертеп куйды. Моннан соң кем хаҗ кылырга теләсә, Мәккәгә бармыйча, Кәлискә килеп гыйбадәт кылсын дип, хөкем куйды. Бу хөкемне Мәлик бин Надар дигән бер егет ишетеп, Сунга шәһәренә килеп, Кәлисне ут төртеп яндырды. Әбраһә моны белеп: «Бу эшне гарәпләр эшләгәндер, Мәккәгә барып Кәгъбәне һәлак итәрмен», — дип ант итте. Патшадан барлык сугышларда җиңү китерүче Мәхмүд исемле бик куәтле һәм мактаулы филен сорады. Шулай ук бик күп филләр җыеп, сиксән меңнән артык гаскәр белән Мәккәне һәм андагы Кәгъбәне алырга килде. Бу вакытта Мәккә халкының хайваннары сахрада иде. Әбраһә гаскәре барчасын куып үзләренә алдылар. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең бабасы Габделмоталлибның ике йөз дөясен дә алдылар, чөнки Габделмоталлибны Мәккә гарәпләренең башлыгы диеп ишеткәннәр иде. Габделмоталлиб, бу хәлне белеп, Әбраһә янына барды, хөрмәт кылып сәлам бирде. Әбраһә сәлам кайтарды, кадер-хөрмәт күрсәтте. Ашап-эчкәннән соң: «Әй, гарәпләр хуҗасы, монда ник килдең?» — диде. «Гаскәрең ике йөз дөямне куып алганнар, шул дөяләрем артыннан килдем», — диде. Әбраһә: «Мин синең үзеңне күргәч бик яраткан идем, сүзеңне ишеткәч, ихласым бетте, бүген дөя сорый торган көн түгел, мин Кәгъбәне ватарга килдем. Синең атаң Ибраһим һәм аның углы Исмәгыйль салган йорт, син шуны сорарга тиеш идең», — диде. Габделмоталлиб: «Мин үземнең дөяләремә хуҗа, дөяләремне бир, ул Кәгъбәнең хуҗасы — Аллаһы Тәгалә, Кәгъбәне үзе саклар, иншә Аллаһ, ваттырмас», — дип җавап бирде. Әбраһә Габделмоталлибның дөяләрен биреп җибәрде.

Габделмоталлиб Мәккәгә кайтып, аның халкына әйтте: «Әбраһә Кәгъбәтулланы ватарга дип бик күп гаскәр һәм филләр белән килгән, күзегез күрмәсен, тауларга качыгыз, мин инде, Аллага тапшырып, Кәгъбәтуллада калам», — диде. Мәккә халкы барчасы чыгып качтылар.

Әбраһә Кәгъбәтулланы җимерергә торган коралларны һәм филләрне алга куйды. Филләр Кәгъбәтулланы күргәч, бик каты тавыш чыгарып кычкырдылар, бөгелеп, сәҗдә кылган кебек йөзләрен җиргә сөрттеләр, күзләреннән бертуктамый катрә-катрә яшьләр агыздылар, аларны хуҗалары һөҗүмгә өндәп никадәр кусалар да, урыннарыннан кузгата алмадылар.

Шул вакыт Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләнең әмере илә, һавада сыерчыктан кечерәк, чыпчыктан зуррак, кызыл борынлы, кара башлы, озын муенлы кошлар пәйда булды. Һәркайсының авызында борчак кадәрле таш, ул ташта Әбраһә гаскәреннән һәрбер кешенең исеме язылган. Кошлар Әбраһә гаскәре турысына килеп, ташларны яудырдылар. Һәр таш язылган исем иясенең башына төшеп, җаны җәһәннәмгә китте. Сиксән меңнән артык гаскәрдән бер сәгать эчендә Әбраһәдән башка һичкем исән калмады.

Әбраһә бу галәмәтне күреп, коты очып, качып кайтып, Мәккәи Мөкәррәмәдә булган хәлләрне Йәмән патшасы Нәҗәшигә сөйләп бетергәч, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән, бер әбабил кошы очып килеп, Әбраһә башына бер борчак кадәр ташны төшерде. Әбраһәнең шулчак җаны җәһәннәмгә китте. Нәҗәши, бу хәлне күреп, Кәгъбәгә ихлас баглады, Аллаһы Тәгаләдән һәм Габделмоталлибтан гафу үтенеп хат язды һәм бүләк итеп бик күп мал җибәрде.

Мәккә халкына килгәндә, туып-үскән җирләрендә һич шау-шу, җимерү тавышлары ишетмәгәч, кире өйләренә кайттылар. Әл-Хәрам шәрифнең, ягъни Кәгъбәтулланың төзек көе торганын күреп, күз яшьләре аралаш шатландылар. Шәһәр тирәсендә Әбраһә гаскәренең барысы үлгәнен күрделәр, аларны берничә көн буе күмделәр.

Габделмоталлиб бу Әбраһә гаскәреннән калган алтын-көмешләрне Мәккә халкына бүлеп бирде, үзенә бернәрсә дә алмады. Мәккәнең исән калуына шатланып, бик күп корбан чалды.

Аллаһы Тәгаләне вә Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламне зикер итү бәянында «әл-Әхзаб» сүрәсе, 41–42 нче

аятьләрдә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Йәә әййүһәлләзиинә әәмәнүз-күруллаааһә зикраң кәсиир (41). Үә сәббихүүһү букратәүвә әсыййлә (42)».

Мәгънәсе: *«И, мөэминнәр, Аллаһы Тәгаләне күп зикер итегез! (41). Көннең әүвәлендә һәм ахырында Аны мактап тәсбих әйтегез (42)».*

Аллаһы Тәгаләне зикер иткәндә Мөхәммәд галәйһиссәламне дә зикер итәргә онытмагыз, чөнки ул кыямәт көнендә безнең шәфәгатьчебез булачак.

Ибн Габбас радыйаллаһу ганһе әйтә: «Хак Тәгалә галәмне, ягъни оҗмах вә тәмугны, җир вә күкне, гареш вә көрсине һәм башкаларны яратырга, бар кылырга теләгән заманда, Үз нурыннан бераз нур алып, нурга: «Хәбибем Мөхәммәд бул», — диде».

Икенче риваятьтә: «Хак Тәгалә җир вә күкләрне бар кылырга теләгән заманда, Үзенең нурыннан бераз нур алып, нурга әйтте: «Әй, нур, син хәбиб, ягъни дустым Мөхәммәд бул!» Ул нур Адәм галәйһиссәлам яратылудан әүвәл биш йөз ел элек гарештә «әлхәмдүлилләһ», дип тәваф кылыр иде. Хак Тәгалә бу хәмедне әйткәне өчен Мөхәммәд диеп исем кушты. Аннан соң Мөхәммәд галәйһиссәламнең нурыннан Адәм галәйһиссәламне бар кылды. Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вәссәламнең тәнен Адәм галәйһиссәлам балчыгыннан яралтты. Моннан соң Мөхәммәд галәйһиссәламнең нурын Адәм галәйһиссәламнең аркасына куйды. Ул нур Адәм галәйһиссәламнән Хәва анага күчте. Шулай атадан анага күчеп, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламгә иреште.

Мөхәммәд галәйһиссәламнең нәселе: сәйидебез, пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламнең атасы Габдулла, аның атасы Габделмоталлиб (чын исеме — Шибәтүл хәмед), Габделмоталлибның атасы Һашим (чын исеме — Гамру), аның атасы Габделмәннәф (чын исеме — Мугыйра), аның атасы Кусай (чын исеме — Мөҗәммигъ), аның атасы Кәлаб (чын исеме — Хәким), аның атасы Мәрра, аның атасы Лүәй, аның атасы Галиб, аның атасы Фәһер (чын исеме — Корәеш), аның атасы Мәлик, аның атасы Назар, аның атасы Кинәнә, аның атасы Хузәймә, аның атасы Мөдрикә, аның атасы Ильяс, аның атасы Мәдар, аның атасы Нәзар, аның атасы Мәгдә, аның атасы Гиднән, Гиднәннең атасы Исмәгыйль галәйһиссәлам.

Әмма Гиднәннән Исмәгыйль галәйһиссәламгә кадәр фәлән фәләннең углы диеп билгеләүдән Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам тыйды. «Кәзбүн-нисәбүн» дип, ягъни нәсел-нәсәбен билгеләүчеләр ялгышырга мөмкин, моны тик Аллаһы Тәгалә генә белә дип әйтә торган була. Безгә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вәссәламнең, без барыбыз да Исмәгыйль галәйһиссәлам нәселеннән, диеп әйтүе бик җитәдер.

Риваять килә: Шам вилаятендә яһүдләрнең галимнәре үзләренең китапларында күрделәр: «Яхъя галәйһиссәлам хөббәсеннән кан тамса, шул вакыт Мөхәммәд галәйһиссәламнең атасы дөньяга килер», — диеп язылган иде. Шул сәбәпле тикшереп, сорашып, Габделмоталлибның улы дөньяга килгәнен белделәр. Габдулла үскәч, аны үтерергә ниятләделәр. Аллаһы Тәгалә аларга фәрештәләр җибәрде, ниятләүчеләрнең барчасын үтерделәр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вәссәламнең анасы Әминәнең атасы Вәһһаб тау башында Яхъя галәйһиссәламнең хөббәсеннән кан тамганын күреп, Габдулла бин Габделмоталлибның тууын белде. Габдулланы бәла-казадан Аллаһы Тәгалә Үзе саклады, үсеп егет булды.

Көннәрдән бер көнне Вәһһаб үзенең хатыны Бәррага әйтте: «Кызыбыз Әминәне Габдуллага хатынлыкка бирәбезме?» — диде. Хатыны Бәрра: «Әйе, андый күркәм холыклы егеткә бирергә мин бик риза», — диде. Бу сөйләшүдән соң берничә көн үткәч, Аллаһының хикмәте Габделмоталлиб бин Габдулла Вәһһаб кызы Әминәне сорап яучы җибәрде. Вәһһаб мең шөкер илә яучыны кабул итте. Рәҗәб аенда җомга кичне туй иттеләр. Зөфаф шул ук кичтә булып, Әминә йөкле булды. Ибн Габбас радыйаллаһу ганһе әйтте: «Бу кичә Курайш кабиләсендә булган һәр җанвар сөйләшеп, бер-берсенә: «Мөхәммәд бу көнне ана карынына төште», — дип сөенеч бирделәр». Бәгъзеләре: «Кәгъбәнең Раббысы белән ант итеп әйтәбез, ул Мөхәммәд дөньяның иминлегедер, ата-бабасының нурыдыр», — диделәр. Иблис мәлгунь Әбү Кәбис тавына менеп кычкырды. Шайтаннар: «Ни булды сиңа, әй, хуҗабыз?» — дип янына җыелдылар. Иблис: «Минем акыру-бакыруымның сәбәбе шул, аһ, минем ничә еллар буе чиккән мәшәкатем юкка чыкты, бу көнне Мөхәммәд ана карынына төште, Аллаһы Тә-

галә аны үткен кылыч белән җибәрер, ул — Ислам динен үз дәрәҗәсенә күтәрер, моңа кадәр барча кешеләр табынган потларны җимерер», — диде.

Хисәб бин Сәбит радыйаллаһу ганһе әйтте: «Мин җиде яшемдә идем, Мәдинә урамында бер яһүди: «Әй, яһүдиләр! Сез беләсезме, бу кичтә Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламнең йолдызы туды», — дип кычкырды.

Әминә радыйаллаһу ганһә әйтте: «Улым Мөхәммәдкә йөкле булганда, башка хатыннар кебек авырлык күрмәдем, ләкин хәез күрүем тукталды. Янә улым Мөхәммәдкә йөкле булгач, бер нур күрдем, бу нурдан мәшрикъ вә мәгъриб яктырды. Бу яктылык вакытында хәтта Шам вилаятендә булган Басра шәһәренең сарайларын ачык күрдем. Йөкле булуымның беренче аенда төшемдә озын буйлы бер кешене күрдем, бу кеше миңа: «И, Әминә! Сөенеч сиңа, пәйгамбәрләр хуҗасына йөкле булдың», — диде. Мин аннан: «Син кем?» — дип сорадым. Ул: «Барча кешеләрнең иң беренче атасы Адәм галәйһиссәлам», — диде. Икенче айда төшемдә янә бер кешене күрдем, ул: «Сөенеч сиңа, Әминә, әүвәлге вә ахыргы кавемнең хуҗасы белән йөкле булдың», — диде. Ул үзен Шис галәйһиссәлам дип атады. Өченче айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, хөрмәтле Пәйгамбәр белән йөкле булдың», — диде. Ул Нух галәйһиссәлам иде. Дүртенче айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, шәрифле хуҗа белән йөкле булдың», — диде. Ул Идрис галәйһиссәлам иде. Бишенче айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, адәмнәрнең хуҗасы белән йөкле булдың», — диде. Ул Һуд галәйһиссәлам иде. Алтынчы айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, Һәшим ыруыннан килүче пәйгамбәр белән йөкле булдың», — диде. Ул Ибраһим галәйһиссәлам иде. Җиденче айда бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, галәмне тәрбия кылучы Аллаһы Тәгаләнең дусты белән йөкле булдың», — диде. Ул Исмәгыйль галәйһиссәлам иде. Бу җиденче айда Багдад шәһәрендә Кәсәри патшаның сарае түбәсендәге манараларның үндүрт гөмбәзе җимерелеп төште. Сигезенче айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, тәхкыйк, ахырзаманның соңгы пәйгамбәренә йөкле булдың», — диде. Ул Муса галәйһиссәлам иде. Бу сигезенче айда фарсы мәҗүсиләренең гыйбадәт кыла торган утлары сүнде. Яхъя Сәрәри радыйаллаһу ганһе әйтте: «Фарсыларның утка табынучы мәҗүсиләренең бу утлары мең

елдан бирле сүнмичә яна иде». Тугызынчы айда янә бер кешене күрдем: «Сөенеч сиңа, галәмнең горурлыгы Мөхәммәдкә йөкле булдың», — диде. Ул Гайсә галәйһиссәлам иде.

Мәшһүр риваятькә нигезләнеп, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам белән йөкле булуының икенче аенда атасы Габдулла Габделмоталлиб радыйаллаһу ганһенең йомышы белән Шам шәһәренә барган иде, шуннан кайтышлый Йәсриб (Мәдинә) шәһәре янында вафат булып, шул шәһәрнең зиратында җирләнде. Фәрештәләр әйттеләр: «И, Раббыбыз! Пәйгамбәрең ятим калды». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Борчылмагыз, Мин аны саклаучы хуҗасы һәм кирәк вакытта җиңү бирүчемен».

Әминә радыйаллаһу ганһә әйтте: «Улымның туу киче җиткәч, дүшәмбе кич таң алды иде. Күктән бер төркем бик күркәм җәмәгать иңде. Аларның өч әләме бар иде: берсен Кәгъбәтулланың өстенә, икенчесен үз йортымның түбәсенә, өченчесен Бәйтелмөкаддәскә кададылар. Йолдызлар шулкадәр якын килделәр ки, хәтта үземә төшәр дип уйладым. Күк ишекләрен тәмам ачык күрдем. Моннан соң өемнең эче зөбәрҗәт борынлы кошлар белән тулды. Дөнья яп-якты булды. Күк белән җир арасында ефәк паласлар түшәлгән итеп, шулай ук һавада кулларына алтын тоткалы көмеш комганнар тоткан ир кешеләрне күрдем. Шул заман сусадым, шул комганнарның берсеннән су эчтем. Мондый тәмле суны моңарчы беркайчан да эчкәнем булмады, бу җәннәттән килгән су иде, тынычланып йоклап киткәнмен.

Уянгач, бу хәлләрне уйлап ятамын, ялгызлыктан күңелем зарыкты, шулчак яныма бер төркем хатын-кызлар керде. Үзләре шулкадәр матурлар вә сөйкемлеләр иде, мин моңа хәйран булдым. Араларында берсенең исеме Асия иде, ул миңа аеруча ярдәм итте.

Тулгагым тулып эчем авыртты, бер кош килеп канаты белән корсагымны сыйпады, шулчак бик җиңеллек белән Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламне тудырдым. Мөхәммәд галәйһиссәлам ике аягы белән туды, ягъни йөзтүбән тумады. Бу аның Аллаһы Тәгалә хөкемендә туры булуына ишарә иде. Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вәссәлам тугач, теле белән: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр кәбиран, әлхәмдү лилләһи раббил галәмин», — диде. Ул сөннәтле һәм кендеге киселгән булып туды».

Риваятьтә килә: сөннәтле булып дөньяга килгән пәйгамбәрләр: Адәм галәйһиссәлам, Шис галәйһиссәлам, Идрис галәйһиссәлам, Нух галәйһиссәлам, Лут галәйһиссәлам, Йосыф галәйһиссәлам, Муса галәйһиссәлам, Шөгаиб галәйһиссәлам, Сөләйман галәйһиссәлам, Яхъя галәйһиссәлам, Гайсә галәйһиссәлам һәм Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вәссәлам иде.

Әминә радыйаллаһу ганһә әйтте: «Мөхәммәд галәйһиссәламне тудыргач, айга охшаган бер фәрештә улымны алып китеп, бер сәгать юк булып торды. Моннан соң яныма китереп: «Улыңны ал, бер сәгать мәшрикъ вә мәгърибкә тәваф кылды, Адәм галәйһиссәлам янына барды, Адәм галәйһиссәлам, ике күз арасыннан үбеп: «Сөенеч сиңа, әй минем дустым, син әүвәлге вә ахыргы балаларымның хуҗасы», — диде. Моннан соң янә оҗмах сакчысы Ридван фәрештәне күрдем, ул: «Әй, дөньяның хөрмәтлесе, ахирәтнең шәрифлесе, беркем синең сүзеңне сөйләсә, синең шаһәдәтең белән шаһәдәт бирсә, кыямәт көнне синең гыйлемең астында булыр», — дип, Аллаһы Тәгаләнең әмере илә Рәсүлулланың аркасына пәйгамбәрлек мөһерен басты», — диде.

Габделмоталлиб әйтте: «Мин ул кичтә Кәгъбәтуллада идем. Кәгъбә авышып, Мәкам Ибраһим тарафына сәҗдә кылды, ләкин бер генә ташы да үз урыныннан авышмады. Потлар куйган урыннарыннан егылып төштеләр. Кәгъбәтулладан тавыш ишеттем: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, гөнаһлардан пакь булучы туды. Мөхәммәд галәйһиссәлам мине Раббым мөшрикләрнең нәҗесеннән пакь кылды».

Әминәнең өенә килдем, аның өен ак төстәге рәхмәт болытлары каплаганын күреп бик гаҗәпләндем. Йокыммы, уяулыкмы диеп күземне сөртәмен. Ишектән: «Әминә, ишекне ач», — диеп кычкырдым. Ишекне ачу белән хуш исле җофар исе борыныма тулды. Мин: «Йә, Әминә, ни хәлең бар? — дидем. Әминә: «Мөхәммәдне тудырдым», — дип, шатлык яшьләре түкте. «Кайда ул, күрим», — дип, аргы бүлмәгә керергә теләдем. Шулчак адәм сурәтендә бер фәрештә чыкты, кулында ялангач кылыч иде, ул: «И, Габделмоталлиб, сабыр ит, кермә, Мөхәммәд галәйһиссәлам белән фәрештәләр күрешеп бетерсеннәр», — диде. (Бу өлеше «Нәзһәтүл-мәҗәлис» китабыннан алынды).

Риваять кылына, Әминә радыйаллаһу ганһә әйтте: «Мөхәммәдне тудыру кичендә өйнең түбәсе күтәрелде, һавада шулкадәр матур кызлар күрдем, матурлыкта тиңдәшләре юк. Сокланып вә гаҗәпсенеп карап торганда, берсе әйтте: «Кайчанга кадәр гаҗәпсенеп карарсың. Без барчабыз да синең хезмәтчеләрең. Гаден җәннәтеннән сиңа хезмәт итәргә Аллаһы Тәгалә үзе безне җибәрде», — диделәр. Мин тынычланып, йокыга талдым, күземне ачканда баламны тудырган идем инде. Улымның бер кулын күзенә, икенче кулын ят әгъзасына куйганын күрдем, шул хәлдә сәҗдә кылды. Колагымны салып тыңладым. «Өммәтем, өммәтем», — дип әйтә иде. Шул вакыт күземнән югалды. Кая киттең, улым, дип торганда, бер ак болыт улымны китереп, яныма куйды. Күрәм, улымны юганнар, күзенә сөрмә тартканнар, хушбуй сипкәннәр һәм ефәккә чорнаганнар. Шул вакыт дусты Гатикә кереп: «Әй, Әминә, ни хәлең бар?» — дип сорады. Әминә булган хәлләрне баштанаяк сөйләп бирде. Гатикә әйтте: «Йоклаган җиремнән сикереп тордым, кайда ул Мөхәммәд диеп, кулыма алып аны кочакладым, җаным тынычланды. Аннан шулкадәр ләззәтле хушбуй исе килә иде ки, андый ләззәтле хушбуйны иснәгәнем һәм күргәнем юк иде. Мин гаҗәпләнеп Мөхәммәднең йөзен ачып карадым, аның йөзе әйтерсең тулган ай иде. Ул төн шундый төн иде, дөньяның әүвәленнән ахырынача андый төн булмас дип уйлыйм, чөнки аны сүз белән сөйләп бетереп булмый. Иртә белән әйтүләренә караганда, Кәгъбәдәге өч йөз алтмыш потның барчасы җиргә егылып төшкәннәр».

Мөхәммәд галәйһиссәлам дөньяга килгәнче, шайтаннар вә җеннәр күккә менеп, фәрештәләрнең сүзләрен тыңлап, ишетеп, багучы-сихерчеләренә бардылар. Тегеләре, дөньядагы иң бөек пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһиссәламнең туачагын әйтсәләр дә, бу вакыйга кайчан һәм кайда булачагын төгәл генә әйтә алмадылар. Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вәссәлам туган кичәдә гадәттәгечә күккә менәргә теләгән вакытларында, Сөбханә вә Тәгалә шайтаннарны, җеннәрне йолдызлар атып куарга әмер итте. Күккә менеп фәрештәләрнең сөйләшкәннәрен тыңлый алмауларына кайгырып, Иблис мәлгунь янына җыелып: «Ни булды икән, бу кичне безне күккә якын да җибәрмәделәр?» — дип сорадылар. Иблис мәлгунь: «Бүген Аллаһының якын фәрештәләренең

күктән җиргә иңгәннәрен үз күзләрем белән күрдем, барыгыз бер яңа хәбәр китерегез!» — дип кычкырды. Шайтаннар вә җеннәр кинәт Мәккә тарафына бер якты нур төшкәнен күрделәр, якын килделәр исә, Мәккәи Мөкәррәмә турысында фәрештәләрнең һавада сафка тезелеп торганнарын күрделәр, саф шулкадәр тыгыз, хәтта инә керерлек урын юк, тирә-юньне сакчы фәрештәләр саклый. Шайтаннар бу нинди галәмәт икән диеп якын килергә тырышсалар да, сакчы фәрештәләр аларны утлы чукмарлар белән кудылар. Алар, куркышып, Иблис мәлгуньгә бу хәбәрне җиткерделәр. Иблис мәлгунь: «Аһ!» — дип акырды. Шайтаннар тагы да ныграк куркышып: «Йә, хуҗабыз, ни өчен бу кадәр кайгырасың, әллә дөнья бетәме?» — диделәр. Иблис әйтте: «Минем өчен бу төннән дә авыррак төн юк, чөнки минем ничә мең еллык тырышканымны аның сәясәте югалтачак. Сезнең күккә менә алмавыгызга һәм Мәккә өстендәге нурда сафка тезелеп торган фәрештәләрнең торуына ул ахырзаман Пәйгамбәренең дөньяга килүе сәбәп. Аның шәригате моңа кадәр килгән барча пәйгамбәрләрнең шәригатен үзгәртер. Мисал өчен, бер адәм гомере буе адашып, азгынлыкта йөреп, мөшрик булса, ялгышканын аңлап, бер сәгать ул Пәйгамбәрнең диненә кереп, тәүбә-истигъфар кылса, аның барча гөнаһысы гафу ителер. Аның өммәтеннән бер адәм гомере буе бозыклыкта булса, берзаман моңа үкенеп салават әйтсә, барча явызлыклары урынына изгелекләр язылыр, кылган бөтен гөнаһысы ярлыканыр. Аллаһының рәхмәтенә лаек булыр. Бу шундый Пәйгамбәр, кыяматтә гөнаһлы өммәтләренә шәфәгать кылып, аларны тәмугтан коткарыр. Менә шуңа күрә мин үземнең көчсезлегемә борчылып акырам».

Алда әйткәнебезчә, Габделмоталлиб, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам янына кергәннән соң, чын Пәйгамбәрне күрде. Мөхәммәд галәйһиссәлам, бабасын күреп, имән бармагын күтәреп, кәлимәи шаһәдәт әйткән кебек ишарәләде. Габделмоталлиб бу кәраматләрне күреп бик шатланды. Кулына күтәреп, Кәгъбә шәрифкә алып керде. Ихлас нияте белән Аллаһы Тәгаләгә мондый бала биргәне өчен шөкер итеп, дога кылды. Җиде көннән соң Мөхәммәд диеп исем куштырып, Мәккә халкын җыеп сыйлады, кадер-хөрмәт кылды.

Мөхәммәд дип исем бирүенең сәбәбе бу иде: Әминә радыйаллаһу ганһәгә төшендә бер фәрештә килеп: «Әй, Әминә,

син барча мәхлукларның хуҗасына йөкле булдың, аны тудырсаң, Мөхәммәд диеп исем куш. Чөнки ул галәмнәрнең хуҗасы бик макталган булыр. Әй, Әминә, Мөхәммәд галәйһиссәламне тудырганда күп гаҗәп эшләр күрерсең. Күргән гаҗәпләрне адәмнәргә сөйләмә һәм бу бөтине Мөхәммәд галәйһиссәламгә так», — диде. Шул заман уянып китә, баш астында бер алтын кәгазь таба, анда болай диеп язылган була: «Үгзүһү бил-үәһиди мин шәрри күлли хәсиди үә күлли халькин раиди миң каими үә кагиди ганис-сәбили хәиди гәләл-фәсәди җәһиди мин-нәфиси әү гакиди үә күллә халькин мәриди йәәхүзү бил-мәрасиди миң турукинил-мәуәриди».

Әминә төшендә күргән фәрештәнең «Мөхәммәд дип исем куегыз, бу — Аллаһы Тәгаләнең әмере», дигән сүзен Габделмоталлибка әйтте. Габделмоталлиб балага Мөхәммәд дип исем бирде.

Мөхәммәд галәйһиссәламнең атасы — Габдулла бин Габделмоталлиб. Ул ибн Вәһһаб исемле кешенең Әминә исемле кызына өйләнгән иде. Бу вакытта Габдуллага 18 яшь иде. Ләкин Габдулла озак гомер сөрә алмады. Габдулланың вафатыннан соң улы Мөхәммәдкә калган малы биш дөя вә Үммү Әймән исемле кәнизәк хатын иде.

Габдулланың вафатыннан соң ике ай үткәч, Әминә бер ир бала тапты. Аның туачагы хакында Коръән Кәримнең «Саф» сүрәсе, 6 нчы аятендә әйтелгән, Тәүратта аның исеме Әхмәд (Мөхәммәд) дип хәбәр бирелгән. Бу хәбәргә Габдулланың атасы Габделмоталлиб һәм туганнары бик шатландылар. Баланың тууы турында хәбәр китерүчеләргә бүләкләр бирделәр. Ошбу бала пәйгамбәрләрнең соңгысы — Мөхәммәд саллаллаһу галәйһиссәлам иде. Бу турыда Коръәннең «Әгъраф» сүрәсе, 157 нче аяти кәримәсендә: «...колларындагы Тәүрат вә Инҗил китапларында Рәсүлнең сыйфатлары язылганын табарлар», — дип әйтелгән. Мөхәммәд галәйһиссәламнең тууы гарәпләр арасында мәшһүр булган фил елында, 570 нче тарих миладн 27 нче апрельдә, тарих һиҗридән 53 ел әүвәл 12 нче рабигыль-әүвәл, дүшәмбе көнгә каршы туры килә. Аллаһы Тәгалә, Пәйгамбәребезне хөрмәтләп, 47 нче сүрәне «Мөхәммәд» сүрәсе дип атады.

Мөхәммәд галәйһиссәламне иң әүвәл имезгән хатын — Әбү Ләһәбнең кәнизәге Сүәйбә иде. Сүәйбә моннан элек Хәмзә

ибн Габделмоталлибны, соңра Әбү Сәлимә ибн Габдул Әсәдне имезгәне өчен, алар Мөхәммәд галәйһиссәлам белән сөт кардәшләр булдылар.

Бу вакытларда Мәккә гарәпләрендә балаларын имезү һәм тәрбияләү өчен сахра гарәпләренә бирү гадәте бар иде. Чөнки бала сахрада таза һәм әрсез, тормыштагы һәртөрле вакыйгаларга чыдамлы булып үсә. Шул гадәт буенча, Мөхәммәд галәйһиссәлам Бәни Сәгъд кабиләсендәге Әбү Зуәйб кызы Хәлимәгә тапшырылды. Хәлимәнең ире Харис ибн Габдул Гуззә иде. Башта Хәлимә: «Без үзебез дә фәкыйрь, бу ятим баланы тәрбияләүдән безгә файда булмас», — дип, тәрбиягә алырга теләмәгән иде, ләкин Мөхәммәдне күргәч, күңелендә зур өмет уянып, баланы авылына алып кайтып китте. Мөхәммәдне кабул иткән гаиләнең хәлләре алга киткәч: «Ятим баланың аягы җиңел булды, бәрәкәтле бала икән», — диделәр. Биш яшенә кадәр сөт анасы Хәлимә кулында тәрбияләнде. Хәлимә Мөхәммәд белән бергә Әбү Суфьян ибн Харисны да имезде. Шуның өчен алар сөт кардәшләр. Хәлимәнең Габдулла исемле улы, Әнисә вә Җүзәмә исемле ике кызы бар иде.

Пәйгамбәребезнең әнисе Әминә һәр ел саен, Мәдинәгә барып, сөекле ире Габдулланың каберен зиярәт кыла һәм иренең туганнарын күреп китә иде. Мөхәммәд галәйһиссәламгә җиде яшь булгач, атасының каберен зиярәт кылу вә атасының якыннарын күрсәтү нияте илә, Әминә улын да Мәдинәгә алып барды. Яннарында Үммү Әймән дә бар иде. Мәдинәдән кире Мәккәгә кайтышлый Әбвә дигән бер авылда Әминә хасталанып вафат булды һәм шунда күмелде. Шулай итеп, Мөхәммәд галәйһиссәлам җиде яшендә тулы ятим булып калды. Мөхәммәд галәйһиссәламне бабасы Габделмоталлиб үз тәрбиясенә алды. Габделмоталлиб Мөхәммәдне бик ярата, киләчәктә аның бөек бер зат булачагына ышана, шуның өчен аны тәрбияләүгә зур игътибар бирде. Габделмоталлибның үзенең дә ун улы һәм алты кызы бар. Мөхәммәд галәйһиссәлам бабасы өендә ятимлек ачысын күрмичә үсә. Ләкин, күп тә үтми, бабасы Габделмоталлиб та вафат булды. Габделмоталлибның васыяте буенча, Мөхәммәд атасы Габдулланың бертуганы Әбү Талиб тәрбиясенә бирелде. Әбү Талиб акыллы, шәфкатьле вә мәрхәмәтле бер зат иде. Ул Мәккә халкы алдында зур хөрмәткә ия, Мөхәммәдне үз балаларын-

нан да артык сөя, аңа шәфкать, мәрхәмәт күзе белән карый.

Курайш гарәпләре һәрвакыт кәрван белән мал алып Шамга баралар, аннан Шам әйберләрен алып кайтып, Гарәбстанга тараталар иде. Бу турыда Коръән Кәримнең «Курайш» сүрәсе иңдерелгән. Әбү Талиб, сәүдәгәр булу сәбәпле, Шамга бик еш бара иде.

Әбү Талиб Шамга кәрван белән сәүдә сәфәренә әзерләнгәндә, Мөхәммәд аннан аерыласы килмичә елагач, аны да үзе белән алды. Ул вакытта Мөхәммәдкә 12 яшь иде. Бик уңышлы сәүдә итеп, кайтышлый кәрван Бусра шәһәре янына җиткәндә, бер йортта гыйбадәт белән мәшгуль булган Бәхира исемле раһиб (монах) алар каршына чыкты, өенә алып кереп кунак итте вә әйтте: «И, Әбү Талиб! Безнең Тәүрат вә Инҗил китапларыбызда соңгы пәйгамбәр турында язылган сыйфатлар, ошбу синең белән килгән Мөхәммәд (Әхмәд)кә туры килә, Мөхәммәд белән тиз вакыт иленә кайт, аны яһүдиләрдән сакла! Әгәр алар аны күреп танысалар, аңа һәртөрле зыян салырлар. Синең туганыңның улын бөек эшләр көтә, аны сакла!» — диде. Әбү Талиб раһибның сүзләрен гаҗәпләнеп тыңлады. Үзенең сәүдә эшләрен юлдашларына тапшырып, ул Мөхәммәд белән Мәккәгә кайтып китте.

Мөхәммәд галәйһиссәламнең тышкы кыяфәте матур, холкы гүзәл, иптәшләре арасында намуслылыгы вә гаделлеге белән аерылып тора. Аны барысы да ярата һәм аның «Мөхәммәд Әмин», ягъни «ышанычлы, тугры Мөхәммәд» дигән кушаматы да була. Курайшләр һәм башка кабиләләр Кәгъбәнең диварларын яңадан төзегәч, гарәпләр өчен аерым әһәмияткә ия булган Хәҗәре әсвад, ягъни Кара ташны Кәгъбәгә кем куя дигәч, алар арасында кызу бәхәс туа. Шуннан соң бер олуг вә дәрәҗәле Вәлид бин Мугыйрә әйтә: «Безнең арабызда яшь булса да Мөхәммәд Әмин исемен йөртүче кардәшебез бар, аның фикерен ишетик», — ди. Мөхәммәд галәйһиссәлам, бераз уйлап торгач, өстендәге озын чапанын җиргә салып, аның өстенә Кара ташны куя. Кабилә башлыкларына шуның кырыеннан тотып, Кәгъбәтулланың билгеләнгән урынына кадәр күтәреп килергә куша, аннары Хәҗәре әсвадны үз кулы белән урынына урнаштыра. Шулай итеп Мөхәммәд галәйһиссәлам кабиләләр арасындагы бәрелешне булдырмый кала.

Мөхәммәд галәйһиссәлам егерме биш яшендә Мәккә шәһәренең бай сәүдәгәре Хәдичә бин Хуилиднең малы белән Шамга янә сәфәр кыла. Мөхәммәд галәйһиссәлам бу сәфәрдән зур табыш белән кайта. Сәүдәгә катнашканнар Хәдичәгә Мөхәммәдне мактап сөйлиләр.

Хәдичә Курайш кабиләсенең кырык яшьләрендәге бай тол хатыны иде. Мөхәммәд галәйһиссәлам бу кабиләнең иң ышанычлы вә тугры бер заты булганга, Хәдичә аңа кияүгә чыгу ниятен белдереп, Нәфисә исемле хатын аркылы сүз сала. Мөхәммәд галәйһиссәлам дә акыллы, зур абруйлы бу хатынның үтенечен кире какмыйча, үзенең якыннары аркылы Хәдичәне хатынлыкка сорады. Шулай итеп, Хәдичә Мөхәммәд галәйһиссәлам белән никахлашып бергә тора башладылар.

Мөхәммәд галәйһиссәлам уку-язуны белмәде, мөшрикләрнең дини бәйрәмнәренә бармады, сыннарга гыйбадәт кылмады. Ул вакыттагы гарәпләрне чолгап алган зина, аракы эчү һәм шуңа охшаш пычрак нәрсәләрдән ерак торды.

Мөхәммәд галәйһиссәламгә вәхи әүвәл төш күрү белән башланды. Аның күргән төшләре барысы да ачык һәм дөрескә чыга иде. Кырык яшьләренә җиткәндә, ялгызлыкны ихтыяр итеп, Мәккә янындагы Хира тавына бара иде. Ул анда, тау куышлыгына кереп, ун-унбиш көн тора иде. Азыгы бетсә, хатыны янына кайтып алып килә иде.

Бервакыт рамазан аенда кич белән Мөхәммәд галәйһиссәлам, Хира тавында гыйбадәт белән мәшгуль булганда, бер тавыш ишетте. Ул тавыш иясе Җәбраил фәрештә иде. Ул Мөхәммәд галәйһиссәламгә үзенең Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелүен әйтте һәм аны пәйгамбәрлек белән сөендерде. Соңра Мөхәммәд галәйһиссәламгә: «Укы!» — диде. Моңа Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Мин укый белмим», — дип җавап бирде. Җәбраил галәйһиссәлам: «Укы!» — дип өч мәртәбә кабатлады. Шуннан соң Җәбраил галәйһиссәлам Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламгә «әл-Галәкъ» сүрәсенең биш аяти кәримәсен өйрәтте.

*«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. 1. Бөтен нәрсәне юктан бар кылучы Раббың исеме белән укы! 2. Ул кешене оешкан каннан барлыкка китерде. 3. Укы! Синең Раббың — бик хөрмәтле вә юмарттыр. 4. Ул — Аллаһ, каләм белән язуны өйрәтте. 5. Кешегә белмәгән нәрсәләрен өйрәтте».*

Күргәнебезчә, Коръән Кәримнең беренче аяте «Укы!» дип башлана.

Аллаһы Тәгаләнең Рәсүлебезгә һәм бөтен мөселманнарга иң беренче әмере шул булды. Коръәннең беренче аятьләре милади белән 610 нчы елның рамазан аеның Кадер кичендә иңдерелде. Моның турында «әл-Кадер» сүрәсендә әйтелә.

*«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Дөреслектә, Без Коръәнне Кадер кичендә иңдердек (1). Сиңа Кадер киченең шәрәфәтен вә аның хикмәтен нәрсә белдерде? (2). Кадер киче мең айдан да хәерлерәктер (3). Ул Кадер кичендә киләсе елга хәтле булачак эшләр хөкем ителер, ягъни тумак, үлмәк, ризык вә дөньядагы башка булачак вакыйгалар тәгаен ителер (4). Кадер кичендә намаз, Коръән укып ураза тоткан мөэминнәргә фәрештәләр Аллаһыдан сәлам укырлар. Кадер киченең дәвамы кояш баеганнан башлап таң атканга чаклыдыр (5)».*

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам курыккан хәлдә өенә кайтты һәм Хәдичәгә булган вакыйганы сөйләде. Аңа каршы Хәдичә: «Син күркәм холыклар иясе, Аллаһы Тәгалә синең янга җен-пәриләрне җибәрмәс. Сиңа күренгән зат — чыннан да Аллаһы Тәгаләнең фәрештәседер. Син — шөбһәсез пәйгамбәр!» — диде.

Мөхәммәд галәйһиссәлам бераз тынычлангач, ул аны абзыйсы Вәрака ибн Нәүфәл янына алып барды. Вәрака элек нәсара динен кабул иткән бер карт иде. Ул Инҗил һәм Тәүрат китапларын укый иде. Алардан Мөхәммәд галәйһиссәламнең килүе турында хәбәрдар иде. Вәрака Инҗилне гыйбрани язуы белән гарәпчәгә тәрҗемә итә иде. Мөхәммәд галәйһиссәлам аңа булган вакыйганы сөйләгәч, Вәрака һич икеләнмичә: «Син ахырзаман пәйгамбәре булачаксың, сиңа күренгән зат — ул Муса галәйһиссәламгә дә күренгән һәм аңа Аллаһы Тәгаләдән вәхи китергән Җәбраил галәйһиссәламдер. Син кавемеңне тәүхидкә, ягъни бер Аллаһыга ышануга өндәргә тиешсең. Син потлар вә сыннарга табынудан туктарга өндәп вәгазьләгәндә, синең дусларың, якыннарың сиңа дошман булачаклар, сине мыскыл вә җәфа кылачаклар, шуннан соң сине туган илеңнән сөрәчәкләр. Мин яшь кеше булсам, әлбәттә, сиңа ярдәм итәр идем, ләкин минем күп яшисем калмады инде», — дип, аны пәйгамбәрлеге белән котлады. Бу вакыйгадан соң озак та үтмәде, Вәрака вафат булды.

Җәбраил галәйһиссәлам «әл-Мүдәссир» сүрәсенең башындагы 7 аятен иңдерде.

*«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. И, киеме белән бөркәнгән зат! (1). Тор, кешеләрне Аллаһы Тәгаләнең газабы белән куркыт! (2). Раббыңны зурлап, тәкбир әйт! (3). Вә киемеңне нәҗестән пакь кыл (4). Аллаһының ачуына илтә торган эшләрне ташла (5). Кешеләргә бернәрсә бирсәң, аннан күбрәк өмет итеп бирмә (6). Вә Раббың ризалыгы өчен, кяферләрнең дошманлыгына сабыр бул, чыда!(7)».* (Ислам дине галимнәре фикеренчә, бу — икенче булып иңгән сүрә).

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам дәгъвәткә, ягъни Исламга өндәүгә саклык белән вә яшерен рәвештә кереште. Иң әүвәл үз туганнарын һәм сүзе үтәрдәй кешеләрне вәгазьли башлады. Гарәпләрдән иң беренче динне кабул итүчеләр хәзрәти Хәдичә, Гали бин Әбү Талиб, Зәид бин Хәрис һәм аның хатыны Үммү Әймән иделәр.

Моннан соң Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам үзенең иң якын булган дусты Әбү Бәкер бин Кәһафне дәгъвәт кылды. Чөнки Әбү Бәкер Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам белән күп вакытлардан бирле дус булып, аңардан һичбер ялган сүз ишетмәгән, аның холкын иң югары дәрәҗә дип белгәнлектән, Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам дәгъвәт кыла башлагач та, аңа иман китерде. Әбү Бәкер күркәм йөзле, гүзәл холыклы, мөлаем табигатьле олы яшьтәге, Курайшләр арасында бик күренекле бер зат иде. Мондый абруйлы бер затның һич шикләнмичә шунда ук иман китерүе Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламне бик шатландырды, дәгъвәт итүгә өметен арттырды. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең вафатына кадәр Әбү Бәкер аңа ышанычлы ярдәмче булды. Әбү Бәкер тырышлыгы аркасында Исламга кергән кешеләр шулардыр: 1) Госман бин Гаффән, 2) Зөбәер бин Гәввам, 3) Габдрахман бин Гауф, 4) Сәгъд бин Әбү Вәкъкас, 5) Талха бин Губәйдулла.

Ошбу юл белән Мәккә эчендә Ислам дине әкрен-әкрен тарала иде. Ислам динен кабул итүчеләр гыйбадәтләрен яшерен сурәттә кылалар, мөшрикләрнең мөмкин кадәр ачуларын китермәскә тырышалар, Ислам дине турында алар белән сөйләшмиләр иде. Пәйгамбәрлекнең дүртенче елы башларына кадәр дәгъвәт гел яшерен сурәттә дәвам итте. Исламга

кергән кешеләрнең саны утызга җитте. Дин вә шәригать хөкемнәрен өйрәнү өчен, алар Әл-Әркам дигән сәхабә өендә җыелалар иде. Дүртенче елда Аллаһы Тәгалә тарафыннан Мөхәммәд галәйһиссәламгә «әл-Хиҗер» сүрәсенең 94 нче аяти кәримәсе иңдерелде.

*«Инде хәзер Ислам динен ачык изһар кыл! Кешеләрне иманга вә Коръән белән гамәл кылырга ачыктан-ачык өндә! Һичкемнән курыкма! Вә мөшрикләрдән аерыл, алар белән булышып, вакытыңны әрәм итмә! (94)».*

Шушы аять иңгәч, Пәйгамбәребез кешеләрне ачык рәвештә Ислам диненә өнди башлады. Иң беренче үз туганнарын вә якыннарыннан булган кырыклап кешене мәҗлескә җыйды һәм аларга шундый сүзләр сөйләде: «Мин бөтен кешегә ялган сөйләсәм дә, сезгә ялган сөйләмәс идем, бөтен кешене алдасам да, сезне алдамас идем. Аллаһ берлә ант итеп әйтәмен ки, мин галәмдәге барлык халыкка, шулай ук сезгә дә Хак Тәгаләнең Пәйгамбәре итеп җибәрелдем. Сез йоклаган кебек үләчәксез, уянган кебек җир астыннан кубарылачаксыз, кылган эшләрегездән хисап кылыначаксыз, яхшылыкка — яхшылык, начарлыкка начарлык белән җәза кылыначаксыз. Сезнең барачак җирегез — я җәннәт, яки җәһәннәм булачак. И, Габделмоталлиб балалары! Кавемемә мин китергән нәрсәдән дә артык берәр нәрсә китергән кешене белмим, мин сезгә дөнья вә ахирәт сәгадәте китердем», — диде. Мәҗлестәге халык, Әбү Ләһәбтән башкалары, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламгә каршы килмәделәр. Әбү Ләһәб якыннарына: «Мөхәммәдне бу эшеннән тыярга кирәк, әгәр тиз арада чарасына керешелмәсә, гарәпләр арасында сугышлар килеп чыгачак», — диде. Моңа каршы Әбү Талиб Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вәссәламне үзе үлгәнче яклаячагын нык итеп, кистереп әйтте.

Шуннан соң Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам гомум Курайш гарәпләрен һәм башка кавемнәрне дәгъвәт итәргә керешә. Беркөн Сафа тавына менеп, Мәккә халкын вәгазь тыңларга чакыра башлады. Халык җыелып беткәч, ул аларга: «Әгәр дә мин сезгә бу тау артында атлы гаскәр бар, Мәккәгә һөҗүм итәчәк дип хәбәр бирсәм, сүземә ышаныр идегезме?» — дип сорады. Мәккә гарәпләре: «Әлбәттә, ышаныр идек, чөнки синнән бу көнгә чаклы ялган сүз ишеткәне-

без юк иде», — дип җавап бирделәр. Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам дәвам итте: «Алай булса, мин сезне сыннарга вә потларга табынуыгыздан тыям, ялгыз булган Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылырга чакырам, әгәр шул батыйль динегездә калуны дәвам итсәгез, сезне каты газап көтәчәк», — диде. Анда җыелган халык Мөхәммәд юләрләнгән булырга кирәк, югыйсә мондый нәрсәләр сөйләмәс иде дигән кебек сүзләр әйтеп таралдылар. Халык арасында Әбү Ләһәб тә бар иде, ул Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламне кимсетә торган сүзләр әйтте.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам дәгъвәт иткән дин, акылга муафыйк, кабул итү өчен бик җиңел бер дин булуына карамастан, ата-бабаларының юлыннан барган надан гарәпләргә бик ят булып күренде. Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәламне һәм иман китергән мөселманнарны, адашкан кешеләр дип, төрлечә мәсхәрә кыла башладылар. Мөшрикләр ничек тә аны дәгъвәтеннән туктатырга чара эзли башладылар. Ләкин Мөхәммәд галәйһиссәламне Мәккә шәһәрендә мөхтәрәм булган Әбү Талиб һәм Әбү Бәкер яклый иделәр.

Мәккә мөшрикләренең Рәсүлебез саллаллаһу галәйһи вәссәламгә һәм аның сәхабәләренә кылган явызлыклары биниһая күп, язып бетерерлек түгел иде. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламгә бигрәк тә дошман, гел явызлык кылучылар: Әбү Җәһил бин Һишам, Әбү Ләһәб, аның хатыны Умми Җәмил бинт Хәрб, Әбү Суфиан, Гукбә бин Әбү Мугайт, Вәлид бин Мугирә, Әсад бин Габд Ягус, Әл-Әсвад бин Мәттәлиб, Гас бин Ваил, Назр бин Харис кебек мөшрикләр иде. Алар турында «әл-Хиҗер» сүрәсенең 95–96 нчы аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә: *«Сине мәсхәрә итә торган кешеләрне һәлак итәргә вә сине сакларга Без җитәбез! (95). Алар (мөшрикләр) Аллаһы Тәгаләдән башка тагын берәр кемне яки берәр нәрсәне Аллаһы урынына тоталар, алар тиздән белерләр бу эшләрнең һәлакәтлек икәнлеген (96)».*

Боларның күбесе Бәдер сугышында үтерелделәр, бәгъзеләре төрле авыруларга дучар булып үлделәр. Бигрәк тә алар яклаучысы яки куәтле якыннары булмаган сәхабәләрне төрлечә газапладылар. Ләкин хаклыкны бер тапкан кеше аңардан кире кайтырмы? Сәхабәләрнең Исламга керүләре дөнья малына

яки дөнья дәрәҗәсенә ирешү өчен түгел, киресенчә, ахирәт бәхетенә өмет иткәннәре өчен иде. Мөшрикләрнең аларга золым итүләре аларны Ислам диненнән кире кайтара алмады, аларга килгән газапларга чыдап, алар соңра өстен булдылар. Хак дин өчен җәфа вә газап чигеп, бичара хәлләрендә яшәгәннәргә Аллаһы Тәгаләнең ярдәме вә рәхмәте килеп, аларның хәлифәләр, имамнар вә варислар булуы турында «әл-Касас» сүрәсенең 5 нче аяти кәримәсендә әйтелә.

Ислам динен кабул иткән өчен газап күргән сәхабәләр: Билал бин Рабах, Билалның әнисе Гамир бин Фухайра, Әбу Фукайһә, Зәннизә, Умми Губәис, Хәббәб бин Әрат. Дин өчен газап күргән кешеләр, әлбәттә, болар гына түгел иде. Алар күргән газаплар гаять дәрәҗәдә каты иде. Бу мәсьәлә турында «әл-Ганкәбут» сүрәсенең 2–3 нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә: *«Әллә кешеләр иман китердек дигәннәреннән соң төрле авырлыклар белән Аллаһы Тәгалә тарафыннан имтихан ителмәбез, дип уйлыйлармы? (2). Дөреслектә, болардан элек тә төрле сыйныф кешеләрен бәла-каза һәм авыр мәшәкатьләр белән сынап карадык, әлбәттә, Хак Тәгалә белер кемнең иманы хак һәм кемнең иманы ялган икәнлеген! (3)».*

Хәмзә һәм Гомәр ибн Хаттаб кеби баһадирларның Ислам динен кабул итүләре мөшрикләрне бераз уйланырга мәҗбүр итте. Алар үзләренең җәбер вә золымнарын арттырдылар. Гарәбстанның күршесе булган Хәбәштә (Эфиопия) гадел падишаһ булганын ишетеп, җәберләнгән бәгъзе сәхабәләр шунда һиҗрәт иттеләр. Болар: Госман бин Гаффән, аның хатыны Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең кызы Рокыя, Әбү Хузәйфә бин Гутбә, аның хатыны Сәхлә бинт Сүһәил, Әбү Сәлимә, аның хатыны Үмми Сәламә, Гамир бин Рабига, аның хатыны Ләйлә бинт Әби Һәсәймә, Зөбәир бин Гәввам, Габдрахман ибн Гауф, Госман ибн Мәзгун, Әбү Сәбураһ, Хәтиб ибн Гамр, Сүһәил ибн Вәһаб, Габдулла ибн Мәсгуд, Мүсгаб ибн Гумәйр. Өч ай анда торганнан соң, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламне вә сәхабәләрне җәберләү туктаган дигән хәбәр ишетеп, Мәккәгә кире кайттылар.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламгә һәрдаим ярдәм кулын сузучы Әбү Талиб вафат булды, аның вафатыннан соң озак та үтмәде, Хәдичә радыйаллаһу ганһә вафат булды. Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам, ике таянычын югалткач, бик каты кайгырды.

## Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламнең мигъраҗ кыйссасы

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә «Бәни Исраил» сүрәсенең 1 нче аятендә әйтә:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ❀ سُبْحٰنَ الَّذِىٓ اَسْرٰى بِعَبْدِهٖ لَيْلًا مِنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ اِلَى الْمَسْجِدِ الْاَقْصَا الَّذِى بٰرَكْنَا حَوْلَهٗ لِنُرِيَهٗ مِنْ اٰيٰتِنَا اِنَّهٗ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ ❀

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Сүбхәәнәл-ләзии әсраа бигәбдиһии ләйәләм-минәл мәсҗиидил хәраами иләл мәсҗидил әксалләзии бәәракнәә хәүләһүү линүрийәһүү мин әәйәәтинә. Иннәһүү һүвәс-сәмиигүл бәсыййр (1)».

Мәгънәсе: *«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Үзенең колы Мөхәммәд галәйһиссәламне бер кичтә Мәккә шәһәрендәге әл-Хәрам мәсҗиденнән Коддус шәһәрендәге әл-Әкъса мәсҗиденә йөртеп кайтаручы Аллаһы Тәгаләне һәр кимчелектән пакь диеп белегез! (1)».*

Аллаһы Тәгалә Коддус шәһәре тирәсен дин вә дөнья бәрәкәте белән нигъмәт кылды. Әл-Әкъса мәсҗиде вәхи иңә һәм Муса пәйгамбәр заманыннан бирле пәйгамбәрләрнең гыйбадәт кыла торган урыны булды. Әл-Әкъса мәсҗиде агымсулар, җимешле агачлар белән чорналган гүзәл бер як. Ошбу гаҗәеп галәмәтләребезне күрсәтү өчен Мөхәммәд галәйһиссәламне шулай кодрәтебез илә йөреттек, әлбәттә, Аллаһы Газзә вә Җәллә һәрнәрсәне ишетүче, белүче вә күрүчедер.

«Нәзһәтүл-мәҗәлис» китабында китерелә: Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам әйтте: «Бер кичне Өмме Һәни өендә ята идем. Берәү килеп уятты. Күземне ачып карасам, дустым Җәбраил галәйһиссәлам икән, ул: «Әй, Рәсүлулла, тор, бүген йокы киче түгел, вәсилә киче, Хак Тәгалә сиңа сәлам әйтте һәм сине Үзенең хозурына чакырды. Дустым Мөхәммәдкә серем бар, Мине вә Минем гаҗәеп галәмәтләремне күрсен, күңеле ачылсын, кайгылары чәчелсен, йә, Рәсүлулла, әзер бул», — диде».

Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам: «Хезмәтеңә әзермен», дип тордым, тәһарәт алдым. Җәбраил галәйһиссәлам җитәкләгән бурак ишәктән зуррак, йөзе адәм йөзенә охшаган, күзләре зур, акыллы, колаклары нечкә, ялтыравыклы,

тәне нурлы. Ак энҗе белән алтын катнашкан йөгән белән йөгәнләнгән иде. Җәбраил галәйһиссәлам, бер кулы белән буракны тотып: «Әй, Әбү Талиб ятиме, бу кич синең кичең, барча дәүләтләр синең дәүләтең, җирдәге хәзинәләр синең хәзинәләрең», — диде. Мин буракка менеп атландым. Буракның күзе кая төшсә, аягын шул җиргә баса иде. Тиз арада Бәйтелмөкаддәскә барып җиттек. Әл-Әкъса мәсҗиденә кердем. Барча пәйгамбәрләрнең җаннары минем каршыма килделәр. Азан әйтелде вә камәт төшерелде, Җәбраил галәйһиссәлам: «Әй, дустым Мөхәммәд, имам бул, намазда имам булу сиңа тиеш», — диде. Ике рәкәгать намаз укыдым. Барча пәйгамбәрләрнең җаннары миңа оеп укыды.

Намаз тәмамланганнан соң, берәү торып: «Барча мактауларыбыз Аллаһы Тәгаләгәдер. Ул шундый Аллаһыдыр, мине барча мәхлуклар арасында саф вә нурлы кылды. Җир йөзендә хәлифә итте, фәрештәләрне миңа сәҗдә кылдырды, хатыным Хәваны хәрамнан саклаучылардан итте, янә оҗмахны безгә рөхсәт итте. Җәннәтнең саф сулы чишмәләреннән, аның балкып торган сарайларыннан, барча нигъмәтләреннән йөз чөергән дошманым Иблис мәлгуньне рәхмәтеннән куып, мөртәт кылды», — диде. Моның Адәм пәйгамбәр икәнлеген белдем.

Янә берәү торып: «Барча хәмед вә сәналарыбыз Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә булса иде. Мине фетнәдән коткарды, кавемемне мең ел иманга өндәдем, кичен вә көндезен дәгъвәт кылдым. Ул дәгъвәтем иманнарын арттырмыйча, иманнан качуны гына арттырды. Алар миңа ышанмадылар һәм Аллаһы Тәгаләгә инанмадылар. Мин соңыннан: «И, Раббым, җир йөзендә йорт тотучы кяферләрне калдырма», — дип дога кылдым. Аллаһы Тәгалә догамны кабул итте, кавемем бәрәкәтсез, ахирәткә гарык булып, туфаннан һәлак булдылар», — диде. Моның Нух пәйгамбәр икәнен белдем.

Аннан соң янә берәү торып: «Барча хәмед Аллаһы Тәгаләгә генә хас. Ул Аллаһы Тәгалә мине үзенә дус итеп тотты, кирәк вакытта комнарны миңа он итте, Нәмруд утын миңа сәламәт булырдай салкын итте. Хатыным баладан киселгәч, бала табу өчен сихәт бирде. Янә Исмәгыйль вә Исхак исемле ике балам булып, пәйгамбәр булулары белән сөенеч бирде. Дошманым Нәмрудны ләгънәт кылып һәлак итте», — диде. Бу кешенең атам Ибраһим пәйгамбәр икәнен белдем.

Янә бер озын мәһабәт кеше торып: «Барча хәмед вә мактаулар тик Аллаһы Тәгаләгә генә хастыр. Ул Аллаһы Тәгалә минем белән сөйләште, аерым-аерым тугыз гаҗәп галәмәтләр бирде. Зөбәрҗәт таш такталарында раушан булучы аятьләр язды, кавемемнең аягын суга чыланмаслык итеп дәрьядан үткәрде, каты таштан унике чишмә чыгарды. Кавемем хозурына ризыклар иңдерде. Явыз фиргавенне суга батырды», — диде. Моның Муса пәйгамбәр икәнен белдем.

Янә берәү торды, кызыл йөзле, кара чәчле, күк күзле иде. Ул: «Барча хәмед вә мактаулар тик Аллаһы Тәгаләгә генә хастыр. Хак Сөбханә вә Тәгалә миңа Зәбур китабын бирде, кирәк вакытта, тимерне камыр кебек йомшак итте, миңа кошларны вә тауларны буйсындырды. Дошманым Җәлутны һәлак итү өчен ярдәм бирде», — диде. Бу кешенең Дауд пәйгамбәр икәнен белдем.

Янә берәү торып: «Барча хәмед вә мактаулар бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә хастыр. Ул Аллаһы Тәгалә минем өчен җилне, адәмнәрне, җен вә шайтаннарны буйсындырды, кошлар телен өйрәтте, олуг патшалык бирде», — диде. Моның Сөләйман пәйгамбәр икәнен белдем.

Янә берәү торды: «Барча хәмед вә мактаулар Аллаһы Тәгаләгә булсын. Минем догам сәбәпле сукырлар сәламәтләнде, ала тәнлеләр шифа тапты, янә Хак Тәгаләнең рөхсәте белән үлеләр терелде», — диде. Бу Гайсә пәйгамбәр икәнен белдем. Бөтен пәйгамбәрләр үзләрен белдергәч, торып басып: «Барча хәмед вә мактаулар Аллаһы Тәгаләгә генә хастыр. Барча галәмнәрне, гареш, көрси, пәрдәләрне бар кылуда, минем исемемне Үз исеменә якын кылучыга барча мактаулар булса иде. Янә исемемне оҗмах ишегенә, оҗмах яфракларына язучы Раббыма барча хәмед вә мактаулар булса иде. Һәр көнне хөтбәләрдә, азанда вә камәттә минем исемемне Үзенең исеменнән соң куючыга олуг сәна вә догаларым булсын иде. Күкрәгемне раушан итүче, хикмәт вә гыйлем илә тутыручыга олуг рәхмәтләрем булса иде. Хөкем кылу өчен Коръән Кәримне бирүче Газзә вә Җәлләгә олуг вә чиксез хәмед-мактаулар булса иде. Әүвәлге вә соңыннан булачак өммәтемнең гөнаһларын кичерүче Җәнабел Хакка барча мактауларым булсын иде. Исемемне әүвәл зикер итте, аннан үземне ахырзаман пәйгамбәре итүчегә өзлексез хәмед-сәналарым булса иде. Җир йөзен минем өммәтемә мәсҗид итүчегә, су булма-

ганда тәяммем белән намаз укырга рөхсәт бирүчегә олуг рәхмәт-сәналарым булса иде. Янә миңа каршылык кылучыларны хур итүчегә, өммәтемнең олугларына гыйлемлек вә мактау, дәрәҗәләр бирүчегә хәмед-сәналарым булса иде. Пәйгамбәрләр догаларын дөньяда кылдылар, әмма минем догам ахирәттә өммәтемә шәфәгать өчен дә мөмкинлек бирүче Раббыма чиксез хәмед-мактауларым булса иде».

Бу сүзләрне ишеткәч, барча пәйгамбәрләр торып бастылар: «Әйе, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәлам, син Аллаһы Тәгалә каршында барыбыздан да өстен булдың», — диделәр.

Моннан соң ике касә китерделәр. Җәбраил галәйһиссәлам: «Боларның икесенең берсеннән эч», — диде. Бер касәдә хәмер, икенчесендә сөт иде, сөт касәсен алып сөтен эчтем. Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Яхшы эшләдең, өммәтең Ислам дине әһеле булыр, әгәр хәмерне эчкән булсаң, барча өммәтең гөнаһлы булып, азгынлыкта булыр иде. Аллаһы Тәгалә дидарын насыйп итәр, өммәтеңне рәхмәтеннән аермас», — диде.

Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәлам әйтте: «Моннан соң Җәбраил галәйһиссәлам кулымнан тотып, Бәйтелмөкаддәснең мөбарәк ташы янына алып барып: «Әй, Исмәгыйль, баскычыңны куй», — диде. Шул вакыт бик күркәм кыяфәтле бер фәрештә бик озын баскыч куйды. Баскычның түбән башы мөбарәк ташта, югары башы күккә ирешкән иде. Баскычның бер як баганасы кызыл якуттан, икенче як баганасы яшел зөбәрҗәттән, энҗеләр белән зиннәтләнгән иде. Ул баскычның басмалары кайберләре алтыннан, кайберләре көмештән, кайберләре зөбәрҗәттән, кайберләре якуттан иде. Җәбраил галәйһиссәлам: «Бу баскычтан пәйгамбәрләрнең җаннары күккә менәрләр, бу баскычны үлгәндә һәрбер мөэмин-мөселман кеше күрер, шуның өчен алар үлгәндә, күзләрен ала алмыйча, күккә карап җан бирерләр», — диде.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам бурак өстендә, Җәбраил галәйһиссәлам алар яныннан очып, соңгы баскычка җиттеләр. Җәбраил галәйһиссәлам: «Ишекне ач, и, Исмәгыйль», — диде. Әүвәлге күкнең вәкиле Исмәгыйль фәрештә ишекне ачты. Бу ишек Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең махсус ишеге иде. Ишекне ачкач, Исмәгыйль фәрештә: «Синең белән кем бар?» — диде. Җәбраил галәйһиссәлам: «Пәйгамбәрләрнең соңгысы, Мөхәммәд Мостафа

саллаллаһу галәйһи вәссәлам, галәмнәре Раббысының яратканы», — диде. Исмәгыйль фәрештә: «Хуш килдең, йә, Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам», — диде. Ишектән кергәч, атабыз Адәм галәйһиссәламне күрдем, каршысына барып сәлам бирдем. Ул: «Үәгаләйкүмүс-сәлам, әй изге улым, ахырзаман пәйгамбәре», — диде. Шул вакыт Адәм галәйһиссәламнең уң ягында бер ишек, сул ягында янә бер ишек күрдем. Адәм галәйһиссәлам уң ягына карап, шатланып көлә, сул ягына карап, кайгырып елый иде. Җәбраил галәйһиссәламнән моның нәрсәгә ишарә булуы хакында сорадым. «Уң ягында оҗмах ишеге, аңа караса, нәселеннән адәмнәрнең урыны булачагына шатлана, сул ягында тәмуг ишеге, аңа карап, нәселеннән керәчәк адәмнәргә шәфкать йөзеннән кайгырып елый», — диде.

Әүвәлге күктә ул шулкадәр фәрештәләр күрде ки, хисабын Аллаһы Тәгалә генә белә. Тәсбихләре: «Сүбехәнә зил мүлки үәлмәләкүт», җир йөзендә берәү бу тәсбихне әйтсә, Хак Сөбханә вә Тәгалә шул фәрештәләргә биргән савапны бирер, диелә.

Моннан соң һавадан биш йөз еллык юлны үтеп, икенче кат күккә җиттек. Җәбраил галәйһиссәлам: «И, Кыйәил, ишекне ач», — диде. «Синең белән кем бар?» — дип сорады. «Ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһиссәлам», — диде. Кыйәил фәрештә: «Хуш килдегез», — дип ишекне ачты. Бүлмәдә бик матур ике урындыкта, бик күркәм ике егетне күрдем: «Йә, Җәбраил, болар кемнәр?» — дидем. «Гайсә белән Яхъя галәйһиссәламнәр», — диде. Барып сәлам бирдем, сәламне кайтарып: «Сиңа да сәлам, йә, изге пәйгамбәр», — диделәр.

Моннан соң өченче кат күккә җиттек. Бередә Йосыф пәйгамбәр белән күрештек. Аннан соң дүртенче кат күккә җиттек. Утыз яшьләрендәге Идрис пәйгамбәр белән күрештек. Аннан соң бишенче кат күккә мендек. Утыз ике яшьләрендәге Һарун пәйгамбәр белән күрештек. Ул Хак Тәгаләнең хөкемен күңеленнән ниятли иде. Аннан соң алтынчы кат күккә мендек, биредә Муса пәйгамбәр белән күрештек. Моннан соң җиденче кат күккә мендек, анда үземә охшаган бик күркәм бер картны күрдем: «Әй, Җәбраил, бу кем?» — дидем. «Атаң Ибраһим», — диде. Сәлам бирдем. Ул: «Хуш килдең, изге улым, изге пәйгамбәр, өммәтеңә миннән сәлам әйт», — диде.

Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәлам бу җиде кат күктә шулкадәр күп фәрештәләр күрде ки, ләкин бер фәрештәнең

дә бер-берсенә охшамаганлыкларына карап бик гаҗәпсенде, Аллаһы Тәгаләнең хикмәтенә шөкрана кылды. Һәр күкнең үз исеме бар: беренче кат күк — Рәкыйга, икенче кат күк — Бәркыйга, өченче кат күк — Кыйдум, дүртенче кат күк — Мәгүн, бишенче кат күк — Әркилүн, алтынчы кат күк — Руткә, җиденче кат күк — Рафга дип атала.

Җиденче катта гыйбадәт кылучы фәрештәләр: «Хуш килдең, әй, Мөхәммәд, син бу дәрәҗәгә лаеклы, «Ләә иләәһә илләлааһү Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ», потларны җимерүче, Аллаһы Тәгаләне берләүче», — дип кычкырып тәбрикләделәр.

Моннан соң бер фәрештә күрдем, аның белән җитмеш мең фәрештә бар иде: «Хуш килдең, Аллаһы Тәгаләнең якыны, изге пәйгамбәр. Син бирегә менгәч, барча җир вә күкләр яктырды. Бүген Аллаһы Тәгалә сине хөрмәтләр, теләгәнеңне бирер», — диде. «Әй, Җәбраил, бу кайсы фәрештә?» — дидем. «Раэсүлһүдә исемле фәрештә», — диде.

Моннан соң сидрәтелмөнтәһага җиттек. Сидрә — ул бер агачтыр, андагы фәрештәләр: «Без сидрәтелмөнтәһада гыйбадәт кылучылар, Аллаһы Тәгалә барча кимчелекләрдән пакь», — дип тәсбих әйтәләр. Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Сидрәтелмөнтәһа җиденче кат күктән югары, аннан түбән нәрсәләр сидрәтелмөнтәһадан уза алмаслар, сидрәтелмөнтәһадан югары нәрсәләр түбән төшмәсләр, шуның өчен мөнтәһа диләр. Мөнтәһа — ирешүче, туктатучы мәгънәсендә йөри».

Рәсүлебез саллаллаһу галәйһи вәссәлам әйтте: «Сидрәтелмөнтәһага ирешкәннән соң Җәбраил галәйһиссәлам шунда калды, чөнки аңа да моннан узарга рөхсәт юк иде. Мин Аллаһы Тәгаләнең гаҗәеп сәнгатьләрен күреп, Хак Сөбханә вә Тәгаләне күрергә теләдем, күңелем аңа ашкынды. Шулчакта шундый бер халәткә кердем, ул халәтне сүз белән сыйфатлау мөмкин түгел. Мин алтыннан булган пәрдәгә килеп җиттем, тәкбир әйтеп пәрдәне тибрәттем, миңа алга барырга рөхсәт булды, алда янә энҗе пәрдә күренде, тәкбир әйтеп, бу пәрдәне дә үттем, күз ачып йомганчы ахыр пәрдәгә кадәр шул рәвешле бардым. Һәрбер пәрдә арасы биш йөз еллык юл иде. Каршымда кояшка охшаган якты нурлы яшел палас күреп күзем камашты. Янә җитмеш мең пәрдә үттем. Аллаһы Тәгалә миңа гарешкә якынаерга рөхсәт бирде. Гарештән авызыма бер тамчы тамды. Андый ләззәтле нәрсәне телем татыганы юк

иде. Аллаһы Тәгалә әүвәлгеләрнең вә ахыргыларның гыйлемен миңа илһам кылды. Телем Хак Тәгаләнең хикмәте вә кодрәте илә ачылды: «Әттәхиятү лилләәһи үәс-саләүәтү үәт-таййибәһ», — дидем. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әссәламү галәйнә үә галә гибәдилләһис-салихин». Җәбраил галәйһиссәлам һәм башка фәрештәләр бу сәламнән хәбәрдар булып: «Әшһәдү әллә иләһә илләллаһу үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһү үә расүлүһү», — диделәр. Моннан соң Аллаһы Тәгалә: «Әй, дустым Мөхәммәд, миңа якын бул», — диде.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам Аллаһы Тәгаләгә хөрмәтле булуда ике җәядән аткан ук микъдары якын булды. Әле моңа кадәр бер пәйгамбәрнең дә бу кадәр якын булганы булмады.

Моннан соң Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй, Мөхәммәд, Мин сине Үземә дус иттем, Ибраһимны хәлилем иттем. Синең белән һәм Муса белән сөйләштем, ләкин сиңа өстенлек бирдем, синең өммәтеңне изге өммәт иттем. Әй, Мөхәммәд, әй, хәбибем, Мин сиңа биргән бүләгемне сакла, шөкер кылучылардан бул», — диде.

Моннан соң Хак Тәгалә хитаб кылды: «Йә, Мөхәммәд, миңа нәрсә алып килдең?» «И, Раббым, ике нәрсә алып килдем, берсе тәгать вә гыйбадәт кимчелеге, икенчесе гөнаһ һәм җәфа күплеге», — дидем. Хак Сөбханә вә Тәгалә: «Тәгать вә гыйбадәт кимчелеген рәхмәтем белән ярлыкадым. Җәфа вә гөнаһ күплеген шәфәгатеңә багышладым, шаять үзең риза булган кадәр итеп рәхмәт кылырмын», — диде.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам әйтте: «Хак Тәгалә минем өчен күп вәгъдәләр иткәннән соң, күп сүзләр сөйләшкәннән соң: «Өммәтеңә кайтып, Минем хөкемнәремне ирештер», — диде. Шул вакыт аягым астындагы палас, мине сидрәтелмөнтәһага төшерде. Алдыма Җәбраил галәйһиссәлам килеп: «Әй, Мөхәммәд, Аллаһы Тәгалә һичбер пәйгамбәргә һәм һичбер фәрештәгә бирмәгән бүләкне сиңа бирде. Күк һәм җир әһеле ирешмәгән урынга ирештерде. Аллаһы Тәгаләнең сиңа биргән мәртәбәләре һәм кәрамәтләре нинди күркәм, шөкер кыл, әй, Мөхәммәд, Аллаһы Тәгалә шөкер кылучыларны сөя», — диде. Мин Аллаһы Тәгаләгә мактау-шөкерләр кылдым. Шуннан соң Җәбраил галәйһиссәлам: «Әй, Мөхәммәд, йөр, оҗмахны вә оҗмахта үзеңә әзерләнгән урыннарны вә нигъмәтләрне күр, шул сәбәпле дөньяда зөһдлегең, ахи-

рәткә кызыгуың артыр», — диде. Оҗмахка бардык, Аллаһы Тәгаләнең рөхсәте белән оҗмахның һәр урынын күрдем. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән дәрәҗәләр күрдем. Бу оҗмах дәрәҗәләренә ирешү өчен, әлбәттә, гыйбадәт кылучылар ихлас күңелдән гыйбадәтләрен арттырсыннар иде.

Моннан соң миңа тәмуг күрсәтелде. Уттан булган зәнҗәр-богауларны күрдем. Биредәге коточкыч җәзаларны сүз белән язып бетерерлек түгел иде. И, Раббым, өммәтемне бу куркыныч тәмугтан Үзең сакла дип, Җәбраил галәйһиссәлам илә алтынчы кат күккә мендек. Аллаһы Тәгаләгә: «Өммәтем илле вакыт намаз укый алмас, җиңеллек бир, дип биш мәртәбә баргач, Хак Тәгалә биш вакыт намазны фарыз кылды. Хак Тәгалә намазны киметкәннән соң әйтте: «Бер вакыт намазга ун вакыт намазның савабын бирермен», — диде.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең мигъраҗда булуы хакында «ән-Нәҗем» сүрәсенең 13–18 нче аятьләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَلَقَدْ رَآهُ نَزْلَةً أُخْرَىٰ ﴿١٣﴾ عِندَ سِدْرَةِ الْمُنتَهَىٰ ﴿١٤﴾ عِندَهَا جَنَّةُ الْمَأْوَىٰ ﴿١٥﴾ إِذْ يَغْشَى
السِّدْرَةَ مَا يَغْشَىٰ ﴿١٦﴾ مَا زَاغَ الْبَصَرُ وَمَا طَغَىٰ ﴿١٧﴾ لَقَدْ رَأَىٰ مِنْ آيَاتِ رَبِّهِ الْكُبْرَىٰ ﴿١٨﴾

«Үә ләкаде раәәһү нәзләтән үхъра (13) гиңдәсидратилмүнтәһә (14) гиңдәһәә җәннәтүл-мәэүә (15). Из йәгъшәссидратә мәә йәгъшә (16). Мәә зәәгал бәсару үә мәә тага (17). Ләкаде раәә мин әәйәәти раббиһил күбра (18).

М ә г ъ н ә с е : *«Тәхкыйк, ул Җәбраилне икенче мәртәбә үз сурәтендә күрде (13). Сидрәтелмөнтәһа агачы янында (14). Мәәва җәннәте шул агач янындадыр (15). Ул агачны күп фәрештәләр каплаган иде (16). Мөхәммәд галәйһиссәламнең күзе шул агачтан һәм фәрештәләрдән читкә авышмады һәм куелган чиктән уңга-сулга үтмәде (17). Тәхкыйк, ул мигъраҗда Раббысының олуг галәмәт вә дәлилләрен күрде (18)».*

Нәрсә ул мигъраҗ? Мигъраҗ дип Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламнең төнлә Мәккәдән әл-Кодескә (Иерусалим), аннан, күккә ашып, җәннәтне күреп, сидрәтелмөнтәһаны кичеп, Аллаһы Тәгаләнең хозурына чыгу мәртәбәсенә лаек булу вакыйгасына әйтәләр. Коръән Кәримдә ул «Исра» дип, хәдисшәрифтә исә «Мигъраҗ» дип исемләнә. «Исра» — «төнге сәяхәт»

дигән сүз, «мигъраҗ» — «күтәрелү, ашу» мәгънәсенә туры килә. Коръән Кәрим мигъраҗ турында «Исра» һәм «Нәҗем» сүрәләрендә кыска һәм серле итеп бәян кыла. «Сәхих Бохари» һәм «Сәхих Мөслим» исемле хәдис китапларында исә, мигъраҗ тәфсилле рәвештә сурәтләнә.

«Нәзһәтүл-мәҗәлис» китабында мигъраҗның төп вакыйгалары һиҗрәттән 19 ай элек, рәҗәбнең 26 нчы көненнән 27 сенә каршы төнлә белән булуы тасвирлана. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам тәкъдир каләмнәренең «сәрирен», ягъни язганда чыгарган тавышларын ишетерлек урынга барып җитә, җәннәт вә җәһәннәмнән хәбәрдар була. Бераздан сидрәтелмөнтәһага кадәр күтәрелә. Гарше әгъләнең (тугызынчы кат күкнең) астында була, җәннәтне һәм күкләрне ихата кыла, күтәрелүе мөмкин булган җирнең чиген белгертә. Җәбраил галәйһиссәлам җиденче каттан югары күтәрелә алмый. Рәсүлуллаһ галәйһиссәлам үзе генә Аллаһы Тәгалә хозурына бара һәм алар арасында «кябе каусәйн», ягъни ике ук очышы кадәр генә ара кала. Шулай итеп, Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вәссәлам Аллаһы Тәгаләгә иң якын кол булу бәхетенә ирешә. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламгә мигъраҗда өч бөек бүләк бирелә:

1. Биш вакыт намаз. Ягъни Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам мигъраҗның гали ләззәтен татыгач, ул бөек форсатның башка бер рәвештә булса да бирелүен Хак Тәгаләдән түбәнчелек белән сорый. Аның бу үтенече кабул ителеп, мөэминнәр өчен Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам кергән ишек мәгълүм бер дәрәҗәдә ачык калдырыла. Хәдистә: «Намаз — мөэминнәрнең мигъраҗы».

2. Аллаһының барлыгын вә берлеген танучыларның, нинди генә гөнаһлары булса да, тәмугта мәңге калмаячаклары вәгъдәсе.

3. «Әмәнәр-Рәсүлү» дип башлана торган «әл-Бәкара» сүрәсенең соңгы өч аяте.

Рәҗәб аеның бу кичәсендә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең төнлә күккә күтәрелеп Аллаһы хозурына баруы, Хак Тәгалә белән сөйләшүе, Аннан әмерләр алып кайтуы бик зур вакыйга. Мигъраҗ — Аллаһы Тәгаләнең бәндәләренә игелекләрен, рәхмәтләрен бүләк иткән кичә. Гыйбадәтләрнең иң зурысы булган биш вакыт намаз бу кичәдә фарыз кылынды. Пәйгамбәребез

саллаллаһу галәйһи вәссәламнең Мәдинәи Мөнәвәрәгә күчүе алдыннан мөселманнар күп мәшәкатьләр һәм золымнар астында изелгән вакытта бу зур вакыйга була. Шуңа күрә бу вакыйга мөселманнарны бик шатландыра.

Мигъраҗ кичендә һәркем Коръән укып, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламгә салават әйтеп һәм ике рәкәгать намаз укып, кичне зикер-тәсбих белән үткәрсә, ул кешегә Аллаһы Тәгалә тәмуг утын хәрам кылды.

Мигъраҗ хакында риваять ителгән хәдисләр Имам Бохарида да, Тирмизидә дә, Нисаида да, Мөслимдә дә бик күп.

Исра кичәсендә Аллаһы Тәгалә мөселманнарга биш вакыт намаз фарыз кылды. Бу мәшһүр Исра вакыйгасы һиҗрәттән бер ел элек булды.

Кәгъбәтуллага зиярәт кылыр өчен Мәдинәдән Әус вә Хазраҗ кабиләләре килә иде. Ул кабилә кешеләре Мәдинәдә яшәүче яһүдиләрдән вә нәсара динен тотучылардан, ягъни Тәүрат вә Инҗил белән гамәл кылучылардан, гарәпләр арасыннан ахырзаман пәйгамбәре киләчәге турында ишетеп беләләр иде. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам хаҗ кылырга килгән Мәдинә кавеменә вәгазь-нәсыйхәтләрен сөйли иде. Мәдинәнең күп кенә күренеклеләре, Ислам дине кабул итеп кайткач, башкаларга да дәгъвәт кылалар иде. Сәхабәләр дә берсе артыннан икенчесе Мәдинәгә һиҗрәт кыла, ягъни күчәнә башладылар. Мәккәдә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам, Әбү Бәкер гаиләләре һәм Гали ибн Талиб кенә калдылар. Мәккә мөшрикләре сәхабәләрнең Мәдинәгә күчеп бетүен, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең дә бервакыт анда барачагын вә Мәдинә гарәпләре белән куәт җыеп, аларның башларына зур бәла булачагын искә алып, аны үтерергә ниятләделәр. 12 кабиләдән берәр егет сайлап, кулларына үткен кылыч биреп, Рәсүлулланың өен камап, ул ишектән чыкканда һөҗүм итеп үтерергә карар кылдылар.

Мәккә мөшрикләренең шул карарларын Аллаһы Тәгалә Рәсүленә белдерде һәм шул төнне үк Мәккәдән чыгып китәргә әмер бирде. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам мәсьәләне Әбү Бәкергә барып сөйләде. Соңра Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам өенә кайтып китте. Өендә Галине күреп, мөшрикләрне алдап, аларның вакытларын үткәрер өчен, үзенең киемен киеп, кич белән ята торган урынына ятарга

кушты. Соңыннан Галигә дә Мәдинәгә күчәргә кушты. Караңгыгы төшү белән әлеге 12 егет Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең өен камап алдылар. Аллаһы Тәгаләнең ярдәменә нык ышанган Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам ул вакытта өйдән чыкмаган иде әле. Озакламый ул мөшрикләр Аллаһы Тәгаләнең теләве буенча каты йокыга киттеләр. Шул вакытта Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам, өеннән чыгып, Әбү Бәкер янына китте. Аннан бик саклык илә алар Сәүр тавындагы бер тау куышына кереп яшеренделәр. Мөхәммәд галәйһиссәламнең өен камап алган мөшрикләр, уянып, аның чыкканын күрмәгәч, өенә басып керделәр. Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәламнең ята торган урынында Галине күргәч, аны кыйнап ташладылар. Соңгра, вакыт үткәрмәстән, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламне эзләргә керештеләр. Мәккә әтрафындагы чокырларны, тауларны карамыйча калдырмадылар, һәр җирдә эзләделәр. Мөшрикләр шау-шу килеп Сәүр тау куышына килгәндә, Әбү Бәкер куркуга төште, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам аңа: «Кайгырма, Аллаһы Тәгалә безнең белән, безгә ярдәм бирәчәк», — дип, аны тынычландырды.

Өч көн үткәннән соң, вәгъдә буенча Габдулла ибн Урайкит тау куышына дөяләрне алып килде. Бер дөягә Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам, икенчесенә Әбү Бәкер атланып, төн уртасында Мәдинәгә туры юл белән бару хәтәр булганга, алар Кызыл диңгез буеннан киттеләр.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламне Мәдинәдә ансарлар, ягъни Мәдинә халкы һәм мөһаҗирләр, ягъни Мәккәдән һәм башка җирләрдән күченеп килүчеләр сабырсызлык илә көтеп тора иделәр. Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламнең Мәдинәгә килүен күргәч, Коръән аятьләре вә мөнәҗәтләр әйтеп, бөтен шәһәр шатлык вә сөенеч тавышлары белән тулды, һәм бөтенесе аны каршы алырга чыкты. Бу вакыт пәйгамбәрлек килүенә унөч ел, рабигыль-әүвәлнең сигезенче, дүшәмбе көне иде. Миладидән 622 ел, 20 сентябрь, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламгә 53 яшь иде.

Мөхәммәд галәйһиссәлам Мәдинәдән ике ярым чакрым ераклыкта урнашкан Кубә авылында туктады. Биредә ул дүрт көн — дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе вә пәнҗешәмбе торды.

Анда беренче булып исәпләнүче мәсҗид Кубә дип мәшһүр булган мәсҗидкә нигез салды.

Соңра, җомга көн, Мәдинә шәһәренә юнәлде. Бәни Сәлим мәхәлләсендә җомга намазын укыды. Ошбу җомгада Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең түбәндәге хөтбәне сөйләве риваять ителә: «И, җәмәгать! Ахирәтегез өчен хәзерләнегез, изге гамәлләр кылыгыз, шәфкатьлелек вә яхшылык кылыгыз! Сез, әлбәттә, бервакыт үлеп, дөнья малларыгыздан аерылып, Раббыгыз хозурына барачаксыз. Раббыгыз сезгә: «Мин сезгә Рәсүл җибәрмәдемме? Сезгә мал бирмәдемме? Кайда кылган гамәлләрегез, кайда яхшылыкларыгыз?» — дип сораячак. Ул вакытта сезгә гамәлләрегездән башка таяныч булмаячак. Алдыгызда җәһәннәмнән башка бернәрсә дә күрмәячәксез. Шулай булгач, сез, шәфкатьлелек вә яхшылык кылып, җәһәннәм газабыннан котылырга тырышыгыз, ярты хөрмә булса да бирегез, хәер-садака бирергә көче җитмәгән кеше яхшы вә мөлаем йөз вә сүз белән ярдәм итсен, чөнки Аллаһы Тәгалә бер яхшылык өчен күп мәртәбә арттырып кайтарачак...»

Җомгадан соң Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам, дөясенә атланып, юлын дәвам итте. Мәдинәнең мәхәлләләреннән үткәндә, мәхәлләнең байлары вә бөекләре, аның каршына чыгып, үзләренә төшүен үтенәләр, дөянең тезгененә ябышып, үз өйләренә борырга тырышалар иде. Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам исә аларга дөяне үз ихтыярына куярга кушты вә дөя чүккән урынга төшәчәген әйтте. Дөя Әбү Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламнең туганы булган Әбү Әюб өенә каршы бер урында тез чүкте. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам, дөясеннән төшеп: «Урыныбыз, иншә Аллаһ, шушында булачак», — диде. Мөхәммәд галәйһиссәлам Мәдинәдә салынган беренче мәсҗид янында үзенә өй салганчы, ошбу өйдә кунак булып торды.

Һиҗрәтнең икенче елы шәгъбан аенда кыйбла тәхвил кылынды. Мәккәдә вакытында Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам Бәйтелмөкаддәскә карап укый иде. «Әл-Бәкара» сүрәсенең 144 нче аяти кәримәсендә Аллаһы Тәгаләдән: «... *Менә хәзер йөзеңне юнәлдер мәсҗид әл-Хәрам эчендәге Кәгъбәтуллага! Кайда гына булсагыз да, йөзләрегезне Кәгъбәтуллага юнәлдерегез!*» — дигән әмер килде. Шул ук елның шәгъбан аенда Аллаһы Тәгалә мөселманнарга рама-

зан аенда руза тотуны тиешле кылды. «Әл-Бәкара» сүрәсенең 183–187 нче аяти кәримәләре иңгәннән соң, рамазан рузасы белән фитыр садакасы да фарыз кылынды. Шул ук елны мөселманнарга зәкят фарыз кылынды: «Үә әкәмүс-саләтә, үә әтүз-зәкәтә», ягъни «Намаз укыгыз, зәкят бирегез!» Зәкят фарыз булып та, зәкят бирмәгән кешеләр Коръән буенча камил мөэминнәрдән саналмыйлар. Шул ук елда Аллаһы Тәгалә мөселманнарга Гает намазын тиешле кылды. Пәйгамбәребез зөлхиҗҗә аеның уны җиткәч, Мәдинә халкын бер җиргә җыеп, ике рәкәгать намаз укыды. Бу — беренче мәртәбә укылган Гает намазы иде. Ошбу Гаеттә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам үзе ике куй сарыгын корбан чалды. Башка хәлле кешеләр дә корбан чалдылар.

Һиҗрәтнең өченче һәм дүртенче, бишенче елларында Мәккә мөшрикләре белән бик күп сугышлар булды, Өхед тавы янындагы җиңелүдән башкасында Ислам гаскәре өстен булды.

Һиҗрәтнең алтынчы елында Мәккә мөшрикләре мәшһүр хатыйбларыннан Сүһәил ибн Гамрне мөселманнар белән сөйләшер өчен җибәрделәр. Сүһәил тарафыннан тәкъдим ителгән шартлар дүрттән гыйбарәт иде: 1) Бәйтулланы тәваф кылу икенче елга кичектерелә. Икенче елны мөселманнар Мәккәгә килеп, өч көн анда торырга хаклары булып, шул вакытта Мәккә халкы Мәккәдән чыгып торачаклар. 2) Мөшрикләрдән Ислам динен кабул итеп барган кешеләр таләп ителгәндә кайтарылачаклар. Мәккәгә киткән кешеләрне кайтару мәҗбүр ителмәячәк. 3) Мәккә белән мөселманнар арасында ун елга сугыш тукталачак. 4) Гарәпләрдән теләгән кеше Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам гаһеденә, теләгән кеше мөшрикләр гаһеденә керә ала.

Ошбу солыхның өченчесе мөселманнар өчен иң кирәклесе иде. Чөнки ул солых буенча сугыш туктатылса, Ислам диненең гаять тиз таралуына сәбәп булачак. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам һәрвакыт башкалар белән тыныч торуны сөя иде. Шуның өчен дә, Мәдинәгә килү белән, Мәдинә шәһәре янында булган әһле китаплылар белән һәм мөмкин булган гарәп кабиләләре белән солых төзеде. Ләкин сәхабәләрнең күбесе бу эшкә каршы булдылар. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам бу солых мөселманнар өчен бик кирәк нәрсә дип бик гүзәл вәгазь сөйләгәннән соң гына алар

солыхнамәне ике нөсхә итеп шаһитлар алдында Гали ибн Талибка яздырырга риза булдылар.

Худайбиядә төзелгән солыхнамәдән соң мөселманнар мөшрикләр белән аралаша башладылар. Исламның Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән дин икәнлегенә ышанучылар күбәеп, мөселманнарның саны шактый артты. Шул вакытларда «Фәтх» сүрәсе иңеп, сәхабәләрнең күңелен шатландырды. Алар, Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәламгә каршы кылган бәгъзе килешсез мөгамәләләренә үкенеп, тәүбә-истигъфар кылдылар.

Һиҗрәтнең җиденче елында мөшрикләр тарафыннан куркыныч беткәч, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам мөселманнарның иң зур, иң мәкерле, иң хәйләкәр дошманнары — яһүдиләр белән сугыш башлады. Аларның Нәтат, Әшшикъ, Кәсибә кальгаларын алды. Иң зур булган Хайбар алынып солых ясалгач, әсир төшкән яһүди Сәллам ибн Мүшкәм хатыны Зәйнәп бинт Харис, куй ите пешереп, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламгә вә аның сәхабәләренә тәкъдим итте. Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам, итне авызына алып бер йоткач та агуланганын сизеп, калганын кире төкерде. Сәхабәләрдән Бәшәр ибн Бәрра агуланып вафат булды. Яһүдия чакырылып, кылган эшенең сәбәбе соралгач, ул: «Әгәр пәйгамбәр булса, аңа зарар итмәс, әгәр ялганчы булса, аңардан котылырбыз дип эшләдем бу эшне», — диде. Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам моны башта гафу итсә дә, Бәшәр ибн Бәрра кебек ышанычлы сәхабәсе вафат булганлыктан, үч итеп ул хатынны үтертте. Ошбу көчле агу Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламгә тәэсир итеп, аңардан һәрвакыт зарланып әйткәнлеге, хәтта чирләгән вакытында да шуны исенә төшереп, авыруын шуннан күргәнлеге риваять ителә.

Худайбиядә ясалган солыхка бер ел тулгач, Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам вә сәхабәләр үткән елгы гомрә-хаҗларын каза кылу өчен Мәккәгә юнәлделәр. Үзләре белән алтмыш корбанлык дөя алып бардылар. Мөшрикләрнең хыянәтләреннән куркып, саклык өчен кылычлардан башка коралларны да алдылар. Ихрамны Мәдинә мәсҗидендә башладылар. Атлы гаскәрне алга куеп, Мәккәгә юнәлделәр. Әл-Хәрамга якын Бәтн Нәҗих дигән җиргә җиткәч, кылычтан башка коралларын калдырып, саклау өчен ике йөзгә кадәр гаскәр калдырып, тантаналы сурәттә Мәккәгә керделәр. Мөселманнар

Мәккәгә кергәндә мөшрикләрнең бөекләре, аларның Бәйтулланы тәваф итүләрен күрәселәре килмичә, өч көнгә чаклы Мәккәне ташлап чыктылар.

Сәхабәләр гомрә-хаҗны үтәгәч, коралларны саклар өчен калган сәхабәләр килеп тәваф кылдылар. Алар урынына башкалары бара тордылар. Мөселманнар өч көн Мәккәдә торып, гаять рәхәт вә тынычлык белән гомрәне үтәделәр. Дүртенче көнне, шарт буенча, Мәккәдән чыктылар.

Һиҗрәтнең сигезенче елында Мәккә мөшрикләре, Худайбиядә ясалган солыхны бозып, Ислам дине кабул иткән Хазәгә гарәпләренә кинәт һөҗүм итеп, аларның берничә кешесен үтерделәр. Мөшрикләрнең беренче булып солыхны бозулары кан түкмичә Мәккәне алуга, Бәйтулланы сыннардан тазартып, бөтен дөньяга Ислам динен таратуга бер форсат булды. Шуның өчен Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам, шул килгән форсатны ганимәт дип, Мәккәне тулысы белән Ислам диненең үзәге иту өчен гаскәр әзерли башлады. Рамазан аеның 10 нчы көнендә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам ун меңнән артык гаскәр әзерләп, Мәккәне Ислам диненең башкаласы иту нияте илә юлга чыкты.

Гаскәр Мәккәгә берничә яктан керсә дә, иң күп гаскәр Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам җитәкчелегендәгесе иде. Халид ибн Вәлид гаскәренә, мөшрикләрнең бер өлеше каршы килеп сугышулары сәбәпле, корал кулланырга туры килде. Шул бәрелештә мөшрикләрдән 13 кеше, мөселманнардан ике кеше үтерелде. Җәза бирелүдән курыккан кайсыбер мөшрикләр Әбү Суфьян йортына, кайсы мәсҗид Хәрамга кереп качтылар. Ислам гаскәре Мәккәгә һиҗрәтнең сигезенче елында, рамазанның 20 сендә, җомга көнне керде.

Мөхәммәд галәйһиссәлам сәхабәләр вә ансарлар белән Бәйтулланы тәваф кылды. Бер кулына ук вә җәя тоткан көе Хәҗәре әсвәдне үпте. Ул вакытта Бәйтулла тирәсендә өч йөз алтмыш сын бар иде, ул аларның барысын да шәһәр читенә чыгарырга кушты. Бәйтулланың эче потлардан вә төрле сыннардан тазартылгач, Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам Аллаһы Тәгаләгә мондый бөек нигъмәт бирүе өчен шөкрана йөзеннән дүрт рәкәгать намаз укыды. Бәйтулла эчендә йөреп, тәкбирләр әйтте. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең Бәйтулладан чыкканын меңләгән халык көтеп тора иде.

Аллаһы Тәгаләнең вә Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәламнең ризалыгы өчен, мал-мөлкәтләреннән аерылып, газиз ватаннарын ташлап киткән мөһаҗирләр белән бергә сәхабәләргә ярдәм иткән ансарлар, Мәккә мөшрикләрен җиңеп, аның сыннардан тазартылуына, Хак Тәгаләнең аларга биргән вәгъдәсенең үтәлүенә ничек шөкер итәргә белмичә бөтен вөҗүдләре белән шатланып торган вакытта, Аллаһы Тәгаләнең Рәсүленә вә аңа ияргән мөселманнарга золым вә кабахәтлекләр кылырга тартынмаган Мәккә мөшрикләренең, җинаятьләренең нәтиҗәсе ни булачагын белмичә, куркуларыннан бөтен әгъзалары тетри иде.

Шәфкать вә мәрхәмәтнең иң югары дәрәҗәсендә булган Мөхәммәд галәйһиссәлам аларның явызлыгына каршы явызлык кылмады. Аларның бөтенесен гафу итте. Моны күреп, Мәккә мөшрикләре шатлыкларыннан ни эшләргә белмәделәр. Пәйгамбәребезгә күп шөкрана кылдылар.

Моннан соң Рәсүлулла галәйһиссәлам халыкка хөтбә сөйләде: «И, мөшрикләр, сез үз күзләрегез илә күреп торасыз, Аллаһы Тәгаләнең вәгъдәсе җиткәч, сезнең Бәйтулладагы җаһилият сыннары юк ителде. Ата-баба белән тәкәбберләнүне бетерде. Сез барыгыз да адәм балалары, Адәм галәйһиссәлам исә туфрактан яратылды. Сез бөтенегез дә бертигез. Бер-берегездән артыклыгыгыз фәкать изге гамәл белән генә булачак!»

Һиҗрәтнең тугызынчы елында румнар белән Тәбук сугышы булды. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам гаскәр әзерлеге өчен мөселманнарны ярдәм итүгә өндәде, бу турыда хөтбәләр сөйләде һәм вәгазь-нәсыйхәтләр кылды. Һәркем кулыннан килгән кадәр ярдәм итте, ярдәм итә алмаганнар әҗер-саваптан мәхрүм калуларына бик кайгырдылар. Сугышка баручылар Аллаһы Тәгаләнең вә Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәламнең ризалыгы өчен шәһит китәргә дә әзер иделәр.

Тугызынчы ел ахырларында «әл-Гыймран» сүрәсенең 97 нче аяти кәримәсе иңдерелде. Анда: *«Көче җиткән һәр мөселманга Кәгъбәне хаҗ кылу фарыз (97)»,* — диелгән иде. Хаҗ фарыз булганлыктан, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам Мәккәгә хаҗ кылучыларның җитәкчесе итеп бу елны Әбү Бәкер Сиддыйкны җибәрде.

Һиҗрәтнең унынчы елында исә 90 000 хаҗи белән Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам үзе хаҗ кылды. Үзе

белән корбанлыкка йөз дөя куып китерде. Җиде мәртәбә Бәйтулланы тәваф кылды. Әүвәлге мәртәбәсендә Хәҗәре әсвәдне үпте. Тәвафтан соң Мәкам артында ике рәкәгать намаз укыды. Сафа белән Мәрва арасын җиде мәртәбә йөгереп узды... Сафа белән Мәрвага менгән саен, Бәйтуллага борылып тәкбир әйтә вә: «Аллаһ бер, Аның ширеге юк, бөтен мөлек һәм мактау Аныкы, һәм Ул бөтен нәрсәгә кадир. Аллаһ бер, һәм Ул вәгъдәсендә торды, Үзенең колына ярдәм итте. Аллаһы Тәгалә Берүзе мөшрикләрнең, кяферләрнең гаскәрләрен җиңде», — дип әйтә иде.

Зөлхиҗҗәнең 8 нче көнендә пәнҗешәмбе көн иртә белән хаҗилар Рәсүлулла галәйһиссәлам белән Мина тавына юнәлделәр вә шунда кундылар. Җомга көн, кояш чыккач, Гарәфәткә юнәлделәр. Юлда сәхабәләрнең кайсысы тәкбир әйтә, кайсы тәлбия әйтә иде. Төш авышкач, дөясенә атланып, Пәйгамбәребез Гуранә дигән җиргә барып туктады. Вә шул җирдә, озын хөтбә сөйләп, Ислам кагыйдәләрен бәян кылды. Билалга азан һәм камәт әйтергә кушты. Җомганың дүрт рәкәгать сөннәтен, азаннан соң ике рәкәгать фарыз һәм дүрт рәкәгать сөннәтен укыды. Кыйраәтне яшерен кылды. Җомга тәмам булып икенде вакыты кергәч, яңадан азан вә камәт әйтелеп, дүрт рәкәгать икенде намазын укыды. Һәм ошбу вакыт «әл-Маидә» сүрәсендәге 3 нче аять иңде: *«Менә бүген динегезне төзеп бетереп тулы кылдым (3)».* Муздәлифәгә төшкәч, Билалга азан әйтергә кушты. Камәт әйтелгәч, ахшам намазы укылды. Берникадәр вакыттан соң азан әйтелде вә камәт төшерелде, ястү намазының фарызы вә сөннәте укылды. Муздәлифәдә кунып, зөлхиҗҗәнең унынчы көнендә, таң аткач, иртә намазын укыды да, дөясенә атланып, мәсҗид әл-Хәрамгача барды. Кыйблага каршы торып дога кылды вә тәкбир әйтте. Соңра Минага юнәлде. Минада, Җәмратул-Гәкабәгә каршы торып, җиде таш атты. Соңра Минада хөтбә укып, халыкка хаҗның тәртипләрен өйрәтте. Мәккәнең башка шәһәрләргә караганда артыклыгын, корбан чала торган көннең бөеклеген сөйләде. Үзенең бу елдан соң хаҗ кыла алмау ихтималын сөйләде. Үзеннән соң бердәмлек белән торырга, ихтилаф, ягъни ызгыш-талаш кылышмаска кушты.Сөйләгән сүзләрен шунда булган кешеләргә ирештерергә кушты. Бу хаҗны Әлвидаг, ягъни саубуллашу хаҗы дип атадылар. Моннан соң Рәсүлулла саллаллаһу галәй-

һи вәссәлам, Мәнхәргә барып, үз кулы белән алтмыш өч дөя чалды. Калган утыз җидесен Гали ибн Талибкә чалырга кушты. Корбан итеннән үзе дә ашады. Тиреләрен садака итеп таратты. Корбаннар чалынып беткәч, Мугәммәр ибн Габдулланы чакырып чәчен алдырды вә ихрамнан чыкты. Шуннан соң дөягә атланып, Мәккәгә килде һәм Бәйтулланы янә тәваф кылды. Аяк өсте торып зәм-зәм суын эчте. Соңра яңадан Минага килеп, өйлә намазын укыды. Минада тәшрикъ көннәренең һәркайсында — беренче Җәмрадә, уртанчы Җәмрадә, вә өченче Җәмрадә дә җидешәр таш атты. Таш атып бетергәч, кыйблага каршы торып, озын дога кылды. Минада шимбә, якшәмбе, дүшәмбе көннәрне калып, сишәмбе көн Мухассабка барды. Анда өйлә, икенде, ахшам вә ястү намазларын укып, азрак ятып алды. Аннан соң Мәккәгә килде. Төн вакытында Бәйтулланы тәваф итте. Моңа саубуллашу тәвафы диләр. Иртә намазын Мәккәдә укып, зөлхиҗҗәнең 14 нче көнендә, чәршәмбе көн, Мәдинәгә юнәлделәр.

Ошбу хаҗ Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вәссәламнең иң беренче хаҗы булды. Гомрә хаҗы исә дүрттер: Худайбия гомрәсе, Гомрәтел-каза, Җигранә гомрәсе вә ошбу хаҗ белән кылынган гомрә.

Һиҗрәтнең унберенче ел сәфәр аенының ахырларында Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам күп кенә сәхабәләрне шәһит иткән румнар белән сугыш кылу өчен зур гаскәр әзерләде. Ошбу гаскәр эчендә күп сугышларда чыныккан мөһаҗирләр вә ансарлар бар иде. Ләкин бу вакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәлам хасталанып киткәнлектән, гаскәр, аның сәламәтләнүен көтеп, сәфәргә чыкмады. (Бу сәфәр Мөхәммәд галәйһиссәлам вафат булып, Әбү Бәкер хәлифә булгач булды.) Алда әйткәнебезчә, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам үзенең вафат була торган вакытын сизгән вә Хаҗҗәтүл-әлвидагта халык белән саубуллашкан иде. Беркөн Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам мөнбәрдә: «Җәнабел Хак бер колын дөнья белән ахирәттән берсен ихтыяр итәргә ирекле кылды, кол ахирәтне ихтыяр кылды», — диде. Әбү Бәкер бу сүзләрдән Пәйгамбәребезнең бик тиздән вафат булачагын аңлап: «Ата-аналарым сиңа фида булсын», — дип елый башлады. Моны күреп, Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам: «Мин иң күп дәрәҗәдә аңа рәхмәтлемен.

Әгәр дус сайларга булсам, Ислам туганлыгы өчен фәкать аны гына сайлар идем», — диде.

Рабигыль-әувәл аенда пәнҗешәмбе көнне Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең авыруы көчәеп, ул ястү намазына чыга алмады. Әбү Бәкер Сиддыйкка халыкка имам булып намаз укырга кушты. Ошбу вакыттан алып, Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам вафат булганчы Әбү Бәкер имам булды. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең аны имам итеп билгеләве аның үзеннән соң хәлифә булачагына бер ишарә кебек иде. Шуның өчен дә сәхабәләр Әбү Бәкергә бәйгать, ягъни турылыклы булырга ант иткәндә: «Динебез өчен Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам разый булган вә ихтыяр иткән кешене дөньябыз өчен ихтыяр итәбез», — димешләр. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам чирләгән вакытта Әбү Бәкернең 17 мәртәбә намазда имам булып торуы риваять кылынадыр.

Бервакыт Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам, үзендә беркадәр җиңеллек табып, Габбас белән Галигә таянып, өйлә намазына чыкты, халык намаз укымакта иде. Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәламнең чыкканын сизеп, Әбү Бәкер артка китмәкче булса да, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам аңа урыныннан кузгалмаска кушты. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламне Әбү Бәкернең янына утырттылар. Намаздан соң Рәсүлулла халыкка хөтбә сөйләү өчен мөнбәргә утырды. Иң башта озын итеп дога вә истигъфар кылды. Соңра ошбу сүзләрне сөйләде: «И, җәмәгать! Сез минем вафат булуымнан куркасыз икән. Миңа кадәр килгән пәйгамбәрләр мәңге калмаган кебек, мин дә калмаячакмын, әлбәттә, бер үләчәкмен, мин дә, сез дә Аллаһы Тәгаләнең хозурына барачакбыз. Мин сезгә үземнән соң мөһаҗирләргә хөрмәт вә игътибар итәргә тәкъдим итәм. Мөһаҗирләргә үзара гүзәл мөгамәләдә булырга кушам. Мөһаҗирләр ансарларга яхшы мөгамәлә итсеннәр. Ансарлар мөһаҗирләрне йортларына кабул иттеләр. Аларга малларын бүлеп бирделәр. Үзләренә юкны аларга бирергә тырыштылар. Әгәр берәрегез аларның өстеннән хөкем сөрәчәк булса, аларга шәфкать белән мөгамәлә итсен. Бәгъзе кимчелекләр булса, кичерсен! И, җәмәгать! Миндә хакы булган кеше сөйләсен. Берәүнең аркасына сукканмын икән, менә арка, үч алсын.

Бәрәүнең намусына кагылганмын икән, шуның үчен миңа кайтарсын. Берәүнең малын алганмын икән, малымны алсын. Минем кәефем китәр, ачуым килер дип курыкмасын. Миндә андый табигать юктыр. Миңа иң сөекле кеше — миннән хакын таләп иткән, өстемдә хакын калдырмаган кешедер. Шулай ук өстендә минем хакым булган кеше дә миңа шуны кайтарсын. Дөньяда хур булырмын дип куркып, ахирәт хурлыгына дучар булмасын!» Ошбу вакыт бер кеше торып Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнән өч дирһәм алачагы барлыгын сөйләде. Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәламнең шул кешегә тиешле булган акчасын түләве хакында риваять кылына.

Риваятьләргә караганда, Пәйгамбәребез чирләгән вакытында янына җыелган сәхабәләргә: «Кая, каләм, кара китерегез. Сезгә бер васыятьнамә языйм. Миннән соң заляләткә, ягъни туры юлдан язып, ялгыш юлга кермәс өчен», — димеш. Сәхабәләр арасында бу хакта ихтилаф, ягъни фикер каршылыгы булып, бәгъзеләре яздырыйк, бәгъзеләре исә: «Мондый вакытта Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәламне борчу дөрес түгел, алдыбызда Аллаһы Тәгаләнең китабы бар, шул безгә бик җиткән», — диделәр. Шул сәбәпле, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам васыятьнамә язмады.

Рабигыль-әүвәл аеның 12 сендә, дүшәмбе көн, Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам, үзендә беркадәр җиңеллек хис итеп, иртә намазында булган сәхабәләрне карар өчен Гайшә радыйаллаһу ганһә һөҗрәсеннән чыкты. Мәсҗид тулы намаз укучы сәхабәләрне күреп, шатланып елмайды. Халык Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламне күреп, шатлыкларыннан ни эшләргә дә белмәделәр. Әбү Бәкер, Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәламне намазга чыга дип зан итеп, юл бирмәкче булса да, Мөхәммәд галәйһиссәлам аңа намазын дәвам итүгә ишарә кылды. Соңра хөҗрәсенә кереп китте. Шул көн, кояш бераз күтәрелгәч, дөньядан кичте. Гайшә радыйаллаһу ганһәдән риваять кылына: «Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам үләр алдыннан савыттан су алып йөзен сыйпады, вә: «И, Раббым, миңа үлем исереклегеннән ярдәм бир, вә рафикъ әгълане ихтыяр кылам», — диде».

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең вафаты һиҗрәтнең 11 нче елында, рабигыль-әүвәлнең 12 сендә, дүшәмбе көн иде. Миладидә буенча 632 нче елның 7 нче июненә

туры килә. Бу вакытта аңа 63 яшь булып, чәч вә сакалында ак бөртекләр күренә башлаган иде.

Берничә сәгать элек кенә аларга елмаеп караган Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәламнең үлем хәбәрен ишетеп, сәхабәләр бөтенләй шашып калдылар. Аның вафатына ышанмаучы сәхабәләр арасында Гомәр сәхабә дә бар иде.

Әбү Бәкер Гайшә радыйаллаһу ганһә хөҗрәсенә керде. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам хөҗрәнең бер тарафына яткырылып, йөзе пәрдә белән капланган иде. Ул Мөхәммәд галәйһиссәламнең йөзен ачып үпте вә каты сүрәттә елады. Соңра мәсҗид тирәсенә җыелган халык янына чыгып, аларның шөбһәләрен җибәрү өчен ошбу сүзләрне сөйләде: «Мөхәммәд галәйһиссәламгә гыйбадәт кылучылар булса, белсеннәр: Мөхәммәд галәйһиссәлам үлде, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылучылар белсеннәр: Аллаһы Тәгалә исән — Ул мәңгелек!» Соңра «Зүмәра» сүрәсенең 30 нчы аятен укыды: *«И, Мөхәммәд галәйһиссәлам, син дә үлүче, алар да үлүчеләр (30)»*, һәм «әл-Гыймран» сүрәсенең 144 нче аятен укыды: *«Мөхәммәд галәйһиссәлам һичкем түгел, мәгәр Аллаһы Тәгаләнең хак Рәсүледер. Әлбәттә, аңардан әүвәл күп рәсүлләр килеп киттеләр. Әгәр Мөхәммәд галәйһиссәлам үлсә яки үтерелсә, сез, сәхабәләр, хак динне ташлап, әүвәлге батыйль динегезгә кайтырсызмы? Бер мөэмин Ислам динен ташлап, әүвәлге батыйль диненә кайтса, Аллаһы Тәгаләгә зарар кыла алмас, мәгәр үзенә зарар кылыр, һәлак булыр. Ислам динендә булганы өчен шөкер итеп, Аллаһы Тәгалә юлында сугыш кылучыга Аллаһы Тәгалә бик тиз җәннәт нигъмәтләре белән хакын түләр (144)».*

Әбү Бәкернең йөрәкләрне тетрәндерә торган сүзләрен ишеткәч, халык, аңнарына килеп, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең вафатына ышандылар.

Мөхәммәд галәйһиссәламне юучылар: Гали ибн Талиб, Фазыл ибн Габбас, Касыйм ибн Габбас, Үсәмә ибн Зәид булдылар. Юып кәфенләгәч, алар халыкка берәм-берәм җеназа укыдылар. Ирләр укып бетергәч, хатыннар, аннары сабыйлар укыды. Җеназа укылып беткәч, Гайшә радыйаллаһу ганһә хөҗрәсендә, рухы чыккан урында кабер казылып, ләхет алынып дәфен кылынды. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам, гомуми зиратка күмелмичә, вафат булган урынга

күмелде. Әбү Бәкернең катгый рәвештә: «Пәйгамбәр кайда вафат булса, шунда күмелә», — дигән Мөхәммәд галәйһиссәламнең хәдисен риваять иткәне өчендер. Бәгъзеләре моны Рәсүлулла галәйһиссәламнең васыяте буенча булды, диләр. Кабер җирдән бер карыш микъдары күтәрелде. Билал кабернең өстенә су сипте. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең дәфен кылынуы сишәмбе көн, төн уртасында иде. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең болай озак дәфен кылынуы сәхабәләрнең җеназа намазын берәмберәм укуларыннан булды.

Газиз кардәшләрем! Шулкадәр аз бер вакыт эчендә Ислам диненең һәм шул ук вакытта төрле фәннәрнең, мөселманнар тарафыннан өйрәнелеп, икенче бер илләргә таралуы үзе бер могҗиза түгелмени? Моңа тарихта охшаш мисал бармы? Әлбәттә, юк. Бу зур эшләр, әлбәттә, Аллаһы Тәгалә ярдәме белән генә булганы мәгълүмдер.

Үәссәламүгаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ!

# КЫЯМӘТ КЫЙССАСЫ

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Аллаһы Тәгалә бу дөньядагы нигъмәтләрне кешегә файдасы тисен өчен барлыкка китерде. Ә кеше нишли? Танымый үзенең барлыкка китерүчесен, шөкрана да кылмый. Ул наданлыгы аркасында тәкәбберләнеп, үзен Раббысыннан өстен куя. Үзенең гомерен дә, Аллаһы Тәгалә биргән иксез-чиксез нигъмәтләрне дә юкка-барга сарыф итә. Шушы мәгънәсезгә, зыянга үткән һәр көне өчен, начар гамәле, буш вә гайбәт сүзләре өчен кыямәт көнендә җавап тотасын онытa.

Аллаһы Тәгаләнең Коръән Кәриме, «әл-Һүмәзә» сүрәсендә бу хакта болай диелгән:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ۝ وَيْلٌ لِكُلِّ هُمَزَةٍ لُمَزَةٍ ۝١ الَّذِي جَمَعَ مَالًا وَعَدَّدَهُ ۝٢
يَحْسَبُ أَنَّ مَالَهُ أَخْلَدَهُ ۝٣ كَلَّا لَيُنْبَذَنَّ فِي الْحُطَمَةِ ۝٤ وَمَا أَدْرَاكَ مَا الْحُطَمَةُ ۝٥ نَارُ اللهِ الْمُوقَدَةُ ۝٦
الَّتِي تَطَّلِعُ عَلَى الْأَفْئِدَةِ ۝٧ إِنَّهَا عَلَيْهِمْ مُؤْصَدَةٌ ۝٨ فِي عَمَدٍ مُمَدَّدَةٍ ۝٩

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Үәйлүлли күлли һүмәзәтил-лүмәзәһ (1). Әлләзии җәмәгә мәәләү-үәгәдәдәһ (2). Йәхсәбү әннә мәәләһүү әхләдәһ (3). Кәлләә ләйүм-бәзәннә фил хүтамәһ (4). Үә мәә әдераакә мәл хүтамәһ (5). Нәә руллааһил мүүкадәһ (6). Әлләтии тәтталигү гәләл әфидәһ (7). Иннәһәә гәләйһим-мүәсадәһ (8). Фии гәмәдим-мүмәддәдәһ (9).

М ә г ъ н ә с е : *«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Һәр сүз йөртүче гайбәтчегә нинди үкенеч вә һәлакәттер (1). Ул гайбәтче нинди юл белән булса да мал җыйды, вә ул малны тиешле урынына бирмичә, саранлык белән яшереп саклады (2). Тәхкыйк, ул гайбәтче саран, малы аны дөньяда мәңге калдырыр дип уйлады (3). Юк, үз башына бәла булган малына таянмасын, әлбәттә, ул әл-Хүтамәһ утына ыргытылыр (4). Әл-Хүтамәһнең нәрсә икәнлеген сиңа нәрсә белдерде? (5) Ул Аллаһының кыздырылган утыдыр (6). Ул ут йөрәкне яндырыр (7). Тәхкыйк, ул мәңгелек ут аларның өсләрендә тоташыр (8). Уттан сузылган озын баганалар белән (9)».*

Гөнаһлы бәндәләрне кем коткарыр? Гөнаһлы бәндәләрнең кайсын Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең шәфәгате коткарыр; кайсын кечкенә балалары коткарыр; кайсын мизанда биргән җаваплары коткарыр; кайсын дөньяда гомер иткән вакытта бөтен халык арасында гаделлек чәчеп йөрүләре коткарыр; кайсын бөтен ихласы илә суйган корбаны коткарыр; кайсын фәкыйрьне, байны аермыйча бер итеп күрүе коткарыр; кайсын калебе илә ышанып хаҗ кылулары коткарыр; кайсын кешегә салынмыйча, үз кул көче илә сабыр гына гомер итүләре коткарыр; кайсын Ислам дине кануннарына туры китереп чыгарган китаплары коткарыр; кайсын мәсҗид салуга, җир астыннан халык өчен сулар чыгаруга хәләл көчен кертүе коткарыр; кайсын...

Ләкин «үләсең дә бетәсең, үлгәннән соң терелү юк», дип йөргәннәр тәмугка керерләр. Болар хакында Коръәннең «Йәсин» сүрәсе, 77–79 нчы аяти кәримәләрендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

أَوَلَمْ يَرَ الْإِنْسَانُ أَنَّا خَلَقْنَاهُ مِنْ نُطْفَةٍ فَإِذَا هُوَ خَصِيمٌ مُبِينٌ ۝٧٧ وَضَرَبَ لَنَا مَثَلًا وَنَسِيَ خَلْقَهُ
قَالَ مَنْ يُحْيِي الْعِظَامَ وَهِيَ رَمِيمٌ ۝٧٨ قُلْ يُحْيِيهَا الَّذِي أَنْشَأَهَا أَوَّلَ مَرَّةٍ وَهُوَ بِكُلِّ خَلْقٍ عَلِيمٌ ۝٧٩

«Әүәләм йәраль иңсәәнү әннәә халәкънәәһү миннүтъфәтиң фәизә һүвә хасыййммум-мүбиин (77). Үә дарабә ләнә мәсәләү-үә нәсийә халкаһү каалә мәййүхил-гизаамәә үә һийә рамиим (78). Куль йүхииһәл-ләзии әңшәә-әһәә әүвәлә мәрратиү-үә һүвә бикүлли халькыйн гәлиим (79)».

М ә г ъ н ә с е : *Кеше белмиме Безнең аны бер тамчы судан халикъ кылганыбызны, шуның соңында ул зәгыйфь кеше Безнең белән каты каршылашамы, үткәннәребездән соң аны яңадан тергезергә кадир икәнлегебезне инкарь итәме? (77). Үзенең бер тамчы судан халикъ кылынганлыгын онытып, кипкән сөяк белән Безгә мисал итеп, бу сөяк череп беткәч, моны кем тергезә алыр, дип (78). Син аларга әйт: «Бу сөякне әүвәл мәртәбә кем юктан бар кылган булса, шул зат тергезер, дип. Ул Аллаһы Тәгалә — барча мәхлукатның хәлен белүче (79)».*

Янә шуңа өстәп Аллаһы Тәгалә «Йәсин» сүрәсенең 54–55 нче аяти кәримәләрендә әйтә:

فَالْيَوْمَ لَا تُظْلَمُ نَفْسٌ شَيْئًا وَلَا تُجْزَوْنَ إِلَّا مَا كُنْتُمْ تَعْمَلُونَ ۝٥٤

إِنَّ أَصْحَٰبَ ٱلْجَنَّةِ ٱلْيَوْمَ فِى شُغُلٍ فَٰكِهُونَ ﴿٥٥﴾

«Фәл-йәүмә ләә түзләмү нәфсүң шәй-әү-үәләә түҗезәүнә илләә мәә күңтүм тәгмәлүүн (54). Иннә әсъхәәбәл-җәннәтил-йәүмә фии шүгулиң фәәкиһүүн (55)».

М ә г ъ н ә с е : *«Бу көнне беркемгә дә үзенең кылган гамәленнән артык гөнаһ куелмас, һәркем үз гөнаһысы хәтле җавап кылыр (54). Бу көнне яхшы гамәлләр кылган кешеләр, Аллаһының рәхмәтен ишетегез, җәннәткә керегез, вә анда мәңге калыгыз, дип әйтерләр (55)».*

Кыямәт көнне һәр әгъза Аллаһы Тәгалә каршында җавап тотачак, шаһәдәтлек бирәчәк. Ягъни, кеше аны тиешле урында файдаландымы, әллә бу әгъзаларны үз нәфесенә хезмәт итәргә мәҗбүриләдеме? Күзләрен Аллаһы Тәгалә тыйган хәрамнан тыйдымы, әллә бозыклыкны, азгынлыкны комсызланып аңына, җанына сеңдердеме? Телен Хак Тәгалә тыйган гайбәттән, әшәке сүзләрдән, ялганнан, буш сүздән тыйдымы, әллә теленә ни килсә шуны сөйләп йөрдеме? Авызын Җәнабел Хак тыярга кушкан хәрам ризыктан тыйдымы, әллә аракысын да, дуңгыз итен дә, башка тыелган нәрсәләрне дә нәфесе күпме тели, шуның кадәр кулландымы? Аякларын Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә тыйган бозык урыннарга йөрүдән туктаттымы, әллә аларны азгынлык, җинаять юлында йөрергә мәҗбүр иттеме? Аллаһы Тәгалә кадерләп биргән йөрәген, баш миен, берни белән дә алыштырып булмый торган башка әгъзаларын тиешенчә саклый белдеме, әллә теләсә нәрсә эшләп, теләсә нәрсә ашап, үз-үзенә зыян китердеме? Һәр әгъза менә шулай соралачак, кеше дөрес яшәмәгән икән, һәр әгъзасы аңа каршы шаһәдәтлек бирәчәк. Чөнки безнең һәр әгъзабыз — Аллаһы Тәгалә безгә бүләк иткән әгъзаларның бер кисәге. Кеше әгъзаларының нәни генә бер күзәнәге, бер бизе эшләмәсә, аны үлем көтәргә мөмкин. Хак Тәгалә кешегә биргән әгъзаларында бер генә артык җире дә, кирәксез нәрсә дә юк, барлык әгъзалар, күзәнәкләр, бизләр үзара бик тыгыз бәйләнгән һәм бер-берсеннән башка яши алмыйлар. Кеше әгъзалары — ул үзе бер дөнья, ул тулы бер бөтенлек-тәгәллекне тәшкил итә. Әмма бу — кеше үзе барлыкка китергән бөтенлек-тәгәллек түгел, бу бер бөтен дөнья аңа инде әзер килеш бүләк ителгән. Бу тән

һәм җан инде әзер килеш, әманәт итеп тапшырылган һәм гомеренең ахырына кадәр ул Аллаһы Тәгаләнең шушы әманәтен кадерләп сакларга тиеш. Моның өчен, әлбәттә, гыйлем кирәк, үз тәнеңне, үз әгъзаларыңны тыңлый, ишетә белергә кирәк. Ә алар безнең өчен көне-төне эшләп торалар, Аллаһы Тәгаләнең гыйлемен сөйләп торалар, үзләрен кем дөньяга яралтканны төзелешләре белән аңлатып, күрсәтеп торалар. Аларны бары тик аңлый, күрә, тыңлый белергә генә кирәк.

Ахирәт көне ничек булачак? Ахирәт, ягъни мәңгелек теге дөнья турында Аллаһы Тәгаләнең Коръән Кәримендә бик күп аяти кәримәләрдә вә бәгъзе сүрәләрдә әйтелә. Шулардан файдаланып, хәлемнән килгәнчә, бәндәләрнең кыямәт көнендә ниләр кичерәчәкләре рәвешендә язарга ниятләдем, болай иткәндә кешеләрнең калебләренә яхшырак барып җитәр дигән өметтә калам. Хак Сөбханә вә Тәгалә ярдәменнән ташламасын. Әмин.

Ахирәт көнендә җир калтырар. Анда булган вак ташлар, зур-зур ташлар астында калып, вак тузанга әйләнерләр вә агулы тузан илә бөтен һаваны тутырырлар... Барлык якта да дөньяда булмаган караңгылык. Бу гаять тә караңгылык илә капланган очсыз-кырыйсыз сахра шикелле урынның тирә-ягы адәм белмәгән, адәм ишетмәгән тавышлар илә тулыр. Бу куркыныч тавышларның куркынычлыгын корыч каләм илә язып күрсәтү вә тасвирлау һич мөмкин түгел. Чөнки һәр секунд вакыт эчендә күк күкрәгән кеби ничә вә ничә мең төрле тавышлар, төрле якка чәчелеп, бөтен дөньяны һәлак иткән кеби гөрелдәп, тетрәп үтеп китү белән янә әүвәлдәгедән дә куркынычрак тавышлар ишетелер. Агулы кайнар һаваның төрле якка агуы шулкадәр куәтле, аны кайнап торган кояшка гына тиңләп булыр иде. Бу куәтле җилнең куркыныч тавышлар арасында төрлечә сызгыруыннан һәм куркыныч тавышлар илә бергә кушылуыннан, куркыныч тавышлар янә дә куркынычлырак булыр.

Кинәт бөтен дөнья икегә ярылган кеби бер гаять тә каты улау тавышлары ишетелер... Җир селкенер... Һава тетрәр... Җир өстендәге булган әйберләр барсы да ботка булып, берберсенә бәрелерләр... Бөтен дөнья ничә вә ничә миллион төрле тавышлар илә тулыр... «Йә, Аллаһ, үзең коткар!» — дип ялварган авазлар һәр яктан яңгырар.

Коръән Кәримнең «әз-Зәлзәлә» сүрәсендә бу көн турында болай әйтелә:

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ❀ اِذَا زُلْزِلَتِ الْاَرْضُ زِلْزَالَهَا ❀١ وَاَخْرَجَتِ الْاَرْضُ اَثْقَالَهَا ❀٢ وَقَالَ
الْاِنْسَانُ مَالَهَا ❀٣ يَوْمَئِذٍ تُحَدِّثُ اَخْبَارَهَا ❀٤ بِاَنَّ رَبَّكَ اَوْحٰى لَهَا ❀٥ يَوْمَئِذٍ يَصْدُرُ النَّاسُ
اَشْتَاتًا لِيُرَوْا اَعْمَالَهُمْ ❀٦ فَمَنْ يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ خَيْرًا يَرَهُ ❀٧ وَمَنْ يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ شَرًّا يَرَهُ ❀٨

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Изәә зүлзиләтил әрду зилзәәләһә (1). Үә әхраҗәтил әрду әскааләһә (2). Үә каалəл иңсәәнә мәәләһә (3). Йәүмәизиң түхәддисү әхбәәраһә (4). Биәннә раббәкә әүхәәләһәә (5). Йәүмәизий-йәсдүруннәәсү әштәәтәл-лийүрау әгмәәләһүм (6). Фәмәй-йәгмәл мискаалә зәрратин хайрай-йәраһ (7). Үә мәй-йәгмәл мискаалә зәрратин шәррай-йәраһ (8)».

М ә г ъ н ә с е : *«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әгәр җир үзенең тетрәве илә селкендерелсә (1), вә җир үзенең эчендәге үлекләрне, йөкләрне, хәзинәләрне чыгарса (2) һәм кеше әйтсә: «Ни булды бу җиргә?» — дип (3), шул көндә җир үзенең өстендәге эшләнгән эшләрдән хәбәр бирер (4). Тәхкыйк, җирнең сөйләмәге Раббыңның аңа сөйлә, дип әйтүе беләндер (5). Ул көндә кешеләр, каберләреннән кубарылып хисап җиренә, гамәлләренә күрә, төрле фиркаләргә бүленеп барырлар, дөньяда кылган гамәлләренең җәзасын күрмәк өчен (6). Берәү тузан бөртеге хәтле генә яхшылык кылган булса, аның рәхәтен күрер (7). Вә дәхи берәү тузан бөртеге хәтле гөнаһ эшләгән булса, аның җәзасын күрер (8)».*

Бу көнне адәм баласының бөтен җаны-тәне куркудан, чарасызлыктан тетрәр... Тирә-ягына әйләнеп караса, бөтен фикере илә бу куркыныч мәхшәрне аңларга тырышыр, әмма дөньяда булган һичбер нәрсәгә дә охшата алмас. Барлык яктан курыккан, «Әстәгъфирулла!» дигән авазлар гына яңгырар. Куркуларыннан башка сүз әйтә алмыйча, җиргә йөзтүбән егылырлар.

Кинәт: «Уяныгыз, аягүрә торыгыз, бәндәләр!» — дигән бер бик көчле аваз ишетелер. Барча бәндәләр бу авазга буйсынып аягүрә торып басарлар вә җансыз булып катып урыннарында калырлар. Алда, бик еракта аклы-аллы гүзәл бер яктылык күренер. Барча бәндәләр калтырый-калтырый шул яктылыкка таба атларлар. Һәр яктан Аллаһ исеме, елау тавышлары, курку, хәсрәт тавышлары — барысы да бер булып, алга атларлар. «Харап бул-

дым, бу мәхшәр көне икән!» — дип, барысы да бик каты еларлар. Алдагы кешеләр яктылыкка таба карап барырлар да барырлар, аларның иге-чиге, хисабы юк. Күп кенә кешеләр елап тәүбә итәрләр: «Бу көн тәүбәләрегез кабул булмый!» — дигән каты тавышны ишетеп, күзләреннән канлы яшьләр агызырлар. Елап торганда биредә тәртип саклаучы фәрештәләрнең берсе ни беләндер аларның аркаларына куәт белән сугар. Мондый каты сугуларны аларның фани дөньяда һич татыганнары булмас. Калебләре, җаннары вә бөтен бәдәннәре яңа куркулардан янә дер калтырап, сызлана башлар. Фикерләре чуалыр, яланаяклар үткен ташларга басып җәрәхәтләнер дә җәрәхәтләнер, моңа беркем дә игътибар итмәс вә беркем беркемне кызганмыйча алдагы яктылыкка таба барырлар да барырлар. Дүрт як тарафтан төрле кызганыч елау вә улау тавышларыннан башка берни дә ишетелмәс. Бу кызганыч яшьләрне түгү аяклар вә арканың канап авыртуыннан түгел, күз алдында булган адәмнәрнең газабыннан. Тәртип саклаучы хисапсыз күп фәрештәләр чукмар белән туктап торучыларны, тезләнгәннәрне, ятарга тырышканнарның һәркайсына кизәнеп, кайсының сыртына, кайсының башына, кайсының йөзенә орырлар. Атлап баручыларның барысы да ялангач, барысы да ир түгел, берсе дә хатын түгел, барысы да җәрәхәт эчендә, барысы да кан эчендә. Газапланучы кешеләрнең күплеген күзләр генә сыйдыра алмый, өстән карап күзәтеп торучы фәрештәләргә алар ничә миллион башлы бер җәнлек кенә булып күренәдер.

Күп кайгыдан барысының да фикере чуалган, барысының да кара кан баскан күзләреннән әллә нинди, бу дөньяда булмаган, сарылы, яшелле эрен кеби яшьләре мөлдер-мөлдер агып торыр, барысының да аркаларында зур-зур бөкреләр чыгар... Кыйшайган авызларыннан бу дөньяда ишетелмәгән каты газап тавышлары чыгып, үткен ташлар илә капланган очсыз-кырыйсыз сахраны тутырырлар. Газапланучылар арасында ата булган кеше баласын танымас. Күзләре тонган хайван күзләре илә үз хатынына, тутасы-сеңлесенә, абзасы-энесенә туры караса да, танымас, хәтерли алмас. Таныса да, үзенең күп булган хәсрәтеннән, янына килеп ярдәм сораган кардәшенә җәрәхәтләнеп беткән йодрыгы белән кызганмыйча сугып егып алга таба барыр. Тирә-ягы күзләреннән аккан яшьләре илә бөтен дөньяны чылатырга җитәр иде. «Тиз булыгыз, бичара бәндәләр, мизанга нәүбәтегез җитә!» — дигән көчле аваз ишетелер. Мизан-үлчәүнең теге ягында сыйрат күпере күренер.

Коръән Кәримнең «әл-Каригә» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ۝ اَلْقَارِعَةُ ۝١ مَا الْقَارِعَةُ ۝٢ وَمَآ اَدْرٰيكَ مَا الْقَارِعَةُ ۝٣ يَوْمَ يَكُونُ

النَّاسُ كَالْفَرَاشِ الْمَبْثُوثِ ۝٤ وَتَكُونُ الْجِبَالُ كَالْعِهْنِ الْمَنْفُوشِ ۝٥ فَاَمَّا مَنْ ثَقُلَتْ مَوَازِينُهُ ۝٦

فَهُوَ فِي عِيشَةٍ رَاضِيَةٍ ۝٧ وَاَمَّا مَنْ خَفَّتْ مَوَازِينُهُ ۝٨ فَاُمُّهُ هَاوِيَةٌ ۝٩ وَمَآ اَدْرٰيكَ مَا هِيَهْ ۝١٠ نَارٌ حَامِيَةٌ ۝١١

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әл-каариган (1). Мәл каариган (2). Үә мәә әдераакә мәл каариган (3). Йәүмә йәкүүнүннәәсү кәлфәәраашил мәбесүүс (4). Үә тәкүүнүл җибәәлү кәлгиһнил мәңфүүш (5). Фә-әммәә мәңсәкуләт мәүәәзиинүһ (6). Фәһүә фии гиишәтир-раадыйәһ (7). Үә әммәә мән хаффәт мәүәәзиинүһ (8). Фәүммүһү һәәүийәһ (9). Үә мәә әдераакә мәәһийәһ (10). Нәәрун хәәмийәһ (11)».

М ә г ъ н ә с е : *«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Җирне вә күкләрне кырып бетерүче кыямәт көне! (1). Никадәр каты, куркынычлыдыр ул кыямәт көне! (2). Ул кыямәт көненең катылыгы вә куркынычы ни дәрәҗәдә икәнлеген сиңа кем белдерде? (3). Ул көндә кешеләр каты куркуларыннан туздырылган чикерткәләр кебек таралышып бетәрләр һәм бер-берсен күрмәсләр (4). Вә таулар буялган вә теткәләнгән йон шикелле булырлар (5). Берәүнең, ягъни мөселманның, үлчәүдә гөнаһысына караганда савабы күбрәк булса (6), ул мөселман җәннәттә, рәхәт тормышта булыр (7) вә берәүнең мизан-үлчәвендә савабына караганда яманлыгы күбрәк булса (8), аның анасы — һавийә исемле җәһәннәмдә аның урыны булыр (9). Ул һавийәне нәрсә белдерде? (10). Ул һавийә — кыздырылган уттыр (11)».*

Коръәннең «әл-Кәһеф» сүрәсе, 48 нче аяти кәримәдә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَعُرِضُوا عَلٰى رَبِّكَ صَفًّا لَقَدْ جِئْتُمُونَا كَمَا خَلَقْنٰكُمْ اَوَّلَ مَرَّةٍ بَلْ زَعَمْتُمْ اَلَّنْ نَجْعَلَ لَكُمْ مَوْعِدًا ۝٤٨

«Үә гүридүү галәә Раббикә саффә. Ләкаде җиэтүмүүнәә кәмәә халәкунәәкүм әүвәлә мәрратим-бәл зәгәмтүм әлләннәҗгәлә ләкүм-мәүгидә (48)».

М ә г ъ н ә с е : *«Кубарылгач, саф-саф итеп Раббыңа тапшырылырлар. Тәхкыйк, хозурыбызга килдегез, әүвәлдә халык*

*кылганыбыз кеби, ялангач хәлегездә, бәлки сез уйладыгыз каберләрегездән кубарырбыз дигән вәгъдәбездә тормабыз, дип (48)».*

Күп вакыт үтмәс, мизанга барып җитәрләр. Биредә һәр кавемнең үз пәйгамбәрләре дә булыр. Мизанда сөаль бирүче фәрештә: «Йә, бәндә! Сине Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә сыйратка хөкем кылды», — дип әйтүенә гөнаһлы бәндәне фәрештәләр сыйратка таба алып китәрләр. Чиратта торган икенче бәндә янына килеп: «Йә, бәндә! Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләне бар һәм бер дип бөтен калебең илә танып ышанадыр идеңме?» — дип сөаль бирер. Бәндә каушар... Каушаса да: «Танып белә идем. Алай да кеше сүзенә ышанмыйча, үз фикерем илә эзләп, уйлап эш итә идем», — дияр. Ике җилкәдәге фәрештә бу бәндәнең гамәл дәфтәрен мизанга куярлар, изгелек ягы авыр килер. Сөаль алучы фәрештә бер секундка юкка чыгар, янә шатлыклы рәвештә пәйда булыр вә әйтер: «Йә, бәндә! Сине Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә ярлыкады. Сиңа җәннәт юлы вә җәннәт ишекләре ачык, бар, кер», — дияр. Аның янына ике фәрештә килеп, аны җәннәткә алырлар.

Фәрештә, алда торучы хатын янына килеп: «Йә, бәндә! Аллаһы Тәгаләне бар вә бер дип калебең илә ышанадыр идеңме?» — дип сөаль бирер. Хатын сыгылыр, калтырый башлар, калтыраса да: «Ышанадыр идем! Ышанадыр идем!» — дип җавап бирер. Фәрештә хатынның күзләренә: «Йә, күзләр! Ни күрдегез? Ни карадыгыз? — дияр. Күзләр, аска карап: «Оялабыз», — диярләр. Фәрештә хатынның колакларына: «Йә, колаклар! Ни тыңладыгыз?» — дияр. Колаклар сөкут, ягъни дәшми тын торырлар вә салынып төшәрләр... Фәрештә хатынның теленә: «Йә, тел! Ниләр сөйләдең?» — дияр. Тел: «Гайбәттән башка бернәрсә дә сөйләмәдем», — дип җавап бирер. Фәрештә хатынның аякларына: «Йә, аяклар! Нинди җирләрдә булдыгыз? Кай җирләргә бардыгыз?» — аяклар сөкут итәрләр. Гамәл дәфтәрләрен мизанга куярлар, бозыклык ягы авыр килер. Фәрештә юкка чыгар, янә бер секундта кайгылы рәвештә пәйда булыр вә: «Йә, бәндә! Сине Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә сыйратка хөкем кылды», — дип әйтүенә, ике тәртип саклаучы фәрештә килеп, хатынны сыйрат күперенә сөйрәп алып китәрләр. Хатын, кылдан нечкә, кылычтан үткен булган сыйрат күпереннән берничә адым атлау белән, җәһәннәмгә төшеп китәр.

# СОҢГЫ СҮЗ

Мөхтәрәм кардәшләр! Насреддин бине Борһанеддин Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» һәм башка «Пәйгамбәрләр тарихы» китапларында пәйгамбәрләрнең һәркайсы авыр хезмәт белән, ягъни Аллаһы Тәгаләнең әмерләрен җиренә җиткерү өчен гомерләрен дә кызганмаганнарын күрәбез. Аларның кайсысы игенче, кайсысы терлекче, кайсысы сәүдәгәр булган. Аллаһы Тәгалә «Нәҗем» сүрәсе, 39–41 нче аятьләрдә әйтә:

وَاَنْ لَيْسَ لِلْاِنْسَانِ اِلَّا مَا سَعٰى ﴿٣٩﴾ وَاَنَّ سَعْيَهُ سَوْفَ يُرٰى ﴿٤٠﴾ ثُمَّ يُجْزٰيهُ الْجَزَاۤءَ الْاَوْفٰى ﴿٤١﴾

«Үә әлләйсә лил иңсәәни илләә мәә сәгә (39). Үә әннә сәгйәһү сәүфә йүра (40). Сүммә йүззәә йәһүл-җәзәә-әл әүфә (41)».

Мәгънәсе: *«Дәхи кешегә һичнәрсә юктыр, мәгәр үзе кәсеп иткән нәрсәсе генә бардыр (39). Әлбәттә, һәрбер кешенең кәсеп иткән савабы һәм булган гөнаһлары тиздән ахирәт үлчәвендә күренер (40). Моннан соң аңа савабына һәм кылган гөнаһларына күрә тулысынча җәзасы бирелер (41)».*

Ислам дине Адәм галәйһиссәламнән башлап Мөхәммәд галәйһиссәламгә чаклы дәвердә эшләргә, кәсеп итәргә, ризык эзләргә куша. Динебез башкаларның хакына тимичә, хәрамнәрдән сакланып эшләнелгән һәртөрле эшне хәләл дип саный.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам үзенең бер хәдисендә: «Кеше үз кул көче белән эшләп тапкан ризыгыннан да хәерлерәк аш ашамады. Дауд пәйгамбәр дә үз кулы белән эшләп ашый иде», — дигән (Мөслим, Нәвави).

Теләнеп йөрү, хәер сорау, ялкаулык — болар барысы да Ислам динендә хәрам, ягъни тыелган. Чөнки алар мөселманны рәнҗетә, аның кадерен төшерә. Әз генә булса да, иң гади эшне эшләп ашау теләнүдән өстенрәк икәнен күрсәтеп, сөекле Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам әйткән: «Сезнең берегезнең җеп алып урманга барып, утын кисеп, аны сатып, шул акча хисабына яшәве — башка кешеләрдән сорап йөрүеннән хәерлерәк» (Нәвави. «Рийәдус-салихин»).

Эш — динебездә гыйбадәт буларак кабул ителгән, ягъни гыйбадәт белән хәләл хезмәт арасында аерма бик аз.

Шулай бервакыт Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вәссәлам сәхабәләре белән утырып торган җирдән озын буйлы, эре гәүдәле бер ир кеше үтеп китә. Сәхабәләр аңа карап: «Эх, бу кеше үзенең көчен Аллаһы Тәгалә юлында сарыф итсә, нинди яхшы булыр иде», — диләр. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам, аларга карап: «Әгәр бу

кеше балаларына ризык табар өчен чыккан булса, ул Аллаһы Тәгалә юлында, әгәр ата-анасының ихтыяҗларын канәгатьләндерер өчен чыккан булса, ул Хак Тәгалә юлында. Әгәр икмәген кәсеп итәр өчен чыккан булса, ул болай да Аллаһы Тәгалә юлында инде. Әгәр тәкәбберләнеп башкаларга үзенең гәүдәсен, көчен күрсәтер өчен чыккан булса, ул шайтан юлында», — дигән (Рагиб Исфаһани. «Әт-Тәргиб үәт-Тәргиб»).

«Кабил вә Һабил кыйссасы»нда да игенче Һабил үзе эшләгәненең яхшы нәтиҗәсен күрә, ягъни яхшы эшләр эшләсәң — файдасын һәм әҗерен, начар эшләр эшләүче Кабил — зарарын һәм җәзасын күрә.

Коръән Кәримдә һәм Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең хәдисләрендә әйтелгән кебек, кеше сөйләгән сүзләре өчен дә, эшләгән эшләре өчен дә җавап бирәчәк.

Шулай булгач, ничек эшләргә кирәклеге дә билгеле. Хәләл булган эшне генә эшләү, хәләл булмаган кәсепне инкарь итү, тапкан малны һәм кулга кергән акчаны хәләл юлларда гына сарыф итү — болар мөселман өчен иң әһәмиятлесе булырга тиеш. Кеше малына кул сузу, урлау, ришвәт алу, алдап сату, үлчәгәндә ким бирү — болар барысы да хәрам. Мондый гамәлләр өчен «Кыйссасел- әнбия» китабында Аллаһы Тәгаләнең Һуд, Салих, Лут һ.б. пәйгамбәрләрнең кавемнәрен ничек җәзалаганын күрдек.

Рәсүлебез саллаллаһу галәйһи вәссәлам янындагы сәхабәләр авыр вакытларда бөтен көчләре белән Исламга хезмәт иттеләр. Аларга Хак Тәгалә сынау өстенә сынау бирде. Бу шулай кирәк иде, чөнки бөтен өммәткә остаз буласы кешеләрнең бик нык иманлы вә сабыр булулары кирәк иде. Алар Җәнабел Хак юлында үзләренең иң соңгы дирһәмнәрен дә һич авырсынмастан бирә иделәр. Аларның бу чорда күрсәткән ярдәмнәренә Газзә вә Җәллә тарафыннан зур бәя бирелде. Алар үзләреннән соң киләчәк буыннарга иман ягыннан, тәкъвалык ягыннан күркәм үрнәк булып торалар. Аларны сөю, пәйгамбәрләрне сөю кебек — иман галәмәте, аларны сүгү — көферлек галәмәте. «Әт-Тәүбә» сүрәсенең 100 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَالسَّٰبِقُونَ الْأَوَّلُونَ مِنَ الْمُهَٰجِرِينَ وَالْأَنصَارِ وَالَّذِينَ اتَّبَعُوهُم بِإِحْسَٰنٍ رَّضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ
وَرَضُوا عَنْهُ وَأَعَدَّ لَهُمْ جَنَّٰتٍ تَجْرِي تَحْتَهَا الْأَنْهَٰرُ خَٰلِدِينَ فِيهَا أَبَدًا ذَٰلِكَ الْفَوْزُ الْعَظِيمُ ۝١٠٠

«Үәссәәбикунәл әүвәлүүнә минәл-муһәәҗириинә үәл-әңсаари үәлләзиинәт-тәбәгүүһум би ихсәәнир-радыйаллааһү гәнһүм үә радуу гәнһү үә әгәддә ләһүм җәннәтиң тәҗрии тәхтәхәл-әнһәәру хаалидиинә фииһәә әбәдәң зәәликәл-фәүзүл-гәзыййм (100)».

М ә г ъ н ә с е : *«Мөһаҗир вә ансарлардан булган беренчеләрдән һәм яхшылыкта аларга ияручеләрдән Аллаһы Тәгалә разый булды, алар да Хак Тәгаләдән разыйлар. Аларга Аллаһы Тәгалә асларында*

*елгалар агып торучы җәннәтләрне әзерләде, алар анда мәңге калырлар. Бу — зур уңышка ирешүдер (100)»*.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең хәдисеннән дәлил: «Ләә тәсүббүү әсъхәәбии фәүәлләзии нәфсии бийәдиһии ләү әннә әхәдәкүм әңфәка мисләә үхүдин зәһәбән мәә бәләга мүддә әхәдим үә ләә нәсыййфәһ».

М ә г ъ н ә с е : *«Минем сәхабәләремне сукмәгез, җаным Аның кулында булган Зат белән ант итеп әйтәм, әгәр сезнең берәрегез Өхед тавы кадәр алтынны садака кылып бирсә дә, бу аларның бер мүд, хәтта аның яртысы микъдары кадәр биргән садакаларының дәрәҗәсенә дә тормас»*.

«Кыйссасел-әнбия» китабыннан күргәнебезчә, пәйгамбәрләр — Аллаһы Тәгаләнең әмер вә тыюларын инсаннарга өйрәтер өчен җибәрелгән хак илчеләр. Беренчесе — Адәм галәйһиссәлам, ахыргысы исә — безнең Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам

Җәнабел Хак Үзенең китабы Коръән Кәримгә иярүне фарыз кылган кебек, Рәсүлебез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең сөннәтенә иярүне дә фарыз кылды. Ул Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламгә итагатьне Үзенә булган итагать белән тиңләде. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам алып килгән нәрсәгә иярмәгән кешенең калебендә иман юк димәктер.

«Хәшер» сүрәсенең 7 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَمَآ اٰتٰيكُمُ الرَّسُولُ فَخُذُوهُ وَمَا نَهٰيكُمْ عَنْهُ فَانْتَهُوا

«Үә мәә әәтәәкүмүр-расүүлү фәхузүүһү үә мәә нәһәкүм гәнһү фәңтәһүү (7)».

М ә г ъ н ә с е : *«Аллаһы Тәгаләнең Рәсүле сезгә нәрсәне алып килгән булса, шуны алыгыз, сезне нәрсәдән тыйган булса, шуннан тыелыгыз! (7)»*.

Ислам диненең нигезен Хак Сөбханә вә Тәгаләнең изге китабы Коръән Кәрим һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең сөннәте тәшкил итә. «Нәрсә соң ул сөннәт?» дигән сорау туа. Сөннәт туры мәгънәсендә гореф-гадәт дигән сүз. Гомумән алганда, сөннәтнең асылын болай аңлатырга була. Коръән Кәрим, мөселманнарга Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелеп, дини кагыйдәләрне билгели, ә сөннәт исә шулар белән ничек эш итәргә икәнен күрсәтә.

Сөннәтнең нигезендә хәдисләр ята. Хәдисләр Мөхәммәд галәйһиссәламнең тормыш-яшәешенә кагылышлы аерым риваятьләр вә аның теге яки бу нисбәттә әйтелгән сүзләреннән гыйбарәт.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам үзен гади кеше дип санаган һәм үзен бервакытта да хатадан хали кеше дип расламаган. Ләкин аның шәхси абруе шулкадәр зур булган ки, барча эш-

гамәлләре дә, әйткән сүзләре дә мөселманнарга үрнәк вә кагыйдә булып торырга тиеш.

Хакыйкый, ягъни чын вә дөрес дип табылган хәдисләр тупланган берничә җыентык бар. Шуларның иң абруйлылары: «Сахих әл-Бохари», «Сахих әл-Мөслими», «Сөнәнә Әбү Дауд», «Җәмигъ Әт-Тирмизи», «Мөҗтәба Ән-Нәсаи», «Мәснәд Әд-Дарәми», «Әбү Һурайра», «Әл-Мәүтаи», «Ән-Нәвави» һәм башкалар.

Хәдисләр язып алынганнар, китапларга җыйналып теркәлгәннәр. Аларны күчерүче ышанычлы имамнар ул хәдисләрне риваять итүчеләрнең бер-бер артлы тәртип белән тезелгән исемлеген күрсәтеп, махсус хәдис мәҗмугалары төзеп калдырганнар. Соңгы буын кешеләренең күңелгә алу вә күңелдә саклау даирәләре тараю, һиммәтләре, иҗтиһадлары азаю сәбәпле, риваять кылучыларның исемлеге онытылыр дип курыкканнар алар. Шунлыктан соңгы гасырларда хәдис өйрәнүнең бердәнбер юлы булып ышанычлы имамнарның китапларына мөрәҗәгать итү кала. Алар дөрес дип таныганнар — дөрес, зәгыйфь дип таныганнары — зәгыйфь булып санала. Әмма равиләрнең хәлләре хакында бәхәскә керешү безнең заманыбыз өчен кыен мәсьәлә булып тора. Чөнки алар белән безнең арада бик күп заманнар узган, бик күп арадашчылар яшәп киткән. Шуңа күрә могтәбәр сөннәтләргә мөрәҗәгать кылган чакта, ул хәдиснең мөәллифенә, ягъни төзүчесенә җиткәнче, ни исемле равиләрнең бер-бер артлы күчерә килгәнлекләрен исемнәре белән китерү шарт итеп куелмый. Хәдисне ишетүче вә тыңлаучыларның шул хәдис белән гамәл кылулары тукталмасын вә хөкем йөртүләр бозылмасын өчен фәкыйһлар җәмәгате шул юлны тотканнар.

Ислам хөкемнәре турында дәлил — Коръән Кәрим илә сөннәт, ягъни Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәламнең әйткән сүзләре. Әгәр дә болардан, ягъни Коръән белән хәдисләрдән анык дәлил табылмаса, ул вакытта «иҗмагъ», ягъни «бер карарга килү» белән «кыяс», ягъни «чагыштыру» да дәлил була ала. Беренче маддәдә телгә алынган нәрсәләр гомуми вә дөньяви эшләр хакында гына дәлил булалар. Коръән вә сөннәт Ислам хөкемнәренең һәрбере өчен дәлил булып торалар. Дөньяви эшләрнең дә Ислам хөкемнәре турында дәлил булырга тиешле урыннары күп. Шуның өчен беренче маддәдәге нәрсәләр турыдан-туры Ислам хөкемнәре хакында дәлил хисап ителмәсәләр дә, берәр нәрсә ярдәмендә дәлил була алулары ачык вә мәгълүм.

«Шәргый дәлил»нең, ягъни «шәригатьчә дәлил»нең ышанычлылыгы да, дәлиллеге дә шөбһәсез булса, аны «катгый дәлил» диләр. Шуннан башка күренешләрнең һәрбере «дәлил занни», ягъни «анык булмаган дәлил» исемендә булыр.

Рәсүлулла заманында булган мөселманнар өчен Рәсүл Әкрамның үзеннән ишеткән сүзләр хис илә мәгълүм булганлыктан, катгый

рәвештә аныктыр. Әмма туры үзеннән ишетмәгәннәр өчен халык телендә күп сөйләнгән хәбәр белән генә ирешсә, катгый рәвештә анык булмас. «Катгый дәлил» булыр өчен шул хәбәрнең дәлиллеге дә катгый булу шарт.

Сөннәт — Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәламнең шәргый хөкемнәргә мөнәсәбәтле вә дин әмерләрен ирештерү хакында булган сүзләреннән вә фигыльләреннән гыйбарәт булып, болардан әүвәлгесе «сөннәте каулия», ягъни «сүздәге сөннәт» вә икенчесе «сөннәти фигълия», ягъни «эштәге сөннәт» дип атала. Сөннәт — шәригать ирештерүче затның дини эшләре хакында булган сүзләреннән, шулай ук бер эшне үзенең кылуы яки башкаларның кылуларын күреп торган хәлдә аңа теләктәшлек кылудан гыйбарәттер. Рәсүл Әкрам саллаллаһу галәйһи вәссәлам дингә бәйле булган эшләрнең бөтенесен өммәткә ирештерде вә башкалар тарафыннан кушарга кирәк нәрсә калдырмады. Шушы ирештерү рәвешенең Коръән Кәримнән башка бүлеге гомумән сөннәт дип атала. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең сөннәтләрен сәхабәләр вә алардан табигыйннәр, ягъни сәхабәләргә иярүчеләр, алардан соң, аларга утырышташ булган галимнәр риваять кылып тордылар вә тарихта мәҗмуга-китаплар рәвешендә тәртип кылдылар. Һиҗри белән икенче гасырда, ягъни милади белән сигезенче гасырда бу мәҗмугалар шактый күбәйде, бик күп хәдис китаплары каләм белән дә язылып, күңелдән белү белән дә таралды. Һәр җәһәттән камил булган олуг хәдис китаплары язылу сәбәпле, әүвәлгеләре онытылды. Иң кабул ителгәннәре «Сахих әл-Бохари» вә аннан соң «Сахих әл-Мөслими»-дер. Калганнары арасында күп аерма бар. Болар да хәдисләр риваять итмешләр вә мәҗмугалар тәртип кылмышлардыр: Әхмәд ибне Хәнбәл, Әд-Дәрами, Әл-Бәззар, Әбү Йәгълә, Ибне Хазимә ән-Нисабури, Әбү Гавәнә, Әт-Тахави, Әт-Табрани, Ибне Гаддә, Ибне әс-Сөнни, Әд-Даркатни, Әбү Нәгыйм, Әл-Хәким, Әл-Бәйһакый һ.б.

Хәдис риваяте тугрысында арадашчылар аз булу бик кыйммәтле саналадыр. Арадашчылар никадәр күп булсалар, хәдиснең дәрәҗәсе шулкадәр төшә, ә никадәр аз булса — шулкадәр күтәрелә барадыр.

Бәгъзе бәндәләр Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәламнең хәдис-шәрифләрен дәва итеп куллана. Моның хакында Ибне Халдун әйткән: «Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәламнән күчерелгән дәвалар вә тыйбка бәйләнешле нәрсәләр вәхи, ягъни күктән иңдерелгәннәр җөмләсеннән түгел, бәлки алар шул вакыттагы тәҗрибә вә гадәтләргә нигезләнгән нәрсәләр иде. Мәгълүмдер ки, Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәлам тыйбб вә шуңа охшаш нәрсәләр өйрәнер өчен түгел, бәлки шәригать вә дин өйрәтер өчен җибәрелде. Шуның өчен, сахих (дөрес) хәдисләрдә бәян ителгән дәваларны шәригатьчә сөннәт гамәлгә йөкләргә тиеш түгелбез.

Мәгәр дә Рәсүлуллаһ кушкан дәваларны тыйбб җәһәтеннән түгел, бәлки бер олылау нияте белән кабул итсәк, бу — башка мәсьәлә. Игътикады, ягъни инануы камил булган бәндәләргә ошбу дәваның, ихтимал, файдасы да булыр».

Газиз кардәшләрем! Пәйгамбәрләр тыйб, хисап, риязыят кебек фәннәр өйрәтү өчен җибәрелгән булсалар, адәм балаларының гакыллары, хисләре, бәйсезлекләре бөтенләй юкка чыгарылып, алар дөньяви эшләрнең дә һәрберендә пәйгамбәр өйрәтүе буенча гына йөрергә тиеш булырлар иде. Җир йөзендә хәлифәлек кылыр өчен таратылган инсаннар хакында моның мөмкин түгеллеген һәркем белсә кирәк.

Сөннәт — Коръән белән хәдиснең һәр икесен бергә җыеп, икесе белән дә гамәл кылу. Әгәр дә инде мондый мөмкинлек булмаса, бу вакытта хәдис шул хәленчә калып торыр, Коръән Кәрим белән генә гамәл кылыныр.

Телдән сөйләнгән сөннәтнең вакытлы гына шәригать булуын дәгъва кылучылар күрелсә дә, дикъкать җәлеп итәрлек дәлилләр китерә алмаганлыктан, дәгъвалары кабул булмыйдыр. Кайбер адәмнәр «телдән сөйләнгән сөннәт»тән булган «хәбәре вахид», ягъни «бердәнбер хәбәр»нең шәригатькә бәйле дәлил булуын инкарь итеп, аның дәлил булмавы сәбәпле Ислам диненә кимчелек килмәвен дәгъва иттеләр. Боларның ышандыргыч дәлилләрен ошбу маддәләргә җыярга мөмкин:

1) Бер ялганчының үзенең мәкере вә үткенлеге белән үзен дөрес сүзле дип күрсәтергә кулыннан килә һәм бу әшәке адәм, икейөзле монафикъ, үзен гадел адәм итеп күрсәтә ала. Икейөзлелек вә монафикълыкта эшләре булмаган һәм үзләреннән башкалар турында яхшы уй уйлауны гадәт һәм кешелеклелек вазыйфасы кылган саф затларның шушындый адәмнәргә алданулары һәм шул сәбәпле әлеге кешеләрнең хәдисләрен беренче дәрәҗәдә санап күчерүләре мөмкин.

2) Хәдисләрнең фәкать мәгънәләре белән генә күчерелгәннәре була, хәтта сүзтезмәләре белән күчерелгән хәдисләргә караганда, фәкать мәгънәләре белән генә күчерелгән хәдисләр күбрәк булса кирәк. Мәгънә белән сүз күчерүчеләр, гадәттә, сөйләүче максатыннан бигрәк, үз аңлауларына карап аңлаталар һәм җөмләләрне үз төшенүләренә карап үзгәртәләр. Бу тәкъдирдә әһәмиятле булган бер кәлиманең мәгънә җәһәтеннән бозык булган икенче бер кәлимә белән алмашынуы мөмкин.

3) Риваятьчеләрне ялганга чыгару, мәсәлән: мөселманнар җәмәгате Әбү Һурайра радыйаллаһу ганһәгә: «Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәссәлам белән өч кенә ел торган хәлдә шулкадәр күп хәдисләрне күчерергә мөмкинлек юк», — дигәннәр һәм үзенә дә: «Берүзең генә ничек бу кадәр күп хәдис риваять итәсең, шул хәдисләрне Рәсүлулла саллаллаһу галәйһи вәссәламнән бер ялгы-

зың гына ишеттеңме? Иптәшләрең булса, алар кемнәр иде?» — дип теңкәсенә тия торган булганнар.

«Мизанүл игътидал» («Уртача үлчәү») китабының 3 нче җилд, 21 нче сәхифәсендә болай диелгән: «Бөтен гыйльми тарихларның дөньяга таралуына сәбәпче булырлык дәрәҗәдә хезмәт итүче Мөхәммәд бине Исхакка («Әл-Мәгази» китабының авторы) бәгъзе хәдисчеләр, хәдис галимнәренең иң олыларына бирелә торган «әмирел-мөэминин», ягъни «мөэмин-мөселманнарның хуҗасы» дигән дәрәҗәне биргәннәре хәлдә, икенчеләре исә аны «әкзәбен-нәс», ягъни «иң ялганчы кеше» рәвешендә хурлаганнар».

Бер фирка, ягъни бер төркем халык тарафыннан динсезлектә гаепләнеп, башы киселергә хөкем ителгән мәшһүр хәдисче Ибне Хаббанны икенчеләре «әлхафиз, мин әиммәти заманиһи», ягъни «Коръәнне яттан белүче, үз заманының имамнарыннан» дип мактаганнар.

«Мизанүл игътидал» китабының 2 нче җилд, 6 нчы сәхифәсендә Әхмәд Ибне Хәнбәл шәехе булган Гамир бине Салих бине Габдулла бине Гарвәт бине әз-Зөбәер бине Гавам хакында Яхъя бине Могыйн: «Кәззәб хәбис», ягъни «бик әшәке ялганчы», — дигән. Әхмәд Ибне Хәнбәл шәехе хакында шундый сүз булгач, башкаларга ни кала?

Инде шулай булганнан соң, «сөннәте каулия», ягъни «телдән сөйләнә торган сөннәтләр»дән хәбәре вахидлар (бердәнбер хәбәрләр) ничек дәлил була алырлар икән? Моңа тәфсилле җавап шушыдыр: икейөзлелек вә монафикълык сәбәпле бер-ике яхшы күңелле кеше алдану мөмкин булса да, бу эшнең бөтен халыктан яшерелеп калуы мөмкин түгел. Булган ялганны төзәтүче галимнәр бер-ике кешедән генә гыйбарәт булмыйча, бәлки хисапсыз күп Ислам галимнәреннән гыйбарәттер. Шулар хезмәте илә табылган гаделлек илә сидкъ, ягъни намуслылык — һәрберсе Хак Тәгалә каршында мөхтәрәмдер. Хәтта бүгенге мәдәниятле кавемнәр саф вөҗдан илә ышанычлы дәлилләр белән хөкем йөртерләр һәм шуларга таянып гыйбадәтләрен кылырлар. Мәхкәмәләргә чакырылучы галимнәр, докторлар үз фәтвалpointsларын, аңлатмаларын шәригать хөкеменә нигезләп бирәләр, хөкем йортлары, шушы фәтваларга таянып, һәртөрле хөкемнәр игълан итә. Фәтва-аңлатма бирүче әлеге галимнәр, үз фәтваларын шәригатькә нигезләүләре сәбәпле, һәртөрле шикләнүләрдән һәм ачык булмаган уйлардан сәламәт сакланалар.

Газиз кардәшләрем! «Кыйссасел-әнбия, ягъни пәйгамбәрләр тарихы» китабын тәмамлап, шуны әйтәсем килә, Рәсүлебез саллаллаһу галәйһи вәссәлам тарафыннан әйтелгән һәрбер сүз яки кылынган эш, әгәр аларга кешеләр иярсен дигән максатны күздә тоткан булса һәм безгә сахих риваятьләр белән килеп җиткән булсалар, дәлил-хөҗҗәт саналып, алар белән гамәл кылу таләп ителә.

Үәссәламүгаләйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ!

*Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк.*

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз ... 3
Дөнья яратылуы кыйссасы ... 9
Адәм галәйһиссәлам кыйссасы ... 12
Кабил вә Һабил кыйссасы ... 32
Шис галәйһиссәлам кыйссасы ... 39
Идрис галәйһиссәлам кыйссасы ... 43
Нух галәйһиссәлам кыйссасы ... 53
Һуд галәйһиссәлам кыйссасы ... 64
Салих галәйһиссәлам кыйссасы ... 71
Лут галәйһиссәлам кыйссасы ... 81
Ибраһим галәйһиссәлам кыйссасы ... 90
Исмәгыйль галәйһиссәлам кыйссасы ... 100
Исхак галәйһиссәлам кыйссасы ... 109
Ягъкуб галәйһиссәлам кыйссасы ... 115
Йосыф галәйһиссәлам кыйссасы ... 120
Әюб галәйһиссәлам кыйссасы ... 130
Шөгаиб галәйһиссәлам кыйссасы ... 145
Муса галәйһиссәлам кыйссасы ... 151
Дауд галәйһиссәлам кыйссасы ... 166
Сөләйман галәйһиссәлам кыйссасы ... 175
Юныс галәйһиссәлам кыйссасы ... 186
Ильяс галәйһиссәлам кыйссасы ... 193
Әльясәгъ галәйһиссәлам кыйссасы ... 196
Локман галәйһиссәлам кыйссасы ... 201
Гөзәер галәйһиссәлам кыйссасы ... 209
Әрмия галәйһиссәлам кыйссасы ... 213
Зәкәрия галәйһиссәлам кыйссасы ... 217
Яхъя галәйһиссәлам кыйссасы ... 222
Зөлкарнәен галәйһиссәлам кыйссасы ... 225
Зөлкифел галәйһиссәлам кыйссасы ... 234
Гайсә галәйһиссәлам кыйссасы ... 242
Мөхәммәд галәйһиссәлам кыйссасы ... 249
Кыямәт кыйссасы ... 289
Соңгы сүз ... 297

**© «Раннур» нәшрияты, 2003.**